ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Фәрит Яхин**

# ӘДӘБИ СҮЗ ХАКЫ

Казан
2020

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2=632.3)**
**Я 90**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни мөхәррир**
*филология фәннәре докторы* **Ә.М. Закирҗанов**

**Бәяләүчеләр:**
*филология фәннәре кандидаты* **Ф.Х. Миңнуллина;**
*филология фәннәре кандидаты* **Л.Р. Надыршина**

**Яхин Ф.З.**
**Я 90** Әдәби сүз хакы / Ф.З. Яхин. – Казан: ТӘһСИ, 2020. – 400 б.
ISBN 978-5-93091-321-7

Татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен өйрәнүгә һәм бәяләүгә багышланган хезмәтләр тупланмасыннан гыйбарәт бу китапта әдипләрнең иҗат үзенчәлекләре аңлатыла һәм бәяләнә, заманча эстетика һәм әдәбият гыйлеме фикерләмәләре тәкъдим ителә, аерым мәкаләләрдә авторның иҗтимагый тормышка һәм сәнгатькә бәйле уйланулары әдәбият белеме һәм әдәби-тәнкыйть, фәнни-тәнкыйди караш кысаларында бирелә.

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2=632.3)**

**ISBN 978-5-93091-321-7**

© Яхин Ф.З., 2020;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2020

# АҢЛАШЫРБЫЗ ДИП БЕЛӘМ

*(Башлам сүз урынына)*

Әдәби сүз кечкенә мәсьәлә түгел. Ул – зур сүз! Җәмгыять тормышын әдәби сүз тәртипкә салып, төзәтеп һәм хәтта оештырып бару көченә ия. Г. Бәшировның «Намус» романы Бөек Ватан сугышыннан соң татар халкын гына түгел, бөтен бер советлар иленә ничек яшәгәндә алга таба дөрес һәм матур булачагы сереннән сурәтләр биреп, күңелләргә дәрт өстәр өлеш биргән. Ул бөек әсәр хакында: «Безне хезмәт дәртенә, яшәү яменә чакырды», – диләр иде шул заман кешеләре. Югыйсә роман сугыш чорындагы тыл тормышын яктырткан. Ә шулай да халык янәшәдә фронт сызыгы барлыгын хәтта фашистлар явын җиңгәннән соң да озак вакытлар оныта алмады.

Татар әдәбияты бай һәм бөек ул. Иҗтимагый әһәмиятләре чиксез булган андый әдәби әсәрләребез шактый. Мисалга М. Фәйзинең «Галиябану» драмасын, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестен, Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» кебек, киштәлекләр түрендә торган китапларны гына атасак та җитәр, барысы да аңлашыла башлый. Ул шигырьләр, поэмалар... Саннары арткан-нан-арта. Әдәби сүзнең үзкыйммәте чиксез, аны берни белән дә алыштырып булмый.

Укучы игътибарына тәкъдим ителүче шушы җыентыкка әдәбият белеме фәне кысаларында, әмма әдәби тәнкыйтьнең публицистик форматына берникадәр якынаю омтылышы белән язылган хезмәтләр сайлап алынып урнаштырылды. Аларда өлгереп җиткән уй-фикерләр гыйльми анализ таләпләрендә бәян ителәләр. Шул сәбәпле ул мәкаләләрне аерым бүлекләр эчендә бирү, төркемләп берләштерү кирәк табылды.

Бу хезмәтләрнең феноменология фәлсәфәсе нигезендә язылган булуларын да искәртергә кирәктер. Феноменологиянең бөтен

барлыгы белән субъектив идеализмның XX гасырда үсеш алган юнәлешләреннән берсе булуын онытмыйк. Әдәбият белемендә, әдәби тәнкыйтьтә һәм, гомумән дә, дөньяны танып белүдә XXI гасырның беренче чирегендә татар әдәбияты фәнендә дә ул тармакланып ныгыды. Әдәби-мәдәни күренешләрнең асыл үзенчәлекләрен барлауга хезмәт итеп, татар әдәбият белеме фәнендә феноменология соңгы вакытларда аерым агым буларак яши башлады, моны хакыйкатьне тасвирлау кысаларында алып бара, шулар белән идеал белемнәр системасын барлыкка китерә һәм аларны гомумиләштерергә омтылышын күрсәтте. Феноменологиянең асыл хикмәте шунда: ул, өйрәнелә һәм тасвирлана торган өлкәнең формасына һәм эчтәлегенә галимнең бөтен игътибарын бирдереп, шушы вакытта әлеге предмет, күренеш яки барышның асыл үзенчәлеген яисә үзенчәлекләрен билгели һәм шул билгеләве ярдәмендә өйрәнелүче объектның моделен тудыра, аннары бу модельгә объект туры киләме-юкмы – охшашлыкларны һәм аермаларны билгеләү ярдәмендә хакыйкатьне ача яки ачылган итеп күзаллата. Күзаллатуының яхшы ягы шунда: ул алга үсешкә һәм фәнни-тәнкыйди фикерләүгә мөмкинлек бирә.

Җыентыктагы хезмәтләр шактый озак вакытларга сузылган фәнни тикшеренү нәтиҗәләреннән булдылар. Һәммәсен укып, аларга бәя биргәннәре һәм кайбер фикерләргә бәйле тәкъдим иткән әһәмиятле киңәшләре өчен Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге хезмәткәрләренә рәхмәтемне җиткерәм!

# I. ШӘХЕС СҮЗЕ

## Ренат Харисның мәхәббәт шигъриятендә лирик герой

*(Аналитик мәкалә)*

XXI гасырга татар шигърияте XX йөздән шактый киң һәм югары үсештә килеп керде, үзенең дәрәҗәсен, алдынгы юнәлешләрен, табышларын дәвамчылыклы күтәрелештә көчәйтә барды. «Шартлы шигъри идеологик юнәлеш»нең байрагы һәрвакыт шагыйрь Ренат Харис кулында кала бирде. Урта буын шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат һәм башкалар ничек кенә ул беренчелек байрагын үз кулларына алырга теләмәсеннәр, аларның шигъриятендә Р. Хариска хас үзенчәлекләр (уртаклыклар шактый булуга карамастан) җитенкерәмәү аркасында, бу мөмкин хәл түгел иде. Татар әдәби тәнкыйте дә Р. Харисның ул беренчелеген Равил Фәйзуллин белән бүлешүен ничек кенә теләмәсен, шул хакта шактый сүз кузгатып, берсен икенчесенә каршы куюда төрле фикер һәм бәя бирәмлекләрен сайлап бәянлап карамасын, бу беренчелекне Р. Харис шигърияте беркемгә дә бирмәде. Аптырагач, шагыйрьне бернинди төркемгә дә кермәүдә, үзенә бер дәрәҗә һәм үзенчәлек саклавында да дусларча «гаепләделәр». Тормышта Р. Харис үз шигъриятенең дәрәҗәсен һәм мәртәбәсен Р. Фәйзуллинга да, Р. Гаташка да, Зөлфәткә, М. Әгъләмовка да, башка әдипләргә дә каршы куймады. Ул даими үз юлында, һәрвакыт иҗатта булды. Сәяси-идеологик хәрәкәтнең эчендә кайнады, шул ук вакытта, үзе шуның эчендә кайнаган шәхес булып та, демократик үзгәрешләргә читтән торып бәя дә бирә белде. Р. Харис, шул рәвешле, шигырьдә һаман шагыйрь булып кала барды. Тормыш үзгәрешләре аның да үзгәрешләре иделәр, шигъри табышлары да укучыларга барып җитә торды. Шунысы гаять тә әһәмиятле: татар шигърияте өчен моның шулай булуы бигрәк

тә кирәк иде: Р. Харис, татар булсын, рус булсын, бүтән милләтнеке булсын, – һичнинди башка шагыйрьләрне кабатламады. Үз шигъри агымына хезмәт итүенә карамастан, ул һаман да шигырьдә Р. Харис булуыннан туктамады. Моның өчен югыйсә әллә нәрсә кирәк тә түгелдер сыман. Талантың бар икән – шул җиткән. Әмма әдәбият фәне, тәнкыйть сыман фикер йөртеп, мондый бәяләү белән генә чикләнеп кала алмый. Ул шушы талантның эчке һәм тышкы үзенчәлекләрен тикшереп-өйрәнеп, асылын ачыкларга, аларны системага салып аңлатырга, закончалыкларын билгеләргә тиешле.

Р. Харисның беренчелеге һәм шигъриятенең үз көчендә калуының төп сәбәбе, әлбәттә, шагыйрьнең әдәби юлын башта ук таба алуыннан килде. Әүвәле аның шундый булуы аңлашылып та җитмәде. Ул башкаларның иҗат алымнарын кабатлыйдыр сыман иде. Р. Харисны үз әдәби дөньясы, үз шигъри алымнары, үз милли герое, үз идеаллары, үз фикерләве булган чын әдип итеп 1981 елда басылып чыккан «Замана эзләре» шигырьләр җыентыгы күрсәтте. Баксак, ул чор әдәби тәнкыйте аның шушы зур уңышын билгеләргә тырышып та карамаган, хәтта, кызганыч, берничек тә бәяләми калдырган. Сүз премияләр, мактап әйтелгән, искәртелгән сүзләр хакында бармый, бәлки шагыйрьнең иҗат үзенчәлекләрен тану хакында бара.

Хәер, Р. Харисның нинди шагыйрь булуы әле хәзер дә бәхәсләр уяту көченә ия. Мәсьәлә чишелмичә калдырылып киленә. Моны шигъри сәхифәләренең дәвам итүе белән бәйләп тә аңлатып була. Әмма әдәби хронотоп системасы кысаларында караганда, Р. Харисның шигъриятендә, катгый сиземләнүче җирлек булуга бәйсез рәвештә, вакытның чиксезлегенә төбәлгән формалар бар, хәтта, мәсәлән, 80 нче елларда язылып та, аның шигырьләре үткәнгә дә, бүгенгегә дә, киләчәккә дә төбәлгәннәр. Мондый итеп яза белү өчен, монументальлек кирәк. Аңа 60–80 нче елларда Е. Евтушенко, Р. Рождественский кебек рус әдипләре дә омтылды һәм зур әдәби уңышка ирештеләр. Әмма аларның шигърияте монументальлеккә корылса да, шул шигырьләрендәге лирик герой үзе монументальлеккә ия түгел иде. Бу яктан Р. Харис хәтта дөньяда кабатланмас шагыйрь буларак бәяләнергә хаклы.

Алдан ук белдереп куярга тиешбез, безне әдәби тәнкыйть юнәлешендә бәяләп фикерләү кызыксындырмый. Сүзләребез дә

әдәби тәнкыйть кысаларында алып барылмый. Максатыбыз әдәби күренешне ачу, ачыклау, аның закончалыкларын билгеләү белән чикләнә. Шунлыктан фикерләребез иҗатны бәяләү түгел, бәлки аның эчтәлеген аңлатуга корылды. Моның өчен Р. Харисның мәхәббәт шигырьләрендәге лирик герое тикшерелде, шушы тематематика эчендәге әсәрләренә ясаган анализларыбыз шагыйрьнең әсәрләре үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирде, аерым нәтиҗәләргә китерде.

I

Р. Харисның мәхәббәт шигырьләрендә лирик герой өч үзенчәлеге белән истә кала: беренчесе – ул зәңгәр күзле, икенчесе – ул күңеле белән салкын, әмма андагы карларның-бозларның эрүен тели, аны кемдер эретергә тиеш, өченчесе – ул һаман-һаман да мәхәббәткә, үзен яратуларына мохтаҗ. Шушы сыйфатлары белән бу лирик герой М.Ю. Лермонтовның «Безнең заман герое» (1839–1840) романының төп герое Григорий Александрович Печоринны да хәтерләтә. Алардагы уртаклык хис дәрәҗәсендә бара. Әмма чорлары гына түгел, аларның күңел стихияләре дә башка, фикер йөртү үзенчәлекләре дә төрле.

Лирик геройның үз-үзен тоюы Р. Хариста яхшы эшләнгән, ул хәтта кайчан-нәрсә хис итәчәген дә алдан ук белеп тора. Башкалардан үзенә артыкны да таләп итми, алар мәхәббәт, ярату, соклану бирә алсалар, аңа шул да җитә. Тик ул хисләр ихлас, чын йөрәктән генә булсыннар:

Туры кара күзләремә,
Күзең сүзе тәңгәл микән
Телең әйткән сүзләреңә...
(«Күзең буйлап»)

Р. Харисның лирик герое укучыны мәхәббәттәге шушындый өстенлеге белән туктаусыз хәйран итә. Мәхәббәт корбаны кебек күзалланып, ул башкалардан өстен чыга бара. Яратуга ышанырга тели, әмма ышанып та җитә алмый.

Күзләремә туры кара...
Сау бул... Киттем... Күзең буйлап
Ят бер егет үтеп бара...
(«Күзең буйлап»)

Яки:

Синең кулда –
Синең балдак,
Минем кулда –
Минем балдак...

Хисләребезне булмый ялгап –
Балдакларны булмый алдап...
(«*** Яфраксыз урманда...»)

Шигырьләре шартлы билгеләрнең күңел хисләреннән өстен чыгарылуы белән аерылып торса да, Р. Харис иҗаты җәмгыятьтә кешенең бәхете мәсьәләсендә лирик геройның туктаусыз борчылуына аерым басым ясый. Лирик герой бу яктан, ягъни җәмәгатьчелек каршында тәүфыйклы, дөрес кеше образы буларак күз алдына килеп баса һәм үзенә карата укучыдан шушындый ук мөнәсәбәт таләп итү көченә ия булуын сиздерә. Монументаль сәнгатьтә сурәтләрнең кискен һәм үтә туры карашка ия икәнлеге бәхәс уятмый. Татар рәссамы Илдар Хановның сурәтләре шушындый көчкә ия, Константин Васильев (1942–1976), монументаль портретлар ясап, Казан, ә аннары Рәсәй тамашачысының күңелендә соклану хисләрен тудырды, «Мамай курганы»ндагы «Ватан-Ана» һәм башка дистәгә якын монументаль һәйкәлләр дә шундыйлардан.

* * *

Үпкәләттем, ахры, –
Стенага капландың.

Стена миннән җылырак, ахры, бу минутта...

Күзләрем – боз,
Күңелем – таш,
Йөрәгемдә, ахры,
Кар ява...

Эрисем килде –
Сулуым бозга
Әверелде үпкәмдә.

Кичер, иркәм,
Озак эредем –
Суык сүзем
Йөрәгемнән кояшымны
Сөйрәп чыгып киткәнгә.

Бу шигырь – Р. Харисның лирик героен тулы чагылдырган әсәрләреннән берсе. Монда күтәрелгән фикерләр, уйлар, темалар мотив рәвешендә дә, фикер-тема һәм хис буларак та башка шигырьләрендә дә кабатлана, яңадан-яңа төсмерләр, эчтәлек ала. Лирик герой салкын, әмма ул кайнарлык эзли (мәсәлән, «*** Кара миңа буран булып...» шигыре), «кораллы, теләкле» ир үзен чакырган яратканын яулый алмый кала (мәсәлән, «Ничек?» шигыре), сөю хатирәсе калдырып үткән яз, аны яңасы алыштыра, алда яңа бер мәхәббәтме көтә (мәсәлән, «*** Җитте бу яз...» шигыре); яңгыр «бүрттерү» көченә ия, лирик герой моңа шатлана, чөнки барысы да бүртә-арта, анда гаилә кору теләге уяна (мәсәлән, «Яңгыр көзгесе» шигыре); хушлашу, әмма озатканда кул изәп калмау, чөнки китеп югалуын теләмәүдән, имеш (мәсәлән, «*** Мин киткәндә...» шигыре) – болардан күренгәнчә, бер үк төрле лирик герой, аның тирәсендәге тормыш ваклыклары да охшаш, хисләренең тарлыгы-киңлеге дә бер үк төрле, шул ук мәхәббәт темасы, әмма шигъри мотивларда аермалык аларны төрләндереп җибәрә, һәркайсына үз фәлсәфәсендә, үз мәгънәсендә ачылырга мөмкинлек бирелә.

Монументальлеккә корылган шигырьләрдә һәрвакыт шушындый үзенчәлекләр белән очрашабыз. Алар укучыныерактан җәлеп итә, күңеле белән якынайган саен, аңардан өстен чыга, югарыга аша баралар. Р. Харис шигъриятенең көче, – тормыш дөреслегенең идеологик нигездә дөрес һәм тулы ачылуы белән бергә, темаларының мотив катламнарына кадәр җентекле эшләнүендә дә.

## II

Китте,
Ялгыз калдым.
Тәмәке
Тынычландыра алу көчен югалтты... –

дип белдерә автор лирик геройның хисләрен «*** Китте...» шигыренең беренче строфасында. Монда сагыну аркасында тынычлыкны югалту хакында сүз баруы аңлашылып тора. Алга таба әсәрдә очрашуны теләү хисе тасвир ителә:

Аһ, ничек телим:
Йөгереп керсен иде дә,

Тетрәгән гәүдәсен
Иңнәремә элсен иде дә
Сыктасын,
Сыктасын,
Сыктасын иде.

Үзен яраттыру, сагындыру, шушы яраттыруы һәм сагындыруы белән елатырга теләве лирик геройның, әлбәттә, үз-үзен яратуы буларак та укучының күңеленә тәэсир итә. Һәм менә лирик геройның үзенең яратмавы нинди тасвири картинада бирелә:

Тәмәкенең көле төшеп
Аның чәч төбен көйдергәч...

Мондый мәгърурлык, үзен өстен кую, башкаларның аны яратуыннан тәм табуы һәм рәхәтлек тоюы монументальлек төсмере белән сугарылган лирик геройда менә шушындый рәвештә була да инде. Укучыны ул аптыраашта калдыру көченә дә ия. Һәм менә лирик геройның усаллыгы тулысынча диярлек ачыла:

Кинәт туктасын иде.
Ычкындырсын иде
Иңнәремнән кулларын.
Башын иеп катып калсын иде,
Аяклары талсын иде,
Идәнгә аусын иде.

Әлбәттә, укучы күз алдына монументаль мәгърур лирик герой да, аңа җанын бирергә әзер, аңарга әсирләнгән һәм әсәрләнгән гашыйк җан да тулы картина буларак килеп баса. Р. Харис – аңлы, тойгылы һәм тоемлы әдәби картиналарны тудыру остасы, бәхәс юк. Бу яктан ул – үтә талантлы шагыйрь. Аның шушы сыйфаты хәтта поэтик чараларны кулланмый язганда да сизелә. Лирик геройның усаллыгын әдип бу шигырендә менә ничек тасвир итә:

Аяклары талсын иде,
Идәнгә аусын иде... –

дип яза да, алга таба:

Гәүдәсе аша атлап чыгып китәр идем,
Калсын иде... –

дигән хыялда бирә.

Бу шигъри юллардагы мәгърурлык, мин-минлек, мәртәбә хисе монументаль геройга хас булганча зур осталык белән сурәтләнгән. Кемгәдер мондый лирик герой кабахәт сыман тоела, кемдер аның чын ирләрчә булуына соклана ала. Бу шигъри картина укучыларның күңелендә төрлечә уела, төрле хисләр һәм фикерләр, мөнәсәбәт уята. Әмма лирик геройның мәгърурлыгы өшендереп алу көченә дә ия. Моны, нинди хисләр кичерүләренә дә карамастан, укучылар бердәй тоялар. Р. Харис шушы кадәр мәгърур монументаль героен да шигъри итә belә. Менә ул:

Аһ,
Син хәзер үк миңа тансык инде... –

дип, аның хисләрен бирә дә лирик героен сагыну тойгылары тәэсиренә кабат кайтара. Шуның белән мәгърурлык аерым монументальлек сурәтендә калдырыла, шул рәвешле, картина шигъри форма рәвешен ала, ә сагыну хисе эчтәлекне барлыкка китерә. Мондый әдәби күренеш бары тик монументальлеккә корылган әсәрләрдә генә була ала. Р. Хариста алар төп тенденцияне, иҗат үзенчәлеген хасил итәләр.

III

Монументаль сәнгатькә тормыш җылылыгы җитмәүчән була. Катгыйлык, мәгърурлык, өстенлек комачаулый, билгеле. Мондый сәнгать төрендә эротик алымнарны файдалану ярдәмендә мәсьәләне чишү юлы табылган. Һәм менә Р. Харис шигърияте ндә дә бу шулай. Катгыйлык, мәгърурлык исә хисләрнең сафланып алуын, тойгылардагы кырпак тутыкның коелуын, чымырдаган йөрәк белән тузаннардан кагынып куюны барлыкка китерә. Мондый тойгыларны кичерү кемгәдер авыр да бирелергә мөмкин, хәтта күпләрдә чиркану да тудыра ала. Әмма монументальлек, никадәр өшендереп алса да, үз мескенлегеңне сиздерсә дә, ул, шул ук вакытта, бөеклекнең бер вәкиле булуыңны тою хисен дә уята. Эротик элемент хисләрне кайнарлап ала. Моның шулай булуын Р. Харисның «Көзге сүрән мәхәббәт» шигырендә дә күрергә мөмкин.

Бу әсәр дүрт кисәккә бүленгән. Беренче кисәге ике строфадан, өченчесе – өчтән, икенче һәм дүртенчеләре берәр строфадан торалар. Шигырь верлибр формасына корылган.

Шагыйрь сагыну хисен мондый шигъри сурәт белән бирә:

1. Карасам күккә –
Моң күрәм: синең моңың.
(Сагыну тәэсир итә
Микәнни күккә?..)

Карасам бакчага,
Лепелди башлый йөрәк:
чияләр – синең иреннәр...
Тизрәк сине күрәсем килә.

Иреннәр хакында искә алу һәм күрәсе килү тойгысын искәртү, әлбәттә, эротик элемент булып тора. Әмма монда монументальлек тә эротик элемент кебек үк салмак, артык күпертелмәгән. Шулай да, «Сагыну тәэсир итә микәнни күккә?..» дип, лирик геройның уйлануы, үзенең сагыну хисен күкләрнең сыйфаты итә белүе мәгъруранә монументальлеккә бәйле. Дөрес, шагыйрьләр-язучылар геройларының хисләрен табигать картиналары аша (бигрәк тә модернистик әсәрләрдә) бик оста сурәтлиләр. Хәзерге чор әдәбияты өчен андый формалар яңалык түгел. Әмма Р. Харис шигърияте
ндә эш башкачарак тора: лирик геройның эчке уй-кичерешләренә табигать күренешләре буйсындырыла, ул алардан өстен, хис-тойгыларын, уй-хыялларын ачар өчен, аларга ярдәмчеләре, хәтта хезмәт итүчеләре итеп карый, аларны үзенә тиң яки үзеннән өстен куя алмый. Әгәр дә эротик элемент булмаса, бу мәгърурлык йөрәкләрне өшетеп калдырыр иде.

2. Карасам күккә –
Сагышың синең,
Карасам бакчага –
Алмагачлар күлмәк сала,
Барам,
барам яныңа, барам...

Лирик герой табигатьне үзе белән тиң куяр иде, әмма ул аның сөеклесенең хисләре турында сөйләүче икән. Монда һичбер төрле кимсетеп карау юк, түбәнлеккә төшерүне дә эзләү урынсыз.

Эротик элемент лирик геройның хисләрен җанлы итә бара, «алмагачлар күлмәк сала» дигәненнән соң хәтта ашкыну хисен дә тудыра. Лирик герой сагыну тойгыларында гына кала алмый. Алар, бу гашыйклар, бергә булырлар дигән өмет, күзаллау барлыкка китерелә.

3. Карасам –
инде күптән
теге болытлар киткән күктән.
Алар урынына
агы килгән,
туй күлмәге кигән.

Йөрәгем – дерт!
Хисләр – күкерт...
Тәмәке кабызам...
Тәмәке генә.

Төтене болытка менә,
Менә,
Менә...
Җитә алмый.
Ә күктә зәңгәр моң.
Синекеме ул?
Минекеме?

Ике арадагы мөнәсәбәтләре туйга барып җитми. Туй, әлбәттә, ике гашыйкны аерылмаслык бер итәр сыман. Лирик геройга күкләр дә туй күлмәген кигән буларак күзалланалар. Кыз һәм күкләр сурәттә шулай үзара параллель куелалар. Әгәр дә лирик геройның тәмәке кабызуын, тәмәке тартуын аның уйлануы билгесе дип кабул итсәк, төтене күкләргә барып җитмәвен (ә ул менә, менә, менә...) туйларга уе ирешмәве дип аңларга тиеш булабыз. Зәңгәр моң исә – хыял, өмет, теләкләрнең буш калуы, әлбәттә.

4. Карасам –
күктән кар ява.
Тирә-юнь тып-тын.
Тыныч,
Сафлык.
Ак карда шыгыр-шыгыр эзем.
Аның белән янәшә
бер эз дә юк.
Салкын дым...

Ялгыз калу шигырьдә шушылай сурәтләнелә. Монда монументальлекнең тантанасы булырга тиешле шигъри юллар юк дәрәҗәсендә. Шагыйрь аларның аз микъдарда булуын кирәк тапкан. Бу

аның лирик героен монументаль дәрәҗәдә бөек итеп тасвирлавына һичбер зыян китерми. Мондагы очракта ялгызлык үзе үк, шушы кадәр эротик хис-омтылышлардан узып та, сафлык һәм тынычлык тойгыларына туры китерелгән. Кар яуган минутларда монументаль һәйкәлләр дә кечерәеп калган кебек күренәләр. Бу шигырендә дә Р. Харис үз иҗат осталыгына хилафлык китермәгән.

IV

Яшьлек белән картлык очрашуы Р. Харисның мәхәббәт шигъриятенең аерым бер тематикасы булып тора. Сабырсыз яшьлек янында картлык тыйнак калырга тиеш. Әмма ул яшьлектән мәхәббәт таләп итә. Лирик герой монда да үзенә гашыйк булуларына мохтаҗ.

Гашыйк бул син миңа,
Гашыйк бул син,
Вакытлыча гына булса да,
Күзләремә сеңгән яшьлек төсем
Кояш, яңгырлардан уңса да...
(«Гашыйк бул син миңа»)

Лирик герой «йөрәгемдә беркем кагылмаган хисләр бар» дип белдерә, күзләремдә «уңмый торган җете төсләр бар», ди. Аның яшьлегенең төсе киткән, әмма бераз калган да әле, алары чекрәеп торалар. Күпләр, электә аны күрмичә, яныннан «җил кебек» үткәннәр, ә менә син аның яныннан болай гына узма. Башкалар үткәндә, ул тын торган, ә менә син узганда «талпынып», «җилкенеп» куйган.

Лирик геройга вакытлы мәхәббәт кенә кирәк, «бер язга гына күңелен чәчәккә төрүче» булсын ул. Башкасына дәгъва итми.

Р. Харисның лирик герое даими, сүнмәс мәхәббәтне күтәрә алмый. Моның сәбәбе дә шул ук монументальлек белән бәйле. Башкача булганда, лирик геройның монументаль үзенчәлекләре артка чигенер, югалыр иде. Мәңгелек белән вакытчалык каршылыгы лирик геройның бөеклеге каршында хәтта мәхәббәтнең дә (шагыйрьләр дәгъва кылган һәм мәңге сүнми торган дип аталган мәхәббәтнең дә) бер «кабынып алу» буларак кузаллануы, вакытлы күренешкә әверелдерелүе үзе үк көтелмәгән тойгылар уята.

Гашыйк бул син миңа –
Үкенмәссең...

Вакытлыча гына...
Китәрсең...
Тик бер язга гына күңелемне
Чәчәк тулы бакча итәрсең...

Гашыйк бул син миңа...
("Гашыйк бул син миңа")

Лирик геройның яшьлектән калган ярасы бар. Әмма ул үзе – төзек «көймә», дулкыннар яра, «ялгыз ярга җитмәс борын татып калыйм бар рәхәтне» дип ашкына, ә ватык көймәләр ярда кала («Дулкын керсен...» шигыре). «Су кермәсен, / Дулкын керсен / Минем яшьлек ярасына» дигәнендә, әлбәттә, яшьлек ярасын яңа хисләрнең төзәтәчәге хакындагы фикер буларак аңларга кирәк. Монда дулкын белән хисләр янәшәлектә (ассоциатив параллельлектә) куелалар, су белән хәвеф, сагыш, борчылу үзара мәгънәдәш итеп алыналар.

«*** Мин бәхетле итәр идем сине...» шигырендә лирик герой ташлап калдырылганны, ягъни «ярда яткан ялгыз каекны» бәхетле итәргә теләген сөйли, чөнки ул «җаный» да «һәр күңелдә зәңгәр җилкән киереп» «йөзәргә лаеклы» икән. Бу «җаный» «ләйсән тулы зәңгәр болыт» та әле. Әмма лирик герой «күңелемдә җылылык җитми» дип уфтанып куя. Монда «күңел җылысы», әлбәттә, метафорик мәгънәгә ия, ул игелек иясе була алу хакында да белдерү буларак аңлашыла.

Бу шигырьдәге лирик герой үзен дә бәхетсез бугаймын дип атый, шуңа күрә сине онытыйм, «ә үзеңә калдыр мең түзем», ди. Шул рәвешле, сурәтләр һәм образлы фикерләүләр ярдәмендә монументальлек тудырыла. Дертләп кабынып, янып алырга мәҗбүр лирик герой тиздән суына, аның «көтмәгәндә учагы сүнә», ә аннары ул кабат кабынырга, башка мәхәббәткә әзер.

Р. Харисның мәхәббәт шигырьләрендә бу туктаусыз шулай. Мондый хисләр берсеннән икенчесенә күчеп баралар.

Ян, дисең син,
Ян, дисең син,
Ян, дисең син!
Яктысымы,
Җылысымы сиңа кирәк?

Алар миндә
Һава белән Җир шикелле –
Якты зәңгәр күзләремдә
Җылы йөрәк.
(«Ян, дисең син...»)

Лирик герой һәр яктылыкта җылы, һәр җылыда яктылык булу мәҗбүри түгеллеге хакында фәлсәфә кора. Мәгънәле сүзләр, билгеле. Лирик геройның күңеле яктылык белән бергә җылылык күрсәтә алганда гына канәгать итәчәк – бусы инде монументальлекнең идеологиягә хезмәт итүенә ачык бер мисал да булып тора.

Р. Харисның мәхәббәт шигырьләре монументальлеккә корылып, лирик геройны тормыш ваклыкларыннан һәм вакытлы күренешләрдән өстен сыйфатында танырга мәҗбүр итә. Әмма ул үз «эго»сыннан гына түгел, хәтта заман идеологиясеннән дә азат түгел. Абсолют шигъри ирек аңарда юк, һәм моңа ул мохтаҗ да түгел. Идеологик яктан төзек һәм ныклы булуы аркасында, лирик геройның әле сүнеп, әле балкып алучы мәхәббәт хисләре дә аклана, чөнки ул, шушы үзгәрешләренә дә карамастан, даимсезлектә даимилек таба. Лирик герой яна-көя ярата, әмма иреннәрдән ары узмый – бу фикер барлык шигырьләрендә дә диярлек кабатланып, бу мотив Р. Харис поэзиясендәге идеологик чараларның тагын берсе ролен үти. Өченчесе – лирик геройның хатыны бар. Ә лирик герой һаман да менә аны сөя, башка учакларда янып алса да, үз хатынына даими тугрылыклы. Бусы да шигъри идеология ролен үти, идея һәм фикер бирү чикләреннән югары күтәрелү билгесе.

Шигырьләрдәге бер үк фикерләрнең һәм идеяләрнең кабатланышы, төрле яклап аларның бер ноктага төбәлгәндәй яктыртылышы, бер сурәттән икенчесенә үзгәрешсез күчерелә барылуы фикер сайлыгыннан түгел, бәлки идеология тудырудан килә.

Р. Харис бу яктан да көчле шагыйрьләребезнең берсе булды. Ул шигырьләренә шушы идеологик фикерләү юнәлешләрен замананың үзеннән дә әзер килеш алды, аны үзенә дә күңелендә, акылында-зиһенендә тудырып бирә алучы әдип сыйфатында җитлекте, шундый буласын беренче адымнарыннан ук күрсәтте. Аның шулай булуы иҗтимагый-сәяси лирикасыннан гына түгел, бәлки мәхәббәт шигырьләреннән дә ачык аңлашылып, күренеп тора иде.

*2011*

## Равил Фәйзуллин шигъриятендә күзәтү һәм шигъри бәян бирәмлекләре

I

1970, тагын да 1980 еллар башы татар зыялы яшьләре арасында мәртәбәле бер хозурлык һәм тантаналы романтик хисләр белән укылып, киләчәк тормышның бәхет-сәгадәт юлына илтүче, үз көненең сагышын, кайгысын, тарлыгын һәм кечелеген тойдыручы әсәрләр сыман кабул ителә иделәр Равил Фәйзуллин шигырьләре. Аларны коры декламатив рәвештә түгел, бәлки чын дулкынлану хисенә төренеп укыганда тәмам аңлашылалар һәм тирән уйларга, фикер-тойгы агымнарына салалар. Шул хисләр эчендә Р. Фәйзуллинның лирик герое күңелләргә күчеп яши башлый. Әсәрләренең җиңел кабул ителүе сөендерә: эчтәлекне һәркем үзенчә төшенә, аңлата ала. Бигрәк тә мәгънә-идея чокынып аптыратучылар өчен мәйданлы иделәр алар. Шигырьнең хикмәте – күңелгә хуш килүендә генә түгел, аның акылга да сыешлы булуында. Бу мәгъкулият кануны эчендә уй йөртә белү (бәяләү хакында әйтергә дә базмыйбыз) кысаларын санга сукмаганда, әдәбият фәненең үз күләгәсе белән үзенең уйнап утыруыннан гайрегә ирешә алмаячагыбыз колаклардан яшереп кенә сөйләнә торган сүз түгел. Ул инде күптән телләрдә йөри, кабатланып-кабатланып, кат-кат ишетелә. Р. Фәйзуллинның кайсыбер шигырьләре, күңелгә хуш килмәгән очракта, акылга сыешлы һәм ярашлы иделәр. Иң кирәге, шигырьдә ул күп вакытта төрен-мәрәсим, ягъни церемонияләр ясап тормый, итагать итүне белми, сүздә чибәрләнү-бизәнү белән иркәлек күрсәтеп аптыратмый, бәлки әйтә дә куя. Бу әйтеп куюлары турыдан килеп чыгамы, әллә ерактанрак әйләндерелеп йөртелеп аптыратамы (мәсәлән, «Сәйдәш» поэмасы) – болары аның сайлаган жанрының хасиятенә, күңеленең стихиясенә бәйле шулай төзеләләр, килеп чыгалар. Р. Фәйзуллин шигърияте футуристик алымнарны үзләштергән, әмма ул өслүбкә икенче төрле, торгынлык чоры кешесенең теләк-омтылышлары белән тулы рухи эзләнүне, дәртле җанны салган әдип буларак укучы каршында тиз үсте, әдәбиятта ныгыды һәм замандашлары арасында шагыйрьләр хыялланып та ирешә алмаган төрле дәрәҗәдәге биеклекләргә күтәрелеп, халыкның һәм дәүләтнең кыйммәтсенеп-тарланып-сайланып һәм хөрмәтләп

кенә бирә торган шанлы исем-дәрәҗәләрен алды. Болары бер хәл. Ә менә Р. Фәйзуллин шигъриятенең асыл хикмәтләре хакыйкатьтә-чынлыкта нәрсәдә һәмниләрдә соң? Бу серле шигъри йомгакның җеп очы булырга тиештер бит инде, аны табуга һәм тартуга ук һәммәсе ачык хәлдә мәгънәви энҗеләр рәвешендә савыла, аңлашыла башлар иде. Бу җеп очы эчтәлекне дә, форманы да бердәй ачып, сүзләренең серен төшенүгә китерәчәк, бәхәссез!

Әсәрләрне бары тематик яктан тикшерү асылда бер үк нәтиҗәләргә китереп, безнең татар шигърияте тарихи, фәлсәфи, көнкүреш-иҗтимагый, әхлакый, сәяси, экологик темалар бәлән чәчәк ата дигән мең кат таныш, әйтелгән, расланган, мәктәп баскычларыннан билгеле һәм өйрәнелгән вульгар-социологик нәтиҗәләргә генә китерәчәк, татар әдәбиятының үзенчәлекләре дә, әсәрләренең хикмәтләре дә ачылмый калачак. Әмма ул без эзләргә тиешле, акылга сыешлы, Р. Фәйзуллин шигъриятен аңлый-аңлата, ача, төшендерә-белдерә-танyта, хәтта «сүтеп куячак» җеп очы нәрсәдә яки, һич югы, нинди соң?

Әдәбиятыбыз фәне бу мәсьәләне кызык кына чиште һәм бу сорауга әлегә яшь һәм урта буын саналган галимнәребезнең хезмәтләре белән эзләнүле җавап бирде. Академик Д. Заһидуллина, япон әдәбиятын яхшы белгәнлекләре сәбәпле булыр: «Р. Фәйзуллин иҗатында классик хокку яки танкадагы кебек аерым бер табигать яки тормыш күренешен күзәтү-тергезү аша сагышлы хисләр бәйләме тудырган үрнәкләр бар»[1], – дип юкка гына расламыйдыр? Әмма галимә, бу юлда алга таба сүзләрен дәвам иткәндә, «ләкин» сүзен куллана һәм, Р. Фәйзуллин шигъриятен бәяләп: «... Классик япон шигърияте өчен мәҗбүри саналырга тиешле хисси төсмерләр (моно-но-аварэ, саби, ваби, сибуми, каруми) иректе урнаша, шуңа аларның көчеше-үзгәреше «төзелеп бетмәгән күпер» концепциясеннән читкә китә»[2], – ди. Фикерләренең дәлиленә шагыйрьнең өчьюллык «Көзге яңгыр» шигыре мисалга китерелә, аның иҗекләр структурасы 7-8-8 үлчәменә корылганлыгы ачыклап узыла[3]. Дөрес,

[1] *Заһидуллина Д.* «Шаш, рухым, дуласын җан!»: Р. Фәйзуллинның 1960–1980 еллар иҗаты: фәлсәфи үзенчәлеге һәм поэтикасы // Казан утлары. – 2013. – № 8. – Б. 123.

[2] *Заһидуллина Д.* «Шаш, рухым, дуласын җан!». – Б. 122–123.

[3] Шунда ук. – Б. 123.

мондый шигъри үлчәм силлабик-сеҗе (сәҗигъ) һәм гаруз системаларында юктыр, японнықында бардыр дигән хәерсез күзаллау барлыкка килә.

Әмма бу – башка мәсьәлә. Шигырьгә кайтыйк. Ул моңардан гыйбарәт:

КӨЗГЕ ЯҢГЫР

Торналар китеп бара.

Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

Бу әсәрдә, беренчедән, шигырь таләпләренә туры килүен раслаучы ни төзек ритм, ни тышкы булсын, ни эчке рифмалар юк. Кемдер, бу шигырь түгел, дияр. Кемдер аны ак шигырь яки верлибр дияр. Икесенә дә, сүзләрен раслар өчен, әсәрдә дәлилләр җитәрлек табылыр. Формадан чыгып фикер йөрткәндә, алар икесе дә хаклы булырлар. Әмма бу әсәрдә хис бар. Шагыйрь хисне шулкадәр шигъри итеп сурәтли, ирексездән хәйранга каласың. Барыбыз да балачактан беләбез: яңгыр болытларның күңеле тулганнан яумый һәм болытларның да күңеле хушлашып китеп барган кошларның канатлары тиеп китүдән тулмый. Әмма мондый бәян – шигырь! Шигъри мантыйкның бөеклеге шунда: ул ышандыра, хис иттертә, серле хакыйкатьне ача. Шигърият галиҗәнабы алдында хөрмәт белән башыбызны ияргә мәҗбүрбез. Рух тантанасы шушы түгелме? Без дә, шагыйрьнең үз теленнән алып, Д. Заһидуллина кебек: «Шаш, рухым, дуласын җан!» – дибез. Димәк, Р. Фәйзуллинның бу әсәре шигырь булып чыга һәм аның шигърилеген бәян мантыйгы дәлилләп торганлыгы безгә төгәл ачыла.

Шул ук вакытта Акъегетнең (Р. Фәйзуллинның энесе Рөстәм Фәйзуллин, нечкә бәгырьле, затлы шагыйрьләребезнең берсе) шигырьләре искә төшә. Аның иҗатыннан бер генә әсәрен мисалга алыйк:

ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Ә күк шундый зәңгәр,
шундый зәңгәр –
Тамчы булып тама зәңгәрлек!
Шундый иркен дөнья,
шундый җиңел!–

Пәрәвезләр оча,
мамык оча,
һаваларда Җирне күтәреп![1]

Һәм безнең рухыбыз: «Гаҗәеп бу, гаҗәеп!» – дип тантана итә. Шигърилеккә ул әсәрдә берәр хилафлык табылырмы? Юк! Тагын да шунысы сокландыра, гаҗәпкә калдыра: бу ике шигырь дә бер үк алымда, бер үк манерада, бер үк аһәңдә, бер үк өслүбтә язылганнар! С. Хәким сүзләре белән әйтсәк (Акъегет китабына сүз башы юлланмасын ул язган): «Акъегет шигырь үзен мең еллар буена сынаган юлны сайлаган»[2]. Сүз, әлбәттә, кыска төзек шигъри формалар хакында бара.

Тагын да шунысы әһәмиятле: С. Хәким мәкаләсендә Сәгъди, Хафиз, Дәрдемәндләрнең иҗатлары искә алынып, рус әдәбиятының символистлары А. Блок һәм А. Ахматова да шул җепкә куелып, аларның «иҗаты өчен иң характерлы шигырьләр шушылар»[3], ди әдип. Шәрык әдәбиятына, әлбәттә, электән, чишмә башыннан ук кыска формалар характерлы. Хәер, ул безнең әдәбиятыбызның борынгы дәверендәге ташъязмаларда, «Ырк битиг»тә дә шулай. Урта гасырлардагы фәрд, бәет, кыйтга, робагый кебек жанрлар берьюллык, икеюллык, дүртьюллыклардан гыйбарәт. Жанрларны билгеләгәндә, Шәрык әдәбияты асылда формаларга бәйле эш йөртә. Эчтәлек ягыннан үзара охшаш газәл һәм касыйдә (Шәрык әдәбиятларында иң киң таралган жанрлар) икесе дә мәхәббәт хисләрен тасвирлауга корылганнар. Газәлнең Аллаһы Тәгаләгә, касыйдәнең Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган булуларын тәҗрибәсез укучы сизми дә. Шәрыкта жанрны формага бәйле билгелиләр. Ә адресат ул – Шәрык өчен форма. Шаһларга язылучы мәдхияне ярлы кешегә атый алмыйлар, аның өчен нәсыйхәт жанры бар.

Хәер, модернизм дәверенә кадәр Европа әдәбиятларында да ул шулай иде. 1849 елдан фрацузларда үзен күрсәтә башлаган модернизм сәнгатьчәлекне максат итеп куя һәм әдәбиятның төп берәмлеге, сурәтләгән әйбере хис дип белдерә. Модернистлар мәдәният өлкәсендә тантана итә башлый, модернизм-җәдитчелек дәвере башла-

[1] *Акъегет.* Ак болытлар шәүләсе: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 47.

[2] *Хәким С.* Иҗатка рухландырсын // *Акъегет.* Акболыт шәүләсе. – Б. 6.

[3] Шунда ук.

нып китә. Хисне тасвирлау ысулларының чиксезлеге, алымнарның төрлелеге шул чорларда ачыклана. С. Хәким искәрткән Сәгъди, Хафизның шигърияте (формаларда кыска булсыннар) – башка агымнан, сурәтләү алымнары белән Дәрдемәнд тә алардан кискен аерылып тора. Ул – А. Блок, А. Ахматова өслүбе агымында, символизм юлында. Дәрдемәнднең тәгъбирче шагыйрь, ягъни символист шагыйрь икәнлеге хакында Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре»ндә шактый киң тукталып үтә[1]. Хәер, бусы да башка мәсьәлә.

Акъегетнең дә шигъри формалары Дәрдемәнднекенә тартым. Әмма ул да – шулай ук башка агым вәкиле. Формаларны охшаш итеп, күпләр Р. Фәйзуллин шигъриятенә ияреп карадылар. Әмма Р. Фәйзуллин бирә алган кебек итеп импрессионистик шигъри сөремне, ни кыска шәкелдә булсын, ни озын формаларда булсын, ясап чыгара алмадылар. Акъегетнең даһилыгында алар импрессионистик шигъри сөрем түгел, бәлки импрессионистик шигъри картина, импрессонистик шигъри сурәт характерын алдылар: детальләр төгәл, ачык, нәзәкәтле, бизәкле һәм төсләр гармониясендә эшләнелгән – чын мәгънәсендә сәнгать әсәре. Һәм безнең Р. Фәйзуллинда да сәнгать ягы көчле, әмма ул ипрессионистик шигъри сөрем анда башкачарак, аңарда әдәбилек шигъриятенең асылын тәшкил итә, шигырьләрен чын әдәби әсәр ясый. Хикмәте дә әнә шул импрессионистик шигъри сөремдә, әлбәттә.

## II

Кечкенә мәкаләбезнең шушындый озын «кереш» өлешеннән соң төп темага күчәбез. Формасы уңышлы килеп чыкмаган, дирсез. Хакыйкатьне ачу максатында алга куелган мәсьәләгә якын килү өчен башка юл табалмавыбыз аркасында ул шулай булды. Һәм без, Р. Фәйзуллинның шигъри алымының хикмәте – импрессонистик шигъри сөремдә, дидек. Бу сүзләр тезмәсе «әсәре кызыклы килеп чыккан, фикерләре бай һәм фәлсәфи» дип сөйләргә, ишетергә, уйларга өйрәнгән татар акылы өчен ят һәм сәер яңгырый торгандыр – бәхәсләшмибез, дөньяның бүген-иртәгә генә үзгәрүен дә өмет итмибез. Әмма кулланылган терминны аңлатып китүебез дә хәерле.

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Сигез томда. – Т. 5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 94–110.

«Импрессионистик шигъри сөрем» дигән сүз русчалатып уйлап күнеккән сәнгатьчеләр телендә «импрессонистический мазок» терминыннан чыга. Безнең татар сүзлекләрендә «мазок» сүзе «буялыш, буяу төшерү» дип бирелә[1]. Әмма табигый яңгырамый. Импрессионист рәссамның ясаган картинасын күреп, аннан берни аңламаска, нәрсәнең-нәрсә икәнлеген төшенмәскә, сурәтләрне бары шәйләргә генә дә мөмкин. Бераз читкәрәк китәсең, картинадагы шәүләләр рәсемгә әверелә, ачык күренешләр барлыкка килә. «Мазок»лар, ягъни сөремнәр, шулай итеп, гаҗәеп гүзәл рәвешкә керәләр. Мондый рәсемнең «мазок»ларын «сөрем»нәр димичә нәрсә дисең? Гомер-гомергә Европа белән тыгыз бәйләнештә яшәгән, шул ук вакытта үзләре дә булып кала алган, XIX йөздә Европа университетларында даими белем алган төрек зыялылары үз телләрендә «мазок»ны «сөрмәк» яки «сөрем» дип беләләр, кулланалар. Безнең татар телендә дә «сөрмә», «сөрмәләү» сүзләре кулланыла. «Мазок» сүзен без шуннан чыгып «сөрем» дип бирдек. Аннары тагын шунысы кызыклы: халкыбызда томанлырак күренешкә «сөрем», диләр, ул русның «смог» сүзенә туры килә. Бу исә «сөрем» төшенчәсенең эчтәлеген тагын да киңәйтеп җибәрә. Һөнәрченең «мазня»сы белән рәссамның «мазог»ы арасында бөек аерма бар, бездәге «буялмыш», ягъни «буяштырып ташлау» белән «сөрем» арасындагы аерма кебек үк. Аннары «буялмыш» сүзендә «пычратылган», ягъни «мазня» мәгънәсе дә бар. Ә Р. Фәйзуллин – буяулар белән түгел, әдәби шигъри сүз белән иҗат итүче шагыйрь.

Р. Фәйзуллинның «Көзге яңгыр» шигырен кабат искә төшерик. Әсәрнең беренче юлы: «Торналар китеп бара». Бу – тормыш күренеше, аны күзәтү. Шигырьнең аерым строфа буларак бирелгән икенче һәм өченче юллары – «Кош канатлары орынгач, болытларның күңеле тулды» – әдәби бәян бирү өлеше. Ул сагыш, моң белән тулы. Аларны укыганда, көзге көндә яңгыр астында очып барган кошлар күз алдына килә. Бу юллардан бер укучының зиһене мәгънәле күренеш таба, икенчеләр аларда фәлсәфә күрә, өченчеләр хис-кичереш тоялар. Импрессионистик ысулның хикмәте дә шунда: һәркем әсәрне үзенчә кабул итәрлек, аңларлык һәм аңлатырлык әсәр тудырыла.

[1] Русско-татарский словарь / под ред. *Ф.А. Ганиева.* – М.: Рус. яз., 1984. – С. 255.

Р. Фәйзуллин кыска шигырьләрен дә, «озын»нарын да ара-тирә «этюд» дип билгели. Рәсем сәнгатенә караган жанр атамаларының әдәби формалар белән уртаклыгы мәсьәләсе – кызыклы һәм өйрәнелмәгән күренеш. Әдәбиятта бу күренеш импрессионистлар чорында көч алып китә. Шагыйрьләрнең мондый уртаклыкларны тоюлары һәм иҗатларында «рәссамнарча» эш итүләре әдәбиятның сәнгать төрләренә шактый якынаюы хакында сөйли. Сәнгать төрләренең үсеше һәм аларның дөньяны тасвирлаудан ачыклауга таба борылулары модернист рәссамнар фәлсәфәсе белән генә түгел, Р. Вагнер кебек бөек композиторлар иҗаты белән дә алга сөрелде. Ул хәтта «Нибелунг балдагы»[1] дип аталган шигъри-драматик трилогия иҗат итә һәм дөньяга әдип буларак та танылa. Тагын шунысы да әһәмиятле: башка сәнгать төрләре белән чагыштырганда, барыбер дә рәсем сәнгате, бүгенге көндә дә алдынгы юнәлешләрне мәйданга чыгарып, иҗатчыларны авангардта үзенә ияртеп бара. Р. Фәйзуллинның иҗатта рәссамнарга якын торуын сиздерүе аның да алгы сафларда ашкынып яшәргә омтылышы һәм яшәве хакында сөйли.

Шигырьнең бөеклеген аңлар өчен, аның асылына ирешергә кирәк. Фән төшенеп кенә калмый. Ул аңлатырга тиеш. Әдәбият белеме фәне, төгәл фәннәрдән аермалы буларак, аңлатып бирә алуы белән яши. Шушы үзенчәлеге белән ул фәлсәфә фәненә тартым, әмма аңардан аерылып та тора. Әдәбият фәне әдәбиятны өйрәнүе белән «фән» турындагы фән ролен башкара, матур әдәбиятның метод-өслүб чараларын өйрәнү ноктасына бәйле рәвештә аңлатмаларын кора. Метод-өслүб мәсьәләләрен атлап кына узып, игътибардан алып ташлап фикер йөртергә никадәр генә тырышмыйк, асылсыз, нигезсез фикерләмәләр белән фәнебезне генә тутырырбыз. Р. Фәйзуллин шигърияте аңлар өчен, аның иҗат өслүбе ачуачыклау төп мәсьәләләрнең тагын да берсе булып тора.

## III

Үткән XX гасырның икенче чирегеннән алып ахыргы дистә елына кадәр татар әдәбияты социалистик реализм кысаларында яшәде. 60 нчы елларда әдәбият мәйданына күтәрелгән Р. Фәйзуллин

[1] *Вагнер Р.* Кольцо Нибелунга: избранные труды. – М.: ЭКСМО-Пресс, 2001. – С. 18–399.

да шуның бер вәкиле иде. Социалистик реализм безнең татар әдәбиятында футуризм, имажинизм, импрессионизм, экспрессионизм, романтизм, реализм, натурализм кебек һәм 20–30 нчы елларда яшәгән башка төр иҗат стильләре, мәктәпләре, агымнары вәкилләренең шартлы «кушылуыннан», «суммасыннан», «берләшү» тантанасы белән игълан ителгән метод иде. Дөрес, коммунистлар («Ленин социалистлары») партиясенең сыйнфый көрәш принциплары нигезендә иҗат иткән әдипләр чын мәгънәсендә социалистик реализм колачында иделәр. Алар коммунистик идеология хезмәтендә булдылар. 60 нчы елларга социализм принципта төзелеп бетеп, сыйнфый көрәш мәсьәләсе чишелде. Бары әхлак, экология проблемаларын гына хәл итәсе калды, ягъни илдә һәркем аң иясе икәнлеге, әмма, ни кызганыч, аларның әлегә акыл үсешенә ия түгеллеге ачыкланды. Һәм тәрбия эше башланды...

Акыл кешелекнең әзәлдән килгән проблемасы иде. Фәлсәфә гыйлеме шушы мәсьәләне чишү белән шөгыльләнүне үз өстенә алган булса да, марксистик-ленинчыл фәлсәфәдә ул аңны өйрәнү һәм тәрбияләү белән чикләнде, моның өчен «акыл» төшенчәсен «аң» төшенчәсе белән алыштырды. Әдәбият фәлсәфә түгел. Аның өлкәсе – хис һәм акыл. Әдәбият фәлсәфә була алмый, әмма фәлсәфәчелек итә, фәлсәфәлек кора, фәлсәфәи нигездә тора ала. Шуның белән ул акыллы тоела да. Акыл бөеклеген әдәбиятта хәтта импрессионистик сөрем дә бирә алмый, чөнки ул сәнгать чарасы булып тора. Аны шуңа да сәнгать чарасыннан әдәби чарага әвереелдерергә кирәк. Бу мәсьәлә Европа әдәбиятларында, хәтта импрессионизм «аталары» тарафыннан да (Стефан Малларме, Поль Верлен, Артюр Рембо, Жюль Лафорг һ.б. турында сүз бара) тәмам хәл ителмичә, ачыкланылып бетмичә, чишелергә асыл юлы табылмыйча «калдырылган»[1]. Хәзер инде ул хакта язып тормыйлар.

Әсәрләре, әдәби иҗат манерасы белән Р. Фәйзуллин импрессионистик әдәби сөрем берәмлекләрен шигърияттә тудыру, иҗат итү юлын тапкан һәм шуның белән дөнья әдәбияты үсеше куйган сорауларга җавап биргән. Аның, татар әдәбияты вәкиле булып та, дөньякүләм югары дәрәҗәле әдип икәнлеген бу үзенчәлеге ачык күрсәтеп тора.

---

[1] *Карагыз: Шиллер Ф.П.* История Западно-европейской литературы Нового времени. – Т. III. – 2-е изд-е. – М.: Изд-во Наркомпросса РСФСР, 1938. – С. 4–80.

Суфилар теле белән әйтсәк, илаһи сүз генә «башлангыч акыл» була ала[1]. Ә чын шигырь үзе үк илаһи сүз түгелме? «Башлангыч акыл» («изначальный, или всеобщий ум») теориясе Ибне-Гарәби (1113–1241) тарафыннан эшләнелгән һәм тугыз гасыр буена кат-кат сыналып килгән санала[2].

Импрессионистик шигъри сөрем дип без хис-тойгы ияту көченә ия булган әдәби бәян һәм күзәтү берәмлекләрен алабыз. Шунысы әһәмиятле: күзәтү берәмлеге буларак бирелгән шигъри юлның яки юлларның эчтәлеген һәммәбез дә бертөрле кабул итәбез һәм аңлыйбыз. Ә әдәби бәян мәсьәләсенә килгәндә, эш башкача тора. Әдәби бәян берәмлеге җиткергән эчтәлекне төрле укучы төрлечә кабул итә, аңлый һәм аңлата ала. Мәсәлән, әлеге дә баягы «Көзге яңгыр» шигырендә боларның икесе дә бар: 1) «Торналар китеп бара» – күзәтү берәмлеге, һәркем тарафыннан бәхәссез кабул ителә, чөнки хәбәр туры мәгънәсендә бирелгән; 2) «Кош канатлары орынгач, болытларның күңеле тулды» – әдәби бәян берәмлеге, бу юлларның эчтәлеген һәр кеше үзенчә аңлап кабул итә, төшенгәненчә аңлата, алар нигезендә хәтта фәлсәфә кора ала.

Күзәтүдән аермалы буларак, әдәби бәянның тагын да бер үзенчәлеге шунда: ул шигырьгә фәлсәфилек төсе-төсмере бирә. Шуның сәбәпле илаһилык белән очрашу хисе укучы күңелендә туа, ягъни шигърият барлыкка килә. Бу әдәби бәян асылы белән «башлангыч акыл» бирүче, хисне генә түгел, зиһенне дә кузгатучы көчкә ия. Укучыда уйлану теләге туа, аңа фикер йөртүгә этәргеч ясала. Уйлану – кеше зиһененең рәхәтлек кичерүе генә түгел, нәрсәнедер төшенеп, аңлап алу тойгысын белән бергә барырга тиеш. Боларга этәргечне Р. Фәйзуллин шигырьләрендә әдәби бәян берәмлегенең эчтәлеге бирә. Менә шуңа күрә дә әдәби бәянны «башлангыч акыл» этәргече дип бәяләргә хаклыбыз. Сәгъдинең булсын, Хафизныкы булсын, аларда да «башлангыч акыл» бирү бар, әмма алар, әдәби бәян берәмлеге белән чикләнмичә, әдәби вакыйга бәянына күчәләр. Хәер, шигърият гомумән дә шул әдәби вакыйга бәяны белән яши. Ул Р. Фәйзуллин иҗатында гына башкача.

---

[1] *Таминдари А.* История персидской литературы. – СПб.: Петербургское Востоковедение, 2007. – С. 32.

[2] Шунда ук. – Б. 32.

Шагыйрьнең «Этюд» шигырен

(Су төбендә көмеш тәңкә
камыш аша якты сузган
ай йөзенә.)

Д. Заһидуллина болай аңлаган: «Бу очракта шагыйрь фәлсәфи нәтиҗәне алга куя: һәр асылның күләгәсе яки дәвамы белән бәйләнеше тормыш кануны кебек белдерелә. Айның чагылышы (көмеш тәңкә) Айга «кулын сузган» дигән сурәт укучы күңелендә төрле ассоциация уятырга мөмкин: баланың – ата-ана назына, кешенең – милли тамырларга, укучының – остазга мохтаҗлыгы ул, йә булмаса иҗатның чынбарлык белән мөнәсәбәтләреме, боларын һәркайсы үзе уйлап бетерә. Ләкин әлеге бәйләнешләрнең барлыгы шәхси хатирәләрне яңарта, узганны сагыну һәм моңсу хисне кузгата»[1], – дип яза ул.

Әлбәттә, шулай. Күренеп, аңлашылып тора: әдәби бәян «башлангыч акыл» функциясен башкарган, кеше аның тәэсирендә акыл табучыга, ягъни хакыйкатьне төшенүчегә «әверелә». Әмма бу төшенү һәркемнең үзенә күрә үзенчәлекле килеп чыга. Фикер яки мәгънә автор тарафыннан укучыга җиткерелми, бәлки укучы үз фикерен яки уйлаган мәгънәне әсәргә (бу әсәр шул турыда дип) йөкли. Д. Заһидуллина сүзләренә килсәк, димәк, асылда, ул да шушы фикерләмәләре белән Р. Фәйзуллин шигырьләренең әдәби бәян һәм күзәтү элементларыннан торуын раслый. Тагын да шунысы кызыклы: Р. Фәйзуллин шигърияте ндәге әдәби бәяннар «импрессионистик шигъри сөрем» буларак тудырылганнар.

«Этюд» шигыренә кире кайтсак, әсәрдә сүз Айның судан үзенә кире чагылган шәүләсе хакында бара дисәк, ә нигә шагыйрь «су төбендә көмеш тәңкә» дип яза? Димәк, су төбеннән Ай нурында көмеш акчаның ялтыравы хакында сүз бара монда. Көмеш тәңкә Ай нурында ялтырый, әлбәттә. Су төбендә булса да. Әгәр дә «су өстендә көмеш тәңкә» дип язмаган булса иде, ул вакытта сүз, чыннан да, Айның үз шәүләсе үзенә ялтыравы хакында барганын уйлар идек. Барыбызга да билгеле, чөнки шәүлә су төбеннән ялтырый алмый, суның төбе түгел, өсте көзге ролен үти. Бу шигырьдәге «су төбендә көмеш тәңкә» шигъри юлы – күзәтү берәмлеге, «камыш аша якты

[1] *Заһидуллина Д.* «Шаш, рухым, дуласын җан!» – Б. 123.

сузган Ай йөзенә» өлеше – әдәби бәян. Күзәтү берәмлегеннән аермалы буларак, әдәби бәян («импрессионистик шигъри сөрем») үзендә хис тудыручы эчтәлекне туплый, әсәрнең мәгънәсен шул эчтәлеккә төшенү аша укучы үзенчә таба. Шушы шигырьнең эчтәлеген якты Ай нурлары астында су төбеннән камышлар аша көмеш акчаның ялтырап күренүе хакында буларак төшенеп, аңардан мәгънә чыгара һәм яктылыктан серләр ячерелми, серләр якты нурга үзләре ачыла, үзләре «кул суза» дигән фикер ясый. Бәлки инде, уйларын тагын да куертып җибәреп, кабат башка нәрсәләрне таба. Шулай итеп, Р. Фәйзуллин шигырьдә фикер түгел, әдәби бәян һәм күзәтү берәмлекләре бирә, ә аларның эчтәлегеннән укучы үзе мәгънә һәм фикер чыгара. Шул сәбәпле аңарда акыл нурланышы уяна.

Мәкаләдә аңлатылганнарга бәйле рәвештә мондый нәтиҗәгә киләбез: Р. Фәйзуллин шигырьләре, күзәтү һәм әдәби бәян берәмлекләреннән торуыннан тыш, укучыны фикерләүгә, мәгънә чыгаруга этәрү көченә ия булулары белән аерылып торалар һәм мондый импрессионистик әдәби алым аны дөньякүләм әдәби мәйданга үзенчәлекле алдынгы (авангард) шагыйрь буларак, үрнәк һәм бөек буларак чыгарырга мөмкинлек бирә. Тагын да шунысы бар: кыска шигырьләре кебек үк, аның күләм ягыннан озын шигырьләре дә шундый төр берәмлекләрдән гыйбарәт, хәтта поэмаларында да ул шулай. Аерма бары тик берәмлекләренең санында, күплегендәазлыгында, ягъни кабатланып яисә сан ягыннан артып баруларында. Ә аларны фәнни нигездә тикшерү тагын да кызыклы поэтик ачышлар вәгъдә итә.

*Май–сентябрь, 2013*

## Роберт Миңнуллинның лирикасы һәм аның «эстетик дөнья сурәте»

«Эстетик дөнья сурәте» төшенчәсендә универсумны күздә тотабыз һәм әдипнең дөньяны әдәби күзаллавын, аның «эстетик модель» тудыру җәһәтендә фикерләмәләрен барлауны максат итеп куябыз. Бу юнәлештә татар әдәбият белеме фәнендә хәзергә кадәр фәнни хезмәтләрнең җитәрлек булмавы кайбер мәсьәләләрне аңлатканда авырлык тудырасын да хәтердә тотарга мәҗбүрбез.

Дөрес, әдәби әсәрләрнең үзкыйммәтен билгеләү, дөньяны танып белүдәге ролен ачыклау аларга эстетик анализ бирүдән башка мөмкин түгел. Әмма нинди дә булса универсаль анализ моделен төзүне максат итеп куймавыбыз сәбәпле, кайбер мәсьәләләр мәкаләбездә шулай ук ачык калачак.

Әдәби иҗат эшчәнлеген бәяләүнең һәммәбезне дә тәмам канәгатьләндерерлек формуласы әлегәчә фәнгә мәгълүм түгел, шулай да моңа омтылыш галимнәр арасында үсә бара.

Лирика дигәндә, аны тематик яктан балалар һәм өлкәннәр шигърияте кебек шартлы бүленешкә таркатмыйча, бергә, бөтенлектә карауны да бу мәкаләдә шарт итеп алдык.

I

Р. Миңнуллин – шигърияттә гадилек һәм гадәтилектә матурлык тапкан әдип. Аның иҗатында тормыш вакыйгалары да, табигать күренешләре дә, кешенең эчке халәте дә шушы юнәлештә ачылып бирелә. Шагыйрьнең фикерләре һәм күзәтүләре гадилек-гадәтилек йомгагында үстерелә. Һәр шигыре шул рәвешле оеша. Укучы аның даими сабырлыкта булуына, тормышның гадәти күренешләреннән тасвир тудыра алуына соклана.

Р. Миңнуллин – күзәтүчән шагыйрь. Әдәби детальләре тирән фәлсәфә белән өртелеп бирелми. Аның каравы хис бирәмлегенең көче аларда шактый нык сиземләнә, күңелләрне кузгата, шушы ягы белән XX йөз башы «рус крестьян шагыйрьләре» аталган әдипләр төркеме иҗатын хәтерләтә (әлбәттә, С. Есенинны).

Ачтым яшел җилкапканы,
Бастым яшел keләмгә,

Аштым яшел сагышларга
Утырдым да үләнгә.

Р. Миңнуллинның Наҗар Нәҗмигә багышлап язган «Шагыйрьнең киңлекләре» шигыреннән бу юллар. Шигъри строфалар фикер һәм тасвир җәһәтеннән катлаулы түгел, гади һәм гадәти. Алар укучы күңеленә барып җитәрлек итеп оештырылганнар. Лирик геройның «яшел сагышларга ашуы» хакында искәртүе күңелгә үзенә күрә бер моң, уй башлангычы бирә. Күз алдына яшел җилкапкалы, яшел келәм булып үскән чирәм килә. Үләнгә утырып сагышланып

алу гадәти хәл кебек. Әмма шагыйрь «яшел сагышлар» хакында сүз алып бара. Яшел сагыш нинди була – бусы әлегә укучыга билгеле түгел, әмма күңелне кузгатырга шул да җитә кала. Яшел үлән төсе белән сагыш-моң төсе, бербөтенлек хасил итеп, күңелдә сорау һәм кызыксыну да уяталар. Х. Туфан иҗатыннан татар укучысына яхшы таныш шушы яшел төс монда да шагыйранә яңгырый. Гади һәм гадәти тоелган шигъри юллар тирәнәеп, мәгънә төсмере белән баетыла. Р. Миңнуллин менә шушы рәвешле хис, аның белән бергә моң тудыра алуга ирешкән чын, затлы шагыйрь буларак укучының күңел түрендә урын ала да инде.

Шагыйрь аунаган чирәмлек,
Шагыйрь үскән үләнлек,
Сабый чакны, яшел чакны
Сагыныплар үләрлек.

Әгәр дә шигъри деталь үстерелми калдырылса, кабатланып, мәгънә төсмерләре белән баетылмаса, ул эчтәлеккә, шагыйрьнең хисләр үстерелешен бирүгә хезмәт итми. Р. Миңнуллин андый түгел, ул, киресенчә, аны, шигъри детален, фикерләренең һәм хисләренең гадилеге һәм гадәтилеге белән бәйле рәвештә кабатлый. Шул рәвешле, лирик геройның кичерешләре укучы күңеленә тагын да якыная, үз була бара. Бу табигыйлык төсмере уята. Укучыга кайчандыр үзенең дә нәкъ шушындый хисләрне кичергәне исенә төшкәндәй тоела. Моны тудыру өчен, шагыйрь «сабый чакны» «яшел чак» буларак сагыну тойгысы һәркемгә таныш булырга тиешлекне генә искәртә югыйсә. «Шагыйрь аунаган чирәмлек» дигәндә, исерек кешенең чирәмдә аунап ятуы кебек ямьсез күренеш күз алдына да килми, чөнки Р. Миңнуллин санап китү юлы белән хисне көчәйтеп кенә калмый, бәлки шигъри күзәтүне шактый конкретлаштыра, чирәмлекне «шагыйрь үскән үләнлек» мәгънәсенә күчерә. Н. Нәҗминең балачакта аунап үскән туган туфрагы хакында сүз барганлыгы тагын да төгәлрәк беленә, хис ителә бара. Р. Миңнуллин тышкы табигый күренешкә сокланудан шунда ук лирик геройның эчке, күңел халәтен бирүгә күчә, сабый чакны сагынудан үләргә дә мөмкинлекне искәртә. Бу шигъри «беркатлылык» гадәти дә, артыгы белән гади дә. Әмма аның эстетик функциясе дә бар. Нәкъ менә шушындый лирик күчеш һәм «борылышлар» белән Р. Миңнуллин оста эш итә белә.

Алар шигъри экспрессия тудыралар. Шушы ук вакытта, экспрессив сагышны көчәйтеп, Р. Миңнуллин строфалардагы фикерләрне катлауландыру ягына китми, киресенчә, мөмкин кадәр аларны гади һәм гадәти итеп калдыра бара. Бер строфада гүяки очраклы рәвештә генә телгә алынган кебек тоелган һәм гадилек, гадәтилек төсмере белән бирелгән шигъри детальне алга таба, икенче строфада яңа мәгънә төсмерләре, фикер берәмлекләре белән тулыландыра, үстерә. Шул рәвешле, әсәрдә хис бөтенлеге барлыкка килә бара. Мисалга әле генә телгә алынган строфаны искәртү дә җитә. Анда автор сабый чакны «сагыныплар үләрлек» дип, халык җырларыннан мең ишеткән, шигырьләрдә укыган формада гади һәм гадәти итеп белдереп узган рәвештә, гүяки бернинди яңа фикер һәм хис тудырмагандай бәянлап уза. Әмма алга таба «сагынып үлү» төшенчәсе шактый баетыла һәм тирәнәя. Р. Миңнуллин болай дип белдерә:

Үләрсең дә... баш өстендә
Асыл кошлар тирбәлсә,
Сайраулары күңелләргә
Бер дә тынгы бирмәсә.

Әлбәттә, кошлар сайраганга карап кына кеше үлми. Шагыйрь бу җәһәттә «прозаик» фикер йөртмәвен, бәлки моңның күңелгә авыр тәэсирен укучы күңеленә ирешерлек итеп җиткерүен генә сиздерә.

«Шагыйрьнең тын нигезенә сандугач оя корган» дип язуы белән Р. Миңнуллин Н. Нәҗминең рухын Сандугачка, Сандугачны Н. Нәҗминең шагыйрьлегенә тиңли, аларны үзара бәйле, рухи тормыш дәвамчылары буларак тасвирлый. Мондый чагыштыруны шигърияткә мәдхия буларак кабул итми мөмкин түгел. Гадәти һәм гади күренгән шигъри тасвир алымы эчтәлектә тагын да байый, тирәнәя бара. Болар берсе дә шагыйранә фикерләмә өчен ят һәм сәер түгелләр. Янәшәлек һәм шул янәшәлектә тасвир барлыкка килерү, бу тасвирны тагын да гадиләштерүгә ирешү белән Р. Миңнуллин хисләр экспрессиясен тудыра. Артык гадиләштерү, әгәр дә шигърилектән мәхрүм ителсә, строфаларны такмакка әверелдерә, билгеле. Мондагы чикне әдипнең сак күңеле тоеп, тотып ала белергә тиеш. Эзлекле рәвештә үстерелеп киленгән, күтәрелә һәм киңәя барган хис фикер тирәнлегенә күчми калмый.

Р. Миңнуллин шигырьләрдә шушы барышны көтелмәгән юнәлешкә «борып», гадәтенә күрә тәмам үзгәртеп кую юлы белән дә эш итә. Мисал буларак алынган әсәрендә дә шушы әдәби күренешкә тап булабыз. Әле генә аяк астында яшел чирәм, баш очында сандугач иде, инде шагыйрь мондый тасвир бирә:

Аяк астында – Агыйдел,
Агыйдел киңлекләре.
Киңлекләрдән дә күренә
Шагыйрьнең кемлекләре.

Сүз Н. Нәҗминең һәм гомумән дә шагыйрьләрнең күңел киңлекләре һәм шул күңел киңлекләренә бәйле кемлекләре хакында бара, әлбәттә. Бу шагыйранә фикер укучыга яхшы аңлашылып тора. Агыйдел буйлары да яхшы ук күзалланган кебек була. Тасвир юк дәрәҗәсендә гади, әмма ул гадәти, шунлыктан данлы елга буе укучы күңелендә ачык күзаллана. Елга тугайларындагы яшел хәтфә үлән дә, тал-тирәкләр һәм алардагы сандугачлар да искә алынмый югыйсә. Әмма алар шигырьнең беренче кисәге тәэсирендә күтәрелгән хисләр ярдәмендә күз алдына килергә мөмкиннәр.

Р. Миңнуллин шигырьләрендә тематик күчешләр тасвир алышынуы белән тәэмин ителә. Бу аның иҗат манерасыннан килә. Ул аларны тулысынча күңел фәлсәфәсенә алыштырмый, бәлки табигать күренешләре белән тәэсирләнү янәшәлегендә алып бара һәм үстерә. Бу яктан Р. Миңнуллин шигъри алымга хилафлык китерми, «форма үзгәрешләре» тудырмый, шуның аркасында бөтенлек һәм камиллек бозылмау тойгысы кала. Бу, – әлбәттә, кызыклы әдәби күренеш. Р. Миңнуллинга хас үзенчәлек.

Н. Нәҗминең күңел киңлекләре Агыйделдәй булуы укучыда җылы соклану хисләрен уята. Гади генә искәртелгән кебек тоелган шигъри чагыштыру хакыйкатьне тирән итеп ачып бирә. Р. Миңнуллинның «эстетик дөньясының сурәте» хисләрне баетуга гына түгел, шушы рәвешле тормыш чынбарлыгын төшендерүгә дә корылган булу белән әдәби әһәмият ала. Ул Н. Нәҗми хакында уйларга бирелә, санап китү рәвешендә генә булса да «Шагыйрьнең кемлекләре... Җанының хөрлекләре...» формасында төп фикер юнәлешләрен билгеләп куя. Күп нокталар әйтелеп бетелмәгән мәгънәне үзлегеңнән тутыруга этәрәләр. Укучыга алардагы

«яшермә фикер» аңлашылып тора, шагыйрьнең туган җире табигате белән күңеленең табигате янәшә куелып тасвирлануы аркасында ул шулай.

Р. Миңнуллин – гади һәм гадәти тоелган табигать, әйләнә-тирә, тормыш-көнкүреш сурәте детальләре белән рухи дөньяга гына хас тоелган үзенчәлекләрне янәшәлектә искәртү ярдәмендә генә дә күпме тирән хис-кичерешләрне тудыра һәм укучыда уята алу сәләтенә ия булган шагыйрь. Моның өчен ул катлаулы тасвирлауларга да бирелми, бәлки һәркемгә таныш тормыш детальләрен генә искәртеп узгандай яза белә.

Фикер-тасвирда гадилек һәм гадәтилек, укучыга бик тә танышлардыр сыман тоелган шигъри строфалар укучы күңелендә шактый көчле хис ташкыны тудыруга сәләтлеләр. Бу күренеш Р. Миңнуллинның әдәби осталыгы хакында сөйләүче төп факторлардан берсе булып тора. Аның тирән фикер фәлсәфәләре кормавы шигъри фикеренең сайлыгы дигән сүз түгел, әлбәттә. Киресенчә, Р. Миңнуллин үз укучыларын тирән хис-кичерешләргә этәрү көченә ия. Ул хис-кичерешләр көчле күңел дулкынлануына күчәләр. Андый вакытта авторның хата фикере дә дөрес буларак кабул ителә.

Сандугачлы, моңлы нигез...
Ул Ходайдан бирелә.
Кем дә шагыйрь булыр иде
Туып үссә бирелә.

Әлбәттә, ул нигездә, Агыйдел буенда бер Н. Нәҗми генә туып үсмәгән. Һәммәсенең дә шагыйрь булуы шарт та түгел. Р. Миңнуллинның шигъри хисне шушылай гади итеп йомгаклап куюы да сәер түгел. Шагыйрьгә мәдхияне туган нигезенә бәйле мактау сүзенә әйләндереп калдыру кебек тоелса да, монда сүз шактый киңрәк мәгънәгә ия булырга тиеш дигән гадәти хис тә уянмыйча калмый. Бу шигъри тәмамлау ысулы белән дә Р. Миңнуллин үзенең «эстетик дөнья сурәте»нә тугры кала. «Кем дә шагыйрь булыр иде туып үссә биредә» дигәндә, халыкның шагыйрьлеге хакында фикер әйтелгән кебек тоела. Шигырьнең эчке, идея агымы тәэсирендә укучыда үсеп килгән хис-тойгылар үзләре үк шушындый фикер нәтиҗәсенә китерәләр. Н. Нәҗминең туган нигезенә лирик герой көнләшеп карый дигән тойгы исә һич кенә дә уяна алмый.

## II

Р. Миңнуллин шигъриятенең «эстетик дөнья сурәте» һәммә җирдә һәм кешедә камиллекне сурәтли, таный, зурлый белү көченә ия, шушы сыйфатлар белән характерлана. Камиллек ул асылы белән гадилек һәм гадәтилеккә барып тоташа, билгеле. Катлаулы күренешләр, вакыйгалар, шәхесләр хаос эчендә булалар, шунлыктан аларның эчтәлегенә тулысынча төшенеп бетү дә мөмкин түгел. Фикер катлаулылыгы, шигырьгә килеп кергәндә, шулай ук хис-тойгыларның хаосын тудыруга сәләтле. Шигъри сүздә гади һәм гадәти булудан барлыкка килгән камиллек исә нәтиҗәдә бөтенлеккә ия хис-тойгыларны уята. Алар беркатлылар сыман да тоелалар. Сихри көчкә дә ия булалар. Гадилек һәм камиллек сихерләми калмыйлар, шигырьдә алар хис-тойгыларны аерым кысаларда һәм юнәлештә тоту көчен табалар.

Р. Миңнуллин иҗатын әдәби-эстетик анализ юнәлешендә тикшергәндә, берничә мисал арасыннан «Туфан урамы» шигыренә тукталып киткәндә дә, безнең фикерләмәдә нәрсәләр күздә тотылганны ачыграк аңлатырга мөмкин булыр сыман. Әдәби камиллек дигәндә, әлбәттә, формаль, рифма-ритм үзенчәлекләре генә исәптә калдырылмый, мәсьәлә әсәрнең эчтәлегенә турыдан-туры бәйләнештә чишелергә тиеш. Шигырьләрнең форма ягыннан төрлесе була ала, аңа карап кына алар әдәби камиллекләрен югалтмыйлар.

«Туфан урамы» шигырендә Р. Миңнуллин, ак каен һәм тимер койма образларын кулланып, Х. Туфанның язмышын, шагыйрь буларак бөеклеген, тәкъдир каршылылыкларын хис-тойгыларга күчерә алган. Бу шигырь эчтәлеге һәм әдәби проблематиканың куелышы белән кызыклы, шигъри камиллеккә омтылыш әдәбиятта кабатланмаган фикер үрнәге саналырга хаклы.

Туфан урамының бер очында
Ап-ак каен – Туфан диярсең.
Ак күңелле, ап-ак чәчле Туфан...
Аклык күмгән якын-тирәсен.

Каенның яшел булмыйча, ак «чәчле» картинасы укучыны гаҗәпләндерә, билгеле. Бу күренеш гадәтилеккә хилаф. Әмма каенның ак кәүсәле булуы шартлы сурәтне кабул итәргә мөмкинлек ача. Сурәтләрнең җитәрлек дәрәҗәдә камиллеген таләп итмәгәндә,

телдә ак каен гыйбарәсенең шактый тотрыклы саклануын исәпкә алганда, шигъри сүз белән укучы күңеле килешми калмый.

Хәер, хикмәт анда гына да түгел, бәлки Туфан күңеленең ак булуында, сафлыгында. Әгәр дә Р. Миңнуллин шигырьдә яшел күлмәкле Туфан турында сүз алып барган булса, даһиның күңел аклыгы да, башкасы да шигъри сурәт камиллегендә акланыр иде сыман.

Каен төсле Туфан шигърияте:
Якты хисле, якты фикерле.
Урам башындагы якты каен
Чал Туфанга һәйкәл шикелле.

Шигырьдә Х. Туфанның кемлеге һәм ниндилеге төгәл ачылып бирелгән. Аның хакында Р. Миңнуллинның шушы шигъри юлларыннан төгәлрәк һәм камилрәк фикер әйтеп булмас шикелле. Гади, гадәти һәм камил. Р. Миңнуллин шигъриятенең төп үзенчәлеге, аның «эстетик дөньясының сурәте» менә шушы сыйфатлардан гыйбарәт. Ул укучының күңеленә шулар белән үтеп керә, анда якты хисләр, якты фикерләр уята.

Бу шигырьдә Туфан урамының икенче очында тимер койма булу факты шулай ук символик мәгънә белән искәртелә. Монда төрмә рәшәткәсеннән, тимер богаудан шушы рәшәткәнең коелган булу мөмкинлеге дә белдерелеп, хис-кичерешләргә драматик төсмерләр өстәлә. Р. Миңнуллин фикерләрне һәм тойгыларны шигырьдә үсештә, үзгәрештә бирә, дидек. Димәк, динамик үсештә бирә. Бу шигъри динамизм ашкын хисле, каршылыкларны җимерә баручы көчкә ия түгел. Ул тәртип һәм сабырлык кысаларындагы кичерешләрнең хәрәкәтеннән гыйбарәт. Җәмгыятебездә «торгынлык чоры» дип аталган Л.И. Брежнев дәверендә татар шигъриятендә менә шушындый динамик күренеш пәйда булды һәм чәчәк атты. Р. Миңнуллин шул чорда халыкка хас, аның кемлеген һәм ниндилеген таныткан иң күркәм сыйфатларыннан саналган сабырлыгын шигърияттә саклап калган әдип буларак күзаллана. Һәр әдипнең иҗатта үз формалашу һәм үсеш алу дәвере бар. Шул чорыннан мәдәниятебезгә уңай сыйфатларны алып килә алган икән, бу инде – талантның көче хакында да сөйли торган факт.

Р. Миңнуллинның шигырьләренә хас «сабырлык» динамизмы хисләрнең хаотик үзгәрешен инкяр итә. Шушы сәбәпле хисләр,

уй-фикер агышы тулы гармония тудыра. Шагыйрь аны шигъри формаларда да оста файдалана, тасвирда да куллана.

Бер каенга багам, бер коймага,
Басып торам ике арада.
Ак каенга карыйм – җан яктыра,
Рәшәткәгә карыйм – карала.

Бу шигъри юллар Р. Миңнуллин шигъриятенә хас «сабырлык» динамизмын тулысынча күзалларга ярдәм итәләр.

Болардан чыгып, Р. Миңнуллинның шигъриятенә, асылда, гадилек һәм гадәтилек, камиллек белән бәйле «сабырлык динамикасы» хас дигән нәтиҗәгә киләбез. Әлбәттә, бу бәяләмә шагыйрьнең бары тик «эстетик дөньясы сурәте»нең төп үзенчәлекләрен генә, нигезен генә ачык танырга ярдәм итә, олы шигъриятнең һәммә үзенчәлекле якларын да колачлап бетерә алмый. Шуңа күрә, фикерләмәләребез объектив булсын дисәк, мәсьәләгә башка яктан да якын килеп карыйк.

III

Һич тә сер түгел, Р. Миңнуллин иҗаты татар укучысы өчен якты хисләр, мәгънәле уйлар һәм итагатьлелек тойгыларын уятуы белән дә аеруча кадерле. Аның шигырьләре кече яшьтән үк зиһенебезне бизәп, акылыбызны сөендереп, күңелебезне биләп, хәтер киңлекләрендә яши башлый. Бу яктан ул Кол Гали, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан кебек бөекләребез белән янәшәдә әдәбимәдәни тормыш күгебезне яктыртучы йолдызларыбыздан берсе сыйфатында мөкатдәс һәм мең кат мөкатдәстер. Аның шигырьләренә язылган җырлар халык арасында тиз таралып өлгерә, балаларга атап иҗат ителгән шигырьләре үзләренең самими һәм беркатлы булулары, шулар белән бергә, зирәк тә, бераз гына хәйләле дә (ягъни төшеп калганнардан түгел инде алар) лирик геройлары балачак хатирәләребезнең онытылмас мизгелләреннән шигъри юлларга сәяхәт иткәннәрдер кебек тойгылар уяталар. Бу ничек һәм ни өчен шулай? Сәбәпләрен, асылын төшенү мөмкинме? Әллә бу мәсьәләләр фән тарафыннан чишелмичә, ачыла алмыйча, сер булып калырлармы?

Үзенең ярты гасырдан артыкка сузылган иҗат дәверендә Р. Миңнуллинның татар шигъриятендә аерым бер шигъри галәм, шигъри дөнья, шигърият җиһаны тудыра, үстерә һәм ашы яшәтә

алуының сәбәпләре ил һәм халык алдында хөрмәтле булуына гына бәйле идеме икән? Берәүләр аның әдәбияттагы бәхетен депутатлык мәшәкатьләреннән калган өлеш кебек аңлатсалар, икенчеләр хикмәтне шагыйрь булып тууында күрделәр. Безнең өчен ул – шагыйрь, шул ягы белән бөек тә. Шунысын да искәртергә кирәктер: үз күңелебезгә килгәндә, шагыйрьләрнең күктәге йолдызлар кебек бер үк төсле, бары тик эрелектә һәм ваклыкта гына бер-берсеннән аерылып торуларын түгел, бәлки җәй башында болындагы чәчәкләр кебек төрледән-төрле булуларын сөя, аларның шулай балкуларын тели. Әмма шагыйрьләр үзләрен йолдыз итеп, бары тик йолдыз сыйфатында гына беләләр...

Йолдызларга карап торган кеше нәрсә уйлый? Мин аларда җан бардыр дип тоям, мине күреп, аңлап торалар, мин аларны тоям, күрәм һәм аңлыйм. Йолдызлар белән кешеләр ниндидер серле, зиһен аңламаган, әмма күңел тоя алган «телдә» сөйләшәләрдер сыман миңа. Әгәр дә Р. Миңнуллин шигъриятен йолдызлары белән балкыган чиксез галәм, күк йөзе дип белсәк, әсәрләре шул биниһая күкнең якын һәм ерак, күренеп һәм күренеп бетмәгән, ачылган һәм ачылмаган, исемле һәм исемсез йолдызлары икән, укучы күңеле шул йолдызлар белән сөйләшүче, серләрен ачып та ачыклап бетерә алмауда бәхет табучы бәрәкәт иясе түгелме?

## IV

Р. Миңнуллин, иҗат иткәндә, шигырьләрен камил детальләр белән бизәп, сурәтле итеп яза, дидек. Бу аның лирик әсәрләренә дә, балалар өчен язылган шигырьләренә дә бердәй хас. Аларның тәүге юлларыннан ук күңелгә күренешләр ачык һәм камил дәрәҗәдә эчке бер ләззәтле һәм мәгънәле хис белән бергә килеп, сагышлары, шатлыклары бөтереп алалар да каршылыксыз кабул ителәләр. Формаль мантыйк таләпләре һәм тормыш асыллары белән ярәшеп бетмәүләрен укучы төшенми, уйламый, хәсрәт итми, чын шигъриятнең дәртле хис агымнарына чума. Сагышы белән сагышландыра, шатлыклары белән сөендерә укучыны бу шигърият.

Һәр бөек шагыйрьнең бөеклеген хәтерләрдә даими дәлилләп торучы, исеме телгә алынуга җиңел генә искә төшүче, күңелгә якын әсәрләре була. Г. Тукайны «Туган тел»еннән, «Китмибез»еннән, «Шүрәле»сеннән, «Су анасы»ннан башка күз алдына ки-

терү мөмкин түгел. Без хәтта шүрәле сынын күрсәк тә Г. Тукайны искә төшерәбез. Хәтер бакчасында Һ. Такташ үзенең «Алсу», «Нәни разбойник», «Мокамай»лары белән «җитәкләшеп» йөри. М. Җәлилнең исемен әйтүләренә «Кызыл ромашка»сы, «Җырларым», «Вәхшәт» әсәрләре искә килә. Һәр әдипкә бәйле шулай. Әсәре авторының исеме белән бергә истә кала икән, бу исә – язучының халыкта кадерле булуы, танылуы хакында сөйли торган факт. Европада киң таралыш алган «әдипләрнең үлеме» теориясе, димәк, нигезле түгел.

Р. Миңнуллин исеме миңа, мәсәлән, «Килен төшкәндә» җыры белән бергә ишетелә. Көе – бер хәл, аның сүзләрендә бөтен хикмәт. Алар татар укучысына шагыйребезнең шигърияте кабул итәргә, аңларга һәм күңеленә алыр өчен «капкаларны киң ачарга» сәбәпче булдылар. Моңарчы да танылган, укылган, сөендерергә өлгергән шигъриятнең инде чын асыл төсе белән кабул ителә башлануын шул әсәргә бәйләвебездә әһәмиятле ачыш бар. Р. Миңнуллинның ачык һәм төгәл детальле, гүзәл сурәтле шигъриятенең бинасы нәрсәгә һәм нәрсәләргә корылганлыгын, нигезен ни тәшкил иткәнлеген ул һәм аннан алынган мисаллар төгәл билгеләргә мөмкинлек бирә. Хәер, «Килен төшкәндә» шигыре урынына шагыйрь иҗатыннан башка һәртөрле әсәрен сайланып тормыйча алырга була, аңа карап, кайбер нюансларны исәпкә алмаганда, башкачалык белән очрашмабыз. Р. Миңнуллинның хәтта балалар өчен язылган шигырьләре дә шул ук «калыпта» барлыкка китерелгән, тудырылганнар. Шуның өчен дә бу әсәрен (аннары ул киң катлам укучыларга, халыкка бик тә яхшы билгеле һәм шуның сәбәбендә укучыга, мәкаләбез белән танышырга туры килсә, безнең белән килешергә яки бәхәс итәргә мөмкинлек тә бирә) шагыйрьнең иҗат манерасын, әдәби өслүбен, төп үзенчәлекләрен ачыклауда һәм аңлатуыбызда бу юлы үзәккә алдык.

Р. Миңнуллинның «Килен төшкәндә» әсәре – неоромантизм агымы биргән иң якты әдәби кыйммәтләрнең берсе! Анда сурәтләнелгән һәр деталь, һәр күренеш, хәтта, әйтергә кирәк, вакыйга татар кешесенә яхшы таныш. Моның сәбәбе җыр булып китүеннән дә килә, билгеле (композиторы – Рөстәм Яхин)[1].

[1] Җырлыйк әле / төз. *И. Надиров*. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 250.

Ак күбеккә баткан юргалар
Кышкы юлдан ярсып чабалар.
Чак-чак кына аумый калалар
Салулаган чакта чаналар,
Арттан чаба бала-чагалар.

Игътибар итик: текстта искә алынган күренеш-вакыйгаларның һәр детале конкретлык, төгәллек белән бирелгән һәм мәйданга камил шигъри сурәт чыгарылган. Ул шунда ук күз алдына килеп баса. Камиллек, әлбәттә, әдипнең рухының көченә, якты акыллы булуына бәйле. Юргаларның кышкы юлдан чабуы да, чаналарның чак-чак аумый калулары да – бик гүзәл манзаралардан. Чаналар артыннан бала-чагалар да чабалар – бусы инде күпкә арттырылган, билгеле. Балалар туй артыннан бераз кушылып-ияреп-йөгереп алырга мөмкиннәр, әмма кышкы юлдан ярсып чапкан юргалар артыннан чабулары – белмим, ерак бара алмаслар, мөмкин хәл түгел, хәтта марафончылар да моны булдырмаслар.

Татар укучысы аңлый, белә: йола-гадәт шундый – узып баручы туй урамдагы балаларга тәм-том сибеп калдыручан, шуларны җыялар алар. Тик тагын да болары бар: кышкы юлдан юрганы ак күбеккә батырып чаптыру – аны яндырып үтерү дигән сүз. Моны ат җиккән һәркем белә. Әмма мәсьәләнең ул яклары шагыйрь тарафыннан искә алынмыйлар. Моның кирәге дә юк. Андый тормыш факты шигърилекне харап итәчәк. Шигъри дәрткә, шигырь куәтенең тәэсиренә чумган укучы да ул исәпкә алынмаган якларны күрми, сизми, тоймый. Аңа, киресенчә, юргаларның ак күбеккә батып чабулары, балаларның туй атлары артыннан чәрелдәшеп-шаулашып йөгерүләре (игътибар итик: укучы үз фантазиясе белән яңа детальләр өсти, шигырь тәэсирендә күзаллауга җиңел бирелә), чаналарның салулаганда авып киткәндәй булулары кыйммәтрәк. Хыял офыклары киңәеп китү белән бергә, тормыш хакыйкатьләре дә шул шигъри сурәт тәкъдим иткән рәвештә күз алдына килә башлый. Р. Миңнуллинның төгәл һәм сурәтле күренеш-детальләрне әдәби ямьдә бирә белү осталыгы укучының күңелендә хис-тойгыларны тирәнәйтә һәм камилләштерә. Бу исә рух тантанасына китерми калмый. Тормышта-чынбарлыкта килен шушылай төшә, татарда менә шулай яшиләр, туй итәләр икән дигән гомуми бер күзаллау да туып өлгерә һәм хәтердә яши башлый. Яшәешнең барышы, көнкүреш мантый-

гы, аның детальләре истән чыгарыла, онытыла, аларның урынын әдәби сурәт, әдәби детальләр, шигъриятнең үзе җанны биләп ала.

Галим-голәма, тәнкыйтьчеләр арасында шундый сүзләр йөрүчән: шигырьнең, асылда, башы һәм ахыры матур эшләнгән була, ә уртасына «чүп» тутырыла, диләр. Мондый карашның тууына төп сәбәп – әсәрләрендә шагыйрьләрнең әүвәле бер-бер фикри хакыйкатьне искәртеп, аннары аны сөйләп биреп, аңлатып, яисә бәяләп алуларына бәйле фикер «үстерүләре», аннары яңадан нәтиҗәле (яки алда, шигырь башламында әйтелгәнне кабатлау юлы белән) фикер йомгагын белдереп, шигъри «фокус» төзүләренә корылган формаларга өстенлек бирүләрендә, әлбәттә. Р. Миңнуллин шигърияте дә мондый корылмалардан мәхрүм калмаска тиеш кебек. Әмма детальле, төгәллек белән бирелгән камил шигъри сурәт моңа мөмкинлек калдырамы? Вакыйга-күренешләр киңәйтелергә, үстерелергә, эчке, рухи халәт тасвирына әверелә барырга мәҗбүр аның әсәрләрендә.

Мамык мендәрләргә төренеп,
Килен төшә бүген авылга.
Борынгыдан калган гадәт ул –
Халык чыга каршы алырга,
Яшь кәләшне күреп калырга.

Безнең татарда Р. Миңнуллин кебек ипле язган башка бер шагыйрь бармы икән? Юк та, ахрысы. Тавыш-гаугасыз, тыныч холкы аның иҗат манерасында да чагылмый калмаган. Шигырьләрен күркәм, тәүфыйклы итеп китереп чыгаруы – шагыйрьнең үз табигатеннән килә торган сыйфат. Ул – шигырьдә катлаулы символларга корылган мәгънәләр бирү юлында түгел. Эпитетлар белән тасвир-сурәтләр тудырып, Р. Миңнуллин шигырьдә эпик стильгә өстенлек куя. Аның иҗаты чагыштыруларга бай, анда аллегорик күзаллаулар еш очрый. Әмма образлы-символик мәгънәләр бирү ягыннан караганда, әгәр дә очраклы рәвештә генә алар аның каләм очына килеп кермәсәләр, бөтенләй диярлек юклар.

Эпик стильдә сурәтләнгән вакыйга-күренешләрне бирүдә мәгънәле күзаллау тудыра алу ягыннан Р. Миңнуллин һәммә татар шагыйрьләре арасында изге тойгылар белән күңелләрне баета алу көченә ия булуда аерылып торды. Аның язганнары тирән дулкынландыра. Мәгънәле күзаллау тормышны яктылык һәм бәхет

тою хисләре эчендә күрүгә һәм аңлауга, бәяләүгә этәрә. Р. Миңнуллинның шигырьләрен укыган кешедә (лирикасын булсын, балалар өчен язылган әсәрләрен булсын) тупаслык, усаллык, кирелек һәм ямьсезлек туа алмый. Үзеңне дөньяның матур бакчасында йөргән, хозурына сокланган күбәләк сыман тоясың. Бу халәт күңелең киңлекләрендә нурлы балкыш булып сүнми озак саклана. Моны, бер яклап, шагыйрьнең эпик киңлекләрне шигъри төзек кысаларга кертә белү осталыгы, икенче яктан, мәгънәле неоромантик күзаллау тудыра белүе, өченчедән, шуларны тәэмин итүче сурәтле детальләштерү алымнарын оста файдалануы белән генә аңлатып була.

«Килен төшкәндә» шигыре белән аның җырга салынган варианты арасында берникадәр аермалар да бар. Менә шушы, әле мисалга китерелгән икенче строфасы шигъри басмаларында болай яңгырый[1]:

Мамык юрганнарга төренеп
Төшә икән килен авылга.
Борынгыдан калган гадәттер –
Авыл чыккан каршы алырга,
Яшь кәләшне күреп калырга.

Күренеп тора, шигырь вариантында эпик киңлек бераз тарайтылган, детальле раслау тоны да түбәнәйтелгән. Бу исә «Килен төшкәндә» әсәренең шигырь варианты романтик хисне калку итеп ясап өлгертеп бетермәве хакында сөйли. Җыр тексты очына, дәрт бирә. Шигырь тексты рационалистик күзаллау ягына тарта, җырда «мамык мендәрләргә төренеп», ә шигырьдә «мамык юрганнарга төренеп» килен төшә, шигырендә шагыйрь киленне каршы алырга авылның чыгуын «борынгыдан калган гадәттер», ди, җыр текстында «гадәт ул» дип, раслау тоны белән белдереп, бу йолага соклану хисен алга чыгара. Җыр тексты шуның кебек кечкенә, әмма мөһим аермалары белән тагын да камилләшеп китә. Алга таба да мондый аермалыклар күзәтелә һәм алар җырга ямь, пластика өстиләр, туй манзаралары белән бергә килеп туган хисләр кебек тоелалар.

[1] Татар поэзиясе антологиясе. – II китап / төз. *Гәрәй Рәхим*. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 325.

*Шигырь текстында:*

Җилкендереп япь-яшь кызларны,
Хәтерләтеп яшьлек узганны,
Килен төшә бүген бер өйгә.
Эһ, кайтмас шул инде тагын дип,
Авыр сулап куя әбиләр.

Күптән инде ачып куйганнар
Килен төшкән өйнең капкасын,
Төшкән килен
Өйнең капкасын
Китәргә дип кире япмасын,
Кайгы җиле килеп какмасын.

*Җыр текстында:*

Җилкендереп япь-яшь кызларны,
Килен төшә бүген бер өйгә.
Кайда калды шундый чагым дип,
Авыр сулап куя әниләр,
Авыр сулап куя әбиләр.

Күптән инде ачып куйганнар
Килен төшкән өйнең капкасын,
Килен төшкән өйнең капкасын
Китәргә дип кире япмасын,
Кайгы җиле килеп какмасын.

Татарда килен авылларга мамык юрганнарга, яисә мамык мендәрләргә төренеп төшә икәнлеген халкыбыз үзе дә Р. Миңнуллинны укып, җырын ишетеп, аңа кушылып җырлап, шушындый күркәм йолаларыбыз булганда яхшы икән дип белә башлады. Моны без, әдәбият тормышны камилләштерде, дибез.

Р. Миңнуллин – эпик формаларда шигъри күренеш, тасвир бирү остасы. Ул менә шушы җыры-шигырендә генә дә туй көнендә авыл халкының төрле төркемнәре-катламнарының ни-нәрсәләр хис итүләрен детальле сурәтли, нечкә итеп бәян итә. Шушындый әдәбиләштерү юлы, тормыштан күтелгән вакыйгаларны күңел сурәтендә чынбарлык итеп бирә белү осталыгы белән ул шагыйранә кабатланмас дөнья барлыкка китерә. Аның эпик планда төзелүе эчтәлеккә киңлек бирә. Укучы анда үзен рәхәт, күңелле һәм бәхетле хис итә.

Р. Миңнуллин, – эпик формалар белән шигъри сурәтне детальләрдә оста рәвештә әдәби гомумиләштерүләр белән иҗат итү остасы буларак, милли шигъриятебезнең үзенчәлекле шагыйре; халкыбызның рухи сафлыгын, гореф-гадәттә тәүфыйк, итагать билгеләрен тәрбияви үстерүче неоромантик рухлы әдипләребезнең яңа заман чоры даһиларыннан, әлбәттә.

Шунысы тагын да кызыклы: аның иҗатын ничек кенә, кайсы юл белән генә тикшермик һәм анализлап бәяләмик, һаман да шул бер үк төрле нәтиҗәләргә килергә мәҗбүрбез. Бу исә хакыйкатьнең тугры ачыклануы дигән сүз дә. Фәннилек башкача була алмый.

*2008–2013*

## Дәрья дәрте

*(Рөстәм Мингалим иҗаты хакында)*

Рөстәм Мингалимнең шигърияте ургып алып китә торган дәрьяны хәтерләтә. Әмма ул болганчык сулы, авыр холыклы караңгы диңгез түгел. Саф, чиста. Һәр шигыре диярлек рухны сафландыру көченә ия.

Аның 2003 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Дәрт чишмәсе: Шигырьләр, поэмалар (мөхәррире – Р.Х. Корбанов, рәссамы – Ф.З. Зөлкарнәева)» тупланмасы шагыйрьнең күңел тантанасы гына түгел, татар әдәбиятының сөенече дә булган иде.

Тик, укучым, сез Р. Мингалим шигъриятеннән «ә»гә «җә» рифмаларын, «сандык-тартмачык» калыпларын, «шаккаттыризм» шәрәлекләрен эзләмәгез. Инде татар шигъриятендә реализм үлде, хакыйкатькә җеназа укылды, сафсата аламасы милли әдәби байрак итеп күтәрелде дигән заманда ул әле һаман, ничә еллар буена дәрья булып шаулый. Р. Мингалимнең дә шигърияте, хәтта «Юл өстендә тургае» да (1978 елда басылып чыккан шигырьләр һәм поэма китабы хакында сүз бара), бүген дә сайрый. Башкача була да алмый, булырга да тиеш түгел.

### I

Белмим, ни өчен Р. Мингалим җыентыгына «Дәрт чүлмәге» дигән исем бирергә уйлагандыр (бәлки, заманага ияреpгә мәҗбүр иткәннәрдер), әмма ул да ташып чыккан. Күңел кайнарлыгы шигырь дәрьясына әверелгән. 1972 елда ук язылган «Нәкъ унбиш ел үткәч...» шигырен укып, һушсыз калгандай булдым: никадәр тормышны аңлау һәм тою, никадәр шигърият һәм яшәеш мәртәбәсе, ул фикер тыгызлыгы һәм җиңеллеге! Әгәр бүгенге көн татар шигърияте хакында сүз алып барабыз икән, һичшиксез, сүз Р. Мингалимнән башланып китәргә тиеш кебек тә хис кала.

Көзге төнгә йөзен куйган иде
Кукчәтауның иркен даласы, –

ди шагыйрь, дала стихиясен күңелләр түрендә җәелдереп.

Шигыренең башындагы шушы шигъри юлларда ук кузгатылган хис-тойгылар алга таба күңел дәрте булып әверелә. Шагыйрь моңсулык агышына күңел кайнарлыгын ияртеп кенә, гадәти тор-

мыш вакыйгаларын гүяки чәчеп-чәчеп җибәргәндәй итә дә җиңел адымлы тезмәдә сөйләп бара. Тракторларның кырда утларын уйнатып эшләве дә, лирик геройның «тирли-тирли чылбыр ялгавы» да, хаталандырган чибәркәйнең, калдырып, үз якташына иргә чыгуы да, «ятимнәрне җыйган ана кебек» булган даладан китәргә мәҗбүр егетнең уйлары да – һәммәсе-һәммәсе, шигъри мизгелләрдә искәртелеп, инде ничәмә еллар сугарыр яңгырны күрми ката барган яргаулы җаннарыбызны гайрәтле үткер сабан төрәне кебек каезлап һәм әйләндереп ташлыйлар...

Авырлыктан качты бу егет, дип
Әйтүче дә бардыр ул барын...

Бардыр, дөнья шул ул, андыйлары гына табылыр! Әмма киткән кешене дә юлның уңае гына көтми, калган кешеләрнең дә эше җиңел генә булмаячак. Әйе, хикмәт китүдә яки калуда түгел, башкада! Шагыйрь моны сиздереп кенә куя. Ул һаман да шул ук тезмә кысасыннан чыкмый сөйли, әмма сүз агышының яссылыгы инде башка. Бу – Р. Мингалимнең шигъри алымы: ул бер фикер һәм хис катламыннан икенчесенә, өченчесенә, дүртенчесенә күчә-күченә һәм кире кайта-кайта, шул рәвешле сулышны, уйны, тоемны һәм аңны алыштыра-алыштыра бара. Әдәбиятның көче дә шунда: син инде чын әсәрне бер укысаң, кабат элекке хәлеңә кайта алмыйсың һәм кайтырга да теләмисең. Син инде башка, бүтән яссылыкта, әүвәлге халәттән еракта.

Ә Р. Мингалим моны бик җиңел тойдыра, бу аның шигъри сүз мәртәбәсенә бәйле. Укып кына карагыз, үзегез дә төшенерсез. Менә ул шушы ук шигыренең ахырында:

Нәкъ унбиш ел үтте,
Бер уйласам
Эшлим кебек эшем җимереп.

Бер уйласам, көзгә йөзен куйган
Күкчәтауның төнге даласы... –

дип, бүселергә әзер дәрт диңгезенең дулкыннарын тынычландыргандай итә.

Әйе, игътибар бирми мөмкин түгел: никадәр сыгылмалык, нинди аһәң-яңгыраш, моң! Гади, гадәти! Һәр буявы-төсе урынында, ягымлы һәм ятыш!

Һәм кайчаннан бирле тракторым
Кабыза алмый йөдим ләбаса.
Дуслар сөрә энә,
Төн караңгы,
Шырпы сызып карыйм моторга.
Ни булды соң әле?
Мотор салкын...
Тәмәкем дә беткән тартырга.

Бу – Рөстәм Мингалим каләме, башка бер генә шагыйрьдә һәм шигырьдә булмаган, яралы һәм сәламәт, тынгысыз һәм сабыр, сагышлы һәм кояшлы язу карасы салынган дәрт чүлмәгеннән буялып чыгучы каләм. Әйе-әйе, дәрт чүлмәге түгел, сагыш һәм кояш чүлмәге дә әле ул! Мең мәртәбә аңлаешлы һәм фикер күзеннән ерак Мингалим. Мондый шагыйрьнең татарда булганы бар идеме?

II

Шигырь хистән-тойгыдан, дәрттән, акылдан буш булмый, юкса ул үлә. Белеп торыгыз, тәнкыйтьче, мәкер айгырына атланып, харабат кылычын пәһлевандай айкаган һәм гыйлем-хакыйкать байрагы тантанасы өчен баһадирларча җан аткан каһарманга тиң ул. Без дә бу эшкә алынганбыз икән, үзебезне нәкъ шулай тотарга тиешбез. Дөресрәге, Мингалим шигъриятен иңгә-буйга йөреп, аннан бушбугазлык эзләмәкчебез. Әмма, егет, кылычыгыз тиз сынар, дип лаф ормагыз, максат ул Мәскәүне дә алдырган, Парижны да тезләндергән!

Менә ул, менә «Зәңгәр ишек» шигыре. Автор аны «Балачак дусларыма» дип багышлаган. 1973 елда ук язылган булса да, ни тәнкыйтьнең, ни адәмнең күзе төшми калган шигырь. Моннан әдәбият фәнендәге һәртөрле «изм»нарның исе аңкып тора. Монда әдәп һәм әдәпсезлек, монда үҗәтлек һәм битарафлык... Бер сүз белән әйткәндә, шәп бит ә?!

Бер-беренә охшаш чуерташлар сыман –
Уйга килә – ярда безнең шәрә яткан...

Яр буенда яткан «балачак дуслары» – чуерташлар! Шунда ук мәңге сөйләшеп туймый торган, бер-берсенә гүяки төскә-биткә дә охшаш иптәш малайлар хәтердә яңара. Шагыйрь хәтта кояш барлы-

гын, күкнең аязлыгын да теленә алмый. Ә шигырьдә никадәр нур, җылылык!

Беренче тапкыр бу шигъри юлларны укыганда, без, учларыбызга егылып төшкән йөрәгебезне тотып, бүлмәбезне аркылыга-буйга йөреп таптап бетердек. Салкын тиеп авырган чагыбыз иде. Тәмам хәлсезләнгәч кенә акылыбызга киленде, урыныбызга яттык. Мингалимне ачуландык: никадәр мең тапкырлар кабатланган, фикерсез һәм кызыл байраклы шигырь, дидек. Зәңгәр ишек, имеш, максат ишеге! Аңа якынаясың, ул арткарак оча, сакчысы бар, калын, бикле... Ә аңа ирешәсе, аны бәреп ачасы бар!

Һәм Мингалим барыбер үзенекен итә, шулкадәр сүзне әйләндереп куя, узылган һәм киләчәк язмышың, бар тулылыгы белән көмеш тәңкәле ак чабак кебек ялтырап, күз алдында күренеп ала...

Үзен зәңгәр ишек итсә серле максат,
Дөнья безне кеше иткән, куәт биргән.

Чыннан да шулай түгелме? Бу әсәр нык үскән куәтле һәм бәхетле социализм дәверендә язылган, җиде елдан илдә коммунизм тантана итәчәк дигән елларда!.. Әйе, заманасыннан чыгып бәя бирсәк, бу – фикерсез шигырь, идеалларны юкка чыгаручы сафсата. Әмма бүгенге көннең ничек итеп киләсен ул вакытта кемнәр белгән дә, кемнәр аңлаган?

Р. Миңгалимнең шагыйрь буларак көче-куәте хакыйкать икән шул, сүз уены, хисләр аймагы гына түгел.

Гафу, шагыйрь әфәндем, мең гафу, сезнең шигырегезне фикерсез дип атарга җөрьәт иткәнем өчен, чөнки тәнкыйть азмы шулай ялгышты һәм ул безнең каләмне дә хаталандырырга җыена. Нишлисең соң, тәнкыйтьнең мәкер алашасы йөгән чәйнәргә, тешләшергә маташа.

Максатына тими узган ташлар кебек,
Соңгы көндә егылмасак иде Җиргә.

Гади һәм гадәти сүзләр кебек!

Шигырьнең җененә игътибар итик: ярда яткан чуерташлар сыман малайлар һәм максатына тими узган ташлар! Йомарлам кебек бөтен, мәгънәле фикерне үзенә сыйдырган тулы канлы, тәмамланган картина булып тормыш хакыйкате күз алдына килеп баса. Догасы да, драмасы да бар!

III

Р. Мингалимнең бу җыентыгының бөтен хатасы – ялагайлана белмәүдә. Әллә кайчан әллә кемнәр булып бетәр иде дә, ул орденнар, ул премияләр, ул катлы-катлы йорт-фатирлар, машиналар, алтыннар, хатын-кыз гыйшкы, мунчасы һәм пәрәмәчләре белән күмелер иде. Юк шул, Мингалимгә боларны Ходай Тәгалә моңа кадәр күпсенгән, аңа туры һәм тугры тел, иман биргән. Ә югыйсә шигъриятендә кемлекләрен язып биргән шул ук депутатлар, чиновниклар, «койрыклар», «койрык арты койрыклар» аның үз танышлары, якын белгән кешеләре, хәтта дуслары да түгелме? Алармы Мингалимне укымыйлар, алармы үзләрен танымыйлар? И шагыйрь, нигә шушы кадәр хакыйкать ялчысы булып туарга кирәк булды икән сезгә? Тарихлар шаһит түгелме, шул дөреслекне сөйләгән шагыйрьләрнең язмышлары нәрсә белән беткән? Хәтта үзләрен, мөслиммен, дип, хакыйкатькә тугрылык саклаучыларбыз, дип йөргән мөселманнармы Хакка, Хаклыкка, Хакыйкатькә хезмәт иткән шагыйрьләрне дар агачларына асып үтермәгәннәр? Әллә данлы европалыlармы кул бармакларыбыз арасыннан каннар агып тормый дип мактана ала? Кичәге тәртипләр бүгенме үзгәрделәр?..

Үзгәрә, дип күз яздылар,
Үзгәрәдер – чындыр ул...

Шушылай тыныч кына башлап китә Мингалим «Идарә чылбыры» (1989) шигырен һәм мыскыллап әйтеп тә куя: «вәйт озын да чылбыр ул!»

Ә бу чылбыр өскә, баш әйләнгеч югарыга таба китә.

Иң түбәннән өскә хәтле –
Арт ялауга корылган...

Аны, алай түгел, дип әйтеп карагыз!

Ярар, идарә чылбыры шундый булсын да, ди, ә безгә, «түбәннәргә, ничек түзеп торырга?!» Укучысы алдына шагыйрь сорауны бар тулылыгы белән, яшермичә китереп куя белә. Йа Хода, дисең, ярый әле, түрәләр шигырь укымыйлар һәм аңламыйлар, юкса татарны бөек бер шагыйрьдән мәхрүм калдырырлар иде дә, хакыйкать урынына ялагай эт кебек шыңшучы куштан читек-кәвеш шигырьләр генә дөньяда калыр, милләтнең хәле харап, эше харап, йөзе харап булыр иде. Шушы кадәр кирәкме инде?

Ничә күрәм күтәрелеп:
ялау да ялау һаман,
җитмәсә –
әле ыштансыз
һәм
тәһарәтсез
заман?!

Хакыйкатьнең татар шигъриятендә бу рәвешле артын ялтыратып мәйданга йөгереп чыкканы юк иде әлегә. Көлке дә, моңсу да. Һәм шагыйрь менторлыкка бирелергә мәҗбүр. Кая барсын? Бәлки, башка берәүнең шигырендә үгет-нәсыйхәтчелек калдыклары сиземләнсә, сару кайнаткыч тойгылар уятыр иде. Әмма Р. Мингалим – кулына сыек чыбыркы тоткан Ментор, ул шушы исемдәге бөек Одиссейның улы Телемахка акыл сабагын бирәчәк мөгаллим генә түгел, үткен каләмле урыс мөхәррире Н.В. Гогольгә кадәр һәм аннан соң да көленгән, каһәрләнгән, мыскылланган, алай да дәвалanусыз калган һәм гариплеген яшерүче, бөтен Рәсәй эчен беренче яратылыш көненнән үк исләндергән түрә-түрәчекләр белән эш итүче бүгенге көннең Каюм агасы.

Товарищлар!
Бу ни гадәт?
Килешми бу, кирәкми,
рас уйладың үзгәрергә –
ялашуны сирәклик!

Бу – җан авазы. Әдип бул да әдәпкә өйрәтми калдыр – алай барып чыкмый шул ул.

Р. Мингалимнең мондый темага язган башка шигырьләренә тимичәрәк торыйк. Тәнкыйть ишәге һаман да мәкер апарасына үрелмәкче.

IV

Р. Мингалим, – яшереп торасы түгел, замананың интернационалист шагыйре. Әйе шул, нигә кирәк иде инде болай да кыерсытылган, кимсетелгән, каһәрләнгән, сүгелгән, пычранып беткән урысны кимсетергә? Агайның үзенә ошамас бит!..

Донос менә шулай, шундый сүзләр белән башланып китәдер әле ул. Аны кем өстеннән язганда да, нәкъ шушы рәвешле сызгалап ташлыйсы, бер дә баш катырып торасы түгелдер әле! Хәер, моның

нәкъ шулай булуын, тәнкыйть мәкаләсен язарга алынучы буларак, сүзебезнең башында ук аңладык. Вакытында туктый белмәдек, чөнки дусларыбыз-танышларыбыз да үртәделәр, әдәбият профессоры булып йөрисез, бер тәнкыйть мәкаләсе дә язып маташтырганыгыз юк, имеш, дип мыскылладылар…

Донос сүзенең татарчасы, безнеңчә, әләкләү, әләк-шаклак китерү генә түгел, илтотарларга илтеп тапшыру булырга тиеш, башы-кулына, аягына кабал кидертеп, билгеле. Эһ, егетләр, туктатмадыгыз вакытында, табылмады арагыздан батырлар, инде шагыйребезне харап итеп ташлыйбыз, Ходам ярлыкасын!

Менә, җәмәгать, Р. Мингалимнең «Татар түбәтәе ник кара төстә, яки Ходай язса...» (2000) дип аталган һәм демократиягә гарык булган капиталистик илләргә хас постмодернистик алым белән язылган шигырен генә алып карагыз. Монда диндарлык та, хөр фикер дә, кайнар хис агымы да, «икеләнү» дә бар. Барысын да тәртип белән барлаганда, энәсе дә, җебе дә ачылыр. Карагыз әле нәрсә ди бу татарның бөек шагыйре!

Ходай язса, әгәр язса,
бирә бит ул байлыкны:
татар иле – татарныкы,
урыс иле дә аныкы?!
Зур урыска – бер генә ил
һәм шунысы кыенрак:
ил үзәге томанлырак,
чикләре – артык ерак?!

Хакыйкать ялчысы булгач, шагыйрь дөресен язмыйча кала алмый. Әмма мондый ук батырлыкны күкрәк киереп йөргән әллә ни кадәрле минкемнәр дә кыла алмады, ә Р. Мингалим... Ил эчендә егетлек күрсәтергә өндәгән дистәләп, йөзләп милләттәшебез барлыгына шигебез юк иде. Әмма Р. Мингалим һәммә ышанычыбызны аяк астына салып таптатты, өметләребезне юк итте, бу калай әтәчләрнең ялтыравыгына хәйран итеп йөрүебезне төшендереп бирде түгелме? «Кайда сез, егетләр?» – дип аваз салырга гына калды. Аларның берсенең дә шушы кадәр батыр йөрәкле булуларын кәгазь өстендәге каләм сугышында да күрсәткәннәре юк иде әлегә. Оят, бик оят! Хәтта үз йөзебезне көзгедән күтәрелеп карарга оят! Һәр дөрес сүздән куркып, хаталарны яшереп, ялагайлык, ялган һәм

куштанлык белән койрык болгап яшәүдә нәрсә башкара алдык һәм алачакбыз соң? Сәясәт мәйданында хакыйкатьнең башы түмрәнгә куелган һәм менә вәхшәтнең үткен балтасы айкалыр да – тын алырга да ирек бирмәс! Рәсәйнең иман шәмнәрен кабызып кына маташмакчы томана халкы шуны көтә, догага теле күнегеп җитмәс борын шуны ялварып сорый. Ә безнең Р. Мингалим интернацхис мәйданында тантана итә. Ник кенә шунда шовинизм мәйханәсендә туй иткән сәрхушларның акырышу-бакырышуларына колак салсын!

... Татарның –
иле икәү дә...
җиңел түгел аңар да:
ике илгә ярый торган
көй һәм бию табарга?!

Һәм, мишәр агайлар әйтмешли, суйган да каплаган! Ә сез: «Татарстанда әллә урыска яшәве рәхәтме?» – дисез. Нишлик, аларның китәр җирләре юк инде, бер уйлап карасак: Мәскәүгә кадәр – мукшы һәм татар җирләре, ә аннан ары – немец һәм карелныкы. Шагыйребез дөрес әйтә:

Ходай язса – бәндә күрә
тәкъдирендә ни барын:
Күрик әле, түзик әле,
Яшик әле, дусларым?!

Инде тагын да «Казанның 1000 еллыгы уңаеннан» язылган «Кылыч йөзе буйлап» (2001) шигырен укып карагыз. Казанны талаган, җимергән, халкын суйган, чукындырган өлкән агабыз урыс халкын шушы кадәр дә кызганырга, аның өчен җан атарга, хәсрәт чигәргә, дөньяның алдынгы әдәбиятларына гына хас постмодернистик алымнар кулланырга кирәк идеме икән?

...Иртән ачсам
Казан радиосын –
ишетәм татар гимны газабын:
авызын Мәскәү учы кыса сыман,
кысылып... тына... көйнең азагы.

И шагыйрь әфәндебез, йөрәгебезгә каты кагыласыз!

Р. Мингалимнең бу китабы интернационализм, интернацхис белән шыгырдатып тутырылган. Дөрес, милләтчелектән башка интернационализм була алмый, интернацхиснең асылы бөтен

барлыгы белән милли хисләр тантанасына корылган. Милләтче мәртәбәсенә ирешә алмасалар, шагыйрьләребез интернационализмга хилафлык китерер иделәр. Бу яктан Р. Мингалим иҗатын әдәбиятыбызның затлы үрнәге дип тәкъдим итә алабыз.

Сүзләребездә шик һәм шуклану юк, монысын да укучыларыбыз аңласалар иде. Каләм карасына бераз шаянлык һәм тапкырлык кушып җибәрү сүз тәме өчен алдынгы халыкларның әдәби тәнкыйтендә бик хуплап кулланыла, ә без исә, аларга ияреп, алар кояшында йөзебезне яктыртырга маташучы алама ай кисәге генәбез, бигайбә!

V

Әйтмәгәнебез булсын, сүзебез озынгарак китте, ахрысы. Әмма күпме хакыйкатьләрне аңлатырга өлгерә алмадык, ничәмә шигыренә күзәтү ясалмады, берсе артына икенчесе тагылып саналмады, төркемләнмәде, бүленмәде, киселмәде. Тәнкыйтебезнең мәкерле корчаңгы аты тигез юлда абынудан гайрегә ярамады. Ә шулай да тагын бер талпынып карарга, Р. Мингалимнең шигъри осталыгына кыек күзебез белән төбәштергәләп ук атарга җөрьәт иттек. Әйтәләр бит, һавадагы чыпчыкка угын мәргән тидерер дә тидерер, менә сукыр яки кылый – торнага эләктереп карасын, егет булыр!

Сез Р. Мингалим шигъриятеннән верлибр эзләмәгез. Дөрес, шигырьләре традицион түгел, авангардизм коткысына бирелгәннәр. Әгәр сезгә аллитерацияләр, аллюзияләр (иллюзия түгел), анафора, антетиза, ассонанс, гротеск, ирония, метафора, перифраз, анжанбеман һәм башкалар кирәк булса – алар монда тулып яталар. Хәтта центон һәм элипсисларны да очратсагыз, бер дә аптырап калмагыз, алдыгызда – замананың бөек татар шагыйре китабы. Монысы да куштанлык һәм шаярту сүзе түгел.

Р. Мингалим шигъриятендә, барыннан да элек, табигый һәм сыгылмалы, мәгънә-эчтәлеккә бай фикер агышын кысалаган форманың төзеклеге сокландыра. Шигырьләренең һәркайсында үз җене, үз җаны бардыр сыман. Хәтта җитәрлек дәрәҗәдә ныклы күренгән шигъри юлларында да верлибрны да чын шигырь итә алган өстәмә эчке бөтенлек бар. Верлибр гына да булырлар иде, әмма алар рифмасыз һәм ритмсыз түгелләр. Тезмәлек мәсьәләсендә Мингалим шигъриятенә тел-теш тидерерлек түгел. Әсәрләренең катлы-катлы шигъри бөтенлеккә корылуы сокландыра, гаҗәеп, бик гаҗәеп...

Кемгә ничектер, әмма бу җыентыкның иң затлы шигырьләреннән берсе дип «Шунда сине күрмим бит һаман...»ны атар идек. Аңа «Каләмдәшем Хәйдәр истәлегенә» дип куелган, ул 2001 елда язылган. «Замана шигыре нинди була» дигән сорауга «нәкъ менә үзе, төгәл шушындый була да инде» дип җавап бирер идек без. Бәлки, арадан кемнәрдер башкачарак фикердәдер? Мәйдан – егетләрнеке, тәнкыйть атын иярләгәндә, шайтан мәкеренә генә бирелмәгез, вәссәлам!

*2004*

## Зөлфәт шигъриятенең үзенчәлекләре

*(Әдәби-эстетик анализ тәҗрибәсеннән)*

Шагыйрь Зөлфәт ХХ йөзнең соңгы чиреге һәм XXI гасырның тәүге елларында татар әдәбиятында иң алдынгы вәкилләрнең берсе булды. Әмма аның шигъриятен билгеле бер чор яки дәвернең кысаларында гына калдырып булмый, ул киң фикерле әдип иде. Дөнья ваклыклары, көндәлек мәшәкатьләре белән бергә, аның шигъриятенә сыя алмадылар. Әдипләр күпчелек очракта билгеле бер чорның уй-кичерешләрен, хис-тойгыларын чагылдыралар. Зөлфәт андый шагыйрь түгел. Ул үз иҗатында чиксез иде, кешелекнең кичәгесенә дә, бүгенгесенә дә, хәтта киләчәгенә дә бәйле кичерешләр эчендә ялкынланып иҗат итте. Аны шулай ук аерым бер милләт шагыйре дип тә атап булмый, чөнки аның шигърияте аерым халыкның уй-кичерешләрен генә түгел, бәлки гомумкешелеккә хас йөрәк тибешен чагылдыра алу дәрәҗәсенә күтәрелде. Боларның сәбәпләре, әлбәттә, аның шигъриятенең көченнән, хисне сурәтли белү осталыгыннан, дөнья әдәбиятын һәм кешелек омтылышларын даими тоеп иҗат итүеннән килде.

Зөлфәт шигъриятен әдәби тәнкыйть табигать һәм мәхәббәт белән бәйле рәвештә бәяләп килде. Хакыйкатьне эзләүче шагыйрь буларак ачылуына зур игътибар бирелде. Һәр шагыйрьдәге кебек, Зөлфәтнең дә үз дөреслеге, үз хакыйкате бар иде. Ул аны иманы кебек үк кадерле һәм беренчел итеп кабул итте, аңардан чыгып фикер йөртте, башкаларга бәя бирде. Шәхес бары тик шулай гына яши ала. Аның лирик герое хакыйкатьне туктаусыз эзләргә мәҗбүр

булды һәм аны табигый матурлыкта тапты. Шушы хакыйкатьне эзләү һәм табу процессы аның шигъри йөрәген даими ялкынсытып торды, борчыды, һәм нәтиҗәдә, нәкъ менә шушы процесс аны чын шагыйрь ясады. Моның мисалы итеп 1999 елда язылган «Ходай сулышы» шигырен алырга мөмкин.

Инде кайтмас яшьлек
Йә якында,
Йә еракта учак кабыза,
Якын-ерак айкала да ялкын,
Бәгырьләрне өтә... Җан сыза!

Монда шагыйрь хис-тойгыларны учак белән бәйле тасвирлый. Бу учак, – әлбәттә, мәхәббәт учагы. Ул – нәкъ менә яшьлеккә хас күренеш. Лирик геройның үзендә түгел, бәлки аңа якында яки еракта кабынгалап тора, ягъни дөньялыкта яшьлек дәвам итә, яшьләрнең йөрәкләрендә утларын тергезә бара. Лирик геройның бәгырен инде менә шул якындагы һәм ерактагы ялкыннар өтеп ала һәм шуңардан йөрәге сызлана. Әмма монда аның җаны сызуны көнчелек дип түгел, бәлки яшьлегеннән ерагайган кешенең сагынуы дип кабул итәргә кирәк. Шул ук вакытта моның мәхәббәт ялкыныннан сызлануы да икәнлеген төшенми мөмкин түгел.

Зөлфәт – ашкын көчкә ия шагыйрь, ул уйлану рәвешендә фикер бирә дә бераз укучы күңелен аптырашта калдыра, шунда ук яшьлекне тасвирлауга күчә, аның нинди икәнлеген ачык күз алдына китерерлек итеп бәянлап бирә:

Шул баш бирмәс еллар –
кайнар яшьлек
Уңны-сулны белмәс булганга –
Кагылганмын былбыл оясына
Һәм басканмын кара еланга...

Монда яшьлекнең кайнарлыгы белән бәйле лирик геройның уйланылмаган гамәле гүяки саксызлыгы итеп, конкрет детальләр ярдәмендә төгәл тасвирланган. Былбыл оясы да, кара елан да әлегә символик мәгънәгә ия түгелләр. Үзсүзле лирик герой тормыш барышында ясаган хаталарын гына исенә төшерә дип укучыга уйларга кала. Шул ук вакытта, яшьлек кабызган учак белән бергә, ялкыннарның айкалуы һәм җан сызлануы, елларның баш бирмәс, уңны-сулны тоймас хәлгә лирик геройны төшерүләре укучыныкы

белән уртак һәм аваздаш яңгыраш таба. Хисләр мозаикасы көч ала. Үткән белән бүгенге тойгылар буталышы барлыкка килә. Әмма бу буталыш шигъри тасвирның мәгънәсен көчәйтү өчен файдаланыла. Яшьлеккә хас шашкын хисләр тәэсирендә калган лирик геройның былбыл оясына кагылуы һәм кара еланга басуы, һичшиксез, укучы күңелен хәвефле итә, моның нәрсә икәнлеген һәмниләргә китергәнен белү теләген уята.

Шагыйрь кабат яшьлек уты хакында тасвири фикерләүгә күчә, шул рәвешле хис алмашын барлыкка китерә, инде онытылырга тиешле кебек тоелган тема яңадан кабатланып, шушы кабатлануы сәбәпле, хатирәләргә илтүче романтик мотивка әверелә.

Дөрли генә яшьлек, ут шикелле,
Сүнмәс, капмас өчен кабынган –
Кичке шәфәкъләрдә учак кабыз
Кичәге таң офыкларыннан!..

Монда шигъри романтик мотив теманың тотрыклы үсешен тәэмин итүче төп чараларның берсе булып тора. Әмма ул темага өстәмә мәгънә дә бирә һәм аның тасвири бизәлешен арттыра, тәэсир көченә хезмәт итә. Яшьлекнең ут шикелле дөрләп, сүнмәс өчен кабынуы йөрәктә калдырган хисләргә бәйле. Зөлфәт шул хакта белдерә. Әмма ул яшьлек утын кабатланмас өчен кабынган дигән фикерне дә әйтә. Монда сүз яшьлек хисенең сүнәргә тиеш түгеллеге хакында бара, аңлашылып тора: ул бер тапкыр кабынып, инде сүнмәгән икән, аның кабатланып кабынуы хис бөтенлегенең саклануы өчен шарт түгел.

Шагыйрь – яшьлек хисләренең сүнми гомер буе сакланырга тиешлеген символик фикер ярдәмендә конкретлаштырып тасвирлау остасы. Ул монда да, шигъриятенә хас буларак, шушы үзенчәлегенә тугры кала һәм, «Кичке шәфәкъләрдә учак кабыз / Кичәге таң офыкларыннан!..» дип, фикеренә сурәтле мәгънә бирә. Монда сүз яшьлек хисләрен картлыкта да саклау кирәклеге хакында бара. Кичке шәфәкъне көннең ахыры, ягъни гомернең соңы дип күзалласак, кичәге таң офыкларының моңа капма-каршы булуын, тормышның яшьлектән офыклары киң ачылып башланып китүен аңларбыз.

Зөлфәт – теманы фәлсәфи эчтәлектә киңәйтә белү остасы. Ул моның өчен мәҗүсилеккә дә, тәңречелеккә дә, ислам дине тәгълиматлары кысаларында яшәгән суфичылыкка да үтә сак кагыла

һәм таяна белә. Шагыйрь кешелек тудырган һәм үстергән бер генә төрле тәгълиматны да кире какмый, аларның кешелек фикере-аңы үсешендә дә, иҗтимагый һәм табигый шартларда да әһәмиятләрен күрә белә. Зөлфәт шул тәгълиматлардан килгән белемнәрен үтә тоемлы шигъри фикер фәлсәфәсенә әверелдерү ягыннан җаваплы эш итә. Совет чорында марксизм-ленинизмга ничек таяна белсә, демократия дәверендә ул аларны кире какты дип әйтә алмыйбыз. Аңарда аң-белемгә, акылга ышаныч хисе көчле. Ул хакыйкатьне инкяр итүдән түгел, бәлки шул хакыйкатьтә тирәнәюдән һәм шул юлда киңәя белүдән эзли. Аның иң явыз дошманы – фикер тарлыгы, фикерне аерым кысаларга бикләү, аның иң сөйгәне – фикер, хыял һәм фәлсәфә хөрлеге. Әмма бу шартлы фикер бирү калыбында алып барылмый. Ул табигыйлекне сөя. Аның әсәрләрендә шигырь өчен кирәк булган бөтен нәрсә дә (сурәтләр, күренешләр, фикерләр, мәгънәләр һәм башкалар) үзләреннән-үзләре, үз табигатьләре белән үз урыннарында җиңел агым рәвешендә бөтерелеп барлыкка киләләр. Зөлфәт табигать белән сөйләшкәндә ничек мәҗүси өннәрне тартса, галәм белән ялкынлы тәңречелек тәгълиматы телендә аңлаша белә, күңел дөньясын ислам дине тәгълиматыннан башка күз алдына китерергә теләми. Аның өчен Аллаһы Тәгалә, Ходай иң беренче чиратта күңел дөньясының ачкычы булып тора.

...Ходай сулыш өргәч җан кергән бит
Безгә –
сынга –
үзле балчыкка!
Бәлки, тагын сулыш өрер Ходай?
«Житте...» – димә, йөрәк, ашыкма!

Үзле балчык гыйбарәсендә үзсүзлелек мәгънәсе дә бар. Бу шигырьнең «Ходай сулышы» дип аталуын да искәрсәк, шагыйрьнең фикерләвеннән аңлашылганча, сүз җан турында бара. Зөлфәт кешенең яңадан тууына һичшиксез ышана. Әмма башка сыйфаттагы туу түгел, ягъни будда дине фәлсәфәсенчә, кешенең үлемнән соң яки үсемлек, яисә хайванга әверелүе хакында сүз бармый, бәлки ислам дине тәгълиматы буенча кеше булып калуы турында. Шунысы әһәмиятле: Зөлфәт – дини-фәлсәфи тәгълиматларны ачык аңлап, бер-берсе белән бутамыйча фикерли белә торган әдип. Бу факт аның белем киңлекләре һәм аң дәрәҗәсенең камиллеге хакында ачык сөйли.

Зөлфәт, шигырьдә яңа бер тематик күчеш ясау өчен, фикер юнәлешләрен үзгәртеп куярга ярата. Әмма мотив һаман да саклanып кала. Шул сәбәпле теманың эзлекле үсеше дә тәэмин ителә. «Ходай сулышы» шигыренең беренче биш строфасында теманың үстерелешен «ут, учак» сүзләре белән бәйле эчтәлек тәэмин күтәрә. Шушы ук вакытта Зөлфәт шигъри фикерләмәләр һәм сурәтләр эчендә Ходай сулышы, былбыл, кара елан белән бәйле яңа тематик юнәлешләргә корылган фикерләмәләренә дә юл ача, әмма ут һәм учак әлегә төп романтик мотив билгеләре булып кала киләләр.

Ут йөгергән шул сулыштан
Сулык-сулык типкән бу канга –
Димәк,
сөю булып килеп кердең
Үзең гомер иткән Ватанга!

Аңлашылганча, монда сүз мәхәббәт тәэсирендә кешенең камилләшүе белән бәйле үзгәреше хакында сүз бара. Әмма ул бу юлы башка тематика кысаларында, үлгәннән соң туу түгел, бәлки яшәгән кешенең яшьлектәге кабатланмас үзгәреше хакында. Зөлфәт кешенең бөтен яшәешенең асылы мәхәббәттән гыйбарәт икәнлеген ачык белдереп яза. Ул аның башкача, башка төрле тәэсирләрдән була алуын шигъриятендә күз алдына китерергә дә теләми.

Билләһи, дим:
гомер дигәнебез,
Еллар белән санап карасаң,
Мең афәтле еллар түгел һич тә –
Мәхәббәтле еллар лабаса!

Шагыйрь бу ачышын тантаналы төстә яңгырата. Антик һәм борынгы әдәбиятлардан ук үстерелеп килгән шушы фикер көчле яңарыш кичерә, шуның аркасында хакыйкатьнең асылын конкретрак төшенү формасы буларак аңлашыла: монда шагыйрь мең афәтле елларга мәхәббәтле елларны каршы куя. Шул сәбәпле мәгънә тирәнлеге дә барлыкка килә.

Зөлфәт һәрвакыт әдәби-фәлсәфи ачышлар шагыйре булды. Аны шигырьнең ритмик буыннарын үзгәртү белән бәйле табышлар да, рифма уйнатулары да кызыксындырмады. Алар аның шигъриятендә очрасалар да, әдипнең иҗади теләге аркасында түгел, бәлки табигый рәвештә, шигырь һәм мәгънә агышы аркасында гына шулай

килеп чыккаладылар. Зөлфәтне әсәрләрендәге хис агымының мәгънә белән уратылып һәм өртелеп барылуы күбрәк кызыксындырган. Шигырьдә мондый агышны саклау гаять авыр. Иң беренче чиратта мәгънә үстерелеше әдиптән фикри эзләнүләр таләп итә. Шагыйрь бер әсәре кысаларында төрле фикер юнәлешләренә кереп китәргә мәҗбүр була. Алар эчтәлектә чагылмый калмыйлар. Андый хатадан котылу өчен, Зөлфәт фикерне сурәткә әверелдерә, теманы саклау максатында, шигъри мотивларга аеруча зур игътибар бирә.

Чәчләремне еллар тараганда,
Уйларымны еллар тарады –
Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Кара елан миңа сайрады.

Зөлфәт бөдрә чәчле иде. Яшьлегендәге купшы бөдрәләре, ул олыгайгач, тәмам тигезләнеп беттеләр диярлек. Әгәр дә шушы фактка игътибар итсәк, чәч бөдрәләренең кайнар холык һәм хис билгесе икәнлеген кыяфәтнамә гыйлеме ярдәмендә күзалласак, чәч тарауның монда шул бөдрәләренең тигезләнүе буларак бирелгәнлеген аңлавы авыр түгел. Шушы тәгъбирдән чыгып, лирик геройның еллар узган саен холкы утыруы хакында сүз алып барганлыгына төшенәбез. Шагыйрь хәтта уйларның да еллар узган саен тигезләнүе, ягъни хисләрдән арына баруы хакында әйтә. Боларга капма-каршы куеп, йөрәген былбыл чагу, кара еланның сайравын тыңлавы хакында искәртә. Бу фәлсәфәсе хисен һәм холкын аңлатучы сәбәпләр сыйфатында бирелә. Яшьлегендә былбыл оясына кагылган, кара еланга баскан иде ул. Шигырьдә шушы тема лейтмотив булып кабатланып килә, әмма яңа эчтәлек ала бара: былбыл – йөрәген чага, кара елан аңа сайрый. Монда былбылның агуы хакында, еланның моң бирүе турында сүз бара дияргә мөмкин. Боларның асыл мәгънәсен аңлавы авыр түгел: сүз шагыйрьнең үз шигъриятенә бәясенә бәйле. Зөлфәт үз иҗаты хакында уйлана һәм аның эчтәлеген дә, үзенчәлекләрен дә ачарга, аңлатып бирергә омтыла. Сәбәпне яшьлегенә, шашкын мәхәббәт хисләренә китереп бәйли.

Зөлфәт конкрет формалар һәм сурәтле күзаллау ярдәмендә фикерли, дидек. Шигырьләрендә мәгънәне образларда тасвир итә. Аның бу осталыгы әсәрләрен хисле һәм киң яңгырашлы итә. Шигырьләре хисне гомуми планга алып язудан башланып, конкрет вакыйганы тасвирлауга күчә, ахырда яңадан гомуми план алына.

Шушы рәвештә әдәби конструкцияләрен коруы шигырьләренә укучы күңеленә ирешү өчен юл ача. Алар тормышчан һәм аңлаешлы эчтәлектә булып чыгалар. Шагыйрь, мондый формаларның беркатлылыкка, артык гадилеккә китерүен аңлап, теманы мотив һәм лейтмотивлар белән шактый катлауландыра алды, шуның белән шигырьләрендә хис һәм мәгънә көчен арттырды. «Ходай сулышы» шигырендә дә ул шулай эшли.

... Ник тоташтан
гашыйк булам һаман?
Алгысытыр еллар күп мәллә?
Ходайның бер Кашка Тәкәсеме?
Яшәр җирем – Изге Күк мәллә?

Монда, «Ходайның Кашка Тәкәсе» дигәндә, автор «Аллаһының Сөеклесе» дигән төшенчәне файдалана. Исмәгыйль пәйгамбәргә нисбәтле вакыйгалар күз алдына килә. Шагыйрь тоташтан гашыйк булуның сәбәбен эзли һәм аны яшәү белән дә, Аллаһының сөекле бәндәсе булуга да бәйли, мәхәббәт аркасында кешенең урыны Изге Күк булачагын да белдерә. Гыйшык өчен җавап бирәчәге дә аны куркыта, мәхәббәт аркасындагы гөнаһлары савапка әверелүгә дә өметләнә.

... Туймас-төкәнмәс бу
гыйшкым өчен
Ни диярмен анда – азакта?
Яратудан кылган гөнаһларым
Саналмасмы икән савапка?

Монда сүз җилбәзәклек турында бармый, билгеле. Шагыйрь шагыйранә мәхәббәт хакында фикерләрен җиткерә. Аның шулай икәнлеген алдагы шигъри строфада тагын да конкретлаштырып әйтеп бирә:

Уйнаклап кан,
әйбәт җөмләләрне
Яшьтән шигырь итеп
мин шаштым –
Болар миңа савап саналмас шул...

Болар –
минем бетмәс гөнаһым!

«Шигырь – шайтан чыбыркысы!» дигән гыйбарә бар. Аны Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисенә нисбәт итәләр. Хикмәт шунда:

Мәккә тормышына бәйле чорда Пәйгамбәрдән кяферләр шигырьләр-такмаклар әйтеп көлеп мыскыллаганнар. Шигырьнең күңелгә җиңел үтү үзенчәлеге бар. Пәйгамбәребез шул шигырьләрдән бик тә мыскылланган һәм, җавап буларак, игътибарга алынган хәдисен әйтә торган булган. Монда шигырьнең бәгырьне телгәләве хакында сүз бара. Әмма гасырлар эчендә бу хәдиснең эчтәлеге вакыйгасына бәйсез аңлатыла башлап, шигырьне шайтаннан килә дигән фикер таралыш алган. Суфи шагыйрьләр шунлыктан шигырьгә мөмкин кадәр дини мәгънә салып, аның хискә корылу үзенчәлегеннән баш тартырга тырышканнар, шуңа күрә әсәрләре коры дидактик эчтәлектән гыйбарәт булган формаларга кергән. Бары тик XIX йөздә Г. Кандалый һәм М. Акмулла татар әдәбиятында шигърияттне хис стихиясенә кайтару эшен башлап җибәрәләр. Зөлфәтнең исә бетмәс гөнаһ дип әйтүе схоластик дини карашлар тәэсиреннән икәнлеге укучыга аңлашылып тора. Әмма, әйткәнебезчә, Зөлфәт һәртөрле тәгълиматлар һәм карашлар белән җаваплылык һәм хөрмәт хисе тоеп эш итә. Китерелгән мисал моны тагын да ачык дәлилләп тора.

Зөлфәт хисләрне ничек кабартса, шулай тынычландыра да белә. Аның гөнаһ һәм савап хакында шигъри уйланулары «Ходай сулышы»нда да шушы рольне башкара. Укучы ул каршылыклар эчендә тетрәнү ала, бу аңа рухи чистарыну бирә. Шагыйрь моны аңлап эш итә һәм, тынычлану стихиясенә бирелеп, шигъри мотивны кабатлап яңгыратып ала. Хис камиллеген тудыруда мондый уңай композицион юлларны файдалана белүдә Зөлфәт кебек уңышлы иҗат иткән шагыйрьләрне күпләп санап булыр иде. Г. Тукайның «Пар ат»ы моңа отышлы мисал икәнлеген искәртеп үтү дә җитәр.

Зөлфәт тынычлануның ни-нәрсә икәнлеген килешү һәм язмышын ничек бар шулай кабул итү турындагы шигъри юлларында тасвирлап бирә:

Китмәс өчен килде, ахры, яшьлек...
Тетрәп,
дөнья онытылганда
Кагылам гел былбыл оясына,
Һәм...
басам гел кара еланга!

Ахырына таба шигырь яңадан тантана көчен ала. Мотив буларак сайлап алынган былбыл һәм кара елан вакыйгасы, ешрак кабат-

ланып, лейтмотивка әвереләдерелеп, әсәрдә төп фикер доминантасын барлыкка китерә.

Рәхмәт, дөнья,
Язмышның син миңа
Тоташ шигырьлесен сайладың, –

Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Һәм өздереп елан сайрады!..

Упкын төпләрендә гөлләр үскән
Кыяларны белеп сайладым...
Мин
былбылдан сезне чактырырмын,
Тыңлатырмын елан сайравын.

Зөлфәт нечкә күңелле лирик шагыйрь буларак дан алды. Аның әсәрләре вакыт чиксезлеге тоемында, кешелекнең яшәеш фәлсәфәсе кысаларында язылган. Әдипне һәрдаим кеше табигате, аның уй-кичерешләре, хисләренең бөтенлеге кызыксындырды. Шигырьләре күңел мәгънәсе тирәнлегендә туып, халкыбызның теләкомтылышларын гомумкешелек мәртәбәсендә яңгыраттылар.

*26.01.09*

## Урал тулпары

*(Шагыйрь Р. Ягъфәров иҗаты үзенчәлекләре)*

Рәшит Ягъфәров галим булып яшәде. Фольклорист иде. Милли хәрәкәт җитәкчеләреннән берсе булып күтәрелде, халкыбызның хөрмәтен яулады. Ә аның шагыйрь икәнлеген бөтенләй дә белмәгәнбез. Ул, чынлап та, шагыйрьлеген артык күрсәтмичә, танытмыйча, шул бөеклеге дәрте белән саф хисләргә бай, затлы күңел моңында сызып кына сагышланып яшәүчеләрдән дә түгел иде сыман. Аның күкрәк аранында мәңгелеккә таба томырылырга тиеш булган тулпар тышауда торган. Көннәрнең берендә ул алтын тояклы, киң канатлы шигъриятенең тулпары үзен тоткынлыкта тоткан диварларны ватып-җимереп, бәреп чыгар да үзенең күркәмлеге белән безне сокландырыр дип көтәргә дә түгел иде. Әмма замананың шартлы билгеләре алып ташландылар. Кичәге идеология шигърияте чигенде. Халыкка чын әдәбият кирәк иде. Яңа, кешелек хисләрен түкми-

чәчми сөйләп бирүче әдәбиятны мәйданга чыгарган шагыйрьләребездән, үткәннән килеп, әмма яңа заманныкы буларак тавышын ишеттергән әдипләребез арасында Р. Ягъфәров та бар иде. Ул вакытлардан бирегә таба еллар узган, ераклаша барган саен, моның шулай икәнлеге тагын да ачыклана төште. Тарихыбызга без дә хөрмәт белән карарга өйрәндек. XX гасырның 90 нчы еллары иманыбызны төзәтте. Ул чор татарның шанлы әдәби мирасын кабаттан кайтып тикшергән, асылда, Г. Исхакыйны гаделлек байрагы итеп күтәргән чаклары иде. Күп әдипләр үз иҗат мирасларын тарих үлчәвенең хөкеменә тапшырдылар. Яңа чор идеал эзләде, шигърияттән илаһи сүз көтте. Әмма яңалар туарга өлгермәгән, без аны кабул да итәргә өйрәнмәгән идек. Бу юлы да онытылган, игътибарсыз калдырылган иҗатлар ярдәмгә килде. Менә шул чорда иске, күнегелгән исемнәр яңа төсләрдә, яңа форсатта яңгырадылар.

Р. Ягъфәровның «Карт диңгезче җыры» (1967), «Агымсулар моңсулата» (1968), «Акбүз ат» (1968), «Тулпарларым» (1969), «Сагынылды» (1969), «Бүген тагын...» (1969), «Кайтыр юлда апак томан» (1969), «Тол буенда» (1969), «Тынгысыз төн» (1970), «Рәхмәт, җырым...» (1971), «Шоңкар моңы» (1971), «Гафу сорыйсы бар...» (1971), «Кайттым бит...» (1971), «Хыянәт» (1976), «Илле яшем» (1981), «Балалар паркында» (1981) дип аталган шигырьләре яратылып укыла башладылар. Аның «Сабантуй мизгелләре» (1975) шигырьләр циклы үзенә бер әдәби табышка корылган, бәйрәмнең күңелле уеннарына багышланган күренешләргә бәйле хискичерешләрне тасвирлау белән характерлы. Дөрес, Р. Ягъфәровның сәяси шигырьләре дә шактый. Уйландыралар. Фикергә этәрәләр.

Шигырьнең хикмәте тышкы һәм эчке кичерешләрнең гармониясен әдәби мантыйкта мәгънәле итеп бирә белүдән гыйбарәт. Гади һәм гадәти итеп язу осталыгы беркатлы тезмәләр белән әсәрне тутыру түгел, бәлки гади һәм гадәти тоелган, кешенең, һәр шәхеснең дөньясында-табигатендә бар хисләр-тойгыларны күңел төпләренәчә төшеп айкалдырырлык, чайкалдырырлык, шуның белән рухи сафлыкның, мәгънә энҗеләренең һәр йөрәктә ачылып китүләрен тәэмин итеп яза белүдән гыйбарәт. Бездә сүз куерталар, мәгънә авырайталар, фикер бирү артыннан куалар. Ә югыйсә чын шигырь өчен әллә нәрсә кирәк тә түгел сыман. Хисләрне тасвир итеп бирү дә җитә. Әмма моны чын шагыйрь генә башкара ала.

Р. Ягъфәровның шигырьләре арасыннан уналтысын сайлап алып күрсәтүебез – аларның менә шушы дәрәҗәдә гүзәл язылган булуларын таныту өчен мисалга китерүебез ул. Алар классик дәрәҗәдә туганнар. Рәшитне чын мәгънәсендә шагыйрь Рәшит Ягъфәров иткәннәр. Язылган елларына карасак, алар 1967 елдан 1981 еллар арасында туганнар (1967 дә – 1; 1968 дә – 2; 1969 да – 5; 1970 тә – 1; 1971 дә – 4; 1976 да – 1; 1981 дә – 2). Аз да, күп тә түгел. Китапта басылып чыгу елларына караганда – чын мәгънәсендә әдәби мирас. Тыелган мирастан да түгел, бары тик күз уңыннан читтә калган, әмма, вакытлар узган саен, күңел-рух ихтыяҗыбызны канәгатьләндерүдә кирәкләре арта барган шигъри мирастан алар. Шул әсәрләреннән күренгәнчә, Р. Ягъфәровның иҗаты 1969 елга чын асылы белән оешып җитә, 1971 елга кадәр үз көчен саклый. Ә аннары сүрелә бара. Аның 1970–1971 еллары, шигырьләреннән күренгәнчә, «Солдат дәфтәре» чорына туры килә. Р. Ягъфәров әгәр дә 1967–1969 елларда тапкан һәм ирешкән шигърилеген югалтмый саклап, алга таба көчле ялкынлы учак итүгә ирешсә, халкыбыз аның шигърияте җылысында күңелен савыктырып яшәгән булыр иде. Әмма моның өчен аңа тормыш та, Тәңренең бирмеше дә җай куймаганнар (ул үзе бу хакта болай дип белдерә: «Тәңрем миңа үзгәреп торучан холык биргән»[1]).

Р. Ягъфәров озак еллар буена киң җәмәгатьчелек алдында шагыйрь буларак беленми торды, дидек. Бу хәл, бәлки, дуслары, туганнары өчен сер дә булмагандыр? Бәлки, аңа наширләр, әдәби редакторлар юл бирмәгәннәрдер?

Р. Ягъфәровның 1969 елда ук язылган «Тулпарларым» шигыре – иң камил әсәрләреннән берсе. Күңеле тулы уйларын ул ыргылырга торган тулпарлар итеп тасвирлый. Шушы уйлары аны йокысыннан уята. Лирик герой алар артыннан йөгерә-чаба.

Бу шигырьнең серле хикмәте бар. Шигъри тойгы-хиснең үзгәреше бер фикердән икенчесенә әверелеш рәвешендә бирелгән. Мондый шигырьләр дөнья әдәбиятында да сирәк очрый. Аны хис-тойгы, хыял-өмет могҗизасы буларак аңларга кирәк.

---

[1] *Ягъфәров Р.* Язмышым – шигырьләремдә [Сүз башы мәкаләсе] // *Ягъфәров Р.Ф.* Тулпарлар моңы: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – Б. 3.

Башны салып йокымсырап китсәм,
Шул тулпарлар кешнәп уята, –

ди шагыйрь. Лирик герой сикереп тора. Әмма тулпар-уйлары юлларда дага чыңы калдырып үтеп киткәннәр. Шагыйрь рухы, алар артыннан калмый, гомер буе шулай йөгерә, бары җил-давыллар – аның юлдашы.

Р. Ягъфәров, уйларны ыргылучы атлар итеп сурәтләп, яңалык та ачмыйдыр кебек. Уйлар шундый инде алар, хыяллар кебек үк ашкыналар. Әмма шагыйрь:

Егылып калсам, очкан тулпар итеп
Ясасыннар минем гүр ташын, –

дип белдерә дә бөтенләй башка тойгылар, мәңгелек белән тоташкан горур һәм мәгърур хисләрнең сафлыгына хисләрне күчерә.

Ир егеткәй белән ат башына
Тәңрем белгән ниләр бирәсен.
Тулпарларга – канат,
Миңа исә
Тулпар җанын биргән, күрәсең.

Бу шигырь – чыннан да могҗиза; ул хис, тойгы, сурәт, фикер могҗизаларының бербөтен булып әверелүеннән туа. Әсәр шагыйрьнең 2006 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан Казанда бастырылып чыгарылган 143 битле «Тулпар моңы» исемле шигырьләр җыентыгыннан. Китап шушы камил, могҗизалы шигырь белән ачылгач, андагы һәммә әсәрләрдән дә шушындый ук бөеклекне көтәсең. Аның янәшәсендә «Рәхмәт, җырым...» шигыре килә.

Аның үзәгендә «идеалларга таба китеп баручы» лирик герой сурәтләнелә. «Йөзен кисеп ачы җил исә». Менә шунда шагыйрь халык җырларын искәртә, лирик геройның «Кара урман»ны җырлавын сурәттә биреп ала. Шундый җырлар упкыннарга төшәр мәлдә өскә күтәрүен белдерә. Асылда, җыр канатлары, дөньяның моң-зарын кыйный-кыйный, кеше рухын күккә ашыралар икән. Шагыйрь моның шулай булуын чынлап ышанып, ихластан яза һәм укучының да гомеренең авыр минутларында җырда күңелен юатуларын исенә төшерерлек итеп тасвирлый. 1967 елда ук иҗатында туган «Карт диңгезче җыры» (аңа автор «Укытучыларыма» адресын да куйган) шигырендә көймәсен, йөзгәнендә аумасын

дисә, дулкыннарга каршы йөздерергә киңәш иткән карт диңгезче вә диңгездә көймәсен дулкыннарга каршы алып баручы яшь кеше сурәтләнелә. Бу шигырь әдәбилек ягыннан да талантлы эшләнелгән. Шагыйрь аны 21 яшендә язган.

Р. Ягъфәров шигырьне сурәтле вакыйга, күренешләр үзгәреше чалымы тасвирлары белән иҗат итә. Мирасында үзгәрешсез, хәрәкәтсез калган күренеш шигърияте бөтенләй юк. Сурәтле тасвирларының хәрәкәт егәре дә көчле, тәэсирле. Алар – олы, гаҗәеп әһәмиятле вакыйгаларның шигъри мизгелләреннән гыйбарәт, тормышның чиста-саф булып күңелдә уелып кала барган хакыйкатьләре, әлбәттә. Болар – шагыйрь Р. Ягъфәров иҗатының асыл үзенчәлекләре, аның әдәби мирасын кыйммәтле дә, әһәмиятле дә иткән төп сыйфатлары да.

*Февраль, 2013*

## Флера Тархănованың шигъри гаме

*(Шагыйрәнең иҗат мирасын барлаганда)*

Шагыйрә буларак дан алган Чистай кызы Ф. Тарханова үзенең гаҗәеп чибәрлеге, ягымлы-моңсу якты күз карашы, үзен тәрбияле һәм пөхтә тотуы белән арадан бер, хәтта бердәнбер диярлек затлы ханымнардан иде. Киң кырлы иҗат эшчәнлеге алып баруы, алар янына иҗтимагый җаваплылык тойгылары эчендә яшәве аны ил халкы каршында олы хөрмәткә ия итте.

Сагындыра, үлеп сагындыра
Туган якның чәчкә-гөлләре.
Шул сагыну салган тирән сагыш
Йөрәгемә кадәр үрләде[1].

Бу шигъри юллар Ф. Тархановaның шигъри гаме өлгеләреннән. Ул шушы дулкында иҗат итте һәм күңелен халыкка ачты. «Яуширмәгә кайттым», «Үпкәләмә миңа, туган авылым», «Чистай», «Әни җыры», «Әйләнде дә кайтты иленә» – бу шигырьләре шуларның берничәсе генә.

[1] *Тарханова Ф.Г.* Йөрәгемә яшерелгән серләр: шигырьләр, җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001 (191 б.). – Б. 7. (Мәкаләдә шигъри өзекләр алга таба да шагыйрәнең шушы китабыннан алып бирелә.)

Кеше күңелен чит-ят җирләр тартмый, чакырмый түгел. Бәхет эзләү дигән нәрсә бар инде ул, адәм табигатенә хас үзенчәлек. Әмма барыбер дә туган туфракны сагыну, җирсү хисләре кеше күңеленнән китми йөдәтүчән. Таныш тойгылар. Ф. Тарханова: «Тик аяк басуга ул җиргә, сагынам туган илемне», – дип яза белде. Аның лирик герое туган иленең гөлләренең хуш исләренә, җырларының көйләренә сусый. Туган иленең болыны гөлләргә ничек бай булса, шулай ук туган халкының җырларына да ямьне туган теле бирүен аңлый һәм тоя, шулар хакында яза ул «Җирсү» шигырендә дә. Туган җирнең гөлләре, иленең җыр-моңнары аңа яшәү бирә, күңеленә үлемне җиңү хисен өсти. Шагыйрьнең мәңге яшәү, үлемне җиңү хисе туган туфракка мәхәббәтеннән килә. Мондый хис М. Җәлил шигърияте идеалларының дәвамчысы, җәлилчеләр кичергән тойгылар белән шагыйрәнең дә лирик герое яшәве хакында сөйли. Туган авылына кайтуы Ф. Тарханованың хәтта күз яшьләрен кузгаткан («Яуширмәгә кайттым»), чөнки анда яшьлегендә калган чәчәкләр инде юк, танышлары да табылмый, иске урыннар да үзгәргән… Монда бары хатирәләр генә калган, хәтта тузган туган нигездә дә бары турсаюга гына юлыга. Болары – яңа сүз, дөньяны яңача тойдыруы шагыйрәнең. Монда алар тугыз бала үскәннәр. Лирик герой күңеле тулган хәлдә калага китеп бара. Бөтен җирдә ул кайтуында аны сагыш каршы алган, бар җирдән дә аны сагыш озатып калган. Әмма шагыйрә белә:

Авылымның сихри табигате
Шифа биргән элек-электән,
Үскән анда кызның иң чибәре,
Егетләре булган сөлектәй.

Бала чагында шагыйрә туган авылында бары тик матурлыкларны гына күрә. Мәчет манаралары, күккә ашып, аның күңеленә маяк булып калкып торганнар. Аларны җимергәч дөньяның яме китсә дә, ярый хәзер яңасын салганнар, дип яза ул «Шөкер, Аллам!» шигырендә. Хәзер яңа мәчетнең манарасы бүгенге авыр заманда юлын югалткан кешеләргә маяк булачагына ышанып иҗат итте Ф. Тарханова.

Шагыйрә туган авылыннан унбиш яшендә үз бәхетен эзләп чыгып китәргә мәҗбүр була. Әмма бәхетенең орлыклары туган туфракка күмелеп калганлыгын, тишелеп чыгарга һәм чәчәк атарга

аны көтеп торуын ачык тоеп яши башлый. Шуңа да җирсү хисе белән көннәре үтә.

Әти йөргән юлга,
Әни сукмагына
Сыкрый-сыкрый тамды яшьләрем,
Изге туфрагымнан
Дәрман алгангадыр,
Яшен кебек күкрәп яшьнәдем.
(«Каршы алырмы?»)

Шагыйрьләр шигырьдә үз шәхси хисләрен, үз шәхси тойгыларын лирик герой аша сөйләргә тиешләр. Шигырьнең үтә шәхси булуы аны иҗтимагый яңгырашлы итә. Шигърият ихлассыз туа һәм яши алмый. Үз күңел тойгыларын читтә калдырып, иҗтимагый тормыш күренешләрен сөйләү белән мәш килгән шагыйрьләр әдәбиятта озакка кала алмыйлар. Андыйларның урыны сәясәт өлкәсенә күчә, алар публицист булып китәләр. Лирика чиген бозып үттеләрме, аларның хисләрендә ихласлылык бетә, югала. Вак шагыйрьләрне ихлас була алмаулары, шул ихласлыкны тоя белмәүләре тагын да кечерәйтә һәм югалуга илтә. Кечкенә кошларның язмышы һаман да лачыннарның чукып алуыннан җаннарын саклаудан гыйбарәт. Шунлыктан алар як-якларына даими каранырга мәҗбүрләр. Аларның күзләрендә курку шәүләсе ята, күңелләрендә бер бөртек азыкка, бер тамчы суга мохтаҗлык яши. Сайрар кошларны, бигрәк тә сандугачларны, гадәттә шагыйрьләргә тиңлиләр. Шуннан чыгып, сайрар кошлар лачыннар кебек эреләрдән булмыйлар, дибез. Бу – әдәби чагыштыру гына. Аңа билгеле бер шартта гына ышанырга була. Олы шагыйрьләргә кечкенә кошларга хас курку, сагаю хисләре бөтенләй ят. Алар вак-төяк хис-тойгыларны да йөрәкләре аша уздыручан. Шуның белән бергә, аларның эчке дөньясында чиксез гармония яши. Әмма ул теләгәнеңне сөйләү, теләгәнеңне хис итү кебек чуарлыктан гыйбарәт түгел. Зур шагыйрьләрдә рухи көч була, ул ташкын кебек бәргәләнергә, бөтерелергә дә мөмкин, ярларын эзләп шашынмый калмый. Олы елгаларга да, үз ярларына сыенып, агымга бирелү хас. Үз ярларын ташламый агымда булу барча агымсуларның табигате. Хәер, чишмә дә үз яме белән челтери, Идел дә үз сагышында ага. Шагыйрьләрне кошлар белән дә, елгалар-чишмәләр белән дә чагыштырып була,

билгеле. Аларның шигъри табигатен хәтта йолдызларга янәшә кую да урынлы. Шагыйрьләр мәңгелек сер ияләре шул. Бөек илаһи серләр аларның күңелләренә яшерелгән. Һәм алар безгә шуларны, һичбер яшермичә, ихластан, күңелләребезгә салырлык мәртәбәдә хис иттереп сөйләп бирә беләләр. Менә шуңа күрә дә Ф. Тарханова шигырь җыентыкларыннан берсен «Йөрәгемә яшерелгән серләр» дип атаган түгелме? Ышана ул үз укучысына, аңлауларын, кабул итүләрен өмет итә. Бу – чын шагыйрьләр теләге!

Шагыйрьләрнең бөеклеге әниләренә атап язган шигырьләреннән җиңел ачыклана. Ә шагыйрәләр күңеленең ихласлыгы ана булу тойгыларында якты сиземләнә. Ф. Тарханова шигырьләрен укып, әнисенең Саба ягыннан булуын да, башлангыч сыйныфларда укытучы икәнлеген дә белми калмыйсың. Кырык икешәр балалы сыйныфлар булган Яуширмә мәктәбендә. Әтисе дә мөгаллим Ф. Тарханованың. Тормышлары да җиңел генә бармаган. Бу типтагы шигырьләре арасында «Әле һаман янәшәдән атлый» шигыре кебек, эчтәлектә, мәгънәдә генә түгел, шигъри ямьдә тагын да матуррагы бармы икән? Бу шигыре әнисенең нинди әни булганлыгын үзе ана булгач кына аңлаган лирик геройның хисләрен тасвирлавы белән дә күңелләрдә шактый җылы, ягымлы тойгылар калдыра.

Ф. Тарханованың язмышы гыйбрәтле. Ул чыннан да унбиш яшендә, 1962 елда Арча педагогия училищесына барып укырга керә[1]. Чистай районы Яуширмә авылының укытучылар гаиләсендә туып үскән кыз балага шулай яшьли ерак юлга чыгып китүләре авыр булгандыр? Әти-әнисе, туганнары, дуслары, якташлары сагындыргандыр? Елагандыр? Башкача була алмый. Адәм баласын ихлас күз яшьләре дә шагыйрь ясый ала, дибез. Бәлки, шулайдыр? Монымы бәхәс итәргә мөмкин?

1966 елда укуын тәмамлап, 19 яшьлек кыз Чистай районы Чирүле Шонталасы мәктәбенә укытучы итеп җибәрелә. Ул бераздан соң моннан Кыргызстанның Ош өлкәсенә китеп бара һәм андагы мәктәпләрдә математика һәм рус теле укыта. 1970 елда Казанга килеп, университетка укырга керә. Һәр әдипнең көче – әдәби та-

[1] Шагыйрәнең тормышына бәйле мәгълүматлар «Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – Т. 2. – 736 б.» китабыннан алынды, б. 418–419.

лантында һәм аң-белем дәрәҗәсендә[1]. Аларның икесенә дә таләпләр югары булырга тиеш. Моны Ф. Тарханова яхшы аңлый, шуңа да университетның тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген сайлый. Университетта укуын тәмамлагач, аны аспирантурада калдыралар. Әмма гаилә хәле ике елдан аның тормышына төзәтүләр кертә. Ф. Тарханова «Радиоприбор» заводына инженер-конструктор эшенә күчә һәм ул унике ел шунда кала. Бу еллар аның әдәби иҗатының һәм фәнни эзләнүләренең чыннан чәчәк аткан чоры булыр иде югыйсә.

Бары тик туксанынчы еллар башында гына Ф. Тарханова әдәби иҗат эшенә кире кайту бәхетенә ирешә, соңрак фәнгә дә кабаттан килә. Баштарак ул журналистика эшенә тартыла. Бу аның үз тормышын өченче тапкыр яңабаштан башлавы була. Шушы вакыттан ул газеталарда тәрҗемә бүлекләрендә эшли, «Татарстан хәбәрләре» газетасында тәрҗемә бүлегенә җитәкчелек итә. Шушы вакыттан шигырьләре, очерклары, хикәяләре матбугат сәхифәләрендә күренә башлый. 1995 елдан Ф. Тарханова Татарстан Министрлар Кабинеты аппаратында тәрҗемәче-баш референт булып эшли башлый, терминология комиссиясе утырышларында актив катнаша, сүзлекләр әзерләү һәм төзү эшләренә дә тартыла. 2005 елда эш кәгазьләре һәм документлар теленә бәйле кандидатлык диссертациясен яклый.

2007 елдан Ф. Тарханова әдәби иҗат һәм әдәби әсәрләрне тәрҗемә итү белән генә шөгыльләнүгә күчә. Бу вакытта ул лаеклы ялда була. Әдәби әсәрләре аерым җыентыклар булып 1998 елдан бастырылып чыгарыла. Бу вакытта Ф. Тарханова илле яшеннән узган була. Шигырь җыентыкларыннан беренче китабы – «Синең кайнар сулышың» (1998) – җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына. «Йөрәгемә яшерелгән серләр» (2001), «Яшьлек эзем калган сукмаклар» (2005), «Язмышлар язылганда» (2007) җыентыклары милли хисләр белән сугарылган, милләткә хезмәт итүдә бәхет тапкан лирик геройның яшәешен, күңел дөньясын укучыга тигез ачалар.

---

[1] *Карагыз: Метченко А.И.* Избранные работы: в 2-х т. – М.: Худож. лит., 1982. – Т. 1. Кровное, завоеванное: Из истории советской литературы. – С. 50–51.

Бер карасам җәл дә кебек хәзер,
Уйлап баксам, артык җәлләмим:
Галим була алмый калсам да мин,
Югалтмадым кебек әллә ни.

Кабат кайттым телем дөньясына:
Тезәм, көйлим шул ук сүзләрне,
Санны санга кайчак бәйләп куям,
Миллионнарга терким йөзләрне.

Исемнәргә кушымчалар ялгыйм,
Фигыльләрне бүләм затларга,
Рәвешенә китереп кайбер хәлне,
Аергычлар ясыйм шарт барда.
(«Үзем турында»)

1990 елда милли телгә, җаны теләгән эшкә әйләнеп кайтуы Ф. Тархановада менә шушындый эчке горурлык хисләрен уята. Аның лирик герое үз бәхетенә сөенеп бетә алмый. Халкына, теленә, диненә мәхәббәт аның күпчелек шигырьләренең эчтәлеген хасил итә башлый.

Һәр шагыйрь – бөек талант иясе, әлбәттә. Алар һәрбер әсәрен укучыларның укуына, бәя биреп соклануы өметендә иҗат итәләр. Моның өчен без аларга рәхмәтле. Шушы хәтле ихлас һәм киң күңелле булмасалар, безнең милли китапханәләребез ярлы һәм буш киштәлекләрдән торыр иде. Һәр шагыйрьнең, хәтта шигырь чыгарырга сәләтле һәр каләм иясенең талантлы булуына минем шигем юк. Әмма һәр укучының күңеле кабул итәрме – моңа җавап бирә алмыйм. Кем-кем, әмма татар укучысы югары дәрәҗәдә таләпчән һәм күпләрне шагыйрьгә дә санамыйча, «шигырьче» ярлыгы белән читкә куярга сәләтле. Ф. Тарханова да иҗат дәверендә шушындый битарафлык белән очрашты. Ул аны да, шушы кадәр гомер яшәп, тормышын өч кат яңадан, тупса төбеннән диярлек башлап, югары баскычка кадәр җиткерә алган чибәр шагыйрә ханымны да, гаҗәпкә, хәтта аптырашта калдырганлыгы сизелә. Шуңа шигырьләре кайчакта корырак чыкканнар, сәхнәдән торып әсәрләрен укыганында да, Ф. Тарханова җитәрлек дәрәҗәдә трибун булып өлгерә алмады. Шагыйрьләр алар шигъри сүз көче белән шаккатырырга тиешле түгелләрме? Әмма Ф. Тарханова шаккатыру теләге белән яшәмәде. Ул үзен аңлауларына, ничек бар, шундый хәлендә ка-

бул итүләренә өметләнде. Шигърият рәхәте белән күңел күзләре сөрмәләнгән татар укучысы да милли әдәбиятны уку бәхетеннән аерылмый яши белде. Ф. Тарханова кайчакта шигъри хисләрен аңламауларына үпкәләп, шагыйрьләрне сайлап кына кабул итәргә өйрәнгән татар укучысы белән хисаплашырга мәҗбүр иде. Шуңа да шигырьләрендә якты хисләрен шигъри чигеше итте. Ул үзен ихлас кабул итүләрен теләде. Моңа чибәрлеге дә, шигъри дәрте дә өмет бирде.

Ф. Тархановаың шигъри фикер мантыйгы үчекләнү-үртәлү һәм үгет, әрнү-үпкәләү һәм соклану үлчәмнәренә корылган булулары белән кызыклы. Аның лирик герое ярата, сөя һәм үртәлә, үчекләнә, үпкәли, өмет итә. Сөйгән яры мәңгегә аның янында булыр сыман. Әмма ул һаман да ялгыз, һаман да очраклы очрашулар белән генә яши. Аның иҗатыннан укучы мәхәббәт бәхете тантанасын эзли алмый. Андый хисләр аның шигърияте өчен тәмам ят. Ф. Тарханованың ихлас шигърияте шушылардан гыйбарәт булды. Шушы үзенчәлекләре белән аның шигъри иҗат мирасы безгә кадерле.

*Май-июнь, 2020*

# II. КИЧӘГЕ СҮЗДӘН БҮГЕНГЕГӘ

## Ә. Еники иҗатында әдәби герой концепциясе

Прозада әдәби геройларның сурәтләп бирелеше аерым әһәмияткә ия булуын, аларны өйрәнү һәм бәяләү үзе үк әсәргә ясала торган төп анализ юлларыннан берсе икәнлеген барыбыз да яхшы беләбез. Укучылар инде мәктәптә үк, югары сыйныфларда, әдәби геройларга характеристика бирү юлларын үзләштерәләр, шуның ярдәмендә тормышта үзләрен һәм кешеләрне танырга, башкаларга карата мөнәсәбәтләрен булдырырга өйрәнәләр. Ә. Еники әсәрләренә килгәндә, алардагы әдәби геройлар татар әдәби тәнкыйте һәм әдәбият фәне тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән, бәяләнгән, аның геройларны күп очракта чагыштырма планда тасвирлавы да катькат бәяләнгән икәнлеген искәртергә тиешбез. Димәк, бу яктан без өстәмә нинди дә булса яңа фикер яки мәгълүмат бирә алмыйбыз. Әдәби герой концепциясенең төп элементларына килгәндә, язучы иҗатын анализлауда конкретлыкка омтылыш соралып тора. Без моның шулай булуын, чәчелмичә, бер әсәр мисалында да күрергә мөмкинбез.

Фикерләмәләребезнең үзәгенә Ә. Еникинең «Йөрәк сере» повестен алып, алардагы геройларның бирелеш концепциясен ачыкларга керешкәнче, игътибарны моңа кадәр билгеле булган фәнни күрсәтмәләргә юнәлтик.

Ә. Еники иҗатын һәм тормышын өйрәнүчеләр арасында төп галимнәрдән саналган Ә.Р. Мотыйгуллина бу повестьның ике геройны каршы кую ысулы белән язылганлыгын болай аңлатып бирә: «Аның беренчесе Нәҗип белән бәйле... Аның кырыс холкын шул еллар мохитеннән аерып карап булмый, – дип яза ул, икенчесе, әлбәттә, аңа капма-каршы куелырга тиешле герой инде:

– ... Очраклы рәвештә генә танышкан... Бәхетгәрәй бөтенләй башка. Ул – хис кешесе»[1].

Әсәрнең эчтәлеген искә төшергәндә, ул катлаулы түгел: Казаннан Идрис исемле тарихчы («Кандидатлык диссертациямә аз булса да хәзерләнермен дип (мин үзем тарихчы, күптән тарих укытам), ярты чемодан әдәбият төяп килгән идем, шуларга тотынып та караганым юк» дип уфтана Идрис әсәрнең IV бүлегендә) Сочидагы «Дулкын» санаториена килә. Ул монда бер ел элек кенә булган. Шул вакытта ук Зөһрә исемле чибәр ханым белән танышып, аның йөрәгендәге серне хикәя итеп сөйләвен тыңлаган да менә хәзер аларны, хәтерендә яңартып, укучыга бәян итә. Вакыйгаларга ярлы, баналь гына мәхәббәт тарихчасы килеп чыга. Зөһрә аны, ни хикмәт, тау сыртындагы имән төбендә, диңгез панорамасы һәм кояш баешы күренеп торган урыннан өч кич буена, алар арасында хәтта берничә көннәр очрашмыйча торып, ашыкмыйча гына сөйләп чыга. Аның хикәясенең беренче зур өлеше Нәҗипкә багышлана, ахырда, бик кыска гына итеп, Бәхетгәрәйгә мәхәббәте бәян ителә. Ул шул ук М. Акъегетнең «Хисаметдин менла»сындагы, М. Фәйзинең «Галиябану»ындагы һәм башка йөзләрчә әдәби әсәрләрдәге «мәхәббәт өчлеге» вакыйгаларын хәтерләтә, алардан әллә ни аерылып та тормый. Мәсәлән, Канифәнең, бай һәм булдыклы Сибгатулланы санламыйча, Хисаметдингә «ябышып чыгуы», яки Галиябануның шундый ук бай егет Исмәгыйльгә бармыйча, авылның урта хәллесе (ярлысы түгел) Хәлилгә «ияреп чыгарга» теләве – болар татар укучысы өчен бик тә таныш, мәхәббәт дигән могҗизаның серен төшенеп бетү мөмкин түгеллеген кат-кат дәлилләгән иделәр инде.

Укучы Ә. Еники кебек талант иясенең дә шушы банальләшкән мәсьәлә белән мавыгуына бераз аптырашта калырга тиеш, билгеле. Әмма әсәрне укыганда да, укып чыккач та андый хис уянмый. Хикмәт нәрсәдә соң? Әлбәттә, Ә. Еникинең, әдип буларак, вакыйгаларны тасвир итү осталыгында. Ул әдәби әсәрләрендә һәрвакыт «сер эченә сер» яшерде. Шуның аркасында бик гади тоелган вакыйгалары тирән эчтәлек алдылар. Иң кызыклысы тагын да шунда: аның шушы «сер эченә сер» бикләп язулары күңел

[1] *Мотыйгуллина Ә.Р.* Психологик проза остасы // Еники Ә. Сайланма әсәрләр. – «Мәктәп китапханәсе» сериясе, Т. II. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 18–19.

белән җиңел хис ителә, әмма акыл белән аларны төшенер өчен зыялылык, интеллектуальлелек кенә аз, интуициядән башка мөмкин түгел. Шунлыктан, мәсәлән, «Йөрәк сере» повестена анализ ясаганда, тәнкыйть тә, фән дә бик җиңел генә хата юлга кереп китеп, дистәләрчә кат әйтелгән һәм кабатланылган фикерләргә килеп төртелми калмыйлар. Хәер, монда сүз Ә. Еники турында гына бармый, бәлки әдәбиятны аңлау һәм аңлату-анализлауга да барып тоташа.

XX йөзнең 60–70 нче еллар татар әдәбияты «конфликтсызлык теориясе» нигезенә корылып иҗат ителде. Ә. Еникинең күпчелек әсәрләре шул чорга карый, «Йөрәк сере» повесте, мәсәлән, шул теориянең иң лаеклы үрнәкләреннән берсе булып тора. Монда Нәҗип һәм Бәхетгәрәй арасындагы тышкы каршылык, конфликт юк, алар бер-берсе белән таныш та түгелләр, бер-берсенең барлыгын да белмиләр. Алар арасында шартлы каршылык булса да, ул бары тик Зөһрәнең аларны үзара каршы куеп, булдыклы, акыллы, тәрбияле, зыялы, зур һәм данлыклы заводның баш инженеры Нәҗипне ярата алмавыннан, сугышка барганында Чиләбедә вакытлыча тукталган, типтәр белән башкорт каныннан туган офицер Бәхетгәрәйгә үзенең хисләрен багышлавыннан гына килеп туа, шул сәбәпле ул хисләре иҗтимагый төс тә алмый. Монда кызның йөрәген яулар өчен төрле авырлыклар аша узарга җыенган геройлар юк. Хәтта Зөһрәнең үзендә дә без андый сыйфатны күрмибез. Вакыйгаларда геройларның кискен каршы куелуы гына әдәби әсәрнең сюжетны мавыктыргыч итә дип белдерергә теләүчеләргә «Йөрәк сере» повесте эшнең киресен сөйләгәне аңлашыла башлый. Хәтта сюжетның нигезен геройларның үзара конфликты төзи дигән теоретик карашны да юкка чыгарырга тиеш булабыз. Шул ук вакытта сорау да тумыйча калмый: бәлки, әсәрнең вакыйгалары, шулар белән бергә сюжеты да, асылда, Нәҗипкә дә, Бәхетгәрәйгә дә бәйле түгелдер? Алар турында сөйләп чыгу авторга бары тик укучының игътибарын башка якка алып китү өчен генә кулланылган булса – бусы инде Ә. Еникинең әдәби осталыгының дәрәҗәсе югарылыгын тагын бер кат раслый торган фактка әверелә түгелме? Бу – әдипнең «сер эченә сер» яшерү осталыгын күрсәтмиме?

Без әдәби иҗатның күңел белән башкарылуын, шул чагында гына чыннан да талантлы әсәрләр туарга мөмкинлеген тәкрарлап сөйләргә яратабыз. Моның асылда ничек булуын язучылар үзләре

дә аңлап җиткерә алмыйлар. Алар язылучы әсәрләрен мөмкин кадәр «акыллы» итәргә тырышалар. Фән дә, тәнкыйть тә, ул әсәрләрне анализлауга, аңлатуга алынып, аларны тагын да акыллырак һәм мәгънәлерәк итеп чыгара.

Ә. Еникинең «Йөрәк сере» повесте, инде искәрткәнебезчә, санаторийга килгән Идриснең былтыргы танышы Зөһрәне сагыну халәтен тасвирлаудан башланып китә. Автор Кырым табигатенең матурлыгын, героеның хисләренең нечкәлеген соклану планында да, фәлсәфәле кичерешләр юнәлешендә дә ача барып, укучы күзләрен санаторий бинасының өченче катындагы, кырыйдан дүртенче балконына төбәлергә мәҗбүр итә. Повестьның хатирәләр эчендә йөзгән герое Идрис бу вакытта тын бакчадагы яшел эскәмиядә утыра. Ул бүген генә, көннең икенче яртысында килеп төшкән, урнашкан, душ та коенып чыккан. Кичке ашка кадәр вакыты бар. Ял итеп утыра. Аның бу юлы Зөһрәне күрергә теләп килгәнлеге аңлашыла.

Әсәр Идрис теленнән сөйләнелеп алып барыла. Ул: «Зөһрә минем бик яшерен йөрәк серем иде», – дип белдерә. Бу сер аның бары тик йөрәгендә генә саклана ала, башкача түгел. Укучыга да бу кызыклы булып тоела. Дөрес, озын гына бер вакыйга бәян ителеп, ахырдан аның морале чыгарылып куелучан. «Хәйләкәр» укучы әсәрнең шул өлешен табып укый да әсәрнең эчтәлегенә төшенеп ала, инде җентекләп укып та торасы юк, кызыгы бетә. Әмма Ә. Еники әсәрләрендә андый мораль бирелү өлеше юк, булганда да, ул башка, әсәрнең тышкы вакыйгалар катламыннан гына килеп чыга, төп фикер булып әверелә, әмма идеясе хезмәтен үтәми. Моны аңлау өчен, мәсәлән, «Әйтелмәгән васыять»кә бәйләнешле алып, бер сорау бирү белән төп фикер һәм идеянең икесе бер нәрсә түгеллеген төшендерергә була: «Ни өчен Ак әби үз васыятен, әгәр дә балалары тыңларга вакыт тапмаганнар икән, кулдан язып калдырмаган соң?» Аннары, аңа васыятен калдыру нигә кирәк булды соң әле? Бу, әлбәттә, «сер эчендә сер», әдәби тәнкыйтькә дә, фәнгә дә, башкаларга кәгазьләр тутырып фәлсәфә корырга, тәрбия, заман, яшәеш мәсьәләләрендә ачыктан-ачык сөйләшү ачарга мөмкинлекләр бирә.

«Йөрәк сере» повестенда да шулай килеп чыгар иде, әмма автор Нәҗип белән Бәхетгәрәйне бигрәкләр дә ачык итеп, контраст сурәтләрдә тасвирлап, гүяки бөтен әйтергә теләгәнен дә күрсәтеп

биргән. Дөрес, монда әдәби тасвирлар детальләштерү ягыннан да аерылып торалар. Нәҗипкә бары коры буяулар гына туры килә. Аның җитдилеге, алдан исәпләп куюлары, нәкъ кирәкчә, китапча үз-үзен тотышлары – болар барысы да турыдан-туры әйтеп сөйләнелә. Бәхетгәрәйгә килгәндә, Зөһрәнең аны яратуын төшенер өчен, бер генә купшы деталь дә ярдәм итми, аның башкортча җәенке бите, кара чәчләре, елтыр күзләре, хәйләле елмаюлары – берсе дә аны Нәҗиптән өстен чыгармыйлар. Ә кызның шушы кешене үзенең йөрәгенә якын алуы укучыны тәмам аптырашта калдыра. Дөрес, без Бәхетгәрәйне әллә нинди куе сүзләр белән матурларга, күкләргә чөеп мактарга, ул хис кешесе бит, әнә сугышка китте, анда да илнең зур ышанычлы кешесе булган, Зөһрәгә сәламне военком аша гына тапшыра алган, бу факт үзе генә дә күп нәрсәләр хакында сөйли диярәк бәхәс кора алабыз. Гадәттәгечә, Нәҗипнең сугыштан бронь белән калуын да хупламыйбыз. Мондый бәхәс корылганда, Бәхетгәрәй, әдәби герой буларак, күз алдында зурая барачак һәм тиздән күңелләребез аның үзе һәм эше белән сокланугa тулачак.

Зөһрәнең Бәхетгәрәйне йөрәк сере итеп сайлавы ни әтиәнисенә, ни үзенә бәхет китерми. Әйтергә мөмкин: ахырдан алар бергә булдылар түгелме соң? Әнә аны Зөһрә ничек ярата, һәр көнне аңа шалтыратып тора, сагынуын әйтә! Тагын ни кирәк инде, диярбез. Әлбәттә, башка берни дә кирәк түгел. Авторның безгә әйтергә теләгән төп фикере аңлашылып тора, әсәрнең идеясе дә шушы дип, Ә. Еникинең үзенә кадәр яшәп иҗат иткән язучылардан берни белән дә аерылмавын, бары тик матур итеп җөмләләр төзү осталыгына хәйранлыкта үзебезне бәхетле тоячакбыз. Әмма без барыбыз да бу әдәби феноменның осталык үзенчәлекләре бик күп төрле икәнлеген белеп торабыз, аның һәр әсәре, бриллиант кашлы йөзек сыман, идея нурланышын йөрәкләрдә калдырып, кайтара-кайтара уйлата, кайтарып-кайтарып укыттыра. Бары тик бик ялкау җаннар гына, аның иҗатыннан ләззәт алып та, алардагы геройларның язмышы хакында уйланулардан баш тарталар, «сер эчендә сер» барлыгын төшенеп, икенче яки өченче кат укып чыгарга да теләк тапмаячаклар. Әйе, Ә. Еники – рәхәт итеп язучы, аны кабат укуы, беренче укуыңа караганда, ләззәтне күбрәк һәм артыграк бирә. Бу хакта ничә кешедән ишеткәнебез һәм үзебезнең дә ничәмә тәҗрибә кылып караганыбыз бар.

Ә. Еникинең әдәби героеның концепциясе, әсәрләренең эчтәлеге сыман, шиксез ачык аңлашылып торалар кебек. Әсәрдә кем макталса һәм өстен чыгарылса, аның шул герое яхшы, кем кире кагылса, хәтта бик яхшы сыйфатлар иясе булуына карамастан, шул герой кире, начар. Нәкъ шушы күзлектән караганда, акыллы, тәрбияле, тәүфыйк иясе, бик яшьли зур заводның баш инженеры дәрәҗәсенә лаеклы булган зыялы татар егете Нәҗип – коры, начар кеше, кире герой, ә менә күкрәгендә «Кызыл йолдыз» ордены булган, бер-ике очрашудан Зөһрәне үзенеке итә алган башкорт егете Бәхетгәрәй – хисле, яхшы кеше, уңай герой. Мондый әдәби герой концепциясе безне аптыраштa калдырырга тиеш түгелмени? Әллә авторның шушы корама концепцияне сайлап алуында берәр сер бармы?

Һич онытырга ярамый: әсәр татарның иң затлы авторларының берсе тарафыннан иҗат ителгән һәм ул әдәбиятта беркатлылык күрсәткән әдипләребездән түгел. Аның акылына татар тарихы, аның затына татар акылы сыйган һәм бүгенге көндә дә ул шәхескә хатирәләребездә соклану белән яшибез.

«Йөрәк сере» Идриснең күзаллавында гүзәл ханым Зөһрәнең сурәте яңартылу күренешләре белән дәвам итә бара. Аларның берсе – ир кеше, үз хатынын сөйми, икенчесе – хатын кеше, үз ирен ярата. Икесен дә бәхетләре санаторийда очраштыра. Алар дуслашып та китәләр. Зөһрәнең Идрисне гашыйк иттерүен укучы әсәр башында ук аңлап та, белеп тә өлгерә. Героиняның алга таба портреты күзалландырыла башлый. Әлбәттә, әлегә Идриснең кемгә, ни өчен, нинди кешегә гашыйк булуы, нидән шулай аһ та ух килеп янып көюләре укучы өчен кызыклы. Автор детальләрне ачык итеп тасвирлаулар, аларга алга таба яңаларын өсти барулар, вакыйгаларны кайта-кайта искә төшерүләр белән укучы күңелендәге кызыксынуларны тулысынча канәгатьләндереп яза. Бер генә тапкыр яки берничә кат кабатланып, яисә өстәп кенә дә түгел, бәлки әсәрнең ахырынача Зөһрәнең портретына аеруча зур әһәмият биреп эш итә. Башка әсәрләренә дә хас бу үзенчәлек «Йөрәк сере»ндә, «Матурлык» хикәясеннән аермалы буларак, бүтән төрле әдәби концепциягә хезмәт итә кебек тоела. Әмма монда да тойгылар шул ук эчке матурлыкны тышкы гүзәллеккә әверелдерүче көчнең тәэсирен бәянлап бирүдән гыйбарәт вакыйгалар сурәтләнелә. Концепциясе

шул ук, әмма мотивлары башка, чөнки «Йөрәк сере»ндә героиня тышкы яктан да бик чибәр.

Автор Зөһрәнең портретын беренче сызыкларында болай итеп тасвирлый: «Дулкынланып иңбашына төшкән аксыл чәчләре һәм аяк йөзенә җиткән эре чәчәкле күк атлас халаты белән ул әллә каян ук балкып күренә». Сүз ханымның санаторий бинасының өченче каттагы, кырыйдан дүртенче балконда торып, диңгез өстенә кояш баешын сокланып каравы турында бара. Әйе, ул чор татар күңеле сөя торган төсләрне уйнатып ала автор.

Зөһрәне Идрис ашханәгә кергәндә күреп кала. Ханым аннан чыгып килә. Йөзгә-йөз диярлек очрашалар. Ә. Еники вакыйганы болай тасвирлый: «Юл бирдем, янымнан гына җыйнак-сылу гәүдәле ханым үтте, нәфис бер хуш ис сизелер-сизелмәс кенә борыныма бәрелеп үткәндәй булды, һәм сирень төсендәге ефәк күлмәгенең чак кына гыжлавы ишетелеп калды». Инде укучы шушы детальләүдән Зөһрәнең буй-сынын, күркәм киемле, затлы ханымнардан икәнлеген хис итәргә өлгерә. Яшен дә беләсе килә. Автор укучыны зарыктырмый, аның тойгыларын аңлап, алар белән идарә итә белеп яза: «Ханым утыз-утыз өчләр тирәсендә булыр. Ак чырайлы ул, чәчләре дә кылган төсле аксыл, әмма шома түгел, ә күпереп, дулкынланып, артка ятып тора. Кашлары нечкә, чәченә караганда шактый тонык... ә менә күзләре ни төсле – ерактан күрә алмыйм. Әлбәттә, я зәңгәр, я соры булырга тиеш...»

Автор махсус рәвештә әсәр герое Идрисне, укучыны да ымсындырып, ханымның күзләренең төсе хакында икеләндертеп сөйләтә. Ул укучыга ханым белән ирнең үзара күзгә-күз карап торуларын да белдерергә тели, шунлыктан күзләрнең төсенә махсус игътибар юнәлттертеп, аралары бик якын да түгеллеген шушындый детальләр ярдәмендә, әдәби осталык кысаларында сурәтли. Бу деталь үзе генә дә Идрискә карата ышану хисен арттыра, ханым белән кызыксыну хисен дә тудыра. Әдәби героена карата укучыда ышану хисен тудыру исә Ә. Еники әсәрләренә хас герой концепциясенең төп үзенчәлекләреннән берсе булып тора. Әгәр дә әдәби герой ышандырырлык түгел икән, ул вакытта ясалмалык өстенлек ала.

Әйткәнебезчә, «Йөрәк сере»ндә Ә. Еники бик баналь бер вакыйганы сөйләргә җыена һәм моның шулай булуын үзе дә яхшы аңлаганын әсәр тукымасында укучыга берничә тапкыр сиздерә, әгәр

дә тасвирланган төп герое да баналь тоннарда гына булса, повесте бөтенләй уңышсызлыкка дучар ителәчәген автор тойган, билгеле. Шул сәбәпле әдип бу әсәрендә герой концепциясен үз күңеленә, моралενә, дөньяга карашына һәммә яктан туры китереп төзүгә алына.

«...Төз аякларын берсе өстенә берсен куеп, кулына кечкенә кара ридикюль тотып, ул уйчан-тыныч кына утыра. Бөтен килбәтеннән үз дәрәҗәсен яхшы белгән масаюсыз табигый горурлык сизелеп тора», – дип тасвир итә автор шушы героинясын, Зөһрәне.

Ханым ашханә ачылуны көтә. Кичке вакыт.

Идрис аңа карап, күзәтеп тора.

Ә. Еники Зөһрәнең сугыш башланган елны унсигездә булуын әсәрдә алга таба берничә кат үзеннән әйттертә, ә хәзер аңа утыз-утыз өч яшьләр. Димәк, вакыйга 1950 еллар башында булган, Бөек Ватан сугышыннан соң әллә ни гомер дә узмаган икән.

Зөһрә белән Идриснең «очрашулары» вакыйгалары әсәрдә дәвам итә, алар инде исәнләшә башлыйлар, ә врач кабинеты ишеге төбендә утырганда сөйләшеп үк китәләр. «...Йөрәкнең акрын гына кысылып, ләззәтле авыртуын тойдым, – дип исенә ала әсәрдә Идрис. – Гаҗәеп, нидән бу? Ханымның матурлыгы мине шулай яшүсмер кебек дулкынланырга мәҗбүр итәме?»

Мондый уйлары аның тәмам беркатлыгыннан килә икәнлеген автор укучыга яшерми ача. Мондый сурәтне әдипнең үзенең дә тирән эчтәлекле геройны иҗат итмәвеннән диярәк тә бәяләргә мөмкин. Әмма автор аны үзенең герой концепциясенә туры китереп шулай эшли. Укучы инде әллә кайчан Идриснең Зөһрәгә гашыйк булганлыгын төшенеп өлгерсә дә, Идрис үзе – юк әлегә. Һәм менә укучы күңеле Идрискә: «Гашыйк булгансың бит, юләр!» – дип пышылдый, хәтта аңардан үз итеп кенә көлә, әмма бу аның ачы көлүе түгел, бәлки үзенең акыллы булуын тоюдан, ләззәтле вакыйгалар агышына кереп чуму рәхәтлегеннән кытыклануы гына. Шушы рәвешле укучы әсәрне уку дәвамында әдипнең герой концепциясенә тәмам бирелеп, берегеп, ярәшеп китә, хәтта аны үз итәргә, аңа берничә «сабак бирергә» өлгерә. Бу чара укучының үзен үк беркатлыландыруга, аның хәтта үз рухы тантанасына ирешә баруына ярдәм итә.

«...Әйе, сүз дә юк, ул чибәр иде, – дип искәртә тагын автор, Идрис исеменнән сөйләп, шушы гомуми тасвирны интим детальләр белән куертып җибәреп. – Якыннан аның йөзе бик чиста,

тик кечкенә колакларыннан түбән яңак сөяге читендә ак мамык төкләр күзгә чагыла. Ләкин алар аңа бик килешәләр кебек, ничектер, аны йомшак итеп, мөлаем итеп күрсәтәләр. Аз гына кайтарылып торган алсу иреннәре дә аның йомшак кебек, бик саф кебек, дорфа-ямьсез сүз әйтә алмый кебек... Алкаланып колак артларына төшкән куе аксыл чәче дә, ап-ак муены да, хәтта аз гына җәенкерәк борыны да – барысы да аңа тулаем бер сөйкемле йомшаклык биреп тора кебек». Сүз дә юк, ефәккә төренгән ханымны Ә. Еники шушылай бөтенләй дә асылташка әверелдерә. Хәер, башкача бәянласа, Идриснең «колактан ашып» гашыйк булуының сәбәбен ничек искәртергә, укучыга җиткерергә мөмкин? Мондый сурәтләр идиллиянең күркәм мисалларыннан түгелләрмени?

«Йөрәк сере»ндә алга таба Ә. Еники Зөһрәнең портретына бәйле һәр детальне аның табигатен һәм холкын ачыклар өчен файдалануга күчә бара, шуның белән героеның тышкы һәм эчке сыйфатларында уртаклыкларны укучы да җиңел таный. Йомшак табигатьле бу ханымның «тик күзләре генә икенче төрле тәэсир калдыра, – дип яза ул, – кашларының чәченә караганда коңгырт булуы, керфекләренең озын һәм кара булуы, аның зәңгәр күзләрен караңгылап торган шикелле, һәм күләгәгә яшеренгән бу күзләр кешегә каядыр ерактан сагаеп-сагаеп карыйлар кебек...»

Хисләренә бирелгән Идрис бу ханымның күңелендә сер барлыгын чамалый, ул аны «ачылмаган чәчәк бөресенә» тиңли. Хәтта: «Әгәр ачыла калса, күңел күптән сагынып эзләгәнен табар төсле...» – дип тә укучыга белдерә. Кайвакытта Зөһрә Идриснең күзенә чалынмый, әмма ир аны һаман эзли, таба. Өч-дүрт көннән соң очрашулары шул ук бакчада, эскәмиядә була. Алар «иске танышлардай» сөйләшәләр. Монда да автор Зөһрәнең портретына укучыны игътибар иттертә: «Әйе, аның өстендә бик гади генә итеп тегелгән, ачык изүле, кыска җиңле яшел күлмәк иде. Күкрәге өстендәге кечкенә кесәсенә ак ефәк кульяулыгын төртеп кенә куйган... Бүтән берни дә юк. Тик сул кулының атсыз бармагында кызыл якут ташлы алтын йөзеге бар икән... Әйе, һаман шулай аксыл чәчләре алкаланып йомшак ак муенына төшкән, һаман шулай кара керфекләре зәңгәр күзләрен күләгәләп торалар...» Автор, шушы рәвешле сурәтләп, гүяки героинясын шактый гына матди байлыкларга ия кеше буларак та күрсәтергә тели, әмма кешечә гадилеген

дә ассызыклый. Шулай да ханым аерылып та тора икән: ул башкалар кебек диңгезгә су коеныргa йөрми, төрле уеннар белән дә мавыкмый. Тыныч һәм сабыр холыклы. Мишәр кызы икәнлеге дә, Чиләбедә үсүе, Ульяновски шәһәрендә телефон челтәре инженеры булуы да тиз беленә. Ул боларны Идрискә яшерми әйтеп бирә.

Ханымның көлү тавышы да ирне сокландыра башлый, «болай көлү, гадәттә, эчкерсез балаларга гына хас була» дип нәтиҗә дә чыгарыла. Һәм шулар ярдәмендә Зөһрәнең Идрискә карата мөнәсәбәтенә дә аныклау кертелә: «Ачык, аңлаешлы, якты бер кеше булып тоелды ул миңа. Ничектер, җиңел, рәхәт иде аның белән сөйләшүе. Гаҗәп табигый итеп тота икән ул үзен. Күп хатыннар шикелле, укам коела күрмәсен дип, бер дә юкка һаваланып маташмый икән».

Шушылар әсәрдә мәхәббәт уенына корылган «курорт романы» бәян ителәчәгеннән хәбәр буларак укучыга аңлашылырга тиешләр югыйсә. Җитмәсә, Идрис үзенең гашыйк булуын яшерми сөйли, мәхәббәт хакында фәлсәфә сата, кыю адымга барырга, ханымга йөрәгендәге серен ачып бирергә дә теләгендә бар. Әмма тагын берничә көн уза. Алар очрашмый торалар.

Идриснең, көчле хисләргә бирелеп тә, кыю адым ясый алмавы, пошмаслыгы, вакыйгаларның бернинди үзгәрешсез калуы әсәрне укырга авырлаштыра, билгеле. Андый урыннарда Зөһрәнең чибәр сурәтенең яңа детальләр белән тасвир ителүе шул караңгылана барадыр тоелган тормыш картиналарына кояш нурлары кебек яктылык сирпиләр. Бу исә авторның алга вакыйганы түгел, геройны чыгаруын тагын бер кат расларга булыша.

Кыяфәте укучыга билгесез калган «төссез» Идрис, һәммә төрле буяулар белән купшыландырып бирелгән Зөһрә белән чагыштырганда, бөтенләй башка концепциягә корылган. Берничә детальне исәпкә алмаганда һәм алардан чыгып фикер йөртмәгәндә, аны бәяләп тә, аңлап бетереп тә булмый. Идрис бары тик, З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романындагы шымчы Шубин кебек, авторга вакыйгаларны ачар өчен ярдәмче образ ролен генә үти түгелме? Әмма шунысы да бар: Шубин кебек ул актив геройлар рәтендә карала алмый, бәлки, киресенчә, Зөһрәнең хәлләрен аңларга ярдәм итүче, аңардан вакыйгаларны сабырлыгы белән сөйләтүче буларак кына әсәрдә катнаша. Хәер, идиллияле хатирәләр йомшак рәхәтлек эчендә булырга тиешләр. Әдәбият өчен мондый тасвир, андый герой

концепциясе яңалык та түгел. Әмма аның сөйләнелгән вакыйгаларга мөнәсәбәте әсәр моралenең нигезен хасил итә. Герое авторның фикеренә каршы да килергә мөмкин, туры да килә ала. Мондый герой язучыга үз фикерен яшерергә яки ачык белдерергә мөмкинлек тудыра, шул сәбәпле аның әдәби әһәмияте җиңел бәяләнә.

Әсәрдә югалып торган герой, бераз вакыт узуга, кабат күренүгә, тагын аның килеш-килбәтенә укучыны игътибар иттертүдән соң, аңа бәйләнешле вакыйгалар тезмәсе башланып китә. Шушы рәвешле язу Ә. Еникигә героен искә төшерергә дә, башкалары белән бутамаска да, характерлап бирергә дә ярдәм итә. Күп очракта язучылар геройларының портретын исәпкә алып тормыйлар, аларның килеш-килбәтләре дә ачык искәртелми, шул сәбәпле кемнең кем икәнлеге дә төгәл күз алдына килми. Бу, әлбәттә, әдәбилеккә хилафлык китерә. Ә. Еники, киресенчә, әсәр геройларын укучы мөмкин кадәр тулырак итеп күз алдына китереп бастырсын өчен, аерым тырышлык күрсәтә. Аның максаты – герое танып беленергә тиешле. Шушы портретларны бирүе белән генә дә ул геройларын реаль тормышта яшәүче кешеләр итеп күзаллауны укучы күңелендә барлыкка китертә, моның белән әсәренең тәэсир көчен арттыра.

Берничә көннәр узуга, Идрис, мәсәлән, Зөһрәне тагын да мондый сурәттә очрата (бу иртәнге вакыт була): «...Паркның төп аллеясы буйлап Зөһрә ханымның каяндыр кайтып килгәнен күрдем. Бик гаҗәпләндем мин бу хәлгә. Күзләремне ала алмыйча, аны көтеп тора башладым. Өстендә аның халат өстеннән генә кигән жакет, башында ияк астыннан китереп бәйләнгән шакмаклы йон косынка иде. Килеп җиткәч, ул миңа “хәерле иртә” диде, бит урталары аның кызарган иде, гадәттә күләгәләнеп торган күзләре, чык бөртегенә нур төшкәндәй, куанычлы елтырыйлар иде, ашыгып килгәнгә, ахрысы, түшләрен тибрәтеп, тирән сулый иде». Боларда Зөһрәнең инде ничәнче тапкыр киемен алыштырганлыгын, нинди шатлыклы хисләр кичерүен, Идриснең аңарга карата йөрәк җылысы белән эретелгән яхшы мөнәсәбәтен, ханымның үзенең дә тирән хөрмәтен – барысын-барысын берьюлы тоябыз. Ул шулай булырга да тиеш. Әдәби сурәт тормышны төрле яклап яктырту гына түгел, укучы күңелен дә шул тормышны полифоник яңгырашта кабул итәргә этәргәндә генә уңышлы була. Шунысы кызыклы: Ә. Еники тасвир кылган бу күренеш-портретта бер генә ачык билгеләнелгән

төс бар, ул «бит урталары аның кызарган иде» дигән сүз-сурәттән гыйбарәт. Ханымның халаты, йон косынкасы, күзләре, башкасы – берсенең дә бу вакытта ачык бер төсе күрсәтелмәгән, алар әһәмиятсез калдырылганнар. Язучының әдәби максаты аңлашылып тора: укучыны Зөһрәнең бит очларына игътибар иттертү, шуның белән гаҗәпкә дә калдырырга теләү. Идриснең бу күренешкә мөнәсәбәтен язып узу белән бергә соклану хисе тагын да көчәйтелә.

Зөһрә әллә кайдан түгел, почтадан кайтып килә икән. «Карты» белән телефоннан сөйләшкән.

Әсәрдә алга таба Зөһрәнең көлү авазлары тагын да калкурак итеп алга чыгарыла. Идриснең хәтерендә автор аны төрлечә яңарта: мәсәлән, «шундый сихри итеп ханым бер көлеп куйды да, ашыгып, вестибюльгә кереп тә югалды», яки, «Зөһрә ханым ничек итеп көлде! Кошлар сайравына биргесез иде бу көлү!.. Гүя ерактан үзенә чакырып торган сихри бер өн ул!» һ.б.

Идрис Зөһрәгә инде өметсез гашыйк була. Аларның бергә «Дендрарий» паркына барулары, бу бакчаның тарихчасы, агава агачына бәйле риваять – болар барысы да укучыда тирән дулкынлану тудыралар.

Алга таба вакыйгалар Идриснең Зөһрәгә мәхәббәтен ничек тә аңлатырга тырышуы белән бәйле. Әмма турыдан-туры әйтсә, ханымның хисләрен кимсетер сыман. Хәер, Зөһрә аны ярты сүзеннән аңлап ала һәм мәхәббәтен дә кире кага. Ә бу кире кагуны ул да үпкәләтерлек рәвештә әйтергә теләми, Идрисне хөрмәт итүен, аңа мөнәсәбәте дә яхшы булуын искәрткәч, «кызыклы бер тарих» сөйләргә, ягъни «башыннан кичкән мәхәббәт тарихын» бәян итәргә була. Аңлашылып тора: Зөһрәнең ни әйтергә теләгәне шушы тарихка яшерелгән. Димәк, анда әсәрнең әчтәлеген ачарга тиешле мәгънәле киная бар. Бу «тарих» 8 бүлекле повестьның VII–VIII бүлекләрендә сөйләнелеп бирелә. Зөһрә аны берничә көн дәвамында, кичен-кичен, кисәкләп кенә Идрискә, Идрис укучыга җиткерәләр.

Ә. Еникинең геройлары күңелләре түрендә сакланган һәм әйтергә теләгән төп теләк-сүзләрен бервакытта да турыдан-туры әйтеп бирмиләр, бары тик кинаядә, метафорик планда белдерәләр. Зөһрә дә шулай эшли. Хәер, бу повестенда башка геройлар да шушы хәлдә. Әмма монда Зөһрәнең сөйләгән «тарихы» әһәмиятлерәк тоела. Шуны аңлап, әсәрнең идеясен дә укучы шуннан эзли.

Хәер, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият фәне дә нәкъ шулай эшләгән[1]. «Йөрәк сере»ндәге VII бүлеккәчә сөйләнеп киленгән вакыйгалар бөтенләй дә исәпкә алынмыйча калдырыла киленгән. Шунлыктан Ә. Еникинең бу әсәренә бүгенге көнгә кадәр өлешчә генә анализ бирелгән дияргә тулы хакыбыз барлыгын төшендерү авыр түгел.

Димәк, «Йөрәк сере» повестенда авторның укучыга җиткерергә теләгән идеясе әсәрдәге төп героиня Зөһрәнең Идрискә мөнәсәбәтенә, Идриснең исә Зөһрәгә булган якты хисләренә бәйле. Ханым тарафыннан сөйләнелгән үз мәхәббәте «тарихы» исә шушы бәйләнешне аңлар өчен китерелгән әдәби иллюстрация ролен үти. Нәҗип кебек егетне дә үзенә лаек күрмәгән Зөһрә, уйлап караганда да аңлашыла, Идрискә үзенең йөрәген багышлый аламы? Юк, әлбәттә. Идриснең драмасы Нәҗипнеке белән аваздаш.

Ә. Еники башка әсәрләрендә дә «сер эченә серне» шулай яшерә белгән. Ул әдәбиятка менә шулай, кинаяле геройларны биреп, яңа герой концепциясен алып килгән һәм шушы рәвешле әдәби-тарихи процесска яңа үсеш этәргече биргән әдип булуы белән дә кызыклы.

*Февраль, 2009*

## Татар әдәбиятында ироник реализм

*(Камил Кәримовның «Ком сәгате» романы уңаеннан)*

### I

Камил Кәримовның язучы буларак әдәби теле һәрвакыт аерылып торды. Ул төртмә кебек тә, уйнаулы уйчан сыман да, бәяләүле дә, үгетләүле дә кебек тоела. Әмма боларның барысын да бергә кушканда гына, бу тел аңлашыла башлый. Кемнәрнеңдер матур дип саналган теле җилләр белән бергә кырлар-болыннар аша йөгереп әлсерәтсә яки Париж, Рим, Каһирә, Истанбуллардагы биек манараларга уралып йөреп, инде дә тау сыртларына бәрелеп китеп, чәчләрне сыйпап үткәндәй хис калдырса, К. Кәримовныкы бөтенләй башка, ул күңел идәненә коелган эре борчакларны хәтерләтә, ул борчакларның кайда таба сикерәселәрен, маңгайгамы, башка

[1] *Карагыз: Сверигин Р.Х., Хатипов Ф.М.* Әмирхан Еники // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 6. 60–90 еллар әдәбияты. – Казан: Раннур, 2001. – Б. 111.

җиреңәме бәреләсен-чиртәсен белеп тә бетереп булмый. Бу – ирония теле, мактаучы, аркадан сыйпаучы һәм кемлегеңне ачык белдерүче бәяле һәм бәһале тел. Ә ирония теле ул – бик тә җитди итеп, әмма «астан» кистереп сөйләүче көлке теле.

Бөтен иҗаты буенча К. Кәримов шушы тел белән яшәде, аны укучысына тәкъдим итте, эндәшми торганында – сагындырды, күп сөйләп ташлаганында – куркуга салды. Укучысы аны иң тәүдә менә шушы теле өчен яратты. Аны юмор теле дип белде. Бу яктан К. Кәримов классик әдипләребездән Ш. Мөхәммәдов, З. Һади, М. Әмир, М. Мәһдиевләрнең данлыклы дәвамчысы булды.

К. Кәримов әсәрләрендәге тел сөйли, әмма сөйли белеп кенә, күп түгел, бераз гына сөйли. Сүз борчаклары сикерешеп-сикерешеп кенә куялар. Ә аннары шул сүзләренә нәтиҗә итеп, язучы бер җөмлә бирә, ул яки чеметтерә, яисә яңа сүз башламына тема ача. Аның «Ком сәгате» дә шушы формага көйләнгән. Бу кадәр дә ашкынулы тел башкача хәрәкәт итә алмый, нәтиҗәдә вакыйгалар озынга сузылудан имин кала.

Кайбер язучылар әсәр эчендә тематик үстерелешне тәэмин итә алмыйча интегәләр. Бу бәладән котылу өчен, аларга К. Кәримов әсәрләрен уку, форма-стильдә аның өлгесенә тартылу шактый зур файда бирер иде.

Ироник тел башкача була да алмый. Анда һаман да сүзләр ниндидер бер ашкынулы ләззәт җебенә теркәләләр. Алар өзелеп калганда, инде икенчесенә күчәргә язучы каләме өлгерә. Бу тел сурәт матурлыгын тудыра. Күп вакытта аның артыннан җитешеп тә булмыйдыр, уйлап, нәтиҗә ясарга да мөмкин түгелдер сыман. Әмма К. Кәримов монда да үзен чын мәгънәсендә әдип итеп күрсәтә, укучысының зиһен мәйданына бер төзек җөмләле фикер бәрәмлеге ташлап калдыра, аны үзлегеңнән дәвам иткәнеңдә, нинди нәтиҗәгә килергә мөмкинлегеңне белеп торасың. Ул үз уе белән безне аптыратмый, аны укучыга көчләп тә такмый. Әмма нәкъ К. Кәримовча фикерли башлыйсың. Аны шуның өчен дә фикер остасы дияргә тулы нигез бар.

К. Кәримовның берничә җөмләсенә генә игътибар итик. Махсус сайлап алып түгел, очраклы рәвештә теләсә кайсына тукталып карыйк. Менә Мәдияр белән Фазыл исемле каһарманнары кич клубка чыгалар. Фазыл, актан киенеп килгәненә күрә, ятсыну

хис итә. Вакыйга Актаныш төбәгендә бара. Мәдияр аңа болай ди: «Актаныш кызлары – деликатес алар!»

Әдипнең каһарманнары да ироник телле. Бу тел белән болай да һәр авылның яшьләре һәм өлкәннәре сөйләшәләр. Язучы бу телне халыктан «алган». Турыдан-туры күчереп түгел, билгеле. Үз күңеле аша уздырып.

Татар – төртмә телле халык. Күрше белән күрше иртә таңнан шушы К. Кәримовтагычарак ироник тел белән сәламләшмәсә – яши алмый. Кемдер бу телне күтәрә ала, кайсылардыр – юк...

Тагын да очраклы гына, ягъни махсус сайлап-сайланып тормыйча тукталган сәхифәгә күз салсак, күрәбез, К. Кәримов алга таба болай яза: «Башта егетләр сәгате суга, аннан соң кызларныкы... Хәер, яшь чакта шулай ул... Ә өйләнгәч, хатыннарның сәгате алга китә, ирләрнеке гел артка кала...» Бу юлларны укыганда, укучы әллә ничә төрле уй эчендә йөзә. Сүз борчаклары коелган, алар күңел идәнендә сикерешкәннәр. Автор нәрсә турында әйтте әле дип, символларның мәгънәләрен эзләп аптыраш юк. Алга таба укуыңны беләсең: «Егетләр, Кырлай бүреләре кебек, якты клуб учагын ташлап, берәм-берәм Карурмандай кара урамга шыла тордылар».

Менә бит ничек! Монда Г. Тукайның «Кәҗә белән Сарыгы» да, татарның «Карурманы» да аһәң биреп ала. К. Кәримовны аңлар өчен, татар булып туарга кирәк, анысы хакында сүз дә юк. Җитмәсә, кызлар белән боткалары пешмәсен аңлаган егетләрнең, «Кәҗә белән Сарык» бүреләре кебек, берәм-берәм качуларын карагыз инде!

Ә вакыйга дәвам итә, әлегә әсәрнең беренче сәхифәсе дә ябылмаган, ә Мәдияр белән Фазыл инде кызлар озата киләләр. «Алар өч чакрымлы юлның икенче яртысын таң атканчы кайттылар. Төннең тәхетеннән төшкәненә сөенеп, хуҗасыз этләр өргәне ишетелә. Сәер дә тиз үтте бу төн! Төн кичмәделәр, ә юл уңаеннан барганда, бер күләгә аркылы гына атлап чыктылар гүя...»

Һәм сез дә кушылырсыз: никадәр тасвир, никадәр күзәтүчәнлек һәм фикерле белү, тел белән эшләү осталыгы! Истә дә кала. Әмма бу сурәтләр җәелеп ясалган акварель буяулардан гыйбарәт түгел, алар төртмә-төртмә рәвештә, майлы буяулар тыгызлыгы белән бирелгәннәр. Җитмәсә, ирония алардан аңкып тора. Ни сокланырга, ни чырай сытарга өлгермисең.

Бу ирония теле коры тел түгел шул. Һәр сүзләр тезмәсенең өске һәм аскы агымы бар. Ирония ул көлдерми, аның максаты бары көлкегә калдыру гына. Әмма ул мактап, зурлап, чөеп, күкрәкләрне киерелдереп көлкегә калдыра. К. Кәримовның каләменнән «коелган», инде синең күңел бүлмәңнең идәнендә сикерешкән сүз борчакларының берсен булса да тотып алырга дип хәтерең иелергә өлгерми, аның икенчесе маңгаеңа чиртеп ала. Зиһенне ирония дә нәкъ менә шулай сугара, сафландыра.

Дөрес, безнең борчаклар турында фәлсәфә коруыбыз хакыйкатьнең һәммә ягын да ачып бетерә алмый. Әмма ул бәяныбызның асыл нигезе дә бар, чөнки К. Кәримовның әдәби тел җәһәтендәге осталыгын азмы-күпме ачып бирергә ярдәм итә ул. Әгәр дә башка төрле символлар табып, кем дә булса әдипнең язу үзенчәлеген ачык аңлата ала икән, рәхим итсеннәр, ризалашырбыз кебек. Ә К. Кәримовның «сүз борчаклары» шытканрак килеп чыгалардыр сыман.

II

Ком сәгате дигәндә, «үзара нечкә көпшә белән тоташтырылган ике пыяла савытчыкның берсеннән икенчесенә билгеле бер вакыт арасында ком коелып тора торган прибор»[1] күздә тотылуын хәбәр итә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге». К. Кәримовның «Ком сәгате» романында ул үзенең туры мәгънәсендә дә катнашып ала, ягъни су бораулаучы эшендә кирәкле җиһаз икән ул ком сәгате.

Шул ук вакытта ул символик мәгънәгә дә ия. «Ком сәгате» геройларыннан Фазыл гомере буе су бораулаучы булып эшләгән, менә аны илле яшендә пенсия чыгарганнар, язмыш сәгатенең комы колба-савытчыкның бер ягына агып беткән. Ул аны икенче башы белән әйләндереп куя. Ком яңадан ага башлый. Бу гади агым түгел, бу аның язмышының кабатлануы кебек килеп чыга. Фазыл үзе узган барча төбәкләрне кабат әйләнеп чыгарга тиеш. Аның һәр су скважинасы бораулаган авылында кемедер калгандыр сыман. Алар агайның якты истәлеге. Бу истәлекләр бер-бер артлы кабатланачагын укучы да аңлап өлгерә. Фазыл үзенә су бораулаучылар вагонын ала, шунда яшәргә ризалык итеп, шул вагон белән сәфәргә чыгып

[1] *Карагыз:* Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. – Т. II. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – Б. 138.

китә. Һәр тагып барган машина шушы яшел вагонны кайсы да булса бер авылга илтеп куячак. Бу – әсәрдән көтелгәне, фабуласының мантыйгы. Моның белән әсәрнең өлгесе күзаллана. К. Кәримов шушы өлгедә романын ахырынача җиткерергә тиеш кебек. Әмма әсәрдәге вакыйгалар барышы укучы алай җиңел генә күзаллаганча булып чыкмый. Яшел вагон Шәле авылына якын юл янында тукталып кала. Геройның хатирәләре генә «сәфәргә чыга». Шушы рәвешле автор укучы күнегә башлаган фабулага үзгәреш кертә һәм әсәрен тулы ике өлешкә аерып куя. Аның бу «ачышы» фабулага зыян итәдер сыман хис туа, әмма автор моны билгеле бер максатларда эшләгәндер дигән уйга килергә мәҗбүрбез. Талантлы һәм тәҗрибәле әдип юктан гына «мөгез чыгару» юлына басмый түгелме соң?

Фазылның яшәеше-тормышы сәер. Ул өйләнгән булган, баласы үсә. Эшләгән акчасын да аларга биреп бара, фатирын да шуларга калдырган. Ә ул үзе кебек су бораулачылар рәтендә, әсәрдә әйтелгәнчә – зимагор. Аның авыл саен сөяркәсе була ала. Укучы да әсәрдән шуны көтә. Менә «Ком сәгате»нең донжуаны шул сөяркәләренә сәфәр чыкты инде, дибез. Ә юк икән шул.

Автор әсәренең башында ук укучыны татар донжуаны маҗаралары белән мавыктырып алган иде түгелме соң? Фазылның Казанда Зөмәйрә белән кич кунып чыгулары, ул бүлекнең дә «Зөмәйрә» дип аталуы шуңа ышандырмадымы?

Авторны татарның замана донжуаннары бөтенләй дә кызыксындырмый икән шул. Вакыйгаларның барышы башка бер үзән белән ага. Актаныштагы Аккүз авылында калган Әлфинәне Фазыл утыз ел буе сөйгән. Алар кавышмаганнар. «Ул кызны күргән кеше утыз елны күпсенмәс», – дип әйтеп куя Фазыл. Һәм ул укучыны ышандыра да. Әмма шик тә бар. Роман җиде бүлеккә бүленгән. Алар һәммәсе дә төрле хатын-кыз исемнәре белән аталган, ул бүлекләр тагын да бүлекчәләрдән тора һәм сурәтләнеләчәк вакыйгаларга бәйле исемләнгәннәр. Ул хатын-кызларның һәммәсе белән дә Фазыл йөреп-сөешеп чыгар сыман. Ә юк икән шул. Аларның берсе – Динә – Фазылның әнисе.

Хәер, темадан киткәнче, дигәндәй, искәртеп үтик: «Ком сәгате»ндә татар донжуаны да бар, ул – пилмән бәбәкле Фәрит. Автор аның хатын-кыз итәгенә ябышырга гына торуын бик яхшы итеп ачып бирә. Фәритне укучыларына авылга килгән «командировка»

хезмәткәрләре арасында таныштыра язучы. Аннары бу егетебез, Актанышка машина белән йөк ташучы сыйфатында килеп, мунчага хатын-кыз артыннан кереп тотылган, унбиш тәүлеккә хулиганлыгы өчен утыртылган, су бораулаучыларга туң җирләрдә сигез куб метрлы чокыр казырга мәҗбүр ителгән тоткын рәвешендә рисвай була. Шушы донжуан Фәрит образы Әмир, Фазыл һәм Мәдияр кебек үз хезмәте көченә таянып, фидакярлектә яшәүче каһарманнарга әдип тарафыннан каршы куела.

Фазыл сугыш вакытында Шәледә көне-төне икмәк иккән Динәдән туа. Ураза вакытында хатыннар урак белән иген уралар. Су да эчәргә ярамый. Хикмәт хәсис Габдулла муллада. Ул үзе көндез йоклап, төнлә ашап ураза тотучы исәпләнелә, ә халыктан шәригать кушканны таләп итә: ураза нинди генә авыр эштән һәм эсселектән дә бозылырга тиеш түгел, имеш. Тик сорау тумыйча калмый. Ничек инде автор сөйләгән шушы «сасы мулла» көмәнле Динәдән ураза тотуны таләп итте икән? Бу кадәр үк аңарга хәсис булырга ярамагандыр бит инде! Әллә шәригать хөкемнәрен белү мәсьәләсендә мулла түгел, халык наданмы? Көмәнле хатыннарга ураза тоту ярамый бит, әгәр алар ураза тотсалар, көферлек була түгелме соң? Шушыны да Габдулла мулла белмәгәнме? Көмәнле хатыннар уразадан азат бит алар! Ә монда, киресенчә, Габдулла мулланың хәсислеге алга чыга, Динә аның тарафыннан уразаны бозуда гаепләнелә.

Авторга бу мәсьәләне кабартып алу төгәл максатларда кирәк булган, билгеле. Ул аның ярдәмендә дин-шәригать мәсьәләләрендәге бездә хәзергәчә сакланган наданлыкны, муллаларның хәсислеген иониягә ала түгелме? Бу вакыйганы укучы бер дә уйлап чыгарылган дип белергә теләми, чөнки иманы камил: К. Кәримов сурәтләгән вакыйгаларын тормыштан һәм нәкъ тормыштагыча ала. Бу – аның иҗат кредосы. Бу – аның реализмы. Әмма ул натурализм түгел. Натурализмга ук кереп китмәс өчен, авторга тормыш дөреслеген ирония аша бирү ярдәм итә.

Фазыл, әсәрдәге төп геройларның берсе буларак, авыр тормышта үскән, кимсетелгән, фронттагыча батырлыкны таләп итүче хезмәттә (монысын су бораулаучылар хакында Актаныш райкомының икенче секретаре Галимҗанов әйтә), хәтта йортсыз-җирсез, ачлы-туклы зимагор хәлендә гомер итә. Хәер, ул гына түгел, ил белән диярлек шул хәл. Су бораулы мастеры Әмир дә шундыйлар-

дан. Алар елына берничә тапкыр гына гаиләләрен күрергә, анысын да акча алган көннәрендә генә мөмкиннәр. Аның каравы хуҗалар дип исәпләнелгән түрәләр башкача яши, башкача гомер сөрә. Аларның хәтта сәясәтләре дә дөрес түгел. Араларында «кукуруз сәясәте»н культуралы көтүлекләр белән алыштыруда башлап йөрүче, шәрә мәкаләләр язучы министр да бар. К. Кәримов аның әүвәле кемлеген хәтта публицистик планга күчеп хәбәр итә. Ә аннары алар Актанышта очрашалар. Министр үзе белән ак «Волга»да инженер Ятманскийны алып килә. Түрәләр барысы да автор каләменнән «симез борынлы» кыяфәтләрендә пәйда булалар.

Министрның Актанышка су бораучылар янына килүе, түрә Ятманский вакыйгалары – болар барысы да, әсәрдәге башка сурәтләр кебек үк, чын мәгънәсендә иронияга корылганнар. Әдип аларны туктаусыз күкләргә чөеп мактый, һәр әдәби геройның артында торырга мөмкин булган һәм танылып беленүче прототипларын да, шул исәптән, иронияга ала. Ирония ул начарны юри яхшы итеп күрсәтү, караны юри ак итеп сурәтләүдән гыйбарәт. Ироник бәяләмә, сурәт, күренешне укучы әүвәле әдип язганча туры мәгънәсендә кабул итә, аннары гына, үз фикере һәм аңы аша уздырып, язылганнарның иронияга корылганлыгын, кире мәгънәгә ия икәнлеген төшенә. Министр да, әле генә язучы каләменнән рәнҗешле публицистик планда бәяләнгән герой, инде мактала. Ул бораулаучылар белән чәй эчкәндәй итә. Моны казылган кое суы дип кабул итә, аннары кар суы булуын белә. Чиркана. Әмма Актаныш кары икәнлеген искәртәләр, ул кабат йөзенә сөенеч билгеләре чыгара. Имеш, Актанышның кары аның өчен газиз, туган ягыныкы бит! Министрның шушы бер-ике сәхифәлек вакыйгада өч тапкыр кыяфәте, ничә кат йөзе, кыланышы, сүзләре капма-каршыга үзгәреш кичерә. Әмма автор теле һаман да аны мактый, олылый. Министр су бораулаучылар белән чирканмый кул бирешеп күреште түгелме? Ә ул алып килгән Ятманский ничек?

Аны министр, бораулаган җир катламнарын үз кулы белән алып, тотып тикшерсен өчен, бер айга Актанышта калдырып китә. Гаеп, имеш, аңарда. Су кирәгенчә һәм проектта каралганча чыкмаган.

Хәбәрдар кешеләр белә булыр: җирнең геологик катламнарын тикшерү методлары һәрвакытта да йөз өлеш дөрес нәтиҗә

бирә алмый. Әлегә кадәр бер генә фәнни өлкә дә хакыйкатьне хатасыз, тулысынча белдерүгә дәгъва тотмый. «Симез борынлы» Ятманскийның, никадәр генә исәп-хисаплары, сызымнары дөрес булмасын, ялгышуы ирексездән.

Әмма әдип бу мәсьәләдә сызымчыларның сукырлыгыннан ирония тудыра һәм дөрес эшли. Әгәр дә без бүгенге фәннең уңышсызлыкларына кул чабып торсак, гыйлем-фән үзе үсешеннән туктаячак. Хәзерге фәндә шундый юнәлеш калыкты: галимнәр конференцияләрдә фәнни «сговор» (килешенү) төзиләр дә (укучыга яхшы билгеледер дип беләбез, фәлсәфә өлкәсендә бу «сговор» дигән сүз очраклы түгел, бәлки дөреслекнең килешенеп билгеләнүенә бәйле хәл ителүен күрсәтүче термин буларак кулланыла) һәм шушыны хакыйкать итеп белдерәләр. Бу дөнья күләмендә шулай. Ул метод белән ачышларны «ясау»ның файдасы да, хатасы да бар булыр. Автор нәкъ менә шушындый фәнни сукырлыктан көләдер сыман.

Ятманскийга карата министрның мөнәсәбәте Фазылны да, укучыны да сөендерәдер кебек хис кала. Әмма, асылда, бу карары министрның мәгънәсез икәнлеген дә аңларга ярдәм итә. Моны хәтта бүлекчәнең ахырындагы вакыйга да раслап тора. Менә министрның кул биреп хушлашып, бораучылар яныннан китеп баруы. «Фазыл үзе дә сизмәстән, йола кушканча күрешеп: «Мин Фазыл булам!» – дип ычкындырды. «Ни хәл, Фазыл?!» – диде аңа министр»[1].

Хәл белешү хушлашканда әйтелә торган сүзмени инде? Әмма әсәрдә бу – ирония тудыру өчен хезмәт итә, сүз борчагы, бөтенләй көтелмәгән якка сикереп, маңгайга китереп бәрә.

### III

Ком сәгатенең, җиһаз буларак, эшләү принцибына кабат игътибар итсәк, борыннары белән үзара тоташтырылган колбасавытчыкларның берсеннән икенчесенә ком савыла, дидек. Ком бер яктан икенчесенә агылып беткәч, башаяк әйләндереп куясың. Тагын шул ук вакыт аралыгында ком савыла. Артмый да, кимеми дә.

К. Кәримовның «Ком сәгате» романында шушы ком сәгате абстракт рәвештә кулланыла, әсәрнең композициясен барлыкка китерә. Әгәр дә игътибар итсәк, ком сәгатендә, ком савыла

[1] *Кәримов К.* Ком сәгате: роман, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – Б. 209.

башлаганда, әүвәле колбаның авызындагы бөртекләре сузылып төшә, акрынлап комда воронка-борын хасил була. Аннары өске, авыздан ерак катлам коела бара. Вакыт-вакыт бу савылу тәртибе үзгәреп тә куя. Анда очраклылык зур роль уйный. Әмма комның савылуын берничек тә тизләтеп яки кысып булмый. Бу романның да эчтәлеге нәкъ шушы рәвештә ачыла. Әсәрнең «Ком сәгате» дип аталуы да менә шуңардан килә. Композицияне тема итеп чыгару белән әдипнең әдәбиятка зур яңалык алып килгәнлеге аңлашыла башлый.

Баштарак әсәрнең фабуласы белән бәйле берникадәр канәгатьсезлек хисе дә кичерәсең. Бу хакта искәрткән дә идек. Инде ул мәсьәләгә әйләнеп кайтырга мөмкин. Әсәрнең композициясе ком сәгатенең эшләү принцибына охшатып корылганлыктан, аның фабуласы да аңа буйсынырга тиеш, әлбәттә. Монысын да К. Кәримовның ачышы буларак күзаллау дөрес булыр иде. Әсәр тулысынча бер принципка буйсындырылуы белән камил булып килеп чыккан. Ком сәгатенең соңгы комы ничек кинәт савылып бетсә һәм шуны күреп торганда ничек вакытның туктылып калуы кебек хис күңелдә туса, К. Кәримовның «Ком сәгате»н укып тәмамлаганда да шундый ук тойгылар эчендә каласың. Менә әсәрнең каһарманы Фазыл, үз бәхетенә ирешү өчен барысын да эшләгән егет, Әлфинә белән гомерлеккә кавышырлар, аңлашырлар сыман, алар хәзер бергә, бер кабинада. Әмма шунда Язилә пәйда була. Ул язгы ташу вакытында, Бөгелмә аша юл табып, бөтенләй мөмкин түгел сыман вакытта, кинәт, төн уртасында ашкынып килеп җиткән. Вәгъдәләшмәгәннәр дә югыйсә. Фазыл аңа беркеме дә түгел. Ә Язилә – максатчан.

Аның аркасында Фазылның бәхете, мәхәббәткә багышланган киче өзелә. Соңгы бөртек ком савылып төшкәндәй тоела. Ком сәгате кинәт туктап кала. Әсәр тәмамлана. «Ком сәгате»н автор тагынтагын әйләндереп куярдыр сыман. Әсәрнең композициясе дә моңа тулы мөмкинлек бирә югыйсә. Бәлки, шушы корылмада әсәрнең дәвамнары да барлыкка килер, кем белә? Әмма хәзергә «Ком сәгате» туктап калган хәлендә.

Әдәбият белән кызыксынучылар хәбәрдардыр: К. Кәримов яшьлегендә су скважиналары бораулаучы булып эшләгән[1]. Бу факт

[1] *Карагыз: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.* Совет Татарстаны язучылары: биобиблиографик белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 272.

әсәрен язганда авторның шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянганлыгын раслап тора. Хезмәте җиңелләрдән булмаган. Фазылның күргәннәре аша әдипнең язмышын да чамалау мөмкинлеге бар. Дөрес, ул бары тик үзенең генә тормышын бәян итеп чыккан дия алмыйбыз. Әмма авторның шәхси тормыш тәҗрибәләре тәэсирендә вакыйгаларның реалистик планда ачылуын һичничек инкяр итү мөмкин түгел. «Ком сәгате» буш фантазиягә корылган әсәрләр рәтендә йөрми, анда саташу һәм саташтыру, башка әдипләргә һәм әсәрләргә ияру дә юк.

Әсәрнең каһарманнарыннан егет кеше Фазыл һәм аның хезмәттәшләре – зур акча эшләүчеләр. Әгәр дә бүгенге чорның хыялый күзлегеннән карасак, алар бәхетле булырга тиеш иделәр бит. Әмма бәхет акчада түгел икән шул. Зур акчалар эшләп алып кайткан Фазылны Шәледә әнисе тарафыннан инде сатылырга өлгергән, үз көчләре белән салынган ятим йорты көтеп тора. Көтеп тора, дип, көтеп тормый шул. Бу йорт инде аларныкы түгел. Әнисе колхоздан алган ссудасын түләп бетерә алмаганга саткан аны. Авылдашлары, бигрәк тә җирле җитәкчеләр күпме мәрхәмәтсезлекләр кылганнар. Автор боларны белдереп үтми кала алмаган. Язучыларны туган авылы һәм авылдашлары гөл туфрагында гына үстермиләр шул! К. Кәримов Шәленеке түгелме?

Әсәрнең башыннан ахырына кадәр шушындый аяусызлык, мәрхәмәтсезлек, мәгънәсезлек белән тулы тормыш вакыйгалары реалистик планда чагылыш таба. Гадел җәмгыять буларак хыялланылган социализм заманында да ул шушындый сурәтендә, инде яңа, монысы да гадел дип аталган демократия чоры да шушындый ук сыйфатта. Берни үзгәрмәгән. Ком сәгате бер башыннан икенчесенә әйләндерелеп кенә куелган. Һаман шулай ук тормыш комы ага бирә, савыла бара.

Хәер, бу хакыйкатьләр, кемнең-кем булуы халыкка күптән мәгълүм. Алар турында күпме каләм карасы түгелгән, күпме бәгырьләрнең каннары кипкән. Тагын күпме язарга мөмкин? Барыбер файдасыз!

Ә К. Кәримов шушы хакыйкатькә бөтенләй башкача караш тәрбияләүгә алынган. Тормышка карата ироник мөнәсәбәт, тормыш авырлыкларына, үткәнгә шушы әсәрендәге кебек ироник караш татар укучысына җитми иде түгелме?

Дөрес, татар әдәбиятында мондый хисләрне тәрбияләүче әсәрләр элек тә бар иде. М. Мәһдиевнең повестьлары нәкъ менә шушылай, авыр һәм мәрхәмәтсез тормышка карата ироник мөнәсәбәт тудырып язылганнар иде түгелме соң? «Без кырык беренче ел балалары», «Ут чәчәге», «Торналар төшкән җирдә» һәм башка әсәрләре белән М. Мәһдиев татар әдәбиятында ирония алымын файдаланмадымы? Әйе, дибез. Ул да шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянды, ул да тормышның авырлыгына карата ироник мөнәсәбәт тәрбияләде. Һәм менә К. Кәримов бу әдәби юнәлешне, әдәби агымны тагын да биегрәк баскычка күтәрде. Без инде хәзер татар әдәбиятында җитлеккән, көчле агым булып яшәүче ироник реализм методының барлыгы турында белдерә алабыз. Ул оптимистик социалистик реализм кысаларында да яшәгән икәнлеген аңлыйбыз, беләбез. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Реализм, әдәби иҗат юнәлеше буларак, романтизм сыман, үзендә әлегә без күз алдына китереп җиткерә алмаган күптөрле мөмкинлекләрне яшәтә, үстерә килә. Вакыты җитеп, аны тарихи бер дәвердә тормыш тәҗрибәсе туплаган һәм формалашкан әдипләр үз иҗатлары белән үстереп җибәрәләр.

Бездә, фәндә һәм тәнкыйтьтә, иҗат методларыннан, аларга яратмыйча гына «изм»нар дип карап, ятсыну һәм курку яши. Моның сәбәпләренең берсе – иҗат методларының табигатен белмәүдән, аңламаудан гына югыйсә. Хәер, сүзебез ул хакта түгел, башкада: татар әдәбиятында бүгенге көндә яңа бер иҗат методының тәмам формалашып җитүе һәм яшәве хакында, ироник реализм турында. Аның тормыш дөреслеген өйрәнү һәм чагылдыру механизмын хәзер күзаллау авыр түгел. Ул тормыш хакыйкатен, бигрәк тә аның авырлыгын ироник планга корып ачудан гыйбарәт. Электә үк язылган ироник әсәрләр һәм ирония алымнары, әлбәттә, аның тамырын хасил итә, әмма аның метод буларак формалашып җитүе К. Кәримовның «Ком сәгате» романына карый. Моңа автор үзенең барлык иҗаты үсеше дәверендә килде. Бу әсәргә татар әдәбиятының тарихи барышының бер затлы нәтиҗәсе буларак та бәя бирергә кирәк.

*12 март, 2008*

## Безнең Фәнзаман

Бүгенге көннең чын әдибе хакында сүз кузгалса, иң тәүдә татарның Фәнзаман Батталын телгә алырлар иде дә, аның дөньякүләм мәшһүр О'Генри һәм Газиз Нәсин белән бер рәттә, хәтта ки кайбер үзенчәлекле яклары белән өстен дә торуын искәртеп куярга онытмаслар кебек. Әмма... Әмма дими дә булмый. Сәбәбе шунда: безнең татар әдәбиятын укудан, аңлаудан дөнья халыклары мәхрүм. Хәтта үзләренең бу яктан никадәр чарасыз икәнлекләрен төшенүдән аз гына да арырак китә алмыйлар. Алар уйлыйлар: имеш, татар халкы күптән урысча яза, урысча сөйли, урысча яши. Хәер, урыс белән гомергә сайрашып яшәвебез аркасында, газиз Г. Тукаебыз әйтмешли, тел-лөгать һәм әхлак алмашканбыз да алмашынганбыз инде. Берберебезне сөештерү гадәтләребез дә юк түгел. Тик урыс та татар әдәбиятын белми, белә дә алмый калган. Ул тәрҗемәи ярым-йорты китаплар аны безнең эчке тормышыбызның тирәнлегенә алып керер дәрәҗәдә түгелләр. Безгә рәхәт, анысы: урыс телен белүебез, аларның әдәбиятын өйрәнүебез, бу исә Анналарын, Базаровларын ялгышмый тануга, урыска нәрсә кирәклеген кыланышыннан ук аңлавыбызга китерде.

Һәр милли әдәбият үз халкын, аның вәкилләрен яза, дөньясын биниһая якты талант кояшының нурлары белән яктыртып бирә. Менә шуңа күрә дә, кайсы гына халыкны өйрәнсәләр дә, галимнәр иң тәүдә аларның телләрен, гореф-гадәтләрен төшенергә тырышалар, моның өчен һәм сөйләм, һәм язма әдәбиятлары белән танышуга ихлас күңел салып эшкә керешәләр. Бу – мең тапкырлар танылган, хакыйкый чара икәнлеге ачыкланган дөрес юл.

Әмма безнең татар белән дөнья халыклары кызыксынмыйлар. Барлыгыбызны белсәләр – рәхмәт, диям. Аннары, алар безнең әдәбиятыбызны асылына төшеп аңламаслар, чөнки әдәбиятыбызны төшенүләре өчен, мәдәниятебезне белүләре, кабул итә алулары кирәк. Ә безгә җайлы, ә безгә күңелле. XIX йөзнең соңгы чирегендә данлыклы бабаларыбыз Европага таба йөз белән борылганнар да, Жан-Жак Руссо, Вольтер, Гейне, Гёте һәм башкалар хакында, аларның фикерләрен актарып ташлап, җиңел кулдан бәхәс кыла-кыла, аларга ияртеп урыс әдипләрен дә өйрәнеп, безнең фәһемдә бөек кызыксыну шаукымы белән сугарылган мең төрле

төсләрдән гыйбарәт мәдәният бакчаларын чәчәккә күмеп, дәртебезгә аңлау, кабул итү көчен биреп калдырганнар. Менә шул үсештә ничек Тукаебыз, Такташыбыз, Җәлилебез, Туфаныбыз, Акъегетзадәбез, Бигиевыбыз, Камалыбыз, Ибраһимовыбыз, Исхакыебыз һәм башкаларыбыз туган кебек, сүз уйнаткан кебек язганында да йөрәк-бәгырьләргә утырган юшкыннарны кубарып ташлаучы Ф. Батталыбыз да дөньяга чыккан. Дөньяга чыккан да, олы бер баһадир адәм кыяфәтендә, каш өстенә кулын куеп: «Абау, сез нигә шушы кадәр ваклар?» – дип шаяртып та аласы иткән.

Ул йомшак чеметә, боргачлап аптыратмый, күсәк күтәреп ору гадәте дә юк. Бездә күпләр, сүз яза башласалар, шулкадәр ерактан һәм тирәннән алдыралар ки, гүяки фикер сабаннары мәгънә туфрагын каергалап салыр сыман. Әмма бу кыланышлары җир өстен тырнап барулары кебегрәк килеп чыга. Тавыклары түтәлгә керә башласа, бакча читәнен сикереп узар өчен җай чамалап уйланып йөри-йөри, көнен, төнен, ничәмә гомерләрен уздыра. Инде менә сикереп менде бу, дисең. Инде дә йөгереп керде дә түтәлләрне актарып ташлады, әшәке җан, дисең. Әмма ул кикрик каһарманы, бичаракаем, максатына ирешә дә алмыйча егылып үләргә өлгерә.

Ф. Батталда хәтта чебие дә андый түгел. Инде карыйсың, әсәренең каһарманы Америкага барып чыккан. Мактанып торырга вакыты юк. Үз дигәнен итеп, милли туфрагыбызга кайтып та җиткән.

Ф. Баттал вакыйгаларны җыйнак төзи, аның фикерләре ныклы нигезгә корылганнар, сүзләре якты һәм ямь булып тезелеп китәләр дә, саф чишмә кебек челтерәп, зиһенгә агылалар, күңелләрне кытыклап алалар. Аларны укыганда, күңелләргә сафлык үзе тула, еллар буе килгән юк-бар уйларыңнан, тормыш юлларының тузаннарыннан арынасың. Аның ул бер-бер артлы бер дә тукталып булмыйча укыла торган хикәяләре, әдәби парчалары бары тик чын татарның талант җимеше, әлбәттә. Башка халыкларда ул вакыйгалар болай була алмыйдыр сыман. Ф. Баттал – әдәби сүзе-җөмләсе, уе-фикере белән ничек чып-чын татар булса, вакыйгаларны тасвирлап бирүдә дә, каһарманнарын сурәтләүдә дә асыл татар, соклангыч милли әдип. Ул – хәтта шушындый булуы һәм була алуы сәбәпле дә дөньякүләм бөек әдип. Дөньяның ирешелмәгән кыйтгалары, табылмаган утраулары юк дияргә ашыкмагыз! Әле әнә күптән түгел генә Төньяк диңгез-океан киңлекләрендә Йайа утравын ачтылар.

Татар әдәбияты һәм әдипләре дә дөнья халкы өчен әлегә ачылмаган бөек кыйтга белән бер.

* * *

Тикшергәндә, ачыклык керткәндә, төгәл билгеле була: безнең Ф. Баттал совет юморыннан үсеп чыкты. Аның әсәрләрен без, укучылары, совет җәмгыятеннән көлү буларак кабул иттек һәм аларда сурәтләнгән хакыйкатьләр ярдәмендә дөньяны ачык аңларга, тоярга, бәяләргә өйрәндек. Көлкеле идек, көлкеле иделәр, әмма хәлләребез еларлык та булган икән шул.

Бу сүзләребезне язганда, Ф. Батталның ике юмористик һәм сатирик хикәяләр җыентыгын күздә тотабыз. Аларның беренчесе «Сакалыңа ут капса...» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 96 б.) дип атала, икенчесе «Гөнаһ шомлыгы» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 247 б.) дип исемләнгән. Совет юморы, яки советча юмор үз тарихы һәм традицияләре белән яшәде. Аның һәр үсеш-яшәеш этабының үз төсе, үз фәлсәфәсе, үз картиналары бар иде. Узган гасырның беренче чирегендә формалашып җитеп, хәтта социалистик җәмгыять таркалып төшкән шул ук гасырның 90 нчы елларында да ул үлмәскә тырышты, аны алыштырган яңа тип юмор әдәбиятыбызда нәкъ менә шул ук 90 нчы еллар ахырында формалашып җитте. Ул да милли Камырбатырыбыз кебек булып чыкты, көн үсәсен төн үсте, төн җитешәсен көн өлгерде. Аны бишегеннән күтәреп алып, алга таба тәпи йөгертеп җибәргән кеше дә Ф. Баттал иде, комедия һәм юмор-сатира остасы Зөлфәт Хәкимне дә аның янәшәсендә атасак, тагын да Камил Кәримовны һәм бер дистәләп исемне искә алсак һичбер хата түгел. Аларның һәммәсен бергә, бераз күпертеп, «батталчылар» дип атарга да мөмкин, әлбәттә. Бөек Батулла агабызның татар юмор-сатирасында башлап җибәргән һәм аерым бәхәсле сөйләшүне дәгъвалаган «батуллаизмы» белән чагыштырып, бу ике мәктәпнең кайсына да беренчелекне бирә алмыйча аптыравыбызны монда искәртеп узарга тиешбез. Әмма сүз башыбыз – Фәнзаман Баттал, «изм»нарга кереп чуммыйча гына, матур әдәбиятыбызның җанны савыктырыр гүзәл бакчаларына сәяхәтебезне яңартып җибәрүебез хәерлерәк булыр.

Без Ф. Батталны «советча юмордан үсеп чыкты» дидек. Әмма ул аның бөтен бер тарихыннан түгел, узган гасырның 60–70 нче елларында куәт алган этабыннан тамырланып килде. Бу табигый

да, чөнки Ф. Баттал шул чорда каләмен чарлап эшкә кереште. Әдәбиятның юмор-сатира өлкәсендә Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, алар янәшәсенә ирешеп килгән Шәүкәт Гали, Гамил Афзал, Мөхәммәт Мәһдиев имзалары өстен куелган чордан иде ул. Бу дәвернең үз хикмәтләре, үз максатлары, үз стратегиясе булды: совет җәмгыятендә сыйнфый-сәяси мәсьәләләр чишелгән, хәл ителгән, ә менә әхлаксызлык, тәртипсезлек, аңсызлык элементлары яшәп калган, – шулар белән көрәшергә кирәк, диделәр. Без хәзер ул фәлсәфәдән көләргә яратабыз. Әхлак-әдәп мәсьәләләрен бик тә сай өлкәгә саныйбыз, яманлыкны кул ишарәсе белән генә дә хәл итү мөмкин дип уйлыйбыз. Һәм ялгышабыз. Кешелекнең асылы – әдәп-әхлакта. Ул икенчел түгел, ул – беренчел, үтә дә архи һәм катлаулы мәсьәлә. Әдәбиятта XX гасырның башыннан үстерелеп килгән сыйнфыйлык һәм партиялелек мәсләгеннән котылу, кешелекнең үз стихиясенә әдәбиятны кайтару, шуның белән аны сәясәттән, коммунистик идеяләрдән арындыра башлау чорының да, ни хикмәт, нәкъ менә 60–70 нче елларга туры килүе тарихыбыз өчен хәерле булганлыгын инде хәзер аңлауга ирештек. Югарыда, баш очында Дамокл кылычы булып коммунистик идеология эленеп торды һәм аның үтә сак һәм сизгер хезмәткәрләре тырышып эшләүләрендә булдылар. Әдәбият исә үзен яңа җилләр булачагын тойгандай хис итте. Моның өчен без «сыйныфсызлык әдәбияты» хакындагы, ул вакытта бөтенләй дә хорафи тоелган мәсьәләне алга куйган, шул идеалларны өстен чыгарырга омтылган тәнкыйтьчеләргә рәхмәтлебез. Әмма аларның да эшләре җиңеллек белән бармады. Югары белем алып чыккан яшьләребезнең колаклары данлы-шанлы марксизм-ленинизм белән дыңгычлап тутырылган һәм тиздән килеп ирешәчәк коммунизмның бөек хезмәт кырларына ул фидакярләребез батырларча ашкынып тора иделәр. Дөрес, үзләрен тынычлыкта калдырганнары да араларында булгандыр – дөньяда барысы да тигез хәлгә кереп бетми.

Менә шул чор әдәбиятыбызга Ф. Батталны – бөек каләм иябезне бирде. Ул да тәрбияле, хәтта ки советча тәрбияле иде. Аның бу советчалыгын «Яңа прораб», «Хатынны ничек кулга алырга», «Кайнар характерым» һәм тагын да берничә дистә хикәясенең эчтәлеге дәлилләп тора. Ул советча гына түгел, хәтта ки чын коммунистларча да булгалады. Әмма безнең коммунист җитәкчеләребез

шикәр чөгендерен мал чөгендереннән, солычаны-сарутны солыдан, арыш саламын бодайныкыннан аера алмаганнары кебек, гаделлек белән гаделсезлекне дә бутый торган аңгыралардан иделәр. Алай түгел дип бәхәсләшергә теләүчеләр Ф. Батталның китапларын ачып укысыннар, ул аларны бармактан суырып чыгарып язмаган, әсәрләрендә тормышның үзен, аның хакыйкатьләрен тасвирлаган. Менә шуңа күрә дә Ф. Баттал әле башы-аягы буталу дәвере – аударылыш елларында, ягъни узган гасырның 90 нчы елларында да кызыл галстуклы һәм кызыл япмалы трибуналы әдип буларак та кабул ителде. Башкача мөмкин дә түгел иде.

Һәм безнең татарны милли хис, милли мәсьәлә тоташтан демократ ясады. Сизенмичә дә калдылар күпләр. Милләтенең татар булуын, милләтнең үз әнкәләредәй газиз икәнлеген аңлау-төшенү белән бергә, алар дертләп уянып киттеләр һәм ашауларын да оныттылар. Бу хисләрдән мәхрүмнәр исә дөнья малларын бүлешү җаен карадылар. Безнең татарда демократия милли мәнфәгать белән бәйле кабул ителә, аңардан башка күзалланмый. Ул газиз Г. Тукаебызның «Туган тел»ен гимны ясады, шуның белән бергә, демократия үзе дә милли горурлыгыбызга әверелде. Ә демократия исә яшәешебез мәйданының түренә гади кешенең хәсрәтен, шатлыгын, бәхетен – барча мәнфәгатьләрен кайгыртуны китереп салды. Татар әдәбияты гади кешегә мөкиббән итте, югарыдагыларны сөйми-өнәми, тәмам яратмый башлады. Язучылар үзләрен милләтнең асылы буларак тойдылар. Алар чын мәгънәсендә милли аристократия иделәр. Ф. Батталның иң сөйгәне гади халык, гади кеше, аның яшәү рәвеше, тормышы, барлыгы-юклыгы, фикере-сүзе, холкы-фигыле иде. Совет чорында иҗтимагый-сәяси торыш хакында хәсрәтләнүдән ләззәтләнгән милли әдәбиятыбыз кешелеккә таба йөз белән теләр-теләмәс кенә, бик авыр борылды. Моңа кадәр «кайбер кимчелекле элементларны» көйдерүче юмор-сатираның демократик әдәбият агымына килеп керүе кайсы әсәр белән башланды икән дигән сорауны үз алдыбызга еш куябыз. Матур әдәбиятыбызга бәйле сорау бирелә калса, аның төгәл җавабын, хәтта датасын да беләбез. Ул әсәр – «Пәйгамбәрләр тарихы», әлбәттә, датасы – 1992 ел. Әмма кайберәүләр ул китапка бугазыннан буып ташларга теләп ябырылдылар. Бу хәл иске тормышның яшәп калырга теләп якалашуыннан шулай килеп чыкты. Аларны җен бутады, аларның

женнәре буталды. Ф. Батталның шул елларда «Гөнаһ шомлыгы» китабы басылып чыкты. Ул һаман да шул ук советча юмор иде. Әмма анда «Кияүнең «кимчелеге», «Бик каты әйтте...», «Сабак» һәм башка берничә хикәясендә ачык чагылган «башкачалык» та сиземләнә иде. Әдипне зирәклеге бөек итте, һәм ул аңа шуның өчен дә гомере буена хезмәттә булды.

Ф. Батталның 2000 елда Казанда «Идел» китапханәсе» нәширлегендә бастырып чыгарган «Юлын белгән адашмас» исемле 367 битле китабы бар. Ул тоташ публицистик язмалардан гыйбарәт. Әсәрләре хронологик тәртиптә бара. 1992 елның маенда Ф. Батталыбыз – милли сукмакка кергән «социализм баласы» – алга таба бер дистә ел дәвамында диярлек демократиянең ни-нәрсә икәнлеген эзләп гаҗизләнә. Югыйсә җавап бик төгәл: демократия ул – гади халык мәнфәгатьләрен яклау, гади халыкның теләк-омтылышларын бар нәрсәдән өстен кую! Бу билгеләмә бөек грек фәлсәфәчесе Әфләтүн тарафыннан 24 гасыр элек дәлилле төшендерелгән. Ф. Баттал аны советча аңлавы белән яшәп, демократияне сайлау ирege, сүз ирege кебек, нәтиҗәләрне сәбәбе-нигезеннән башка гына күзаллый. Ә талантның үзенчә булырга хакы бар. Бу китабы Ф. Батталның чын мәгънәсендә яңа чор әдибе төсен ала баруын ачык күрсәтеп тора. Китапка сүз башы язган тәнкыйтьче Мансур Вәли-Барҗылы аның авторының үткен каләм иясе икәнлегенә кат-кат басым ясый һәм җыентыктагы барча публицистик язмаларының тупланып бирелмәвен искәртүне кирәк таба (китапның 5–8 нче битләрендәге «Сатира батыры» язмасы хакында сүз бара). Дөрес яза: Ф. Баттал – фидакяр. Аның публицистикада да шундый булуын «Замандашларым» (Казан: Ихлас, 2013. – 192 б.) китабы тагын бер кабат раслый. Ул андагы язмаларында рухлары белән үзенә якын кешеләрне бәяли, бәянлый. Кызыклы да, уңышлы да хәбәрләр. Кешеләрне бәяләве – бер хәл, алардан Ф. Баттал үзен дә эзлидер сыман тойгы калдырыла, ул үзенә дә читтән караш ташлыйдыр кебек. Бу да, – әлбәттә, фидакярлек, күңеле сафлыгыннан килә. Ә талант иясенең күңеле караңгы була алмый.

* * *

Ф. Батталның бөек талант иясе икәнлеген тәкрарлар өчен, «Сигезенче оҗмах» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 351 б.), «Менә

шулай яшә!» (Казан: «Идел-Пресс», 2008. – 384 б.), «Көлмә кешедән...» (Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 383 б.) китапларын да дәлил итәбез. Алар юмористик һәм сатирик әсәрләреннән, төрле планлы язмаларыннан төзелгәннәр. Дөрес, берсендәге хикәянең икенчесендә дә кабатланган очраклар бар. Әмма бу кабатланып басылган әсәрләре, талантлы язылган булулары сәбәпле, ул кабатланылуларын аклыйлар. Ә менә «Башыңны сакла, кызым!» хикәясен укыганда котларың очарлык. Кая ди ул көлү, елап җибәрүдән чак тыелып каласың. Заманага хас вәхшилекне язганда, Фәнзаман аганың бөек каләме хакыйкатькә бәйле штрихларны «басыбрак», «кәгазьне тырмабрак» язып куя. Мондый урыннар аның әсәрләрендә очраучан. Әдәби әсәрләрне тигез генә, сикәлтәсез генә язылырга тиеш дип белгән сак күңелле укучылар, мондый урыннарны укыганда, «әтәч җибәрде», «фальшь ясап алды» дияләр, әлбәттә. Бу хикәягә бәйле дә ул сүзләр дөрес булачак. Акланырлык та түгелдер сыман. Язучы язганнарга карасак, ямьсез килеп чыккан. Чибәр Рәмзияне баянчы инде «харап иткән» булган икән. Имеш, ерткыч егетләр хәзер нишләсә дә ярый.

Болай ук кирәкми иде. Бу әдипләрчә түгел! Моны яшереп калырга ярамас, язучының үзенә дә шелтәле искәртми мөмкин түгел. Дөрес, укучының хисләрен кызганудан, әсәрдә тасвирланган ситуацияне бераз йомшартырга, трагедияне юморга борырга теләүдән бу шулай килеп чыккан, бөек талантыбызның аягы таеп киткән, дия алабыз. Әмма әйтмибез, чөнки сәбәп аңардан түгел, бәлки заманабыздан килә. Без хәзер барча бәлане җилкә аша җиңел үткәреп җибәрү ысулларын психологларның һәм шарлатаннарның төрлечә бастырылып таратылган киңәш китапларыннан өйрәнеп бетеп киләбез. Монда әдибебез шушындый коры тәэсиргә бирелгән, анысын да аңларга тиешбез. Шулай да Ф. Батталның бөек таланты аклауга һәм акланугa мохтаҗ түгел. Бәлки менә шул «фальшь тоелган» урыннарның кайвакыт әһәмияте зурарактыр да әле? Алар җәмгыятебезнең йөзен күрсәтү алымнарының яңаларыннан түгелләрме?

Ф. Батталның талантлы язу сере гади, хәтта, әйтер идек – үтә дә гади: ул бер-бер тормыш фәлсәфәсенең җеп очын эләктереп ала да аны җай гына сүтә башлый. Чияләнеп беткән, ягъни «фальшь тоелган» җирләрен дә сак кына җайлап җәеп-төзәтеп җибәрә. Хикәя

формасындагы йомгагына урап бетерә дә әсәрен укучы алдына «тәгәрәтә». Күренеп тора – бик гади, үтә дә гади. Әмма аны шулай итәр өчен язучылык сәләтең генә аз, моның өчен Ф. Батталныкы кебек бөек талантка ия булуың кирәк! Бу О'Генри һәм Г. Нәсин иҗатларында да нәкъ шулай.

*Декабрь, 2013*

## «Оча торган кешеләр», яки Ак төс тантанасы

*(Г. Гыйльманов иҗатына бәйле)*

Г. Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» романы 2007 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан бастырылып чыгарылган шул ук исемдәге «Роман, повесть, бәяннар» җыентыгында дөнья күрде. Моңа кадәр ул алдан «Идел» журналында, журнал варианты буларак, укучыга тәкъдим ителгән иде.

Күләме белән бу роман зур түгел, китапта алдагы 150 сәхифәне алып тора. Язылышы белән кызыклы, укучыны үзенә җәлеп итә. Вакыйгалары һәм геройлары, Г. Гыйльманов каләменә хас булганча, аерым бер күңел җылысы белән ачылалар. Каршылыклар геройларның үзара юктан гына үпкәләшүләреннән, бер-берсен якын итмәү, аңламауларыннан, үз «эго»ларының өстен куелуы сәбәпле барлыкка киләләр, шушы «су» белән даими сугарылып, шушы «су» белән вакыйгаларда үстереләләр, конфликт дәрәҗәсенә җиткерелеп, ахырда чишеләләр. Бу конфликт эчке каршылык төсен ала, әдәби герой бөтен сурәтләнелеше белән тышкы дөньяга каршы куела. Аның үз дөньясы гына хакыйкый, үз карашлары гына дөрес, үз әдәбе генә әдәп, ягъни бөтен яктан да ул үзе булып кала. Вакыйгалар барысы да аның барлыгын һәм өстенлеген раслау өчен хезмәт итәләр. Мондый геройлар үзләре шулай ук ак яки кара була алалар. Романда Г. Гыйльманов нәкъ менә шушы ике төсне уңышлы файдалана, чагылдырган тормыш һәм табигать картиналарын да шушы буяулар белән сурәтләп бирә. Моның да уңышлы як булуын искәрергә тиешбез. Вакыты-вакыты белән әдәби картиналарда аерым төсләр дә барлыкка килеп ала тора, мәсәлән, төп геройның балачак хатирәләреннән калган кояшлы көннәре яки кыр чәчәкләреннән җыйган букеты, яисә авылга кайткач, клевер чабар-

га барырга ниятләнеп-сөйләшеп йөрүләрендә клеверны күзаллавы, кызыл-бакыр чәч һәм зәңгәр күзләр – болар шушы ак һәм кара төстәге күренешләргә аерым-аерым төртке-нокталар рәвешендә төс биреп алучы тере картиналар.

Г. Гыйльманов бу романында махсус рәвештә ак төсне өстен чыгара. Әсәренең теле дә моңа хезмәт итә. Автор, шушы төсне бирү өчен, стилистик модельләрне оста файдалана, бигрәк тә әйтемнәр, мәкальләр, хикмәтле сүзләр романда еш кулланылалар. Укучы мондый хикмәт-аксиомаларның, берсен икенчесе алыштырып килеп, тезмәләргә әверелеп китүләрен дә уңай кабул итә. Алардан артык та, ким дә түгелләр сыман дигән тойгы кала, чөнки бер мәкальгә икенчесе бәйле, икенчесен өченчесе ачыклый, конкретлаштыра, өченчесенә дүртенчесе мәгънәви яктан берегеп китә. Мондый урыннарны, Д. Заһидуллина термины белән әйтсәк, стильдә җөмләләрнең вакыт-вакыт «җем-җем җемелдәп китүе» очраклары дип атарга тиешбез. Ул «җемелдәүләр»дә автор бик оста рәвештә халык мәкальләрен дә, үзе уйлап чыгарганнарын да, хәтта ярым-хикмәт, ярымаксиома рәвешендә булуларына да карамастан, уңышлы кертеп җибәргән. Мәсәлән: «Кайсыдыр изге китапта әйтелгән бит: «Алла безгә биргән рухны нык сагына», – дигән» (романның беренче битләрендә үк бу сүзләр). Һәм автор шушыңа бәйле үз фәлсәфәсен тезә башлый. Стильдәге ул «җемелдәүләр», аерым төс алган картиналар белән үзара ярәшеп, романның укучыга тәэсирен камилләштерәләр. Әсәр көчле җәлеп итә. Бер сулышта диярлек укыла. Артык аклыгы, артык буталчык булуы, артык таркау вакыйгалардан торуы һәм аларның гүяки очраклы рәвештә бергә җыелулары кебек тойгылар уятуы, инде кайдандыр таныш булган, ремейк элементларының төрле культураларга хас әдәби әсәрләрне һәм кинофильмнарны искә төшерүләре – болары шулай ук үз рольләрен башкаралар. Романны анализламаган очракта, уку өчен генә укыганда – әсәрләндерә, бик тә яхшы хис-тойгылар калдыра. Анализлаганда исә, аның эчтәлеге көтелмәгән яктан ачыла. Бу ягы белән Г. Гыйльмановның «Оча торган кешеләр»е үзенең үк «Албастылар»ына да, А. Хәлимнең «Өч аяклы ат»ына да, Н. Гыйматдинова, Ф. Бәйрәмова, М. Галиев, З. Хөснияр, З. Хәким әсәрләренә дә тартым. Бу әдипләр һәм аларның иҗаты татар әдәбиятында бердәм көчле әдәби агым барлыгын раслый. Без аларның

барысын да «постмодернистлар» дип атыйбыз. Араларында нинди әдип булуы ачык аңлашылып торганы, постмодернизмның һәммә якларын да үз иҗатында раслый, үстерә, милли үзенчәлекләрен тагын да ныгыта алганы Г. Гыйльманов, әлбәттә. Шунысы кызыклы: бу әдип-әдибәләр бер-берсен кабатламыйлар, әдәби дөньяларын үз стихияләрендә, үз карашлары эчендә, үз фәлсәфәләре белән бәйле яшәтә беләләр.

Г. Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» романы һәм аның бүгенге укучы өчен иң әһәмиятле ягы – җиңел укылуы белән дә кызыксыну уяту көченә ия булуында. Андагы туктаусыз кабатланучы символлар, символик һәм мистик эчтәлеккә ия әдәби картиналар, уйдырма һәм чыннан да халыкта таралган яки юк мифлар, экиятләр, дөрес һәм ярым-дөрес сынамышлар, аларга геройларның игътибар итүләре һәм әсәр барышында шуларның дөрескә чыгулары яки геройларның боларны хак дип искәртүләре, халыкта булган яки булмаган йолаларны халыкта сакланып кына калмаган, онытылган яисә хәзер дә бар, әмма аңа игътибар гына итми торылган дигән фикерләр уздырылу – болар барысы да авторга карата да укучыда соклану тойгыларын уяталар һәм әсәрнең талантлы язылуын раслап торалар.

Төп геройлары да бик кызыклы бирелгән. Романда өч Сәүбән хакында сүз бара. Беренчесе – Сәүбән үзе, авылда туган, ак йөзле, сыек зәңгәр (күк) күзле, бакыр чәчле – Венера планетасы кешеләре шундый, имеш. Һәм анда әтисеннән калган гадәт бар: ул – «оча торган кеше», ягъни таудан да сикерә ала, биек йортның балконыннан да төшеп китә, башкача да. Аның арка-сыртында канатлардыр сыман. Автор укучыны шушы характеристика һәм портретлары белән тулысынча ышандыра.

Сәүбән, мәктәпне бетергән елны, колхозда бригадир булып эшләүче көрәшче егет Рәмис белән каршылыкка килеп, яраткан кызына көнчелеге аркасында сугышып, тәмам кыйналып, икенче көнне авылдан бакча артлатып кына чыгып кача. Казанга килә. Авиация институтына укырга керә. Аның шушы китүеннән 18 ел буе авылга бер генә кайтмавы әсәрдә берничә кат әйтелә. Ә роман поезддан төшкән, авылына таба атлаучы, күңеле моңлы булуы йөзенә чыккан, «җыйнак кына мыек җибәргән, тыйнак кына, әмма ыспай итеп чәчен кистергән... кырык биш яшьләр чамасы булыр»

(романның иң тәүге беренче абзацыннан) – шушылай Сәүбәннең портретын сурәтләү белән башланып китә. Әгәр дә мәктәпне бетергәнендә Сәүбәнгә кимендә унсигез булса (яки иң күбе 18 булсын), аның тагын да унсигез ел авылга кайтмавын искә алсак, аңа бу вакытта 35–36 яшьләр чамасы булыр иде. Әмма авторның белдерүеннән без аңа инде 45 яшьләр тирәсе икәнлеген беләбез. Дөрес, романда Сәүбәннең авылына бу юлы кайтканындагы яше төрлечәрәк бирелеп барыла. Әмма автор аны кырыктан киметми. Һәм без моны Г. Гыйльманов махсус рәвештә шулай эшли дип уйларга мәҗбүрбез.

Икенче Сәүбән – ул беренче Сәүбәннең өрәге, бала чагында калган Сәүбәннең җаны дип аңларга кирәк. Әмма аңа, нигәдер, 12 яшь. Әгәр дә Рәмис белән сугышуына һәм авылыннан Сәүбәннең чыгып качуына бәйләп карасак, бу өрәккә унике генә яшь була алмый.

Романның башында ук бу өрәк белән дә очрашабыз. Ул авыл капкасы янында Сәүбәнне унсигез ел буена кайтырмы дип көтеп утырган. Аңлашыла, бу – аның тынычлыгын югалткан җаны. Шушы мистик образ романның тәэсир көчен бермә-бер арттыра, укучыда шик һәм уйлану тудыра, күңелендә интригалы тойгылар хасил итәргә этәргеч бирә. Хикмәти мәгънә алып, чынбарлык белән хыял, тышкы дөнья белән эчке дөнья буталышы (яки кушылышы) барлыкка китерелә. Әсәр үзенең реалистик эчтәлеген шушы өрәк килеп күренүдән башлап, ягъни беренче битләрендә үк югалта. Фэнтези дөньясы башланып китә. Ул, әлбәттә, аклы һәм каралы гына. Монда барысы да яки ак: дөнья да (әйләнә-тирә мохит) һәм андагы кешеләр дә (Ак әби, Ак бабай һ.б.), яисә кара гына: тау эче, болытлы яңгырлы төн, кайбер кешеләр (Зәлифә, Рәмис, хатыны Сәвия һ.б.). Әсәрдә буталчык урыннар берсен икенчесе алыштыра. Монда автор түгел, герой бутала. Вакыйгаларны ул бер логикага салырга тырыша, әмма мантыйкта алар төрлечә килеп чыгалар. Шул сәбәпле Сәүбәннең сөйгәне Сәвия дә көмәндә баласын кай очракта елдан артык, икенче бер логик тезмәле ачыклауларда хәтта ике ел һәм аннан да артык йөрткән кебек аңлашыла. Баланы табу вакыйгалары да әсәрдә төрлечә сөйләнелә.

Бу бала Сәүбәннең улы булып чыга. Нәкъ аның үз өрәгенә охшаган әле, җитмәсә. Шулай ук 12 яшендә. Әүвәле Сәүбән аны үз

баласы итеп танымый, аннары гына, вакыйгаларны исенә төшереп, андагы буталчык урыннарга ачыклык кертә. Бу – шизоанализ юлы, шизакатьлек стихиясе. Шул Сәүбән, Сәүбәннең улы, романдагы өченче Сәүбән буларак, алга таба тагын да фэнтези элементын вакыйгага әверелдерү һәм үстерү өчен хезмәт итә башлый.

Әсәрдә ике Сәвия бар. Аның берсе – Сәүбәннең үз хатыны, икенчесе – яшьлегендә яраткан Сәвиясе. Алар авторның әхлакый карашларын яктырту өчен хезмәт итәләр. Бу яктан Зәлифә образы да уңышлы файдаланылган. Бер геройларына әсәрдәге вакыйгаларның сюжет йөген йөкләп, икенчеләренә әхлак-әдәп карашларына бәйле фикерләмәләрне биреп, Г. Гыйльманов, башка әсәрләрендәге кебек үк, «Оча торган кешеләр» романында да әдәби образларны бирү системасына ия булуын таныта. Бу аның, әлбәттә, уңышы дип хаклы рәвештә бәяләнергә тиеш.

Шулай да «Оча торган кешеләр» (романның тулы исеме: «Оча торган кешеләр, яки Иясез язмышлар хакында бәян») әсәре кемнәр һәм нәрсә хакында соң? Анда мантыйк та, тормыш дөреслеге дә юк сыман да, бар сыман да тоелса да, аңа ничек һәм нинди бәя бирергә?

Бу сорауларның үзләрендә үк җаваплары бар. Романның тулысынча ак төс эчендә, ак төс тантанасы белән язылуы, моңа язучының стилистик табышлары да хезмәт итүе, вакыйгаларның осталык белән сайлап алынуы, ак әби һәм бабайларның күплеге, кешеләрнең күңелләрендә шәфкать хисенең өстен чыгарылуы – болар барысы да хастаханә атмосферасының чагылышы. Сәүбәннең тормыш картиналарында логикасы булмау, вакыйгаларның «римейка» тәртибендә төзелүе – төп геройның шизакатьле (шизофреник) булуын раслыйлар. Бу романны, шулай итеп, шизоанализ принцибына корылган дип әйтә алабыз. Әсәр, татар постмодернизмының гүзәл үрнәге буларак, хаклы рәвештә бәяләнергә тиешле.

*2005–2011*

# III. КАБАТЛАНГАН СҮЗ ТҮГЕЛ

## Риза Фәхретдиновның ваһһабилар хакында тәнкыйди фикерләре

Р. Фәхретдиновның Ваһһабилар хакындагы мәкаләсе 1906 елда «Әлгасрелҗәдид» («Яңа гасыр») журналының 2 нче санында дөнья күрә. Ул аны «Ваһһабилар кемнәр?» башы астында урнаштырган. Авторы «Ризаэтдин бине Фәхретдин, Уфа» дип күрсәтелгән. Димәк, ул аны Уфа шәһәрендә яшәгән чагында ук язган, жанрына караганда, фәнни хезмәттән бигрәк, ул журналистик мәкалә стилендә эшләнелгән һәм анда фикерләр публицистик калыпта бәян итүгә корылганнар. Шунлыктан бу мәкаләсен, асылда, сәяси юнәлештә иҗат ителгән публицистик әсәр дип билгели алабыз.

Мәгълүм булганча, XIX йөзнең башлангыч чорында ук ваһһабичылык татар дөньясына үтеп керә. Шул ук йөзнең соңгы чирегендә иҗтимагый фикер үсешендә ныклап урнашкан алдынгы җәдитчелек идеяләре дә ваһһабичылык тәэсирендә формалаша. Асылда Р. Фәхретдиновның үзен дә, аның дини карашларын һәм тәрбия-әхлак тематикасын күтәргәндә нинди мәсьәләләргә зур игътибар бирүләрен дә искә алсак, бу яктан ваһһабичы дип билгеләрә алабыз. Әмма бу карашларын татар әдәбияты һәм иҗтимагый фикере тарихында яктыртканда ваһһабичылык белән бәйләп карау әлегә актуаль булмады, шунлыктан ни сүзлекләрдә, ни фәнни мәкаләләрдә бу хакта ачык кына язылган һәм хәтта ваһһабичылыкның нәрсә икәнлеге аңлатылып бирелгән материалларны табуы һаман да кыен. Хәтта ваһһабичылыкка караган үзенчәлекләр татар җәдитчелек хәрәкәтенең генә түгел, хәтта татар кадимчеләренең дә асыл сыйфатлары итеп аңлатыла һәм тасвир кылына киләләр. Мәсьәлә киң планда алынып, һәрьяклап тикшеренү-эзләнүләрне, бәяләр бирүне таләп итә.

Ваһһабичылыкны прогрессив хәрәкәт дип карамау хата булыр иде. Шунысын алдан ук белдерергә тиешбез: данлыклы сөгъдиләрнең сәяси омтылышларында төп идеологик коралга әверелдерелгән ваһһабичылык милли-азатлык көчләрен хәрәкәтләндерү өчен дә актив файдаланылган.

Р. Фәхретдинов журналдагы мәкаләсен «Бу сүз башыны күрән затлардан бер чугысы: “Ваһһабилары белмәк нәдән лазем улды, беленмәсе лазем улан башка шиләремез юкмы?” – дия бәхәс итәчәкләре күңелә кәлер» дип башлап китә һәм реаль училищеда укучы улының: «Әткәй! Ваһһабилар кемнәр?..» – дигән сорауны куюын, аңа җавап биргәнендә генә бу мәсьәләгә дикъкать итүен белдерә. Ул урыс мәктәпләрендә укучы татар балаларында ваһһабилар хакында хаталы фикерләр бар икәнлеген искәрә. Мисалга И. Янчинның «География» (Ч. II. – Изд. 25-ое. – М., 1904. – С. 48) дәреслеге алына һәм аннан ваһһабилар – «секта, не признающая Магомета» дигән билгеләмәгә игътибар юнәлтә. Шуннан соң Р. Фәхретдинов, бу фикернең хата булуын аңлату өчен, «Ваһһаби җәмгыяте» тарихын сөйләүгә күчә.

Мөхәммәд бине Габделваһһаб бине Сөләйман Ән-Нәҗәди Әт-Тәмйәми Әл-Ханбали (1703–1787) – «Ваһһаби мәзһәбе»нә нигез салучы галим – үз чорының иң укымышлы затларыннан булган. Туган иле Йәмәндә белем алганнан соң, Басра, Хиҗаз һәм Шам вилаятьләрендә сәяхәтләр итеп, анда исемнәре мәшһүр галимнәр белән очрашкан, алар белән кайнар бәхәсләр оештырган. Ул таркаулыкка дучар ителгән иИслам дөньясын ныгыту өчен җан ата башлаган. Шунлыктан шигый һәм сөнни мәзһәбләрдә урнашкан, бер-берсен инкяр итешүгә корылган каршылыкларны юкка чыгаруның, суфичылыктан һәм диндарлыктан, халык фикерен буып торганнарына күрә, котылырга кирәклеген яхшы аңлап эш итү юлын сайлаган. Аның бу омтылышлары шул заманның галимнәре тарафыннан тәнкыйтькә очраган. Әмма Мөхәммәд бине Габделваһһаб динне сафландыру, тарихи үсеш тузаныннан арындыру кирәклеген кайнар бәхәсләрдә дәлилләү юлын да тапкан һәм шул вакытларда ук аның теоретик карашлары да формалашып өлгергән. Аның «Китабы-тәүхид» хезмәтендә алар чагылыш тапкан.

Мөхәммәд бине Габделваһһаб ул фикерләрен хаҗилар алдында да, гарәпләр арасында да кайнарлык белән аңлата торган була.

Ислам динен саф көенчә саклауны, Мөхәммәд пәйгамбәр заманындагы рәвешенә кайтаруны, бары тик Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәхси үзеннән теркәлеп алынган хәдисләр белән генә гамәл кылуны алга сөрә.

Р. Фәхретдинов шушы мәсьәләләргә тукталып, Мөхәммәд бине Габделваһһабның эшчәнлегенә уңай бәя бирә, аның үз артыннан күпләрне ияртә алуын да билгеләп уза һәм шул вакытларда Йәмәндә сәясәт белән шөгыльләнгән Габделгазиз бине Сөгудның шушы мәзһәбне үз максатларында файдалана башлавын да ачыклый.

Габделгазиз бине Сөгуд, ваһһабиларның җитәкчесе мәртәбәсенә күтәрелеп, бу мәзһәбкә сәяси төс кертә. Асылда диннең сафлыгы өчен көрәшкән ваһһабилар дин карендәшләре булган сөнни Төрек империясенә каршы азатлык хәрәкәте җәелдерәләр, Мәккәне үз кулларына төшерәләр, ваһабилар буларак, бик күп җирләрне буйсындыралар, хәтта Мисыр һәм Төрек мәмләкәтләренең гаскәрләре белән аяусыз сугышлар алып баралар. Р. Фәхретдинов ваһһабилар мәзһәбенең тәэсире тиз арада барлык Ислам дөньясына таралуын билгеләп уза. Гарәбстанда гына түгел, хәтта Һиндстанда да галимнәр Мөхәммәд бине Габделваһһабның фикерләрен яклап чыгалар. Ваһһабилыкны Р. Фәхретдинов асылда яңа бер мәзһәб булмыйча, «бәлки Исламы җәнабе Рәсүлуллаһ вә әсхабе гасырында улан садәлегенә вә табигый хәленә куймактан гыйбарәттер» дип аңлата. Әмма алар хакында һаман «Ваһһаби мәзһәбе» исеме астында яза. Мөхәммәд пәйгамбәр мәзһәбе буларак аңлатылган сөнниләрне инкяр итүчеләр буларак, ваһһабиларны гаепләүнең зур хата икәнлегенә аерым тукталып уза.

Дөрес, ваһһабилар бу вакытларда мөселманнар арасында урнашып җиткән күп кенә йолаларны инкяр иткәннәр: «Бунлара күрә, үлекләр хозурына варып Аллаһтан хаҗәт сорамак, үлекләр исеме илә нәзерләр итмәк вә корбаннар чалмак, үлекләрдән ярдәм эстәмәк, каберләрә зиярат итәр өчен сәфәр әйләмәк, каберләр өстенә биналар салмак, мәсҗетләргә манаралар куймак – мөнһи эшләрдәндер».

Р. Фәхретдинов ваһһабиларның шушы фикерләре белән килешүен белдерә, бу гамәлләрнең, чыннан да, Аллаһыга мөшриклек икәнлеген таный. Дөрестән дә ислам дине бәла-казалардан бары тик Аллаһыга гына сыенырга таләп итә, гыйбадәт Аллаһыдан

гайрегә дөрес түгел, чөнки бөтен галәмнең хуҗасы бары тик ул гына дип өйрәтә. Бу – Мөхәммәд бине Габделвәһһабның «Китабы-тәүхид»ендә генә түгел, бәлки мөселманлыкның нигезе булган иманның асыл эчтәлеген аңлатучы китапларда да тәфсилле язылган. Ә ваһһабилар һәммә йолаларны да тәүхид күзлегеннән уздыралар һәм тарихи үсеш дәверендә барлыкка килгән шәригатьтәге күп кенә карашларның хаталанудан гыйбарәт икәнлеген дәлилләп чыгалар.

Әгәр дә татар әдәбиятының XIX йөз башыннан үсешен күзәтсәк, ваһһабиларның йогынтысыннан безнең җәмәгатьчелекнең дә читтә калмаганлыгын күрербез. Ваһһабилар дөньяви гыйлемнәрне дини схоластика белән сугаруга каршы килгәннәр, шуның белән фикер хөрлеген дә яклап чыкканнар. Шунлыктан аларны турыдан-туры фанатизмда гаепләүне хата дип бәяләр идек. Р. Фәхретдинов исә ваһһабиларны көферлектә гаепләргә омтылучыларның сүзләренә каты бәрелмичә генә, моны «гүзәл эш түгел» дип бәяли.

Ваһһабилар сугышка хәвеф намазы укып кергәннәр, тәкбир әйтеп көрәшкәннәр. Бу хәл Мисыр һәм Төрек гаскәрләрен куркуга салган.

Мәкаләсендә Р. Фәхретдинов, тарихи чыганакларга таянып, Мисыр һәм төрек гаскәрләре арасында үзләре белән сугышкан ваһһабиларга карата хөрмәтләренең шактый көчле булганлыгын да бәян итә. Ахырда: «Ваһһабилар – Рәсүл Әкрам өммәтеннән вә безем дин карендәшемез улан мөселманнардыр», – дип белдерә. Әмма аңа карап кына бу юлдагыларга иярүне кирәк эш дип санамый. «Шуйлә исә дә, – дип яза ул, – игътикад вә гамәл тугрысында мөтәббигать итәргә тиешле улан бер мәзһәб вар исә, ул да ялгыз Фәхрел-әнбия әфәндемез Мөхәммәд бине Габдулла Әл-Һашими Әл-Корәйши Әл-Мәкки Әл-Мәдинәи мәзһәбедер. Мөмкин кадәр бунын юлына иярмәк вә һич улмадыгында иярер өчен лазем улыр. Халыклар истәр ваһһаби улсыннар, истәр әшгари вә матуриди мәзһәбендә улмак ла ифтихар итсеннәр, хаклык исә Рәсүлуллаһ юлында улмактадыр».

Р. Фәхретдинов мәкаләсен шуның белән төгәлли һәм улына да бу рәвешле аңлатып биргәнлеген яза, урыс китапларындагы хаталы аңлау-аңлатуларга таянып эш итүнең буталуларга гына китерүен белдерә.

Ваһһабилар мәсьәләсенә әйләнеп кайтып, аларның карашлары, Ислам мәдәнияте үсешендә керткән өлешләре зур булганлыгын ассызыклап үтәргә кирәк. Әмма дин юлы, XVII йөз татар шагыйре С. Аллаһияр язганча, бик нәзек, анда бик тиз ялгыш эзгә басарга, читкә чыгып китәргә мөмкин. Ничек кенә булмасын, дин ул рухани өлкә генә түгел, ул мәдәни, фәнни берәмлекләрне генә дә түгел, хәтта гадәти күзаллауларны да үз эченә ала, әхлакый нормаларны төзи. Тарихи үсеш дәверендә барлыкка килгән йолалар да кагыйдә булып киткән икән, мәсәлән, Мәүлет бәйрәме һ.б., аларны фундаменталистик-ревизионистик карашлардан чыгып инкяр итү динне сафландыра дип фикер йөртергә нигез була алмый. Ваһһабиларның фикерләре белән артык мавыгып китмичә, әмма мәдәниятебезне үстерүдә аларның идеяләреннән файдаланып, шул ук вакытта тәнкыйтьләрен дә искә алып, Р. Фәхретдинов кебек галимнәребез халык күңелен ныклы итүдә зур эш башкарганнар.

*Октябрь, 1999*

## XIX йөз татар китабы үзенчәлекләре: эчтәлек һәм тәртипләштерү

Китапның «оформление»се дигәнне, татар теле сүзлекләрендәгечә «күренешкә кертү» тезмәсе белән күрсәтүгә караганда, «тәртип итү», ягъни «тәртипләштерү» терминын кулланып тәрҗемә бирүне дөрескә санадык. Хикмәте шунда: монда сүз эчтәлек белән бәйле төзелеш хакында бара. Берникадәр форма, рәсемләү мәсьәләләренең кузгатылуын бу термин таләп итүгә карамастан, алар белән бергә наширләрен, редакторларын, авторын, бүлекләрен, җаваплылык һәм шушындый мәсьәләләрнең куелуын да эченә ала кебек.

Китап коммуникатив яссылыкның киңәюендә һәм тирәнәюендә аерым төп рольләрнең берсен башкара. Аның барлыкка килүе һәм үсеше җәмгыятьнең мәдәни дәрәҗәсе хакында сөйли.

Татар кулъязма китапларының сакланып калган, бүгенге көнгә килеп җиткән төп күпчелеге XVIII һәм XIX гасырларга карый. XVIII йөзнең беренче яртысы, XVII йөзнең китаплары бик сирәк очрыйлар һәм хәтта юк дәрәҗәсендәләр. Бу хәл татар иҗтимагый мәдәни тормышында зур үзгәрешләр бары тик XVIII йөз

ахырыннан XIX гасыр башларында гына кузгалганнар дигән фикергә этәрә. Әмма сәбәпнең язу материалына бәйле булганлыгын да истән чыгармаска тиешбез.

Рәсәйдә кәгазь эшләп, аны сатуга чыгару пергаменга[1] язудан арына баруга гына түгел, иҗтимагый активлашуга да китергән. Кытайда беренче гасырда кәгазь ясау технологиясе уйлап табылуга карамастан, Европада XII йөздә бу эшне тәртипкә салсалар, бездә ул тагын да соңрак, XIV гасыр ахырында, XV йөз башларында гына күзәтелә.

Асылда, XVIII йөзгәчә бездә «ефәк кәгазь» дип аталучы Урта Азия һәм Төркиядән кертелгән кәгазьләр файдаланылган. Ул кәгазьләрдә «су билгеләре» юклыгы җитештерелү датасын һәм урынын ачыклауда комачаулык итә. Кәгазь эшләү технологияләренең 1840 елларгача һәр төбәктә дә бертөрле булганлыгы ясаган кәгазьләреннән күренеп тора.

Кәгазьнең Европада киң таралыш алуы XIV–XV гасырларга карый. Аны җитештерү өчен, чүпрәк аламалары күпләп кирәк булган. Бу исә тукыма эшләп чыгаруның үсешенә, җитештерелгән товарның сатуда очсызлана баруына да бәйле. Сәнәгать революциясе генә мондый шартларны тудырган.

Рәсәйдә кәгазьнең киң массага файдалану өчен җитештерелә башлавы XVII йөзгә генә карый[2]. Татарларда тукыма җитештерү фабрикалары XVIII йөздә үсеш ала. Әмма чүпрәк аламаларыннан кәгазь ясау очрамый. Шулай да бу эш белән алар да таныш булганнар дип фараз кылырга урын бар.

Кытайда җитештерелгән ялтырап торучы тыгыз шома кәгазьгә каурый белән хәреф төшерү – шактый авыр мәсьәлә, бу эштә камыш каләм дә кулай түгел. Моның өчен тимер каләмнәр ясарга кирәк. Язу эше өчен пергамен кулайрак булган. Дөрес, татарларда тире җитештерү шактый алга киткән. Юка тиреләрне дә Урта

---

[1] Галим *Д.С. Лихачев*, «пергамен» һәм «пергамент» дип ике төрле язу очраклары булуга игътибар итеп, б.э.к. II гасырда Пергам шәһәрендә бу язу материалының камилләштерелүенә бәйле килеп чыккан термин икәнен исәпкә алып, аны «пергамен» рәвешендә куллану дөресрәк була дип бара. *Карагыз:* История русской литературы X–XVII веков / под ред. Д.С. Лихачева. – М.: Просвещение, 1980. – С. 14.

[2] История русской литературы X–XVII веков / под ред. Д.С. Лихачева. – С. 14.

Азиядә «булгарый» дип атап йөрткәннәр һәм аларның Идел буйларыннан сәүдә юлы белән китерелүенә ишарә итәләр.

Пергаменны бозау тиресен юкартып кырып, пемзаны файдаланып шомартып һәм агартып ясыйлар. Әмма кәгазьнең пергаменнан өстенлекләре дә шактый. Аны китап төзүдә файдалану китапның күләмен кечерәйтүгә, язуны вагайтуга мөмкинлек биргән. Бу хәл коммуникатив яссылыкны киңәйтүгә хезмәт итми калмаган. Авырлыгы ягыннан китап шактый җиңеләйгән.

Татар китабының үзенчәлекләре башка халыкларныкыннан аерылып тормый. Шул ук форматлар кабатлана. Әсәрнең исемен еш кына китап башында күрсәтү белән чикләнелә. Авторы, әсәренең асыл аталышы һәм язылу еллары да әсәрнең колофон өлешендә бирелгәнчә калдырыла. Атрибуция эше күп көч сарыф ителүче фәнни-текстологик хезмәтне таләп итә.

Автор тарафыннан тексттан тыш күрсәтелеп калдырылган әсәренең язылу датасы да кайсыбер күчермәләрдә кабатлана. Мондый сирәк булса да очрый торган күренеш укучыда аптырау хисе дә уяткан. Китап күчерүчеләр кайбер авторларның кульязмаларына хас ул үзенчәлекне исәпкә алмый калдырган очраклар исә бездә ешрак күзәтелә.

Басма китапка күчү баштарак әсәрләрнең таралышын киңәйтү өчен генә хезмәт итә. Аның кульязма китап вариантын кабатлавы шул хакта сөйли. Китап бастыру сәнгатенең үсеше XIX йөзнең икенче яртысы өчен характерлы.

Татар китабының язма үзенчәлекләре хәрефләрнең кульязмаларда үзара тыгыз рамкаларда теземләнүеннән, аларны туры, авыштырмый язудан гыйбарәт. Бу үзенчәлек, басмага күчерү өчен, шактый уңайлыклар тудырган. Хәрефләрне туры бастырып язу типография ысулы гына түгел, татар кульязмаларына хас күренеш икәнлеген Казандагы Ш. һәм М. Яхиннар литографиясе исәпкә алып җиткермәгән һәм алар Урта Азия, бигрәк тә фарсы язмаларына тартым каллиграфик үзенчәлекләргә таянуны өстен куйганнар. Бу хәл татар кульязмасына күзе күнеккән укучыда берникадәр авырлыклар китереп чыгарган.

Хәрефләрнең «тырнакларын» язып тормау үзенчәлеге татар кульязмаларына хас түгел, фарсы йогынтысының күренеше. Хәрефнең өс һәм ас ноктaларын төшереп калдырып язу исә мәмлүк

язмаларының кагыйдәсе икәнлеге яхшы мәгълүм. Дөрес, әгәр дә тарихи документларга, хан ярлыкларына игътибар итсәк, аларда язу үзенчәлекләре шулай ук башкачарак. Хәрефләрнең койрыкларын дәвамлы итеп сузып язу яки уйнатып алу урта гасырларда рус һәм Европа патшалыкларындагы фәрманнарда, феодалларның аермалы карарларында, хәтта хатларында мәртәбәлек билгесе саналган. Төрек солтаннары да ул рәвешне дәрәҗәлек дип күргән. Кульязма татар китабы өчен андый график стиль табигый күренеш түгел. Шигъри әсәрләрнең строфасын, хәтта дүрт юлдан гыйбарәт строфасын мөмкин кадәр бер юлда бирергә тырышканнар. Әмма юллар арасында бушлык калдырып, багана-багана итеп тезеп төшерү формасын файдалану тупланмаларның чәчмәме-тезмәме булуын беренче күз салуда ук ачыклау мөмкинлеген биргән. Тыныш билгеләрен бөтенләй кулланмау автордан җөмлә төзегәндә мәгънә бирүдә зур таләпчәнлек сораган. Бу хәл әдәби телнең грамматик формаларда калыплануына зур этәргеч биргән.

Мәгънәгә хилаф иткән текстлар борынгы китаплар өчен гайре табигый күренеш диярлек. Шул ук вакытта аларда кызыл юл бөтенләй юк, әмма бүлекләргә бүлү, язма юлны өзмичә кызыл кара белән бирү яки, кызыл кара булмаганда, җәя яисә җәяләр эчендә күрсәтү басма китапларга да күчкән. Шулай да татар басма китаплары, кызыл караны эшкә җикмичә, бүлек исемнәрен, кульязмадагы кызыл кара белән язылган урыннарны җәя эчендә төп текст төсендәге буяуда бирүне тәртип иткәннәр. Җәя эчендә бүлекләрнең исемен күрсәтү хәтта бүлекләрне бер-берсеннән аерып язу формасына күчкәч тә шактый вакытлар сакланып калган. Бу, әлбәттә, татар китабының үзенчәлеге буларак бәяләнә ала. Дөрес, юлларның төзеклеге һәммә кульязмаларда да күзәтелми, басмаларда исә технология бары тик төзек юллар белән генә эш итәргә мөмкинлек бирә.

Беренче басма китапларда текстны рамкаларга алу традициясенә нигез салына. Хикмәт шунда: рамкаларга алу төп текстны хашияләр белән бутамас өчен дә кирәк, басма китапның уңайлыгын, игътибарны җәлеп итү көчен арттыра. Кульязмалардан килгән бу татар китабы үзенчәлекләре – башка мөселман төбәкләре мәдәнияте үсеше үрнәгендә туган күренеш. Басма китаплардагы текстлар калын һәм нечкә параллель сызыклар белән әйләндерелеп алыну традициясе XIX гасыр буена үзгәрешсез диярлек кала бирә. Бит

номерларын җәя эченә алып, сәхифәнең өске ягына уртага урнаштыру һәм текстны каймалаган рамкадан тышта, сәхифәнең аскы ягында киләсе бит текстының нинди сүз белән башланып китүен күрсәтү, шулай ук кульязма китаплардан күчерелгән табигый күренеш буларак, татар басма китабының форма күренеше рәвешен ала.

Әмма татар кульязма китапларында сәхифәләрнең номерларын күрсәтү бөтенләй юк диярлек. Басма китапларда бит номерын бирүнең яңалык булуын сиздерер өчен, ул саннарны җәя эченә алганнар дип хаклы рәвештә билгели алабыз. Кульязма китапларда алдагы сәхифәне башлап китүче сүзне кыеклап язып, күп очракларда аның астына сызык сызып куелган. Басма китапларда ул сүзләр сызыксыз, сәхифәдәге текст тигезлегендә бирелеп барыла. Бу хәл, әлбәттә, типография мөмкинлекләренә бәйле, хәрефләре җыелма булганда гына кулай. Литографик ысулда исә бу форма кульязмалардагыча кала. Әмма аларда бит номерлары куелу тәртипкә керә.

Бу ысуллар укучыга да, китапны төпләүчегә дә битләрне бутамау мөмкинлеген биргән. Төшеп калган яки ертылып алынган сәхифәне җиңел билгелисең. Сәхифәнең аскы өлешендә киләсе битнең тексты нинди сүз белән башланып китүне күрсәтеп бару сәбәпле, сәхифәнең номеры куелу кульязма китапны төзүчеләрдә артык эшкә саналган. Ә басмаларда яңа форма белән бергә иске форманың да файдаланылуы китапка хөрмәтне арттыра. Алга таба сәхифәләрнең сан белән күрсәтелүенә татар укучысы да күнегеп җитеп, номерлар җәя эченнән чыгарылганнар, өске яктан аска да күчерелгәннәр, киләсе бит текстының беренче сүзен бирүнең дә кирәклеге калмаган. Бу яңалык әүвәле газета-журналларда барлыкка килеп, алга таба китапларга да күчкән.

Китапның титул битендә беренче басмаларда аның исемен күрсәтү белән генә чикләнгәннәр. Гадәттә, ул урта җирдә, бернинди бизәксез, калын һәм эре шрифт белән бирелгән. Типографиясе һәм цензура рөхсәте, нашире хакында мәгълүмат соңгы биткә калдырылган. Алга таба цензура рөхсәте һәм нашире күрсәтелү алга чыгарылган. Текстларның рамкаларга алынмау очраклары да бар. Алар калын һәм йомшак кәгазьләргә басылганнар. Типографияләрдә ул китапларны бер табак кәгазьгә сыйдырып бетерергә тырышу аркасында, хәрефләр ваклана барганнар. Беренче китаплар бизәлешсез бастырылган, берничә табак бергә тегелгән,

тышлыклары да булмаган. Китап ахырында басманың хаталары күрсәтелгән, аларның төзәтмәләре бирелгән. Бу факт татар китабының корректурасын тикшерү эше булганлыгын сөйли. Ул яктан башка халыкларның типография эшеннән татар басма эше аерылып тормаган. Хәтта литографияләр дә корректура эшен шушы формада оештырган очраклар бар. Корректура нигезендә текстны басмага киткәнче үк төзәтеп эшләү газета-журналлар үсеше дәверендә тулысынча хәл ителгән дияргә була.

Беренче фәнни югарылыктагы китап 1825 елда Казан университеты нәшриятында бастырылып чыгарылган. Ул – «Шәҗәрәи-төрек» китабы. И. Хәлфин аның тәнкыйди текстын, татар һәм башкортлар арасында сакланып калган ике нөсхәсен чагыштырып, гыйльми өйрәнү рәвешендә сыйфатлы итеп төзи. Ике нөсхәнең һәрбер аермаларына конкрет игътибар ителә, ас төшермәдә, номерлап, алар күрсәтелеп барыла. Әмма монда да корректура хаталары калган, алар китап ахырында бирелгәннәр.

Хива ханы Әбул-Гази Баһадурхан, «Шәҗәрәи-төрек» китабын язып бетергәч, 1609 елларга аны унҗиде нөсхәдә күчертә һәм төрки төбәкләргә тараттыра. И. Хәлфингә шул күчермәләрнең икесе килеп ирешүендә шик юк. Соңрак та «Шәҗәрәи-төрек» берничә тапкыр басыла һәм алар «Татар-монгол тарихы» исеме белән чыгалар. Шунысы әһәмиятле: мәсәлән, Х. Фәизханов аны «татарчага тәрҗемә»сендә бастыра, әмма ул вариантның теле гарәп-фарсы сүзләре белән авторныкына караганда күбрәк чуарланган. «Шәҗәрәи-төрек»нең үз теле хәзерге татар әдәби телебезгә шактый якын тора. Тагын шуны ассызыклап китәргә кирәк: И. Хәлфин басмасы – бүгенге көндә дә үрнәк булып кала биргән фәнни югарылыктагы басма. Борынгы текстларны өйрәнүче һәм халыкка җиткерүче галимнәребез текстологик эшне әлегәчә аның дәрәҗәсендә башкарып чыга алганнары юк, Төркия галимнәрен искә алмаганда.

Казанда һәм Рәсәйнең башка төбәкләрендә татар китабын бастырып чыгаруда, татарлардан тыш, төрле милләт вәкилләре катнаша. Бу факт исә татар китабының киң иҗтимагый функциясе булуы хакында сөйли. Шунысы әһәмиятле: татар китабы, махсус белгечләр өчен әзерләнүдән бигрәк, киң катлам укучыларга аталган, Кавказга, Урта Азиягә, Төркиягә, гарәп илләренә, Һиндстанга

барып ирешкән. Дөньякүләм әһәмияте югары булуы татар мәдәни тормышын башка халыкларның якынаюына китергән.

Татар китабы XIX гасырда хәрефләренең пөхтәлеге, хаталарының азлыгы, җыелу тәртибенең төгәллеге белән сокландыра. Уку өчен уңайлы, ачык итеп төзелүләре, эчтәлеккә муафыйк бизәлеш сайлаулары игътибарны җәлеп итә. Литография ысулында басылган китаплар төсләрне уңышлы файдалана башлыйлар, караңгы яшел, сыек кара төс, куертылган кара төс, хәтта кызыл һәм зәңгәр буяулар белән эшләү тәҗрибәләре, шул юлда укучыга тәкъдим ителгән китапларның сафлыгы һәм чисталыгы бу чорда татар басма китабының югары зәвык белән башкарылуы хакында сөйли. Монда укучыларның таләпчәнлеге белән бергә, эшне башкаручыларның югары культуралы булулары да төп рольне үтәгән.

XIX йөз татар китабының эчтәлеге төрле өлкәләргә карый, әдәби әсәрләрдән тыш, дини, дини-дөньяви, медицина, мистика, этнография, тарих, фәлсәфә, география, тел, ысул-методика, ветеринария һ.б. юнәлешләргә бәйле. Дөнья әдәбиятына, рус-европа әдипләре әсәрләренә игътибар көчәя бара. Тәрҗемә эше 1860 елларга җайга салынып җитә. Моңа кадәр гарәп-фарсы әсәрләре актив тәрҗемәдә булсалар, инде рус, француз, немец, инглиз телләрендәге язмаларга мөрәҗәгать итү дә башлана. XIX йөзнең соңгы чиреге бу яктан татар китабының шактый алга барышы елларына туры килә.

Татар китабының бизәлеше XIX йөздә ике юнәлештә үсеш ала. Аның берсе үсемлек орнаменты ысулына бәйле булса, икенчесе, мөшарәбия стилен файдаланып, мозаика ысулын кулланудан гыйбарәт. Бу төр бизәлеш типографияләр өчен кулай, аннары – мөшарәбия гарәп илләрендә киң таралган, архитектура-төзелештән алып, мебель ясауда, келәмнәр тукуда бик актив кулланылган һәм, иң мөһиме, шул формадагы бизәлешләр татарның басма китапларына күчереләп, мөселман руханилары күңелендә дә һичбер төрле каршылыклы хисләр уятмаган. Иң күп бизәлештә «Мөхәммәдия» китабы басыла һәм ул мөшарәбия стилендә типографик юл белән рәсемнәр бирүдә татар китабының зур ачышы булып тора. Наширләр бу стильгә бар игътибарны юнәлтәләр. Һәммә китапларның диярлек титул битләре, унваннары мөшарәбия стилендә бизәкләнеп чыгарылу татар китабының XIX гасырда һичшиксез уникаль икәнлеген күрсәтә.

*2013*

## «Тотса мәскәүләр якаң»

*(Алтын Урда шагыйре Ходадат)*

1

Г. Тукайның шушы исемдәге шигъри фельетоны 1908 елда «Яшен» сатира журналының 1 нче (30 август) санында басылып чыга[1]. Әсәрдә Мәскәү байларыннан ссудага акча алып, шуның хисабына кыяфәттә бай булып йөреп, шул байлыкларына мактанып, театрны сүгеп, монафикъ муллалар белән дуслык корып, яшьләр өстеннән донос язучылар төркемендә, кяферләр «җәннәтендә» яшәүче хаҗи абзый, надан татар агае тибы рәвешендә сурәтләнеп, төрле яклап көлкегә алына. Әгәр дә Мәскәү байлары якаңнан алсалар, ягъни ссуда акчаларын кайтарып бирүне таләп итсәләр, ул вакытта үзеңә «зиндан» булачак дип кисәтү ясала.

Р. Гайнанов, Г. Тукай томлыкларын төзүче һәм искәрмә-аңлатмаларын эшләгән галим: «Әсәр «Бакырган китабы»ның бер шигырен үрнәк итеп язылган һәм «Яшен»дә «Бакыргандин» дип куелган», – дип, фельетонның исеме «Бакыргандин» икәнлеген дә белдерә һәм «Бакырган китабы»ннан шул шигырьнең ике строфасын укучыга танышу өчен мисалга китерә[2].

«Бакырган китабы» җыентыгында ул әсәр биш строфалы. Г. Тукайда: «Ни кылырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?» – дип башланып китә һәм һәр шигъри строфаның, ягъни бәетнең рифмасын кабатланып килүче «тотса мәскәүләр якаң» рефрены хасил итә. Шагыйрь татар гадәтенчә «мәскәүчәләп» русча гыйбарәләрне дә файдалана: «как ты будешь отвечать там», «даже в тюрму сыярсың», «нет, князь, постой» кебек кисәтү сүзләре шигырьгә табигый төстә кертелеп, үзенә бер әдәби осталык белән кулланылалар, укучы күңелендә кызыксыну, мыскыллау, ятсыну хисләрен уятуга хезмәт итәләр. Борынгы шагыйрьләр Коръән сүзләре белән, «гарәпчәләп» укучыны ничек шомландырсалар, Г. Тукай, русчалап язып, мәскәүләрнең хаҗи абзадан өстенлеген сиздерер дәрәҗәдә тасвирлау өчен, бу алымны оста файдалана.

---

[1] *Карагыз: Гайнанов Р.* Искәрмә һәм аңлатмалар // Тукай Г. Әсәрләр: биш томда. – Т. I. Шигырьләр һәм поэмалар (1901–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 379.

[2] Шунда ук. – Б. 378.

«Бакырган китабы»ндагы шигырьдә исә үлем хәвефе алга чыгарыла. Ул «Ни кылырсың, мескен адәм, тотса Газраил якаң?» дип башланып китә, биш строфасында да «Тотса Газраил якаң» шигъри юлы кабатланып, әсәрне кафияләп килә. Г. Тукай: «Как ты будешь отвечать там?» – дисә, «Бакырган китабы»нда: «Ничек җавап бирерсең?» – дигән сүзләр килә. Аерма бу сүзләрне Г. Тукайның русчалатып бирүендә генә икәнлеген күрми мөмкин түгел.

Г. Тукай фельетонындагы икенче строфаның беренче строфасы белән «Бакырган китабы»ндагы шигырьнең өченче строфасының беренче строфасы үзара туры киләләр, бер үк сүзләрдән торалар:

Г. Тукайда:

«Сыгмас ирдең киң җиһанга – малыңа мәгърур булып...»

«Бакырган китабы»нда:

«Сыгмас ирдең дөньяга –
Малыңа мәгърур улып...»

Бу фактлар Г. Тукайның чыннан да «Бакырган китабы» җыентыгындагы шигырь нигезендә *кайтарма әсәр* иҗат итүен, борынгы әсәрне, кадими шигырьне *җәдитләштерүен* раслап торалар. Калган өлешләрдәге аермалар замана сурәтләренә бәйле. «Тотса мәскәүләр якаң» фельетонында Г. Тукай үз иҗат манерасына тугры кала, борынгы әдәби әсәр мотивларына таянып, яңа әсәр иҗат итә. Бу аның әдәби иҗат өслүбе-методы да. Г. Тукай шушы ягы белән үз чоры әдипләреннән кискен аерылып торды, шушы ягы белән җәдитче-новатор, алгарыш шагыйре булуын күрсәтте. Ул чын мәгънәсендә җәдитче, ягъни модернист әдип иде.

«Бакырган китабы»ндагы «Тотса Газраил якаң» газәле (исемен шартлы рәвештә куйдык) җыентыкта 88 әсәр буларак урын алган һәм аның авторы Ходадат дип күрсәтелгән. Бу хакта Ходадат үзе болай дип белдерә:

«И Ходадат, Тәңредин
Куркып һәмишә[1] тәүбә кыл,

Асыг имәс[2] тәүбә соңра,
Тотса Газраил якаң!»

---

[1] *Һәмишә* – даими, һаман да.
[2] *Асыг имәс* – файда итмәс, җиңелгә булмас.

«Бакырган китабы»нда Ходадатның барысы биш шигъри әсәре урнаштырылган, шартлы рәвештә алар 85–89 нчы номерлар астында соңгы басмада аерымланганнар[1].

2

Ходадатның «Бакырган китабы»ндагы газәлләре Аллаһ гыйшкына багышланганнар һәм шагыйрьнең эчке рухи халәтен, хискичерешләрен чагылдыралар. Ә Аллаһы Тәгаләгә аталган шигъри әсәрләр газәл дип, Мөхәммәд пәйгамбәребезгә адресланганнары исә касыйдә буларак йөртелүләре һичкемгә сер түгелдер?

Биш шигъри әсәреннән беренчесен (китапта ул 85 нче номер белән бирелгән) «Ничек сине тапгаймына?» исеме белән аерымларга мөмкин. Шушы мөрәҗәгать сүзләре аның алты строфасында да кабатланып киләләр. Әсәр Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» үлчәмечә язылган, беренче өч шигъри юллары үзара рифмалашканнар, соңгы строфика аларны буеннан-буена кафияли, шул сәбәпле ул күләмле, дастани әсәрдән өзек буларак та аңлашыла. Әмма алтынчы строфада шагыйрьнең үз исемен атавы әсәрнең традицион рәвештә тәмамлануын, бербөтен икәнлеген ачык күрсәтә. Шушы строфада шагыйрь үз сүзләренә эшләре туры килмәүгә, лаеклы ураза һәм намазы юклыкка, соңгы юлга чыгар өчен Ходай каршына килерлек файдалы эше булмауга зарлана. Билгеле, моны суфичыл әдәп буларак кабул итми мөмкин түгел. Әмма әсәренең гомуми рухы, эчке мантыйгы бу тойгы-хисләрен уяткан сәбәпләрнең чыннан да бар һәм тирәндәрәк икәнлеген дә сиземләүгә этәрә.

Ходадат Аллаһыдан аерылуына көне-төне хәйран итүен, шуның аркасында бәгыре көюен тасвирлаудан сүзен башлап китә, күзләреннән кайгылы күз яшьләре акканлыгын яза. Үзе югыйсә диндарлар кебек мәчеттә намаз да укый, муллалар сыман Китап та ача, суфилар рәвешендә җанын да фида кыла икән, әмма Аллаһы Тәгаләне таба алмый. Монда «йа Илаһым!» дигәнендә, сер түгел, әлбәттә, хаклыкны, хакыйкатьне эзләве хакында сүз барганлыгын да аңлавы авыр түгел.

---

[1] Бакырган китабы: XIII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре / текстларны әзерләүче, искәрмәләр язучы *Фәрит Яхин*. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – Б. 105–107.

Суфилар хакыйкатьне эзләүне, табуны, хаклыкка ирешүне Аллаһы Тәгаләгә «кавышу» буларак аңлаганнар. Шәригатьтән тарикатькә, тарикатьтән мәгърифәткә, мәгърифәттән хакыйкатькә күтәрелү мантыйгына буйсынып яшәгәннәр. Алар өчен шәригать ул – үзләренә кадәрге ачылган, билгеле булган хакыйкатьләр, кануннар; тарикать исә – хакыйкатькә ирешүдә үз юлыңны, танып белү методыңны табу. Шуннан соң гына, тарикать аша гына син белемле, мәгърифәтле була аласың. Әмма хакыйкать ул инде ирешелгән танып белү, белем дәрәҗәсе, мәгърифәт кенә түгел, ул – дөреслекне, хаклыкны аңлау, төшенү, тою мәртәбәсенә ирешү. Алар шушы юл белән генә Хакны – Аллаһыны «табып булганлыгын» белгәннәр.

Ходадатны да хакыйкать кызыксындыра, ул аңа омтыла, әмма таба алмавына зарланырга мәҗбүр. Кемне очратса да, аны Хозыр пәйгамбәргә санап, аңардан дога үтенергә дә, Аллаһыга кол булучылардан мәгънә сорарга да, аларга мөритлек итәргә дә, хаҗга барып, Кәгъбә туфрагын күзләренә сөрмә кылырга да әзер. Сугышчы ирләрдән ярдәм үтенеп, базарларда картларның-яшьләрнең кулын тотып, изге догачалардан гозерләнеп: «Йа Илаһым, ничек сине тапгаймына?» – ди.

Ходадат бу шигъри юлларда үзенең диндарлар дәрәҗәсенә ирешергә теләге барлыгын, әмма ул бәхеттән ерак торуын олы хәсрәте буларак сөйли. Әмма ни өчен болар бары тик аның теләге генә, ни өчен ул үзен шушыларны үтәүче итеп тасвирламый – болар әсәрендә җавапсыз калдырыла. Дөрес, татар теленең көнбатыш диалектына хас «үтәй», «ачай», «кылай», «барай», «сорай» кебек сүзләрне куллануы Ходадатның изге гамәлләрне башкарганы кебек тә сыман хис уяталар, әмма әсәренең беренче һәм соңгы строфаларындагы вакыйгаларны тасвирлау рәвешләре ул эшләре әлегә теләктә генә калуын тоярга мөмкинлек бирә. Мондый алымда язу шигъри әсәрне, әлбәттә, киң планлы, тирән эчтәлекле итүдә аерым тәэсирле роль башкара, лирик геройның шушы хис-кичерешләрендә объектив сәбәпләр булырга тиешлеген дә сиздертә.

Алга таба 86 әсәр буларак шул ук формадагы тагын бер шигъри әсәр килә. Ул биш строфадан гыйбарәт. Монда шулай ук дүртенче шигъри юллар кабатланып баралар. Әсәрнең исемен дә шушы кабатланучы «Синдин үзгә максудым юк» сүзләренә нисбәтле рәвештә атарга мөмкин.

Монысында шагыйрь мөселманнарның иртән намаз укуларын, гашыйкларның үз сөйгәннәрен кочуларын, һәр бәндәнең шәхси теләге барлыгын яза. Ә минем, Илаһым, синнән башка «максудым юк» дип белдерә.

Икенче строфада Нух пәйгамбәр гомере, Карун байныкыча байлыклар, ике җиһанның милке «булса миңа», ди, «синдин үзгә максудым юк, йа Илаһым», ди. Өченче строфада җәннәтне үзенә теләве сурәтләнелә. Дүртенче строфада егет чагы томаналыкта үтүен, картлыкның гаҗизләвен һәм түбәнлеккә төшерелүдән зар елавын сөйли, соңгы строфада ахыргы сулышы Аллаһ исеме белән булуын теләвен әйтә.

Ходадатның бу әсәре дә суфичыл эчтәлеккә корылган һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләреннән эчтәлектә башка юнәлеш алуы белән аерылып тормый кебек. Әмма бу беренче карашка гына шулай. Касыйдәдән аңлашылганча, Ходадат инде, беренчедән, картлык яшенә ирешкән, икенчедән, үз дәрәҗәсеннән, иҗтимагый мәртәбәсеннән төшерелгән, өченчедән, җәннәткә кертелүенә өмет итсә дә, үзенә Нух пәйгамбәр гомере, Карун байлыклары, ике җиһанның милке бирелсә дә, барыбер максаты Аллаһыга ирешү икәнлеген ачык белдерә. Дөньялыкта аның фәкыйрьләр юлында йөрмәгәнлеге дә аңлашыла. Әлбәттә, лирик герой белән авторны тәмам тәңгәл кую әсәрне аңлау-аңлату өчен дөрес алым түгел. Әмма шагыйрь, лирик героен сурәтләгәндә дә, үз хис-тойгыларына, рухи омтылышларына нигезләнеп иҗат итә, әсәре шунлыктан аның рухының көзгесе булмый калмый. Язмаларының уникальлеген шигъри иҗат материалында шул рухының кабатланмас үзенчәлекләре чагылышы тудыра. Ходадатның да, шәхес буларак, үз рухи дөньясы әсәрләрендә урын тапмый калмаган. Ә кешенең җаны тышкы факторларга һәрвакыт бәйлелектә була.

Җыентыкта бирелгән алдагы әсәрен «Ни кылай?» исеме белән атау урынлы булыр. Касыйдә формасында язылган, биш строфадан тора. Әмма аны да газәл жанрына карый дип билгели алабыз. Монда Ходадат үзен, исеме белән атап: «Мәнҗәбе җаһ җиһандин, Ходадат, тотыбән, гыйззәтне таләп мин харь булдым», – дип белдерә, ягъни: «Җиһанда, Ходадат, олы дәрәҗә тотып, хөрмәтне таләп итеп хур булдым», – ди. Шушы бишенче строфадан алдагы дүрт бәетендә ул йөз төрле гамәлләр башкаруын, Аллаһының «җамалын күрмәк өчен» тырышуларын яза.

Бу шигъри төркемгә кертелгән соңгы бишенче әсәре дә, биш строфалы газәл, ул да нечкә лирик хисләрне сурәтләүгә корылган, суфичыл эчтәлеккә ия. Ходадатның бу шигъри әсәре дә аның чын мәгънәсендә бөек шагыйрьләрдән берсе булуы хакында сөйли.

Әмма аның кемлеге, кайчан, кайда яшәгәнлеге әдәбият тарихы фәнендә ачылмыйча калдырылган. Хәтта, әйтер идек, бу юлда бер генә омтылыш та булмаган. Югыйсә аның әсәрләрен татар укучысы электән укыган. Г. Тукай кебек бөек шагыйрь, аның иҗатына таянган хәлдә, кайтармалы җәдиди иҗат методын файдаланып, телләргә күчкән шигъри фельетон тудырган. Мәсьәләнең актуальлеген аңлау өчен, болар үзләре дә җитәрлек этәргеч бирәләр булыр.

3

Фәнни тикшеренү-эзләнүләр безгә Ходадатның шагыйрь буларак кына түгел, яугир сыйфатында да тарихка кереп калган шәхес икәнлеген ачарга ярдәм иттеләр. Аның исемен рус, поляк, Шәрык елъязмачылары телгә алганнар. Дөрес, Ходадатны рус һәм поляк елъязмаларында «Кудадат» дип атыйлар. Аның Алтын Урда тәхете өчен Олуг-Мөхәммәд хан белән сугышу вакыйгаларында да актив катнашып алганлыгы билгеле икән.

1421–1425 еллар арасында алты хан Алтын Урда тәхетенә утыру өчен тартыша. Бу хакта Ян Витовт, Польша һәм Литва короле, Ливония ордены магистрына 1426 елның 1 гыйнварында язган хатында хәбәр итә[1]. Шуларның берсе – Бәрке хан (аны тарихка багышланган кайбер китапларда Бату хан, Сартак ханнардан соң тәхеткә утырган, Бату ханның энесе Бәркә хан белән бутап язгалыйлар) – мәмлүкләр Мисыры илчеләрен дә Алтын Урда ханы буларак кабул иткән, ике арадагы бәйләнешләрне ныгытырга тырышкан, Нугай Урдасы җирләрендә хан булуына карамастан, башка урдаларны да үзенә буйсындырырга омтылган шәхесләрнең берсе. Ул 1422 елның 21 августында Иделнең уң ягына һөҗүм белән чыга, шактый биләмәләр яулый. Мондагы җирләр Ходадат хан кулында була, Себердә исә Хаҗи-Мөхәммәд хан булып утыра. Олуг-Мөхәммәд хан Алтын Урда тәхетен үзенеке итеп расларга омтыла.

[1] *Карагыз: Сафаргалиев М.Г.* Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций...: Из опыта образования и распада империй X–XVI вв. – М.: ИНСАН, 1996. – С. 450.

Алар арасында иң уңышлы хәрәкәт итүче Бәрке (яки Бәрәк) хан гаскәрләре 1422 елның август ае ахырында Ходадат хан гаскәрләре белән йөзгә-йөз очрашалар. Каты бәрелеш була. 31 августта соңгы тапкыр сугышалар, һәм Ходадат хан гаскәрләре җиңелә[1].

Бәрке хан үзе Алтын Урда ханы Коерчакның улы булганга, төп тәхетне мирас нигезендә, әлбәттә, үзенеке булырга тиеш дип саналган. Ходадат та нәселенең башы Җүҗи һәм Бату ханнардан икәнлеген белгән. Әмма бу чорда Дәште-Кыпчакның ханы асылда Олуг-Мөхәммәд саналган. Аны Польша короле дә олуг хан буларак таныган. Акчалар Әстерханда, Сарайда, Болгарда аның исеме белән бастырылганнар.

1424 елда аның гаскәрләре Ходадат хан гаскәрләренә каршы сугыша. Әмма Олуг-Мөхәммәд хан җиңелә һәм Польшага качарга мәҗбүр була[2]. Димәк, 1422 елның 31 августында Ходадатның Бәрке ханнан җиңелүе вакытлы күренеш булган. Шул сугыштан соң Бәрке хан үз гаскәрләрен Олуг-Мөхәммәд белән сугышка алып барган.

Бу вакыйгаларны дөрес күз алдына китергәндә шулар аңлашыла: Бәрке хан, Иделне гаскәре белән кичеп, Көнбатышка таба яу чапкан һәм Ходадат хан, үз җирләрен саклау өчен, аңа каршы сугышырга мәҗбүр булган. Үзен олуг хан сыйфатында таныган Олуг-Мөхәммәд хан да гаскәрләрен күтәргән.

1423 елда Бәрке хан гаскәрләре рус җирләренә барып керәләр. Ука елгасы буендагы Одоев шәһәренә якынлашалар. Князь Юрий Романович Одоевский һәм воевода Мценский Григорий Иротасьевич, аңа каршы гаскәр күтәреп, бәрелештә өстен чыгуга ирешәләр. Шуннан соң Бәрке хан, күп югалтуларга дучар булып җиңелү сәбәпле, үз ханлыгы чигенә, Иделнең сул ягына чыгып китә. Алтын Урдага сугыш белән башка килми. Олуг-Мөхәммәд, Алтын Урда ханы буларак, илендә тәртип урнаштыруга алына һәм Ходадатны ханлыкка омтылу нияте барлыгын уйлап буйсындырырга ниятли.

Монгол-татарлар, билгеле булганча, яулап алынган илләренә тамга системасы кертәләр. «Урда» дигән сүз «йорт», «өй» төшенчәләрендә дә, шул ук вакытта «ил», «ил-йорт» мәгънәсенә дә ия булып киткән. Әмма, асылда, ул «тамга» дигән сүз. Хәзерге телебездә

[1] *Сафаргалиев М.Г.* Распад Золотой Орды. – С. 449.

[2] Шунда ук. – Б. 450.

без аны «орды» дибез. «Тамга салды», «мөһер орды» дигән сүзләр шул заманнардан калган.

Тамга системасы нигезендә, Алтын Урдада йортлар, ихаталар сары төскә буялган булган, Күк Урдада исә – зәңгәр һәм яшел төсләргә. Шунысы кызыклы: зәңгәр һәм яшел төсләр күк төсе буларак кабул ителгәннәр. Шулай ук Ак Урда иле булган. Бүгенге көннәрдә дә татарларда үз төсләрен саклау хисе яшәп килә. Көнбатыш татарлары йорт-җирләрен, ихаталарын сары буяулар белән буяп куялар. Казан татарлары, ягъни Идел-Урал арасындагы татарлар яшел һәм зәңгәр төсләргә өстенлек бирәләр. Бу хакыйкатькә игътибар итми мөмкин түгел һәм аның нигезендә тарихи аң, хис-тойгылар ята дип белдерергә мәҗбүрбез. Күченеп, берсе икенчесенең арасына килгәннәрендә дә, алар үз төсләрен саклап калдырганнар. Себердә сары буяулы йортлар-ихаталар очрый икән (хәтта авыллары-авыллары белән), аларның мишәрләрдән булуларын абайларга, телләрендә дә мишәрчәлекнең саклануын күрергә мөмкин.

Ходадат ханга килгәндә, ул, гаскәрләре белән Одоевский җирләренә үтеп, русларны җиңүгә ирешә, хәтта Польшага якынлаша һәм чик буенда 8 көн тора. Әмма ахырда поляк һәм рус гаскәрләреннән җиңелә. «Худайдат после порожения в 1424 г. Исчез с политического горизонта», – дип яза М.Г. Сәфәргалиев аның хакында[1]. Алга таба тагын да мондый нәтиҗә чыгара тарихчы: «Войска Худайдата и Барака были разгромлены военными силами русских и литовских князей»[2].

Бу тарихи вакыйгаларда Ходадат ханның сәяси-хәрби эшчәнлеге, көнбатыш татарларының аның яклы булулары, әлбәттә, шул чордагы татар халкында кайнаган иҗтимагый хис-тойгыларга бәйле булган, болар, ахырда, Касыйм ханлыгын оештыруга этәргеч ролен башкарганнар. «Бакырган китабы»на әсәрләре кертелгән суфи шагыйрь Ходадат һәм яугир хан Ходадат (Ходайдат) арасында уртаклыклар юк кебек тоелырга мөмкин. Ә менә Алтын Урда ханнарында хорафилык, язмышка-тәкъдиргә өстенлек бирү хисе көчле булганлыгын исәптә тотсак, бу шигебезнең урынсыз икәнлеге дә ачылыр.

[1] *Сафаргалиев М.Г.* Распад Золотой Орды. – С. 451.

[2] Шунда ук.

Ходадатның кайда, кайчан тууы, тормышының башка яклары әлегә безгә мәгълүм түгел. Әмма аның XV гасырның беренче яртысында яшәгән татар шагыйре, яугир, хан булуы фактлары әдәбият тарихыбызның әһәмиятле һәм кызыклы сәхифәләреннән берсе булып тора.

## Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы нигезләре

2002 елда «Мәгариф» китап нәшриятында күренекле галим-фольклорчы Фатих Ибраһимович Урманченың «Татар халык иҗаты» дип аталган монографик хезмәте басылып чыкты[1]. Анда татар фольклористикасында беренче тапкыр буларак дип әйтергә мөмкин, татар халык авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү тарихы тәфсилле итеп яктыртыла, татар фольклоры төрләр һәм жанрлар буенча системага салына, катлаулы мәсьәләләре аерып алып күрсәтелә. Билгеле, моңа кадәр 1967 елда галим-фольклорчы Хәмит Ярми «Татар халкының поэтик иҗаты» исемле күләмле генә монографиясен бастырып чыгарган иде[2]. Анда татар фольклористикасы фәне үсешенә берникадәр йомгак та ясалды. Ә менә Ф.И. Урманченың хезмәте белән яхшылап танышу татар фольклорын җыю һәм өйрәнү юнәлешендә XX гасыр татар фольклористикасы үсешенә бәя бирү, аңарга йомгак ясау һәм алдагы үсеш перспективаларын күрсәтү өчен дә язылган дигән фикер уята. Бу монографиянең 6–29 нчы битләрендә «Татар халык иҗатын өйрәнү тарихы» кыскача гына яктыртыла. Монда татар милли фольклористикасы формалашу турында да кызыклы фикерләр әйтелә[3]. Төп игътибар XIX гасырда татар халык иҗатын өйрәнүгә юнәлтелә. Ул: «XIX йөз – Россия тарихында, шул исәптән татар халкы тарихында да катлаулы һәм каршылыклы чорларның берсе. Безнең өчен бу очракта иң мөһиме – гуманитар фәннәрнең бер тармагы булган татар фольклористикасының барлыкка килүе һәм

[1] *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2002. – 335 б.

[2] *Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – 308 б.

[3] *Карагыз: Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. – Б. 18–21.

формалашуы»[1], – дип билгеләп тә үтә. Мисал буларак, К. Фукс, К. Насыйри, В.В. Радлов, Г.Н. Потанин һәм Н.Ф. Катанов, С.Г. Рыбаков кебек галимнәрнең бу юнәлештә керткән өлешләренә фәнни югарылыкта бәяләмәләр бирелә, аларның галим буларак эшчәнлекләре яктыртылып узыла[2]. Шулай итеп, бу хезмәттән XIX йөздә татар фольклористикасы нинди булганлыгы безнең күз алдыбызга килеп баса. Әмма мәсьәләнең барлык яклары да ачылып беткәнме дигән урынлы сорау да туа. Дөрес, Ф.И. Урманче бу хезмәтендә андый, без искәрткән максатны куеп эш итми, чөнки аның ул монографиясе асылда югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек сыйфатында язылган. Димәк, «XIX йөздә татар халкы иҗатын өйрәнү юнәлешләре» дигән тема әлегә фольклористика фәнендә көн тәртибенә куелган һәм тикшерелгән мәсьәләләрдән санала алмый. Әмма татар халык авыз иҗатын өйрәнү барышы безне һаман да татар фольклористикасының «чишмә башына» әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә.

Татар фольклористикасы үсешенә зур хезмәт куйган дистәләрчә галимнәребезнең исемнәрен һәм хезмәтләрен санап китә алабыз. Әмма ул безнең максатыбызга керми. Язмабызның дәвер чикләрен XIX гасыр кысаларыннан ары җәелдермәскә, өйрәнелгәнне кабатламаска булдык.

Билгеле булганча, 1878 елда Казан университеты каршында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» төзелә[3]. Анда А. Соловьев, И.Ф. Готвальд, Н.Ф. Катанов, К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Г. Ильяси, Ш. Әхмәров һәм башка галимнәр зур эшчәнлек күрсәтәләр[4]. Бу җәмгыятьнең төп максатларыннан берсе буларак, татар халык иҗатын барлау, җыйнау һәм тикшерү эше тора. Алар аны этнография гыйлеме белән бәйләнештә алып барганнар, халыкның аңын, дөньяга карашын аңларга-аңлатырга һәм фольклоры аша бәяләргә омтылганнар. Бу юнәлештә фәнни системалар барлыкка китереп, татар рухи дөньясын гыйльми югарылыкта тикшерүдә һәм бәяләүдә аерым уңышларга да ирешкәннәр. Бу мәсьәләләр бүгенге көнебездә дә әһәмиятле булып кала бирәләр.

---

[1] *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. – Б. 19.

[2] Шунда ук. – Б. 19–20.

[3] *Гайнуллин М.Х.* Татарская литература XIX века. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С. 34.

[4] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 2. – Б. 556.

Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең эшчәнлеге турында тулы, махсус бер монографик хезмәт юк, бигрәк тә аның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеге бөтенләй диярлек яктыртылмаган. Дөрес, аерым галимнәребезнең хезмәтләрендә бу хакта берникадәр мәгълүматларны табарга мөмкинбез, әмма алар да, мәсьәләне үзәккә алып, киң планда гыйльми тикшеренүләр уздырмаганнар.

XIX гасырда татар фольклористикасы гыйлемен XVIII йөз Европа мәгърифәтчеләре куйган нигездә өйрәнүче һәм үстерүче төп галимнәребездән берсе Каюм Насыйри булды[1]. Аның эшчәнлеге татар фольклористика фәнендә XX йөз башыннан бирле өйрәнелеп һәм бәяләнелеп килде, әмма төп хезмәтләрнең берсен галим Хуҗиәхмәт Мәхмүтов башкарды. Ул «Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы» мәкаләсе белән К. Насыйриның татар халык иҗатын җыеп эшкәртүенә бәйле аерым томлык бастырып чыгарды[2]. Болар барысы да безнең фәнни эзләнүләребезнең нигезләрен тәшкил иттеләр.

Билгеләп узганыбызча, бүгенге татар фольклористика гыйлеме шактый югары үсешкә ия, һаман да халык авыз иҗатын өйрәнү, барлау һәм туплау эше белән бергә, ул ядкярләрне фәнни нигездә анализлау һәм системага салу да дәвам итә. Татар фольклористикасы тарихын галимнәр хаклы рәвештә Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегеннән башлап китәләр. Аңа да багышланган шул ук галим Х. Мәхмүтовның аерым хезмәте дә бар[3].

Халкыбызның иҗаты бик борынгы заманнардан бирле яшәп һәм үстерелеп киленгән, ашуг, акын, чәчән кебек импровизаторлар, әкиятче бабайлар һәм әбиләр аларны бүгенге көннәргә кадәр китереп җиткергәннәр. Халык авыз иҗаты халыкның ышанулары, дине һәм дөньяга карашы үзгәрү белән бергә берникадәр трансформацияләнгән, әмма аның нигезе шул килеш кала килгән. Кайбер

---

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйри эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). – Казан: Татгосиздат, 1948. – Б. 97–106.

[2] *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Т. III / төз., гарәп графикасындагы аерым текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авт. *Хуҗиәхмәт Мәхмүтов*. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 384 б.

[3] *Мәхмүтов Х.Ш.* Мәңгелек ядкәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002 . – 127 б.

борынгырак фольклор иҗаты жанрлары кулланылыштан төшеп калганнар, әмма алар бүгенге көнгә кадәр сакланып калынган күп кенә әдәби һәм язма истәлекләрнең протографлары буларак хезмәт иткәннәр. Алар безнең үткәнебезне, бүгенгебезне һәм дә киләчәгебезне дөрес күзаллауга, хәтеребезне яңартуга, фикер офыкларыбызны киңәйтүгә, холкыбызны аңларга һәм бу дөньяда нәрсә өчен, нигә яшибез дигән сорауларга ачык кына җавап бирергә, шушы сорауларга җавапларны төшенергә турыдан-туры ярдәм итәләр. Шунлыктан бүгенге көндә дә халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм аларны саклау, өйрәнү, фән өчен генә түгел, гомумән дә җәмгыятебез өчен бәяләп бетергесез иҗтимагый-тарихи әһәмияткә ия.

Тагын да шунысы бар: төрки халыкларның ышанулары буенча, әгәр дә халык иҗат иткән дастанны, бәетне һәм гомумән дә һәртөрле әсәрне кыскартсаң – гомерең дә кыскара, имеш. Фольклор әсәрләренең борынгыдан сакланып килүендә бу ырымның да роле булгандыр, мөгаен?

Татар фольклористикасы катлаулы үсеш юлы кичергән. Ул XIX йөзнең икенче яртысына кадәр Шәрык мәдәниятенә хас фәнни классификацияләү кысаларында яшәгән, аерым алганда сүзлекләр һәм шәрех китапларында фольклористикага кагылышлы шактый кызыклы мәгълүматлар бар. Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи-Газизә» китабында да фольклористика гыйлеменә бәйле материалларны таба алабыз[1]. Аларны без аерым өйрәнү объекты дип саныйбыз.

XIX гасырның икенче яртысыннан татар фольклоры европачалык позицияләреннән торып өйрәнелә башлый. Фольклористика фәне ул чорда үз гыйльми тикшерену системаларын булдыра һәм шул юнәлешне үстерү юлына баса. Әмма бу процессның үз каршылыклы якларын исәпкә алмыйча мөмкин түгел. Фольклористика гыйлеме әле XIX гасырда да этнография фәне кысаларында берникадәр кала бирә, ягъни ул этнография фәненең бер өлеше буларак билгеләнә килә. Моның шулай булганлыгын Казан университеты

[1] *Карагыз: Ялчыгол Т.* Рисаләи-Газизә / әсәрне басмага әзерләүче (гарәп графикасындагы текстларны укып, басмалар арасындагы аермалыкларны күрсәтеп, гамәлдәге язуга күчерүче, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләрне һәм юлларны тәрҗемә итүче, тиешле шәрехләр бирүче) һәм кереш мәкалә авторы Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Иман, 2001. – 480 б.

каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» бастырып чыгарган гыйльми язмалар да раслап торалар.

Фольклористика гыйлеме белән география җәмгыятьләре дә кызыксынганнар. Алар аны география гыйлеме белән бәйләп караганнар. Мисалга Санкт-Петербург университеты каршындагы География җәмгыятенең XIX йөзнең беренче яртысыннан ук җәелдергән эшчәнлеген һәм бастырып чыгарган гыйльми хезмәтләрен китерергә булыр иде.

Фольклор гыйлеме дин белгечләрендә дә кызыксыну тудырган. Алар халык әкиятләре, риваятьләре ярдәмендә дөньяны милли күзаллау үзенчәлекләрен, дини йола һәм гадәтләрне өйрәнгәннәр һәм өйрәткәннәр. Асылда рус елъязмачыларын да моңа мисал буларак китерә алыр идек. Безнең татар галимнәре арасында, Т. Ялчыгол кебек үк, бу өлкәдә Гали Чокрый шактый зур эшчәнлек алып барганлыгын әйтеп китәргә мөмкин[1].

Халык иҗатын өйрәнү һәм халык иҗаты әсәрләре тәэсирендә әдәби иҗат белән язучылар һәм шагыйрьләрнең шөгыльләнүен дә искәртеп үтәргә тиешбез. Ул алар өчен бетмәс-төкәнмәс рухи чыганак булып тора. Һәр дәвердәге әдипләр дә халык иҗатына азмыкүпме мөрәҗәгать иткәннәр һәм аның үрнәкләрен үз иҗатларында файдаланганнар.

## 1

К. Насыйриның фәнни эшчәнлеге 1855 елдан башланып китә. Бу елда аны «Духовное училищега татар теле укытучысы итеп чакыралар»[2]. Алдында торган төп бурычларның берсе буларак, ул татар телен укучыларына мөмкин кадәр яхшырак өйрәтү тиешлеген аңлап эш иткән. Аңа кадәр дә татар теле төрле уку йортларында укытылган, Казан университетында да татар теле предмет рәвешендә өйрәнелгән. К. Насыйри аларда булган тәҗрибәләрне үзләштерми калмагандыр? Аның Казан университетына ирекле тыңлаучы сыйфатында йөрүе дә[3] шуның белән бәйләнгән булырга тиеш. Рус телен өйрәнә башлавы да татар телен өйрәтү практика-

---

[1] *Карагыз: Чокрый Г.* Дастан хаҗнамә / әсәрне басмага әзерләүче Мәсгут Гайнетдин. – Казан: Иман, 2002. – 112 б.

[2] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 2. – Б. 259.

[3] Шунда ук.

сын көчәйтү өчен файдаланылган дия алабыз. Шунысы әһәмиятле һәм безнең өчен кызыклы: К. Насыйри «китап теле»н түгел, бәлки татар җанлы сөйләм телен өйрәнүгә зур игътибар бирә. Бу аның шушы чорда тел гыйлеменә бәйле хезмәтләреннән дә аңлашылып тора. Дөрес, ул «китап теле»н, ягъни иске татар әдәби телен – төрки телне инкяр итмәгән, әмма җанлы сөйләм теле һәм аның милли элементлары аны күбрәк кызыксындырган. Ә җанлы сөйләм теле исә чын мәгънәдә халык авыз иҗатының төп нигезен тәшкил итә.

Шушы чорда К. Насыйриның фәнни карашлары барлыкка киләләр һәм формалашып үсеш ала баралар. Ул Шәрык филология гыйлеме кысаларында һәм өйрәтмәләре нигезендә фикер йөртүдән берникадәр ерагая, Европа мәгърифәтче галимнәре тарафыннан барлыкка китерелгән һәм үстерелгән европача методларга һәм методологияләргә күчеш этабын кыю уза. Шушы вакыттан башлап халык сөйләмен өйрәнү максатларында халык иҗаты әсәрләре, фольклористика гыйлеме белән кызыксынып китүе ачык сизеләнеп тора. Безнең белүебезчә, К. Насыйри – татар гыйлем дөньясында этнография фәнен яңача нигезләп, үстереп җибәргән галим дә. Әлбәттә, аның ул хезмәтләре XVIII һәм аңа кадәрге булган татар сәяхәтче галимнәренең этнографик күзәтүләреннән фәнни гомумиләштерү югарылыгы белән, мәсьәләгә әтрафлы аңлатма бирергә омтылыш ягыннан аерылып торалар. К. Насыйри фольклор гыйлеменә этнография фәненең бер тармагы буларак карый гына түгел, ул аны аерым фәнни өлкә рәвешендә аерып чыгару дәрәҗәсенә кадәр җитлеккән галим дә. Моның дәлиле буларак, фән кешеләре «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимешләре») хезмәтен атыйлар[1]. Бу чыннан да шулай. «Фәвакиһел-җөләса» хезмәте К. Насыйриның фикерләве, дөньяга карашы, әдәбиятны аңлавы чын мәгънәсендә фольклорчы галимнәргә хас икәнлеген бөтен тулылыгы белән диярлек күрсәтеп тора. Шушы хезмәтендә ул хәтта, аерым алганда, дини мәсьәләләрдә дә киң белемле, халык рухын һәм әдәп-әхлак кануннарын яхшы тоеп эш итүче галим сыйфатында чыгыш ясый. Моңа исә «Мәҗмәгыль-әхбар» («Хәбәрләр җыентыгы») китабы белән 1859 елда юл сала.

[1] *Карагыз: Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 100–101.

К. Насыйриның һәр мәсьәләдә халыкчан әдип һәм галим төсен алуының төп сәбәбе, әлбәттә, фольклорчы булуына барып тоташа. Ул безнең әдәбиятыбызны нәкъ менә шуның белән бәйле рәвештә, ягъни халыкчанлыгы аркасында, мөмкин кадәр гавам рухына таба, халыкка, аның тормыш-көнкүреше мәсьәләләрен яктыртуына йөз белән бора алды. Әмма үзе, әсәрләреннән күренгәнчә, һаман да урта гасырлардан килгән язма әдәбиятка хас кыйсса һәм хикәят кысаларыннан котылып җитмәде. Бу яктан ул берникадәр каршылыклы да булды. Хәер, Европада Яңарышны башлаган әдипләрдән итальян гуманисты Җиованни Боккаччио (Giovanni Boccaccio, 1313–1375) // Джованни Бокаччо нәкъ шундый әдипләрдән түгел идемени? Аның да данлыклы әсәрләре, мәсәлән «Декамерон»ын гына алыгыз, урта гасыр әдәбиятларыннан килгән мотивларга һәм сюжетларга корылган. Язучы аларны шулай итеп үзгәртеп эшләгән ки, ул новеллалар гуманистик идеалларга хезмәт итә башлаганнар[1]. Тагын да шунысы бар: XX гасыр ахырында безнең татар галимнәре XIII йөздән башланган Европага хас Яңарыш хәрәкәте үзенчәлекләрен, механик рәвештә аңлап һәм кабул итеп әлбәттә, татар әдәбиятының К. Насыйри һәм Г. Искакый чорларына күчереп куйдылар. Тарихи үсеш мотивларындагы охшашлык ул тарихның кабатлануы кебек тоела гына икәнлеген исәпкә дә алмадылар. Татар җәдиди хәрәкәте белән Европа Яңарышы охшаш кебекләр, икесе мәгънәдәш тә сыманнар. Тик татар җәдитчелеге ул – модернистик хәрәкәт, модернизм, европача модернизмның бер күренеше. Моны кайбер галимнәребез әле шушы XXI гасыр башында да аңлый алмыйча аптырыйлар.

К. Насыйрига килгәндә, инде билгеләп үткәнебезчә, татар халык иҗаты белән кызыксынуы аның татар телен фәнни нигездә өйрәтү өчен гыйльми эзләнүләргә тотынуы белән дә бәйле иде. Духовное училищеда укытканда, ул татар теленең язма һәм сөйләм кагыйдәләренең үз чорына хас фәнни казанышлары һәм таләпләре югарылыгында эшләнелмәгән булуына игътибар итә. Аның физика, биология фәннәре белән кызыксынуы да иң беренче чиратта мөгаен дә шушыларга бәйле булгандыр? Чөнки татар телендә сүзләрнең

---

[1] *Карагыз: Алексеев М.П., Жирмунский В.М., Мокульский С.С., Смирнова А.А.* История зарубежной литературы = Средние века и Возрождение: учебн. пос. для филол. спец. ун-тов и пед. ин-тов. – 3-е изд. – М.: Высш. шк., 1978. – С. 228–247.

дөрес яңгырашын тәэмин итү өчен фонетика гыйлемен яхшы белергә, шул фәнни өлкә таләпләрендә авазлар системасын һәм үзенчәлекләрен тикшереп чыгарга кирәк. Кайсы авазны әйткәндә авыз куышлыгында нинди әгъзаларның катнашы барлыгын ачыклау эше генә дә җиңел башкарылмый. Моны дәлилләп төшендереп бирергә кирәк. Әүвәл башлап шушы эшкә тотынуы аркасында, К. Насыйри татар тел гыйлемен яңа фәнни баскычларга күтәрә алды. Аның ул өлкәдәге уңышлары, мәсәлән, «Краткая татарская грамматика, яки Нәхү китабы»нда 1860 елда басылып та чыга[1]. Бу 79 сәхифәдән гыйбарәт булган дәреслек-кулланмасы русчаны өйрәнүче татарларга һәм татарчаны өйрәнүче урысларга тәкъдим ителә, үзенең универсальлеге белән аерылып тора. Хезмәт К. Насыйриның тел гыйлеме белән никадәр җитди һәм фәнни-гамәли нигезләрдә шөгыльләнгән булуын күрсәтә. Бүгенге көнебездә тел гыйлеме үсеше асылда ул башлаган юл белән дәвам итә дия алабыз.

Бу мәсьәләдә тел галиме Ш. Рамазанов болай дип язып чыккан иде: «...XIX йөзнең соңгы яртысына чаклы татар әдәби теленең теоретик нигезләре, сөйләм һәм язу нормалары, стилистик алымнары билгеләнмичә килде. Бу мәсьәләләрне һәм бу идеяләрне беренче буларак К. Насыйри күтәреп чыкты. Татар милли әдәби телен нигезләү, аның потенциаль мөмкинлекләрен һәм бик нечкә хасиятләрен ачып бирү, грамматик, орфографик һәм орфоэпик нормаларын кагыйдәләштерү бурычларын тарих Насыйрига йөкләгән»[2]. Әмма телне сөйләмнең үзеннән, аның үзенчәлекләрен барлау эшеннән башка тикшереп булмый дип беләбез, ягъни телнең үзенчәлекләре сакланган «тормыш материалы»н барлау һәм өйрәнүдән гайре генә К. Насыйри да уңышка ирешә алмаган булыр иде. Ул моны яхшы аңлап эш иткән. Шунлыктан К. Насыйри татар җанлы сөйләменең сәнгатьчә үзенчәлекләре гасырлардан гасырларга үстерелә килгән халык авыз иҗаты ядкярләренә мөрәҗәгать иткән, аларны җыйнап, эшкәртеп, китаби дәрәҗәгә җиткергән һәм бу аның язучылык таланты ачылуга да зур этәргеч биргән. Шул

[1] Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). – Б. 142.

[2] *Рамазанов Ш.* Каюм Насыйри – татар әдәби теленә нигез салучы. – Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). – Б. 63.

ук 1860 елда ул, «Нәхү китабы» белән берлектә, аңарга ярдәмлек сыйфатында уйланылып та, аерым китап итеп 12 сәхифәдән торган «Буш вакыт» тупланмасын бастырып чыгара һәм аны уку китабы буларак укучыларына тәкъдим итә[1]. Без андагы әсәрләрнең асылда халык иҗаты материалларыннан гына торганлыгын бәхәс итмибез. Башка халыкларның әдәбиятыннан «тәрҗемә» ителгәннәре дә очрый дип ашыгыч нәтиҗә дә чыгара алмыйбыз, әмма шунысын ассызыкларга тиешбез: К. Насыйри бу хезмәтендә халык иҗаты, халык сөйләменең үзенчәлекләрен шактый яхшы күзаллап һәм аның кысаларын, характерын, агышын белеп, төшенеп эш иткән. Аның әдәби фикерләве, әдәби образлар, сурәт-картиналар тудыру, вакыйгаларны тасвирлау үзенчәлекләре нәкъ менә фольклор, халык иҗаты нигезендә формалашалар һәм ул безгә шунлыктан халыкчан рухтагы әдип буларак тоела.

Шулай итеп, без бу фикерләмә нигезендә шундый дәлилгә дә килә алабыз: К. Насыйриның иҗатында халыкчанлык татар фольклорын яхшы белүе аркасында һәм халык иҗатын өйрәнүе сәбәпле барлыкка килә һәм үсеш ала. Шуны да онытмыйк: ул бит, үз чорының башка әдипләре кебек үк, татар мәдрәсәсендә белем алган, китап ятлап, «китабат теле»н генә белергә мәҗбүр ителгән шәкерт булган. Аның хакында М. Гайнуллин: «Башлангыч белемне атасыннан ала. 1841 елда аны Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга бирәләр»[2], – дип яза. Фикер уңаеннан шуны да искәртик: монда Казанның Әхмәдия мәдрәсәсе хакында сүз бара һәм ул татарның иң алдынгы уку йортларыннан берсе булган, анда данлыклы Әхмәт хәзрәт укыткан[3]. Әмма К. Насыйриның әдип буларак формалашуында, безнең уебызча, Духовное училище укытучыларыннан саналган, төрки халыкларның теле, әдәбияты һәм

[1] Бу хезмәте 1963 елда 87 сәхифәгә җиткерелеп, яңа вариантта бастырылып чыгарыла, 1909 елда аны «Мәгариф көтепханәсе» кабаттан бастырырга әзерли һәм «Балалар көтепханәсе» сериясеннән 5 нче китап буларак укучыларына тәкъдим итә. Бу факт исә К. Насыйри иҗатының XX йөз башында да актуаль булганлыгы хакында сөйли.

[2] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. II. – Б. 259.

[3] *Карагыз: Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Татар коммунистлар университетында укылган әдәбият дәресләренең ысулы һәм материаллары буенча язылды. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926. – Б. 42.

тарихы белән даими кызыксынган, шушы өлкәдә фәнни хезмәтләр язган В.В. Радловның тәэсире дә зур булган. Нәкъ менә ул аның күңелендә татар теленә һәм халык иҗатына мәхәббәт уятканлыгы күз алдына килмичә калмый. Бу хакта галим Габдрахман Сәгъди дә үз заманында боларны язып уза: «1850 елда башлангыч дини рус мәктәпләрендә (Духовное училищеда), шулай ук Духовная семинариядә татар телен укытырга чакырылып, рус гыйлем дөньясына барып керә һәм мәшһүр Радлов кебек галим, Европа тюркологлары белән якыннан катнаша башлый. Соңыннан, 1873 елда татарлар өчен ачылган "Учительская школа" янындагы (бу школа 1872 елда ачыла) "Рус-татар башлангыч мәктәбе"нә рус теле укытучысы, ягъни татарлар арасыннан чыккан беренче учитель булып хезмәткә керешә; татар балаларына русча укыта башлый»[1].

Василий Васильевич Радлов (үз исеме – Фридрих Вильгельм, 1837–1918) 1884 елда Санкт-Петербург Фәннәр академиясенең академигы итеп сайлана, төрки телләрне өйрәнүдә һәм фәнни тикшерүдә, аларны классификацияләүдә зур эшләр башкара, гомере буе төрки халыкларның җанлы сөйләме чагылыш тапкан фольклор әсәрләрен туплап бастырып чыгаруга зур көч куя[2].

К. Насыйриның фольклористикага тартылуы, шулай итеп, очраклы гына булмаган һәм аның дөньяга карашы формалашуда, гыйльми фикерләре һәм күзаллаулары барлыкка килүдә һәм үсешендә, иҗатының халыкчан нигезләрдә башланып китүендә, европачыл мәгърифәтчелек позицияләренә күчешендә В.В. Радлов зур роль уйнаган. Без моны фольклор һәм әдәбиятның тыгыз бәйләнешен дәлилләүче мисал буларак та билгели алабыз.

К. Насыйриның «Буш вакыт» хезмәте 1909 елда яңача басмада дөнья күрә. Китапта «Наширдан бер-ике сүз» дигән кереш мәкалә урнаштырыла. Анда: «Тәрбиятел-әтфаль[3] фәненә маһир галимнәр балаларның зиһеннәрене ачу, мәгълүматларны күбәйтү өчен төрлечә юллар күрсәтәләр. Болар арасында иң мәкъбуль күрелгән тарикъләрдан[4] берсе – сабактан бушаган заманнарда баланың ку-

---

[1] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. – Б. 43.

[2] *Карагыз:* Татарский энциклопедический словарь / гл. ред. *М.Х. Хасанов*. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1999. – С. 460.

[3] *Тәрбиятел-әтфаль* – балалар тәрбиясе.

[4] *Иң мәкъбуль күрелгән тарикъләрдан* – иң лаеклы күрелгән методлардан.

лында бик җиңел тел илә ачык итеп язылган китаплар булдырудыр. Фәнгә яки әдәбиятка даир[1] бик асат тел илә язылган китапларны уку һәм аңлауда бала һичвакыт мөгаллимгә мохтаҗ булмый. Әгәр китаплар да бала ялыкмаслык рәвештә кыска һәм кызыклы нәрсәләрдән гыйбарәт булса, үз-үзлегеннән бик күп мәгълүматы артып, зиһене ачыладыр. Ләкин балага биреләчәк китапларның балалар өчен махсус язылган булуына дикъкать кылынырга тиешледер. Баланың кулына зиһене җитмәслек агыр язылган китаплар керсә, ул вакыт укудан тәмам гайрәте чигәдер»[2], диелгән.

Бу урында наширләрнең балалар әдәбиятына мөнәсәбәте генә түгел, бәлки К. Насыйриның эшчәнлегенә дә тирән эчтәлекле бәя бирелгән һәм аның фольклористика өлкәсендәге хезмәтләренең төп тенденцияләре дә ачыклап күрсәтелгән. Болардан чыгып без К. Насыйриның җәдиди мәгърифәтче позицияләреннән торып эш иткәнлегeн аңлап торабыз. Аның карашынча, татар фольклоры милләтебезне кызыксындырган аң-белемне киңәйтүдә зур әһәмияткә ия саналган.

«1860 елны басылып чыккан “Буш вакыт” исемле әсәре татар телендә, бер яктан, фәнни-популяр әсәрләрнең берсе була, икенчедән, балалар өчен язылган, укырга күңелле итеп төзелгән фәнни-әдәби әсәрләрнең дә башлангычы булып тора», – дип аңлаткан үз вакытында галимә Җ. Вазеева[3]. Дөрес, бу фикер белән өлешчә генә килешергә мөмкин, чөнки балалар өчен фәнни, фәнни-популяр, фәнни-әдәби хезмәтләр татар әдипләре тарафыннан элгәрерәк чорларда да тудырылып килгәннәр. Әмма К. Насыйриның бу хезмәте асылы белән башка төрле, ул нәкъ менә европачыл җәдиди мәгърифәтче карашлары кысаларында язылган. Тагын да шунысын онытмыйк: «Буш вакыт»ның татар мәдәнияте үсешендәге әһәмиятен кабаттан өйрәнәсе бар әле. Ул безнең яңа, ягъни җәдиди әдәбиятыбызның балалар өчен язылган тәүге әдәби әсәре дә түгелме? Чын мәгънәсендәге балалар әдәбияты Европада Ш. Перроның

[1] *Даир* – караган.

[2] *Насыйри К.* Буш вакыт: «Балалар көтепханәсе»ннән беренче җөзьә. – Казан: Мәгариф көтепханәсе, 1909. – Б. 3–4.

[3] *Вазеева Җ.* Каюм Насыйри һәм балалар әдәбияты // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). – Б. 110.

(1628–1703) халык иҗатыннан алынган әкиятләреннән (1697 елдан) башланып киткән кебек[1], бездә ул К. Насыйриның «Буш вакыты»ннан (1860 елдан) беренче адымнарын ясамыймы? Әлбәттә!

1868 елда чыгарылган «Буш вакыт»ның эшләнеше 1860 елгысыннан шактый аерылып та тора. Китап 12 битледән 87 сәхифәгә җиткерелә. Аның тышлыгы да башка рәвешле формалаштырыла, анда: «Буш вакытларда сүзләр, берничә төрле нәрсәләр хакында. Бу дөньяда ни-нәрсәләр, ни эшләр бар. Белергә мәел итүчеләрне[2] белемләндерер өчен, Габделкаюм Габденнасыйр углы тәэлиф итеп бастырды», – дип куелган. Шушы ук хәлдә, үзгәртелүсез, китап 1884 елда кабат дөнья күрә.

«Буш вакыт» китабына (аның да 1868 елгы вариантына) мөрәҗәгать итсәк, бусы җыелма дәреслек-өйрәтмәлек рәвешен дә алган. Аның башлангыч 44 сәхифәсе татарча-русча сүзлекчәдән гыйбарәт. Алга таба 43 сәхифәдә анатомия, минералогия, табигать күренешләре хакында фәнни-популяр, фольклор һәм әдәбият материаллары бирелә. Икенче бүлек «Яңа дөнья» турында, ягъни Американы Христофор Колумбның ачуы белән бәйләнештә сөйләнелә, аннан ары бүлекләр Җир шары, һава, күк йөзе, ел фасыллары, пыяла, тимер, кит балыгы, болан һәм башкалар турында. К. Насыйри алар хакында халыкчан тел белән, җиңел аңлаешлы итеп сөйли. Болар, беренчедән, европачыл җәдиди мәгърифәтчелек идеяләрен тарату булса, икенчедән, балаларга белем бирү өчен шактый җиңел итеп төзелгәннәр, өченчедән, уку әсбабы хезмәтен дә үтиләр. Аның төзелеше, методик яктан төгәл эшләнелеше татар телен өйрәнүчеләр өчен аталганлыгын да аңлатып торалар һәм безнең бу хезмәтне «дәреслек-өйрәтмәлек» дип билгеләвебезнең дөреслеген раслыйлар. Балалар җәдитчелек матур әдәбияты бездә шулай киң кырлы, тирән эчтәлекле, мәдәни-мәгънәви юнәлеш алып башланып китә. Аның татарның акылына, рухына, аңына муафыйк килүе сокландыра. Татар акылы практик юнәлешле, рухы ихтыярый куәткә ия, аңы табигыйлекне сөя.

---

[1] *Карагыз:* Зарубежная детская литература: Учебник для студентов библ. фак. ин-тов культуры / сост. С.Н. Черняевская. – 2-е изд., перераб. и доп. – М.: Просвещение, 1982. – С. 27–28.

[2] *Мәел итүчеләр* – теләүчеләр.

«Буш вакыт»ны язганда, К. Насыйри, европачыл җәдиди мәгърифәтчелек карашларыннан тыш, хәтта фольклористик фикерләмәләрдән дә чыгып эш итә. Ул, һәр хәбәрен халыкчан рухта бирү белән бергә, аларга татар әкиятләренә хас аңлатып тасвирлау алымын да сала. Бу юл белән әдип китап башында ук язып белдергән үзенең максатына бара: милләтне аңлы, белемле итү, томаналыкта адашудан саклау. Татар әдәбиятында нәкъ менә шушы уңай башлангыч җәдиди мәгърифәтчел әдәбиятны тудыра да инде, Әхмәтҗан Биктимеров, Әхмәт Хуҗаши, Әхмәтфәрит Ширвани кебек XIX йөз ахыры – XX гасыр башы әдипләренең иҗатында К. Насыйриның «Буш вакыт» хезмәтенең урыны зур. Р. Фәхретдинов исә тулысы белән К. Насыйри юлындагы әдип буларак хаклы рәвештә бәяләнә ала. Аларны халкыбызның алга дөрес юлда китеше кызыксындырган. Болар – татар милли аңын башлап формалаштыручылар.

«Иҗтимагый прогресс идеясе белән нык сугарылган Каюм Насыйри, – дип язган Х. Ярми, – халыкның үз тарихы белән янәшә баручы, аерым урыннарда халыкның тарихын аңлауга ярдәм итүче халык авыз иҗатын яшәүчән, тормышны алга этәрүчән культура җимеше итеп карады»[1]. Аның борынгы Болгарстан һәм болгарлар, кадими-тәүге Бөек Татарстан һәм татар халкы тарихына кагылышлы иске язма һәм фольклор истәлекләрен өйрәнүе, аларга биргән бәяләмәләре милләтебезнең тарихын аңларга, төшенергә омтылуы белән бәйле иде. Ул «Тәварихе Болгария», «Дәфтәре Чыңгызнамә» кебек борынгы татар язма истәлекләренә дә бик сак карады, Ш. Мәрҗани бу әсәрләрне тәнкыйть итеп чыкканда, К. Насыйри «Тәварихе Болгария»не да яклый алды. Билгеле инде, моның аркасында алар арасында каршылык та барлыкка килде. Әмма ул галимнәр икесе дә үз позицияләрендә тотрыклы кала бирделәр. Хикмәт нәрсәдә иде соң? Җыйнап кына әйткәндә, К. Насыйриның фольклорист булуында һәм халык күңеленә ышаныч белән каравында, ә Ш. Мәрҗанинең дәлилле китап сүзенә, расланган мантыйкый фикердә рационалист буларак эш итүендә иде. Бу факт исә шулай ук татар фикер үсешенең XIX гасырдагы тенденцияләре

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). – Б. 97.

белән бәйле, һәм ул хәтта фольклористика фәненә дә уңай йогынты ясамый калмаган.

Ш. Мәрҗани фольклорист түгел, ул халык иҗатына К. Насыйри кебек зур хөрмәт һәм ихтирам белән карамаган. Аны язма истәлекләр һәм аларның ышанычлы фактларны эченә алулары күбрәк кызыксындырган. Ә К. Насыйри тарихны халык күзаллавы аша өйрәнергә, тикшерергә һәм аңлатырга омтылган. Аларның икесенең дә дөрес юлда булганлыгын билгеләве авыр түгел. Бер-бер тарихи вакыйгага халык үзенчә бәя бирсә, галимнәр аны башкача күзалларга хаклы, хөкемдарлар ул хәлләргә үзләренчә караш-мөнәсәбәтләрен белдергәннәр. Монда аерма – принципларда, хәтта бу аерма шактый зур яки капма-каршы да булырга мөмкин. Һәм шулай булуы зыялы кеше өчен бер дә сәер тоелмый. Хакыйкать тә берьяклы гына булмый.

Халык авыз иҗатын өйрәнү эшчәнлеген К. Насыйриның өч төрле юл белән алып барганлыгын билгеләп үтеп, Х. Ярми: «Беренчедән, ул татар фольклорын халыкның үз авызыннан язып ала һәм, еллар буенча үз тарафыннан җыйналган фольклорның иң яхшы үрнәкләрен сайлап алып, аны бастырып чыгаруда зур хезмәтләр күрсәтә»[1], – дип яза. Бу өлкәдә әдипнең никадәр зур көч түккәнлеге китапларыннан да күренеп тора. «Икенчедән, – дип белдерә Х. Ярми, – Каюм Насыйри татар халкының аң-белемен күтәрү өчен культура ягыннан алда торган милләтләрдән ярдәм алуын истә тотып, иң элек үз халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, дөньяга карашы белән башка халыкларны, бигрәк тә рус халкын таныштыру кирәклеген алга куя»[2]. Монда аның рус теленә татар фольклоры ядкярләрен тәрҗемә итү фактлары күздә тотыла, билгеле. «Ул татар халкының борынгы ырым һәм ышанулары турында рус телендә аерым мәкаләләр яза»[3]. К. Насыйриның фольклористика өлкәсендә башкарган эшчәнлегенә бәя биреп, Х. Ярми: «Өченчедән, – дип белдерә, – Көнчыгыш халыклары фольклорын өйрәнү һәм аның үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итеп, татар халкын алар белән таныштыру өлкәсендә шактый хезмәт күрсәтә»[4]. Монда, әлбәттә,

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 97.

[2] Шунда ук. – Б. 97–98.

[3] Шунда ук. – Б. 98.

[4] Шунда ук. – Б. 98.

аның «Кырык вәзир», «Әбугалисина кыйссасы» кебек Шәрык әдәбиятыннан тәрҗемә әсәрләре күздә тотыла. Аларда К. Насыйриның фольклорчы буларак кына түгел, чын мәгънәсендә язучылык осталыгы да ачыла. Шунысын онытмыйк: бу әсәрләр Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында сурәтләнгән Галим муллалар заманында барлыкка килгәннәр.

Г. Ибраһимов, татар байлары һәм муллалары арасында булган бер сөйләшү вакыйгасын тасвир итеп, Галим мулладан үз укучысы яшь әдип Салих хакында мондый сүзләрне әйттертә: «Сөйләмә шул юкны! Күрдем мин аның ул лыгырдыкларын... Кайчандыр Сабир китапче йөгереп килгән дә, алтын тапкан адәм кебек: “Хәзрәт, хәзрәт, кара әле, – ди, – синең шәкертең, теге ятим Салих, зур мәртәбәгә ашкан икән... Менә әллә нинди гыйбрәтле нәрсәләр язган... Калада бар халык мактый!” – дип очына. Карасам, Сабирның керткәне әкиятләр, җырлар икән. Өстенә аяк тибеп кычкырдым да, син мине мыскыл итәргә кергәнсең икән, дип, эт урынына тиргәп чыгардым. Үзе ахырдан тәүбә итә, юк, ди, хәзрәт, ди, кешеләр мактагач, мин яхшы нәрсә дип белгән идем, ди...»[1] Мондагы вакыйгалар нәкъ менә К. Насыйри чорларына туры килә. Кадимче, искелек тарафдары булган муллаларның типик йөзе шушы Галим муллада ачыла. Менә аның әдәби иҗат хакындагы фикерләре: «Ул әкиятне кем язмас?.. Имеш, бер кыз булган, кияүгә барган... Ире кыйнаган... Бер шәкерт булган... мәдрәсәдә укыган... кызлар артыннан йөргән... Шуны язалар да китап дип чыгаралар. Җитмәсә, җырлар да кушалар»[2].

Г. Ибраһимов язганнарны исәпкә алсак, К. Насыйриның да мондый каршылыкка очраган булуына шик калмый. Әмма ул барыбер дә фидакярләрчә хезмәт итүеннән туктамаган. Х. Ярминең фикерләре белән дә тулысынча килешә алабыз. Шәрык халыкларының фольклор әсәрләрен үз халкыбызга җиткерүе дигәнендә исә, исәпкә алынып җитмәгән башка бер мәсьәлә дә бар. Ул да булса – «Әбугалисина кыйссасы», «Кырык вәзир» һәм башка шундый әсәрләрне татар халкы электән белгән, әмма К. Насыйри аларны «яңа әдәби телдә» халыкка тәкъдим иткән. Хикмәте дә шунда: моңа кадәр татар әдипләре төрки әдәби тел кысаларында иҗат итеп

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. II. Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Б. 138.

[2] Шунда ук. – Б. 138.

килсәләр, К. Насыйри «яңа әдәби тел»не мәйданга чыгарган галим һәм язучы да булды. Ул казан сөйләшенә нигезләнгән әдәби тел нормаларын барлыкка китерде, аның дөрес язу һәм дөрес уку кагыйдәләрен эшләде, үз хезмәтләрен шул кагыйдәләргә таянып язып халыкка җиткерде.

Бу мәсьәләгә аерым тукталып, «Каюм Насыйриның татар телен назари эшләве иң беренче мәртәбә фәнни нигездә, чын татар грамматикасын төзеп бирүендә булды»[1] дип, Г. Сәгъди татар әдәби теле үсешендә XIX йөзнең икенче яртысында «каюмчылар» һәм «гаспринскийлар» юллары барлыкка килүе хакында язды. К. Насыйри юлы, академик М.З. Зәкиев фикерләренә таянып әйтсәк, сепаратизмга корылган иде[2].

Әмма без моны асылда татар милли әдәби телен мәйданга чыгару эше дип бәяләргә тиешбез. Татар халкы XIX йөзнең икенче яртысынача һәммә төрки халыкларга уртак буларак үстерелеп килengән төрки әдәби тел чорын К. Насыйри заманнарында узып, иҗтимагый-сәяси яктан тотрыклы һәм алгарышлы фикерле дөнья халыклары белән бергәлекне һәм бердәмлекне алга куйган буржуаз милләт сыйфатында формалашуын дәвам итеп, милли әдәби тел рәвешендә казан сөйләшен мәйданга куярлык дәрәҗәдә житлекте. К. Насыйри, татар әдәби телен Казан татарлары теле нигезендә өйрәнеп, аны гамәлгә куя алуы белән тел өлкәсендә зур галим мәртәбәсендә танылды. Бу аңарга татар фольклорын җыю һәм өйрәнү өчен дә юл ачты. Моны ничек аңларга? Бик гади дә кебек: татар сүзен татар авызыннан җыеп алу өчен, язмада бу телнең төгәл чагылуын тәэмин итәргә кирәк. Ә моңа төрки тел нормалары җавап бирми. Димәк, татар теленең үз сөйләм үзенчәлекләрен чагылдыручы язу кагыйдәләрен ачыклау сорала.

Шушы урында Х. Ярми сүзләрен искә алу урынлы булыр. Ул бу хакта болай дип белдерә: «Ачык итеп әйтергә кирәк ки, К. Насыйрига хәтле татарлардан халык авыз иҗатын халыкның үз авызыннан фәнни нигездә җентекләп һәм бөтен нечкәлекләрен

[1] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. – Б. 52.

[2] *Карагыз: Зәкиев М.З.* Беренче Бөтенсоюз тюркология съездына Г. Ибраһимов бәяләмәсе һәм хәзерге көн // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан: ИЯЛИ, 2007. – Б. 23.

истә тотып язып алучылар булмады. Бездә фольклорны турыдан-туры җырчының, әкиятченең үз авызыннан язып алу эше Каюм Насыйридан башланып китте»[1].

Халыкның сөйләмен камил рәвештә язып алу өчен, әлбәттә, шул сөйләмнең үзенчәлекләрен белергә һәм язмада чагылдыру юлларын, сүзләрнең яңгырашын дөрес тасвирлаучы язу кагыйдәләрен ачыкларга һәм булдырырга кирәк, ягъни ул сөйләмне тел гыйлеме ярдәмендә гамәлгә кую сорала. Менә бу яктан К. Насыйрига тел өлкәсендә ясаган үз гыйльми ачышларын практик җәһәттән тикшерү мөмкинлекләре ачыла. Димәк, аның фольклорчы булып китүендә субъектив сәбәпләр дә бар икән. Халыкның теле белән кызыксыну, аны өйрәнү, әлбәттә, авыз иҗатына карата да мәхәббәт уята. Менә шуның өчен дә филология факультетларында студентларның фольклор һәм диалектология экспедицияләрен оешкан төстә уздыру, практик эшне җәелдерү укыту программаларына кертелгән. Әмма аларның зарурлыгын кайбер югары уку йортларында белеп һәм аңлап кына җиткермиләр.

1871 елда «Казан календаре»н чыгара башлавы белән К. Насыйри татар милли мәдәни тормышына зур яңалык өсти. Шул ук вакытта анда фольклористиканың тарихи-иҗтимагый әһәмиятен бар тулылыгында аңлавы күзгә дә ташлана.

Календарьга материаллар туплау эше шактый катлаулы булган, билгеле. Халык өчен файдалы итәргә тырышканлыгы да ачык сизелә. Календарьның беренче чыгарылышында ук К. Насыйри аның ахыргы өлеше итеп бик әһәмиятле булган бүлек ача һәм исемен «Халык арасында тәҗрибәләр буенча көн вә һава үзгәрүнең галәмәтләре бәянында» дип атый. Бүгенге фәндә аларны «Сынамышлар» дип йөртәләр. «1871 елга «Календарь»да... күк җисемнәренең, хайваннар һәм кошларның үз-үзләрен тотышларына карап һава торышының нинди булачагын белдерүче 81 сынамыш китерелгән. Шулар ук 1879 ел өчен «Календарь»да кабат басылганнар»[2]. 1876 елгы «Казан календаре»нда К. Насыйри шушындый сынамышларны «Халык телендәге сүзләр» башы астында урнаштыра.

---

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 99.

[2] *Мәхмүтов Х.* Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы // Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Т. 3. – Б. 5–6.

Ул җыйнаган сынамышлар халкыбызның күзәтүчән һәм борынгыдан мәдәни халык булуын сөйләүче фактлар буларак бәяләнергә тиешләр. Алар К. Насыйриның шушы фәнни-практик юнәлештәге эшчәнлегенә карата укучыда зур хөрмәт уяталар. «1875 елгы календарьда инде халык телендәге сүзләр, – дип бәяләп яза Х. Ярми, – нәкъ халык арасында әйтелеп йөргәнчә матур рифмага салынып китерелә»[1]. Мисал буларак, кайберләрен карап үтәргә мөмкин:

*«Январь аенда 6-сында тулы ай – язгы ташу суга бай.*
*6-сында бик җылы – кырда икмәк бик куе.*
*6-сында ябалак кар – бик нәфис килер яз.*
*6-сында ябалак кар – кырда икмәк бик уңар»[2].*

Болар һәммәсе дә, хәзерге ел исәбенә күчергәндә, 18 гыйнвар көненә туры киләләр. К. Насыйри һәр ел фасылына бәйле шушындый милли сынамышларны җыюга бик зур көч куйган. Мондый фидакяр хезмәтне бүгенге көндә бәяләп бетерү мөмкин түгел. Х. Ярминең хәбәренә караганда, шушы рәвешле сынамышлар календарьның 1877 елгысына кадәр даими рәвештә бирелеп барыла[3], алары да бер-берсен кабатламаулары белән кызыклы. Асылда, бу сынамышлар иртәгәгә яки алдагы көннәрнең ничек булулары хакында гына сөйләп калмыйлар, алар татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен дә чагылдыралар.

Аларның күбесе игенчелеккә карый. Игенчелек – хәзер дә табигать шартларына тыгыз бәйләнештә яши торган җитештерү-икътисади өлкә. Моны К. Насыйри бик яхшы аңлап эш иткән. Шушы сынамышлар гына да халкыбызның борынгы заманнардан бирле игенчелек белән шөгыльләнгән булулары хакында сөйлиләр. Аларның кайберләре *Никола (Микула), Питрау, Симән, Ыспас* дип аталган керәшен бәйрәмнәре белән бәйле. Мәсәлән:

*«Никола көн җил булса, бөтен җәй җил.*
*Никола җитми җәй булмый,*
*Никола җитми кыш булмый»[4].*

---

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 99.

[2] *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Т. 3. – Б. 43.

[3] *Карагыз: Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 99.

[4] *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Т. 3. – Б. 44.

Бу Никола, ягъни Изге Микула бәйрәме, елына ике тапкыр була, аның беренчесе хәзерге ел исәбе белән 21 майга туры килсә, икенчесе 18 декабрь көнендә уза. Әмма без шунысын да онытмыйк: бу хисап-сынамышлар кайвакытта һава торышына бик төгәл туры киләләр. Шулай да без аларны шартлы күренеш буларак билгеләргә тиешбез. Бу шартлылыкны борынгы бабаларыбыз да яхшы аңлаганнар, әмма аларга таянмый эш итми калмаганнар. Тагын да шунысына игътибар күзен салырга тиешле: сынамышлар керәшеннәрнеке булмасын, мөселман татарларына карамасын, алар К. Насыйри тарафыннан үзара бәйләнештә тикшерелгәннәр, ягъни бер-берсенә каршы куелмаганнар һәм әдип тарафыннан дингә бәйле инкяр ителмәгәннәр. Бу факт исә татарларның борынгыдан бер үк халык булуын да раслый. Тагын да шунысы әһәмиятле: бу сынамышларда бәрәңге һәм помидор кебек бакча культуралары искә дә алынмый, ә менә шалкан һәм кыяр турында әйтелә. Болар да кызыклы нәтиҗәләр ясарга, ул сынамышларның борынгы булуларын ачыкларга мөмкинлек бирәләр.

К. Насыйри календарьларында «Казан бәете», «Шыгали бәете» кебек халык иҗаты әсәрләренә дә, Казан шәһәренә һәм Кабан күленә бәйле легенда-риваятьләргә дә урын бирә (мәсәлән, 1881 елгысында). «Бу вакытларда инде Каюм Насыйриның халык телендә йөргән төрле тапкыр сүзләр, авыл хуҗалыгы-игенчелек тәҗрибәләре белән бәйләнгән төрле ышануларны гына язып алу белән чикләнеп калмыйча, фольклор әсәрләрен җитди өйрәнә башлауга күчүен күрәбез»[1]. Бу исә фольклористиканың этнографиядән аерылуыннан килгән процесска да бәйле булган.

Х. Ярми шушы елларда К. Насыйриның халыктан җырларны, табышмак һәм мәкальләрне, әкият һәм башка төр жанрларны зур кызыксыну белән фәнни юнәлештә җыярга керешүенә игътибар итә, календарьларында аңлатмалы язулар бирүне шушы фикерен куәтләүче факт рәвешендә китерә[2]. Календарьларында К. Насыйри теге яки бу фольклор әсәренә мөнәсәбәтле махсус аңлатмасын урнаштырып, асылда, аларга карата фәнни фикер тудыра. Бәяләмәләре гомумилек характерына ия һәм фәнни югарылыкта булулары

---

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б.100.

[2] Шунда ук.

белән аерылып торалар, әдипнең чын мәгънәсендә фольклорчы буларак җитлегүе хакында сөйлиләр.

Халык иҗатына игътибар борынгы заманнардан ук үстерелеп килсә дә, «фольклор» термины фәнни кулланылышка бары тик XIX йөзнең икенче яртысында гына кертелә[1]. К. Насыйри, фольклористика белән даими рәвештә шөгыльләнеп, халыкның бөек иҗатчы булуын раслаучы шактый күп дәлилләр таба, ул фольклорга халыкның примитив аңы чагылышы дип карамый, бәлки анда мәдәни яктан камиллек үрнәкләрен күрә, таба һәм фикерләрен башкаларга җиткерә белеп эш итә. Бу исә татар фольклористика фәненең төп тенденциясен барлыкка китерә һәм ул К. Насыйри тарафыннан формалаштырыла. Нәкъ менә шушы юнәлештә Г. Тукайның да фикерләре җитлегә һәм ул «Халык әдәбияты» (1910) хезмәтендә шушы юлдан килеп татар халык иҗатына бик югары бәя бирә[2]. Анда хәтта фәнни әһәмияткә ия мондый нәтиҗә чыгара: «Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр»[3]. Ул монда халык иҗаты матур әдәбиятның нигезе икәнлеген ачык итеп раслый. Тукай чыннан да пәйгамбәрләрчә әйткән, XX йөз шигъриятебез халыкчан рухта, халыкчан алымнарда, халыкчан үлчәмдә, ягъни халык иҗатыннан килгән традицияләр агымында үсте.

К. Насыйриның татар халык иҗатын җыйнап бастырып чыгаруда төп хезмәтләреннән берсе дип, әлбәттә, «Фәвакиһел-җөләса...» китабын санарга кирәк. Дөрес, шушы 609 сәхифәдән гыйбарәт булган күләмле җыентыгының башлангыч өлешен китаби материаллар били, әмма да 546 биттән соң ул татар халык иҗатына караган мәкаль һәм әйтемнәргә игътибарын юнәлтә. Аның фольклорны шушы рәвештә бирүенең хикмәте дә бар. К. Насыйри татар халкының мәдәни үсешен Шәрык халыклары иҗатыннан аерылгысыз үсеш алганлыгын дәлилләүне максат итеп куйган. Шуңа күрә дә, «Кырык бакча» китабы кебек үк, монда гарәп-фарсы халыклары иҗаты белән уртак мотивлар һәм җитди уртаклыклар булган материаллар урын

[1] Краткий словарь по эстетике: кн. для учителя / под ред. М.Ф. Овсянникова. – М.: Просвещение, 1983. – С. 181.

[2] *Тукай Г.* Әсәрләр: биш томда. – Т. 4. Проза. Публицистика (1907–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 163–186.

[3] Шунда ук. – Б. 177.

алганнар. Аларны бары тик Шәрык халык әдәбияты ядкярләре дип кенә түгел, бәлки татарның үзенеке буларак та бәяләргә кирәк. Уртак яшәү рәвеше, дөньяга караш, мәдәни мохит К. Насыйри иҗатында инкяр ителмәде. Бу факт аның чын мәгънәсендә фәһемле, интернационалистик рухлы әдип булуын да дәлилли.

Халык иҗаты ул милли компоненттан гына гыйбарәт түгел, аңарга интернационалистик рух хас. Халыклар аралашмыйча гына яшәмиләр, алар бер-берсенә тарихи, иҗтимагый, гыйльми, әдәби, мәдәни, тәрбияви тәэсирләр ясаудан һичвакыт тукталмаганнар. К. Насыйриның 1884 елда басылып чыккан шушы рухтагы «Фәвакиһел-җөләса...» хезмәте, шул исәптән 1880 елда ук дөнья күргән «Кырык бакча»сы боларның ачык дәлиле булып торалар. Андагы материалларны әдип бары тик Шәрык халыклары иҗатыннан гына алган, алар белән татар халкын таныштыру максаты белән эш иткән дип мәсьәләне җиңелчә хәл итәргә омтылучы галимнәрнең фикеренә катнашып китү безне бер дә җәлеп итми.

«Моннан соң үз халкымызда бәгъзы мөгамма вә лөгазьләрне[1] бәян кылаек ки, телебездә җомак вә табышмак тәгъбир кылыныр[2]. Ләкин мәзкүр[3] җомак вә табышмак дигәнебез күбрәк ләгызь кабилендәдер[4]», – дип белдерә К. Насыйри «Фәвакиһел-җөләса...»да. Әдипнең «Сайланма әсәрләр»ен укучыларга тәкъдим итүчеләр «Фәвакиһел-җөләса...»дагы бу бүлекчәне «Халык иҗаты әсәрләре» башы астында, «Табышмаклар» исеме белән атап, кайдан алынганлыклары күрсәтелмичә биргәннәр[5].

«Фәвакиһел-җөләса...»да 27 табышмак китерелә, алардан соң «Шигырьләр» дигән бүлек башлана. Фольклорчы галим Х. Мәхмүтов: «Шигырь дип К. Насыйри җырларны атый»[6], – дигән искәртү ясый.

К. Насыйри төп игътибарын халык җырларының төзелеш үзенчәлекләренә юнәлтеп кенә калмый, аларның эчтәлеген ачыклауны да максат итеп куя һәм бу хакта болай дип белдерә: «Мәгълүм ки,

---

[1] *Мөгамма вә лөгазьләрне* – табышмак һәм тапкыр мәсьәләләрне.

[2] *Тәгъбир кылыныр* – гыйбарә ителер, мисалга китерелер.

[3] *Мәзкүр* – телгә алынган, бәян ителгән.

[4] *Ләгызь кабилендәдер* – табышмак мисалындадыр.

[5] *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Т. 3. – Б. 15–22.

[6] Шунда ук. – Б. 53 (астөшермәләр өлешендә).

логатемезнең[1] шигырьләре һәркайчан ике мисраглы[2] булып, күбрәк шигырьләрдә соңгы мисраг максудны ифадә кыладыр[3]. Вә янә телемезнең хавасыннандыр[4] ки, бер шигырьне 10–15 төрле итеп тәрәннем кылмак[5] мөмкин. Бу хасият башка телләрдә ишетелмидер. Вә дәхи шигырьләремез фирак вә һиҗран[6] вә мәдех[7] вә иштиякы-васләт[8] вә үпкә бәянында тәрәннем кылынадыр». «Фәвакиһел-җөләса...»дан бу бүлек К. Насыйриның «Сайланма әсәрләре»нең өченче томы «Җырлар» бүлекчәсендә кайдан алынганлыклары күрсәтелмичә генә бирелгәннәр[9].

«Фәвакиһел-җөләса...»дагы 116 җырның барысы да диярлек сөю-сәгадәт турында. Шунысы әһәмиятле: К. Насыйри кайбер җырларга үзенең шәрех-аңлатмаларын да бирүне кирәк тапкан, аларның шуклык белән иҗат ителүләрен дә сиздерми калмаган. Бу аның җыр тематикасын шактый яхшы аңлап һәм укучыларына эчтәлекләрен төшендерергә теләп эш итүеннән килә. Мәсәлән:

Кашларың нечкә бик әйләнгән,
Казанда бөккән дугадай,
Йөзең күркәм, буең зифа –
Банкаларда үскән кынадай, –

дигән җырга ул мондый аңлатма бирә һәм: «Бу мәзкүр[10] шигырьдә мәхбүбләрнең[11] кашын дугага тәшбиһе[12] мөнәсәбәтсезрәк күренсә дә, җырның йыртыгы юк дигән көллияне[13] игътибарга алсак, мәгъфүдер[14] », – дип белдерә[15].

---

[1] *Логатемезнең* – телебезнең.
[2] *Мисраглы* – строфалы.
[3] *Ифадә кыладыр* – белдерәдер.
[4] *Хавасыннандыр* – үзенчәлегеннәндер.
[5] *Тәрәннем кылмак* – көйләмәк, җырламак.
[6] *Фирак вә һиҗран* – аерылу һәм китү.
[7] *Мәдех* – мактау.
[8] *Иштыякы-васләт*– кавышу теләгендә сагышлану.
[9] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Т. 3. – Б. 53–84.
[10] *Мәзкүр* – телгә алынган, искәртелгән.
[11] *Мәхбүбләрнең* – гашыйкларның.
[12] *Тәшбиһе* – охшатуы.
[13] *Көллияне* – әйтемне, сүзне.
[14] *Мәгъфүдер* – гафу ителерлектер.
[15] *Насыйри К.* Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият. – Казан: Университет табигъханәсе, 1884. – Б. 548.

Җырлардан соң, инде искәрткәнебезчә, «Чәй бәете» һәм «Уңмаган килен бәете» китерелә һәм К. Насыйри аларның шигъри яктан төгәл һәм дөрес төзелештә булуларын мактый, эчтәлекләренә игътибар итә, вәзен үлчәмнәрен билгели. Алардан соң мәкаль һәм әйтемнәргә күчә.

«Каюм Насыйри, – дип яза Х. Ярми, – халык авыз иҗатының мәкальләр өлешеннән бик нык файдалануы һәм аңа аерата бер мәхәббәт белән каравы билгеле»[1]. «Фәвакиһел-җөләса...»да да мәкаль һәм әйтемнәргә ул шактый зур урын бирә.

Мәкаль һәм әйтемнәр хакында К. Насыйри боларны яза: «Мәгълүм ула ки, һәр телнең үзенә махсус әмсаль вә мәкальләре, вә көллияләре буладыр. Халкына күрә гакыл ияләре вә хәкимнәре дәхи бардыр»[2]. К. Насыйри әйтемнәрне монда көллияләр дип атый, әмсаль дигәнендә хайваннар һәм киек-җанварларга карата әйтелеп тә, асылда кешегә нисбәтле мәкальләрне күздә тота. Аның бу рәвешле мәкаль һәм әйтемнәрне өч төрлегә бүлүе – кызыклы күренеш һәм хәзерге фольклористика гыйлемендә әлегә файдаланылмый. Әгәр дә бүгенге фәнебезгә «әмсаль» термины кире кайтарылса, бу хәл табигый буларак аңлашылыр иде.

«Фәвакиһел-җөләса»ның 583 сәхифәсеннән башлап К. Насыйри 310 мәкаль һәм әйтем, әмсальләрне китерә. Сайланма әсәрләренең 3 томында ул 22–43 нче битләргә урнаштырылган. Әмма анда да мәкаль, әйтем һәм әмсальләр аерымланып урнаштырылмаганнар. Тагын да шунысы әһәмиятле: К. Насыйри бу материалларның эчтәлегенә аерым игътибар итә, аларны аңлатып, укучыларына төшендереп бирә, кайбер урыннарда гарәп яки фарсы фольклорыннан мәгънәдәшләрен китерә. Шуңа да аны без шактый олы хезмәт дип атарга батырчылык итәбез.

Х. Ярми К. Насыйриның фольклористика белән даими шөгыльләнүенең төп сәбәпләрен аның татар әдәби телебезне баету өлкәсендәге эшчәнлеге дип бәяли[3]. Димәк, К. Насыйри Казан татарлары сөйләшен әдәби телебез буларак туктаусыз пропагандалау

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 102.

[2] *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Т. 3. – Б. 22.

[3] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 102.

эшен дә башкарган, шунлыктан әдәби тел җәһәтендә «каюмчылык» юнәлеше барлыкка килгән. Бер яктан, татар әдәби теленең язма һәм сөйләм нормаларын грамматик нигездә тикшерүе һәм гамәлгә куюы, икенче яктан, шушы әдәби телне халык иҗаты материаллары һәм язма мирас ярдәмендә (ул бу җәһәттән Г. Кандалый иҗатын аерып алып өлге итә) туктаусыз ныгытуы, үзенең дә шул нигездә әдәби иҗат һәм фәнни хезмәтләр язу эшләре белән шөгыльләнүе К. Насыйриның карашлары җитлеккән, максатчан галим булуы хакында сөйлиләр. Бу гына да түгел, ул әле татар фольклоры җәүһәрләрен башка халыкларга җиткерү белән дә кызыксына.

1880 елда чыккан «Записи Императорского географического общества» тупланмасының VI томында ул рус телендә «Поверья и обряды казанских татар» мәкаләсен бастырып чыгара. Бу язмасын Х. Ярми «Казан татарлары мифологиясен өйрәнүдә беренче фәнни хезмәт»[1] дип атый.

Аның белән килешми мөмкин түгел. Ул мәкаләдә халкыбызның ислам динен кабул иткәнчегә кадәрге булган карашлары, мифик затларга ышанулары һәм шулар белән бәйле гореф-гадәт һәм йолалары махсус тикшерелә.

К. Насыйриның хезмәтләре, асылда, XIX гасырга карасалар да, алар бүген дә актуальлекләрен югалтмаганнар, төрле фәннәр үсешендә зур әһәмияткә ия булып торалар. Без аның бары тик татар фольклористика фәнен барлыкка китерүендә һәм үсешендә керткән өлешенең кайбер якларын гына карап үттек, бу гыйльми өлкә белән кызыксына башлавының төп сәбәбен ачыкладык. Ә менә ислам мәдәнияте кысаларында үсеш алган башка халыкларның иҗатларына бәйле язмаларын, аларны да фәнни нигездә өйрәнүләрен читкә куеп тордык.

Шунысын онытмыйк: К. Насыйри татар халкы үсешендә ислам мәдәниятенең шактый әһәмиятле роль уйнаганлыгын ачык күзаллап эш иткән, татар халык иҗатын ислам мәдәниятеннән аерылгысыз дип санаган. Моны аның «Фәвакиһел-җөләса...» хезмәте кебек үк башкалары да раслап торалар. Татар халкының рухи дөньясы шушындый катлаулы мәдәни кысаларда формалашкан һәм үсеш алган, без моны бүгенге көндә дә инкяр итә алмыйбыз.

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 103.

К. Насыйриның татар фольклористика гыйлемен үстерүдә төп эшчәнлеге, беренчедән, милли әдәби татар телебезне гамәлгә кую белән бәйле булса, икенчедән, халык авыз иҗатын өйрәнү аша аны пропагандалаудан, халкыбызның дөньяга карашын киңәйтергә омтылышыннан гыйбарәт. Фольклорны җыйнау гына да гаять зур хезмәт сорый. Ул – аларны анализлаган, фәнни нигездә эшкәрткән, бастырып чыгарган, бу гына да түгел, татар халык авыз иҗатын беренче булып системага салган, татар фольклористикасын гыйльми нигездә үстереп җибәргән галимебез дә. Без аны татар фольклористика гыйлемен европача җәдиди нигездә үстереп җибәргән беренче зур галимебез дип атыйбыз һәм монда бернинди арттыру юк икәнен дә беләбез.

2

К. Насыйри Казан Император университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең төп галимнәреннән берсе булган. Җитмәсә, аңа акчалата да ярдәм итеп торган. Монысы тагын да гаҗәп. К. Насыйри галим һәм язучы гына түгел, сәүдәгәр, ягъни, үз чорының термины белән искәрсәк, «гельдий купец» дәрәҗәсен дә йөрткән. Мондый кеше галимнәргә ничек инде матди ярдәмен күрсәтми калдырсын? Тик шунысы бар: К. Насыйрины бездә фәкыйрь булган, авыр яшәгән, фатирда гына торган, подвал бүлмәдә гомер сөргән кебек һәм башка шундый хәбәрләргә ияртеп искә алырга маһирлар. Ул да үз тормышында төрле авырлыклар аша узгандыр, бәхәс итмибез. Әмма аның дәрәҗәле, товар-акча әйләнешендә йөргән шактый гына сумма акчасы да булган сәүдәгәрлек таныклыгын өнәмәвебез дә бер көлке күренеш түгелме?

«Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең 1896 елгы «Известия» альманахының XIII томында К. Насыйриның рус телендә «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы Казанских татар») дигән зур һәм җитди фәнни хезмәте басылып чыга, ул анда, табышмак, мәкаль һәм әйтемнәр белән бергә, халык җырларының үрнәкләрен дә татар һәм рус телләрендә урнаштыра. Профессор Н.Ф. Катанов аның татар фольклористикасы өлкәсендәге казанышларына аерым басым ясап, шушы мәкаләгә сүз башы буларак язган бәяләмәсендә болай дип белдерә: «Бу көнгә хәтле Казан татарларының халык иҗаты памятникларын

җыйнаучылардан берәү дә бу хәтле күп җырлар һәм мәкальләр тапшырганы юк иде. Насыйров әфәнде тарафыннан тапшырылган материаллар, бөтен гомерен үз халкы арасында үткәреп, аны төрле яктан өйрәнүе аркасында, аның үз халкының тормышы һәм теле белән яхшы таныш икәнлеген бик ачык күрсәтә. Безнең җыйнаучыбыз тарафыннан китерелгән табышмаклар аның халкының искиткеч акыллы икәнлеген исбат итәләр... Барлык бу җырлардан мондагы татар халкының үзләренең шатлык һәм кайгыларын тасвирлы һәм җиңел итеп сурәтләүләрен күреп була» (Х. Ярми тәрҗемәсе)[1]. К. Насыйри татар халык җырларын «Кырык бакча» китабындагыча бүлекләргә бүлеп, тематик яктан аларны классификацияләп һәм тәртипкә салып, укучыларына тәкъдим итә. Аның «Сказки казанских татар и сопостовление их со сказками других народов» дигән хезмәте дә шушы ук җәмгыятьнең «Известия» тупланмасында 1900 елда басылып чыга (XVI том). Монда барлыгы 11 әкият китерелә. К. Насыйри аларны гарәп графикасында әзерли, профессор Н.Ф. Катанов аларга академик транскрипция ясый, академик П.А. Поляков исә аларга башка халыкларның әкиятләре белән чагыштырма анализ уздыра[2]. «Каюм Насыйри бу әсәрендә, – дип яза Х. Ярми, – татар халкының тормышын, аның үз тирә-юнендә, үзен әйләндереп алган табигый көчләргә булган карашын ачык чагылдырган реалистик әкиятләрне сайлап биргән»[3].

Монда бирелгән әкиятләрнең табигый рәвештә башка халыкларның да иҗатлары белән уртак яңгырашка ия булулары ачыклана. Бу факт исә татар халкының мәдәният ягыннан бер дә башкалардан калышмавын, рус халкы белән дә бер дәрәҗәдә икәнлеген галимнәргә төшенергә ярдәм итә.

Шушы җәмгыять «Известия»сенең XII томында 1894 елда хәрби офицер В.А. Мошковның (ә рус офицерлары арасында фән белән шөгыльләнү, традиция буларак, XVIII йөздән үстерелеп килә) «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. – Мелодии Оренбургских и

[1] *Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 103.

[2] *Бу хакта киңрәк мәгълүматны карагыз: Ярми Х.* Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге. – Б. 104.

[3] Шунда ук.

Ногайских татар. Введение» хезмәте 1–67 сәхифәләрдә урнаштырыла. Ул шушы материалларны Варшава хәрби округында хезмәт итүче татар солдатларыннан җыя[1]. Хезмәтнең башлангыч 20 бите сүзлекчәдән гыйбарәт. Тел тарихын өйрәнүчеләр өчен кызыклы материаллар арым төркемнәргә бүленгәннәр. Мәсәлән, анда мондый кызыклы материал бирелгән: «Козалык җир» – козалык үзе арба дигән сүз; козалык җир – борынгы үлчәү берәмлеге; арбаның ике тәгәрмәче арасындагы тар һәм 100 атлам озынлыгындагы (30 сажин) җир бүлеме. 15–20 шундый кишәрлек пай була. Бер пай бер гаиләгә бүлеп бирелә. Тамга – шушы пай җирләренә куелган билге»[2] *(алынма безнең тәрҗемәдә)*.

Мондый кызыклы хәбәрләр һәм аңлатмалар тарихи яктан да әһәмиятле һәм татар халкының җир бүлешү системасын дөрес аңларга ярдәм итәләр. Тагын да шунысын искәрик: Алтын Урдада монгол хөкемдарлары тарафыннан кертелгән тамга (урда = хәзер без аны «орды» дибез, ягъни «мөһер орды») системасы татарда XIX йөздә дә яшәгән икәнлеге тарихлардан хәбәрдар кешегә аңлашылып тора. Алтынчы бүлекчәдә В.А. Мошков «Верования» («Ышанулар») белән бәйле материалларны туплый. Халык авыз иҗатында татарлар Җирне табак кебек дип күзаллауларын яза, аны Күк Үгезе мөгезендә тотып тора икән, ә ул Үгез Балык өстендә тора, ә Балык Диңгездә йөзеп йөри[3], имеш. Бу, әлбәттә, Ислам динендә кабул ителгән Җир шары хакындагы мифка туры килә.

Беренче кеше Җирдә Исуп (Йосыф) пәйгамбәр булган икән («...Первый человек назывался Исуп Пайһамбар»[4]). Ул баштарак ялгызы яши, аннары картая. Аллаһы Тәгаләдән бирелгән хатынын очрата – Залека, ул да ялгыз яши.

Кыш көнне алар юллары туры килеп очрашалар. Бер-берсен күреп исләре китә.

Исуп сорый: «Син кайдан киләсең? Моңа кадәр Җир йөзендә бер генә кешене дә күрмәгән идем».

---

[1] *Карагыз:* Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – Казань: Типолитография Императорского университета, 1894. – С. 1.

[2] Шунда ук. – Б. 19.

[3] Шунда ук. – Б. 21.

[4] Шунда ук.

Залека да моңа кадәр һичбер кешене күрмәгән булуын сөйли, әмма очратачагы төшенә кергәнлеге хакында сөйли. Исуп аңарга тәкъдим ясый һәм аны өенә алып кайта.

Икенче көнне Исуп уяна һәм бер төш күрүен Залекага сөйли. «Мне, говорит он, явился во сне Джибраһил Гиссалям и сказал, что нам так жить нельзя, что мы должны обвенчаться»[1].

Залека да төшендә шушыны ук күргән икән. Исуп Пайһамбар кулына китап ала, үзен үзе никахлый, чөнки әлегә бүтән кешеләр булмый. Шулай алар яшиләр һәм беренче балалары Исаф Пайһамбар туа.

Әүвәле алар җәннәттә, матур бакчада яшиләр. Бернәрсә дә ашамыйлар. Аннары Ходай аларга җимеш – «курма» бирә, кечкенә һәм тәмле, баллы. Тәүлеккә берне генә ашыйлар, «йомышка да йөрмиләр». Соңрак алар комсызлаланалар, күбрәк ашый башлыйлар. Шуның өчен «йомышка да йөрү» ихтыяҗы туа. «В раю, где они жили, были все хорошие запахи, а тут пошел дух нехороший и Бог вывел их из рая»[2].

В.А. Мошков бу риваятьне хәрби хезмәттәге Әстерхан татарларыннан язып алган. Аларның ышанулары буенча, Җирдәге беренче кешеләр шушы Исуп һәм Залека, ягъни Йосыф белән Зөләйха булганнар.

Бу факт аерым тарихи-мәдәни әһәмияткә ия. Мотивлары белән ул рәсми дини риваятьләргә дә берникадәр якын, Адәм белән Хәува турында да кебек, әмма хәбәр ителгән вакыйгалар аларныкыннан шактый нык аерылып та торалар. Шунысы да бар: берничә дини риваятьнең бергә кушылуы аркасында барлыкка килгән дип нәтиҗә чыгарырга һич мөмкин түгел. Әмма В.А. Мошков язып алган ул риваять бу факт шактый кызыклы һәм ислам диненә кадәр үк дини ышануларга бәйле түгелме дигән фикергә дә китерә.

Шушы ук вакыйгаларны Оренбург татарлары башкачарак сөйлиләр икәнлегенә тукталып, хезмәтендә В.А. Мошков, махсус игътибар юнәлтеп, Исуп белән Залеканы Шайтан котыртканлыгына ышануларын искәртә, («уговорил их съесть пшеницу») бодай

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 21–22.

[2] Шунда ук. – Б. 22.

җимешен ашарга күндерүен әйтә[1]. Мондагы бодай//богъдай җимеше исә ислам динендә рәсми кабул ителгән версиягә туры килә, әмма Адәм белән Хәува урынына Йосыф белән Зөләйха булуы факты мәсьәләне катлауландыра. Солдатка аңгы-миңге егетләрне алмаганнар, билгеле. Алар хаталы сөйләмәгәннәр. Мәгәр шулай икән, димәк, халык ышанулары төрле төбәкләрдә төрлечәрәк булган. Оренбург татарлары сөйләгәннәр «Пәйгамбәрләр тарихы»нда тасвир ителгән вакыйгаларга, ягъни ислам диненең канунлаштырган риваятьләренә турырак килә. Бу фактлар татар халкында Йосыф-Зөләйха белән бәйле сюжетларның актив кулланылышта йөрүләре һәм хәтта рәсми дини риваятьләрне алыштырулары хакында да сөйлиләр.

Краснодарски нугайларында, В.А. Мошковның аңлатуынча, беренче кешеләр татар телендә сөйләшкәннәр, аларны бу телгә Җәбраил фәрештә өйрәткән. Шулай ук шушы Җәбраил фәрештә, Аллаһы Тәгалә кешеләрне бар кылгач, аларга, шәрә йөрмәсеннәр өчен, шунда ук киемнәр кидергән[2]. Болары – милли үзаңның татарда ул заманнарда шактый көчле булуы хакында сөйли торган фактлардан.

В.А. Мошков бу риваятьләрне һәм мифларны турыдан-туры татар халкының ырым һәм ышануларына китереп бәйли. Дөрес, алар арасында Ислам дине тәгълиматы тарафыннан тәмам ныгытылган мифларның кайбер элементларын да очратырга була, әмма ул уртак мотивлар һәм яңгырашлар борынгы татар ышанулары белән турыдан-туры бәйле булырга да мөмкиннәр.

В.А. Мошков язып алган кыргый хайваннарның килеп чыгышы хакындагы татар мифы да фәнни яктан кызыклы.

Борын заманда бер бай була, ул бик тә саран икән. Аның хайваннары, мал-туары шактый күп, ди. Әмма ул аларны корбан итеп чалмаган, ярлыларга алардан өлеш чыгармаган.

Бервакыт бара икән бу, җир ярылып, тездән шунда чумган. Ходай килеп, аңардан: «Ярлыларга моннан ары корбан чалырсыңмы?» – дип сораган, ул: «Әйе!» – дип җавап биргән. Шунда ук бәладән котылган. Әмма биргән сүзендә тормаган.

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 22.

[2] Шунда ук.

Мондый хәл өч тапкыр кабатланган. Икенчесендә бу саран бай, җир ярылып, шунда биленнән чумган, өченчесендә муенына кадәр һәм дә ахырда бөтенләй җир тишегенә олаккан. Аннан инде чыга алмаган.

Шунысы әһәмиятле: өч тапкыр кабатлану вакыйгасында без дүртенче очракка да тап булабыз. Димәк, татарлар Аллаһы Тәгаләне өч тапкыр сыный, дүртенчесендә хөкем итә дип белгәннәр. Безнең халыктагы борынгы нумерологиядә менә ни өчен «дүртле» үлем саны буларак аңлатыла икән! В.А. Мошков моңа игътибар итмәгән.

Бу саран бай җир астында калдырылгач, аның мал-туарлары берәм-берәм таралышып бетәләр һәм кыргыйлашалар. Кайсылары бүрегә, төлкегә, куянга һәм башка хайваннарга әвереләләр. Әүвәле бу хайваннарның теле булмаган, аннары соң Ходай аларның берләренә сөйләргә ярый, икенчеләренә юк дип, тиешле санаганнарына тел биргән[1].

Бу миф гыйбрәтле һәм тәрбияви әһәмияткә ия. Карун бай турындагы риваятьләрне дә бераз хәтерләтә, әмма аны һич тә кабатламый.

Шушы риваятьләрдә борынгы татар халкы ышануларының мифологик-хорафатлы катламы чалымнарын шактый таба алабыз. Ислам дине үзенеке дип таныган риваятьләрнең татарлар арасында активлашуында халык иҗаты белән аваздаш мотивлары булудан икәнлеге дә аңлашыла башлый. Халыкның борынгы заманнардан яшәп килгән ышанулары һәм мифлары белән аваздашлык һәм уртаклыклары сәбәбеннән ислам дине татарда утсыз-кылычсыз таралыш алган. Моны башкача итеп турыдан-турыраслап булмый, әмма бу фәнни гипотезаны уздырмыйча да мөмкин түгел, фактлар күбәйгән саен ныклы күзаллау да тумыйча калмый.

Шундый ук мифларның берсе Ходайның җан ияләренә ризык бүлүе хакында. Ходай, хайваннарга мөрәҗәгать итеп: «Кем кайсы ризыкны ашыйсы килә?» – дип сораган. Ат шунда кеше ризыгы саналган итне, икмәкне һәм башкаларны ашарга теләге барлыгын белдергән. Аның белән Ходай да килешергә әзер икән, әмма Исуп Пәйһамбәр (В.А. Мошков аның Оренбург татарларында һәм

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 22–23.

нугайларда шушылай сөйләнелгәнлеген ассызыклый) яки аның улы Исаф Пәйһамбәр (монысын В.А. Мошков Краснодарски нугайларына нисбәтли) үтенгәч, ит һәм икмәк кешеләргә калдырылган, ә атларга – үлән.

Елан шунда кеше канын эчәргә теләге барлыгын белдергән. Хәбәрендә вакыйгасы болай була:

Ходай кешеләрнең гөнаһы өчен Җирне суга батыра. Идел ташып чыга. Исуп Пәйһамбәрдән ары башкалар батып үләләр. Ул зур көймәдә исән кала. Аның көймәсе бер тау яныннан үтеп барганда, берничә кеше аңардан үзләрен коткаруын үтенәләр. Ул, аларны кызганып, үз янына ала. Ходай моңа ачулана һәм тычканнарга көймә төбен тишәргә куша. Тишектән су кереп, көймә бата башлый. Исуп һәммәсен көймәне төзәтергә чакыра. Әмма файдасыз. Шунда елан килә. «Әгәр дә миңарга кеше канын эчәргә Ходайдан рөхсәт алып бирсәң, мин ярдәм итәм!» – дип белдерә. Тормышы өчен курkынган Исуп Пәйһамбәр риза була. Елан үз койрыгы белән көймәнең тишеген каплый.

Болардан аңлашылганча, бу хәбәрләр Нух пәйгамбәр вакыйгаларын искә төшерәләр. Әмма Ислам динендә канунлаштырылган риваятькә Исуп Пәйһамбәр вакыйгалары туры килми, Идел елгасы хакында сүз бару да хәбәрнең татар акылы белән уйлап чыгарылуы хакында сөйли. Тау яныннан узып барганда көймәгә кешеләрне утыртуы да кызыклы һәм, гомумән, мондый тәфсилле вакыйгалар халык уйдырмалары булып торалар, әлбәттә. Дөрес, авыз иҗатына нигезләнеп язылган хикәятләрне искә алсак, башка хәл. Аларда без әллә нинди гайре табигый һәм табигый, хикмәтле вакыйгаларга тап булырга мөмкинбез. Аннары Җирне су басуны татар халык авыз иҗатында, күргәнебезчә, беренче кеше дип күзалланган Исуп Пәйһамбәргә нисбәт иткәннәр. Бу фактлар фән өчен аерым игътибарга лаек.

Еланга рөхсәт бирер алдыннан Ходай, В.А. Мошков язып алган татар риваяте буенча, кеше канын эчеп карарга дип, шунда черкине җибәрә. Татлымы икәнен белергә. Черки очып бара, туйганчы кеше канын эчә, кире кайтканында аңарга карлыгач очрый. Ул: «Татлымы?» – дип сорый. Черки: «Аннан да тәмлесе юк», – ди. Карлыгач әйтә: «Әйдә, телеңне күрсәт!» – ди. Черки күрсәтә. Карлыгач шунда аның телен тешләп өзә.

Черки шулай Ходай каршына килә. Әмма соравына җавап бирә алмый, безелдәп тик тора. Хода белми кала, еланга бака канын эчәргә боера. Елан, ачуы килеп, карлыгачны койрыгыннан эләктереп ала, шуннан аның койрыгы өчпочмаклы булып бүленеп кала[1].

Моңа охшашлы хикәят 2004 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Гыйбрәтле хикәятләр» китабында «Ни өчен карлыгачның койрыгы икегә аерылган?» дигән исем астында китерелә, әмма аның кайдан алынганлыгы искәртелми[2].

Детальләргә игътибар итеп, аларны чагыштырганда, шуңа тап булабыз: «Ни өчен карлыгачның койрыгы икегә аерылган?» хикәятендәге елан кеше канын түгел, бәлки итен ашарга рөхсәт ителүен теләп Нух пәйгамбәрдән сорый. Аннары еланнар да бер генә булмыйлар. Шулай ук черки урынына соры чебен, Ходай урынына да, Исуп Пәйһамбәр урынына да Нух пәйгамбәр куела. Әмма Карлыгач койрыгының икегә аерылуы белән өчпочмаклы булып калуы мотивларында охшашлык бар. Бу гыйбрәтле хикәят шактый әдәбиләштерелгән һәм В.А. Мошков китергән халык риваятеннән детальле һәм сурәтле булуы белән бик нык аерылып тора. Бу фактлар исә халык әсәренең бер-бер укымышлы шәкерт тарафыннан хикәят итеп язып алынган, эшкәртелгән булуын фараз кылуга этәрә.

Элекләрне, димәк, татар халкында беренче кешеләрне Адәм белән Хәува дип түгел, Исуп Пәйһамбәр һәм Залека дип күзаллау да яшәгән, аларның улы Исаф Пәйһамбәр хакында да хәбәрләр сакланган. «Пәйһамбәр»нең «пәйгамбәр» икәнлеген төшенүе авыр түгел, аннары җәннәт, Җәбраил фәрештә, туфан-су басу вакыйгасы – болар барысы да ислам динендәге канунлаштырылган риватьләргә нисбәтләре барлыгын дәлил итүче фактлар булып торалар. Ә менә ни өчен аларда зур аермалар бар – болары фәндә яңа бер эзләнүләргә һәм ачышларга таба юл ача. Исупның Йосыф пәйгамбәр, Залеканың Зөләйха икәнлеген искәрттек. Моны Болгар чоры шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» әсәреннән халык күңелендә уелып калган эздер бу дип әйтергә була. Әмма Исафы кем?

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 23–24.

[2] *Карагыз:* Гыйбрәтле хикәятләр / кулъязмаларны басмага әзерләүче, хәзерге әдәби телгә күчерүче һәм рәссам-бизәүче Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 135–136.

Анысы – Нух пәйгамбәрнең улы Яфәс (төрле китапларда Яфес, яки Яфәз, яисә Яфет исемнәре белән искә алына), монда шик була алмый. Берничә дини риваятьнең бергә укмашуы кызыклы. Бу күренеш акыл күчешеннән түгел, бәлки тарихи аңның яшәү рәвешеннән килә. Ерак хәбәрләр белән якын вакыйгалар, үзара охшашлыклары була калса, халык күңелендә кушылып китүчән. Монда да шундый метаморфозалар күзәтелә. В.А. Мошков теркәп алган бу миф һәм риваятьләр, шулай итеп, татар халкының борынгы заманнарын аңлау-аңлату өчен дә, шактый зур фәнни әһәмияткә ия булып чыгалар. Бер яктан Адәм белән Хәувага бәйле риваятьләр, икенче яктан Нух пәйгамбәр вакыйгалары халкыбыз иҗатында Йосыф белән Зөләйханыкы (Исуп һәм Залека) булып киткән, Нух пәйгамбәр улы Яфәз пәйгамбәр дә аларның улы итеп аңлатылган. Ә өченче яктан монда Йосыф һәм Зөләйханың үз тарихлары да катнаша. Бу өч катламның бергә туплануы һәм бер үк яссылыкта яшәве татар акылының һәм аңының шактый катлаулы булуын гына түгел, аның борынгыдан үз дини күзаллаулары яшәгәнлеген дә күрсәтә. Дөрес, мондый риваятьләр халкыбыз тарафыннан тарихи үсеш дәверендә дә тудырылган булырга мөмкиннәр. Ул вакытта без мондый әсәрләрнең җаһилияткә төшкән заманнарда барлыкка килүләрен искәрергә тиешбез. Әмма ул XIX йөз (коммунистик уку-тәрбия еллары XX гасыр түгел инде) бер дә андый чор сыйфатында хәтергә килми. Шушы мантыйгыбыз дөрес һәм хакыйкый икән, димәк, фикерләмәләребездән бары тик берсе, ягъни борынгы заманнардан татарлар беренче кешеләрне шулай Йосыф-Зөләйха дип күз алдына китергәннәр дигән фаразыбыз гына урынлы булып кала.

В.А. Мошковның хезмәтендә табигать күренешләренә бәйле ырым һәм ышануларның да теркәлеп калынуы кызыклы. Аның язмасыннан аңлашылганча, борынгыдан Оренбург нугайларында Кояш һәм Айның бердәй, игезәкләр сыман итеп яратылулары хакында хәбәрләр йөргән. Аларны бер-берсеннән аерып та булмаган. Шуннан Ходай, фәрештәләр җибәреп, Айның яктылыгының бераз өлешен кырып алырга һәм Кояшка кушарга боерган. Шуннан соң Кояш яктырак яна башлаган.

Краснодарски нугайларында Ай-Кояшка бәйле риваятьләр тагын да кызыклырак итеп сөйләнелә: болар икесе дә буш куык-шар икәннәр. Аларның эчендә игезәк корткалар утыралар. Кояшта – Җилмәвез

кортка, Айда – шундый ук исемдәге Җилмәвез әби. Димәк, исемнәре дә бер үк төрле. Аларның берсе көндез, икенчесе төнлә Җир йөзен күзәтәләр. Кояш, Ай баткан төннәрдә бу әбиләр, Ходайга килеп,ниләр күргәнлекләрен сөйлиләр. Кояш һәм Айның тотылулары сәбәбе дә Җир йөзендә күп төрле явызлыклар булудан икән[1].

«Җилмәвез» сүзенең асыл мәгънәсе «фәрештә» түгелме икән дигән сорау да күңелдә туа.

Бу риваятьнең тәрбияви функциясе шактый көчле. Аның килеп чыгышы борынгы ырым-ышануларга барып тоташканы аңлашылып тора. «Ходай» сүзе урынына «Тәңре» атамасы кулланылса, без андый нәтиҗәне хәтта хакыйкать буларак та таныргa өлгерер идек. Гомумән дә, В.А. Мошковның хезмәтен укыганда, безнең күңелдә Краснодарски нугайларында (татарлары хакында сүз барганлыгы аңлашыла) борынгы ырым һәм ышанулар белән бәйле халык авыз иҗаты әсәрләренең шактый әһәмиятле катламы сакланып калган дигән тойгы уяна.

Татарлар һәркемнең үз бәхет йолдызы барлыкка ышанганнар, кеше үлсә, йолдызы да егылып төшә дип исәпләгәннәр[2]. Димәк, күктә йолдыз атылуны алар кеше үлеме, кайгы килү буларак күзаллаганнар, хәзергечә бәхеткә юрамаганнар.

«Киек Каз Юлы» йолдызлар тезмәсен Краснодарски нугайлары «Кавы жула» дип, Оренбург татарлары «Кәгъбә юлы» исеме белән йөрткәннәр[3]. «Кәгъбә юлы» дигәненең мәгънәсе аңлашылып тора. Сүзнең хаҗга бару юлы белән, ул йолдызлар тезмәсенең кыйблага таба юнәлеш тотуга бәйле аталуыннан икәнлеген инкяр итү урынсыз. Халкыбыз яшәгән җирләрдән Мәккә шәһәре көньяк тарафта, Идел елгасы аккан юнәлештәрәк урнашкан. Бу йолдызлар тезмәсе дә нәкъ шул якка юлны күрсәтеп тора. Ә менә «Кавы жула» дигәнендә «Кави юлы» күздә тотылуын, ягъни «Куәт ияси Аллаһы Тәгаләгә илтүче юл» икәнлеген дә белә алабыз. Рухларның Аллаһы каршысына ашу юлын фаразлап шулай аталганмы ул? Әллә халкыбыз борынгыда «Киек Каз Юлы»н дини-мистик аңлау-аңлатуларга төргәнме? Бәлки, ул шул ук «хаҗилар юлы», «Кәгъбә юлы» дигән сүздер?

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 24.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

Бу кызыклы фактка аңлатманы В.А. Мошков та эзләгән. Аны шул ук солдатларның үзләреннән тапкан. Аларның сөйләве буенча Кавы – дөньяда иң матур һәм рәхәт урын, анда бервакытта да кыш булмый. Кавыга кергәндә, рәшәткәле капка бар икән, аны «Кавы капхасы» дип йөртәләр һәм ул гаҗәеп үзенчәлекләргә ия: әгәр дә аңа муллалар һәм изгеләр килсә, рәшәткәләре ачылалар, кешеләр имин рәвештә аннан узып китәләр, әгәр дә гөнаһ ияләре керергә тырышсалар, алар тараялар һәм болар шунда кысылып үләләр, ди. Шушы Кавыга барганда, «Изге Караташ» бар, аны «Сынтас» дип йөртәләр. Гөнаһ иясе аңа якын килсә, бу таш сытып үтерә икән[1].

Бу бәян ителгәннәрне Ислам динендәге хәбәрләр белән тәңгәл китерсәк, «Кавы»ны «Каф тавы» дип тә кабул итәргә мөмкин. Шулай икән, димәк, аның Кавказ тауларына бәйле булуы да бик мөмкин. «Кавы капхасы» да «Каф тавы капкасы»ның иске нугайча әйтелеше дип аңларга була. Әгәр дә Кавыны Кавказ тавы дип алсак, Кавказ тауларында андый капканың барлыгы билгеле, аны «Дирбәнд капкасы» дип тә йөртәләр. Ислам диненә бәйле риваятьләрдә Зөлкарнәйн пәйгамбәр төзеткән дип аңлаталар. Хәзерге Коръән тәфсирләрендә Зөлкарнәйн пәйгамбәрнең тарихи шәхес буларак кем икәнлеге тәгаенләнеп атала. Ул – Мидия һәм Персия шаһы, ягъни ике илнең патшасы (төшендә ике кулына бер тәкәнең ике мөгезеннән тотучы итеп үзен күргән, шуңа бәйле аны Зөлкарнәйн, ягъни Ике мөгезле атап дип йөрткәннәр; төшен ике илне берьюлы идарә итәрсең дип юраганнар, аларның берсе – фарсы иле, икенчесе – туран азәрбайҗаны икән) Дарий Беренче падишаһ[2].

Дарий I падишаһ б.э.к. 521–485 елларда хөкемдарлык иткән. «Еще более убедительным, однако, может служить свидетельство Британской энциклопедии: «Дербенд, или Дарбанд, город на Кавказе, находится в провинции Дагестан, на западном побережье Каспийского моря… Он занимает узкую полоску земли вдоль моря, поднимаясь вверх по крутым склонам гор… К югу находится юж-

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т.XII. – Вып. 1. – Б. 24–25.

[2] *Карагыз:* Священный Коран: двуязычное издание / авт. пер. с арабского языка на английский, вступ. ст. и комм. *Маулана Мухаммад Али;* пер. на русский язык подготовил д-р *Александр Салецкий* (проф. университета Лаваля). – США: ЛАХОР ИНК: Ахмадийа Анжуман Ишаат Ислам, 1997. – С. 601–602 (подстрачный комментарий № 1517).

ная оконечность Кавказской стены (протяженность 50 миль), иначе известной как стена Александра, она перегораживает узкий проход Железных, или Каспийских, ворот (Порте Албане или Порте Каспе)…» Неправильное название *Стена Александра* произошло, видимо, вследствие ошибки мусульманских историков, считавших, что Дху-л-карнайн – это Александр»[1].

«Кавы капхасы» шушы Дарий I падишаһ төзеткән Тимер капка яки Каспий капкасы, яисә Дирбәнд капкасы, я Кавказ капкасы һәм Каф тавы капкасы исемнәре белән төрлечә аталып йөртелә торган капка булып чыга түгелме? Мөгаен, борынгы заманнарда татарлар, шул капка аша узып, хаҗга барганнардыр, В.А. Мошков теркәп калдырган халык риваяте безгә шул хакта да, бәлки, хәбәр итәдер? Чөнки ул шунда ук хаҗилар хакында телгә ала, аларның «аккып» дип аталуларына туктала. Сәбәп хаҗиларның намазга ак чалма киюләренә бәйле икән[2].

«Сынтас» һәм «Кавы капхасы» турындагы риваятьләр гөнаһлы кешеләрне хаҗга барудан тыяр өчен дә уйлап чыгарылган булырга мөмкиннәр. Әмма ул ташның изге Караташ икәнлегеннән дә ваклап кызыксынучан В.А. Мошковка солдатлар искәрткәннәр. Тик, нигәдер, аны үзләре дә Кавы юлындагы таш дип белгәннәр.

Әмма бу «Кавы капхасы» дигәне «җәннәт капкасы» буларак та аңлашыла, чөнки аның аша гөнаһлылар уза алмыйлар дигән хәбәр язмада ачык сөйләнелә. Шушы капкадан кергәннәрне алда бәхетле тормыш көтә, ул җирдә кыш булмый – бу хәбәрләр дә җәннәт тасвирына турыдан-туры бәйледер кебек.

Шулай да «Сынтас» һәм «Изге Караташ» дигәннәре мәсьәләне дөрес чишәргә ярдәм итәләр. Ул «Сынтас» – «сын ташы» дигән сүз. Андый таш Кәгъбәдә бар. Аны «Караташ» («Хаҗәре-әсвад») дип тә әйтәләр. Бу хакта да В.А. Мошковны солдатлар искәрткәннәр. Ул таш чыннан да сын, ягъни мәҗүсиләрнең табына торган потларыннан берсе булган, метеорит, күк җисеме кисәге. Мөселманнарда изге таш санала. Пәйгамбәребезгә аны Кәгъбә ташы итәргә белдерелгән. Хәзер дә халкыбызда ул таш хакында, әгәр

[1] Священный Коран: двуязычное издание. – С. 605 (подстраничный комментарий № 1523).

[2] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 25.

дә гөнаһлы кешеләр аңа якын килсәләр, сытып үтерә икән диген урынлы-урынсыз сүзләр сөйләнелә.

Алга таба шул ук хезмәтендә В.А. Мошков, кызыклы риваятьләрдән берсе, җил турындагы мифик күзаллауны теркәгән. Краснодарски нугайлары җилне бер карчык һәм аның кызлары белән бәйләнештә сөйлиләр икән. Имеш, бер карчык бар, ди, аның да җиде кызы. Шуларның берсе аксак һәм усал икән. Калган алты кызы аның белән бергә яшәргә теләмиләр, һаман да аңардан качалар. Качканда йөгерәләр һәм итәкләре белән җил чыгаралар. Качып өлгергәч, беразга хәл җыярга туктыйлар, шуңа күрә андый вакытларда җил дә исми тора, имеш[1].

В.А. Мошковның өермә белән бәйле язып алынган хәбәрләре дә кызыклы. Алары да әкияти планда бирелгән, мифик әсәрләр рәтенә керә.

Өермә белән тузан кубарыла, чөнки аның эчендә Шайтан утыра, имеш. Әгәр дә кешегә өермә килсә, тиеп китсә, яки аны эчендә калдырса – аңарга Шайтан сихере эләгә икән. Кешене хәтта акылдан яздыру көченә дә ия, ди. Аңардан котылу өчен, өермә күрсәң, дога укырга, өрергә һәм төкеренергә кирәк[2].

Болардан соң В.А. Мошков Шайтан һәм шайтаннар хакында халык ышануларын теркәгән. Татарларның белүләре буенча, шайтаннар күп икәннәр, аларның җитәкчеләре Иблис, ди.

Иблис әүвәле пәйгамбәр булган, җәннәттә яшәгән. Ходай аңарга кукуруздан башка барлык җимеш һәм җиләкләрне дә ашарга рөхсәт иткән. Ул аны беренче кешегә алдап ашаткан. Моның өчен Ходай Иблискә «яман камыт» кидергән, аны җәннәттән куган. Шуннан бирле Иблис Ходай белән ярыша башлаган, пәйгамбәрләрне һәм кешеләрне дөрес юлдан яздырырга тырыша икән.

Иблиснең ярдәмчесе – яман рухлы Даджал. Аны Иблис көн дә кешеләрне аздырырга җибәрә, үзара сугышсыннар, аракы эчсеннәр дип өйрәтергә куша. Хатыннары ирләренә хыянәт итсеннәр, ирләре – хатыннарына. Һәм шуның ише башка начар гамәлләргә кешеләрне шушы Даджал өйрәтә, имеш[3].

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 25.

[2] Шунда ук. – Б. 25.

[3] Шунда ук. – Б. 25–26.

Ислам дине тәгълиматлары буенча караганда, монда китерелгән вакыйгалар ул өйрәтмәләргә туры да киләләр сыман. Әмма берникадәр аерымлыклар да бар. Мәсәлән, богдай//богъдай җимеше урынына «кукуруз кайаба» (ягъни кукуруз бодае – кукуруз чәкәне) хакында сүз бара, Иблиснең Аллаһы Тәгалә белән ярышуы, Адәм һәм аның балаларына Даджалны җибәрүе кебек урыннары дини риваятьләргә тартымнар, әмма аерылып та торалар. Ходайга Иблисне каршы кую да борынгы, Ислам дине таратылганчы булган мәҗүси тәгълиматтан килә кебек. Дәҗҗалны дөрес итеп «Дәҗҗал» дип түгел, «Даджал» дип атап йөртү татар халкында хәзергәчә очрый, Казан татарлары да аны «Дәджал» яки «Дәджан» дип әйткәлиләр, бигрәк тә шаян һәм шук балаларны шушы рәвешле атап ачулану гадәте аларда бүген дә сакланган.

В.А. Мошков Даджал (ягъни Дәҗҗал) хакында бер кызыклы риваятьне дә искәртә. Татар солдатларының сөйләгәннәренчә, ул Даджал бер ярлыга хезмәтче булып яллана һәм алар арыш үстерергә килешенәләр. Иген үскәч, Даджал аңардан бер тәпән аракы ясый һәм моны эшләү серен шул адәмгә өйрәтә. Ул менә шулай һәртөрле исерткечләр ясау серен кешеләргә белдереп йөри торгач, ахырда җир ярылып, шунда төшеп олаккан, артыннан кара төтеннәр генә чыгып калган. Бу хакта Иблис белеп алган, аны каршыларга музыка һәм биюләр белән бәйрәм оештырган. Шайтаннар бер ай буена олы туй ясаганнар[1].

Әстерхан татарларын да В.А. Мошков нугайлар дип атый һәм алардан да Дәҗҗал белән бәйле бер риваятьне язып ала. Анысы да Ислам динендә кабул ителгән мифик күзаллауларга берникадәр охшаш, әмма алардан аерылып та тора.

Көнбатышта, дөньяның иң читендә Гаф-таһа бар икән. Аның артында шайтаннар иле башлана. Шайтаннар арасыннан Татҗал (ягъни Дәҗҗал инде бу) дигәне яшь чагында ук кешеләрнең җирләрен яулап алмакчы була. Татҗалның әтисе аның бу ниятенә каршы чыга. Татҗалның моңа ачуы килә һәм әтисен үтерә. Моның өчен Ходай шушы Татҗалны туган җиренә бәйләп куярга куша. Шуннан бирле ул чылбырда утыра икән һәм Гаф-таһаның төбен казый, шуннан ке-

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 26.

шеләр ягына тишеп чыкмакчы була. Көне буе казый, арып йокыга китә. Таң белән уяна. Ә тау яңадан үз хәленә кайткан икән.

Ул кабат казый. Кай вакытларда бу авыр эш аның ачуын чыгара һәм ул чылбырларын өзгәләп ташларга тырышып бәргәләнә, боргалана. Шул сәбәпле җир тетри. Татҗалны тынычландырырга дип Ходай Тәгалә пәйгамбәрне җибәрә.

Пәйгамбәр, килеп, Татҗалны тимерчыбык белән кыйный. Кыйналган Татҗал җиргә ава. Кабат аңына килә һәм, тырмашыптырмашып, Гаф-таһа төбен казырга кабат керешә.

Аның кешеләр яши торган бу дөньяны күрәсе килә. Ул бу дөньяга чыкса, дөнья бетәчәк. Дөнья бетәр алдыннан 30 ел кала Татҗал Гаф-таһаны тишеп чыгачак. Ул музыка һәм җыр белән дөнья буйлап үтәчәк. Кемнәр аны күрә һәм ишетәләр, алар аңа иярәчәкләр һәм шайтаннарга әверелә барачаклар. Шунда хак дин ияләре Татҗалны үтерәчәкләр.

Кайчан Татҗалны пәйгамбәр кыйный, шуннан яшен чыга. Татҗалның яман үкерүеннән күкләр күкри. Яшен сугудан үлгән кеше гөнаһлы була, андыйларның рухы чиста түгел, диләр. Андый кешене, үзен үзе үтерүчене, эчкечене, суга батучыны башкалар янына күмәргә ярамый.

Салават күперен Әстерхан татарлары һәм нугайлар «айэндук» дип йөртәләр икән. Аның бер башы суга тиеп тора дип беләләр. Ул шулай суны суыра, тирәсендәге алтмыш чакрым җирдәге кораб һәм көймәләрне дә үзенә тартып ала, хәтта тимер чылбырларын да өзеп калдыра, ди[1].

В.А. Мошков җыйнаган бу фольклор әсәрләре асыллары белән мифларга туры киләләр. Татар халкында алар киң таралыш алганнар. Алар әдәби мотивлары, сюжет элементлары, кайбер геройлары белән ислам динендәге хәбәрләргә дә тартымнар. Беренчедән, халкыбызның борынгыдан яшәп килгән ырым һәм ышануларына барып тоташсалар, икенчедән, ислам диненә бәйле риваятьләрне дә хәтерләтәләр. Димәк, алар ислам дине таратылу чорында борынгы ырым һәм ышанулардан трансформацияләнгән булырга тиешләр. Дөрес, халык авыз иҗаты үсештән тукталып тормый. Димәк, өченче яктан, без бу ырым һәм ышануларның халык тарафыннан баетыла

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 26–27.

барылуларына да игътибар итәргә тиешбез. Әмма шунысын онытып бетерергә ярамый: ырым һәм ышану кебек шактый катлаулы һәм үтә җаваплылык сорый торган мәсьәләләрдә иҗатка һәм фантазиягә бирелү дә бик үк мөмкин түгел һәм ярамый торган гамәлләрдән санала. Алар булган кадәрләренчә үзгәрми сакла违налар һәм традицион кысаларында, үз рәвешләрендә кала бирәләр. Ә менә яңа тәгълиматлар тәэсирендә иҗади үзгәрүләрен фәнни яктан тикшерү тарихи һәм мәдәни әһәмияткә ия. Мәсьәләнең ул ягы да бар.

Татар ырым һәм ышануларында төрле ияләргә бәйләнеше дә шактый. Су анасы, йорт иясе, шүрәле кебекләргә килгәндә, Әстерхан татарлары һәртөрле сулыкларның да ия-рухлары бар дип ышанганнар. Су анасын алар «албаслы» дип йөртәләр[1]. «Дух этот, как и человек, бывает обоих полов и плодится, – дип язып алган В.А. Мошков алар хакында. – Кроме воды, главного его местопребывания, албаслы водится еще в старых банях, на мельницах и на старых кладбищах. Видом он похож на человека, но у него нет носовых костей, а только одна ноздря. Тело его покрыто очень мягкой шерстью в роде пуха, а ноги обращены ступнями назад»[2]. Аны әгәр дә чәченнән тотып өйгә алып кайтсаң, ул гади кеше рәвешенә керә. Албаслының күкрәкләре гайре табигый, зур, җиргә кадәр асылынып торалар, аңа йөрергә һәм йөгереп качарга комачаулыйлар.

Әгәр дә албаслыны күкрәкләре алга салынып торган чагында күрсәң, аны куып тотарга була. Әгәр дә инде ул аларны аркасына ташлап өлгерсә, артыннан атта чаптырып та җитү мөмкин түгел.

Албаслы кешеләрне суга батырып үтерә, хатыннарның, бала тапкан чакларын туры китереп, җаннарын суырып алырга тырыша. Кайвакыт моңа ирешә дә.

Албаслыны бил каешы белән генә кыйнарга ярый, әгәр дә аңа камчы яки чыбыркы ише белән суксаң, ул үсә, зурая башлый. Күпме күбрәк суксалар, шулкадәр үк дәү була бара.

Оренбург татарлары су иясен «албаслы» дип әйтмиләр, бәлки «су анасы» дип йөртәләр икән, аның чәчләре бик озын һәм күкрәкләре шулай ук тезләренә чаклы, ди[3].

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 27.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук. – Б. 28.

Әлбәттә, безнең күңелгә Г. Тукайның «Су анасы» әкият-поэмасы килә, әмма Әстерхан һәм Оренбург татарларында таралган бу риваятьләрдә алтын тараклары барлыгы хакында нигәдер бөтенләй искә алынмый.

Су анасы, ягъни албаслы белән бәйле мондый бер вакыйганы В.А. Мошков Әстерхан нугайларыннан язып алган:

Нишләргә кирәклеген белгән бер кеше албаслыны эләктергән һәм чалбар каешы белән кыйнаган. Албаслы елый икән, башка һичкайчан аңа яманлык эшләмәскә антлар итеп, күзләреңдә яшь тә күренмәс дип.

Бу кеше ул албаслының ике чәч бөртеген алып кала, ә үзен җибәрә. Әгәр дә кешедә албаслының чәч бөртеге булса, ул аңарга бер дә зыян кыла алмый икән.

Ул кеше, аның чәч бөртекләрен алып кайтып, Коръән эченә яшереп куйган. Ә албаслы килгән, чәч бөртекләрен кире бирүен сорый икән. Ә теге кеше ахмак булмаган, бирергә ашыкмаган.

Албаслы хәйләгә керешкән. Бу кешегә хезмәтче булып яллангән. Хуҗалар туйга киткәч, аларның биш-алты яшьлек малайларыннан теге чәч бөртекләрен Коръән эченнән алып бирүен сораган да, теләге үтәлгәч, ул баланы кайнар казанга ташлап, чыгып та качкан. Шуннан бирле күзгә күренгәне юк, ди[1].

Оренбург һәм Әстерхан татарлары җил тегермәнендә тартылган оннан пешерелгән ризыкны ашауны гөнаһка саныйлар икән[2]. Оренбург татарлары тегермәннең иясе бар дип уйлыйлар, аны «тегермән пирисы» яки шулай ук «албаслы» дип йөртәләр. Тегермәндә йоклаган кешеләрне алар басып үтерәләр, ир һәм хатын затларыннан булалар, имеш.

Йорт ияләренә килгәндә, В.А. Мошков фикеренчә, күчмә һәм ярым күчмә нугайлар аларның барлыгына ышаналар, әмма ул рухларны урысча «домовой» дип атыйлар, чөнки йорт салуны алар руслардан алганнар икән[3].

Йорт ияләре бүрәнә ярыкларында яшиләр, имеш, аннан чыксалар – зураялар. Йоклаган кешене буарга мөмкиннәр. Әгәр ку-

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 28.

[2] Шунда ук. – Б. 29.

[3] Шунда ук.

лың белән селтәнеп суксаң, тимиләр, ди. Оренбург нугайлары исә аларны «ий албастысы» яки «ий асы» дип йөртәләр. Имеш, ул хатын-кыз затыннан, чәчләре 40 аршын озынлыгында, 70 имиле, һәрберсе җитмешәр мендәрле. Төп эшләре – хатыннарны, шулай ук ат-бияләрне, сыерларны, сарык һәм башка йорт хайваннарын куркыту. Әгәр дә аларны сөйсәләр, чәчләрен тарап үрәләр, бөдрәләтәләр, ди[1].

Шүрәлегә килгәндә, ул – урман иясе. Аны Әстерхан татарлары «тирәк иясе» дип йөртәләр. Алар утка яки эткә әверелергә мөмкиннәр, яисә адәм сурәтенә дә керәләр. Кешене суга кадәр куып киләләр, ут шары сыман очып баралар, әмма суны үтеп чыга алмый. Оренбург татарларында аларны «шурали» дип атап йөртәләр, ирләре дә, хатыннары да, балалары да булуга ышаналар. Үзләре кеше кебек, кул-аяклары да бар, әмма бармаклары һәм тырнаклары озын. Кешеләрне кытыклап үтерәләр. «Астраханские ногайцы думают, что род человеческий, с тех пор, как живет на свете, становится всё хуже и грешнее, – дип яза В.А. Мошков, – а потому всё более мельчает: первые люди были великаны – *и к о п а д а м,* а потом измельчали и стали среднего роста; после нас же люди больше измельчают и сделаются совсем карликами – *к е ш к э а д а м*»[2].

Болардан тыш, В.А. Мошков Әстерхан һәм Оренбург татарларыннан төрле легендалар да язып ала. Алары да Казан татарлары тарихи риваятьләреннән аерылып торалар. Мисалга «Хәмит хәзрәт» турындагысын алырга мөмкин. Анда Хәмитнең әүвәле бик көчле баһадир булуы хакында сөйләнелә, ул бик күп дошманнарын җиңә.

Аның аты булган, хуҗасының телен аңлый икән. Хәзрәт Хәмит Әстерханда мәчет төзеткән.

В.А. Мошковның хәбәрләренә караганда, бу мәчетне 1602 елда руслар чиркәү итеп үзгәртәләр, ә 1698 елда бөтенләй сүтеп, яңадан салалар.

Мәчетне төзеткәндә, хәзрәт әйтә: «Монда беренче булып килгән берәр малайны күрсәгез, тотыгыз да нигезгә салыгыз!» – ди. Төзүчеләр янына беренче булып Хәмит хәзрәтнең үз малае килә.

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 29.

[2] Шунда ук. – Б. 30.

Осталар аны кызганалар һәм бер рус малаен үтереп салалар. Хәзрәт, килеп алардан сорап, ничек булганын белгәч: «Харап иттегез төзелешне!» – дип борчыла. Ахырда нәкъ аның фаразынча килеп чыга: мәчет итеп төзетелгән бина чиркәүгә әверелдерелә[1].

«Хәзрәт Кхали», «Тува батыр», «Хәзрәт Игали» кебек тарихи риваятьләрдә дә сугышчан баһадирлар турында сөйләнә. В.А. Мошков аларны да язып ала. «Хәзрәт Кыхали» вакыйгаларында калмык-кытайлар белән сугышлардан хәбәрләр бирелә. Кхалины икенче төрле исем белән дә йөртәләр, ул – Казыр-Мөхәммәд (Хозер-Мөхәммәд) икән. Аның Арыслан дигән аты булган. Кытайларның Шака исемле баһадирлары белән сугыша һәм аңардан өстен чыгуга ирешә, аны үтерә. Кытайлар куркып качалар.

Вакыйгаларны бәян иткәндә, В.А. Мошков бу баһадирның аяусыз булуына игътибар итә. Ул шулкадәр көчле икән, бер сугуда йөзәр дошманны кырып сала. Арый, йокыга китә. Уяна. Маштагы (ягъни аты) аның янында тора. Фарсыларны да «татар диненә кертмәкче була». Алар белән дә сугыша, әмма җиңә алмый, һәлак ителә. Фарсылар шунлыктан үзләренең әүвәлге диннәреннән китәләр, әмма татар диненә дә кереп җитә алмый калалар[2] (монда сүз сөнни мәзһәбе хакында барадыр дип уйларга кирәк).

Тува батыр исә руслар белән сугыша. Әстерханны руслар алгач, ул Сарычин (Царицын) шәһәренә кача, урысларны тупка тоткалап тора. Әмма җиңелә башлый һәм суга батып үлүдән гайре аңа башка юл калмый. Аны Әстерхан янындагы Сарай зиратына күмгәннәр. Кайчан Татҗал Гаф-таһын тишеп чыгачак, Тува батыр да каберennән кузгалачак һәм аның белән сугышачак[3], диләр.

Игали хакындагы риваятькә килсәк, В.А. Мошковның белдерүе буенча, ул да баһадир булган. Бу риваятьнең эчтәлеге «Бакырган китабы»ндагы Хатаи Сакыйнның «Кыйссаи Әхтәм» әсәренә туры килә[4], бу факт җитди аерым әһәмияткә ия һәм ул шагыйрьнең нугай татарларыннан булуын фаразларга юл ача. Әмма бу әсәрләр

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. – Т. XII. – Вып. 1. – С. 63–64.

[2] Шунда ук. – Б. 64–65.

[3] Шунда ук.

[4] *Карагыз:* Бакырган Китабы: XII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре. – Б. 208–230.

арасында кайбер аермалыклар да бар. Мәсәлән, Мәдинә шәһәре урынына – Ташкент, яһүдиләр урынына – руслар. Еллар узу белән әдәби язма әсәр, халык эчендә фольклорлашып, заманасына бәйле үзгәреш кичерүе аркасында ул шулай килеп чыккан. Һәрхәлдә, риваятьнең Оренбург нугайлары арасында телдә йөргән булуы – кызыклы һәм фәнни әһәмияткә ия күренеш. Фольклор әсәрләрен өйрәнү һәм аларны язма әдәби мирас белән тәңгәл куеп тикшерү көтелмәгән гыйльми ачышларга китерә ала.

«Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете» тупланмасында туры-дан-туры фольклорга гына багышланган мәкаләләр, күзәтү материаллары алай ук күп түгел. Тарихка, археологиягә һәм этнографиягә караганнары төп күпчелекне тәшкил итә. Шулай да этнографик язмалар арасыннан фольклор әсәрләрен һәм фольклористикага бәйле хезмәтләрне дә таба алабыз. Моның сәбәбе фольклористика гыйлеменең аерым фәнни өлкә буларак бары тик XIX йөзнең икенче яртысында гына формалашып җитүенә бәйле. Россия гыйлем дөньясында ул әлегә күтәрелеп кенә килә. Халыкның әдәби иҗаты гыйлемен җирле сөйләшләрне этнографик планда өйрәнү җәһәтеннән дә, ырым һәм йолаларны тарихи-этнографик планда барлау белән бәйле дә искә төшерәләр. Шулай да әдәбият, тарих, этнография һәм тел фәннәре берсе дә халыкның авыз иҗаты материалларыннан башка һәм фольклористика гыйлеменең фәнни казанышларын исәпкә алмыйча эш итми диярлек.

В.А. Мошковның шушы анализлап үтелгән хезмәте рус фольклористика гыйлеменең XIX йөз ахырында да әлегә этнография фәне кысаларыннан тәмам аерылып җитмәвен күрсәтеп тора. Бу тенденция XX гасыр башында да шушы рәвештә сакланып кала. Әмма алга таба фольклористика гыйлеме киңәя һәм үсә, ныгый бара.

Татар фольклористикасы исә, К. Насыйри эшчәнлеге белән бәйле рәвештә, этнография гыйлеменнән иртәрәк аерымлана. Аның бездә барлыкка килүендә һәм үсешендә тел гыйлеме, әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр дә, этнографлар да, тарихчы галимнәр дә катнашканнар.

Тагын шунысы әһәмиятле: рус хәрби офицерлары да татар халкының авыз иҗаты белән кызыксынганнар, шул белемнәре ярдәмендә халкыбызны аңларга тырышканнар. Мошков Валентин

Александровичка (1852–1920) килгәндә, ул хәтта Россия география җәмгыятендә һәм Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә әгъза да булып торган[1].

3

Фольклористика гыйлеменә XIX гасырның икенче яртысында нигез салына һәм ул шул чордан безнең татар фән дөньясында татар халык авыз иҗатын барлау, җыйнау, өйрәнү, системага салу эшчәнлеге киң җәелдерелә һәм ул уңышлы рәвештә үсә башлый. Бу аның тамырлары нык булудан килә, билгеле. Шул сәбәпле XIX йөздә татар халык иҗатын өйрәнүнең торышын, үзенчәлекләрен, кайбер үсеш юнәлешләрен барларга туры килде. Дөрес, мәсьләнең барча якларын да колачлап алу мөмкин дә түгел. Әмма аңа омтылышыбыз булмады түгел. Куелган мәсьәләләр катлаулы, аларны чишү зур белем һәм җитди эзләнүләр таләп итте. Аларның нәтиҗәсе буларак, ясалган ачышлардан чыгып, без боларны төгәл белергә тиешбез:

Беренчедән, татар фольклористикасы XIX гасырда тулысынча формалаша һәм үсеш ала башлый. Аның формалашу һәм үсешендә мәгърифәтче, галим һәм язучы К. Насыйриның эшчәнлеге бәяләп бетергесез. Татар дөньясында фән һәм гыйлем бервакытта да башка халыкларныкыннан артта булмаган, аларга ияреп кенә баручы түгел икәнлеген төшенергә вакыт. Әдипләрнең XX йөз башында халкыбызны наданлыкта һәм артталыкта тәнкыйтьләве дә бары тик әдәби идея буларак махсус кабартылган фикер икәнлеген аңларга вакыттыр.

Икенчедән, К. Насыйри фольклористикага тел гыйлеме белән шөгыльләнә башлаган елларында ук игътибар итә. Ул, Казан татарлары сөйләше нигезендә татар телен әдәби тел буларак гамәлгә кую өчен, халык авыз иҗатын өйрәнүгә алына, аның ярдәмендә тел үзенчәлекләрен гыйльми тикшерү эшенә керешә. Халыкның җанлы сөйләме аңа күптөрле кызыклы материалларны һәм хикмәтле гыйлемнәрне барларга булыша. К. Насыйри үзе дә рәхмәтле булып кала һәм халыкның җанлы сөйләмен өйрәнеп, аның матурлыгын аңлап, аны әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрә. Бу юлдагы эзләнүләре фәнни фикерләмәләренең дөрес юнәлештә алып барылуын төшенергә дә ярдәм итә. Әдип чын мәгънәсендә халыкчан язучы буларак

[1] Татарский энциклопедический словарь / гл. ред. *М.Х. Хасанов.* – С. 369.

формалашып өлгерә. Аның хикәят һәм кыйссалары бүгенге көндә дә безне сокландыралар. Җанлы һәм сурәтле әдәби тел ул чорның кайсы татар язучысында аныкы кебек камил иде икән?

Өченчедән, К. Насыйри Шәрык халыкларының авыз иҗатлары ядкярләре белән бергә, язма әдәби мирасларының нәкъ менә фольклорга иң якын торган үрнәкләрен халкыбызга җиткерә, шуның белән безне Шәрык мәдәниятенә тагын да ныграк якынайта. Аның ул ядкярләрне халкыбызга җиткерүенең төп сәбәбе халкыбызның да алар белән кызыксынуына бәйле булган, билгеле. Гомумән дә бу өлкәдәге К. Насыйриның эшчәнлеге туктаусыз мактауга лаеклы.

Дүртенчедән, К. Насыйриның төп хезмәтләре татар фольклорын барлау, җыйнау, системага салу һәм халыкка кабат кайтару белән дә бәйле. Ул болар белән чын фольклорист галим буларак шөгыльләнә һәм татар фольклористикасы фәнен гамәлгә куюга ирешә. Аңа кадәр бу өлкәдәге эшне аның кебек дөрес юнәлеш тотып, аңлап һәм белеп башкарган бер генә галим дә булмаган. Дөрес, кызыксынучылары шактый, әмма алар фольклорист буларак түгел, бәлки этнограф яки тарихчы, яисә телче сыйфатларында, үз фәнни эзләнү һәм тикшерену өлкәләре белән бәйле юнәлештә эш алып барганнар. К. Насыйри исә халык авыз иҗатын өйрәнүнең зарурлыгын һәм әһәмиятен ачык күзаллап эш иткән, бу өлкәдә күләмле, тарихи һәм гыйльми әһәмияткә лаеклы хезмәтләр язган. Бу очракта аңа әдиплеге, язучылыгы ярдәм иткән, этәргеч биргән. Башка халыкларны да татар фольклоры белән таныштыруны ул кирәк тапкан һәм гыйльми мәкаләләр белән рус матбугатында да чыгышлар ясаган.

Бишенчедән, татар фольклористикасы барлыкка килүдә һәм аның үсеп китүендә Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» һәм аның туплап бастырып килгән фәнни альманах-җыентыклары зур ярдәм иткәннәр. Бу өлкәдә Н.Ф. Катановның эшчәнлеге аерым әһәмияткә лаеклы. Аерым алганда, В.А. Мошков кебек этнограф галимнәрнең дә татар фольклорын өйрәнү белән бәйле эшчәнлегенә игътибар бирергә вакыт. Аның фәнни җыелмалар нигезендә төзегән, мәкаләбездә анализланган язма хезмәте татар фольклорының кызыклы катламын яктырта, киң җәмәгатьчелеккә дә ул туплаган фактлар күптән ачылырга тиеш иделәр.

Алтынчыдан, М.А. Мошков барлаган риваятьләр һәм мифлар татар халкының ырым һәм ышануларының шактый катлаулы үсеш һәм үзгәреш кичүен күзалларга булыша. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанының халык күңеленә никадәр тирән үтеп керүен дә төшенергә алар ярдәм итә. В.А. Мошковның мәкалә-тупланмасы белән күптән фәнни әйләнешкә кертелеп тә, ни өчендер игътибардан читтә калдырылган кызыклы риваятьләребез, мифларыбыз булганлыгын ачыклау үзе бер әһәмиятле гыйльми яңалык буларак бәяләнә ала.

Шулай итеп, XIX йөз татар фольклористикасында ике төп фәнни көч мәйданга чыккан, аның берсе – халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын, телен һәм дөньяга карашын яхшы белеп, аның үзендә тәрбияләнеп үскән вәкил буларак, К. Насыйри кебек фидакярләрчә хезмәт итүчеләр, икенчесе – яңа буын зыялы рус галимнәре, алар татар халкының эчке дөньясы белән фәнни нигездә кызыксына башлыйлар, аның авыз иҗатын өйрәнү аша үзләренең һәм рус халкының да дөньяга карашларын киңәйтәләр.

Бу фәнни көчләр татар фольклористика гыйлемен XIX гасырда ук башлап җибәрәләр, аның төп үсеш юнәлешләрен билгелиләр. Алар, ягъни ул тенденцияләр, беренчедән, халык авыз иҗатын барлау һәм җыйнап бастырып чыгарудан, икенчедән, аны фәнни яктан системага салып бәяләүдән, үсеш закончалыкларын ачыклаудан гыйбарәт булалар.

## М. Акмулла иҗатының тарихи әһәмияте, әсәрләренә текстологик анализ

### I

Мифтахетдин Акмулла (1831–1895) – татар шигъриятендә ике төп борылышның икенчесен башлаган һәм тормышка ашырган шагыйрь. Аның беренчесе, – әйтергә кирәк, мөгаен авырыдыр, Габделҗәббар Кандалый иҗаты белән бәйле рәвештә булды. Тагын да шунысын алдан ук белдереп куярга тиешбез: Габдерәхим Утыз Имәнинең бу хәрәкәтләргә нисбәтән мөнәсәбе юк иде.

Шушы борылышлар, бәлки, үзләреннән-үзләре, тарихи-мәдәни процесс сәбәбеннән барлыкка килгәннәрдер? Әмма монда ша-

гыйрьләрнең үз ихтыярларын бөтенләй исәптән чыгарып ташлау хата булыр иде.

М. Акмулла – татар шигърияттен идея-проблематиканың куелышы ягыннан кискен үзгәртеп җибәргән шагыйрь буларак хаклы рәвештә характерланырга тиешле әдип. Моның өчен аңа Ш. Мәрҗани шәхесенә булган мөнәсәбәтеннән чыгып кына бәя бирү аз. Әйе, галимнең әдәби образын ул мәйданга куйды, халыкка белдерде. Бу зур эш, батырлык иде. Әмма аның бөеклегенең хикмәте анда гына да түгел!

М. Акмулланы татар фәне «җәдитче» дип тә, «мәгърифәтче шагыйрь» дип тә атый. Моңарга без дә каршы түгел, әмма җәдитче белән мәгърифәтче дигәннәребездә аермалар барлыгын онытып җибәрмик. Бәлки, тарихчы галимнәр өчен барыбердер, әмма әдәбият фәне бу мәсьәләгә сак карарга тиешле. Бездә тарихи сәбәпләр аркасында җәдиди хәрәкәтне, аңа бәйле туган җәдитчелекне мәгърифәтчелек, хәтта ренессанс-яңарыш дип күзаллыйлар, аларның үзара мәгънәдәш сүзләр түгеллеген исәпкә алып тормыйлар. Моны социализм дәверендә җәдитчелекне дөрес аңламау һәм аңлатмау аркасында туган күренеш дип бәяләми мөмкин түгел. Югыйсә бу хатаны һәм аның белән барлыкка килгән буталуларны ничек акларга мөмкин? Дөрес, җәдитчеләр мәгърифәт байрагын югары күтәрделәр, әмма ул әле сәбәп түгел, сәбәпнең нәтиҗәсеннән гыйбарәт күренеш иде.

Җәдитчелек татар буржуаз демократиясенең XX йөз башында рәсми идеологиясенә әверелде. Бу исә татар буржуазиясенең аерым сыйныф буларак оешып җитүенә һәм милләтнең әйдәп баручы көченә әверелүенә бәйле иде. Димәк, җәдитчелек, – идеология буларак, әдәби түгел, бәлки иҗтимагый күренеш. Шулай икән, әдәбият тарихына бәйле рәвештә без аны ничек аңлатырга тиешбез, дигәндә, әлбәттә, идеологиягә бәйләнештә аңлау хәерлерәк икәнлеген ассызыклау белән генә чикләнә алмыйбыз. Җәдитчелекнең татар фикере үсешендәге роле һәм милли мәгариф системасына ясаган йогынтысы инде тикшерелеп, шактый гына кызыклы күзаллаулар һәм белем системаларын тудырды. Әмма әдәбиятка бәйләнештә җәдитчелекне өйрәнү, дөресрәге – җәдитчелек белән бәйле татар әдәбияты тарихын тикшерү эше XX йөзнең 20 нче еллары дәрәҗәсендә кала бирде дисәк тә әллә ни ялгыш сүз булмас. Шулай

итеп без, М. Акмулла хакында фикер әйтергә җыенганда, аның җәдитчелек вәкиле икәнлеген ассызыклаудан эшне башларга тиешбез. Текстологик анализ өчен текстка нинди карашлар системасы белән якын килергә кирәклеген белүдән тыш, ул текстның кайсы әдәби алымны яки методны кулланып язылуын ачыклау төп шартларның берсе булып тора.

Җәдитчелекне без татар милли буржуазиясенең асыл идеологиясе булуын ассызыклап тагын бер кат искәртеп үтәргә тиешбез. Әгәр дә ул аның идеологиясе икән, М. Акмулла шушы җәдитчелек әдәбиятының төп вәкиле саналгач, ул ничек казакъ яки башкорт туганнарыбызга бәйле шагыйрь була ала соң? Без хәтта, мәсәлән, рус әдибе И.С. Тургеневның да татар каныннан булуын яки А.С. Пушкинның да эфиопларга нәсел башы барып тоташканын беләбез. Бу исемлек бик озын, аны санаудан монда мәгънә юк. Әмма аларга мөнәсәбәтле аерым мәсьәлә бар: болар кем язучылары-әдипләре соң? Әлбәттә, рус әдәбияты вәкилләре! Ни өчен? Чөнки рус әдәбияты, аның ярдәмендә рус халкының мәнфәгатен яклауга, аның аша рус халкының бөек мәдәниятен үстерү өчен, алар хезмәт иткәннәр! Әйе, рустан гайре халыклар турында да язганнар, башкаларның да мәнфәгатьләрен яклаганнар. Әмма шушыларга карап кына рус әдәбиятыннан аларны чыгарып ташларга тиешбезме? Алар әле әсәрләрендә, мәсәлән, француз сүзләрен дә кулланганнар. Әмма моңа карап без аларны француз әдипләре дип атарга тиешбезме? Юк, әлбәттә. Рус әдәбиятын һәм мәдәниятен алардан башка күз алдына китерүе мөмкинме соң? Ә татар әдәбиятын ничек Акмулласыз калдырып була? Аның казакъ икәнлегенә дә, башкорт белән бәйләнешенә дә каршылыгыбыз юк. Безнең бөек мишәребез Габдерәхим Утыз Имәни дә «башкорт» аталган ләбаса! Әмма алар бит татар әдәбияты үсеше өчен хезмәт иткәннәр һәм, әдип буларак, татар әдәбияты вәкилләре булып торалар. Әллә Гали Чокрый яки Таҗетдин Ялчыгол «башкорт» аталган түгелләрме? Аңа карап кына без аларны татар әдәбияты тарихыннан һәм мәдәниятеннән чыгарып ташларга, татар әдәбияты һәм мәдәнияте үсешләрендә рольләре юк дип белдерергә тиешбезме? Язган хезмәтләре, әлбәттә, бәяләп бетергесез һәм без дә мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз үсеше өчен шундый әдипләр «биргәннәренә» бөек башкорт халкына да мең рәхмәтлебез, казакъларны

да олыларга тиешбез. Әмма әдиплектә уртаклык мәсьәләләренә килгәндә, гафу, без аларны һәм алар белән бергә Акмулланы да татар милли мәдәнияте һәм әдәбияты үсеше системасыннан алып ташлый алмыйбыз, Акмулланың татар әдибе булуын хаклы рәвештә горурланып белдерергә тиешбез. Фәнни мәсьәләләрдә сәясәт уенын файдалану хакыйкатькә, гыйлемгә хилаф эш икәнлеген искәрсәк иде.

Шулай итеп, М. Акмулланы татар җәдитчелек әдәбиятының икенче этабына караган төп әдипләребездән берсе дип белдереп, моңа нисбәттә аның әсәрләрен бүгенге көндә ничек аңларга һәм кабул итәргә тиешлегебезне ачыклауны алга куябыз. Бу мәсьәләләрнең органик рәвештә үзара бәйле булуына инде тукталып узган идек.

Беренче карашка, әсәрләренең эчтәлегеннән, шигырьләрендә фикер корылышыннан чыгып тикшергәндә, М. Акмулланың хәтта XII йөз шагыйребез Әхмәт Ясәвидән дә әллә ни аерылып тормавын күрербез. Шундый ук дини-иҗтимагый фәлсәфә, фикер сөреше, агымы, шундый ук шигырь тукымасы, шул ук үгетнәсыйхәтчелек. Болар – татар әдәбиятының безгә мәгълүм булган 800 еллык дәвере буенча шулай бара, шигърият һаман да бер агымда килә, аның фикер һәм алым чикләре төгәл аңлашылып тора, яхшылыкка өйрәтә, дини булырга чакыра, гөнаһтан януны алга сөрә. Һәм менә XIX йөз башында Г. Кандалый үзгә агымны пәйда итеп, шул гасырның икенче яртысында М. Акмулла: «Шагыйрьләрдән сүз чыгар хикмәт белән!» – дип белдереп, татар әдәбияты мәйданында хикмәт, ягъни фикер фәлсәфәсенә тугры кала. Бу инде хикмәт жанрында иҗат итүгә чакыру дигән сүз түгел, бәлки шигырьдә хис белән фикернең берлеген таләп итү буларак та кабул кылына.

Шулай да М. Акмулла – татар шигъриятен яңа, үзгә агымга борып җибәргән әдип тә әле. Г. Ибраһимов аны татар прозасын яңа, Европа эзенә кертеп җибәргән Муса Акъегет белән янәшә куя[1]. Прозада М. Акъегетнең җәдитче әдип булуын, шигъриятта М. Акмулла икәнлеген аның дәлиленнән соң раслап торасы да юк.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. V. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 290.

II

М. Акмулланың әсәрләрен бүгенге көндә ничек аңларга һәм кабул итәргә тиешбез дигән сорауны алга чыгарып, әлбәттә, җәдитчелеге белән бәйле рәвештә генә төшенә, асыл эчтәлегенә ирешә алабыз дип җавап бирергә мөмкин.

Безгә кадәр дә шулай аңлаганнар, без дә җәдитчелекне «яңарту» буларак аңлатабыз. Әмма бу ренессанс мәгънәсендәге яңарту түгел, бәлки камилләштереп яңарту, ягъни мөкәммәләштерү, модернизация тибындагы яңарту. Моңа күптән игътибар итәргә тиеш идек инде.

Модернизмны татарда, термин буларак, җәдитчелек дип үз чорында ук атаганнар һәм бу бер дә сер түгел. Әдәбиятта без аны, иң әүвәле, европалашуда, икенчедән, миллиләшүдә күрәбез. Аңарга кадәр милли әдәбият булмаган икән дип күзалларга ярамый, әлбәттә. Җәдитчелек милли әдәбият кысаларын милли тел һәм күзаллаулар, милли эчтәлек белән тыгыз бәйләгән. Моңа кадәр ислам (Шәрык) мәдәнияте кысаларыннан тайпылмау, милли әдәбиятны ислам әдәбияты юнәлешендә үстерү эстетик карашларыбызның нигезен тәшкил итсә, инде җәдитчеләр яңадан-яңа идеяләрне алга чыгарып, әдәбиятның милли үзенчәлекләрен башкача аңлый башлыйлар. Әмма бу процесс җиңел һәм үз агымы белән генә бармаган, кадимчелекнең, ягъни иске карашларда торучыларның басымы әледән-әле көчәеп алу вакыйгалары белән озатыла килгән.

Җәдитче буларак М. Акмулла, Г. Кандалый башлаган юлны дәвам итеп, халык аңлаган телдә язуны алга чыгаручылардан санала. Ул чорда татар милли буржуазиясе барча Россия мөселманнары өчен үзен җаваплы тоеп, алдынгы сыйныф дәрәҗәсен ала бара. Һәрхәлдә, татар, башкорт һәм казакъ халыкларына милли буржуаз идеяләр, һаман да әлегә дини фикерләр белән төрелеп, киң җәелдерелә. Татар дөньясында 1850 еллардан башланып киткән телдә татарчалык, 1883 елдан аңа каршы булып килеп кушылган төрекчәлек ярышы[1] кискенләшә бара. Кырым һәм Кавказ төрки халыклары бу ярышны төрекчәлек файдасына хәл итү ягында торалар. М. Акмулланың исә турыдан-туры ул мәсьәләгә кагылышлы фикерләрен белдергән әсәрләре юк, әмма мөнәсәбәтен аңлар

[1] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. – Б. 98–99, 167–168.

өчен, шигъриятенең теленә игътибар итү дә җитә. Тел өлкәсендә шагыйрь, борынгы төрки традицияләрне дәвам иттерү белән бергә, җирле сөйләм сүзләрен актив куллану ягында тора. Әдәби телне халыклаштыру юнәлешендә әсәрләрен язуы сәбәпле шигырьләренә башкорт һәм казакъ сүзләре, сүз формалары да күпләп үтеп керә. Билгеле, мондый үзенчәлекле әдәби телне халкыбызга Әхмәт Уразаев-Кормаши үзенең «Бүзьегет» һәм «Таһир-Зөһрә» дастаннарында да тәкъдим иткән иде. Без аларны да XIX йөз әдәбиятының җәдитчелек агымына бәйле әдәби үрнәкләр буларак бәяләргә тиешбез.

Безнең татар мәгърифәтчелек реализмы асылда җәдитчелек әдәбияты, ягъни модернизм юнәлеше белән параллель, хәтта бергә үсеш алды. Моны милли әдәби-тарихи үзенчәлек дип бәяләү дөрес булыр. Шушы чорда рационалистик агымның да көч алуы хакында эндәшми киләбез. Безнең әдәбият фәнендә һәммә әдәби агымнарны һәм алымнарны-методларны бер термин артына яшерү күренеше яшәп килә. Моның хаксызлыгын галимә Д. Заһидуллина беренче булып дәлилләп чыкты түгелме? Без аның «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» хезмәтен күздә тотабыз[1].

Җәдитчелекнең асылы – яңартуда (иске карашларны дип тә әйтергә мөмкин, әмма тормышыбыз нигезен хасил иткән дөньяга карашларны дип билгеләү дөресрәк булыр), дөньяга караш системаларын үзгәртеп коруда, ягъни модернизацияләүдә, яшәешкә яраклаштыруда. Моның хикмәте нәрсәдә соң?

XIX йөзнең соңгы чирегенәчә әдәбиятыбыз үзенең үсешендә һаман да бер эздән күтәрелә килә. Европалашу гына аны бу эзеннән тайпылдыра ала, тип буларак әдәбият үзгәреш кичерә башлый. Бу – кискен һәм көчле яңару, җәдитләшү. Тик җәмгыять үзе моңарга каршы килә, чөнки бу яңарыш аркасында милли үзенчәлекләр юкка чыга баралар. Моны җәдитчеләр югыйсә дөрес аңлап эш итү ягында торалар. Алар миллилекне иң беренче чиратта ислам дине йолаларын саклау һәм ныгытуда күрәләр. Шул ук вакытта бу юнәлештә иске карашларда да кала алмыйлар, Әбун-Насыйр Курсави күтәреп чыккан фикер хөрлеген алга үстереп[2], дини карашларны яңарту

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 255.

[2] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 2. – Б. 21.

идеясе ныгытыла, картлар сүзенә таяну хата буларак аңлатыла башлый. М. Акмулла да «фәлән сәләф (бабай) фәлән нәрсә әйткән диләр» тезисы белән чыгыш ясый, карашларны фән нигезендә яңартып тәртипкә салуны, рационалистик юнәлешне тотуны җәмәгатьчелектән таләп итә. Әмма шагыйрь «сәләф сүзе» белән «борынгылар сүзен» нисбәтле, үзара мәгънәдәш бергәлектә аңламый һәм тәкрарламый. Аныңча сәләфләр һәм борынгылар бер үк төшенчәләр түгел. Моны дәлилләү өчен, шагыйрь Ш. Мәрҗанине үрнәк итеп күрсәтә, Хисаметдин Мөслими адресына, аның «Тәварихе Болгария» хезмәтенә бәйле рәвештә, кискен тәнкыйть белән чыга. М. Акмулла өчен Х. Мөслиминең шәхесенә бигрәк тә әдәп-әхлак принципларыннан чыгып бәя бирү әһәмиятле. Аның китабына каршы фикерләр белдерүдә ул Ш. Мәрҗанидән узмый, әмма сүзләрен кабатлап, Х. Мөслиминең хаталарын санап чыгуны кирәк тапмый, бәлки «нинди кеше булган ул шундый ялганчы» дигән рәвештә, усал сүзләрен куертып, шәхесенә төрттерә.

М. Акмулла өчен Х. Мөслими дә сәләфләр исемлегендә, алар һәр заманда да булган, халык менә шуларга ияру аркасында хаталанган, ә Ш. Мәрҗани кебек ирләр юлыннан барырга кирәк иде.

Шагыйрь менә шушындый җәдитчелек карашларында тора, әсәрләрен шушы юнәлештә аңлавыбыз аларны дөрес төшенергә һәм бәяләргә ярдәм итә.

М. Акмулла, никадәр генә без аны җәдитче-модернист дип әйтмик, борынгы әдәби традицияләрне дәвам иттерүче нәсыйхәтче шагыйрь дә булып тора. Билгеле булганча, нәсыйхәтчелек – бөтен Шәрык әдәбиятына хас күренеш. Хикмәт нәрсәдә соң, нигә Шәрык әдәбияты һәм XX гасыргача аның бер тармагы булган татар әдәбияты хәтта Г. Тукай иҗатында да нәсыйхәтчелек кысаларында кала биргән? Моның сәбәбе Шәрык әдәбиятының ислам дине идеологиясе белән сугарылган булуыннан килә, хәтта шигъриятне дини карашлар аерым кысаларда тота. Аның «шайтан чыбыркысы» *(хәдистән)* булмавы өчен Коръән нигезендә өммәткә тәрбия бирүе шарт, ягъни үгет-нәсыйхәт итүе тиешле. Шәрык суфичылык шигърияте шушы юнәлешне хис-тойгы белән 800 елдан артык, хәтта 900 еллар буена үреп бара алды. Моңардан бер тын белән генә котылу мөмкин түгел иде. Башкача шигырь, шигырь буларак кабул ителмичә, җыру мәгънәсендә кире кагыла, «бидгатьнамә»

атала иде. М. Акмулла нәкъ шушы каршылык белән очрашкан шагыйрьләрдән булды да. Әмма ул бу каршылыкны чишү юлын тапкан әдип икәнлеген белдереп чыкты. «Шагыйрьләрдән сүз чыгар хикмәт белән» тезисын алга таба үстереп, бу мәсьәләдә хәдискә мөрәҗәгать итүне кирәк тапты һәм «Хатыннар биегәндә, пәйгамбәребез кулын чәбәкләп торды» дигән хәбәргә халык игътибарын юнәлдерде. Моның хикмәте исә диннең үгет-нәсыйхәт белән генә чикләнмәвен, кысаларны киңәйтү кирәклеген, хиснең кеше өчен дөньяны танып-белүдә әһәмиятен белдерүдән гыйбарәт иде.

М. Акмулла «сәләфләр» фикеренә каршы борынгы галимнәрнең дәлилләрен куя алды, аларның карашларына яңача күз салды һәм шуның белән әдәбиятта яңача яшәүне, яңалыкны яклаучы буларак күтәрелде. Без башка төрле Акмулланы белмибез. Аның бүгенге көн укучысына килеп җиткән әдәби мирасы тулысы белән җәдитче икәнлеген дәлилләп тора.

М. Акмулланың реалист шагыйрь булуында да, мәгърифәтчелек идеяләрен яклавында да һичбер бәхәс юк. Шуңа күрә дә аны әдәбият галимнәре татар мәгърифәтчелек реализмы вәкиле буларак бәялиләр[1]. Җәдитчелек-модернизм белән реализм арасында без шулай ук каршылык күрмибез, бәлки модернизмны романтик яки реалистик юнәлешләрдә бердәй була дип кенә билгелибез. Әмма мәгърифәтчелек реализмын модернизм агымы кысаларына кертүне аларның табигатьләренә каршы килә дияргә тиешбез. Димәк, М. Акмулланың җәдитче-модернистмы, әллә мәгърифәтче реалистмы булуы хакында бәхәсләр мәйданга алда да чыгачак әле.

Аның нинди агым шагыйре булуын төгәл күзаллар өчен, тулы иҗатына бердәм анализ ясарга кирәк. Моның өчен текстологик анализ принципларына мөрәҗәгать итәбез. Әдипләрнең тулы иҗатларына бердәм анализ ясау шактый катлаулы эш һәм монографик планда эзләнүләрне, фәнни-тикшерү эшен оештыруны таләп итә. Текстологик анализ юлы исә бу эшне шактый җиңеләйтә. Иң әүвәлдә әдипнең барлык иҗат мирасын яхшы күзалларга, бергә тупларга, аннары гына билгеле бер принципларны алга куеп, әсәрләрен шул нигездә төркемләргә тиешбез.

[1] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 2. – Б. 440–462.

### III

Әдипләрнең тулы әдәби мирасын төркемләүнең хронологик, монографик (ягъни тематик) һәм хронологик-тематик принциплары бар. Асылда, без беренче ике принцип белән эш итүче галимнәрне ешрак очратабыз. Соңгысы таләпләрендә язылган хезмәтләргә дәреслек мәкаләләрен кертә алабыз. Бу принципларның һәркайсын җөпләп аңлатуның монда кирәге юк. Хронологик-тематик принципны файдалану да фәнни эзләнү мәкаләсе өчен кулай түгел. Әдипләрнең иҗатларына анализ ясар өчен (бөтен бар, тулы иҗатлары хакында сүз бара), монографик (ягъни тематик) принципны сайлап алу уңышлы дип беләбез. Мисалга Г. Тукай иҗаты белән бәйле бер фикерне белдереп узасы килә: ул бөек шагыйребезнең әсәрләрен инде ничәмә еллар буе укучылар игътибарына хронологик принцип нигезендә тәкъдим итәбез (монда җыентыкларын, томлыкларын төзеп бастырып чыгаруларны күздә тотабыз) һәм китапларын «Мужик йокысы» яки «Государственная думага» шигырьләренең берәрсе белән ачабыз. Һәм алар аның шагыйрьлегенә бераз шик тә тудыруга сәбәпче булалар. Әгәр дә шунда монографик принципны сайлап алып, мәсәлән, шул ук «Государственная думага» шигырен «Китмибез!»е артыннан укучыга тәкъдим итсәк, ул «бичара» «Государственная думага» шигыренең эчтәлеге һәм шигъри яңгырашы күңелләргә мәгънә белән барып ирешер иде. Димәк, монографик принцип томлыкларны бастыруда уңышсыз юл түгел икән!

Шигырь җыентыкларын чыгарганда, Г. Тукайның тематик принцип белән эш итүенә Г. Ибраһимов та үз вакытында «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә игътибар иткән һәм моны «сәүдәгәрлек кылудан» күргән[1]. Бу юл белән бүгенге шагыйрьләребезнең дә эш итүен китапларыннан күрергә мөмкин. Асылда, алар һәммәсе дә шигырьләрен тематик яктан бер-берсен ача торган итеп төзергә тырышалар һәм шушы принципта җыентыкларын эшләп чыгаралар. Бу юл аларны уңышка китерә. Хронологик принцип исә иҗат мирасын «сыеклandырып», «сибеп җибәрә». Шунлыктан әдәби иҗат үзенчәлекләрен билгеләнгәндә тематик (монографик) принцип иң уңышлыларыннан санала ала.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. V. – Б. 111.

Әгәр М. Акмулланың иҗат мирасын төркемләсәк, аның «Дамилла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәре үзенә күрә аерым тематик төркемне хасил итүен ачыклаудан эшне башлау таләп итеәлә. Аның мәдхия алымы белән язылган мәрсия булуы сер түгел, фәндә мәгълүм факт[1]. Шуңа да карамастан, жанрын мәрсия (элегия) дип билгеләп, аны анализлаганда җиде кисәктән гыйбарәт булуын күрсәтүдән эшне башлый алабыз. Беренче кисәген «Шиһабетдин хәзрәтнең мәдхиясе...» дип тә атаганда дөрес булыр, икенчесен «Акмулла, күп сөйләмә, инде җитәр...», өченчесен «Бирелдем мин яшьлегемдә угрылыкка...», дүртенчесен «Акмулланың сүзе шул...», бишенчесен «Карасаң, Акмулланың «Диван»ы бу...», алтынчысын «Бәгъдәс-сәлам, Нургали мулла...», җиденчесен «Нургали мулла белән бәхәс» исемнәре белән аерырга тиешбез.

Асылда аларга бу исемнәрне авторның үз шигъри юлларыннан чыгып куябыз, ул кисәкләрнең эчтәлеген тулы килеш ачарга мөмкинлек бирүләренә игътибар итәбез. Аңлашыла ки, монда да нәкъ шул тематик (монографик) принцип белән эш итәбез, төркемләүне зур әсәрне анализлау, ягъни таркатуга, кисәкләргә бүлгәләү принцибына корабыз. Әсәрнең бу бүлекләре шактый катлаулы һәм мәрсия кысаларыннан чыгып китүен дәлилләп торалар, мәдхия генә дә түгеллеген аңларга ярдәм итәләр.

М. Акмулла бу әсәрен, әйе, Ш. Мәрҗанигә атаган, әмма мәдхия яки мәрсия итеп кенә түгел, бәлки үз уй-кичерешләрен шул «алмаз кебек галим» белән уртаклашу максатында да язган, чөнки һәр шигъри кисәге аерым бер эзлекле фикергә этәрә, мөрәҗәгать тойгысы калдыра. Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд үз кичерешләрен ханнар белән уртаклашкан булса, XIX йөз ахыры әдибе М. Акмулла бәхетенә фикер алышыр өчен бөек галим бар, менә шуңа горурлык хисләре кичерә ул, дан һәм мактау сүзләрен мул куллана түгелме? Әсәрдә авторның «сәясәте» шигъри алымга әверелеп киткәне, хәтта стильгә тәэсир иткәне сизелеп тора.

Шагыйрьнең иҗат мирасының икенче төркемен үз язмышына зарланган әсәрләре тәшкил итә. Алар беренче төркем белән шактый авааздаш та әле: «Гаҗәп һәркем – гани булса...», «Йа Хода, юлыңда булсын бу газиз башым фида...», «Адәмнән һәва калмас –

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 2. – Б. 452.

гарип булмай...», «Һәркемне мулла димез алдаганда...», «Муллалык эше кыен – җүн белмәсә...», «Хат йибәрдем Ырынбург каласыннан...», «Минем кебек булыр микән бәхетсез...», «Акмулла, хәлеңне бел, үзең калай...» һәм «Хатимә». Аларда М. Акмулла үз язмышына карата суфичыларча мөнәсәбәттә тора, тәкъдирнең Аллаһы Тәгалә кулында булуын тәкрарлый, дөньялыкны кабул итмәвен әйтә, муллаларны наданлыкта гаепли, кешенең күңеле тулы фетнә икәнлеген белдерә. Шушы әсәрләрендә ул үзен чын мәгънәсендә суфийана шагыйрь итеп күрсәтә. Моның сәбәбен борынгы әдәби традицияләрне яңартуыннан һәм модернизацияләвеннән килә дияргә кирәк. Шагыйрь суфилык-диндарлыкны эчке халәт итеп тоя, күрә.

Болар янәшәсендә М. Акмулланың нәсыйхәт бирү юнәлешендә язган «Аһ дәрига, безнең җортта җук иттифак...», «Бөрадәр, чын мулла кем, беләсезме?..», «Мамәрдкә сүзең зая – ялынсаң да...», «Үткән җук алдымыздан хәвеф-хәтәр...», «Айтамын үгет кылып казакъ халкын...», «Тугрылык бу заманда корып калган...», «Адәм шул – гадел булып, диндар булса...» әсәрләрен алырга кирәк. Аларда бер үк әдәби мотивлар, шул ук тематика кабатлана диярлек, әмма аермасы шигъри композициядә һәм үгет аша акыл бирү, акылга өйрәтү эчтәлегендә булуларында. Бу бүлекне «М. Акмулла нәсыйхәтләре» дип атарга мөмкин. Казакъ теленә тартым язылган «Кыпчак эче Карабалык – карагызлар...», «Һәр заман сүз башланыр бисмилладан...», «Бәгъдәс-сәлам мин мосафир Акмулладан...», «Әссәламәгаләйкүм, асыл зата...» шигъри әсәрләре дә шул ук рухта язылганнар. Шагыйрь үгет-нәсыйхәтләрен халык эчендәге җитешсезлекләрне шәригать, әдәп-әхлак таләпләрен белдереп тәнкыйтьләү ашау бирә. Үгет-нәсыйхәтләрендә суфичылык фәлсәфәсе нигезендә торуы аның борынгылардан әллә ни ерак китмәвен күрсәткән кебек тоелса да, М. Акмулла фикерләмәләрне конкрет тормыш вакыйгалары белән бәйләнештә куя белүе белән әдәби иҗатта алга чыга. Ул тормыш материалын үз күңеле аша уздыра һәм дини белеме ярдәмендә тудырылган әдәп-әхлак карашларыннан чыгып аларны бәяли. Шул рәвешле, М. Акмулла конкрет тормыш материалы белән эш итә, фикер йөртүдә рационалистик карашларда торса да, чынбарлыкны тасвирлауда реалистик планда язса да, киләчәккә өмет уятучы романтик юнәлешне дә иҗат манерасы итеп ала. Аңардан аермалы буларак, мәсәлән, Г. Кандалыйда натурали-

стик сурәт тудыру көчле, ул хәтта публицистик планга да авыша, ә М. Акмулла тормышны чагылдыруда реализмнан читкә тайпылмый.

М. Акмулланың иҗат мирасындагы 14 әсәр аерым дүртьюллыклардан тора һәм формалары буенча *кыйтга* жанрына карый. Алар, шигъри кисәкләр буларак, хиснең тулы чагылышын бирмиләр, шигъри фикерне каләм очына алу, кәгазьгә төртеп кую буларак боларны кабул итәргә тиешбез.

Шуларның берсе алты шигъри юлдан, тагын берсе исә бишьюллыктан гыйбарәт.

Дөрес, ул кыйтгаларны аерым төркемгә җыю, асылда, тематик төркемләү принцибына каршы килә, шулай ук казакъ теленә тартым әсәрләрен аерым бүлек итеп чыгару да уңышлы түгел кебек аңлашыла. Шунлыктан М. Акмулланың иҗат мирасын өч өлештән тора дип билгеләү дөресрәк булыр иде. Аның бер өлешен Ш. Мәрҗани шәхесен әдәби образ дәрәҗәсенә күтәреп сурәтләү белән бәйле дип алсак, икенче төркемен үз язмышын сурәтләп бирүеннән гыйбарәт дияргә мөмкин, өченчесен чорны-заманаы тасвирлау ярдәмендә үгет-нәсыйхәт итүче шигъри әсәрләреннән тора дип бәяли алабыз.

Бу рәвешле төркемләү уңышлырак төсле. Әмма шунысы да бар: М. Акмулла кайбер әсәрләрендә бу өч теманы бергә куша яки ике теманы берләштерә. Шулай да, темаларга бәйләнештә әсәрләрен төркемләп җыйган очракта да, шагыйрьнең аерым бер тематиканы доминанта итүен истә тотарга, шушы рәвешле әдәби абстракт фикерләүгә ирешүен исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән:

Һәр җәүһәрнең асыллыгы – алтын ташы,
Берәүнең – милиун сумлык кара башы;
Сөягең сөягемнән ким димәймен,
Затыңыз – затымызның садакасы!

Монда *садака* дигәнендә бөтеннең өлеше дигән мәгънә күздә тотыла, чөнки садака, зәкәт, хәер, бөтеннән өлеше аерылып, Аллаһ каршында кабул булуы теләнеп бирелә. М. Акмулланың «затыңыз – затымызның садакасы» дигәнендә, шулай итеп, бөтен белән кисәкне чагыштыруы аңлашыла. Бу кыйтгада шагыйрьнең үзен кем дип күзаллавы белән үгет-нәсыйхәт, ягъни акыл бирүе бергә бәйләнештә бирелгән.

Тематик яктан бу кыйтганы шагыйрьнең үзе турындагы шигырьләре рәтенә кертү уңышлы булачагы әсәрнең төп фикер салынган кисәгеннән чыгып анализлаудан да аңлашыла башлый. Димәк, төркемләү өчен әдәби әсәрләрне әүвәле анализлап-аңлатып чыгарга тиешбез, аннары гына аларны темаларга беркетү дөрес булачак.

IV

М. Акмулланың әсәрләре композицион яктан катлаулы түгел, әмма фикер үстерелеше белән шигырь структурасы бәйләнешендә гадәти булмаган очраклары шактый очрый. Бу аның бер әсәр эчендә өч теманы бергә җыюыннан килә. Әмма бу очракта аның әсәрләрендә фикер үсешенең структур бәйләнеше һәр строфада ничек органик бербөтенлек хасил итә алган соң? Алар таркаулык тойгысы калдырмыйлармы? Һәм без «һич юк» дип җавап бирергә мәҗбүрбез, чөнки ул доминанта фикерне аерып чыгара белә.

Мәсәлән, М. Акмулланың үз язмышына багышланган һәм үгет-нәсыйхәт бирүгә корылган шигъри әсәрләренең строфалары әүвәле бер фикер әйтелеп, аннары ул фикерне тулы килеш яисә өлешчә инкяр итү төсмерендә яки куәтләү аша хикмәтле, мәгънәле нәтиҗә чыгаруга корылган. Моның шулай булуын шагыйрьнең бигрәк тә «Хатимә» шигыре ачык күрсәтеп тора, ул тулысынча диярлек шушы конструкцияне кабатлый.

Дус дигәндә – риядән зәррә микъдар булмасын,
Дөньясы тар улса улсын – күкрәге тар улмасын.

Беренче строфадан ук шулай башлап китеп, әсәренең ахырынача бу үзенчәлек саклана. Аның инкаре – раслау, раславы – инкяргә әверелә. Бу исә әйтелгән фикерне тагын да куәтләндерә, шигъри сүз хикмәт сыйфатын ала. Раслауны инкяр итү төсмере белән белдерү шагыйрьгә әсәренең эчтәлеген киңәйтергә мөмкинлек бирә.

М. Акмулла гадәти тасвирларда гына сурәтләүче шагыйрь түгел, гади бәян итү формаларын да өнәп бетерми, ул – раслаучы. Аның шигъри фикерләү рәвеше шундый. Моның өчен шигырьне яки раслау һәм инкяр итү тонына кору хәерле, чөнки башкача юл белән укучыны шагыйрь үз фикерләрен кабул итүгә этәрә алмый. Әмма аның инкяре дә раслый, автор теләгән төгәл белдерүгә хезмәт итә. «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе», мәсәлән, раслап бару юнәлешендә язылган. Моның өчен аңа бәян итү алы-

мына да тартылырга кирәк булган югыйсә. Без бу очракта әсәрдәге бәхәсләшү тонына корылган урыннарны күздә тотабыз. Ул монда бәян итү формасы белән бәйле публицистик алымны гына файдаланып калмый, аның раславы коры тезмәләр белән генә дә чикләнми, бәлки алар сурәтле-метафорик раслау булып әвереләләр. Сурәтле-метафорик раслауларны М. Акмулла гадәти атау алымнары, хәтта *эт, үгез, кишер* дип ярым сүгенүләр куша барулар белән дә тудыра. Ул аңлатып тору ягында түгел. Раслау интонациясе белән әйтелгән фикерне дәлилле буларак күзаллата, аның шигыре шуның аркасында ышандыра һәм укучыга тәэсир итә, уйландыра. М. Акмулла хәтта юклык формасын да барны раслау итеп куллана, мәсәлән:

Зәррәдәй гаебеңне күрә калса,
Гаурәтне җамауга – бар, ачмауга – юк!

Мондый формалар аңа шигъри агымны монотон итүдән саклау чарасы сыйфатында хезмәт итәләр. Бу исә фикерне бер төенгә җыю һәм бер ноктага юнәлтү өчен дә уңай.

Шулай итеп, М. Акмулла укучы алдына раслау интонациясе белән фикер йөртүче шагыйрь буларак килеп баса. Мондый юнәлештә иҗат итүе аны көчле рухлы итә. Ул шигырьләрен бер-бер әһәмияткә ия фикерне раслау яки инкяр итү калыбына кора, әмма үгет-нәсыйхәт һәм публицистик юнәлеш юлларын киңәйтеп, образлы чагыштыруларны һәм әдәби сурәт чараларын мул кулланып, укучыга үз мәгънәләрен тәкъдим итә.

Казанда бер фазыл чыкты алмас булып,
Хасидләре күбәйде гамь-хас булып,
Мәганә җәваһирен кулга элгән –
Хакаикъ диңгезендә гаувас булып.

Аның бу шигъри юллары суфичылык символикасына корылганнар, гүяки һаман ул да Ә. Ясәви һәм С. Бакырганилар эзеннән бара кебек. Әмма монда инде яңа эчтәлек бар. Ул исә үз заманы шәхесен әүлиялар, изгеләр мәртәбәсендә күрә белү көченнән, замандашына пәйгамбәргә соклангандай соклана белү бәхетеннән килә.

V

М. Акмулла әсәрләрендә шигъри юллар һәм аларга аңлатма-шәрехләр, ягъни интерпретацияләр замана үзгәреше белән бергә тирәнәя дә бара. Моның өчен милли тарихыбызны, милли фикер

үсешенең эчтәлеген тирәнрәк төшенә бару ярдәм итә. Акмулланың шигырьләрендә замандашлары гыйсъянчылык күрсәләр, без аларда тарихилык һәм халыкчанлыкны табабыз. Ул телдә генә түгел, уйда-фикердә дә, төрекчелек ягына бармыйча, татарчалык юнәлешендә хәрәкәт иткән һәм XIX йөзнең икенче яртысы өчен төп шагыйребез булды. Әмма аның телендә гарәп-фарсы сүзләре дә шактый иде. Шулай да алар инде төркиләшкән, дөресрәге, татарлашкан иделәр, үз чорының гади халкы аңлаган һәм кулланган мәгънә вариантларында булдылар. Ә бу исә бүгенге көн текстология фәненә авырлыклар китереп тудыра. Һәр чорның-заманның үз мәгънәләре булган кебек, сүзләренең дә эчтәлекләре төрлечәрәк.

Сүзләренең төгәл мәгънәсен ачу һәм билгеләү М. Акмулланың әсәрләрен дөрес төшенү, фикерләренә төгәл бәя бирү өчен дә кирәк. Барыбызга да билгеле, ул әле җирле сөйләм сүзләрен, әле Себер татарлары һәм башкорт, казакъ гыйбарәләрен уңышлы файдаланган шагыйрь дә. «Акмулла хакында бары стихияле рәвештә «катнаш» телдә язучы шагыйрь сыйфатында хөкем итәргә ярамый»[1] дип, шагыйрьнең әсәрләрен текстологик яктан әзерләп бастырган галим М. Госманов хаклы рәвештә күрсәтмә ясарга кирәк тапкан.

Акмулланың шигырьләре XIX йөз татарчалык юнәлешен тоткан әдәби фикерләүнең үзенчәлекләрен дә үзләренә җыйган иде, билгеле.

Хәл килсә, төрле фәнне күргән яхшы,
Камилләр катарына кергән яхшы,
Урысча укып кына түгел белмәк –
Хәл килсә, французча белгән яхшы, –

дип яза ул «Бөрадәр, чын мулла кем, беләсеңме?..» шигырендә һәм тел белән динне бер бәйләмдә карамау тиешлеген белдереп чыгыш ясый.

Шушы строфада «камилләр катары» хакында искә алына. Бу исә «гыйлемдә камиллеккә ирешүчеләр төркеме»н аңлата, «катар» дип, асылда, «кәрван»ны атыйлар, «көтү» һәм «төркем» мәгънәләрендә дә аны аңларга мөмкин. Әмма ул очракта мәгънә тупаслана. «Камил кешеләр кәрваны» дигәндә мәгънә шигъри төсмер ала, Ә. Ясәви, Колшәриф кебек урта гасырлар дәвере әдипләре

[1] *Акмулла*. Шигырьләр / төзүчесе, сүз башы мәкаләсе һәм искәрмәләр авторы *М.А. Госманов*. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – Б. 30.

хәбәр иткән «суфилар силсиләсе» күз алдына килеп баса. Алар да фикердә һәм гамәлдә үзләреннән тарихи алдагы галимнәрнең «итәгенә ябышып» баруны мактап язган иделәр түгелме?

> Фәйзе Хак һәр мескинә шарт имәс Багдад, Хәләб,
> Йорты Болгар булса булсын – йортны болгар булмасын!
>
> (*Ягъни:* Аллаһы насыйбы белән һәр суфига Багдад яки
> Хәләбтән булуы мәҗбүри түгел, Болгардан булса да ярый,
> әмма илне болгатучы булмасын!)

Бу шигъри юллар М. Акмулланың «Хатимә» шигыреннән, бүгенге көндә дә теллдәрдән төшмәгән гыйбарә булып тора. Ул, шушы рәвешле мәгънәдәш сүзләр кулланып, укучыны уйланырга мәҗбүр итә белә. Омонимнарны оста файдаланып, шагыйрь гарәп һәм фарсы алынмаларына еш мөрәҗәгать итә. Бу хәл исә текстологларны тагын да каршылыклы, хәтта бәхәсле эзләнүләр эчендә адаштыра. Шул сәбәпле М. Акмулла әсәрләренә өстәмә шәрехләр бирү мәҗбүрияте туа һәм ул эш, әдәби әсәргә текстологик анализ биргәндә, төп шартларның берсенә әверелә.

Татар әдәби ядкярләре гомумән дә шәрехкә мохтаҗ. Бу аларның зур мәдәни традицияләр тәэсирендә язылулары сәбәбеннән килә. Монда без М. Акмулланың һәр әсәрен дә шәрехләп бирә алмыйбыз, әмма шуны белдерергә тиешбез: хәзерге вакытта иске китапларны юл асты сүзлекчәләр белән баетып бастырып чыгаруны «шәрехле басма» дип атап йөртү урынлы. Чөнки алар гадәти сүзлекчәләр генә түгел, күбесе аңлатмаларны эченә алган шәрех төсмерендә биреләләр түгелме?

## VI

М. Акмулладан иң каһәрләнгән кешеләрнең берсе – истәк мулла. М. Госманов бу сүзгә аңлатма биреп, болай яза: «Акмулла башка әсәрләрендә дә башкортларны шулай «истәк» дип атый»[1]. Шагыйрь «истәк мулла» атамасын казакъ старшинасы Исәнгилдегә бәйле дә куллануы әсәрләреннән аңлашыла. Бу сүзнең мәгънәсе нинди һәм каян килеп чыгуы да кызыклы. Әгәр дә М. Госманов фикере дөрес булса, Исәнгилде түрәне башкорттан чыккан шәхес дияр идек. Шуны күздә тотып булса кирәк, М. Госманов «истәк –

---

[1] *Акмулла*. Шигырьләр. – Б. 252.

башкорт, казакълар тарафыннан кулланылган этноним»[1] дип атап фикер йөртә.

Ә кемнәргә карата кулланылган этноним соң ул? Бәлки, М. Госманов монда башкортларның һәм казакъларның «истәк» дип аталуларын искәртергә телидер?

Текстологик анализ – гомуми аңлатмалар таләп итүче гыйбарә, хәтта абзацларны барлап, аларның мәгънәсен ачыклауны да үз өстенә алудан башка була алмый. М. Акмулла иҗатына килгәндә, бу эшне М. Гайнуллин, М. Госманов, Р.Әхмәтов һ.б. галимнәр этрафлы башкардылар. Әмма «истәк мулла» кушаматы, безнеңчә, әле аңлатуны таләп итә.

Истәк белән Исәнгилде арасында берникадәр аваздашлык бар һәм ул үзен сиздереп тора. Тик текстологик аңлатма өчен бу гына җитми, дәлилләп бирү, раслаучы чыганакларны барлау, аларга таяну сорала. Без бу сорауга җавап эзләп карадык, әмма таянырлык хәбәр табылмаган иде. Шулай да татарда «истәк» һәм «иштәк» атамаларының параллель кулланылуын билгеләп үтәргә тиешбез.

*Иштәк* дип Себер татарларын атау әле XX гасыр башында кулланылышта булган. Бу – кызыклы факт. Бездә Казан татарларын *чохым* (*ч* авазы белән сөйләшүчеләр яки чокырда яшәүчеләр, ягъни Казанны шулай түбәнсетеп-шаяртып әйтү, «казаннар» мәгънәсендә), көнбатыш диалект вәкилләрен *мишәр* дип аеру гадәте бар. *Чохым* яисә *чокым* бик кулланылмаса да, *мишәр* атамасы телдән төшәргә җыенмый. Ә менә *иштәк//истәк* дип Себер татарларын аерып атап йөртү гадәте бөтенләй диярлек онытыла төшкән. Моның дәлиленә Р. Фәхретдин тарафыннан Оренбург шәһәрендә «Шура» журналына кушымта буларак чыгарылган «Тел ярышы» җыентыгының 1910 елгы 63 номерлы «Ата-бабадан сөйләнә килгән» дип аталган «Тройскида мөгаллим Әхмәт Туктабаев» исеме белән имзаланган мәкаләне китерергә була. Автор сүзне «Табуллык улдыгымнан» дип башлап китә. Аның язмасында: «Бу көндә суның түбән агымнарында җәелгән «иштәк» дигән курчакга табынучы кешеләр илә безнең телемез бер булган»[2], – дигән сүзләр бар һәм аларның бер өлеше ислам диненә күчкәнлеге дә искәртелә. Димәк, *иштәк//истәк* атамасы

[1] *Акмулла*. Шигырьләр. – Б. 252.

[2] Тел ярышы / Мөтәртибе *Ризаэтдин бине Фәхретдин*. – Оренбург: «Вакыт» мәтбагасы, 1910. – Б. 155.

белән Себер татарларын мәҗүси вакытларында ук белдергәннәр булып чыга. Хәзерге вакытта Төньяк Боз океанына таба Иртеш буйларында хант һәм мансий халыклары яши. Акмулла «истәк» атамасы белән шуларны искә ала дисәк, бик тә сәер һәм гайре табигый булыр. Борынгы Америка астеклары белән истәкләрне бер үк халык дип сүз җылытучыларны да аз ишетмәдек.

*Истәк//иштәк* этнонимының Себер татарлары белән бәйләнешен раслаучы дәлилебез ныклы. Башкорт һәм казакъ халыкларының иштәк дип аталмаулары ачык аңлашылып тора. Шулай ук бу атама-этнонимның географиясе шактый киң булуы да тарихлардан күренә. М. Акмулла аны Исәнгилде түрәгә атап кына кулланган дисәк, ул вакытта да сорау туа: ни өчен аны мулла дип белдерә икән соң? Бәлки, истәк мулланы без Акмулланың үзенә антиподы дип белергә тиешбездер? Тик бу сорауга җавап бирү өчен, бездә әлегә аргументлар җитешми, шунлыктан аны ачык калдырырга мәҗбүрбез. Әмма мондый фаразыбыз да бар: Исәнгилде себер татарларыннан булган, кайчандыр муллалык иткән, аннары казакъларга түрә итеп куелган, халыкта шул сәбәпләр белән бәйле рәвештә «иштәк мулла» дип аталып йөртелгән (ягъни «себер татары мулласы» мәгънәсендә). Хәер, әле XX йөз башында гына да Исәнгилдин дигән данлыклы себер татар байлары булган түгелме?

Бу урында М. Акмулла иҗатына ясалган текстологик анализның төп нәтиҗәләрен генә бәян иттек. Шуны аерым ассызыклап үтәргә тиешбез: тулы бер иҗатка текстологик анализ ясау шактый катлаулы эш. Аны аерым әсәрләргә бәйле рәвештә уздыру уңышлырак кебек күренә. Әмма бу фәнни анализ методы шактый киң планда да кулланыла ала.

## Акмулланың әдәби мәктәбе

Г. Тукай үзенең «Шигырьләребез»[1] дип аталган, «Фикер» газетасының 1907 елгы 22 нче апрель санында басылган мәкаләсендә, татар шигърияте үсешенә карата фикерләрен белдереп, М. Акмулла иҗатына да бәя биреп уза. Шунысы әһәмиятле: ул

[1] *Тукай Г.* Әсәрләр: биш томда. – Т. 4. Проза. Публицистика (1907–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 31–34.

монда үз өстәлендә яткан бер казакъ «үләңе», ягъни шигыре нигезендә бу уйларга килүен белдерә һәм гомумән дә казакъ шигъриятендә дөньяви мотивларның көчлерәк булганлыгын дәлилләп үтә, аннары Суфи Аллаһияр һәм Габдеррәхим Утыз Имәни иҗатларында суфичылыкның өстенлек алуын, аларның шигырьне «тик тәсаувыф бабында[1] гына сөйләгәннәр»ен әйтә, дөньяви мотивларның татар язма шигъриятендә бөтенләй үстерелмәгән булуына зарланып, андый юнәлештә шагыйрьләр иҗат иткән булсалар да, ул «шигырьләр шагыйрьләре берлә бергә кабергә күмелдеме?» дип ачынуын яза.

М. Акмулланың әдәби мирасына килгәндә, аның иҗатына да тәгассеп-схоластика катышканлыгын ассызыклаганнан соң, «безнең татар рухына, татар халкына бер дә тәэсире юктыр, шигырьләреннән тик казакъ исе, күчмә халык исе чыгып торадыр» дигән нәтиҗә ясый. Шуннан соң фикерен үз чоры шагыйрьләренә юнәлтеп, «безнең 17 октябрьдән соң мәйданга чыккан ике бөек шагыйребез үрнәкне шул мәрхүм Акмулладан алганнар булырга кирәк, чөнки шигырьләрен галибән[2] шул казакъ бәхре илә[3] язалар» дип, фәнгә мәгълүм булганча, Мәҗит Гафури һәм Нәҗип Думавиларны[4] М. Акмулланың шигъри мәктәбе вәкилләре буларак бәяләп уза. Академиклардан М. Госманов бу исемлеккә Дәрдемәндне дә кертә, Х. Миңнегулов исә «Дәрдемәнд иҗатындагы хас афористик фикерләү казанышлары» белән «Ш. Бабичның тәнкыйди сатирик рухлы язмаларында Акмуллага аваздаш яклар бар» дип конкретлаштырып, бу исемлектә Ш. Бабичны да саный[5]. Шулай итеп, ХХ йөз башындагы әдәбиятта М. Акмулла шигъриятенең традицияләре яшәүдән туктамаганнар, шагыйрьдән шагыйрьгә үстерелеп килгәннәр, хәтта бер әдәби юнәлеш хасил иткәннәр икән дияргә кала. Г. Тукай бер дә юктан гына бу турыда язмаган, билгеле. Аның сизгер күңеле әдәби процессны яхшы тойган.

---

[1] *Тәсаувыф бабында* – суфичылык юнәлешендә.

[2] *Галибән* – күбесенчә.

[3] *Бәхре илә* – шигъри үлчәме белән.

[4] *Карагыз: Тукай Г.* Әсәрләр: биш томда. – Т. 4. – Б. 296.

[5] *Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – Б. 136.

Әмма шуны да искәртергә кирәк: М. Акмулланың шигъри традицияләре М. Гафуриның иҗатында дәвам иттерелү хакында беренче булып аңлатып чыккан әдип Г. Тукай түгел. XX гасыр башы татар шигъриятенең Акмулла традицияләре нигезендә үсеш алуын «Морад» имзасы астында язган Р. Фәхретдинов 1906 елның 9 декабрендә үк белдереп уза. Ул, Г. Тукай шигъриятен әл-Мәгари иҗаты белән тәңгәл куюдан тыш, М. Гафурида фарсы шагыйре әт-Туграи үзенчәлекләрен күрә, әмма М. Гафури шигъриятенең асылда Акмулланы дәвам итүен ачык билгели[1].

Г. Тукайны Р. Фәхретдиновның бу мәкаләсе белән таныш булмаган дип әйтеп булмый. Аның «Шигырьләребез» мәкаләсен дә Р. Фәхретдиновка җавабы буларак күзалларга ярамый. Хикмәт шунда ки, Г. Тукай, 1905 елгы илдәге үзгәрешләр тәэсирендә мәйданга чыккан яшь шагыйрь, бары тик бик кыска ара эчендә, ягъни 1906–1907 елларда үзенә әдәбият мәйданын яулый башлый. Хәтта каләмдәшләренә карата да гаять кискен, мыскыллау дәрәҗәсендә диярлек чыгышлар ясаудан һичбер авырыксынмаган яшь шагыйрь, тәнкыйть мәкаләләрен генә түгел, хәтта әдәби әсәрләрен дә моңа кадәр яшәгән һәм барлыкка килгән әдәби традицияләргә каршы куйгандай иҗат итә. Моны тәрбия җитешсезлегенә генә дә кайтарып калдырырга ярамый. Бу дәвердә, иҗтимагый тормыштагы кебек үк, төрле мәнфәгатьләр каршылыкка киләләр. Шунысы әһәмиятле: ул мәнфәгатьләр һәммәсе дә тормышчан һәм яшәү көче белән сугарылганнар. Аларның кайсы хаклырак булганлыгын тарихлар үткәннән соң гына ачык күз алдыбызга китерергә мөмкинлек туды. Асылда, Г. Тукай, үз шигъриятенең көчен әдәбият мәйданында раслап чыгу өчен тырышуы белән бергә, халык күңеленә якын шигъри мәктәбен дә барлыкка китерә алды. Ә мондый зур һәм җаваплы адымны бары тик көчле рухлы әдипләр генә ясый ала. Бу хәзер дә шулай.

Г. Тукай, әдәби-эстетик карашларын раслау белән бергә, үзен әйләндергән әдәби мохитнең эчтәлеген һәм үзенчәлекләрен дә ачыклап аңлатып бирә алды. Бу чорда, билгеле булганча, аның иҗат кредосы белән каршылыкка килерлек куәтле әдәби агым – Акмулла башлаган һәм юнәлешен билгеләгән, Г. Ибраһимовның «Татар

[1] Вакыт. – 1906. – 9 декабрь.

әдәбиятында өч дәвер» дигән хезмәтендә аңлатылганча, «җәдит әдәбият» инде яшәп килә иде[1]. Г. Ибраһимов «Берничә сүз» (1921) дип исемләнгән мәкаләсендә бу дәверне болай дип характерлый: «Аврупа капитализмы арага керә башлый, матди тормыш үзенең иске үлек ноктасыннан кузгала, үзгәрү мәҗбүрияте килә. Шуның тәэсире белән бездә дини яңалык хәрәкәте туа – Шиһаб Мәрҗани, Насыйри, Курсавилар дәвере башлана. Бу дәвернең шагыйрьләреннән һәммәбезгә мәгълүм булганы – мәшһүр Акмулладыр»[2].

Прозада бу дәвернең башлангычын Г. Ибраһимов М. Акъегетнең «Хисаметдин менла»сына бәйли, Ф. Кәрими, Ярулла Вәли, Р. Фәхретдинов, Җ. Вәлидиләр белән бергә шушы «җәдитчелек әдәбияты» вәкилләре итеп Н. Думавины, М. Укмасины, Дәрдемәнд һәм С. Рәмиевләрне дә күрсәтә[3]. Әдәби процессны тикшерүгә багышланган мәкаләләренең һәркайсында диярлек Г. Ибраһимов шушы фикерләрен туктаусыз кабатлап бара һәм М. Гафурины татар әдәбиятында, аерым алганда, «Берничә сүз» мәкаләсендә, Акмулла традицияләрен үстереп җибәрүдән башлап, җәдит, ягъни мәгърифәтчелек, буржуаз милләтчелек, ягъни тәнкыйди реализм һәм эшчеләр әдәбияты, ягъни социалистик реализмга, өч этапны да узып, өч дәвергә дә хезмәт итә алырлык дәрәҗәдә бөек әдип булуын аңлатып уза[4].

Бу фикерләрне Акмулла иҗаты белән бәйләп карасак, шушы шагыйребезнең татар шигърияте үсешендәге роле никадәр зур икәнлеген күз алдына китерербез һәм аның шигъри мәктәбенең көчле рухлы һәм яшәүчән булганлыгына соклануыбызны да ачык белдерү урынлы тоелыр. Димәк, Г. Рамазановның Акмулладан М. Гафури «шигырьнең табигый агышын, халыкчан кинаялекне, афористик образлылыкны, төзек ритм һәм анык рифмалар белән эш итүне өйрәнә, Акмулла кебек үк ул да халык мәкаль һәм әйтемнәрен, халыкчан параллелизмнар куллана»[5] дигән иҗтимагый-

[1] *Карагыз: Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 290.

[2] Шунда ук. – Б. 256.

[3] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 290.

[4] Шунда ук. – Б. 254–260.

[5] *Рамазанов Г.* Мәҗит Гафури // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 152.

фәнни әһәмияткә ия нәтиҗәләргә килүендә һичбер хата, хакыйкатькә хилафлык юк.

Г. Халит исә, М. Акмулла һәм М. Гафуриларның иҗат мирасларындагы уртак якларны билгеләп, «ике гасыр аралыгында – туып килгән яңалыкларны, прогресс һәм мәгърифәтчелек романтикасын хәбәр итеп – (...) шигырь мәйданына аяк бастылар» дип, аларга теоретик югарылыкта бәяләмә бирә. Галим Р. Әхмәтовның «Акмулла иҗаты татар поэзиясендә мәгърифәтчелек реализмы хәлиткеч җиңүгә ирешә бару хакында сөйли. Сурәтләү объекты чынбарлык булу, тел-сурәтләү чараларын халыкның җанлы сөйләм теленнән, халык авыз иҗатыннан эзләү, әсәрләре турыдан-туры киң халык массасына, аның да изелгән, ярлы катламына адреслану, социаль тигезсезлекне, сыйнфый тигезсезлекне фаш итү, залимлеккә кискен протест белдерү – болар барысы яңа чор – XX йөз башы поэзиясенә юл ачалар»[1] дип биргән билгеләмәсе шагыйрь М. Акмулланың иҗат үзенчәлекләрен тулы канлы итеп ачуын ассызыкламый мөмкин түгел.

Шулай итеп, М. Акмулланың әдәби процесста шактый төгәл һәм әһәмиятле урын биләвен күрәбез. Ул үзеннән соңгы шагыйрьләрнең мәйданга чыгуында да зур роль уйнаган. Шигърияте үзенчәлекләре аларның да иҗат кредосына әверелгән. Болардан чыгып, һич шикләнми Акмулланың татар әдәбияты тарихыннан тәмам аерылгысыз булуын ачык билгеләргә тиешбез.

М. Акмулланың иҗат үзенчәлекләре, сакланып калган иҗат мирасы һәм аның үзеннән соңгы шагыйрьләрнең формалашуына һәм үсешенә йогынтысы фәндә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән, билгеле. Әмма кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертәсе бар әле. Шуларның берсе Акмулланың шигъри мәктәбе белән бәйле. Яшермик, М. Акмулланың М. Госманов тарафыннан әзерләп чыгарылган шигырьләр җыентыгына кертелгән текстларындагы сүзләргә бирелгән ас төшермә аңлатмаларда һәм тәрҗемәләрдә авыр хаталар булу сәбәпле фикерләре буталган. Күп урыннарда ялгыш укылулар аркасында әдипнең әдәби-эстетик карашларын ачыклауга да кыенлыклар тудырылган. Төп мәсьәләне чишү, ягъни шагыйрьнең әдәби-

[1] *Әхмәтов Р.* Мифтахетдин Акмулла // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 2. XIX йөз татар әдәбияты. – Б. 246.

эстетик карашларын билгеләү – аның шигъри мәктәбенең, яңа бер әдәби агымга башлангычының нигезен ачыклау дигән сүз ул.

Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән,
Анчә[1] күз алартмаңыз миддәт[2] берлән,
Ниһайә[3] булса мөкайад йә мөнәүвәл[4]:
Харам-хәләл шәхесенә нисбәт берлән, –

дигән юллар белән «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» поэмасында М. Акмулла үзенең әдәби-эстетик карашларын бәян иткән бер бүлекчәне башлап китә. Асылда, нәкъ шушы тугыз строфа эчендә шагыйрь шигърият үсешендә төп роль уйнаган фикерләрен ачыклап бирә дә инде. Монда сүз шигырьнең мәгънәдә тирән, ягъни хикмәтле булырга тиешлеге, әсәрне өмет һәм әҗер белән сугару кирәклеге хакында бара. Гади, тирән, ачык шушы таләп алга таба шигърияттнең төп үсеш кыйбланамәсенә әверелә, XX йөз башы әдәбияты шушы юнәлешне тота. Г. Тукайны гына алсак та, аның шигърияте һәммә барлыгында шушы рух белән сугарыла.

*2001*

## Г. Тукай иҗатының беренче чоры: асыл хикмәтләре

Г. Тукайны бездә бөек дип атыйлар. Шушы бәяләмәне раслау омтылышында йөзләрчә әдипләр тарафыннан әсәрләр, фәнни мәкаләләр язылды һәм язылачак. Ни өчен Г. Тукай чыннан да бөек дигән сорауга җавап биреп бетерү мөмкин дә түгелдер сыман. Хикмәт нәрсәдә соң? Һәр чор-заманның, хәтта укучының да үз Г. Тукае булуда гынамы? Ни өчен аның гадәти һәм телдән-телгә күчеп йөргән шигырьләре һаман да безнең күңелләрне нурландырып тора?

Боларга кайчан да булса җавап биреп бетерү мөмкин түгелдер сыман.

Г. Тукай татар дөньясының искесе белән яңасы арасында басып торган маяк шикелле ул. Әдәбият халыкның эчке дөньясын чагыл-

---

[1] *Анчә* – алай, аңа.
[2] *Миддәт* – тупаслык, әллә кемлек.
[3] *Ниһайә* – нәтиҗәсе.
[4] *Мөкайад йә мөнәүвәл* – әҗер йә өмет.

дырырга тырыша. Әхлак-әдәп, гадәт кануннарын бәян итә, кешене тормышка әзерли, гомере буе күңелен-зиһенен шатландырып, ныгытып, баетып килә.

Г. Тукай, татар яшәешендә иске карашларга бәйле сакланган гадәтләр белән каршылыкка кереп, яңа дөньяви күзаллауларга бирегеп туган әхлак-әдәп төшенчәләрен төгәл аера алып, шигърияттендә хисләрне рухи-мәдәни омтылышлар югарылыгында кора алган әдип буларак иҗат итте. Аның әсәрләре дә яңа белән искенең кискен конфликтын кичерү аша мәйданга чыктылар һәм халык күңелен яулап алдылар.

Г. Тукай яшәгән чорда тормыш реальләре катлаулы үзгәрешләр белән тулган була. Әмма бу үзгәрешләр һаман да көчле каршылыклар эчендә бара иделәр. Моны яхшы тоеп, ул чор әдипләре бу көрәшне «кадимчелек һәм җәдитчелек тартышы» дип атадылар. Тормыш реальләре үзгәрү шул ук тормышка мөнәсәбәтне дә борды, ничек дөрес була дигән сорау халык алдына килеп басты. Әлбәттә, бу иҗтимагый мәсьәләне чишүгә күп төрле әдипләр тартылдылар. Г. Тукай алар арасында беренчесе дә, соңгысы да түгел иде.

В. Шкловскийның итальян гуманисты Җ. Боккаччио (1313–1375) иҗаты белән бәйле тикшеренүләрендә мондый фикер алга чыгарыла: «Мы должны понимать, что единство самобытного нравственного отношения к предмету описания для разных эпох разное, как отличается для разных эпох сама нравственность»[1].

Тарихи-рухи күчеш чорында әхлакый карашлар үзгәрә, язучылар шул үзгәрешләрне прозада характерлар рәвешендә яки шагыйрьләр поэзиядә хисләр каршылыгында сурәтләп бирәләр. Шушы юнәлештә XX йөз башы татар әдипләре ачылдылар да инде. Г. Исхакый, Ф.Әмирхан, С. Рәмиев, Г. Камал, Дәрдемәнд, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Фәйзи һәм башка йөзләрчә язучы һәм шагыйрьләрне татар әдәбияты тарихы нәкъ шундый акыл ияләре буларак бәяли. Г. Тукай алар арасында иң халыкчаны иде.

Татар әдәбияты тарихында талантлар Г. Тукайга кадәр дә бар иделәр, аның чорында да аларның саны ике йөзгә кадәр җитте, аннан соң да алар тудылар. Бу яктан халкыбыз үзенең алдынгы милләтләрдән булуын күрсәтте һәм күрсәтә килә. Мәсәлән, бер

[1] *Шкловский В.* Художественная проза: Размышления и разговоры. – М.: Сов. пис., 1961. – С. 177–178.

Дәрдемәнд яки С. Рәмиев кенә дә, Г. Тукайның чордашлары, бөек шагыйрьләр, талант ягыннан, шигъри фәлсәфә, хис-тойгы, әдәби эшләнеш, иҗат мәртәбәсеннән килеп бәяләгәндә – хәтта өстенгә дә чыгалар әле. Моны үз заманында Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» (1912–1913) фәнни-тәнкыйди аналитик хезмәте белән раслап аңлата да алды. Аның фикерләре белән килешергә була, килешмәскә, әмма ул күп очракта хаклы да булып кала бирә. Фәнни анализ нәтиҗәләре бәхәс тудыра алалар, әмма аларны юкка чыгару мөмкин түгел.

Г. Ибраһимовның анализлары дөрес, Г. Тукай иҗатын яхшы белүе күренеп тора. Ә карашларда һәммә кеше чикле. Г. Ибраһимовның фикер сөрешен аңлый алган очракта, без аны хаталануда, тенденциоз язуда гаепләргә тиешбез. Хезмәте шундый эчтәлектә аңлашыла да. Дөрес, кистереп әйтергә дә тиешбез: Г. Ибраһимовны якларга яки аның хаталарын акларга да җыенмыйбыз. Ул аңа мохтаҗ да түгел, бу безнең максатыбызга да керми. Әмма аның фикерләрен санга алмау шулай ук томаналык сөреме астындагы наданлык булып калыр иде.

Кабатлап белдерәбез, шунысы әһәмиятле: Г. Ибраһимов Г. Тукай турында дөрес яза, иҗатын дөрес анализлый, аңа туры бәя бирә. Һәр фикере дәлилләнелгән, саллы, очраклы фикерләр җыелмасын тәшкил итми. Бары тик бер мәсьәләгә генә игътибары җитмәгәнлеген төшенми калырга ярамый: Г. Тукай, чыннан да, коеп куйган шагыйрь генә түгел, аның шигъри строфикасында мантыйк гаҗәеп көчле булу белән бергә, шигырьләре поэтик төзеклеге, метафорика ягыннан эшләнешләрендә алай ук хәйран итәрлек тә түгелләр сыман. Бу хакыйкать бары тик башка әдипләрнең иҗатлары белән әсәрләрен чагыштырма планда өйрәнгәндә генә ачыла ала. Шунысын онытмыйк: Г. Тукай шигъри-метафорик мантыйкны формаль логика кысаларыннан читкә чыгаруны өнәмәгән әдип, ягъни ул образлылыкның мантыйклы булуы өчен җан аткан, болар хакында мәкаләләрендә туктаусыз белдерә килгән. Шушы ягы белән ул чын мәгънәсендә даһиларча эш итә. Шигырь теориясендә ат уйнаткан сакчыл хисле күңелләрне ул хәтта аптыраштта да калдыра.

Болар без Г. Тукайның шагыйрь буларак талантын, шигырь тудыру ягыннан гаҗәеп тә оста икәнлеген шик астына алабыз кебек аңлашылырга мөмкин. Аның талант дәрәҗәсенең югарылыгы

бәхәссез! Сүзләребез Г. Ибраһимовны кабатлау кебек яңгырасалар да, ачык итеп искәртми узу мөмкин түгел: Г. Тукайның шагыйрь буларак хикмәте яңа шигъри формалар, шигъри осталык үрнәкләре күрсәтүдә генә түгел. «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле! / Дөньяда күп нәрсә белдем син тагын тел аркылы», – дигән шигырь юлларын укыганда ук, «теле» белән «аркылы» рифмасының төгәл булмавы күзгә ташланса-ташланмаса да, шушы «Туган тел» шигыреннән тыш башка әсәрләрендә дә мондый «кытыршы» рифмалар очраса да, халкыбызда аларга карата тискәре караш бөтенләй юк. Хикмәт бит рифмада түгел, шигырьне аны рифма һәм ритм гына тудырмый. Борынгы грек шагыйрьләре әллә рифма белән генә язганнар дисезме, әллә инглиз әдибе бөек Уильям Шекспир (1564–1616) рифмага береккән булганмы? Хәер, Г. Тукайның поэтик осталыгын дәлилләүчеләр дә аның ише урыннарга бөтенләй «күз салмыйча» узу ягын карыйлар. Болай эш итүләре әлбәттә гадел дә түгел, чөнки матур өлешләрне генә күзәтеп, башкаларын атлап үтү хакыйкатьне ачарга ярдәм итми. Шулай да төгәл белергә тиешбез: шагыйрьнең бөеклеге камил рифмалы-ритмлы әсәрләр бирүендә генә түгел, бу бары тышкы як кына. Хикмәте – мәгънәләрендә. Әмма шигырь – әдәби сәнгать әсәре, аның һәммә яктан да килгәне, камил булганы яхшы, ягъни әдәби сәгате белән дә, әдәби мәгънәләре белән дә ул җанга үтеп керсен, йөрәк аша, кан тамырлары аша узсын, акылны-аңны нурландырсын. Без менә шуны чын шигырь дип атыйбыз, шуңа да шигырьләрдән мәгънә тирәнлеге һәм сәнгать югарылы эзлибез, шундый шигъриятне илаһи дип таныйбыз һәм аңа коллык итәбез. Андый әсәрләр шайтаный була алмыйлар. Әдәби иҗатта башка төрле принципларга таянып яшәүчеләрне һич тә аңламыйбыз, шулай да әсәрләрен кабул итәргә һәм аңлатырга тырышабыз: дөньяда яшәп тә дөньяныкыннан читтә калу, дөньяныкын артка тибәреп ташлау мәгънәсезлек ул, дибез.

Шәрык әдәбиятлары XII йөздән алып XIX гасыргача бер үк темаларны һәм формаларны, ритм-рифмаларны «чарлап» яшәгән. Әмма әдәбият үсешендәге торгынлыкның ни рәвешле булуына иң яхшы тарихи мисал да булып санала бу чорлар.

Шигырь өчен рифма һәм ритм (алар эчке яки тышкы булсыннар) – бик тә мөкатдәс нәрсәләр, дияргә тиешбез. Аның камиллеге

шигырьне әдәби-сәнгати яктан шулкадәр нурландырып җибәрә ки, укучының күңеле мең төрле сөенечләргә тула. Рифманың да, ритмның да шигырь өчен хикмәтләре бар инде анысы!

Г. Тукай иҗаты турында сүз чыкканда, һаман да бу сорау күңелгә килә: әмма хикмәт аларда, рифма-ритмда, әдәбият сәнгате ягында гынамы соң? Һәм, Тукайга соклануыбыз бер дә кимемичә, юк, аларда гына түгел, дибез. «Соң ни бар алайса?.. – дип сорый шул ук «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә Г. Ибраһимов та һәм моңа бу рәвешле җавап бирә: – Татарлык бар, татар рухын һәм тормышын һәйбәт гавамча, табигый итеп ясап чыгару бар...»[1]

Г. Тукай татар күңеле хис иткәнне, теләгәнне, акылы-зиһене омтылганны сурәтләп яза белүче әдип иде. Г. Ибраһимов та аның нәкъ менә халыкчан булуында бөеклеген күрә, таный, мактый. Г. Тукай татар халкының теләк-омтылышларын, өмет һәм хыялларын, дөньяны аңлавын һәм ни рәвешле кабул итәргә, бәяләргә, анда тормыш корырга кирәклеген тоеп алып, шуларны ачык итеп тасвирлап бирә алган әдип иде. Мондый итеп аңардан башка бер шагыйрь дә шушы кадәр халык рухына, җанына үтеп кереп, аңлап, белеп язмады. Г. Тукай әсәрләрендә үзе яшәгән XX йөз башында татар халкының әдәп-әхлакта кискен үзгәрешен тоеп, үзгәрергә теләвен сизеп, үзгәрә баруын аңлап һәм аңлатып сурәтләп бирде. Шуның өчен дә аның иҗатында һәртөрле искелек, иске карашлар кире кагылдылар. Шуның өчен дә ул безгә әхлак һәм әдәп тәрбиясе бирергә омтылучы мөгаллим дә, үгет-нәсыйхәт итүче хәлфә дә сыман яза белде. Шушылар аркасында аңарда мәгърифәтчелек аһәңнәрен, хәтта мәгърифәтчелекнең үзен, вәгазьчелекне күрделәр. Г. Тукайның милләт рухын үзгәртүгә алынуында «мөгаллимлек» итүен без «мәдрәсә исе килеп тора», ягъни ул укытучыларының дәресләрдә сөйләгән сүзләрен колакларыбызга кабатлап сөйли дип тә билгеләргә мөмкинбез. Әйе, анысы да булгандыр. Әмма үз җаны аша уздырылган шул «мөгаллимлекләр» милли аң, милли әдәп, милли әхлак үсеше файдасына иделәр, бүген дә үз көчләрендә кала киләләр. Әйе, Г. Тукай, чыннан да, әхлак тәрбиясе бирергә алынучы мөгаллим дә, үгет-нәсыйхәт итүче хәлфә дә сыман яза белде. Г. Ибраһимов исә бу хакта болай дип белдерә: «Ул шуның

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 133.

белән авыз ачты, бисмилласында фикер бирде, кеше өйрәтте... Һәм һичбер вакыт ул бу чирдән, бу мөгаллимлек авыруыннан котыла алмады»[1].

Яңа, җәдиди, заманча әдәп-әхлак принципларын һәм идеалларын күтәреп чыгуны Г. Ибраһимовның шушы рәвешле кабул итүенең шәхси, әдипләргә хас аерым сәбәпләре булуы бер дә сер түгел. Ул әлегә саф сәнгатькә омтыла. Бу аның рухи теләге. Ул әдәби сәнгатьчелекне әдәби мәгънәләрдән әлегә өстен куя, аның эзләнүчән күңеле сәнгать биеклегендә оча, мәгънә тирәнлегенә дә чумарга тиешлеген акылы тоеп бетерми. Моның бәхәссез шулай булуы аның шул елларда язылучы «Яшь йөрәкләр» романында да ачык сиземләнеп тора. Әдипнең күңел хисләре төп геройларыннан Зыя образында тулысынча диярлек чагылыш таба.

Г. Тукайга үгет-нәсыйхәт бирү алымнарына да, сабак өйрәтү юлларына да барырга туры килгән. Заман рухы шуны таләп иткән. Дөрес, кайбер әдипләр үгет-нәсыйхәтчелеккә тәмам кереп батканда да, ул аның белән артык мавыкмаган. Ничек кенә булмасын, халыкта яңа әдәп-әхлак принципларын барлыкка китереп, аларга алга таба үсәргә мөмкинлекләр ачып, бөек шагыйребез кешелек тарихында күп төрле талантларның кулыннан килмәгән олы һәм югары эшне башкарды, шуның белән заман үзгәрешенә, тарихи барышка көчле этәргеч бирде.

* * *

Г. Тукай үзенең әдәби иҗатын ярым-төрки, ярым-госманлы (төрек) теле белән башлап китә. Бу вакытта татар әдәбиятында, К. Насыйри юлыннан барып, Казан татарлары телен үрнәк итү мисаллары да, И. Гаспринскийча кырым-татарлары теленә авышуны өстен күргән әдәби әсәрләр дә җитәрлек иде. Г. Тукай сүз башлаганында ук бөтен ислам дөньясы теленнән сөйләүгә алынды. «И каләм!» (1906) шигыре аның башлангыч чор иҗатының һәммә үзенчәлекләрен күрсәтеп тора, автор аларны ачыктан-ачык үзе үк тезмә рәвештә анда язып чыга.

Яңа, җәдиди чор татар әдәбияты фәне, үзенең үсешендә XIX йөзнең икенче яртысыннан европачылыкка омтылып, 1914 елга объектив фикерләүдә тәнкыйди карашның өстенлекле булуын

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 129.

төшенерлек һәм корал итә алырлык дәрәҗәгә килде. Г. Тукайның бөеклеге шигъри фикер бирә алуында һәм шигъри нечкәлегендә генә булмыйча, киңрәк масштаблы икәнлеген бәяләргә теләсәк, шул чордагы әдәби тәнкыйтьне дә яхшылап өйрәнергә тиешбез.

Г. Тукай ислам дөньясының артталыгына хәйран иткән әдипләрнең беренчесе дә, соңгысы да булмады. Төрек, азәрбайҗан әдәбиятлары да XIX йөздә үк шушы юлда иделәр. И. Гаспринский 1883 елдан, Бакчасарайның бөек даһие буларак, «Тәрҗеман» газетасы аша халыкка шушы фикерне кабатлап килде. Г. Тукай да аларга иярде. XIX йөзнең соңгы чиреге шагыйре М. Акмулла (1831–1895) иҗаты белән алга чыгарылган шигъри фикер бирү агымы, Г. Тукай тарафыннан куәтләнелеп, XX гасырда тагын да киңәя барды. Фикер әйтү М. Гафури, Н. Думави, З. Бәшири кебек шул чорда исемнәре танылырга өлгергән әдипләрнең дә төп иҗат кредосы иде. Алар фикер сурәтен вәгазь бирүдән аерылгысыз итеп күрделәр. Г. Тукайга да шушы мөгаллимлек сыйфаты хас иде. Әмма ул, башкалардан аермалы буларак, яңа заманның, яңа әхлаклылыкның, гореф-гадәтләрнең җәмгыятьтә барлыкка килә баруын күрергә өлгерде. Моның сәбәбе, әлбәттә, демократик мөнәсәбәтләргә омтылыш белән бәйле иде.

XX йөз башында барлыкка килгән яңа татар демократик матбугаты прогрессив идеяләрне тормышка ашыруда зур ярдәм ролен үтәде. Н. Думави, З. Бәшири, хәтта С. Рәмиев тә «Бәянел-хак» кебек иске карашлы, кадими матбугат кочагында калган чорда Г. Тукайга башка шартлар тудырылды, башка мөмкинлекләр ачылды. Әдипнең формалашуында, әлбәттә, беренче адымнары зур этәргеч бирә. Монда уңай шартларның булуы гаять тә зур әһәмияткә ия. Г. Тукай «Әлгасрелҗәдид» («Яңа гасыр»), «Уклар» журналлары, «Фикер» газетасы мәйданнарында ирекле үсә, ныгый. Шуның өчен дә шушы Уральски татар вакытлы матбугатын тарихыбызда зур хөрмәт белән искә алырга тиешбез.

«И каләм!» шигыре янында шул ук 1906 елда язылган «Ифтиракъ соңында», «Шагыйрь һәм Һатиф», «Мөридләр каберстаныннан бер аваз», «Пушкинә», «Дәрдемәнд дәгелмием?», Борадәранә нәсыйхәт», «Хур кызына», «Милләтә», «Сөеклемнең кабер ташында», «Шәкерт, яхуд Бер тәсадеф», «Кем ул?», «Мөхәммәдия» көе», «Сөальләр» (басылу вакыты – 1907) кебек әсәрләрен искә алсак,

алар һәммәсе дә, төрле-төрле эчтәлектә булуларына карамастан, юнәлешләре белән һаман да яңа әхлак, яңа гореф-гадәт, яңа тәртипләр төзүгә юнәлдерелгән иделәр. Г. Тукай бу эшен бер дә өзмичә, туры һәм дәлилле итеп алып бара белде.

«Гыйшык бу, йа!» шигыренә игътибар итик:

Бер гидае җан фидаем, гыйшкыңа пәрванаем;
Кәл, гүзәл, гарз-ит җәмалың: янаем, кил, янаем.

И Ходаем, вир гакыл, чөн хәбсә мәхбүс улмыям,
Бу кызың гыйшкында бән диванаем, диванаем.

*(Бер мескен җан корбаным, гыйшкыңа күбәләкмен,*
*Кил, гүзәл, күрсәт чибәрең: янырмын, кил, янырмын.*

*И Ходаем, бир акыл, чөнки зинданга тоткын буламын,*
*Бу кызның гыйшкында мин диванамын, диванамын.)*

Мәхәббәттә Г. Тукайның шигарь дәрәҗәсенә җиткерелгән шигъри юллары болар. Шул ук вакытта аларны яңа әхлак һәм гадәт омтылышлары сыйфатында да кабул итәргә тиешбез. Лирик герой үзен мәхәббәт утына очып баручы күбәләккә тиңли. Борынгы суфичыл әдәбияттан укучыга яхшы таныш, символик мәгънәгә ия образ бу. Әгәр дә урта гасырларда шагыйрьләр Аллаһыга мәхәббәтне шушы рәвешле символик тасвирласалар, суфи-диндарның җанын Аллаһы Тәгалә нурына юнәлүче һәм шунда эреп югалучы сыйфатында күзалласалар, Г. Тукай җир кызына мәхәббәтне дә шул дәрәҗәдәге хисләр яктылыгында тасвирлый. Бүгенге укучы бу ике шигъри күзаллау, шигъри хисләр арасындагы аерманы тоймый да, аңламый да диярлек. Әмма XX йөз башы татар тормышы өчен бу аермалыкларның әһәмияте гаҗәеп зур. Лирик герой гүзәл кызның чибәрлекләрен күрергә тели, шулар ялкынында аның янасы килә. Шагыйрь Аллаһыга гыйшыкны инкяр итми, ул бу хакта сүз дә кузгатмый. Урта гасырлар әдипләре С. Сараи булсын, Котб, К. Сайади яки Мәҗлиси, яисә Мөхәммәдьяр бине Мәхмүт, башкасы булсын, Г. Хәям, Г. Нәваилар хакында искә алсак та шул ук хәл, – алар Аллаһыга гыйшык турында сөйли иделәр, Аллаһының үзеннән бу мәхәббәттә ярдәм, ягъни лаеклы җавап үтенергә база иделәр. Әмма Г. Тукайда мәсьәлә башкачарак куела: аның лирик герое, Җир йөзендәге кызга мәхәббәт тоткыны булырга теләмичә, Аллаһы Тәгаләдән бирешмәс өчен акыл бирүен үтенә, чөнки үзен гыйшык

аркасында дивана хәлдә күрергә теләми. Бу инде моңа кадәр әдәбиятта яктыртылмаган хәл иде, яңа әхлак билгесе сыйфатын алды.

Суфичылык әдәбиятына хас шул ук образлар, символлар, метафоралар Г. Тукай иҗатында да кабатланып киләләр. Әмма алар башкача мөнәсәбәтләрдә, ягъни үзенчәлекле поэтик модус тәртибенә корылганнар. Шуның аркасында шигъри сүзнең эчтәлеге дә үзгәрә. Суфичыл мистицизм дөньяви карашлар белән алыштырыла. Г. Тукай мәхәббәткә яңача, заманча әдәп-әхлак карашларын тудыра: мәхәббәт хисләрендә һәркем янарга хаклы, әмма акылны югалтыр дәрәҗәгә, диваналыкка төшеп түгел. Бу юлда лирик геройга Ходай үзе ярдәмче!

Бу фикер татар күңеленә генә түгел, суфичылык карашлары тәэсирендә калган башка халыклар өчен дә зур яңалык булып тора. Әгәр дә моңа кадәр Аллаһыга мәхәббәттә дивана хәлгә җитү макталса, Г. Тукай гыйшыкның хисләрне андый дәрәҗәгә җиткерелүен өнәми. Без монда йөрәк эшләрендә яңа әдәп-әхлак кагыйдәсенең эчке һәм тышкы чикләре белән очрашабыз. Шагыйрь аны Ходай бирергә тиешле саналган акылда күрә. Әйе, дини күзаллаулар белән кысаланган шигырь бу, борынгыларны кабатлыйдыр сыман тойгы калдыра, әмма принципиаль яңа, дөньяви әхлак һәм әдәп юнәлешендә тудырылган.

«Мөридләр каберстаныңдин бер аваз» шигырендә дә Г. Тукай яңа дөньяви әхлак һәм гадәтләрне эзләү эшен дәвам иттерә һәм болай ди:

Милләти вәйран идән ишан икәндер, белмәдем;
Ул ишанлар милләтә дошман икәндер, белмәдем.

Милләти идһам идән, игъдам идән шунлар имеш,
Анлари инкарь идән зи шан икәндер, белмәдем.

*(Милләтне харап иткән ишан икәндер, белмәдем,*
*Ул ишаннар милләткә дошман икәндер, белмәдем.*

*Милләтне тузан иткән, харап иткән шулар, имеш,*
*Аларны инкяр иткән намуслы икәндер, белмәдем.)*

Шигырь XIII йөз шагыйрьләре Ә. Ясәви һәм С. Бакыргани хикмәтләренә хас вәзен, кафияләү принципларында язылган. Хәтта фикерләр дә шул килеш калдырылган, әмма эчтәлеге бөтенләй башкача. Суфи шагыйрьләрдә замана, Җир тормышы кешене, ха-

лыкны, рухны юкка чыгаручы, җимерүче итеп бирелсә, Г. Тукай монда ишаннарны, ягъни суфиларның үзләрен гаепли. Әлбәттә, *милләт* һәм *өммәт* сүзләренең мәгънәдә берлелеге дә исәпкә алынган. Г. Тукайдагы *милләт* төшенчәсе әлегә шул ук мөселман өммәте булып кала бирә, әмма ул инде татар милләте буларак та кабул ителә. Бу рәвешле *милләт* сүзен концепт чикләрендә алу шагыйрьгә фикерен үткен һәм үтемле итәргә мөмкинлек биргән. Г. Тукай динне түгел, диндар суфичылыкны милләтне артта калдыруда гаепли, урта гасырчылык белән бәйле карашларны инкяр итүне намуслылык билгесе буларак бәяли. Бу әсәрдә яңа әхлак һәм әдәп принциплары шушы рәвешле ачыктан-ачык бәян ителәләр.

Әгәр дә без Г. Тукайның дөньяны үзгәртүен, яңа әхлак һәм әдәп белән бәйле карашларын тәкъдим итүен суфичылыкны кире кагуга бәйләп кенә аңлатсак, бу бер яклы һәм чикләнгән фикерләмәләрнең нәтиҗәсе булыр иде. Ул никадәр генә кискен бәяләр-бәяләмәләр биреп эш итмәсен, иске тәртипләрне тулысынча инкяр итү юлыннан гына барган дия алмыйбыз. Аның модернизмы урта гасырларда барлыкка китерелгән принципларны яңартуга корылып, шигъри вәзен һәм кяфияләрдә генә түгел, фикер сөреше юнәлешендә дә аларны кабатлый иде. Әмма бу кабатлану хакыйкатьне күктән җиргә төшерү, абстракт рухтан конкрет тормышка кайтару юнәлешендә барды. Шул ук урта гасырлар әдипләре Ә. Ясәви, С. Бакыргани, яисә Икани, Раҗи һәм Газзәзиләрнең фикерен куәтләгән рәвештә аның сүзләре яңгыраш алып, яңа тормыш реальлеге белән бәйләнешкә кертелде. Бу яктан караганда, бөтен борынгы һәм урта гасырлар (ул чактагы татар укучысына таныш булган дәрәҗәдәгесе) Г. Тукай белән фикердәш һәм сөхбәттәш булып татар укучысының колагына һәм күңеленә барып җиттеләр. Ни өчен колагына? Чөнки аны күңеле белән кабул итмәүчеләр дә арада бар иде.

«Дәрдемәнд дәгелмием?» шигыре алар өчен махсус язылган сыман аңлашыла:

Нәйләем, аслым, әсасем дәрдә идмеш ибтина?
Та әзәлдән дәрде шәүка мөбтәнаем, нәйләем?

Тәңре гыйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбәла,
Бән шәһидем дәр мәхәббәт, дәр бәлаем, нәйләем?

*(Нишлим соң, асылым, нигезем дәрткә бәйле төзелгән,*
*Яратылыштан көчле дәрткә дучармын, нәрсә эшлим?*

*Тәңре гыйшкында ант итсәләр Гәрбәлада,*
*Мин шәһитмен мәхәббәттә, бәладә, нәрсә эшлим?)*

Г. Тукай шигырьнең исеменә үк үзен дәрт иясе, ягъни Аллаһыга гыйшык тотучы суфи-диндар кеше белән тәңгәл куя. Әсәрне шагыйрь Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) белән бәйләү, әлбәттә, урынсыз. Монда аның катнашы юк. Әмма дә бу әсәр Дәрдемәнднең күңеленә хуш килми калмагандыр.

Чөнки Дәрдемәнд шигъриятендә көчле мистицизм бар, ул аңарда дини-суфичыл әдәбият тәэсиреннән шулай. Ә Г. Тукай суфичылыкны инкяр итә. Аңа мистик күзаллаулар һәм мистицизм кыргыйлык булып тоелган. Ул аларда хәтта шигърилек тә күрмәгән. Шуның аркасында иҗатына корылык үтеп кергән. Мистицизм, ни генә дисәк тә, ул әле үлән суты кебек, кешенең тамырлары буйлап хәрәкәт итүче яшәеш, тереклек билгесе сыман да түгелме?

Г. Тукай үзенең күңеле-рухы дәрт белән тәмам бәйләнештә торуын, ягъни асылының дәрткә төрелүенең сәбәбен мәңгелек чикләрендә җаны яратылган чакларда ук Аллаһының биргән тәкъдиреннән күрә. Шунда ук Кирбәланы исенә төшерә, моның белән Ислам дөньясында фән-гыйлем, мәгърифәтнең чәчәк аткан үзәкләреннән берсе – урта гасырларның Испания Андалузиясен искә ала. Бу рәвешле Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәттә ант итүне, ягъни иман китерүне иске чорлар өчен җиңел, сөенеч булуын белдерсә, яңа дәвердә, ягъни наданлык, артталык дәверендә мәхәббәттә һәм бәладә гуаһлык итәргә мәҗбүр икән лирик герой. Шагыйрь монда поэтик модусны сурәтләрне тәңгәл кую ярдәмендә төзи. Г. Тукай бу шигырьдә дә *шәһадәт* һәм *шәһит* сүзләрен концепт чикләрендә ала, гарәп теленнән кергән ул сүзләр төрле эчтәлекләрдә яңгыратыла.

Шагыйрьгә болай эшләү яңа әхлакый принципларны билгеләү өчен кирәк булган. Г. Тукай ислам дөньясының куәтле, алга киткән дәверен үз чоры белән янәшә куеп, аермалыкларны хистойгыларны кузгатып ача һәм яшәештәге гореф-гадәт принципларының да башкача булырга тиешлеген укучысына сиздереп үтә. Дөрес, Г. Тукайның бу рәвешле белдерүе «Тәрҗеман» газетасы

мәкаләләрен, М. Акъегетнең «Әлгасрелҗәдид» журналында басылып чыккан «Аврупа мәдәнияте» күләмле хезмәтен белүеннән үк килә, ул заманның татар укучысы колагына бер дә ят булып ишетелмәве дә аларга да бәйле.

Һәм менә шул җептәге «Японияне мөселман идәчәк голәма нәрәдә?» шигыре. Бу әсәре Г. Тукайның дин мәсьәләсендәге карашларын тагын да ачыграк төшенергә ярдәм итә:

Сез, и чалмалылар, безне буңа дик итдеңез игъфал,
Вә тәхсыйли дә тәгълими сәрасәр итдеңез иһмаль.

Гасырлар кичде мәрзая өфермәк лә, төкермәк лә;
Язып ялган догаларны вә яхуд ачтыңыз сез фал...

Диләр: – Исламә кермәк хәзрәти солтаны Микадо;
Сези дәгъват идәр дәргяһына – тиз варыңыз фил-халь!..

Такыр баш улмая тәклиф идәрмисез янә бунда?
Мыеклар шөйлә кыркылсын, ки улсын юклыга мәйяль?..

Йитәр, инсаф идең, артык кәрәк инсаф, хәясызлар!
Японлар да чапан кисен диеп куптармаңыз җәнҗал!

*(Сез, и чапанлылар, безне моңа кадәр надан-белемсез иттегез,*
*Һәм гыйлем табуда һәм алуда башыбызны буш иттегез.*

*Гасырлар үтте авыруны өшкерү белән, төкерү белән,*
*Язып ялган догаларны һәм дә ачтыгыз сез фал...*

*Әйтәләр: – Ислам динен алмакчы хәзрәт солтан Микадо,*
*Сезне чакырыр каршысына – тиз барыгыз шул хәл!..*

*Такыр баш булырга кушарсызмы тагын монда?*
*Мыеклар шулай кыркылсын – юк кебеккә якын ителсен?..*

*Җитәр, инсафлы булыгыз, артыгы белән инсаф кирәк, оятсызлар!*
*Японнар да чапан кисен дип куптармагыз җәнҗал!)*

Сүз бары тик дин тарату турында гына бара һәм Г. Тукай исламчылыкка каршы булган дигән фикер чыгару шулай ук чикләнгәнлектән, шигырьне аңламаудан килер иде. Хәер, фәндә мондый карашлар өстенлек алган чорлар да булды. Татар акылы аларны совет хакимияте заманнарында бик сөенеп кабул итә иде.

«Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?» шигыре Г. Тукайның ислам дөньясына бәйле, аның бигрәк тә прогресста-үсештә

артта калуына ачынып язган әсәрләреннән берсе булды. Тарихи әһәмияте бүгенге көндә дә югалмады.

Шулай итеп, «И каләм!» шигыре белән Г. Тукай яңа әхлак, гадәт, әдәп принципларын татар тормышында урнаштыру юнәлешендә эш башлап, идея-идеалларын әсәреннән-әсәренә җәелдерә һәм фикерләмәләрендә ныгыта барды. Иҗатының шушы башлангыч чорында шагыйрь бөтен-бар ислам дөньясы исеменнән сөйләде, әдәби телне дә шуңа күрә, Г. Ибраһимов терминологиясен файдаланып әйтсәк, «гомуми әдәби лисан» кысаларында тотты.

Бу вакытта ул Җаек буендагы Уральски шәһәрендә яши иде. Яшьлегендә Мисырның әл-Әзһәр университетын тәмамлаган киң һәм югары белемле Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин һәм аның улы, шулай ук әл-Әзһәрдә югары университет белемле белгеч-мөгаллим, татар һәм рус матбугатында баш мөхәррир, язучы, журналист, шагыйрь Камил Мотыйгый Г. Тукайның укытучылары булдылар. Г. Тукайның үз әсәрләрендә аларның фикерләрен халыкка җиткерүе дә сер түгел. Ул бу яктан, ягъни яңа әхлак һәм әдәп принципларын барлыкка китерү һәм халыкта ныгыту юлында әлбәттә ялгызы гына булмады. Шигъриятендә, фикере үсешендә даимилек күрсәтеп, борынгыдан килгән әдәби традицияләргә таянып, каршылыклы иҗтимагый шартлар эчендә кайнап, Г. Тукай татарның рухи-мәдәни тормышында һәм яшәешендә яңа дәверне башлап җибәрде.

Аның иҗатының беренче, башлангыч чоры «Китмибез!» (1907) шигыре белән тәмамланды. Бу әсәре Г. Тукайның ислам дөньясына хас карашлар системасы эчендә яшәвеннән һәм иҗат итүеннән Россия шартларына күчүен күрсәтте.

Дөрес, «Государственная думага» (1906) шигырендә үк ул ил эчендәге иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә якын килә башлаган иде. «Китмибез!» шигыре Россия һәм милләтләрнең андагы яшәеше мәсьәләсенә карата Г. Тукайның карашлары төгәл формалашып җитүгә бәйле, аларны ачык күрсәтүче төп әсәрләренең берсе булды. Ул һәр халыкның үз тарихи үсеше барлыгын, аны үзгәртү мөмкин түгеллеген, һәм яшәүдә, һәм белем алуда хакларының шактый икәнлеген ачыктан-ачык белдереп чыгыш ясады. Моңа кадәр татар халкы Россия шартларында аерымланган хәлдә тормыш коручы буларак күзалланса, «Китмибез!» шигыре бу яктан да гадәти карашларны үзгәртте. Россиянең уртак ватан буларак күзаллануы

«Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре»ндә (1913) тагын да үстерелде, тәмамланган, бербөтенлек төсен алды. Әмма ул әсәр аның иҗаты чәчәк аткан Казан чорына карый.

## Г. Тукай «Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты»нда

Уральски чоры Г. Тукайның шагыйрь һәм иҗтимагый фикер иясе буларак танылуында аерым урынны алып тора. Монда «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең, бигрәк тә Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның роленә аерым тукталып үтү сорала. 1903 елда Каһирәдән әл-Әзһәр университетын тәмамлап кайткан К. Мотыйгый, «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыту белән генә чикләнмичә, иҗтимагый эшләрен дә киң җәелдереп җибәрә. Әдәбият түгәрәкләре оештыра, кулъязма «Әл-Мәгариф» газетасын даими чыгаруны җайга сала.

Сакланып калган нөсхәләреннән күренгәнчә, бу газета асылы белән «госманлы теле»нчәрәк мәйданга куела. Моның сәбәбе бик гади булган: К. Мотыйгый әл-Әзһәрдән госманлычага ихластан күңелен салган, шуның белән галимлеккә остарган кеше буларак кайткан. Ул анда начар укымаган. Фәннәрне бик тиз төшенеп, курсларны тиз арада узып, 1900–1903 еллар эчендә тәмам галим буларак җитлегеп өлгерә. Аның әтисе, мәсәлән, Мотыйгулла Төхфәтуллин исә үз заманында анда 10 ел буена белем алган. Камилгә ул кадәр үк вакыт та кирәк булмаган.

К. Мотыйгый, Уральски шәһәренә кайтып, «Мотыйгыя»да укыта башлауга, шәһәр халкы тормышыннан бер-бер артлы берничә әсәр дә язып өлгертә. Аларны цензура комитетына юллый. Байлар тормышын көлкегә алып тәнкыйтьләүгә багышлаган ул әсәрләренә (асылда аларны тезмә һәм нәсер алымнары белән иҗат итә) басылырга рөхсәт тә ителә, алар дөнья да күрә торалар. К. Мотыйгый шулай төрле яклап танылу ала бара.

Аның иң әһәмиятле эшләреннән берсе – «Бердәмлек вә тәрәккыять комитеты»н оештыруында. «Әл-Мәгариф» газетасы һәм «Мотыйгыя»дагы әдәбият түгәрәкләре шушы комитетның Уральскидагы эшчәнлегенең нәтиҗәләре буларак та күз алдына килә. Аның эшендә актив катнашкан Г. Тукай исә К. Мотыйгыйның шәхси секретаре ролен башкара. Кулъязма газетаның нөсхәләрен

күчерүдә, аны халыкка таратуда Г. Тукайның ролен аз гына да киметергә мөмкин түгел.

«Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты» шәһәрдә мөселманнарны мәгърифәт һәм мәдәни үсеш өчен туплау, конкрет максатлар белән хәрәкәт итүгә юнәлтү белән шөгыльләнә. Әлбәттә, каршылыклар аз булмый. Татар тарихына «җәдит-кадим тартышы» буларак кереп калган, шул кысаларда гына аңлатылган иҗтимагый хәрәкәтләрнең кайсылары асыллары белән төрекләрдәге иҗтимагый-фикри алгарышларга барып тоташуы мәсьәләсе дә фәнебездә әлегә игътибардан читтә кала кебек.

К. Мотыйгый оештырган комитет һәм исеме, һәм җисеме белән «Яшь төрекләр» хәрәкәтенең 1889 елдан яшәп килгән «Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты» эшчәнлегенең бер күренеше сыйфатында бәяләнә ала. Алар сәяси, милли, иҗтимагый һәм мәдәни платформалары белән дә туры киләләр. Моны ниндидер бер вакытлы мавыгу, яисә «Яшь төрекләр» хәрәкәтен татар тормышына күчерергә омтылыш буларак кына бәяләргә ярамый. К. Мотыйгыйның, татар тормышы үзенчәлекләрен аңлап, эшен байларга, иске карашларга каршы юнәлдерүенең дә тарихи, сәяси, мәдәни әһәмияте аз булмый.

«Яшь төрекләр» үзләре Төркиядә милли иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрнең башында XIX йөзнең ахырларыннан тора башлыйлар. Алар «Яңа госманнар» сәяси-мәдәни оешмасына алмашка киләләр. Төп максат итеп илдәге монархияне юк итүне куялар. «Яңа госманнар» төрек тормышын европалаштыруда төп эшне башкаралар, илдә конституцион җәмгыять оештыралар, парламент төзеп, буржуазиягә үсеш мөмкинлекләре тудыралар да. Әмма аларның уңышлары озакка бармый. Башлаган эшләре туктатыла. Җитәкчеләре шагыйрь һәм язучы, актив җәмәгать эшлеклесе, журналист Намык Кемал (1840–1888) кулга алына. Югыйсә солтан булып Габдел-Хәмит II (1876–1909) тәхеткә «Яшь госманнар» ярдәме белән утырган була. Ул солтанлык тәхетендә бер ел торырга да өлгерми, «Яшь төрекләр»нең илдә солтан идарәсен юк итәргә җыенуларын ачык төшенеп, аларны эзәрлекли башлый. Үз фәрманы белән Н.Кемалны зинданга салдыра, илдә яңа идарә юк ителә, тирания урнаша һәм «золым дәвере» башланып китә. Солтан Габдел-Хәмит II төрек байлыгына кызыккан чит илләрнең тыкшынуыннан

мәмләкәтне коткаруның башка юлын күрми. Әмма бу, аның сайлаган юлы, шулай ук уңышлы булмый. 1882 елда Франция Тунисны яулый, 1882 елда Бөекбритания Мисырны басып ала. Болар гына да түгел, чит илләрнең тыкшынуы Төркия казнасына, гаскәрләренә үтеп керә. Шушы вакытта Габдел-Хәмит II дини дошманлык идеясен таратуга зур ышаныч баглый башлый. Бу юлда эш җәелдерелеп, халыкларга каршы халыклар куела. Җәмгыятьтә оешкан милли прогрессив көчләрне юка чыгару, сәяси хәрәкәтләрне бастыру һәм таркату, европалашуга каршы сәяси, иҗтимагый, икътисади, әхлакый һәм башка һәртөрле көчләрне туплау эше оештырыла. Милләтчелек һәм мөселманчылык идеяләре солтан тарафыннан иң уңай һәм үз сәясәтен ныгытуда яраклы дип табылалар.

Болар вакытлы күренеш кебек күзалланырга тиеш түгелләр. Әмма «Золым дәвере» төрекләрнең аңлы милли-мәдәни көчләренә зур зыян сала. Әдәбиятта төп геройның «үз эчке дөньясына качуы» тасвирлана башлый. Габделхак Хәмит Тархан (1852–1937), Риҗаизадә Әкрәм (1847–1913) романтик хисләр дөньясына бирелергә мәҗбүр булалар. Әмма европачылык һәм Европа әдипләренең тәэсирләреннән дә читләшмиләр. В. Гюго, А. Ламартин, А. Мюссе кебек романтик шагыйрьләрнең шигъри мотивлары төрек әдәбиятында актив чагылыш таба.

Алдынгы төрек әдипләре «Сәрвәти-фөнүн» журналы тирәсенә туплаактар. Төрек әдәбиятында заманча «яңа әдәбият» шул шартларда формалаша. Төрек укучысына Э. Золя, Г. Мопассан, бертуган Гонкурлар, Стендаль, О. Бальзак иҗатлары киң пропагандалана. Төрек шагыйре Тәүфыйк Фикрәт (1867–1917) иҗаты активлашып китә. Ул гади халыкның хис-тойгыларын ихлас суларак сурәтләүне, гражданлык пафосларында иҗат итүне төп юнәлеше итеп куя. Җәдитчелек юнәлешен тоткан яңа тип татар әдәбияты да шушы ук төрек әдипләре әсәрләре йогынтысын кичерми калмаган.

Бу яктан караганда, К. Мотыйгыйның әсәрләре дә тулы канлы гражданлык хисләренә бай булулары белән үзләренә укучыны җәлеп итәләр. Т. Фикрәт һәм К. Мотыйгый иҗатлары арасында охшаш һәм уртак мотивларны табуы авыр түгел. XIX йөзнең икенче яртысында, бигрәк тә соңгы чирегендә төрек прозасында үзәккә чыгарылган «кечкенә кеше язмышын» «тулы канлы» итеп сурәтләү соңрак та татар әдәбияты үсешенә шактый зур этәргеч биргән.

Төрек әдипләре мәгърифәт һәм тәрәккыять идеалларын югары күтәрәләр, әсәрләрен иҗтимагый эчтәлеккә коралар, психологизмга зур игътибар бирәләр, француз натуралистлары йогынтысында язалар. Тормыш материалын әдәби әсәр вакыйгасына әверелдерү алымнарын К. Мотыйгый татар әдәбиятында уңышлы башкарган, Г. Тукайга да аның иҗат манералары тәэсир итми калмаган.

«Яңа госманнар» эшен дәвам иттерүче «яшь төрекләр» хәрәкәте вәкилләренең ахырда милләтчелеккә бирелеп китүләре, сәяси мәсьәләләрне милли мәнфәгать кысаларына кайтарып калдырулары XX йөз башы татар әдипләрен берникадәр аптырашта калдырган, билгеле. Хәер, анысы башка мәсьәлә.

Г. Тукайның Уральски чорында язылган мәкалә-фельетоннарында «яшь төрекләр»нең фикри тәэсирләре нык сизелә. Аның «Кавказ тормышыннан» дип күрсәтелгән «Ай, бат!» (1907) хикәясе дә моны ачык күрсәтеп тора.

К. Мотыйгый оештырган Комитетның алга таба булган язмышы аерым әһәмияткә ия. Кулъязма газетадан кулъязма «Әлгасрелҗәдид» («Яңа гасыр») журналына, аннары басма журналга күчеп, алар Рәсәйнең эчке сәяси-иҗтимагый хәрәкәтләренә кушылып китәләр. Сайлауларда К. Мотыйгый оештырган «Әлгасрелҗәдид» журналы һәм «Фикер» газетасы эре буржуаз партияләрнең мәнфәгатьләрен яклаучылар буларак та үзләрен күрсәтәләр.

Г. Тукайның гражданлык пафосы белән сугарылган беренче шигырьләре һәм мәкаләләре дә шул матбугат органнарында дөнья күрә. Шунысы мактауга лаек: ул илдә, җәмгыятьтә, татар эчендә гаделлек урнаштыру юлларын эзләвен, сәяси дөрес юлны ачыкларга омтылышын туктатмый. Бу яктан аның аңы бик яшьли ачыла. Монда К. Мотыйгыйның һәм ул оештырган Комитетның роле зур булган, билгеле.

1905 елда алар Россиянең әүвәле конституцион-демократия тарафдарларына ияреп китәләр, ә 1906 елның урталарыннан алдынгы революцион партияләр ягына тартылалар. Бу инде К. Мотыйгыйның да, Г. Тукайның да «яшь төрекләр» платформасыннан китү юлына керүләре хакында сөйли торган фактлар буларак бәяләнергә тиеш. Әмма ул процесс та күптөрле фикри, иҗтимагый, сәяси, әхлакый эзләнүләр белән озатылып барылган. Халык алдында, җәмгыять каршында олы җаваплылык тоеп эш итүләре аларның

әдәби-журналистик эшчәнлегендә, мәкаләләрендә, язган әсәрләрендә чагылыш тапкан. Бу яктан Г. Тукай иҗаты шактый өйрәнелгән, К. Мотыйгыйның әсәрләре бүгенге җәмәгатьчелектән әлегә читтә калып килә. Бу юлда эшлиселәребез бар әле.

*2012*

## «Г. Тукай журнализмы»

Каләм ияләре исемнәре белән бәйле андый термин, ягъни кемнең дә булса «журнализмы» төшенчәсе әлегә фәнебездә юк. Журналистикада «журнализм» термины файдаланыла, анысы. Ул мәдәни тарихта Америка матбугаты белән бәйле барлыкка килгән.

Журналистика тарихы «журнализм»ны XIX гасырның соңгы чирегенә нисбәт итә. Әмма вакыйгалары шул ук йөзнең беренче яртысыннан башлана. 1833 елда Бенҗәмин Дэй (Америка журналисты) 1 цент бәяле «The Sun» газетасы чыгара башлый. Төп игътибар сенсацияләргә юнәлтелә: җинаятьләрне ачу, скандаллар һәм мистификация. Газетаны, ягъни матбугат органнарын ул шушы яңалыклары белән табышлы, кызыклы һәм, иң мөһиме, иҗтимагый яктан әһәмиятле итеп оештыра, халыкка чыгара башлый.

Бездә дә, татарда да, газеталарны дүртенче хөкүмәт органы («четвертая власть») дип атау гадәте бар. Әмма һәр газета да андый булып өлгереп җитә алмый. Хәтта хөкүмәт тарафыннан чыгарылучы, матди яктан тәэмин ителгән матбугат чаралары да «дүртенче хөкүмәт» дәрәҗәсенә ирешә алмый интегәләр. Аларга анда юл ябылган. Юк, моны кемдер өстән махсус кушып алай эшләми, хәер, бәлки эшли дә алмыйдыр, гаеп журналистларның, җитәкчелекнең үзендә. Моның асыл сәбәпләрен, әлбәттә, аңлый һәм төшенә белергә кирәк.

1907 елның 30 декабрендә Казаннан Уральскига, дусты Габдулла Кариевка язган хатында Г. Тукай болай дип белдерә: «Әйе, Уральскида берничә «сабый балалар» тарафыннан надан вә җаһиланә чыгарылган «Яңа тормыш» монда килеп тора. «Мәрхүмнәр!» – дим дә куям»[1]. «Үле туган» матбугат органы хакында сүз бара,

[1] *Тукай Г.* Әсәрләр: биш томда. – Т. 5. Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). – Б. 81.

әлбәттә. «Яңа тормыш»ны югыйсә үзен данлыклы журналист буларак танытkan һәм белдереп йөргән Камил Мотыйгый Төхфәтуллин, «Фикер» газетасының эшен дәвам иттереп, нәкъ шул елда бастырып чыгара, анда хәтта революцион эчтәлектәге мәкаләләр дә бирә. Әмма «Фикер» газетасының данын «Яңа тормыш» уза да, алыштыра да алмый. Тиражсыз калган матбугат органы яшәүдән туктый.

Ни өчен «Яңа тормыш» «Фикер» мәртәбәсенә ирешми, хикмәте нәрсәдә соң? Нәрсәгә Г. Тукай шушы газетаның журналистларын «сабый балалар» һәм «мәрхүмнәр» дип атый? «Яңа тормыш» та, нигәдер, «надан һәм җаһиланә чыгарылган» (монда «җаһиланә» сүзе татар халкында кулланылган «ялагай» һәм «томана» дигән мәгънәләрдә килә) газета буларак искәртелә?

Тукай тугры һәм туры сүзле. Бу яктан бәхәс итеп булмый. Әмма аңарда ихтыяри булырга чакыру гына түгел, бәлки акыл, аң, белем тантанасы белән бергә матбугатның нинди иҗтимагый дәрәҗә тотарга тиешлеген аңлау һәм сиземләү сөйли. Тукай тупас түгел, ул хакыйкатьнең үзе кебек үк ачык, аңлаешлы. Бүгенге көндәге сыман, XX йөз башында да татар матбугат чараларының күбесе «үле туганнар», зәгыйфь булганнар һәм шуңа күрә дә елдан-елларга ныгый, киңәя, көч ала барып яши алмаганнар.

Бөтен хикмәт тә тираж мәсьәләсенә килеп төртелә. Йә кемнең инде өенә макулатура алдыртып ятасы килсен, җитмәсә, акча түләп?

Моны 1833 елда ук, инде искәрткәнебезчә, Америка журналисты Бенжамин Дэй төшенеп өлгерә. Ә 1878 елда дөньяда «яңа журнализм», яки, икенче төрле аталышы белән әйтсәк, «эффектлы журнализм» барлыкка килә. Аның төп эш формасы һәм эчтәлеге төрле кампанияләр оештырудан, сенсация һәм агрессия юнәлешен мәкаләләрнең стиле итеп алудан гыйбарәт була. Вакыйгаларны мөмкин кадәр сюжетка корып бирергә омтылыш ягы да урынлы, укучыда андый язмалар чыннан да зур кызыксыну уята.

Тарихыбызга карасак, 1906 елның башында Г. Тукай Уральскидагы К. Мотыйгыйның арендага алган «Тәрәккый» («Тәрәккыййать» – ул шушы рәвешле гүяки ике төрле исемдә, ягъни кыскартып әйтү һәм тулы исеме белән атау шәкелләрендә йөртелгән) типографиясендә хәреф җыючылыктан «Фикер» газетасына корректор, аннары мөхәррир-журналист итеп күчерелә. Моңа кадәр

Бәхетҗан Каратаев җитәкләгән казакъ кадетларына хезмәт итүне максат итеп алга чыгарган, Дәүләт думасына ышаныч баглаган, аң-белем һәм мәгърифәт тарату эшенә кыйбласын төбәгән, буш эчтәлекле газета Г. Тукай аркасында тиз арада үзгәрә башлый. Әмма Г. Тукайның журналист буларак эшчәнлеге 1906 елның июнь аеннан гынаирекле көч ала. Ул аңа кадәр шагыйрь һәм хикәяче ролен башкара.

Шул 1906 елның апрель аенда газетада «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?»[1] дип аталган әһәмиятле мәкалә басыла. Тукайчылардан тәүдә Ф.-С. Казанлыдан башлап, ягъни «Г. Тукай әсәрләре» өчтомлыгыннан (1929–1931) алып бүгенге көнгә кадәр бу мәкалә шиксез рәвештә Г. Тукайга нисбәт ителә. Хәер, ул мәсьәләдә бәхәс итү урынсыз булыр. Чөнки ап-ачык күренеп тора: бу мәкалә чыннан да Г. Тукай каләме белән язылган, аңардан әдиплек мәгънәләре генә түгел, хәтта «Тукай журнализмы»ның (дөресрәге, әлегә журналист буларак та тавышы ачылып килүче Г. Тукайның) барлык үзенчәлекләре сиземләнә.

Иң тәүдә игътибар ителергә тиешле хикмәте – телендә, стилендә, аның очлы, үткен булуында, эффектында. Икенчедән, фикерләр мәкаләдә төгәл атап әйтелеп бирелгән, кискен куелганнар. Ике төрле уйларга урын калдырылмаган. Өченчедән, риторик сорау белән укучыга мөрәҗәгать итү ысулы файдаланылган. Дүртенчедән, нишләргә кирәклеге бәхәс ителмичә, ачык күзаллату юлы белән, төп фикер рәвешендә төшендерелгән. Бишенчедән, карар бирү, фәрман итү стиле файдаланылган.

Әлбәттә, мондый үзенчәлекле билгеләрен тагын да күбрәк ачыклап, аларны киңәйтергә дә мөмкин, әмма вакланып кына китәчәкләр. Шунлыктан әлеге биш сыйфатын аерып билгеләү белән чикләнергә тиешбез. Тик шунысын онытмаска кирәк: бу мәкаләсе «Тукай журнализмы»ның башы, тәүге адымнары гына. Алга таба Г. Тукай каләме аны тагын да шомарта, тагын да эффектлырак ясый. Әмма язу – бер хәл, ә язганны ишеттерә алу – икенче. Моның өчен матбугатның да тиражлы булуы шарт.

Ул вакыттагы Уральски шәһәре кебек татарның, русның, казакъның провинциясендә гомум көндәлек (хәтта атналык яисә

[1] Фикер. – 1906. – 17 апрель.

көнаралаш чыгарылучы аталсын) татар матбугаты оештыру өчен хәбәр табу, аны халыкка укырлык кызыклы итү бик җиңел эш сыман күз алдына килми. Тормыш иске рәвештә бара. Вакыт акрын кыймылдый, вакыйгалар бер-берсеннән әллә ни аерылып та тормыйлар: анда берәү өйләнгән, монда кемнәрдер аерылышканнар, кайсы кем кайсына нидер әйткән кебек яңалыклар белән матбугат чәчәк ата алмый, билгеле. Журналист кеше «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дип лаф орырга, уфтанырга мәҗбүр.

Һәм менә халыкны кузгату өчен төрледән-төрле чаралар, җыелышлар, бәхәсле утырышлар кирәклеген Г. Тукай тоеп, аңлап алган. Мондый иҗтимагый чараларны кем оештыра ала? Әлбәттә, К. Мотыйгый, аның дәрәҗәсе дә зур, сүз күтәрү ягыннан да ул аерылып тора, «серкәсенә су төшерә» торганнардан түгел. «Дәрелмөгаллимин», ягъни укытучылар әзерли торган яңа тип югары уку йортлары ачу, җәдитчелек, дин, яшәеш мәсьәләләре, китапханә оештыру, «Җәмгыяте-хәйрия» булдыру, татарларның үз мәдәни үсешләре өчен кирәкле программаларны төзү һәм аларны тормышка ашыручы комитетларны, идарәләрне сайлау һәм башка мәсьәләләр бер-бер артлы кузгатылып, болар белән бәйле эшләрне, җыелышларны уздыруны К. Мотыйгый үз өстенә алып, шулар аша «Тукай журнализмы»ның эффектлы эшләвен тәэмин итә башлый. Әмма ул моны үзе аңлап-төшенеп бетердеме икән? Әллә Г. Тукайның ихтыярына буйсынганын сизенми калдымы?

Уральскида иҗтимагый мәдәни хәрәкәт тәгәрмәчләре акрын кузгалалар, әмма Г. Тукайның эффектлы мәкаләләре аларга җан өрә (юккамы XX йөз башында татарның беренче эстрада җырчыларыннан, театр артистларыннан, һәртөрле сәнгатькәрләреннән төп вәкилләре Уральски шәһәреннән?); җыелышларда сөйләнгән берәүләрнең сүзләре көлкегә алына, икенчеләре – хуплана. Г. Тукай, әлбәттә, үзен дөреслек ялчысы итеп күрә, әмма аның каләме шәһәрнең өлкән һәм авторитетлы муллаларын, имамнарын, байларын, сәүдәгәр-миллионерларын хәтта мыскыллау объектына әверелдерә. Аның кулында – матбугат. Без аны дорфалыкта гаепли алабыз. Әйе, журналист Г. Тукайның каләме дәрәҗәләрне санга алып тормый. Ә эффекты нинди? Аның журналистлык таланты менә шунда ачыла да инде.

Аның каләме «азына» бара. Ул Казанда һәм Оренбургта чыгучы газета-журналларны да, аларда язышкан яки журналист булган авторларны да тынычлыкта калдырмый. Бигрәк тә «Бәянел-хак»ка һәм шуның юлындагы дини рухлы матбугатка, үзләрен каләм остасы санаучы буш фельетончыларга һәр мәкаләсе саен диярлек каләм очы белән төртеп-төрттереп узуны гадәте итә. Бу исә абунәчеләрнең саны һәм географиясе киңәюгә китерә, газетаның тиражы саннан-санга тизлек белән арта бара. Г. Тукайның каләме аның саен тантана итә, үткенләнә, сүзе дә үтемлегә әверелә.

Шагыйрьнең басма томнарын кулга алсак, иҗат мирасының төп өлеше менә шушы Уральски матбугатына караганын күрербез. Әгәр дә вакытында Г. Тукай үз журналистик принципларын мәйданга чыгармаган булса һәм аңа моның өчен мөмкинлекне матбугат хуҗасы К. Мотыйгый бирмәсә, ХХ йөз башы татар журналистикасы үткенлеге, иҗтимагый аң үсешен тәэмин итүче көч үзенчәлекләре белән аерылып тормас, үз юлын тапкан матбугат чарасы сыйфатында яшәмәс иде. Хәер, милли үсешебез дә мескенлектән чыгалмый калыр иде.

*2013*

## Мәҗит Гафури шигърияте

Татар укучысы өчен М. Гафури шигърияте һәрдаим игътибар күзендә булганлыгын, аның шагыйрьлек мәртәбәсе Г. Тукайныкы белән гүяки бердәй икәнлеген искәрткән язмалар матбугатыбыз сәхифәләрендә күренгәләп тора. Әйе, М. Гафуриның шигырьләре халык күңеленә тәэсир итми калмаган.

Шагыйрь яшәгән чорга «әйләнеп кайтсак», ХХ йөз башы татар матбугаты битләрендә генә түгел, бәлки «шәкерт дәфтәрләре» кебек аеруча шәхси-шәхсәни тупланмаларда да М. Гафуриның әсәрләрен Г. Тукай шигырьләре белән янәшә очрата алабыз. Моңардан чыгып кына да М. Гафуриның шигърияте татар укучысына кадерле, халык күңеленә якын булганлыгын билгеләп үтәргә мөмкин.

Әмма әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме фәне, шагыйрьлек мәртәбәсеннән чыгып билгеләгәндә, М. Гафурины һичбер вакытта

да Г. Тукай биеклегенә күтәрергә омтылмады. Асылда, аларның икесенең дә әдәбиятыбызда үз урыннары бар дип белде.

Шушы урыннарын ачык күз алдына китерү өчен, аларның үз индивидуаль иҗат үзенчәлекләрен ачыкларга кирәк. Шунысы әһәмиятле: зур әдәбиятларда әдипләр бер-берләреннән иҗатлары белән шактый кискен аерылып торалар, аларны, хәтта бер мәктәп, бер әдәби юнәлеш вәкилләре булуларына карамастан, үзара бутау мөмкин түгел. Әсәрләреннән иҗат үзенчәлекләре шулкадәр сиземләнелә ки, затлы укучылар аларны үзара бутамыйлар. Әмма шул ук вакытта ул әдәби үзенчәлекләре күренеп аерылып тору сәбәпле, иҗатта «иярүчеләргә» теге яки бу «әдип булып» язу мөмкинлеге дә, шул манерада «каләм тибрәтеп», әсәрләре белән укучыларны бутау куркынычы да туа. Бу хакта әдәбият галиме Н. Юзиев «Әдәбият чыганаклары белеме» китабында дәлилле хәбәрләрен язып та чыккан иде[1]. Мәсәлән, З. Ярмәкинең шигырьләрендә Г. Тукайга гына хас манера һәм аһәңне кабатлау очраклары бар. Кайбер әсәрләре Г. Тукайныкыннан аерылмый да кебек, хәтта образларын, символларын, мәгънәләрен һәм гыйбарәләрен дә кабатлый.

Г. Тукай, шигърият мәсьәләсенә килгәндә, М. Гафурины Н. Думави белән янәшә искә ала, кайвакытта ул исемлектә З. Бәширигә дә урын таба. Дөрес, Г. Тукай шигъри осталык мәсьәләсен генә кузгатып калмаган, бәлки бу өч әдипнең шигъриятендә уртак мотивлар, мәгънә-аһәңнәр шактый булуыннан чыгып фикер йөрткән.

Хәер, бер Г. Тукай гына түгел, Г. Ибраһимов та, мәсәлән «Әдәбият мәсьәләләре» дигән 1910 елда «Йолдыз» газетасында басылган зур күләмле мәкаләсендә, М. Гафурины Н. Думави, З. Бәшири, М. Укмаси белән беррәттән атый һәм: «Матбагатымызга байтак ук мәгълүм булган Гафури, Думави, Бәшири һәм Укмаси әфәнделәрнең яздыкларының дөрест һәм чын шигырь мәнзум булыпбулмавы хакында кул кисеп бәхәсләшерлек урыннары гайре мөтәнаһидер»[2], – дип белдерә. Алга таба фикерләренә тагын да ачыклык кертеп, ул, С. Рәмиев мисалында аңлатып, аның белән бәйле «поэт души» терминын алга чыгара һәм шигъриятнең хис

---

[1] *Юзиев Н.Г.* Әдәбият чыганаклары белеме (Әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре). – Казан: Фикер, 1998. – Б. 67–76.

[2] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 34.

үсешенә һәм тәрбиясенә хезмәт итәргә тиешлеген дәлилли. Бу яктан М. Гафурины Н. Думави белән тәңгәл куя, Г. Тукайның алардан аерылып торуын белдерә. Ә «Татар шагыйрьләре» рисаләсендә исә Г. Тукайны халыкның уй-кичерешләренә җавап таба белүче, ягъни: «Халык бөтендөнья мөселманы өчен кайгырганда, Тукаев шуны җырлады; аннан милләткә күчкәч, аның теленнән татарлык аһлары коелды», – дип, ягъни халыкчан шагыйрь буларак билгели һәм: «Вакыты белән Гафурине дә күтәргән нәрсә – шул иде», – дигән фикер уздыра[1]. Г. Ибраһимовның бәяләмәләреннән Г. Тукай белән М. Гафури шигъриятләренең халыкчанлыкта шактый охшашлы икәнлеге ачык аңлашыла. Әйе, чынлыкта да ул шулай.

Г. Тукайның вафатыннан соң татар халкы М. Гафурига тукайчылыкны саклап калучы һәм дәвам иттерүче, әдәбиятыбызны Г. Тукай эзеннән алып баручы шагыйрь итеп тә караган. Әмма М. Гафури үз оригинальлеген, үз индивидуальлеген саклаган һәм үстерә дә алган. Шунлыктан бу ике шагыйрьнең иҗатын чагыштырып өйрәнми, уртак һәм аерымлы якларын ачыкламый һич мөмкин түгел. Хәер, әдәбият галимнәребез XX йөз башының кайсы гына шагыйренә бәя бирергә алынмасыннар, аны Г. Тукай белән чагыштырмый кала алмыйлар.

Г. Тукайныкы кебек үк М. Гафури шигъриятенә дә милләтнең аяныч хәленә канәгатьсезлек, халыкның киләчәге өчен чиксез борчылу хисе хас. Үз заманында бу ике әдипнең шигъриятеннән рухи азыкның микъдар дәрәҗәсен эзләп аптыраган Г. Ибраһимов та аларны хиссез һәм җансыз шагыйрьләр дип атарга ашыкмаган.

М. Гафури шигъриятенә канәгатьсезлек, чиксез борчылу хисе хас, дидек. Һәм ул хис-тойгылар әсәреннән әсәренә бер агым рәвешендә көчәя бара. Шунлыктан аның шигърияте күңелне арыта, үзең дә тормышка, кешеләргә карата булган ышанычыңны югалта барганыңны тоясың. Гүяки бу кешелек һәм милләт бары тик авырлык һәм газап эчендә генә җәфа чигүгә дучар ителгән. Дөрес, татар әдипләре бәхеткә ирешү юлларын ул вакытларда да күрсәтә килделәр. М. Гафури да бәхетне әүвәле гыйлемдә, аң-белемдә күрде, аннан соң гади халык арасында гына табуына ышанычын тәкрарлады, ахырда, көрәшкә өндәп, хезмәт тантанасына дан җырлады.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 134.

Бу яктан XX йөз башы татар әдипләре үзара охшашлар, гүяки «игезәкләр» сыман. Моңардан чыгып әдәбиятыбызның ул чорында тәнкыйди реализм чәчәк атуын теоретиклар күптән билгеләгән иделәр инде. Тәнкыйди реализмның төп вәкилләреннән саналган М. Гафуриның ул юнәлешкә килеп керүе һәм шигъриятенең елдан-елга үсә баруы Г. Ибраһимов, Г. Халит, Х. Госман, И. Нуруллин, М. Мәһдиев һ.б. тарафыннан тәфсилле өйрәнелде, билгеләмәләр алды һәм бәяләнде. Асылда, XX йөз башы татар әдипләре иҗат эшендә бердәй һәм бертөсле үсеш юлын кичергәннәр иде. Әдәбият теориясенең ул бәяләмәләре һәм билгеләмәләре белән тулысынча килешергә кирәк, чөнки алар хакыйкатькә туры килә.

Соңгы вакытларда галимнәребезнең иҗат методы мәсьәләләрен яки тулысынча инкяр итүләрен, яисә фәнни фикерләүдән чыгарып ташларга омтылуларын тулысынча хаталы һәм буталуларга илтүче юл дип карарга кирәк. Иҗат методларын ачыклау ул әдәби әсәрләрне дөрес аңлау һәм бәяләү мөмкинлеген бирә.

Әдәбият фәнен гомумиләштерүләрдән тыш, аермалыкларны ачыклау мәсьәләсе дә кызыксындыра. Әдипләрнең зурлыгы – иҗади бердәмлекләрендә, иҗади охшашлыкларында гына түгел, бәлки ачык һәм конкрет индивидуальлекләрендә, ягъни шәхси үзенчәлекләре булуда да. Шунлыктан, М. Гафури шигърияте дигәндә, аның иҗатына хас үзенчәлекләрнең башкаларныкына охшашлыклары, уртаклыклары да, аерымлыгы мәсьәләләре дә безне тигез кызыксындырырга тиеш.

М. Гафуриның иҗатын шактый җентекләп өйрәнгән Г. Халит аның ике үзенчәлеген ачыклап биргән иде. Аларның беренчесе 1917 елгы революциягә кадәрге иҗат чорына хас, ә икенчесе – совет дәверенә. Әмма аларның үзара бер-берсенә тыгыз бәйләнештә икәнлеген алдан ук искәртергә тиешбез.

«Билгеле булганча, – дип белдерә Г. Халит, – Гафури иҗатына электән үк тормышның иң гади көндәлегенә, конкрет, җанлы күренешләренә игътибар көчле иде»[1]. Бу – беренчесе. Шуның белән М. Гафуриның иҗат кредосын ачыклап, галим аның «поэзиясенә агитацион-публицистик пафос характерлы»[2] икәнлеген дә

[1] *Халит Г.* Мәҗит Гафури // Гафури М. Әсәрләр: дүрт томда. – Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 29.

[2] Шунда ук.

ача. Бусы – икенчесе. Г. Халит аның эчтәлеген бу рәвешле аңлата: «Яңа чынбарлыкның җиңү һәм төзү пафосы – Гафури поэзиясенә бик хас сыйфат. Ул чын мәгънәсендә гражданлык һәм патриотлык пафосы иде»[1].

Дөресрәге, аның бу гражданлык һәм патриотлык пафослар белән сугарылган агитацион-публицистик шигърияте 1902 елгы «Себер тимер юлы, яки Әхвәле милләт» мәдхиясендә үк үзен ачык сиздерә һәм: «Россиягә кадәре хәл мәдех кирәк», – дип, ягъни Россияне хәл кадәре мактарга кирәклеген белдереп язуыннан ук күренә. М. Гафуриның бу пафосының үсеш этапларына игътибар итеп, Г. Халит ахырга таба шагыйрьнең «сурәтле уй-кичерешләрнең таркаулыгыннан һәм газетчыл-информацион стиль тәэсиреннән дә азат булып җитә алмавын»[2], ягъни аның тәмам социологизм белән сугарылган пафос вәкиленә әверелүен ачыклаган иде.

Г. Тукай шигъриятендә дә пафос бар, хәтта бик көчле дип әйтергә кирәк. Шунлыктан аның иҗатында кайбер галимнәр романтизм чалымнарын да табалар. Пафос һәм романтизм югары хисләрне кузгатсалар да, аларны бердәй үзенчәлекләргә ия дип карарга ярамый. Пафос ул романтизмның да, реализмның да (әйтик, социалистик реализм) уртак күренеше буларак түгел, бәлки аерым шагыйрьләрнең әдәби сыйфаты рәвешендә дә каралырга тиеш.

Әмма Г. Тукайның пафосы бөтенләй башка. Әйе, анда да патриотик һәм гражданлык хисләре белән сугарылган пафос бар, әмма Г. Тукайда ул «минминлек» һәм «без кемлек» белән сугарылган мәртәбә пафосы да. Г. Тукайдан аермалы буларак, М. Гафурида менә шушы рухи тынгысызлык белән сугарылган пафос юк. «Без сугышта юлбарыстан көчлебез», яки «Тарихында бер дә тапсыз көзгебез», – ди Г. Тукай гражданлык һәм патриотлык пафосы белән сугарылган «Олуг юбилей илә халык өмидләре»ндә.

«Минминлек», «дөньяны беләмлек» – Г. Тукайның рухи кредосы. Аны талантының көче шундый хисләр дулкынында язарга мәҗбүр итә. Әйе, М. Гафури да Г. Тукай кебек үк затлы җәдитче («Хисап көне» шигырен генә мисалга алу да җитә). Әмма М. Гафури, шуның белән бергә, минминлексез, дөньялыкта өмет чаткысы тапкан шагыйрь. Хәтта «Кызыл байрак» шигыре дә,

[1] *Халит Г.* Мәҗит Гафури // Гафури М. Әсәрләр: дүрт томда. – Т. 1. – Б. 29.
[2] Шунда ук.

башка революцион дип хаклы рәвештә аталырга тиешле әсәрләре дә гыйсъян-бунтарьлык хисе белән түгел, бәлки шатлык-сөенеч, рухи күтәренкелекне тану тойгылары белән сугарылганнар.

Г. Тукай иҗатына дөньяны тулысынча тәмам инкяр итү, аңа югарыдан карап, яратмыйча гына күз салу хас. Дөньялыкка мондый инкяр – борынгыдан, суфи шагыйрьләрдән үк килә торган пафос, бу – татар әдәбияты өчен традицион шигъри рух. М. Гафури да шундый ук юлдан баручы шагыйрь, әмма ул дөнья алдында баш иеп, аны инкяр итә, аңа югарыдан түгел, бәлки үз заманы, үз чоры бөеклегеннән генә карый һәм бәя бирә белә. Тормыш белән бәйле очракларда шушы әдәби сыйфатлары М. Гафуриның шагыйрь буларак өстенлеген тәкрарласа, яшәеш принципларыннан чыгып караганда – бу аның көчсезлеге дә иде; моны, Г. Халит билгеләгәнчә, «шигъри талантының зәгыйфьләнүенә дә китерде» дип билгели алабыз. Әмма шуны да онытмаска кирәк: М. Гафури шигъриятенең бәян ителгән бу эчке үзенчәлекләре иҗат процессының шактый катлаулы булуын, тышкы факторларга да бәйлелектә каралырга тиешлеген искәртүне сорый.

М. Гафури мәгърифәтчелек реализмыннан алып социалистик реализмга кадәр шактый тигез камил рәвештә үскән һәм бу яктан, әйтергә кирәк, дөнья күләмендә караганда – бердәнбер шагыйрь. Аның бу үсешен Г. Ибраһимов 1921 елда язылган «Берничә сүз» мәкаләсенең өченче бүлегендә тәфсилләп һәм зурлап бәяли, шагыйрьнең «Эшче» поэмасын иң яхшы әсәре буларак атый. Дөрес, 1930 елларда ул, вульгар-социологизмга бирелеп, үзе үк бу фикерләрен юкка чыгара. Әмма монысы икенче мәсьәлә.

*Окт., 2000*

## IV. АҢЛАП ТА СӨЙЛӘРГӘ БУЛА

### Г. Ибраһимов – экспрессионист әдип

Г. Ибраһимов, татар классик язучыларының берсе буларак, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында өйрәнелә. Аның иҗатының үзенчәлекләренә зур игътибар бирелә. Ул тудырган әдәби геройлар укучыларның күңелләрен яулый, сокландыра, кызыктыра. Алар беркемне дә битараф калдырмый. Әдипнең фикерләре, сурәтләгән тормыш вакыйгалары әледән-әле төрле бәхәсләр уята тора. Бу фактлар үзләре генә дә язучының иҗат мирасының тарихи һәм әдәби әһәмияте зур булуы хакында сөйли.

Г. Ибраһимовның иҗат үзенчәләре нәрсәләрдән гыйбарәт? Бу сорауга әлегә кадәр бер төрле генә җавап та юк. Әдипнең үз иҗатына бәйле 1927 елда Г. Толымбайга аталган хатында: «Мин – реалист мөхәррир. Беренче әсәремнән хәзергәчә шул мәсләктә бардым. Арада кайбер әсәрләремдә романтизм элементларының бераз куера төшкән урыннары булгалады (реакция чорында), ләкин боларда да төп мөндәрәҗә-нигез реализм иде», – дип язганына игътибар юнәлтеп, М.Х. Хәсәнов, алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның 3 томында боларны белдергән иде: «Ләкин Ибраһимовның бу сүзләренә тәнкыйть аша карарга кирәк, чөнки ул әдәбият белемендә романтизмга берьяклы, тискәре караш хөкем сөргән чорда әйтелгән; аңа вульгар социологизмның йогынтысы сизелеп тора»[1].

Мондый методологик күрсәтмәгә таянмый мөмкин түгел. Әмма Г. Ибраһимовның үзен даими рәвештә реалист буларак күрсәтүе һәм аңлатырга омтылышы аның башка язмаларында да чагылыш тапкан. Дөрес, иҗат методлары мәсьәләсе фәндә узган гасырның егерменче-утызынчы елларында гына барлыкка килгән, ул чорда

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 341.

реализм өстен куелып, романтизм кискен тәнкыйтьләнгән. Шул вакытларда романтизмны әкияти уйдырмага корылган, хыялый һәм нигезсез, тарихи әһәмияте булмаган иҗат юнәлеше дип аңлату барлыкка килгән. Мондый вульгар социологик фикер әдәбият фәнендә дә ныклап урнашырга өлгергән.

Бу мәсьәләгә ачыклык кертеп, галим Ф.Г. Галимуллин «Г. Ибраһимовның иҗат ысулы» мәкаләсендә болай дип яза: «Егерменче-утызынчы елларда иҗат методы турында сүз барганда, иң элек идеология максаты күздә тотылды. “Совет әдәбиятында романтизмны үз итәргәме-юкмы?” дигән сорау үзәк мәсьәләнең берсе булып чыкты. Романтизмны реализмнан түбәнрәк баскычта торучы иҗат ысулы дип карау булды. Реализм һәм романтизмга мөнәсәбәттә вульгар социологизм таләпләрен нигез итеп алу күзәтелде. Шундый яктылыкка куеп караганда, Г. Ибраһимов иҗатының каршылык уятуына гаҗәпләнергә кирәкме икән? Аның иҗат ысулы хәрәкәтен билгеләгәндә, “романтизмнан – реализмга” дип карауның тенденциоз булуы әйтмәсәң дә аңлашыла иде»[1].

Мәкаләдә иҗат методы һәм иҗат процессы мәсьәләсе үзәккә алып тикшерелә һәм кызыклы фикерләр әйтелә. Язучыларның әдәби әсәрләрен матурлык законнарына нигезләнеп тудырулары исәпкә алынмау кискен тәнкыйть ителеп, Ф.Г. Галимуллин фәнни әһәмияте зур булган фактларны искәртә: «Утызынчы еллар башында реальлек дәрәҗәсен билгеләгәндә «чынлык эквиваленты» дигән үлчәү куллануга чакырулар булды. Әйтик, ул елларда мәсьәләгә болай якын килү очрый: «Әгәр образ уйлап чыгарылган һәм аңар чынлыкта эквивалент юк һәм була да алмый икән, димәк, ул реаль түгел һәм шуның белән логикалы да түгел»[2]. Шушы тәнкыйть ителгән вульгар социологик фикерләр озак вакытларга әдәбият фәнендә яшәп калалар.

Ф.Г. Галимуллинның бу мәкаләсе бүгенге көндә дә мәсьәләне шул рәвешле аңларга-аңлатырга тырышуларны күздә тотып язылганлыгы аңлашылып тора. Вульгар социологик позицияләрдә торучылар, әлбәттә, реализм белән натурализмны бутаганнар. Шуның аркасында Г. Ибраһимов 1933 елда «Коммуна» газетасында, Башкортстан педагогия институты студентларының үзенә мөрә-

---

[1] *Галимуллин Ф.Г.* Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 179–180.

[2] Шунда ук. – Б. 182–183.

җәгать хатына җавап буларак, «Кайбер әдәби мәсьәләләр» мәкаләсен бастырып чыгарган һәм анда болай дип белдергән: «Мин натурализмга каршы. Тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк. Минемчә, әдәби әсәрләр тормышның каты көрәшле, күп катлаулы, бай каршылыклы тирән процессларын иҗат механизмы аркылы, җанлы сурәтләрдә гәүдәләндерү, чагылдыру юлы белән язылганда гына, социалистик реализмга ирешеп булачак»[1].

Г. Ибраһимовның иҗат юнәлеше мәсьәләсен, әдәби иҗат осталыгын ачыклау белән бәйле рәвештә эзләнүләр фәндә туктаусыз кабатланып тора. Аны реалист та, романтик та, натуралист та дип, кайбер әсәрләренә карата гына әйтелеп киленә. Әмма бу исә бөек әдибебезнең туры, аерым мәсләге булмаган икән, иҗат юнәлешен бер кыйблага гына төбәп алып бармаган дигән фикерләргә дә этәрә. Бу бик тә хаталы бәяләмә, билгеле.

Язучы, тормыш фактларын өйрәнгәндә һәм аларны яктыртканда, үзенең әйтергә теләгән фикеренә таянып эш итәргә тиеш. Ул матурлык кануннарына таянып эш итә икән, тормышны әсәрендә сурәтләп бирү ысулын да сайларга, шул сайлаган юл белән вакыйгаларны бәян итәргә хокуклы. Бары тик матурлык кануннарына хилаф китермәскә тиешле.

Г. Ибраһимовның иҗат үзенчәлекләрен галимнәр халыкара фәнни-гамәли конференцияләрдә туктаусыз чишеп баралар. XX йөз башы татар әдәбиятын әдәби-эстетик җәһәттән фәнни нигезгә салып өйрәнүче галимнәрдән булган Г. Халит бу дәвергә үзенең «Портреты и проблемы» дип аталган хезмәтендә эзлекле һәм эчтәлекле бәяләмәләр бирә, ул әдәби чорның төп үзенчәлекләрен дөрес ачыклый алган һәм күрсәткән.

«Наше литературоведение иногда представляет татарскую литературу как бы стоящей в стороне от влияния модернизма и декаденства»[2], – дип яза ул, шул чорда татар әдәбиятында модернизмның шактый көчле алга баруын дәлилләп чыга һәм мондый әһәмиятле фикергә килә: «Особенно в десятые годы, в годы революционного подъема, идейно-эстетические тенденции в творчестве

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 520–521.

[2] *Халит Г.М.* Портреты и проблемы: избранные статьи разных лет. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – С. 209.

таких демократических писателей, как Г. Тукай, М. Гафури и Г. Ибрагимова, явно свидетельствуют, что в нашей литературе были мощные зародыши романтического реализма»[1]. Алга таба бу фикерен тагын да ныгытып һәм конкретлаштырып аңлатып уза: «Характерные примеры этого выпукло отразились в творчестве Г. Ибрагимова. Такие его произведения, как «Наши дни», «Новые люди», «Сказание о красных цветах», можно рассматривать как примеры романтического реализма»[2].

Г. Халитның «романтик реализм», «синтез романтизма и реализма» төшенчәләре совет чоры әдәбият белгечләренең модернизмны шулай атауларыннан килеп туган «ачышлары» иде. Моның сәбәбе бик гади, совет фәне модернизмны, ягъни декадансны (алар икесе дә бер үк күренешкә бәйле терминнар) – «сәнгатьнең череп таркалуы күрсәткече» дип бәяли иде. Мондый методология кысаларында Г. Ибраһимовның әсәрләрен ничек модернистик дип атап тикшерергә мөмкин? Менә шуннан романтик реализм, романтизм һәм реализм синтезы кебек сәер мәгънәләр барлыкка килде.

Иҗат методы мәсьәләсендә шактый катлаулы проблемаларны кузгатып, иҗат процессы хакында чикләнгән һәм гадиләштереп, аңлап җиткерми фикер йөртүләргә каршы чыга югыйсә Г. Халит, әдәби иҗатның асылы иҗат методында гына булмавын аңлата, бәлки матурлык тудыру чараларын, юлларын барлауга һәм фәнни тикшерүгә чакыра, ачык итеп, «Творческий метод – не талисман» дип, мәкаләсенең исеменә үк чыгара[3]. Игътибар итсәк, аның бу хезмәте 1967 елда ук язылган һәм бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. Әмма шунысы да бар: Г. Халит бу китабында, асылда, үзе дә иҗат методларын барлый, тикшерә, бәяли, фикерләрен алга үстереп, аларны бәхәс кыла.

Г. Ибраһимовның әсәрләре үзенчәлеген ачыклаганда да, шул ук романтизм һәм реализм иҗат методлары белән бәйләнештә фикер йөртә, романтизм һәм реализм синтезы хакында сөйли. Моны әдипнең иҗатын бер иҗат методы кысаларында галимнең аңларга һәм аңлатырга омтылышы белән дә бәйләргә мәҗбүрбез.

---

[1] *Халит Г.М.* Портреты и проблемы: избранные статьи разных лет. – С. 206.
[2] Шунда ук. – Б. 216.
[3] Шунда ук. – Б. 281–300.

Г. Ибраһимов иҗатын фәнни эзлекле һәм барлык яктан диярлек тикшергән галим М.Х. Хәсәнов, әдәбилек үзенчәлекләренә төп игътибарын юнәлтеп, әдипнең башлангыч хикәяләрендә экспрессионистик үзенчәлекләрнең өстенлек алганлыгын ачыклый һәм болай дип аңлата: «Ибраһимовның бу чор хикәяләрендә чынбарлык белән шәхес арасындагы каршылык реаль, объектив тормыш ситуацияләрендә түгел, ә геройның экспрессив хисләрендә, эчке кичерешләрендә, рухи омтылышларында чагыла»[1], – ди. Әмма ул да Г. Ибраһимов иҗатына хас «романтик алымнарны реалистик чаралар белән якынайту»[2] мәсьәләсенә кереп, иҗат методы проблемаларын үзенчә яктыртуга алына. Хисләрнең экспрессиясе хакында сүз кузгатылып та, ул үстерелмичә, тиешенчә аңлатылмыйча калдырыла. Г. Ибраһимовның иҗатына хас бу үзенчәлек, шул рәвешле, әлегәчә чишелмәгән, фәнни яктан ачык итеп куелган хәлендә кала бирә.

Иҗат методы мәсьәләләрендә галимнәрнең бәхәсләренә керү, асылда, безне әллә ни кызыксындырмый. Әмма кайбер күзаллауларына карата фикерләребезне белдерми үтүне дә кулай күренеш түгел дип беләбез.

Без реализмның төп үзенчәлеген геройларны һәм вакыйгаларны авторның «читтән торып сурәтләвендә» күрәбез. Ә романтизмны геройларны һәм вакыйгаларны «эчтән торып», ягъни әдәби герой исеменнән сөйләүне атыйбыз. Монда реализм һәм романтизмның аерым бер якларын гына алып, катлауландырмый фикер йөртергә тырыштык. Бу исә мәсьәләне артыгы белән гади итеп аңлау һәм аңлатуга да китерергә мөмкин. Моның шулай икәнлеген белә торып, төшенеп эш иттек. Фәнни конкретлаштыру өчен башка төрле, киң планда, чәчелеп эш итү кулай дип табылмады. Экспрессионизм төшенчәсен «хисләр ташкыны», көчле эмоциональлек буларак аңлап һәм төшенеп фикер йөртү уңышлы.

Экспрессионизм ул – әдәби-мәдәни агым, XX йөзнең беренче яртысында, бигрәк тә сәнгатьтә, эмоцияләрнең көчле чагылышын тасвирда гәүдәләндереп-сынландырып сурәтләүгә корылган була. Хис-тойгыларны бу агым мөмкин кадәр күтәренке халәткә, соңгы чиккәчә җиткерергә омтыла, шуның өчен дә хис-тойгыларны, эчке

[1] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. – Б. 340.
[2] Шунда ук. – Б. 341.

кичерешләрне, тәэсирлелекне тирән мәгънә һәм эчтәлек белән бирергә дип кирәк таба. Ә моның өчен экспрессионистик, ягъни көчле хис-тойгылы сурәтләү үзенчәлекләрен булдыру сорала. Билгеле, әдәби метод буларак, язу алымы дип тә, стиль үзенчәлеге рәвешендә дә карарга була аны. Әмма экспрессионистик алымнар – романтизм һәм реализм иҗат юнәлешләренең икесенә дә хас күренеш. Әдәби геройларның уй-хисләрен дә, тышкы яктан үз-үзләрен тотышлары аша табигатьләрен дә бергә, берьюлы бирүне, әле реализм, әле романтизм планнарында язуны модернистик алымнарга хас буларак карарга тиешбез. Шулай да модернизмны, реализмнан да, романтизмнан да аерып, өченче төр иҗат юнәлеше рәвешендә аңлау-аңлатуны кабул итәргә ярамый. Хикмәте шунда: кешенең тышкы һәм эчке дөньясы гына бар, өченче дөньясы юк. Сурәтләүдә эчке һәм тышкы дөньяларның кушылма-синтезы белән эш итү модернизмга хас. Алар шулкадәр тыгыз берләштерелә, хәтта әдәби герой да чынбарлык белән хыял дөньясын үзара бутый, аера алмаслык халәткә китерелеп тасвир ителә. Укучы да аларны аермаслык хәлгә җиткерелә. Менә шул рәвешле хис-тойгылар ташкыны әсәрнең башыннан ахырынача көч агым белән үстерелеп алып барыла. Моны экспрессионизм диләр. Ул модернизмның, бигрәк тә аның яңачасының, неомодернизмның, сәнгати алымнарыннан берсе булып тора.

Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романын гына алып карыйк. Әсәр экспрессионистик планда язылган. «Яшь йөрәкләр»нең, татар әдәбият гыйлемендә кабул ителгәнчә, романтизм үрнәге булуына каршы килмибез, чөнки анда романтик хис-тойгыларны сурәтләү өстенлек итә, романтик хыял, романтик идеал аның геройларын яшәтә. Әмма вакыйгалар бу әсәрдә реалистик планда, тормыштагыча итеп тасвирланып бирелгәннәр. Менә шуның өчен Г. Ибраһимов үзен реалист язучы буларак күрә. Реалистик вакыйгалар эчендә романтик герой гаҗәеп тәэсирле ачыла, аның һәр адымы, һәр хәрәкәте хис-тойгыларны уята. Менә шушы үзенчәлеге, ягъни тормыш белән ярәшә алмавын табигый рәвештә сурәтләү экспрессионизм алымын тудыра да инде, һәм әсәрдәге шул якларны барлау һәм табу «Яшь йөрәкләр» романын дөрес аңлау-аңлатуга китерә.

Г. Ибраһимов шактый катлаулы дәвердә яшәгән, И.В. Сталин чорында репрессия корбаны булган. Иҗатына үз бәяләре белән танышканда, аның коммунистлар хакимияте, вульгар социологизм

чоры әдәби-эстетик карашларын үзгәртергә, хәтта сәнгати иҗат асылларын яшерергә мәҗбүр иткәнлеген дә аңлап эш итәргә тиешбез. Аның укучылары белән ачыктан-ачык сөйләшү чоры, үз әдәби-эстетик карашларын яшерми белдерү дәвере дип бары тик XX йөз башын саный алабыз. Хәер, татар әдәбияты белемендә вульгар социологизмны нигезләгән галимебез дә Г. Ибраһимов булды, – анысын да онытмыйк.

Әдипнең әдәби-эстетик карашларын ачык күз алдына китерү максатын тотканда, әлбәттә, аның язган әдәби тәнкыйть мәкаләләрен, әдәбиятка караган фикерләрен, әдәби әсәрләрен өйрәнү зарурлыгы туа. Шушы юнәлештә эзләнүләр алып барып, безгә бу хезмәтебездә тагын да кайбер мәсьәләләрне өстәмә рәвештә чишәргә туры килде.

Беренчедән, Г. Ибраһимовның ни сәбәпле С. Рәмиев иҗатына югары бәя бирүен ачыклау кирәк табылды, чөнки әдип нәкъ шушы эше өчен гомере буе шактый авыр тәнкыйть сүзләренә дучар була, Г. Тукайны аңламавында, тенденциозлыкта бүгенге көнгә кадәр гаепләнеп киленә. Аны акларга яки якларга тиешлебез дигән юлга бару максатыбыз булмады. Бары тик шул бәяләмәләрен өйрәнеп, С. Рәмиев шигъриятен нигә, нинди әдәби һәм эстетик критерийлардан чыгып бәяләвен беләсебез килде. Нәкъ менә шул, ягъни «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә Г. Ибраһимов, асылда, экспрессионистик алымнар хакында киң мәдәни планлы һәм әдәби-эстетик тирәнлектә фикер йөртә.

Икенчедән, Г. Ибраһимовның әдәби осталыгы нәрсәдән гыйбарәт, шуны беләсебез килсә, моңа юлны шул ук «Татар шагыйрьләре» хезмәте ача. Язучының укучыларга мәктәп дәресләреннән яхшы таныш әдәби әсәрләренә яңача, экспрессионистик алымнарын ачыклау юнәлешендә анализ ясау һәм иҗатының төп үзенчәлекләрен, асыл табигатен ачыклау, фәнни-тәнкыйди юнәлешкә караган күп санлы хезмәтләрендә аның экспрессионистик карашларга таянып фикер йөрткәнлеген, шул әдәби-эстетик агым принципларын үзләштереп, шушы юнәлештә иҗат эшчәнлеге белән шөгыльләнгәнлеген ачыклау күп белем, көч һәм вакыт таләп итә. Боларны онытырга ярамый.

Шуның өчен дә әүвәле Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» хезмәтеннән С. Рәмиевкә багышланган беренче кисәге

анализланды, әдипнең әдәби әсәрләргә карата булган бәяләү принциплары һәм таләпләре ачыкланды. Шушы бәяләренең эчтәлеге һәм тәртибе конкретлаштырылды. Г. Ибраһимовның теге яки бу термин-төшенчәне нинди эчтәлектә файдаланганлыгы төшенелеп, аларның хәзерге терминология нигезендә атамалары бирелеп, бары шуннан соң гына нәтиҗәләр чыгару зарур дип табылды. Бары шушы эшләрне башкарганнан соң гына, алга таба әдипнең әдәби әсәрләре анализланды, алардагы хис ташкынын сурәтләү, экспрессия үзенчәлекләре ачыкланды һәм бәяләнде.

Ни өчен болар хакында искәртәбез? Бары шул сәбәпле – әдипнең иҗат мирасын без дөрес аңлыйбызмы, хаталы аңлатмыйбызмы дигән сораулардан борчылуыбызны сиздерер өчен, алардан котылу юлында нинди нәтиҗәләргә ничек килә алганыбызны төшендерергә кирәк табылганга күрә, дибез. Юлың хаталы булса, максатыңның изге булуы да коткара алмый, адашасың, имеш. Бу фәлсәфә никадәр дөрестер – анысы да күренер, дидек.

Г. Ибраһимов экспрессия алымнарын һәм романтик, һәм реалистик планда язган әсәрләрендә дә бик оста файдаланган. Аны, чыннан да, бары тик яки романтизм, яисә реализм вәкиле дип тә булмый. Хәер, ул хакта да галимнәрнең фикерләре инде әйтелгән, хезмәтебездә аларның фикерләре тагын да бер кат раслану таптылар кебек.

1

Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» дип аталган монографик хезмәтендә әдәби-эстетик, әдәби-теоретик карашлары тулысынча диярлек бәян ителгән. Ул аны, билгеле булганча, 1912 елда иҗат иткән һәм 1913 елда Оренбургта аерым китап итеп бастырып чыгарган[1]. Бу вакытта ул танылган язучы, журналист, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче буларак билгеле.

Шушы хезмәтендә Г. Ибраһимов татар шагыйрьләре С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Г. Тукай иҗатларына бәйле фикерләрен белдерә һәм, аларның әсәрләрен аңлату аша, үзенең әдәби-эстетик карашларын укучыларына җиткерә. Шушы сәбәпле бу хезмәт XX йөз башы татар әдәбияты, аның мәдәни тормышы белән бәйле гыйльми тикшеренүләр өчен аерым әһәмияткә ия, әмма, моңа да карамастан,

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 553.

галимнәр аны мөмкин кадәр читләтеп үтәргә тырышалар, авторның фикерләрен кабул итәргә яки аңлатырга алынырга теләмиләр. Моның сәбәбе бик гади, әлбәттә. Хезмәттә Г. Тукаебызның шагыйрьлеге мәсьәләсе ачыктан-ачык куелган, шик астына гына булса да алынсын иде, юк шул, турыдан-туры белдерелеп-аталып инкяр ителгән. Г. Ибраһимов ни өчен шулай эшләгән? Моның җавабы табылырга тиеш иде. Югыйсә ул башка хезмәтләрендә андый фикерен кабатламый.

«Татар шагыйрьләре»н Г. Ибраһимов турыдан-туры С. Рәмиев иҗаты белән бәйләнештә башлап китә һәм үзенең күңеленә, «татар шагыйре» дигәч тә, аның исеме килүен беренче сүзләреннән үк белдереп куя[1]. Ул аның хәтта иң аз язганлыгын һәм халыкта иң аз мәгълүм булганлыгын да яшермичә әйтеп уза. «Гавам аны укый алмый; укыганнар эчендә аны тәкъдир итүчеләр дә бик аз»[2], – ди ул. Димәк, Г. Ибраһимов бу хезмәтендә С. Рәмиевнең халык арасында шагыйрь буларак танылмаганлыгын да яхшы белеп һәм аңлап эш итә, шунда ук, моның сәбәпләрен искәртүне үз өстенә алып, китап бастыручыناширләрнең зәвыксызлыгы аркасында шушы хәлнең килеп чыгуын ассызыклап уза. Әмма аның фикере «шигырь нәрсә ул» һәм «шагыйрь кем ул» дигән сораулар тирәсендә бөтерелә. Хезмәтнең аларга җавап эзләү юлында язылуы авторның һәр сүзеннән диярлек аңлашылып тора.

Безгә дә С. Рәмиевнең халык арасында танылу-танылмау мәсьәләсе, Г. Ибраһимовча фикер йөртсәк, әллә ни әһәмиятле түгел. Шуңа күрә аның хезмәтендәге һәрбер читкә алып куела барылган тезисны тикшерүгә алынмыйча, авторның әдәби-эстетик карашларын ачыклауны үзәккә куярга тиешбез.

Бу җәһәттән иң тәүдә калку итеп алга Г. Ибраһимов боларны чыгара: беренчедән, С. Рәмиевне ул «безнең шагыйрьләремез эчендә чын вә куәтле»[3] дип атый, ягъни аның чын шагыйрь икәнлеген дә, көчле шагыйрь булуын да ассызыклап белдереп куя. Димәк, алга таба ул моның сәбәпләрен, шагыйрьлек хикмәтен ачыкларга һәм ачарга тиеш булып чыга. Икенчедән, «шигърият ягыннан

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 74.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук. – Б. 75.

караганда иң алгысы вә иң куәтлесе улып»[1] торганлыгына ышанычын белдерә. Моны без С. Рәмиевнең татар шигъриятенең авангард вәкиле икәнлегенә төшендерүе буларак аңларга тиешбез.

Г. Ибраһимов фикеренчә, С. Рәмиев калган барча татар шагыйрьләреннән дә шигъри яңалык ягыннан алда бара һәм бу алдынгылыгы бик көчле бер алдынгылык булып чыга. Беренче тезиста да, икенчесендә дә ул «куәтле» сүзен куллана. Монда һичбер кабатлану юк икәнлеген аңларга кирәк. Беренчесендә куәтлелек мәсьәләсе С. Рәмиевнең чын шагыйрь икәнлегенә карый, икенчесендә исә аның авангардлыгының дәрәҗәсен белдерә. Өченче тезисын Г. Ибраһимов бу рәвешле билгели: «Аның язганнары үз бабында иң беренче урынны алып»[2] тора, ди.

Монда бигрәк тә «үз бабында» дигән терминны аңлау-аңлату зарурлыгы килеп туа. Аны шагыйрьлек белән бәйләргәме, әллә шигърилеккәме, әллә шигърияттә алдынгылык тотугамы? Бәлки, Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларын ачыклау аша гына «үз бабы» төшенчәсен аңлатып биреп буладыр? Һәрхәлдә, мәсьәлә менә шушының белән бәйле кебек аңлашыла.

Дүртенчедән, Г. Ибраһимов С. Рәмиевнең шигырьләре халык тарафыннан ирексез ятланылып, телләрдә дога урынына сөйләнелеп йөртелә дигән фикерне дә ассызыклап уза[3]. Димәк, аның төшендерүенчә, чын шигырь ул ирексез рәвештә хәтердә калырга тиеш. Әгәр дә шигырь укылуга онытыла, хисләрне кузгатмый икән, ул чын шигырь була алмый.

Г. Ибраһимовның шушы дүртенче тезисын без һәммә төрле шигырьгә бәйле рәвештә төп эстетик канун буларак алга чыгара алабыз. Әдәби әсәрнең никадәрле талантлы була алуы яки алмавы аның укучы күңеленә үтеп керә алу-алмавына бәйле икән. Телләрдә дога итеп сөйләнелеп йөртелә торган әсәрләр генә чын, зәвыклы булып чыгалар. Моны халык телендә әйтелеп йөртелә торган «навязчивость», ягъни «бәйләнчеклек» белән бәрабәр куяргамы, юкмы? «Бәйләнчек көйләр» безне, бер тапкыр колакларыбызга кергәч, озак вакытлар аптыратып-йөдәтеп бетермиләрме? Бәлки,

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 75.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

монда Г. Ибраһимов ялгышкандыр, ул «бәйләнчек шигырьләрне» чын шагыйрь дип хата белән атагандыр?

Аның шигырь хакында, шигъри сүзнең куәте турында искәртеп, «телләрдә зикер вә вирд урынына йөртелмәктәдер»[1] дигәненнән дә, әлбәттә, тирәнрәк мәгънәләр ята, бу сүзләре белән ул шигырьнең илаһилыгы хакында сүз алып бара. Алга таба шушы хезмәтендә бу тезисын тагын да киңрәк итеп ачып бирә. Без аңа әйләнеп кайтырбыз әле.

Хезмәтенең тәүге сәхифәләрендә шушы фикерләмәләрен белдерә-белдерә килеп, санап узганнан соң, Г. Ибраһимов ачыктан-ачык болай яза: «С. Рәмиев бервакытта да гавам һәм гомум тарафыннан, әллә кем шагыйрьләр кеби, тәсдикъ һәм тәкъдир ителәчәк адәм түгел»[2], – ди. Димәк, С. Рәмиевнең башка шагыйрьләр кебек халык тарафыннан чын шагыйрь буларак кабул ителмәячәген һәм халыкта танылу алмаячагын Г. Ибраһимов ачык аңлап эш итә. Моның белән ул үзенең әдәби-эстетик карашларының асылын тәгәл ачыклап та куя: халык арасында танылу һәм халык тарафыннан кабул ителү аның чын әдиплек түгел әле.

Ә тарих, мәдәни үсешебез бу сүзләрендә хаклыкның күләме шактый зур икәнлеген көннән-көнгә дәлилләп тормыймы? С. Рәмиевнең шагыйрь буларак мәртәбәсен югары куеп буламы? Бүгенге татар укучысы аны бөтенләй дә белми, диярлек. Әгәр дә Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре»ндә аның урынын шулай өстә дип күрсәтмәсә, әдәбият тарихыбыз сәхифәләренә иҗатының монографик планда өйрәнелүе дә икеле. Бу рәвешле уйларга бирелергә дә хакыбыз бар кебек. Әмма Г. Ибраһимовның бәясе белән дә килешми мөмкин түгел. С. Рәмиевнең шагыйрьлеген һәм чын мәгънәсендә шагыйрь булуын берничек тә юкка чыгарырлык түгел.

Әгәр дә Г. Ибраһимов шулай ди икән (ә ул чыннан да моны ачык белдерә), ул вакытта нәрсә соң чын әдиплек, чын шагыйрьлек? Ни өчен аның тарафыннан С. Рәмиев «чык һәм көчле шагыйрь» аталды? Нигә дип Г. Тукайның «моңлы сазында» ул шагыйрьлек күрмәде? Автор үз-үзенә каршы килмиме? Бу халыкка, гавамга каршы атылган зәһәрле кайнар ук түгел идеме? Әллә бер тендинциозлык, мин-минлек, мин кемлек кебек галәмәтләрдәнме?

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 75.

[2] Шунда ук.

Безнеңчә, бу проблеманы чишә алсак, Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларын да тулысынча төгәл һәм нигезле ачарга мөмкинлек туачак.

С. Рәмиевнең халыкта танылу алмавының сәбәбен Г. Ибраһимов шагыйрьнең артыгы белән «үзенчә», артыгы белән мөстәсна-аерымлы, артыгы белән «оригинальный» язуыннан чыгып аңлата, бары тик югары зәвыклы, сизгер күңелле өстен катлам вәкилләре генә аны кабул итәчәген, төшенәчәген аерым белдереп ассызыклый[1]. «Туң, тупас һәм калын табигатьләр, шулай ук үзләрен һәрбер адымда салкын гакыл, коры мантыйклар рамкасына тыгып йөрергә өйрәнгән “бөекләр” дә аны, әлбәттә, талант дип танымаслар һәм танымыйлар»[2], – ди ул. Шактый төгәл әйтелгән. Зәвыкларны алыштырып булмый.

Г. Ибраһимов «туң, тупас, авыр табигатьле» дигәнендә, әлбәттә, хис-тойгыларга бирелмәүче кешеләрне күздә тотып фикер йөртә, «салкын гакыл, коры мантыйк рамкаларында» йөрүчеләрне рационалистлар, исәп-хисаплылар буларак аңларга кирәк. Аларны автор «бөекләр» дип атый, ягъни әдәбиятка карата өстән караучылар, аны кирәксез һәм файдасыз дип белүчеләр күздә тотыла монда.

Шунда ук кызыклы фикер уздырыла: халык танымаса танымасын, әмма С. Рәмиев аңа карап кына бөек шагыйрь булудан туктамый[3], ди ул. Димәк, халыкта танылу алу чын шагыйрьлекнең күрсәткече түгел икән әле.

Нәрсә соң ул вакытта чын шагыйрьлек?

Сорау бу юлы да Г. Ибраһимов тарафыннан җавапсыз калдырыла. Әмма ул алга таба, укучыларына мөрәҗәгать итеп, әдәбият белемендә XIX гасырдан үстерелеп килгән культура-тарих фәнни мәктәбе вәкиле, рус галиме, әдәби тел өлкәсендә шигърият-поэтика белгече Д.Н. Овсянико-Куликовский хезмәтендә язылган фикерләргә игътибар юнәлтә, аңардан укучының шигырьне аңлау һәм кабул итүенә бәйле аңлатмаларны ала. Алардан бу чыга: шигырь яратучылар үзләре дә кечек шагыйрь булырга тиешләр, рухында шигырь яшәмәгән кеше шигырьне аңламый, шигырьне төшенүе өчен, аның үз күңелендә дә шул шигырьнең чаткысы балкырга

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Сигез томда. – Т. 5. – Б. 75.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

тиеш, әгәр дә рухында шигырьнең орлыгы юк икән, никадәр галим аталмасын, әдәбиятның кирәклеген һәм мәгънәсен таный алмаячак. Шулай итеп, бу сүзләргә бәйле, «чын шагыйрьне күңелләрендә шигырь уты булучылар гына таныйлар» дигән мәгънә чыгара алабыз. Бу, әлбәттә, субъективлык. Ә хис-тойгылар алар шундый субъектив нәрсәләр, алар кешесенә, ягъни аның холкы-фигыленә, күңел халәтенә һәм башкаларга да бәйле. Аз гына бер тәэсир дә кайсы-кемдә көчле бер тәэссорат тудырырга мөмкин. Була тагын да шундыйлар, аларга таш яуса да барыбер. Димәк, бу фикерләмәдә бернинди мантыйсызлык, хакыйкатькә хилаф итү юк. Аның белән килешергә кала.

Г. Ибраһимов, бу аңлатмага таянып, С. Рәмиевнең татар халкында шагыйрь сыйфатында танылмавының сәбәбе укучыларының тупас табигатьле булуларыннан килгәнлеген белдереп куярга кирәк таба. Ул моның белән тагын да С. Рәмиевнең заманнан алда барганлыгын, авангард шагыйрь икәнлеген, киләчәктә аны аңлаучы һәм чын шагыйрь буларак кабул итүчеләр барлыкка киләсен төшендереп ала. Болар, шулай ук, әлегә әдәбиятны аңлау-аңламау, кабул итү һәм кабул итмәү, укучының әзерлеге мәсьәләләрен искәртүдән генә, ягъни зәвык мәсьәләсен ачыклаудан гыйбарәт фикерләмәләр булып кала бирәләр. Әмма Г. Ибраһимов әдәби әсәрнең асылы хискә корылганлыгын, бигрәк тә шигырьнең эчтәлеге хис белән бәйле икәнлеген ачыклап, нигезләп уза. Хискә коры мантыйк, күңел тупаслыгы каршы куела. Әдәби әсәрне коры мантыйклы һәм тупас күңелле, ягъни зәвыксыз кешеләр генә аңламый икәнлеге ачыкланыла.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов әдәби әсәрнең талантлы булуын аның хис-тойгыга бәйләнешле икәнлегеннән чыгып бәяләргә кирәклеген ачык итеп аңлатып бирә. Тупас, коры мантыйкка корылган әсәрләрне тупас, зәвыксыз кешеләрнең генә кабул итүен, чын әдәби әсәрләрне аларның аңламавын төшендерә.

Шушы рәвешле фикерләрен алга таба үстереп, әдип шул ук вакытта С. Рәмиевтән дә «түбән һәм тупас нәрсәләр»[1] таба, әмма шагыйрьне аклап, аларны «вакытлы бер тәэсир илә»[2] язылганнар дип атый. Шул әсәрләр исемлегенә ул «Уку», «Муллалар эше»,

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 76.

[2] Шунда ук.

«Хатыннар галәме», «Театру» дигән шигырьләрне кертә, аларны хәтта «әкәмәтләр» дип атый[1]. Шуннан соң гына С. Рәмиевнең, кеше буларак, тормышын, дөньяга карашын, әхлак һәм идеалларын, нинди тәэсир астында язуын белмәвен дә искәртеп куя. Болар белән Г. Ибраһимовның һәртөрле әдипнең иҗатын яхшы күзаллау өчен аның биографиясен, әхлак принципларын, иҗат процессын өйрәнү кирәклеген инкяр итмәвен ассызыклап киткәнлеге аңлашылып тора. Әмма мондый, ягъни тарихи-биографик юл белән иҗатка бәя бирү кайбер әдипләр белән бәйле зарур да түгеллеген ачыклый[2]. Шуннан соң гына шагыйрьнең әсәрләрен аңлатуга, шуның белән үзенең әдәби-эстетик карашларын бәян итүгә керешә.

С. Рәмиевнең шигырьләре – «тугрыдан-тугры үз рухының көзгесе»[3], дип белдерә Г. Ибраһимов, укучы алдында субъективлыкны өстен чыгарып. Монда әдәбиятның тормыш көзгесе дә булуы әлегә исәпкә алынмый. С. Рәмиевнең чын мәгънәсендә шагыйрь булуын шигырьләрне «үз иркеннән башка, үзеннән-үзе» китереп чыгаруында, «хезмәт куәтен» сарыф итмичә генә язуында күрә Г. Ибраһимов. Моны шигырьләрен укыганда ук аңларга, күрергә мөмкин икәнлеген төшендерә[4]. Чын һәм көчле шагыйрь шушындый булырга тиешлеге укучыга аңлатыла. Ул сүзләргә ышана башлыйсың. Шушындый рухи стимул бирүче көчнең башкаларга сер булуын, ягъни әдипнең талантына бәйле икәнлеген ул яхшы төшенеп фикер йөртә.

Г. Ибраһимов, кабатлана-кабатлана, С. Рәмиевнең шигырьләре үз иркеннән башка, ягъни «ирадәсез» туалар дип белдерә. Моның белән ул шагыйрьнең күңелендә шигырьнең илаһи бер тәэсир аркасында барлыкка килүе хакында сөйли. Шулай итеп, С. Рәмиевнең шигырьләре күңеленнән, рухыннан кайнап чыгып барлыкка килүен төшендереп узып, Г. Ибраһимов аларга хезмәт куелмау мәсьәләсен дә ача, моның белән бергә тәнкыйть сүзләрен дә әйтә. Бу инде шигырь техникасы мәсьәләләрен кузгатуы да, поэтик яктан әсәрләрне эшләү-эшкәртү кирәклеген төшендерүе дә.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 76.
[2] Шунда ук. – Б. 77.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук.

«Аның һәрбер сүзе йөрәгенең әллә кай җиреннән кайнап, рухының төбеннән, эчке нокталарыннан ялкынланып килеп чыга»[1], – дип белдергәннән соң, Г. Ибраһимов бу яктан кызыклы гына аңлатма да биреп уза: «Хәяттә булган бер вакыйга, бер күренеш тәэсире илә аның йөрәген ут ала, рухына ялкын тулып, күңеле ашкына; шуннан соң ул, шигырь чыгаруны уйламастан, үзен-үзе оныткан хәлдә, кулына каләм ала да язарга тотына. Шуннан соң аның укучының рухын да ялкынга әйләндерер дәрәҗәдә куәтле булган шигырьләре туа: килеп чыга «Таң вакыты», килеп чыга «Авыл», килеп чыга «Дөньяга», «Ул», «Пәйгамбәр» һәм башкалар»[2].

Бу шигырьләрнең барлыкка килүендә куәтле илһам көче тәэсиренең зур булуы әдипне сокландыра. Шунысы әһәмиятле: С. Рәмиев ясалма язмый, аның күңелендә шигырь үзеннән-үзе, аерым вәзенгә салынган килеш туа. Ул моңа кадәр татар укучысы укып өйрәнгән гаруз белән дә, халык иҗатына хас силлабик шигырь үлчәмендә дә әсәрләрен кормый, бәлки әлегә барлыгы сизелмәгән-күрелмәгән, ишетелмәгән, әдәбиятта булмаган яңа төр һәм яңа тип үлчәмнәрне таба, алар ашкын бер көч белән ургылучы саф чишмәне дә, шашкын булып агылучы давылны да, кинәт тынып калган дөньялыкны да хәтерләтәләр. Нәкъ менә шушылар аның шигырьләрен сихри һәм тәэсирле итәләр. С. Рәмиевнең хис ташкыны белән язылган шигырьләреннән көчле кайнарлык, шашыну, хәтта «җенләнү» кебек үзенчәлекләргә дә тап буласың. Болар – хис ташкыны, дидек.

Г. Ибраһимовны да шушы хиссилек кызыксындыра. Әмма бу субъектив хис ташкынын объектив дөньяның, тормыш чынбарлыгының шагыйрь күңеленә тәэсире тудыра. «Хәяттә булган бер вакыйга, бер күренеш тәэсире илә аның йөрәген ут ала», – дип аңлата Г. Ибраһимов. Моның ахыры шигырь туу белән тәмамлана. Моны без «әдәби-эстетик танып белү» буларак beләбез. Әдип объектив башлангычның ролен бер дә киметми, әмма шагыйрьләрнең үзенчәлекләрен, чын мәгънәсендә шагыйрь булуларын аларның субъектив, эчке, рухи-мәдәни потенциальләрендә, хисне тасвирлый белү куәтләрендә күрә.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 77.

[2] Шунда ук. – Б. 78.

Алга таба Г. Ибраһимов, фикерләрен дәлилләп, С. Рәмиевнең шигъриятенә хас үзенчәлекләрне бәян итә һәм ике төп билгесен аерып чыгарып, тасвири рәвештә күрсәтеп уза.

Аның беренчесе моңардан гыйбарәт: «Сәгыйтьнең бу тәэссораты, бу ялкыны артык куәтле таша, күңел чыдамсыз һәм гайре табигый ашкына, шул дәрәҗәдә ки, рухның ул куәтле, хәтта тиле ашкынуын, ниһаятьсез куәтле изтирабны[1] икенчеләргә ачык әйтеп бирергә сүз җиткерә алмый, тел аларны матурлап, табигый ясап чыгарырга өлгерә алмый»[2]. Болар белән Г. Ибраһимов С. Рәмиев шигырьләренең хисси тәэсир аркасында тууларын, шул рәвешле бик тә хисле барлыкка килүләрен раслый. Һәм ул хаклы. С. Рәмиев шигырьләре көчле хис ташкынының агышы белән тәэсирле. Хәтта бер хис ташкынын икенчесе алыштырып килә. Бу ташкын киң җәелеп һәм ургылып ага. С. Рәмиевнең шигырьләрен укыганда сулыш кысыла, ә хис агымы һаман көчәя бара.

Бу исә экспрессивлык күренеше. Ул күренешне «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» болай дип төшендерә: «Экспрессивлык – сәнгатьлелек, тәэсирлелек, тәэсир итүчәнлек»[3]. Бу аңлатма белән Г. Ибраһимовның фикерләмәсе үзара туры киләләр.

Димәк, С. Рәмиев иҗатына, Г. Ибраһимов бәяләмәсенә нигезләнеп фикер йөртсәк, көчле экспрессия хас икән дигән нәтиҗәгә килергә тиешбез. Тагын да шунысын искәртик: Г. Ибраһимов – үзе дә язучы, әдип, димәк, С. Рәмиевкә бәя биргәндә, ул үзенең әдәбиэстетик карашларыннан да чыгып эш йөртә.

Моңа гына карап С. Рәмиевне экспрессионист шагыйрь булган икән дип бәяләргә ашыкмыйк. Татар әдәбияты тарихында ул романтизмның башлангыч вәкиле буларак бәяләнә һәм аның әсәрләр тупланмасын барлап, җыйнап, өйрәнеп бастырып чыгарган зур галим Ш.Г. Садретдинов бу хакта болай дип язган: «Сәгыйть Рәмиев – XX йөз башы татар демократик әдәбияты үсешендә тирән эз калдырган әдипләрнең берсе. Татар әдәбиятында романтизмның башлап мәйданга чыгуы аның иҗаты белән бәйләнгән»[4].

---

[1] *Изтирабны* – дулкынлануны.

[2] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 78.

[3] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда / төз.: *И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова һ.б.* – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – Б. 564.

[4] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. – Б. 172.

Бу фикер белән тулысынча, бәхәссез килешергә була, чөнки романтизм ул, «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә аңлатылганча, «бигрәк тә матур әдәбият өлкәсендә ачык гәүдәләнде. Романтизм язучылары реаль чынбарлыкны үзләренең таләпләре һәм тойгыларыннан, максатларыннан чыгып сурәтләргә, кеше образларын да тормыштагыча түгел, бәлки үзләре уйлаганча күрсәтергә омтылганнар»[1]. Галим А. Әхмәдуллин редакциясендә чыккан «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә исә «татар әдәбиятының барлык чорлары өчен дә романтизм юлдаш»[2] дип аңлата. Д.Ф. Заһидуллина да шушы ук фикерләргә таяна һәм: «Романтизм әдәбиятны кешеләргә яшәеш нигезләре хакында сөйләүче, белем-мәгълүмат бирүче дип карый. Сәях образы – мәңгелек буйлап сәяхәт итүче, шушы мәңгелектә үз урынын эзләүче герой өчен тарихи-географик чикләр, бу һәм теге дөнья, өн һәм төш, хакыйкать һәм хыял арасында чикләр җуела. Үткәнне – тарихны идеаллаштыру, экзотик материалга мөрәҗәгать итү, авторның субъектив позициясе ачык билгеләнү, фәлсәфи һәм лирик чигенешләр ясау күзәтелә»[3], – дип яза. Әдәбият теоретигы Ф.М. Хатипов романтизмны иҗат методы буларак түгел, бәлки иҗат тибы сыйфатында (әдәби иҗат агымы дисәк тә мөмкин) карый һәм: «Романтизм ул – художникның хәятне үзенчә күрү җирлегендә туган үзгә бер дөнья»[4], – дип, фикерен тагын да конкретлаштыра. Әдәбият теоретигы В.Е. Хализев исә романтизмны бары тик романтика чикләрендә генә күзаллый, әдәби агым яки әдәби иҗат методы төшенчәләрен кире кага, романтизм, ягъни романтиканы «авторның эмоциональлек тибы» кысаларында тикшерә, идиллия һәм сентиментализм белән бер яссылыкка куя[5]. Аның фикеренчә, идиллия белән язылган әсәрләр шатлыклы дулкынлану көче белән сугарылалар, сентиментализмда башкалар хәленә керергә

---

[1] Әдәбият белеме сүзлеге / төз. *Н. Гыйззәтуллин.* – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – Б. 142.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. *А.Г. Әхмәдуллин.* – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 157.

[3] Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / төз.-авт.: *Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов һ.б.* – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 165.

[4] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 243.

[5] *Карагыз: Хализев В.Е.* Теория литературы: учеб. – 3-е изд., испр. и доп. – М.: Высш. шк., 2002. – С. 89–92.

омтылыштан туган хиссилек өстенлек алса, романтикага анысы да, монысы да хас, әмма аңарда төрле каршылыклар, борчылулар, авторның «үз эченә чумуы» күзәтелә[1]. Шулай итеп, романтизмны бер төрле галимнәр иҗат тибы буларак, икенчеләре иҗат методы дип, өченчеләре «авторның эмоциональлек тибы» рәвешендә карыйлар. Безнең фикеребезчә, әдәбиятта романтизмның реализмнан аермасы шунда: ул геройны һәм вакыйгаларны «тыштан торып», «тышкы яктан күзәтү юлы белән» түгел, бәлки «эчтән торып», «эчке үзгәрешләрен барлау рәвешендә» сурәтли, бу мәгънәдә иҗат юнәлеше яки иҗат принцибы саналырга тиешле. Реалист әдип геройларны һәм вакыйгаларны читтән күзәтүче ролендә тасвирлап яза, эчке дөньяны тышкы сыйфат үзгәреше һәм күренешләр ярдәмендә ача, ә романтик әдип, киресенчә, геройларны һәм вакыйгаларны «эченә кереп» тасвирлый, шуның белән хакыйкатьнең чын асылын төшенүенә инанып эш итә. Болар исә төрле стильләрне, эмоциональлек үзенчәлекләрен барлыкка китерәләр. Шулай итеп без романтизмны эчке дөнья аша тышкы дөньяны ачу дип атасак, реализмны тышкы дөньяны сурәтләтү ярдәмендә эчке дөньяны төшенү дип белдерәбез. Шушы фикерләмәдән чыгып, С. Рәмиевне берничек тә романтизмның гына вәкиле дип, бер генә төрле бәяләп куя алмыйбыз. Аның иҗаты берничек тә романтизм кысаларына гына сыеп бетә алмый. Ул – романтик та, реалист та. Димәк, берсенең генә вәкиле түгел, аның иҗатында алар икесе дә бергә, бөтенлек хасил итеп яшиләр.

Г. Ибраһимов дөрес бәяли, С. Рәмиевнең шигъриятенә көчле хис ташкыны, тәэссорат-эмоциональлек, экспрессия хас, бу фикерен һичничек читләтеп үтеп булмый. XX гасыр башында модернистлар үз язмаларында, «хисле кеше» теориясен калку итеп алга чыгарып, «тәэсирле шагыйрь»нең бөеклеген, аның гына чын шагыйрь була алуын раслый иделәр[2]. Әмма Г. Ибраһимов тормыш дөреслегенең иҗат өчен стимул булуы хакында сүз алып бара. Чыннан да, хакыйкатьне күрергә, аның үзенчәлекләрен тоярга һәрбер кеше дә сәләтле түгел. Әлегә сүз бары шул хакта гына бара. С. Рәмиевнең тоя белүе Г. Ибраһимовны кызыксындыра. Аның кайнар хисләнүен дә ул дөрес таный.

---

[1] *Хализев В.Е.* Теория литературы: учеб. – 3-е изд., испр. и доп. – С. 89–92.

[2] *Мисал өчен, карагыз: Бальмонт К.* Горные вершины. – М., 1904. – С. 94.

«Язгы ташкында су ничек үзенең мәгъруф юлыннан читкә, һәртөрле юлсызлыкларга китә, Сәгыйтьнең шигърияте дә шулай, – дип белдерә Г. Ибраһимов, С. Рәмиевнең иҗатына хас төп үзенчәлекләреннән булган икенче билгесенә игътибарын юнәлтеп һәм шигырьләрендәге хис ташкынының дәрәҗәсен билгеләп. – Ягъни анлар да, артык тиле куәт белән ашкыну тәэсирендә генә язылганга, юлсызлыкка китәләр»[1]. Сүз, әлбәттә, иң беренче чиратта рифма һәм ритм бозылу хакында бара. Бу – урынлы әйтелгән бәя.

С. Рәмиевнең шигырьләренең төзелеше ул вакыт өчен татар укучысына бөтенләй дә билгеле булмаган калыпка корылганнар. Шагыйрьнең моңа кадәр укучыга яхшы таныш саналган силлабик һәм гаруз шигырь төзелешләренә бөтенләй дә каршы килгән, эчке хис ташкынына корылган һәм сулыш кысылырлык дәрәҗәгә җиткерелеп язылган әсәрләре әдәбиятта яңалыкка омтылуы белән дә бәйле булганнар. Г. Ибраһимов моны ясалма омтылыш дип исәпләми, бәлки шигъри табигатенчә әдипнең шушы рәвешле иҗат иткәнлеген төшенә һәм аңлатып бирә. Шул сәбәпле ул чын шагыйрьнең асылын аның әсәрләрендәге хиснең ялкынлы да, язгы ташкын кебек тә булуыннан күрә. Әдәбиятның хисләр белән эш итүе, хисләрне кузгатуы белән күңелгә үтеп керүе турында гомум билгеле фикерләрне раслап тормаска да мөмкинбез. Әмма хиснең экспрессив формаларда бирелүенә Г. Ибраһимовның игътибар иткәнлегенә без монда аерым тукталып китәргә тиешбез. Ул, бу яктан караганда, үз заманы өчен бөтенләй дә яңача фикер йөртүче буларак күзаллана.

Хиснең яки хисләрнең көчле дулкын рәвешендә шигырьдә һәм гомумән дә әдәбиятта бирелүенә Г. Ибраһимовның төп игътибарны юнәлтүе, М.Х. Хәсәнов билгеләп үткәнчә, «дидактизмга каршы көрәш белән кирәгеннән артык мавыгып китеп»[2] язуыннан килә. Монда, «дидактизм» дигәндә, татар әдәбиятында урта гасырчылыктан ук бик тә актив файдаланылган үгет-нәсыйхәт биреп язу күздә тотыла. Әдәбиятның, бигрәк тә шигъриятнең дидактик формаларга корылуы электән, бигрәк тә суфичылык әдәбиятына хас хикмәтләрдән үстерелеп килгәнлектән, бернинди үзгәрешсез татар әдәбиятында һаман да яшәп кала баруы, коры фикер әйтү һәм

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 78.

[2] *Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. – Б. 345.

шул фикерләрнең бер әсәрдән икенчесенә күчә-күчә кабатлануы әдәби-эстетик торгынлыкка китергән, билгеле. Әдәбиятта дидактизмның алга чыгарылуы, димәк, ул аның үсештә торгынлык чорына килеп керүе дигән сүз дә әле. Шушы мантыйк нигезендә фикер йөртсәк, С. Рәмиевнең хискә корылган шигырьләр язуы тулысы белән яңалык рәвешендә Г. Ибраһимов тарафыннан кабул ителгән, шунлыктан әдип мондый шигърияттне алдынгы, авангард буларак күзаллаган.

Әмма шигырьнең, әдәби әсәрнең хискә корылуы ул әле мәгънәсезлеккә борылуы дигән сүз түгел. Моны Г. Ибраһимов яхшы аңлап эш итә. «Шунлыктан, – дип яза ул, – аның шигырьләре мәгънә, хис һәм шигъриятнең артык голүвияте[1], артык тирәнлеге ягыннан ничаклы кыйммәтле булсалар, тел вә ләфыз җәһәтеннән караганда шул дәрәҗәдә түбән һәм кимчелекле булалар»[2]. Димәк, С. Рәмиевнең шигырьләре тел һәм сүз ягыннан караганда бик тә түбән һәм кимчелекле икәннәр. Әмма мәгънәдә, хистә һәм шигърилектә бик тә югары кимәлдә язылганнар.

Шигъри теленең табигый булмавын бәяләп, Г. Ибраһимов бу яктан С. Рәмиевне Дәрдемәнд һәм Г. Тукай белән бөтенләй дә якын куярлык түгел икәнлекне аерым басым ясап искәртеп уза[3]. Аның шушы белдергәненә татар әдәбияты тарихы фәнендә бөтенләй дә диярлек игътибар ителми үтелә. Моның ачык сәбәбе дә бар. Укучы Г. Ибраһимовның С. Рәмиевне мактавыннан тәмам хәйранга кала, шуның аркасында аның тәнкыйть сүзләренә игътибар югала. Аннары тагын да бер сәбәбе, безнең фикеребезчә, Г. Ибраһимовны аңларга омтылудан бигрәк, аның фикерләрен akларга тырышу да әдәбият фәнебездә нык тамыр җәйгән. Югыйсә, «Татар шагыйрьләре»н тәртип белән укыганда, барысы үз урыннарын ала баралар түгелме соң?

С. Рәмиевнең татар шигыренә яңа рух, яңа көч бирүе хакында фикер йөртеп, Г. Ибраһимов хискә корылган әдәбиятны дидактикага, ягъни үгет-нәсыйхәт тезгән әсәрләргә каршы куя, дидек. Әгәр дә аның әдәби әсәрдә хис белән үтә игътибарлы һәм сак эш итәргә тиешлеге хакында әйтелгән тәнкыйть сүзләре урынлы булуга әйлә-

[1] *Голүвияте* – бөек уйлары, югары фикерләре.
[2] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 78.
[3] Шунда ук.

неп кайтсак, ул шушы фикерләре белән С. Рәмиевне күкләргә чөя дип бер дә әйтә алмыйбыз. Җитмәсә, ул аның күп кенә әсәрләрен «шигырьләре рәтеннән юк итәргә кирәк»[1] икәнлеген алдан, сүзе башында ук белдереп куя.

Г. Ибраһимов фикере буенча, С. Рәмиевнең шигырьләре «табигый агымлы» түгелләр[2]. Шушы бәясен биргәндә, әдип «аның нәзымнары» дигән терминын куллана. Билгеле булганча, ул шигырь белән нәзымны үзара каршы куя. Нәзым дигәндә, тезмә белән язу күздә тотыла, аны һәрбер белемле кеше төзи, тезеп яза ала, әмма шигырь дигәндә, ул йөрәктән, кешенең белемле-белемсез булуына бәйсез рәвештә, хис ялкыны буларак, бары тик чын шагыйрь тарафыннан гына тудырыла ала.

Тел һәм сүз җәһәтеннән «табигый агымлы» шигырь нинди була соң ул? Моңа Г. Ибраһимов С. Рәмиевнең «Авыл» һәм «Сызла, күңлем!» кебек шигырьләреннән мисаллар китереп җавап бирә: «Нәкъ көлә, нәкъ елмая, нәкъ юри бәгъреңне өзә» кеби бик гаҗаиб, ят, шуның илә бәрабәр, теләнгән мәгънәне аңлатуда искиткеч муаффәкыятьле[3] булган, яки «Сызла, сызла, сызла, күңлем, сызла бер туктамыйча – сызла айлар, сызла еллар – сызла төн йокламыйча» кеби, рухның чын мәгънәсе илә аңлату өчен әллә никадәрле сәхифәләр кирәк булырлык изтираб[4] вә хаәте әләмне[5] бер-ике җөмлә илә гаҗаиб дәрәҗәдә ачык һәм тулы аңлаткан мисрагълар[6] очрый»[7], – ди ул. Димәк, Г. Ибраһимов фикеренчә, тел җәһәтеннән «табигый агымлы» шигырьләр, беренчедән, гаҗәпләндерерлек дәрәҗәдә булырга, ят, ягъни кабатланмаган, тәүге тапкыр әйтелгәндәй тоелырга, шулар белән бергә, теләнгән мәгънәне отышлы итеп җиткерергә тиешләр, икенчедән исә, рухның-җанның дулкынлануын-сыкрануын бер-ике җөмлә белән ачык һәм тулы сөйләп-аңлатып бирсеннәр. Башка төрле әйткәндә, шигырьгә «табигый агым» кабатланмас сокландыргыч мәгънә һәм хисне ачык,

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 76.
[2] Шунда ук. – Б.79.
[3] *Муаффәкыятьле* – уңышлы, отышлы.
[4] *Изтираб* – дулкынлану.
[5] *Халәте әләмне* – күңел сыкрануын.
[6] *Мисрагълар* – шигырь юллары, строфалар.
[7] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 79.

тулы чагылдырып бирү өчен хезмәт итә икән. Аңлашылып тора, Г. Ибраһимов мәгънә һәм хис бергәлеген туктаусыз үзара бәйләнештә тота, хис агымының мәгънә бөтенлегенә хилафлык китерергә мөмкин икәнлеген С. Рәмиевнең «нәзымнары»на бәйле сөйләп бирә.

«Урманның сикәлтәле юлыннан начар арба өстендә барган адәмнең гәүдәсе ни-нәрсә хис кылса, Сәгыйтьнең бәгъзе бер шигырьләрен укыганда да, чын татар, зәвыклы сизгер татар теле шуны тоячак»[1]. Г. Ибраһимовның С. Рәмиев шигырьләренә карата әйтелгән бу фикере зур әһәмияткә ия. Ул аның әсәрләренә хас төп җитешсезлекне төгәл тотып алган һәм аңлатып биргән.

Шушы юлларны укыганда, Г. Ибраһимовны С. Рәмиевнең шигырьләренә тәмам мөкиббән киткән дип әйтеп булмавын төшенәсең. Күренеп тора, ул аларны шактый каты итеп тәнкыйтьли.

Шигырьләренә җитешмәгән шул «табигый агым» С. Рәмиевкә әсәрләрен бары тик хис-тойгы стихиясенә бирелеп иҗат итүеннән килә, билгеле. Г. Ибраһимов моны төгәл аңлатып бирә, фикерләрне дәлилсез сөйләми, мисалларны мул китерә. Аларны хәтта, мисал итеп алганда, азмы-күпме тәртипкә китерүләре, төзәтүләре хакында да искәртә әдип һәм, «күрәсез, боларны укып барганда, тел «табигый акмый», әле анда, әле монда барып терәлгәндәй, төртелгәндәй була»[2] дип, С. Рәмиев шигырьләрендә рифма-ритм мәсьәләсенең хәл ителми калдырылуына уфтана. Әмма «табигый агымлы» шигырьләрен дә әдип күрми үтми, алар исәбенә «Көлсеннәр», «Таң вакыты» (аның да башы белән ахырын гына), «Авыл», «Пәйгамбәр», «Дөньяга» шигырьләрен кертә[3]. Шулардан соң, кабат нәтиҗәгә килеп, үзенең әдәби-эстетик карашларын конкретрак белдереп куюны кирәк таба һәм кабат «нәзыйм» һәм «шагыйрь» төшенчәләренә килә.

Нәзыйм дип ул сүзләрне тезмәгә салучыларны, ягъни тезмә белән язып «шигырь ясаучыларны» атый, «яздыклары чын вә куәтле шигърият белән тулган»нарны шагыйрь дип билгели[4]. Димәк, Г. Ибраһимов фикеренчә, тел җәһәтеннән караганда камил һәм ма-

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 79.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук. – Б. 79–80.

[4] Шунда ук. – Б. 80.

тур тоелган шигырьләр алар асыллары белән нәзымчылыктан, шигырь төзи белү осталыгыннан килә, ә чын шагыйрьдә исә сүзләр камил һәм матур булып та бетмәскә мөмкиннәр, әмма алар шагыйрьнең йөрәгеннән кайнап чыгалар, аның хис-тойгылары белән өртелеп туалар. «Сәгыйть начар нәзыйм булыр, – ди ул, – мин аңа карышмыйм, хәтта тәсдыйкъ итәм, әмма аның яздыклары чын вә куәтле шигърият белән тулган»[1].

Г. Ибраһимовның төп тикшерү объекты, үзе белдергәнчә, «зарурәте шигърия», ягъни «шигъриятнең асылы». Аның ни-нәрсә икәнлеген тәнкыйди фикерләре белән янәшәдә туктаусыз кузгатып бара ул. Аны әле аңларга теләү, әле белгәнен төшендереп бирү омтылышы били. Кайвакытта алар зур мәсьәләгә әверелә, һәм Г. Ибраһимов әдәби тасвир ярдәмендә сурәтләүләргә дә күчәргә мәҗбүр була.

Укучы алдында «Шагыйрь кем?» «Шигырь нәрсә?» кебек сораулар конкрет, ныклы итеп куела. Боларга җавап бирү эшенә керешеп, Г. Ибраһимов бу тезисны алга чыгара: «Бездә шигырь белән нәзымны[2], шагыйрь белән нәзыймны һаман бутыйлар»[3], – ди. Шуннан соң гына шигырь нәрсә һәм нинди булырга тиешлекне төгәл аңлатып бирә: «Безнең рух вә хыялымызга тәэсир итәчәк, хиссиятемезне, тәэссоратымызны кузгатачак һәрбер нәрсә – шигырь»[4]. Димәк, шигырь ул, Г. Ибраһимов таныганча, рухыбызга һәм хыялыбызга тәэсир итә, бу – беренчедән, ә икенчедән, хисләребезне һәм тойгыларбызны кузгата. Бер фикер тирәсенә җыеп әйткәндә, шигырьне хис-тойгыларга корылган булырга тиеш, шигырь, гомумән дә, хисләрне тасвир итүдән тора дип әйтә алабыз. Әмма бөтен әдәбият-сәнгатьнең хис-тойгыларны сурәтләүгә корылуын исәпкә алсак, Г. Ибраһимовның фикерләрендә әллә ни яңалыкны тапмабыз. Әгәр дә инде татар әдәбиятының дидактик юнәлештә иҗат итүне урта гасырлардан бирле яшәтеп, үстереп килгәнлеген, башка төрле, ягъни чын, хис-тойгыларны сурәтләүгә корылган сәнгати әдәбиятны татар укучысы танымавын һәм бидгать, бозыклык, шайтаный гамәл дип санавын искә алсак, әдипнең

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 80.
[2] *Нәзымны* – тезмәне.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук. – Б. 81.

ул фикерләренең тарихи-мәдәни яктан әһәмиятләре гаҗәеп югары икәнлеген дә төшенербез. Хәер, дидактик шигърият кысаларында талантлы шагыйрь тарафыннан язылган әсәрләр кайсы укучыны дулкынландырмый калдырырлар икән, дибез. Дөрес сорау. Моңа да нәкъ Г. Ибраһимовча җавап бирергә кирәк: тәэссоратсыз әсәр талантлы була алмый.

Монда һичбер теоретик хата күренми. Шигъри әсәргә анализ биргәндә, без аны хис бирәмлекләренә таркатабыз, шул хис бирәмлекләрен аңлатуыбыз исә шигырьне төшенүебез дигән сүз.

Билгеле булганча, чәчмә әсәрләр, ягъни эпос-дастан төренә караган әсәрләр хисне сюжетта тасвирлауга корылалар, драма төренә караган әсәрләр исә хисне драматик ситуацияләрдә тудырудан гыйбарәт булалар. Әмма ни өчен прозаик, чәчмә әсәрләр язучы Г. Ибраһимов шигърилеккә игътибар итә соң? Ул да булса бик гади, аны прозада хисне бирү юллары кызыксындыра. Моны әдип шигырьләрне өйрәнү аша ачып бирә аласын аңлап эш итә.

«Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа»[1], – ди ул. Димәк, Г. Ибраһимов фикеренчә, шагыйрь акылга һәм зиһенгә таянмый, бәлки хисләренә таяна. Ә хисләрнең чыганагы – күңел, кешенең рухы. Монда тагын да хыял хакында әйтелә.

Моңа кадәр без дә хыял мәсьәләсенә аерым игътибар бирмәскә тырыштык. Сәбәбе гади иде: әдипнең шигырьне хис-тойгыларга бәйләп каравын төгәлрәк төшенү өчен, башка юл күренмәде. Инде хыял мәсьәләсен киңрәк карый алабыз.

Хыял дигән вакытта күп очракта романтиканы, романтизмны күздә тоталар. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» аның ике мәгънәсен бирә, беренчесе романтизм төшенчәсенә бәйле, диелә, икенчесендә: «Берәр нәрсәгә карата эмоциональлек, күңел күтәренкелеге тудыра торган, кешене алга әйдәүче хисләр, фикерләр һ.б.»[2], – диелә. Романтизмга аңлатма биргәндә, өченче мәгънәсе буларак, болай дип язылган: «Романтиклык, чынбарлыкны идеаллаштыру, хыялга (тойгыга, хискә) бирелү хәле»[3]. Болардан аңлашылганча, романтика-романтизм ул әле хыял гына түгел, бәлки чынбарлык-

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 81.

[2] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. – Т. II. – Б. 598.

[3] Шунда ук.

ны идеаллаштыру да икән. Димәк, чынбарлык идеаллаштырылган вакытта гына, романтика барлыкка килә. Болардан романтизм әсәрләре чынбарлыкны идеаллаштыруга корылган булырга тиешләр икәнлеге конкрет аңлашыла башлый. Ә чынбарлыкны безнең хыял һәм теләкләребез генә идеаллаштыруга сәләтлеләр. Язучының зиһене һәм акылы реаль тормышның дөреслеген аңламый һәм төшенми калмый. Әмма ул да, шушыны аңлавыннан китеп, тормыш дөреслегеннән читләшә, аны идеаллаштыру юлына баса ала. Моның өчен аңа үзенең рухи теләк-омтылышлары ярдәмгә килә, бигрәк тә идеология басымы дәвере буларак тарихка билгеле Совет (коммунистлар) чорында эшнең шушылайрак торганлыгы яхшы мәгълүм. Әмма тормышны ничек идеаллаштырып була соң? Әлбәттә, күңел дөньясын сурәтләү аша, чөнки күңел, рухи дөнья камилме ул, түгелме – барыбер дә идеал дөнья. Тик күңел дөньясы белән тышкы чынбарлык, нинди генә камил рухи дөньяга ия булмыйк, барыбер дә үзара туры килеп бетмиләр. Өметләр акланмый калырга мөмкин, хыял канатлары да каерыла. Мондый вакытта хис-тойгылар тумыймы? Туа, билгеле. Димәк, хыялга бирелү, хыял дөньясы ул турыдан-туры бары тик романтик дөнья, романтика күренеше генә дә түгел.

«Хыял» төшенчәсенә шул ук «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» дүрт төрле аңлатма бирә: «**1.** Чынбарлыкта булмаган, ләкин уйда, күңелдә фантазия белән туган нәрсә. **2.** Чынбарлыкта яши дип күз алдына китерелгән нинди дә булса образларның уйда, күңелдә барлыкка килү процессы. **3.** Күңел теләгән һәм бик мавыктыргыч уй, фикер турында: теләк, өмет; омтылыш. **4.** Тормышка, гамәлгә ашмаслык, тормышта булмаган берәр нәрсә турында буш уй; уйдырма»[1].

Әмма әдәбият аллегорияләр һәм символлар, образлар белән эш итә. Әгәр дә С. Рәмиев «Таң вакыты» шигырендә хатаның тамыры тирәндә булуны, зур булып үсеп китеп, яфраклары коелмый каплап торулар хакында яза икән, бу бит хыялый агач түгел, бәлки борынгыдан килгән татарның хатасы хакында образлы-символик фикерләүнең нәтиҗәсе. Монда без аны агач кебек итеп күз алдына китерә алабыз. Бу яфрагын да какмыйча каплап торучы, тамырларын

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. – Т. III. – Б. 376.

тирәнгә җибәргән хатаны, ягъни наданлыкны, кояш яктысыннан каплап торучы агач кебек итеп аллегорик күзаллаудан барлыкка килгән символ-төшенчә буларак кабул итәбез. Һәм хыял диярга хакыбыз бармы? Әллә бу хыяллаумы?

*Хыяллау* сүзен шул ук «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», бер генә төрле итеп, «уйлау, күз алдына китерү»[1] дип төшендерә, ә хыяллануны «**1.** Хыялга бирелү. **2.** Акылын җую; зиһене, акылы зәгыйфьләнү»[2] дип белдерә, икенче аңлатманың гади сөйләмгә хас аңлау тәртибендә икәнлеген дә ассызыклый.

Болардан чыгып, Г. Ибраһимовның хыял хакында әйткәннәрен без хыяллау белән, ягъни уйлау һәм күз алдына китерү белән бәйләргә тиешбез. Әгәр дә хыялга бирелү хакында сүз барса, ул очракта без хыялның чикләрен ачык күз алдына китермичә, реаль дөньядан тәмам аерылып, фантастик өметләргә бирелеп, саташуга кадәр җитүне истә тотарга тиеш булачакбыз. Андый хыяллануны шайтаный хыял диярга мәҗбүрбез.

Шагыйрьнең хыялы – уйлау һәм күз алдына китерүдән гыйбарәт икәнлеген Г. Ибраһимов үзе болай итеп аңлатып бирә: «Әнә сызылып таң ата. Әнә дөньяны нурына, җәмаленә хәйран итеп кояш чыга. Әнә бөтен дөньяны матурлыгы, ләтафәте[3] кашында сәҗдә иттереп яз килә. Менә су өстләрен һәм дөньяның ярты ягын алсу-кызыл, ләкин гаҗаиб мөәссир[4] утка күмеп кояш бата. Әнә сулар, асыл чәчәкләр, әнә матур болыннар, таулар, урманнар. Әнә табигатьнең җәмаленә гыйшкыннан чыдый алмыйча сандугач сайрый башлый. Әнә моң, мөәссир музыка уйный. Әнә җәмал вә голувияте[5] кашында мең мәртәбә сәҗдә итәргә риза булган синең җанашың, үзенең озын керфекләрен сузып, ялкынлы күзләре илә сиңа сөеп карый да бөтен дөньяны оныттырачак рәвеш илә бер елмая. Көннәр кичә, син аның илә үпкәләшәсең, аерылышасыңаерыласың... Бер адәм шул таңнар, шул табигатьләр, шул җанашларны күрә, рухында ялкын, дулкын күтәрелә – моң, мөтәәссир...

---

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. – Т. III. – Б. 376.

[2] Шунда ук.

[3] *Ләтафәте* – гүзәллеге.

[4] *Гаҗаиб мөәссир* – бик тә тәэсирле.

[5] *Җәмал вә голувияте* – чибәрлек һәм күркәм уйлары.

Тота да шул ялкынны, шул тәэссерне, шул табигый сәвекъ илә[1], матурлап язып чыгара. Шуннан килеп чыга шигырь»[2], – ди.

Әдип хыял һәм хис бердәмлегенең шигырьгә ничек әверелүен һәм аңа кагылышлы ни-нәрсәләр әйтергә теләгәнен менә шушы нәсере ярдәмендә сурәтләп аңлатып бирә. Монда да, хыял дигәндә, шулай ук күз алдына китерү, уйлау хакында сүз бара, ул «хыяллау» төшенчәсенә туры килә.

Әмма «хыяллау» сүзе әдәби телебездә бөтенләй диярлек кулланылмый һәм тел табигатебезгә ят кебек тоела. «Хыялга бирелү» дигәнебез уңайлырак та, табигыйрәк тә сыман. Хыял дип без, Г. Ибраһимовтан аңлашылганча, уйланган, күз алдына китерелгән тәэсирле вакыйга-күренешне атарга тиешбез.

Әдип әдәби хыял һәм иҗатта аңарга таяну турында тагын да бер «икенче төрле» нәсер бирә: «Күрәсең, адәмнәрнең хәзерге яисә тарихи хәятләреннән бер вакыйга, бер күренеш. Бу ни белән булса да сиңа охшый, сиңа йә шатлык, йә кайгы вә яки башкача бер тәэсир бирә. Син тотасың да шул тәэссерең, шул дулкының тәэсире астында шул вакыйга, шул күренешне матурлап, гүзәлләп тасвир кыласың. Шул тормыштан алынып, кәгазьдә җанлы, тере бер тасвир, бер күренеш килеп чыга. Ул йә матур, йә ямьсез – ничек кенә булса да, укучының хыялына яңа бер галәм китереп, каршысына җанлы ләүхә бастыра, һәм үзе мөәссир дә, куәтле дә була»[3].

Бу юллардан аңлашылганча, сүз гадәти хыял хакында гына бармый. Әдип әдәби иҗатта этәрүче хыял турында фикер йөртә. Шушындый әдәби хыялны ул «менә бу да шигырь була»[4] дип белдерә. Әдәби хыялның ничек кәгазьгә әдәби әсәр буларак төшүе процессына җентекләп бирелеп тормый. Әмма аның әсәр туудагы роленең әһәмиятен ачык күзаллап яза.

Г. Ибраһимовтан аңлашылганча, тормыш факты әдипнең күңеленә тәэсир итәргә, шул тәэсир вакытында әдәби хыялы кузгатылырга, ягъни әдәби күзаллавы барлыкка китерелергә тиеш. Шушы әдәби күзаллау иҗат процессында, әдәби әсәр тууда төп рольне башкара. Шагыйрь бу әдәби күзаллавы аркасында тәэсирләнә,

---

[1] *Табигый сәвекъ илә* – табигый дәрт белән.

[2] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 81.

[3] Шунда ук. – Б. 81–82.

[4] Шунда ук. – Б. 82.

ягъни күңелен хисләр белән баета һәм шушы күзаллавын кәгазьгә төшерә, шулай әдәби әсәр туа.

Г. Ибраһимов әдәби хыялның чикләрен әдәби әсәр тудыра алу көче белән генә дә, әдәби әсәрнең барлыкка килүе белән генә дә чикләми, мәсьәләне тагын да алга таба үстерә. Әдипнең әдәби иҗатта төп максаты, аның фикеренчә, әсәр язуда гына түгел, бәлки «укучының хыялына яңа бер галәм китереп, каршысына җанлы бастыра»[1] алуда. Димәк, әгәр дә язылган әсәр укучының күңеленә, хисләренә тәэсир итә алмый, аның хыялында тасвирланган күренешләрне барлыкка китерми, сурәтләнгән вакыйгаларны җанландыра-сынландыра алмый икән, андый әсәрне шигырь дип булмый, ул нәзым гына. Бөтен хикмәт тә әдәби хыялның хисләргә тәэсир итә алу көчендә. Аннары, әдәби әсәрнең яңа бер дөнья тудыруы, тудырырга тиешлеге хакында да ул дөрес әйтә.

Чын шагыйрьләр буларак Пушкин, Лермонтов, Байрон, Гёте исемнәре китерелә. Г. Ибраһимов аларның табигатьтәгетормыштагы вакыйга-күренешләрдән тәэсирләнеп, шул тәэсир белән күңелләрендә матурлык тойгылары һәм изге уйлар туып, шулар аркасында «шигърият кайнаган»[2] әсәрләрен иҗат иткәннәрен яза. Хикмәт әдәби хыялда гына да түгел, бәлки шул хыялның гүзәллегендә һәм изге, бөек уйлар белән тулы булуында да икән. Әгәр дә әдәбиятта кемнеңдер шагыйрьме-түгелме икәнлеген бәяләргә кирәк булса, менә шушы әдәби хыялының дәрәҗәсенә, аңарга тулган гүзәллек һәм изге, бөек уйларга, хис-тойгыларга әсәре баймыюкмы икәнлегенә игътибар итәргә кирәклеге хакында искәртеп, моны Г. Ибраһимов тәнкыйтьнең бердәнбер үлчәве буларак билгеләп үтә. Шуның белән ул әдәби тәнкыйтьнең төп бәяләү принцибын төгәл ачыклый һәм: «Шул үлчәүне кулга тотып, Сәгыйтьнең шигырьләре эченә кереп китәбез», – ди. Димәк, әдәби әсәрне ул яңа мәгънәләр тудырудан, укучыда изге хисләрне тәрбияләвеннән башка күз алдына да китерми. Шулай итеп әдәбият, Г. Ибраһимов аңлаган һәм аңлатканча алсак, тормыш чынбарлыгын яңа әдәби дөнья иҗат итүе аша чагылдыра, шулай матурлык тудыра һәм кешенең хис-тойгыларын тәрбияли.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 82.

[2] Шунда ук.

Әдип, һәрбер шагыйрьнең табигате матурлыкка дан җырлаудан, матурлык алдында тез чүгүдән гыйбарәт икәнлеген искәртеп, С. Рәмиевтә мондый сыйфат «бик тирән куәт илә бар»[1] дигән фикерләмәгә туктала. Шагыйрьнең шигырьләре, аларда күтәрелгән һәртөрле темаларның укучыны тәэсирләндерүе мәсьәләсе аны даими җәлеп итә. Моны шагыйрьнең табигатькә һәм табигыйлеккә, матурлыкка соклануыннан күрә. «Бу җәмал, бу күрек аның рухын шулкадәрле югары, якты, киң галәмгә ашыра ки, аның бу мәүзугъта[2] язган шигырьләрен укыганда, үзең дә, бер генә минутка булса да, рухның күтәрелүен, каршыңа матур күренеш килеп, шуннан күңеleңә шатлык йөгергәнен сизенәсең»[3], – ди. Моның дәлиленә мисал итеп С. Рәмиевнең «Авыл» шигыре алына, аның шигъри юллары анализлана. Әдип бу әсәрнең укучы күңеленә көчле тәэсир ясау сәбәпләрен тикшерә, әдәби хыял ярдәмендә тасвир тудыра алуына, ул тасвирның бик тә гүзәл килеп чыгуына, шушы матурлык хисләрне кузгата алуга әһәмият бирә һәм мондый шигырьнең «тиңдәшен табарга мөмкин түгел»[4] дип нәтиҗә чыгара. Г. Ибраһимов бу шигырьне, фәнни нигездә караганда дип, «идиллия»гә ачык мисал буларак та бәяли. «Мин үләм» шигырен дә шундыйлар исәбеннән саный.

Шушылардан аңлашылганча, С. Рәмиевнең иҗатын Г. Ибраһимов «идиллия» белән бәйли, бер генә тапкыр да аны романтик шагыйрь буларак бәяләми. Әдәбият теоретигы В.Е. Хализев идиллияне, авторның эмоциональлек тибы буларак, сентиментальлек һәм романтика белән бәйләнештә карый[5]. Бу хакта инде искәрткән идек. «Идиллическое в литературе составляет не только сравнительно узкую область изображения жизни безмятежной, созерцательной и счастливой, – дип яза ул, – но и безкрайне широкую сферу активной, действенной устремленности людей к упорядочиванию и гармонизации их собственной жизни, без чего реальность неминуемо скользит в сторону хаоса»[6].

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 82.
[2] *Мәүзугъта* – темага.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук. – Б. 83.
[5] *Хализев В.Е.* Теория литературы. – С. 89–92.
[6] Шунда ук. – Б. 90.

Әдәбиятта романтикага килгәндә, В.Е. Хализев аны болай дип аңлата: «Романтикой принято называть умонастроение, с подъемом чувства личности, полной душевного бытия, верой человека в собственные безграничные возможности, с радостным предчувствием осуществления самых высоких, сокровенных желаний и намерений»[1].

Димәк, идиллия дигәндә, бәхет-бәхетлелек тою хисе күздә тотыла, романтика дигәндә исә, аңардан аермалы буларак, шатлык-сөенеч хисе әйдәүчегә әверелә. Беренче очракта хисләр гармониягә омтылу белән бәйле булса, икенче очракта, романтикада, хисләр шәхеснең үз көченә ышануы һәм изге хыялын тормышка ашыруга омтылышы шатлык-сөенеч тойгысына әверелдерелә. Шулай итеп, бәхет гармониясе идиллия әсәрләренә хас булса, хыялны тормышка ашыруга омтылышлы шатлык-сөенеч стихиясе романтиканы барлыкка китерә. Асылда, идиллия төшенчәсе булдырган-булган белән канәгатьлек итүдән бәхет тойгысы уянуны аңлата, романтика дип көрәш һәм җиңү пафосын, тантанасын кичерүдә рәхәтлек хисе тууга бәйле тойгыларга әйтелә.

«Әдәбият белеме сүзлеге»ндә «идиллия» терминының әдәби жанр буларак төшенчәсе алына, аны антик чор грек шагыйрьләре көтүчеләргә һәм гади кешеләргә багышлап язганнар, «табигатьнең гүзәллеген һәм авыл кешеләренең табигать кочагында тыныч һәм җай гына гомер кичерүләрен тасвирлаганнар»[2], диелә. Романтикага килгәндә, аны шушы ук сүзлек болай дип аңлата: «Художестволы иҗатта уй-хыялларны, дәртле омтылышларны, идеалларны раслауга юнәлдерелгән рухи күтәренкелек, югары *пафос*»[3]. Болардан да шул ук бәхет гармониясенең идиллия булуы, хыялларны тормышка ашырырга омтылышның романтика икәнлеге ачык аңлашыла.

Шушы фикерләмәләрдән чыгып, романтик әсәрләргә рухи омтылыш хас, идиллия әсәрләрендә канәгатьлек белән яшәү хисе төп үзенчәлек дип әйтә алабыз. Димәк, идиллия белән язылган шигырьләрдә лирик герой булганы белән канәгать итсә, шушы бәхет гармониясен урнаштырырга һәм сакларга омтылса, романтик әсәрләрдәге лирик герой үз көченә ышана һәм хыялын тормышка ашы-

[1] *Хализев В.Е.* Теория литературы. – С. 91.
[2] Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. *А.Г. Әхмәдуллин.* – Б. 55.
[3] Шунда ук. – Б. 158.

рырга җан ата булып чыга. Аның берсе булганы-барына риза, икенчесе үзгәрешләргә ашкына, гыйсъянчы.

Г. Ибраһимов исә, шулай итеп, С. Рәмиев шигъриятен идиллия белән бәйләп, аның лирик героен да барына, булганына риза булараk бәяли түгелме соң? Димәк, ул аңарда романтиклык та, романтизм да күрми булып чыга.

Г. Ибраһимовның С. Рәмиев хакында тәфсилләп бәян ителгән фикерләреннән чыгып, без шундый нәтиҗәләргә килергә мәҗбүрбез: беренчедән, ул, мәгънәле һәм җитди фикерләмәләр төзеп, «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә шигырьнең төп корылмасы итеп хисне һәм аның үзгәрешен билгели, икенчедән, хыял турында сөйләгәндә, ул әдәби хыял, ягъни әдәби күзаллау хакында яза, өченчедән, С. Рәмиев шигырьләренең идиллиягә корылган булуын ачыклый.

Алга таба фикерләрен ул мондый тезис белән дәвам итә: «Шагыйрь, әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрь булса, шөбһәсез, хиссият колы»[1], – ди һәм хисләрнең сыйфаты хакында сөйләүгә күчә. Аларны Г. Ибраһимов ачыга һәм татлыга бүлә. Бу хисләр шагыйрьдә яки нәфрәт, яки шатлык тудыралар, ягъни аның мөнәсәбәтен барлыкка китерәләр, ди.

Беренче хис итеп Г. Ибраһимов мәхәббәтне ала. Мисалга Йосыф һәм Зөләйха гыйшкы китерелә, һәр шагыйрьнең үз Зөләйхасы булуы искәртелә, шушы мәхәббәт аның өчен «хәят чишмәсе»[2] булып тора, илһам чыганагы санала, ди. Шагыйрьнең мәхәббәтен Г. Ибраһимов: «Сөйгән яр», «сөю-сөелү» мәсьәләсенең шигырьдә бик еш очравына мода яки гадәт дип түгел, табигать теләве, шагыйрьлек бәласе дип карарга тиеш»[3], дип аңлата. Илһам чыганагы буларак, сөйгән ярының матурлыгы, аңа карата булган хисләренең илаһи гүзәллек белән тасвир ителүенә мисаллар дөнья әдәбиятыннан китерелә. С. Рәмиевнең «Ул», «Бер кеше» шигырьләре дә шулар исәбеннән. «Ул» шигыренең, русчадан тәрҗемә ителсә дә, оригиналыннан күпкә яхшырак килеп чыгуы әйтелә. Шигырьләргә аерым-аерым анализ ясалып, шушы рухтагы башка әсәрләре

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 84.
[2] Шунда ук. – Б. 85.
[3] Шунда ук.

барлыгы да искәртелә. «Перчатка» шигыре тикшерелә, мондагы күз алдына китерерлек дәрәҗәдә эшләнелгән оста тасвирлар мактала.

Икенче хис итеп Г. Ибраһимов аһ-зарны ала. Аның тормыштан канәгать булмаудан тууын аңлатып уза. С. Рәмиевтән «Дөньяга», «Минем төн» шигырьләрен мисалга китерә. Төп игътибарны хиснең көчле бирелүенә һәм аның ясалмалыкмы-түгелме икәнлеген ачыкларга кирәклеген төшендерүгә юнәлтелә. Шигырьнең ясалма түгеллеген белү өчен, шагыйрьнең аны «үзе хис кылган рәвешчә чыгаруы»[1]на бәйләп бәяләү юлы барлыгын да искәртә.

С. Рәмиев шигырьләрендә зар-интизар гына түгел, хәтта нәфрәтнең дә яшерелмичә сурәтләнелүе әйтелә. Моңа мисал буларак, Г. Ибраһимов «Дөньяга» шигырен китерә һәм: «Ул дөньяга да, адәмнәр өстенә дә «ләгънәт күле» сибә, аларны ачы, усал сүзләр илә каргый, хурлый»[2], – дигән фикер уздыра. Кабат аһ-зар хисе мәсьәләсенә кайтып, Г. Ибраһимов нәфрәт хисен аһ-зар белән бәйли, аларның бер-берсенә күчүләрен ачыклый. С. Рәмиев шигырьләрендәге лирик геройның үз-үзен аһ-зардан, нәфрәттән юатуын дөньядан үч алуга омтылышына нисбәттә карый.

Г. Ибраһимов алга таба тукталган асыл фикерләрендә С. Рәмиевнең шагыйрь буларак мөстәкыйльлегенә, башкаларга иярмәвенә, халыктан һәм мохиттән үзен өстен куюына игътибар итә. Аның хакында: «Дөньяның бөтен гадәт, әдәп вә низам дип йөртә торган нәрсәләренең һәммәсеннән аша сикерә, дөньяга хөррияте шәхсияне ниһаясез югары вә мөкаддәс урынга куеп, үз хисе вә үз уена башка булган һичбер нәрсә илә хисаплашмый торган адәмнәрдән бередер»[3], – дип язып, хөр күңелле, үзенчәлекле шагыйрь булуын дәлилләп аңлата, фикерләренә дәлилгә «Мин» шигыреннән бер строфасын мисал итеп китерә. Моның татар халкы өчен көтелмәгән, табигый булмаган хәл икәнлеген дә әйтеп узуны кирәк таба: «Шундый куәтле бер сүзне күңеле төшкән, рухы үлгән, йөрәге хәлсезләнгән безем кеби татар халкыннан берәүнең әйтә алуы, – чыннан да, уйланмаган, өмид ителмәгән бер гаҗибәдер»[4], – ди.

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Сигез томда. – Т. 5. – Б. 90.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук. – Б. 92.
[4] Шунда ук.

С. Рәмиевнең идеалист шагыйрь булуына Г. Ибраһимов аерым туктала. Әмма фикерен киңәйтүне, мәсьәләне төшендереп аңлатып узуны кирәк тапмый. Ахырда «Таң вакыты» шигыренә кабат килә һәм аның эчтәлеген ачыклау эшенә керешә. Татар халкы таң вакыты кебек бер дәвердә яшәгәнен билгеләгәч, Г. Ибраһимов, шушы чорны (XX йөз башын, әлбәттә) «безнең халыкның гасырларча дәвам кылган йокысыннан, өстен каплаган кара төннән яңа дөньяга, якты кояшлы мәдәният галәменә чыгарга торган заманы»[1] буларак белдерә. Шагыйрь белән тулысынча килешеп, бу уяну дигәннәренең инде мәгърифәтле анадан яңадан туугa бәйле, ягъни татар халкының уянуын мәгърифәткә омтылышыннан күрә. С. Рәмиевкә багышланган фикерләрен шуның белән тәмамлый, алга таба Дәрдемәнднең шигырьләренә күчүче яңа бүлекне ача.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов С. Рәмиевнең шигырьләренең хис ташкынына корылганлыгына, аларда әдәби хыял-күзаллау көчле булуга төп игътибарын юнәлтә. Бу исә әдипнең үз әдәби-эстетик карашларын да ачыкларга ярдәм итә. Аның карашында С. Рәмиев идеалист, идиллия шагыйре булып гәүдәләнә. Хис ташкынына килгәндә, аларның арасыннан Г. Ибраһимов мәхәббәт хисе һәм тормышка нәфрәт белән өртелгән аһ-зар хисен аерып чыгара. Шушылар белән С. Рәмиевнең кабатланмас, баш бирмәс рухлы, алдынгы фикерле шагыйрь икәнлеге ачыла. Аның баш бирмәс рухлы булуыннан ул гыйсъянчылык һәм романтик омтылышлар күрми, болар хакында сүз дә алып бармый.

Ә безнең XX йөз урталарыннан татар әдәбияты фәне С. Рәмиевне гыйсъянчы, романтизм вәкиле шагыйре дип билгеләп хаталанмыйммы?

Г. Ибраһимовның С. Рәмиев иҗатында романтиканы күрүе хакындагы хаталы фикер әдәбиятыбыз белемендә урнашып калуның сәбәбе «Татар шагыйрьләре» хезмәтенә ясалган аңлатмаларга да бәйле. «Ибраһимов, татар тәнкыйтендә беренче буларак, – дип яза, мәсәлән, М.Х. Хәсәнов том артындагы «Искәрмәләр» өлешендә, – Рәмиев һәм Дәрдемәнд поэтик талантының романтик үзенчәлеген ачып бирде»[2].

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Сигез томда. – Т. 5. – Б. 93.

[2] *Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. – Б. 347.

Мөгаен, С. Рәмиевнең гыйсъянчылыгын, хөр рухлы шагыйрь булуын ассызыклавы аркасында Г. Ибраһимовның фикерләре шулай кабул ителгәндер? Әмма хөр рух, рухның тантанасы идиллиядә юкмыни?

Бәлки, без С. Рәмиевтә гыйсъянчылык күреп ялгышмыйбыздыр? Әмма Г. Ибраһимов С. Рәмиев иҗатында гыйсъянчылыкны да күрми, ул хакта хәтта сүз дә алып бармый, бәлки «хөррияте шәхсия» турында гына искәртә, гадәт, әдәп һәм тәртип кануннарыннан үз рухын өстен куюын яза.

С. Рәмиевнең лирик герое иҗтимагый кануннарны ватмый, җимерми, аңарга бөтенләй омтылмый да. Ул бары тик аларның «хөррияте шәхсия» каршында чүп кенә булуларын раслый, шуңа күрә дә «Мин» шигырендә:

> «Мин!» димен мин, «мин» дидисәм,
> Миңа бер зур көч керә,
> Аллалар, шаһлар, кануннар
> Булалар бер чүп кенә, –

дип белдерә.

Монда Аллаһыга каршы сүз әйтелми, билгеле, бәлки ирекле шәхес рухының бөеклегенә, тантанасына дан җырлана.

Г. Ибраһимов шуның өчен дә бу мәсьәләне аерым алып, конкретлаштырып, С. Рәмиевне идеалист дип атый. Идеалист шагыйрьгә гыйсъянчылык билгеләмәсен тагып буламы икән?

С. Рәмиев шигъриятенең хис ташкынына корылганлыгы мәсьәләсенә кире кайтып, моның сәбәпләрен искәртеп үтми мөмкин түгел.

Аңарда хис ташкыны эчке экспрессия тудыра. Моны Г. Ибраһимов дөрес төшенеп алган. Әмма бу экспрессия, хисләрнең ташкыны, романтик планда бирелмәгән, бәлки идиллия, ягъни хөр рухның өстенлегенә бәйле канәгатьлек тойгысына корылган. С. Рәмиевнең лирик герое менә шушы хиссият дөньясына чума һәм аның кысаларында яши, шуңа күрә дә ул, мәсәлән, «Пәйгамбәр»дә: «Бөтен җиргә мәхәббәт орлыгын сач!», – дип, шигырен чакыру белән тәмамлый, ә «Таң вакытында»: «Тугъ яңадан мәгърифәтле анадан... Бул кеше, үзең тырыш... Хата ул коры өмид Алладан!», – дип белдерә. Болар үгет-нәсыйхәт түгел, болар – шигъри шигарь!

Монда Аллаһыга каршы сүз әйтелми, бәлки Аллаһыдан өмет итеп утырмыйча, үзеңә тырышырга кирәклек хакында сүз бара. Болар барысы да – С. Рәмиевнең лирик героена рухи хөрлек хас булу хакында сөйли торган аерым дәлилләр. Менә шушы рухи хөрлек һәм аның дөньяда урнашуы шагыйрьгә чын бәхет буларак тоелалар.

«Идиллические ценности и воля к их воплощению широко и многопланово запечатлены русской литературой XIX в.»[1]– дип белдерә В.Е. Хализев. Рух хөрлеге шушы идиллик кыйммәтләрнең асылы булып тора да инде. XX йөз башы татар әдәбияты өчен бу үзенчәлекләрнең бик тә хас булганлыгын да әдәбият тарихыннан яхшы беләбез.

2

Г. Ибраһимов – XX йөзнең беренче чирегендә яшәп иҗат иткән иң көчле һәм данлыклы классик әдипләребезнең берсе, татар әдәбияты үсешенә иң зур өлеш керткән язучы. Болар һичшиксез бәхәссез. Шулар белән бергә, инде аңлашылганча, әдәби иҗатка ул нык-лы теоретик һәм тәнкыйди әзерлек белән килде. Аның үз фикере, үз максатлары, үз әдәби-эстетик карашлары тудырылган һәм җитлеккән иделәр. Шуларга таянып, ул «Татар шагыйрьләре» хезмәтен яза алды һәм анда үзенең дә язучы буларак үзенчәлекләрен, әдәбиятны аңлау һәм әдәбиятка нәрсәләр алып килгәнлеген, алга таба алып киләчәген ачык итеп бәян итте. Фикеребезне кабатлап, шуны ассызыклыйбыз: *Г. Ибраһимов әдәби-эстетик карашларында хис ташкынына корылган, ягъни экспрессионистик алымнарга нигезләнгән, әдәби күзаллауга таянылган идиллия стихиясеннән гыйбарәт әсәрләргә өстенлек бирде, бигрәк тә мәхәббәт хисенең матурлыкны тоярга ярдәм итүен, аһ-зар итүнең дөньяга нәфрәт белән карарга өйрәтүен мактап чыкты, шушы сыйфатларны С. Рәмиев шигърияте ннән табып, аны әдәбиятта үрнәк буларак тапты.*

Әмма аның шушы әдәби-эстетик карашлары башкалар тарафыннан яклау таптылар дип әйтеп булмый. Ул бу фикерләмәсе белән, шул ук вакытта, татар шагыйрьләренә биргән бәяләрендә

[1] *Хализев В.Е.* Теория литературы. – С. 90.

чикләнгәнлек тә күрсәтте. Төп сәбәбе – татар әдәби-эстетик традицияләрен исәпкә алмавыннан, артыгы белән яңалыкка, яңача язарга, татар әдәбиятын өр-яңа, кабатланмас, үзенчәлекле итеп күрергә тырышуыннан килде. Г. Ибраһимов хәтта халыкчанлыкның әдәби-эстетик мәртәбәсен өстен чыгармавы белән дә шик уяткан иде. Бу бигрәк тә Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәтендә чагылды. Ә югыйсә Г. Тукай шигъриятендә дә хис ташкыны, әдәби күзаллау, идиллия күренешләре, мәхәббәт хисе, дөньяга аһ-зар итү кебек сыйфатлар җитәрлек иделәр. Әмма Г. Тукай традицион шигъри формаларга үзенең иҗатында өстенлек бирде, аның шигъри образлары һәм символлары да гадәттәгечә һәм традицион иделәр. Бу исә Г. Ибраһимовка искелеккә, мәдрәсә гыйлеменә таянып яту кебек аңлашылды. Мондый чикләнгәнлек аның алга, алгарышка омтылышлары, иҗат интереслары белән януы аркасында да булды, билгеле. Аның шулай булуы инде, заманалар узгач, шиксез аңлашылып тора.

Г. Ибраһимов татарның бөек әдипләреннән берсе буларак формалашты һәм беренче әсәрләреннән үк хис ташкынын сурәтләргә омтылучы экспрессионист язучы сыйфатында күп кенә классикларыбыздан аерылып тора башлады. Дөрес, ул әле татар әдәбиятында социалистик иҗат методын нигезләүчеләрдән дә иде. Әмма бу вакыйгалар аның башка иҗат дәверенә карыйлар, без исә аның икенче, ягъни 1910–1912 елларны эченә алган язучылык чорыннан әллә ни ерак китәргә уйламыйбыз.

Тагын бер тапкыр кабатлап, галим М.Х. Хәсәновның сүзләрен искә төшереп үткәндә, урынлы булыр: «Ибраһимовның бу чор хикәяләрендә, – дип язган иде ул 1970–1980 елларда, – чынбарлык белән шәхес арасындагы каршылык реаль, объектив тормыш ситуацияләрендә түгел, ә геройларның экспрессив хисләрендә, эчке кичерешләрендә, рухи омтылышларында чагыла»[1].

Г. Ибраһимовның 1910 елда язылган һәм басылып чыккан «Яз башы» хикәясендә үк хисләр ташкыны шактый катлаулы итеп сурәтләнелә. Аның тәүге әдәби әсәрләреннән берсе санала. Әдипкә ул вакытта бары тик 22–23 яшьләр генә булган. Ә әдәби

[1] *Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. – Б. 340.

осталык белән язылуына килгәндә, бүгенге укучыны да хәйранга калдырырлык.

Бу хикәясендә Г. Ибраһимов кешенең эчке дөньясы белән тышкы чынбарлыкны каршы куя, хиснең фикергә, фикернең хискә күчешенә төп игътибарын юнәлтә, әсәренең идеясен шушы катлаулы кичерешләрне раслауга нигезләп төзи. М.Х. Хәсәнов әсәрнең тирән психологизмга корылуын раслап яза[1], хисләр ташкынының көче анда чыннан да психологик яктан чишелә.

«Яз башы» хикәясендә вакыйгалар мәдрәсәдән җәйге ялга кайткан авыл шәкертенең хис-тойгылары мул итеп сурәтләнүгә корылган. Анда, асылда, өч вакыйга бар: беренчесе малайның укуда өлгереш билгеләрен әнисенә күрсәтеп, аны сөендерүенә, кичерешләр эчендә ананың шатлык яшьләре күрсәтеп куануларына бәйле, икенчесе шушы шәкертнең авыл балалары белән урамда төрле уеннар уйнап рәхәтләнүләре хакында, өченчесе аларның авылдан өч чакрым гына ераклыкта булган күлгә балыкка барулары, кармак салулары, ахырда, яңгыр астында калмаска дип, авылга йөгерүләре, елан һәм аждаһалар хакында сөйләнелгән хәбәрләрдән артыгы белән хисләнеп, төп геройның (авыл шәкертенең) аңын югалтуы турында. Хисләр тыныч кына, салмак агымда һәм куанычка төреп бирелә, күренешләр идиллия белән өртелеп башланып китәләр. Вакыйгалар барышында шушы рәхәтлек тагын да камилләшә, мавыктыргыч күренешләргә әверелә бара. Шәкертнең уй-тойгылары бигрәк тә балык каптыру күренешләрендә тагын да мәгънәле канәгатьлек ала. Малай кешегә гүяки дөньяда башка төрле рәхәтлек була да алмас төсле: янында дуслары, ул туган авылында, рәхәтләнеп ял итә. Укулары да бик яхшы билгеләргә тәмамланган, моңа әнисе дә куанган. Герой үзе дә идиллиягә бирелгән. Балык каптыру вакыйгалары да аны хисләргә күмә. Җитмәсә, күңеленә тагын да дулкынландырулар салып, малайлар төрле әкиятләр, мифик затлар турында риваятьләр сөйләүгә күчәләр. Бу – аларның стихиясе. Герой ышанучан. Ул әлегә юкны бардан аера белми. Димәк, яшүсмер дә түгел. Мәдрәсәдә белем алып кайткан, дини ырым һәм хорафатларга тәмам ышанган бала башка төрле була да алмагандыр.

[1] *Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 3. – Б. 340.

Менә шушы сыйфатлары, җитмәсә артыгы белән хисләнүләре аны харап итә дә инде. Язучы бу фактны шундый оста итеп тасвир кыла, укучы да геройның хис-тойгыларына иярә, төрле кичерешләргә бирелә. Бары тик оста каләм иясе генә мондый вакыйгалардан тәэсирле әсәр барлыкка китерә ала.

Шәкерт, әсәрдә сурәтләнелгәнчә, һушына килгәнендә, рус кешесе кыяфәтле врачның әйткән сүзләрен искәрә: «Хыялдан нинди бәлаләр туа бит»[1], – ди ул. Шушы сүзләрне авторның укучыга җиткерергә теләгән төп фикере дип тә кабул итә алабыз. Аңлашылып тора: хыялга бирелүе Салих исемле шушы шәкертнең артыгы белән хисле булуыннан килә. Аның акылы саташып авыруы хакында автор бер сүз дә әйтми.

Хикәянең ахырында вакыйгаларны болай тәмамлавы белән Г. Ибраһимов үзенең әдәби-эстетик карашларына каршы киләдер сыман. Әмма, шул ук вакытта, врачның сүзләре аша әдип хыялланугa, хыялланудан юләрләнүгә кадәр җиткерүче хис-тойгыларны сурәтләгәнлеген дә укучыга хәбәр итә түгелме?

Билгеле, Салих, әгәр дә күңеле хис-тойгыларга бай булмаса, тормыш вакыйгалары, авылга кайтуы, әнисенең сөенүе, дус малайлары белән рәхәт уеннар уйнап, тәмам рәхәтлек белән тулмаса, бәлки көчле хыялга һәм кичерешләргә дә бирелми калыр иде. Әмма малай таш йөрәкле түгел, ул уйчан, фикерле, күз алдына китерү сәләте дә көчле. Аңа моның өчен каралып килгән һәм яшен ташларын атучы яңгыр болыты да, күл буенда шаулаган камышлар да, җил белән тузан-туфрак күтәрелү күренешләре дә ярдәм итәләр.

Г. Ибраһимов шушы табигать детальләрен, Салихның күзаллавын сөйләр өчен, бик оста файдалана. Әүвәле бер вакыйгадан икенчесенә геройның яңара барган хис-тойгылары, тәмам бергә җыелып, хыялый хис ташкынына күчәләр. Вакыйгаларны әдип үзара шундый да яраштырып һәм бөтен итеп кора, укучының хис-тойгылары баштарак аяз күкнең зәңгәрлеге кебек сыек кына тоелсалар да, алга таба куера барып, ташкын сыман ургылып килүче болытның үзенә әверелгәндәй булалар. Бу, чыннан да, тирән психологизмны барлыкка китерә. Әсәрнең вакыйгалары хис-тойгылар эченә күмелеп кала. «Яз башы»ның эчтәлегеннән, сурәтләнелгән

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Хикәяләр (1907–1929). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – Б. 64.

вакыйгалар барышыннан бигрәк, аңардан алган тәэссорат өстен чыга. Болар әсәрнең психологик экспрессионизм алымы белән язылганлыгын раслап торалар. Вакыйгаларның агышыннан бигрәк, хисләрнең кайнаган ташкын итеп тасвирланып бирелеше күңелдә уңай хисләрне уятырга сәләтле.

Хыялга бирелү, хис-тойгылар эчендә яшәү Салих исеме белән бирелгән геройның характерлы сыйфатымы, әллә авторның позициясеме? Әлбәттә, автор позициясе. Г. Сәгъди, мәсәлән, Г. Исхакыйның язучылык осталыгы артуда аның рационализмнан сентиментализмга күчүен төп сәбәп итеп дәлилләп аңлатып биргән[1]. Бу факт язучының нинди эмоциональлек юнәлешен сайлап алуы хакында ачык сөйли. Г. Ибраһимов та, беренче карашка, нәкъ менә сентиментальлекне, хисләрне сурәтләү юлын үз иткәндер кебек. Бу аның өчен әдәби сүз буларак аңлашылган, әлбәттә. Әгәр дә ул иҗат иткән дәверне исәптә тотсак, татар әдәбияты шул чорларда бер әсәрдән икенчесенә күчеп килгән фикерләрдән, тормышны рационалистик юл белән сурәтләп бирүдән уза алмый аптырагандыр кебек. Асылда, бу хәл публицистик стиль белән әдәби әсәрләр тудыру аркасында шулай килеп чыккан.

Әдәби стиль исә сурәт барлыкка китерүгә юнәлтелә, ә аның өчен хис-тойгыларны оста итеп тасвирлый белергә кирәк. Г. Ибраһимов кайсы эмоциональлек юлын сайлаган соң? Сентиментализмнымы, әллә идиллиянеме?

Сентиментализм үзе XVIII йөз ахыры – XIX гасыр башында Европа әдәбиятында һәм сәнгатендә төп әдәби алымнарның берсе була. Әмма шул чордан соң да ул үзенең әдәбиятта көчен һәм әһәмиятен югалтмый, бәлки, сентиментальлек буларак, геройларның бигрәк тә хис-тойгыларын сурәтләүдә ышанычлы психологик алым сыйфатында сакланып кала. Татар әдәбиятында аның барлыкка килүе һәм яшәү тарихы өйрәнелеп, ачыкланылып җиткән күренеш түгел. Сентиментализм һәм рационализм дигәндә, асылларында берникадәр шул ук романтизм һәм реализм арасындагы аерманы күрәбез. Әмма сентиментализм һәм романтизм, рационализм белән реализм араларында тигезлек билгесе куярга мөмкинлек юк. Шулай ук сентиментализм белән сентиментальлек тә

---

[1] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. – Б. 125.

бер үк төшенчәләр түгел. Хис-тойгыга бирелү реализм методы белән тудырылган геройларга да хас була ала.

Аны без, геройның хис-тойгыларга бирелүен сурәтләүне, реалистик әсәрдә «әдәби чигенеш»нең уңышлы бер төре буларак кына кабул итәбез. Сентиментализмда геройның эчке хис-тойгылары тәэсирле һәм ачык чагылыш ала.

Г. Ибраһимов та «Яз башы» хикәясендә сентиментальлекне шулкадәр мул куллана, ул хәтта әсәрнең төп нигезен хасил итә башлый кебек. Әмма әсәрнең әдәби тукымасы сентиментализмга корылмаган. Хикәясен автор Салих авызыннан сөйләтә. Аның герое, әнисе күзләреннән тамган сөенечле күз яшьләренә нисбәттә, «боларның нидән һәм ни өчен килгәнен мием белмәсә дә, эчем сизә иде»[1], ди. Шушы рәвешле, автор күңел дөньясын акылдан өстен куя.

Ул С. Рәмиевнең шигъриятенә анализ ясаганда да, нәкъ шушы хакта фикер йөртеп: «Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа»[2], – ди Г. Ибраһимов. Монда сүзнең шигырь хакында гына түгел, бәлки гомумән дә нәфис әдәбият белән бәйле барганлыгы аңлашылып тора. Тагын да шунысы бар: әдипнең әдәби-эстетик карашлары «Татар шагыйрьләре» хезмәте язылганга кадәр үк формалашып җиткән һәм әдәби иҗатында чагылыш тапкан булган. Язучылык осталыгы да үсә барган. Хаталары да күренә.

Мәсәлән, «Яз башы»нда, шәкерт Салих авызыннан вакыйгаларны «сөйләтеп» барганда, Г. Ибраһимов әдәби мантыйкта ялгышлык ясый. Әсәргә егет кешеләргә хас хисләр килеп керә: «Бу киң вә дулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан назлы кыз йөреше кеби боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә»[3].

Малай кеше елганың агышын кызлар йөреше белән чагыштырып фикерли белми, билгеле. Бу урында автор башкача, казүрдәкләр яисә сыгылмалы кармак сабы, яки боргаланып киткән

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 52.
[2] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 81.
[3] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 55.

авылга таба илтүче сукмак, юл белән чагыштырудан сурәт ясый алган булыр иде.

Хикәянең үзендә дә башка андый «әдәби ялгышу» очрамый, әсәрнең башыннан ахырына таба хис һаман да көчәя бара, тойгылар яңгырашы арта. Үзәк нокта булып балык каптыру вакыйгаларында барлык хис-тойгылар җыелып төйнәлер сыман аңлашыла. Әмма автор вакыйгаларны тагын да алга алып китә. Игътибар итсәк, хиснең, мәсәлән, бер төенләнешен Г. Ибраһимов ничек итеп бирә: «Кармакның суга китүе белән, барлык тәнем кайнап, эчем әллә нинди бер кызу белән тулганын тойдым»[1]. Бу инде сентиментальлек тә, идиллия дә түгел, монда эчке бер хисләр киеренкелеге, экспрессия бар.

Г. Ибраһимов хикәянең башыннан ахырынача менә шушы рәвештә тойгы-хисләрне киеренке итеп сурәтләп-сурәтләп ала да, әдәби чигенешле берничә җөмлә кертеп, укучыны беразга тынычландырып куя, аннары тагын икенче бер яклап хисләрне ялкынлы халәткә күтәрттерә, кабат «йөрәккә сулыш алу» мөмкинлеген бирә. Салихның хисләре өчен куану, бәхеткә ирешү тойгысы укучыны биләп ала. Балык каптыру вакыйгасына корылган бүлекчәдә генә дә шушындый кискен үзгәрешле дүрт үзәк бар. Героеның эчке кичерешләрен генә түгел, автор башкаларның эшхәрәкәтләрен сурәтләүдә дә әдәби экспрессив детальләрне оста файдалана. Мәсәлән (вакыйга Апрай исемле малай белән бәйле бара): «Ул, су кырыена үләнгә төшкән балыкның өстенә егылып, тотарга маташа, үзе бизгәк кебек калтырый, кабалана иде...»[2]

Монда да сурәтләнелгән хисләр динамикасының көчен тоябыз. Балыкның малай кулыннан читкә сикерүе дә, Апрайның аңа кабат ташлануы да, дулкынланулары да күз алдына килә.

Экспрессив детальне, әлбәттә, тулы текст эчендә укырга кирәк, ул вакыйгаларның динамик барышында тагын да тәэсирле яңгыраш ала. Моның сәбәбе бик гади: экспрессия сурәтнең өзлексезлеген, эчтәлек агышының катлаулы һәм тизләнештә булуын таләп итә.

Г. Ибраһимов шушы «Яз башы» хикәясендә хис-тойгыларны тәэсирле итеп сурәтләп килә-килә дә, иң тәэсирле ноктасына китереп җиткергәндә, вакыйгалар барышына хыялый, мифик-әкияти

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 57.
[2] Шунда ук. – Б. 58.

юха, аждаһа турындагы хәбәрләрне кертә. Алар чыннан да вакыйга эчендә вакыйга күренешен алалар, хикәяне тагын да мәгънәлерәк һәм катлаулырак итеп баетып җибәрәләр. Асылда, алар Салихның һәм аның иптәш малайларының хыялында башкалардан ишетү аркасында гына барлыкка килгән күзаллаулар. Әмма көннең үзгәрүе, яшенле яңгыр, җил, куе камышлар шул хыялый дөньяны малайның тойгыларында «реальләштерә». Хис-тойгыга бирелүчән Салихның «күз алдында» (дөресрәге, күңел күзе алдында) хыял белән хис, бергә кушылып, «чынбарлыкка әвереләләр». Малай, йөгереп барган җиреннән куркып, аңын җуеп, җиргә егыла.

Монда автор хис-тойгыларны бирүне шундый да экспрессив алымнар белән алып бара ки, картиналар укучы күңелендә дә тиз-тиз, динамик алышыналар, хисләр куера, йөрәкне ялкынсыта. Сәнгатьнең тәэсире нинди көчле булуын укучы менә шушы урында тулысынча сизә.

Әгәр дә бу хикәя сентименталь генә булып калса, аңарда мондый экспрессив вакыйга урыннары очрамас, очраганда да бу рәвешле ачылмас иде. Салихның әнисе белән икесе арасында барган сөенечле вакыйгалары, асылда, сентиментальлек һәм идиллия белән чигелсә, монда инде хәл башкача тора. Эчтәлек үстерелеше идиллик экспрессия планында алып барыла.

Хикәянең соңгы бүлеге хис белән хыял берлегенең тормышчан, ягъни кеше табигатенә хас, реаль тормыш чынбарлыгына туры-дан-туры бәйләнешле икәнлегенә дәлил хезмәтен үти. Без һәммә нәрсәне үз теләгебезгә, күзаллавыбызга бәйле рәвештә кабул итәбез һәм аңлыйбыз икәнлеге беленә. Шушы фикерләмә нигезендә хәтта, ялгышлык итеп, бу әсәр чыннан да реализм методы белән язылган дигән фикергә дә килергә мөмкинбез. Әмма анализыбызның нәтиҗәсе башкача килеп чыга: Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясе бәхет һәм рәхәтлек тойгысы белән өртелгән хисләр ташкыны агышында язылган, ягъни идиллик экспрессионизм үрнәге булып тора.

Әдипнең шушы ук 1910 елда язылган «Диңгездә» хикәясе дә «Яз башы»на тартым сыйфатларга ия. Монда инде вакыйгаларны ул өлкәннәр белән бәйле рәвештә алып бара, ягъни төп геройлары бала-чагалар түгел. Әсәрдә сурәтләнгән диңгез күренешләре, җилкәнле көймәнең киерелеп йөзүе, башкалары хис-тойгыларны автор-

га бер юнәлештә «җыярга» мөмкинлек бирә. Әдип, шул хисләрне сөйләп кила-килә, укучыны көймәдәге мөселман карты Нуретдин Фәрраш белән таныштыра, аның изге картлардан булуы күзаллана башлый. Юлларында бернинди хәвеф булмастыр сыман. Көн дә чалт аяз, табигать тә матур. Идиллик сурәтләр монда тәмам өстенлек ала.

Әмма көймә давылга эләгә. Мәхшәр башлана. Автор шушы вакыйгалар эчендә Нуретдин Фәррашның намазга тезләнүен төп экспрессив күренеш буларак тасвирлый.

Хис-тойгыларның тәэсирле рәвештә үстерелүе алга таба да дәвам итә. Давыл үзе үк хисләр ташкынын көчәйтүгә хезмәт итә башлый.

Көймә һәлакәттән имин котыла. Әсәрдә, композицияне ныгытуга бәйле, әлбәттә, Гаптулла хаҗи вакыйгалары да сөйләнеп алына. Әмма аларда экспрессив детальләрнең азлыгы сизелә.

Г. Ибраһимов, романтизм методына хас рәвештә, төп героен илдәге җәмгыятьне, буржуаз тормыш-яшәешне кабул итмәүче буларак күрсәтеп, хикәясен тәмамлый. Көймә урынга килеп җиткәч, пассажирлар шатланышып шаулашалар. Әсәрнең төп герое: «Ярга якынлашып, андагы поездның вәхши акыруын ишетү, корымнар, төтеннәр белән буялып беткән завод морҗаларын күрү белән җаным кысыла, йөрәгемдә бер әрнүле пошыну уяна, эчемдә нидер җимерелә, нидер югала»[1], – дип үзен хис итә.

Монда да шулай ук экспрессионистик рәвештә ике төрле хисне капма-каршы куеп сурәтләү алымы файдаланылган. Бу факт исә экспрессионизм белән романтизмның үзара ярәшүен белдерә түгелме? Гомумән дә экспрессионизм романтик планда да, реалистик планда да яши ала.

Г. Ибраһимовны фән дөньясында реалист язучы дип атау кайдан килә дигәндә, реаль вакыйгаларга, реаль тормыш чынбарлыгына таянып, шуның нигезендә әдәби картиналар, образлар, хәтта фикерләр тудыру осталыгыннан булуына инде тукталып узган идек. Шул ук вакытта сәбәпне, хис-тойгылар экспрессиясен сурәтләвенә игътибар бирүебездән чигенеп, Г. Ибраһимов әсәрләренә, галим Г. Халитча әйтсәк, реализм һәм романтизм синтезы хас, бу

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 81.

исә татар әдәбиятының XX йөз башында «тизләнелгән үсешенә» бәйле дип тә аңлатырга мөмкинбез[1].

Әдипнең иҗатындагы үзгәреш үзенчәлекләренә тукталып, үз вакытында М.Х. Хәсәнов болай дип белдергән иде: «Бу үсеш берьяклылыктан әдәби камиллеккә, романтик һәм реалистик чараларның органик берлегенә, романтизм белән реализм синтезына ирешүдән гыйбарәт иде»[2].

Геройларының эчке дөньясын ачуы белән Г. Ибраһимовны, 1910–1912 еллар иҗатына бәйле рәвештә, галимнәр бертавыштан диярлек асылда романтизм вәкиле дип игълан иттеләр[3]. Бу раслауларының нигезе юк, болар хакыйкатьтән ерак дип әйтеп булмый. Чынлыкта алар бары тик каршылыклы һәм тулы түгел иделәр. Шуңа күрә дә бу күрсәтмәләр кысасында Г. Ибраһимов әсәрләрен анализлау өстәмә авырлыклар, аңлашылмаучылык, асылсыз фикерләмәләр тудыра килде.

Экспрессионизм һәм экспрессионистик эзләнүләр белән бәйле тикшергәндә, әдипнең иҗат үзенчәлекләре тагын да ачылып китә һәм аңлашыла башлый түгелме? Әсәрләрен идиллик экспрессионизм юнәлешендә иҗат итүен аңлау шактый төгәл һәм тулы фәнни күзаллау тудыруы бәхәссез.

Г. Ибраһимовның 1911 елда язылган «Йөз ел элек» тарихи хикәясе исә – реалистик планга куелып иҗат ителгән романтизм әсәре. Ни өчен реалистик планга куелып? Чөнки тормыш вакыйгаларын һәм геройларны тышкы халәтләренә бәйле ача автор. Ә ул вакытта нигә романтизм әсәре дибез? Чөнки тарихи әсәрләр билгеләмә буенча романтизм, аның да регрессив романтизм дип аталган өлкәсенә карыйлар. Монда реализм һәм романтизмның синтезы ачык күренеп тора. Бу механик, ясалма синтез түгел, органик рәвештә туган күренеш. Дөрес аңларга тиешбез, тормыш хакыйкате эчке халәтне сурәтләү аша тасвирлаган романтизм әсәрендә дә, тышкы күренешләрне бәянлауга корылган реализм әсәрендә дөрес

[1] *Халит Г.М.* Портреты и проблемы: избранные статьи разных лет. – С. 198–237.

[2] *Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. III. – Б. 341.

[3] Шунда ук. – Б. 18–20.

һәм тулы килеш ачыла ала. Хикмәт язучының талантына бәйле, иҗат методына түгел.

Г. Ибраһимовның әлеге хикәясендә Уфадан туксан чакрымдагы Карлыман авылы халкы сурәтләү объекты итеп алына. 1810 елларда бу авыл Югары Күл исеме белән йөртелгән. Моңа кадәрге чорларда исә анда зур мәдрәсә булып, данлыклы Хатип хәсрәт шунда белем биргән. Инде имамлык эше аның улы Садыйк муллага калган. Ә ул, әтисеннән аермалы буларак, гыйлемдә маһир кешеләрдән түгел икән.

Вакыйгалар шушы эзлеклелектә сөйләнеп алына. Укучыда мондый хәбәр биреп куелу бернинди хис тә уятмый әлегә.

Һәм менә Садыйк мулланың капка төбенә кешеләр Урыс Пәкри (Әбүбәкер Сәлимов дигән кеше бу) белән ат көтүчесе Салих картның хатыны Камиләне зинада тоттык дип алып киләләр. Эш, инде караңгы төшү сәбәпле, иртәгәге көнгә калдырыла. Шуның белән әсәрдә сюжет төенләнеше барлыкка китерелә. Вакыйганың ничек дәвам итәсен, нәрсә белән бетәсен белергә теләү хисе уяна, әсәр кызыктыра башлый.

Бу авыл халкының надан һәм ялкау булуын Г. Ибраһимов белдереп тә һәм сөйләп тә узуына карамастан, үз-үзләрен тотышларын да, кыланышларын да вакыйга тасвирларында ачып бирә бара. Шушы рәвешле, публицистик алым белән әдәби стиль берлеге дә тудырыла.

Авылның усал ирләре чибәр, яшь хатын Камиләне, кызганып та тормыйча, кыйнап ук ташлыйлар. Мондый мәрхәмәтсезлек укучыда аһ-зар хисе белән бәйле нәфрәт тойгысы уята. Наданлык, томаналык өшәндерә. Нәфрәт тойгысын автор беренче тапкыр шушы әсәрендә ача, моңа кадәр аны игътибарыннан читтә калдыра килә. Җәмгыятькә карата тәнкыйди әсәр булдымы, дөньялыкка бәйле нәфрәт тойгысы өстен чыгарыла дигән сүз түгел әле бу. Әмма Г. Ибраһимовның талантлы каләме үзен яңа яктан күрсәтә. Монда сүз, әлбәттә, иҗат манерасы хакында бара.

Урыс Пәкри белән Камиләгә нинди максаттан чыгып гаеп тагуларын автор искәртми. Берсенең Урыс аталуы, икенчесенең яшь һәм чибәр булуы сәбәп идеме – төшендерелми, әмма халыкның үтә дә тинтәклеге һәм кабахәтлеге шактый сиздерелә. Укучы күңелендә наданлыкка карата нәфрәт тойгысының уянуы өчен болар да

җитә. Автор шушы авыл халкының ахмак гамәл кылуларын көчле бер нәфрәтләнү белән яза ки, вакыйгаларны да шуның белән бәйле кискен һәм киеренке итеп сурәтли. Хикәянең «1810 елның 30 май көне иде»[1] дип башланып китүе дә тарихилык һәм документальлек төсмерен арттыра, Эстәрлетамак өязендәге авыл булуы һәм башка хәбәрләр, хәтта авылның исеме үзгәрү факты да әсәрдә, тарихилык белән бергә, реаль чынбарлыкка, хәтта документаль дөреслеккә бәйләнеше барлыгына ышанычны ныгыталар. Шунысы әһәмиятле, геройларның эчке дөньясы, уй-кичерешләре әсәрдә бөтенләй дә исәпкә алынмый, аларның психологиясе, характерлы сыйфатлары, вакыйгаларга катнашулары, нәрсә һәм ничек дип әйтеп сөйләүләре, үз-үзләрен тотышлары – барысы да эш-гамәлләрен сурәтләп күрсәтү аша ачылалар. Болар хикәянең реалистик планда язылганлыгы хакында сөйли торган үзенчәлекләре. Әмма шунысына да игътибар итик: автор сурәтләгән каһарманнарның бирелеше эчке бер динамика һәм экспрессия белән алып барыла, шул сәбәпле әсәр тәэсирле картиналар ярдәмендә вакыйгаларны укучының күз алдына китереп бастыра. Бу исә хикәянең сәнгатьчәлеген тагын да көчәйтә. Моңардан чыгып без экспрессия алымнарының төрле булуын, уңышлы сәнгати чара икәнлеген ассызыкларга тиеш булабыз. Ул гына да түгел, шушы тарихи хикәясе белән Г. Ибраһимов үзен реалистик пландагы язучы итеп тә күрсәтеп ала. Димәк, без аны яки романтик, яисә реалист язучы дип кенә, бер генә яклы алып һәм шул бәяләмәбезне алга куеп раслау юлына бара алмыйбыз икән. Тагын да шунысын ассызыкларга тиешбез: әдипнең реалистик планда язылган шушы әсәренә дә эчке экспрессия хас, монысын инкяр итү мөмкин түгел.

Әдәби әсәрдә эчке динамика булса һәм геройларның эш-хәрәкәтләрендә аңлашылып бетмәгән, мантыйкка сыеша алмаган сыйфатлары артыгы белән бар икән, моны без «экспрессия күренеше» дип атыйбыз. Кеше психикасы, аңыннан, акылыннан аермалы буларак, мантыйкка буйсынмый. Билгеле, ул аның хәтта аң-белеменә дә карамый, хикмәт хис-тойгыларына һәм рухының куәтенә бәйле. Экспрессионистик әсәрләр дә менә шул күңел тәэссоратын яктыртуга бар көчен юнәлтә, алары да сәнгатьчәлекнең рухият-

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 82.

кә бәйле булуы сәбәбеннән килеп туа. Шулай итеп, хис ташкыны күңелне «борчучы» көчкә әверелдерелә, зиһенне, фикерне кузгатырлык итеп эшләнелә.

Реалистик пландагы әсәр өчен тәэсирлелек, экспрессия уңышлы алым түгелме икәнлеген Г. Ибраһимов «Йөз ел элек» хикәясендә гүяки тәҗрибә кылып карагандыр кебек. Шушындый ук әдәби тәҗрибә мисалы дип «Сөю-сәгадәт (Карт шагыйрь тәэссораты)» фәлсәфи хикәясен дә атарга була.

Монда төп герой Ризаның яшьлеген, анда калган мәхәббәтен сагынып хатирәләргә чумуы бәян ителә. Әдипнең бу әсәрендә вакыйгалар бөтенләй юк диярлек, булганнары да фәлсәфәләр, уй-фикерләр эчендә югалып, төссезләнеп кала. «Сөю-сәгадәт»тә төп элемент – тәэссорат. Г. Ибраһимов шуны экспрессив хис үсешендә бирергә омтыла. Әмма монда хис һәм фәлсәфә берлеге хис һәм хыял булып уңышлы рәвештә үрелеп-әверелеп китә алмаганнар. Вакыйгаларда кискен күчеш һәм үзгәрешләр динамикасы җитенкерәмәү хис-тойгыларның әсәр буенча үсешен тәэмин итеп җиткермиләр. Әмма бу инде рационалистик фикер, дидактик акыл бирү түгел, бәлки сентименталь, хәтта идиллик хатирәләрдән гыйбарәт фәлсәфә коруга кайтып кала торган хикәя дә кебек аңлашыла. «Сәгадәт», ягъни бәхет сүзен әсәренең исеменә чыгаруы белән автор аның идиллик хикәя булырга тиешлеген расларга тырышмыймы дигән фикер дә уянмый калмый. Чыннан да, геройның хатирәләре никадәр нәзберек сентиментальлеккә корылмасыннар, алар шул ук вакытта идиллик экспрессия стихиясендә дә тасвир ителгәннәр. Шунлыктан бу хикәяне сентиметаль әсәр дип кенә бәяләргә ашыкмыйк.

Әдипнең үзе өчен генә түгел, әдәбият тарихында да «Сөю-сәгадәт»нең әһәмияте шунда ки, ул бераз соңрак язылачак «Яшь йөрәкләр» әсәре белән бик күп яклап аваздаш, шушы зур романга эчке агымы белән нык якын торган хикәядән санала ала.

«Мөмкин булып та, шул көннәрнең сәгадәтен, аның бөтен хәятемдә тоткан урынын, мәгънәсен аңлата алсам, үземне мәсгуд санар идем»[1], – дип белдерә әсәрнең төп герое сүзләре белән автор.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 120.

Бу – Г. Ибраһимовның үз омтылышы, максаты да. Тойгы-хисләрне тәэсирле итеп укучы күңеленә күчерә алуга ирешүдән гыйбарәт ул.

«Романтик геройның рухи дөньясын сурәтләве белән Ибраһимов кеше кәйфиятенең җанлы хәрәкәтен, хисләр көрәшен күрсәтте, – дип белдерә М.Х. Хәсәнов. – Татар прозасын лирик психологизм, бай әдәби буяулар, гадәттән тыш көчле характерлар һәм ситуацияләр белән баетты»[1]. Шушы фикерләре белән бәйле рәвештә М.Х. Хәсәнов Г. Ибраһимовның романтизмына берьяклылык кына хас булуы турында да яза, моның сәбәбен реализм белән бәйләнеше ерак булудан күрә, «Татар шагыйрьләре» хезмәтен, «Яшь йөрәкләр»не, гомумән дә 1910–1912 елгы иҗатын моңа мисал итеп атап күрсәтә[2].

Әмма Г. Ибраһимов реализмга таба «Йөз ел элек» тарихи хикәясе белән күчеш ясамадымы дигән сорау туа. Башка кайбер әсәрләрен дә, мәсәлән, «Казакъ кызы»н, «Карак мулла»ны, «Карт ялчыны» шул ук исемлеккә кертеп карап булмыймы? Әллә әдипне әсәрләре реализм яки романтизм чаралары белән язылганлыгы ул вакытларда бөтенләй борчымаганмы?

Мондый сораулар урынсыз кебек. Г. Ибраһимов әдәби әсәрләрендә һәм романтизм, һәм реализм алымнарын яхшы белеп, тоеп язган әдип сыйфатында күзаллана. Әмма ул әдәби-эстетик кредосына әверелгән экспрессионизм өчен реалистик планда яки романтик планда гына, ягъни аларның берсендә генә иҗат итү максатка ирешүдә мөмкинлекләрен чикләү икәнлеген дә яхшы төшенеп эш иткән. Бу хакта әдип үзе ничек дип аңлата: «Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа»[3]. Алга таба ул моның механизмын да аңлатып бирә: «Бер шигырьнең камил шигырь булып чыгуы өчен, шагыйрьнең бер нәрсәдән тәэссоры һәм шуны укучыга тәэсир итәчәк рәвештә шигъри сүзләр эченә салуы лазем»[4]. Һәм ул үзе нәкъ менә шушы юл белән әсәрләрендәге геройларын, картиналарны тасвирларга омтыла. Бу каһарманнар үзләре дә бер-бер вакый-

---

[1] *Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 19.

[2] Шунда ук.

[3] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 81.

[4] Шунда ук.

га яки хәбәрдән тәэсирләнәләр, хискә биреләләр. Язучы аларның шушы хисләрен әсәрләрендә үтемле итеп бирә, моның өчен экспрессионистик сурәт тудыру ысулын сайлап ала. «Яз башы» һәм «Диңгездә» хикәяләрендә бу рәвешле язуы уңышлы барып чыкканына инде тукталып узган идек, ә менә «Уты сүнгән җәһәннәм» әсәренең исеменнән үк хикәянең шушы алым белән язылуын дәгъвалаганы күренә.

Әдипнең бу әсәре «сызлану фәлсәфәсе»нә корылган, экспрессионистик хис буларак Садыйк мулланың үз тормышы, яшәеше белән канәгать түгеллеген табигать күренешләре, җил, яңгыр, караңгы төн һәм мәгънәсез яшәеш хакында хәсрәт чигүенә бәйле уйлар өермәсенең ташкынлы агышын сурәтләүдән гыйбарәт. Романтик планда язылган әсәрләрендәге идиллия бу әсәрендә бөтенләй юк дәрәҗәсендә, аның урынына аһ-зар, сызлану һәм шулар белән бәйле барлыкка килгән нәфрәт тойгысы шактый өстен чыгарыла. Әдәби сурәттә тирәнәйгән саен әдип идиллиядән читләшә бара.

Г. Ибраһимов хикәяләрендә сюжетларның нигезен реаль дөнья һәм геройның күңел халәтләре арасындагы каршылыклар төзи (М.Х. Хәсәновның моңа тартым фикерен инде искә алып узган идек), тормыш чынбарлыгы итеп алынган вакыйгаларының туктаусыз үзгәреше рух хиссиятенә тәэсир итүеннән герой тирән кичерешләргә бирелә, бигрәк тә хыялга төшүе аның эчке кайнарлыгын тудыра. Бу үз чиратында, әлбәттә, психологизмга китерә.

Күңел дөньясы сентиментальлектән, идиллиядән һәм романтикадан гайре яши алмый. Ул аның хасияте. Менә шуңа күрә дә Г. Ибраһимов әсәрләре романтизм иҗат методы белән язылганнар булып аңлашыла. Әмма алар асылда экспрессионизмга корылганнар, романтик яки реалистик планда иҗат ителгәннәр.

Экспрессинизм ул – әдәбиятлар үсешендә XX йөзнең беренче чирегенә хас әдәби-сәнгати юнәлеш, дидек. Бердәнбер хакыйкать, чынбарлык дип бары тик кешенең шәхси рухи дөньясын гына таный, менә шул чынбарлыкны сурәтләүне сәнгатьчәлек дип саный, тойгы-хисләр эчендә яшәүне ул дөрес, мактауга лаеклы тормыш дип атый[1].

---

[1] Словарь иностранных слов и выражений / авт.-сост. *Е.С. Зенович* – М.: Олимп; АСТ-ЛТД, 1997. – С. 556.

Г. Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм» хикәясе дә, аерым алганда Садыйк мулла нәкъ шушындый планда сурәтләнелә. Аның сызлануының төп сәбәбе яшьлек хыялларының тормышка ашмавыннан булса, шушы тәэссоратына этәргән чынбарлык вакыйгасы да бар, ул – мәдрәсәдә укыган чорында аңарда самавырчы малай хезмәтендә генә торып та, ахырда зур белемнәргә ирешкән, «урыс түрәсе» рәвешендә килеп керүче, алтын күзлекле, европача киемле, элек Тубал кушаматы белән йөртелгән, инде хәзер үзенә бары тик исеме белән генә мөрәҗәгать иттерер мәртәбәгә ирешкән Гыйльман Каһиров.

Малайлар, Садыйк мулланың өенә йөгереп кереп, урыс түрәсе килде дип, Гыйльман хакында хәбәр бирәләр. Ул аны каршы алырга чыгарга мәҗбүр. Түрә дигәннәрендә элеккеге самавырчысы Тубалны, ягъни Гыйльманны танып алуыннан әсәр вакыйгаларында хис көчеше барлыкка килә. Күрше авыл баеның балаларына җәен дәресләр бирергә сүз беркетүенә бәйле юлга чыгып, ат башы тотучы һәм бер иптәше белән бергә яхшы тарантаста Гыйльманның узып барышы икән.

Менә шул очрашудан соң Садыйк мулла йокысын югалта, тынычлана алмый. Гыйльманнан көнләшү хисе түгел, бәлки дөньяның аяусызлыгы, яшьлек хыялларыннан баш тартырга мәҗбүр ителүе сызландыра аны. Һәм ул кешеләр өчен тормышта ике төрле яшәү юлы бары икәнен төшенә: аларның берсе – ихтыяр белән көрәшеп, юл ярып; икенчесе – язмышка, тәкъдиргә буйсынып. Садыйк мулла үзенең ихтыярсызлыгына хәйран итә, юкса ул мондый гына кеше буласы түгел икән.

Г. Ибраһимов, шушы рәвешле төшендереп, укучы күңелендә көрәш, үз язмышы өчен җаваплылык хисләрен уятырга омтыла. Әмма әсәренең тукымасына җәелдерелгән сызлану фәлсәфәсе моңа ирек бирми.

Хикәянең герое коры сызланудан, тормышына, язмышына буш борчылудан узмый. Тойгыландырган фәлсәфәсе дә сүнә. Аңарда хыяллану гына бар, яшәешкә, батырлыкка илтүче, ихтыярга таяндыручы романтик рух юк.

Алда Садыйкны тыныч йокысы көтә икәнен белдерә автор. Язучы нәкъ менә язмышка, тәкъдиргә буйсынучанлыкны, тормышта реалист булуны йоклаганлык итеп күрсәтә. Әсәрдә тасвир-

ланган бу халәт җәһәннәмгә эләгү сыман бер хәлдер кебек аңлашыла башлый. Садыйк мулла дөньялыкны караңгы, «уты сүнгән җәһәннәм икән» дигән фикергә килә. Тормышта ихтыярга таянып, хыялларны тормышка ашырырга омтылып яшәргә кирәк икән, шул вакытта гына ул «җәһәннәм»нән котыласың дигән уй укучы күңеле аша, аның акылын яктыртып уза.

Хис-тойгы – кеше күңелен кузгату көченә ия. Ул уйга, фикергә, һич югы – хыялга этәрә. Экспрессионизм вәкилләре нәкъ менә шуңа игътибар иткәннәр дә. Алар, хис-тойгы ярдәмендә «сызлану фәлсәфәсе» тудырып, аңардан котылу юлын эзләргә, әдәби геройларының язмышын кабатламыйча яши белергә укучыларын өйрәтергә кирәк тапканнар. Экспрессионистлар, хисне иң көчле дәрәҗәгә җиткереп, укучыны «шок халәте»нә китерергә омтылганнар, моның өчен алар төсләрне саташтыру, формалардан баш тарту юлына да барганнар, реаль дөньяның «чын йөзе» аны без кабул иткәнчә, тойганыбыздагыча дип аңлатканнар, тормыш дөреслеге ул – кеше хисләренең чагылышы гына, дигәннәр[1].

Әдәбиятта экспрессионистик ысулларны файдалану, аның да яңа чараларын эзләп табу һәм куллану ягыннан Г. Ибраһимов үз чоры әдипләренең иң көчлеләреннән берсе булуы белән аерылып тора. Бу яктан караганда да аның эшчәнлеге мактауга лаеклы. Әдипнең тормыш чынбарлыгын «контраст буяулар»да аңлатырга алынуы, яшәеш перспективасын эзләве, хис төенләнешен реаль вакыйгаларга бәйли белүе һәм шуларның әдәби ысулларын, чараларын табуы татар әдәбияты үсешенә зур этәргеч ясады дип хаклы рәвештә белдерә алабыз. Ул экспрессинистик алымнарны романтик планда язылган әсәрләрендә куллана башлап, реалистик планда сурәтләүдә дә бик оста файдаланды. Моның белән алдынгы әдипкә әверелде.

Г. Ибраһимовның 1911 елда язып тәмамлаган «Карак мулла» һәм 1912 елда иҗат иткән «Карт ялчы» хикәяләре чын мәгънәсендә реалистик әсәрләр булып торалар. Нәкъ шушы 1912 елда ул «Татар шагыйрьләре» хезмәтен дә басмага әзерли. Аларда аның шул ук эстетик карашлары төп урынны алганлыгын бу факт үзе генә дә

[1] Краткий словарь по эстетике: кн. для учителя / под ред. *М.Ф. Овсянникова.* – М.: Просвещение, 1983. – С. 197–198.

катгый раслап тора. Әдәби-эстетик карашларын ул конкретлаштырган, тагын ачык күзаллап һәм аңлап иҗат итүгә керешкән.

«Карак мулла»да Г. Ибраһимов Тимри язмышын сурәтли. Ул караклар нәселеннән булып, гәүдәле, таза беләкле егет, читкә мәдрәсәгә китеп, анда «укымыйча да белеп», белем алуда өлгерлек күрсәтә, әмма караклык аның канында икән, кием-салым урлауда фаш булып, укуыннан куыла. Авылларына кайта. Белеме бар дип аны әүвәле мәзин итәләр, аннары карт хәзрәт муллалык эшен дә тапшыра. Әмма халык арасында караклар белән бәйләнеше хакында сүзләр таралып, ул указыннан баш тартырга мәҗбүр.

Хикәядә беренче экспрессионистик, тәэсирле вакыйгалар Тимринең шәкертлектәге караклыгы фаш булу белән бәйле сурәтләнелеп, мәзин-муллалык хәлләре сөйләнелгәндә тагын да көчәйтеләләр.

Бу хикәянең икенче өлешен мукшы бае белән татар бае Сафа арасында барган ярышу алып тора. Автор моны татарларга һәм мукшыларга (мордваларга) бәйле бер милли иттифакый ярыш булырак сурәтли. Мукшы баеның акбүз биясе сабантуйларда өстен чыга, әмма Сафада андый чабышкы юк. Һәм менә аның бәхетенә базарга чегәннәр ат сатарга киләләр. Арада бер тай да була. Ат танууда даны чыккан Гәрәй карт Сафа байга аны сатып алдырта.

Атлар турында язганда Г. Ибраһимовның каләме сабырсызланучан, аның сүзләрендә тәэсирлелек, экспрессив динамика бермә-бер арта. «Ул тайдан кечек, чандыр, аз итле, бераз бөкрерәк аркалы, ләкин гаҗиб дәрәҗәдә сөйкемле һәм җанлы бер ат чыга. Ул болай бертөрлерәк кенә, әмма җигеп, яисә менеп чыксаң, шундый матур йөри, бөтен кешеләр исләре китеп карап калалар. Үзе торганы ялкын, шул дәрәҗәдә ки, тик дилбегәне генә тотып өлгер. Ул кузгала, шул арада әллә кая очкан була»[1].

Бу тай ярышта мукшының акбүзен ике чакрымлап артта калдыра. Бәйрәм татар ягына күчә. Мукшы бае менә шушы тайны урларга Тимрине яллый. Алар, очраклы килеп чыккан каравылчы картны үтереп, тайны бикле сараеның түбәсе аша чыгарып, авыл башындагы тауга алып менеп суялар. Вакыйгаларның бу рәвешле кискен рәвештә үзгәреш алуы көтелмәгәнлек тәэсирен уята.

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 1. – Б. 141.

Г. Ибраһимов, сюжет борылышларын сурәтләгәндә, тәэсир көчен катлауландырып һәм үтемле итеп бәян итә белә. Мәсәлән, ат урлау турында язганда ул Сафа байның ике олы этен дә искә ала, аларга «ришвәт» буларак, ягъни алдап ашатырга каракларның симез башмак сыерны акыртып суюларын искәртә, каравылчы картның маңгаена Тимри шайкасындагы Гомәр кистән белән җибәрә, миләрен чәчрәтә һ.б. Бу картиналар вакыйганың тәэсир көчен арттыралар, авторның ваклап сөйләп алҗытмавы исә шул ук урыннарны экспресссив һәм динамик агышлы итә. «Карт ялчы» хикәясендә дә андый өлешләр җитәрлек.

Г. Ибраһимов, әдәби чигенеш ясап, каһарманнарының нәселнәсәбен сөйләп чыгуны да хикәяләрендә оста файдалана, алар укучыны яңа тәэссорат-кичерешләр күтәрелешенә җай гына әзерлиләр.

Карт ялчы Шаһи (Шаһибәк) Өлкән авылындагы ярлы гаиләдән, бала чагыннан ятим калып, Байморзада ялчылыкта эшли, аннары Әхми байның этисенә яллана, соңрак аның усал һәм кешелексез малае хезмәтендә кала. Шаһиның әнисе Миңлегөл үлеп, этисе читкә чыгып киткәч, баланы бабасы Шәмси карт белән әбисе Гайни карчык бишек яшеннән үстергәннәр. Алар бик тә сабыр, Ходай биргәненә рәхмәтле булып, фәкыйрьлектә яшәгәннәр.

Вакытлар узган. Инде Шаһи үзе дә тәмам картая, көчсезләнә.

Яңгырлы көз көне басудан көшел ташыганда, шушы Шаһи карт белән хикәянең төп каһарманы Сәфәр, атлары йөкләрен тартып Яманташ тавына менә алмыйча тукталганга, кырда кичлек ясап, кунарга мәҗбүр булалар. Автор тормыш картиналарын тәэсирле итеп тасвирлап, вакыйга эчендә вакыйгалар биреп, экспрессионизм алымнарын реалистик әсәр тудыруда оста файдаланып, шушы юл белән укучының тойгыларын үстереп килә-килә, хакыйкатьнең асылын ачыклап бирүгә ирешә. Аның реалистик планда язылган әсәрләренә тормыштагы күренешләргә карата күңелдә нәфрәт уяна, мондый яшәешнең мәгънәсезлеге хис агышы белән тагын да көчәйтелә. Суфиларча тормыш корган өлкәннәрнең тәрбиясен күргән Шаһи бөтен гомерен коллыкка багышлаган. Ул – Хода биргәнгә ризалык тотып яшәүче.

Шуны да искәртү урынлы булыр: нәкъ менә шушы 1912 елда Г. Ибраһимов «Яшь йөрәкләр» романын да тәмамлый. Аны да

ул экспрессионизмның барча әдәби-эстетик алымнарын файдаланып яза. Әсәренең төп каһарманнарыннан булган мирза кызы Мәрьямнең язмышы вакыйгаларга бай түгел, аның бөтен барлыгы хис-тойгыларында тупланган. Ул үзенең дөньялыкта яшәвен дә, Зыяга карата мәхәббәтен дә тәмам аңлап бетерер дәрәҗәдә түгел. Хәтта Фәхригә кайчан, ничек кияүгә бирүләрен дә, аны үтерүен дә ачык кына төшенми. Һаман да хисләр дөньясында яшәве хәтта Зыяның кемлеген, ниндилеген тануга да китерми. Дөрес, ул вакыт-вакыт дөнья тормышына «кайта», әмма алар Мәрьямнең асылына хилафлык кына китерәләр. Бөтен барлыгы романнар укудан, Зыяга мәхәббәттән генә торган бу кыз хисләр дөньясында йөзәргә генә сәләтле. Ул хис-тойгылар аның һәр хәрәкәтендә, һәр төсчалымында чагылыш таба.

Зыяның да бөтен барлыгы һәм яшәеше хис-тойгыларында. Ул тормыш чынбарлыгыннан шактый югарыда. Катлаулы хис-тойгыларын сурәтләп бирү өчен, автор музыкага булган мәхәббәтен алгы планга чыгара. Аның бар белгәне, барлык тойгылары, хис иткәннәре музыка белән бәйле. «Татарның табигате бүтән һичбер халыкныкына охшамаган кебек, ул тарихы, язмышы белән дә бөтенләй башка рәвештә тора. Шуңа күрә аның музыкасы да, бәлки, башка һичбер кавемнекенә охшамас, һәм охшамавы табигый да... Бер халыкның язмышы вә табигате белән аның музыкасы арасында нинди дә булса бер якынлык, мөнәсәбәт булмавы мөмкин түгел. Чын милли музыка – халыкның йөрәгендә булган тойгыларының тудырган җимеше, җанының аһы-зарларыдыр. Татарның асыл табигате бөек, җаны мәртәбәле, йөрәге бик хәссас булып, икенче яктан, язмышы бик агыр, тарихының соңгы сәхифәләре баштанаяк көенеч вә хәсрәт илә тулыдыр»[1], – дип фәлсәфә кора Зыя, үзенең дусты Госманны да аптыраштა калдырып, үз халкын эчтән тоеп, бөеклеген төшенеп. Ул һәммә нәрсәгә музыка аша карарга, хакыйкатьләрне музыкага бәйле уйларга, дөреслеккә шул юл белән бәя бирүгә сәләтле. Аңа хәтта тормыш һәм андагы яшәеш кызыклы да түгел. Мәрьямгә булган мәхәббәте дә музыка кебек. Ул моны яхшы тоя. Музыка аны сокландыра, яшәтә, хисләндерә. Зыя шушы музыка белән бәйле хәлендә азгынлыкка да, һәлакәткә дә бара. Үлеме

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 2. Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Б. 185.

дә музыкага бәйле була. Солдат хезмәтеннән ялга кайткач, ул моңа кадәр күңелендә йөрткән, әмма аның ни рәвешле, нинди булып чыгасын белмәгән хәлдә музыка коралында, скрипка-саз-сызланда уйнап җибәрә, көчле хис-тойгылар эчендә йөрәге бу рәхәтлекне күтәрә алмый. Егет үлә. Шул рәвешле Г. Ибраһимов хис экспрессиясен һәлакәт мизгеленә кадәр үстерә.

Әсәрдәге Җәләш (Җәлал, Җәлалетдин) мулла да дуамаллыгы, үз дигәненчә генә яшәргә-эшләргә омтылуы белән экспрессив герой буларак сурәтләнелә. Ул әле азгынлыкка бирелә, әле Зыяны хәрби хезмәттән алып калу теләге белән шашына. Эшләре барып та чыгарга тиеш була, әмма тормыш аны да ега. Җәләш муллага, шушы атлар, хатыннар, исереклек, балалар белән «җенләнгән» кешегә, тормыш чынбарлыгыннан качып хаҗга китеп котылу, кире әйләнеп кайтмау гына «тынгылык» бирә. Автор аны даими хисләр ташкыны эчендә яшәүче герой итеп тасвирлый. Әсәрдә «яшерен шагыйрь» дә, башкалар да бары тик хис-тойгылар сөремендә тормыштан читләшеп, рух дөньясына китеп яшәүчеләр буларак күзалланалар.

Бары тик Сабир гына аларча түгел. Ул мондый хисле-тәэссоратлы, суфийана дәрәҗәдәге кешеләр арасында яши алмыйча, гомерен читтә уздырырга мәҗбүр. Дөньяны башкача хис итә. Ул тормыш реальлегендә тора. Шунлыктан бердәнбер диярлек тәкъдири герой буларак тоела. Әтисенең йортына кайтып, ахырда авыл тормышы белән яши башлый, үзе кебек эшчән кызны хатынлыкка ала.

«Яшь йөрәкләр» романы вакыйгаларга ярлы, әмма анда хисләр һәм тойгылар, рухи омтылышлар шактый тирән итеп сурәтләнеп бирелгән. Әсәрне сентименталь ноталарга корылган дип әйтеп булмый. Монда да хисләр идиллиясе өстен чыгарыла. Геройлар асыллары белән үзләренең күңел дөньяларында гына яшиләр, шуның өчен дә әсәрнең башыннан ахырына кадәр алар үз дигәннәренчә генә булырга омтылалар, бернинди йола һәм кануннарны санга алмыйлар. Мулла булуына карамастан, Җәләш тә вакыт-вакыт эчеп, исереп йөри, йортына кайтмыйча аптырата. Аның күңелендә улларын шәһәрдәге олы һәм бай мәхәлләләрнең имамнары итү, халык алдында түрдә йөрү һәм йөртүдән генә гыйбарәт хыял. Шуны тормышка ашырам дип байлыгын да, вакытын да кызганмый. Боларны Г. Ибраһимов экспрессив эмоциональлек белән тасвир итә. Бу хыял – романтик хыял. Менә шуның буш булуын аңлый

бару Җәләш мулланы юк итә. Аңа бу, өмет-хыяллары акланылмаган, чикләрен табалмый аккан тормышыннан качып китүдән гайре башка юл калмый.

Әдипнең 1910–1912 елларда иҗат иткән хикәяләре кебек үк, «Яшь йөрәкләр» романы да классик сюжет төзү осталыгына нигезләнеп түгел, бәлки тәэссорат, лирик хисләрнең үсешен, кичерешләрнең барышын тасвирлауга корылып язылган. Әсәрләренең кайсылары реалистик планда, кайсылары романтик юнәлешне алда тотып язылганнар. Һәммәсенең уртак ягы – Г. Ибраһимовның экспрессионистик алымнарны таба һәм файдалана белүендә чагыла.

Болардан чыгып, без язучының бу чорда экспрессионизм вәкиле булуын белдереп нәтиҗә ясарга мәҗбүрбез. Экспрессионист буларак эстетик карашларын тормышка ашыруы белән бергә, ул нәкъ менә шушы елларда «Татар шагыйрьләре» хезмәтен яза. Аның шушы әдәби тәнкыйть әсәре бүгенге көндә дә татар әдәби фикеренең иң гүзәл үрнәге буларак хаклы рәвештә санала ала.

Хикмәт безнең экспрессионизмга мөнәсәбәтебезгә дә бәйләнмәгән, башкада да түгел. Хикмәт «Татар шагыйрьләре»нең үзендә. Ул, беренчедән, катгый эстетик-әдәби карашлар нигезендә язылган, икенчедән, автор үз фикерләрен дә бәяли белеп бәян итә, өченчедән, татар әдәбияты үсешен һәм тарихын, шулар белән бергә әдәбият теориясен яхшы белеп һәм күзаллап фикер йөртә. Безгә аның хакыйкатьне ачу принциплары кызыклы, алар бүгенге көндә дә Г. Ибраһимовның әдиплек үзенчәлекләренә кайта-кайта бәя бирергә ярдәм итәләр.

XX йөз башы татар әдәбияты үсештә шактый катлаулы юнәлешләрдә бара. Ул чор язучылары, шагыйрьләре, драматурглары эзләнүчән булулары белән татар әдәбияты тарихының башка дәверләре әдипләреннән аерылып торалар. XX гасыр башы татар әдәбияты үсешенә, андагы иҗат юнәлешләренә, чараларына, ысулларына бер генә төрле караш тудыруга, бәяләүгә каршы килгән Г. Халитнең сүзләренә инде тукталган идек. Ул чыннан да хаклы. Бу дәвер татар әдәбиятының шактый катлаулы чор булуын истә тотып, авторларның әдәбиятка зур әзерлек һәм җитлеккән зәвык белән килүләрен дә аерым ассызыкламый мөмкин түгел. Г. Ибраһимовның иҗаты моңа ачык дәлил булып тора. Анализлаган материаллар боларны ачык күрсәтәләр.

* * *

«Татар шагыйрьләре» хезмәтендә беренче тезис итеп Г. Ибраһимов чын шигырьнең күңелгә үтеп керә алу көченә ия булуын, хәтердә калу үзенчәлеге барлыгын искәртә. Моның сәбәбе, әлбәттә, шигырьнең рухи куәт белән тууына да, шигырь камилиятендә язылуына да, шигырь сыйфатында төзелүенә дә, шигыйранә хисләр ташкыны булуына да бәйле. Г. Ибраһимов, боларга мисал рәвешендә алып, бер укылуда хәтергә сеңүче шигырьләр хакында сүз алып бара.

Әдипнең икенче тезисы – «тупас нәрсәләр», ягъни тупас әсәрләр «вакытлы бер тәэсир» аркасында туалар. Әдәбиятта тупас сүзләр, тупас формалар, тупас эчтәлек булмаска тиешлеген ассызыклап, Г. Ибраһимов андый шигырьләрне С. Рәмиев иҗатыннан сызып ташлавы хакында белдерә. Бу да әдипнең әдәби-эстетик кредосы ныклык хакында сөйли торган факт булып тора.

Өченче тезис итеп ул шигырьнең «рух көзгесе» булырга тиешлеген алга чыгара. Язучы, шагыйрь башкача яза да алмый. Үзе бер төрле, әсәре икенче рәвешле булу бары тик ялган гына тудыра, андый әсәр хакыйкатьтән ерак тора. Кеше дөньяны, чынбарлыкны хисләре белән танып белә, димәк, экспрессионистик фикерләмә буенча, тормыш дөреслеге менә шул хисләрдә инде. Моның асылы модернизмның һәм формализмның нигезен хасил итүче, XIX йөзнең соңгы чирегендә Европада киң җәелеш һәм үсеш алган «хис итү теориясе»нә барып тоташа[1]. Г. Ибраһимов бу хакта белгәндерме-юкмы, кистереп әйтеп булмый, әмма ул дүртенче тезисын, нәкъ аңардан хәбәрдар кебек, болай дип ачыклый: «Ул шигырь язмый, шигырь чыгармый, бәлки аның шигырьләре шагыйрьнең үз иркеннән башка, үзеннән-үзе килеп чыгалар»[2].

Бишенче тезис итеп Г. Ибраһимов шагыйрьне «рухи бер сәвекъ астында гына иншад итә ала», ди, ягъни «рухи стимул, этәргеч аркасында гына шигырь барлыкка килә ала»[3] дип белдерә. Бу рухи этәргечнең тормыш икәнлеген ачыклый, «күңелне кайнатып җибәрүенә» игътибар итә һәм, алтынчы тезис буларак, С. Рәмиев иҗатына мондый бәяләмә бирә: «Аның һәрбер сүзе йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап, рухның төбеннән, эчке нокталарыннан

[1] Краткий словарь по эстетике: кн. для учителя. – С. 27.
[2] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 77.
[3] Шунда ук.

ялкынланып килеп чыга»[1]. Моңа дәлилләр итеп С. Рәмиевнең шигърияте тезмә калыпларга гына сыеп бетмәвен мисалларда китерә. Шигырьнең «табигый агымы» бозылуының сәбәпләре дә менә шул хиснең артыгы белән күплегеннән килә икәнлеге төшендерелеп бирелә.

С. Рәмиев шигырьләрендә Г. Ибраһимов, шул рәвешле, хис ташкыны көчле булуын яклый, әдәби күзаллау буларак хыялга төп игътибар бирелүне өстен чыгара, мәхәббәт һәм нәфрәт тойгыхисләренең уңышлы бирелешен аңлата һәм шигърияттен идиллия кысаларында язылган дип белдерә.

Аның бу фикерләре С. Рәмиевнең шигырьләре экспрессиягә корылганлыгын раславына турыдан-туры бәйле. Г. Ибраһимов татар әдәбияты фәнендә «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә экспрессионизм теориясен барлыкка китерә һәм аның үзенчәлекле сыйфатларын аңлатып, төшендереп бирә. Болар – аның әдәби-эстетик карашлары тәмам формалашып җиткәнлек хакында ачык сөйләүче фактлар.

Г. Ибраһимовның бөтен максаты татар әдәбиятын югары сыйфатлы әсәрләргә баету белән бәйле икәнлеге тәнкыйтенең таләпчән булуыннан ук аңлашылып тора. Нәкъ менә шушы кимәлдән чыгып, ул С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Г. Тукай шигъриятенә бәя бирә. Аерым С. Рәмиев иҗатын тикшергәндә, аның шигъриятендә хиснең тирәнлеген таный, әмма шигырьләренә әдәби эшләнеш җитмәвен дә ассызыклый.

Инде тәмам ачыклый алдык кебек: Г. Ибраһимовның С. Рәмиев шигъриятенә өстенлек бирүенең төп сәбәбе – аларның икесенең дә иҗат принципларының үзара туры килүенә бәйле. Моңа төшендерерлек шактый гына дәлилләр белән очраштык түгелме?

Дөрес, аларның икесен дә әдәбият тарихы фәнендә галимнәр романтизм вәкилләре буларак бәялиләр. Әмма бу әдипләрнең ул иҗат методы кысаларына гына сыеп бетмәүләрен дә игътибарсыз уздырып җибәрү мөмкин түгел. «Карак мулла», «Карт ялчы» хикәяләрен генә алып карасак та, аларның реалистик планда иҗат ителүләре шик тудырмый. Ул әсәрләрдә экспрессионистик алымнарның шактый уңышлы файдалануын инкяр итү мөмкин түгел. «Яшь йөрәкләр» кебек роман жанрында язылган әсәрен алып анализлаганда да, шундый ук нәтиҗәләргә килергә мәҗбүр булабыз.

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Б. 77.

Тагын шунысы бар: модернистлар романтизмны өстен күргәннәр, реализмны, натурализм белән янәшә куеп, хәтта сәнгатькә, сәнгатьчәлеккә санамаганнар. Әмма Г. Ибраһимов ул юлга бармый, реализмны читкә какмый. Бу яктан аның әдәби-эстетик карашлары тагын да кызыклырак һәм мавыктыргычрак кебек тоела.

Г. Ибраһимов хисләрне мөмкин кадәр тулырак тасвир итәргә тырыша. Шушы яктан ул роман жанрын кулай күреп сайлап ала һәм аның төрле юнәлешләрдә, күләмле итеп тормыш картиналары тудырырга мөмкинлек бирүен уңай файдалана.

«Яшь йөрәкләр»дәге Зыя да, Мәрьям дә, Җәләш мулла да хисләр эчендә яшәүчеләр итеп биреләләр. Бу геройларның эчке дөньясын автор төрле яклап ача. Алар әле хис-тойгылар кайнарлыгына биреләләр, әле кинәт суыналар. Аларда мәхәббәт тә, нәфрәт тә бергә яши. Геройларны шушы рәвешле катлаулы хис-тойгылар эчендә сурәтләү ягыннан XX йөз башы татар әдәбиятында Г. Ибраһимов зур уңышка ирешә. Ул романтик планда да, реалистик планда да экспрессионизм алымнарын оста файдаланып эш итә. Бу аның җитди һәм көчле, киң кырлы язучы булуы хакында сөйли.

*2008*

## Г. Ибраһимов «Мөселман иттифакы» партиясе хакында

Әдипнең татар тарихын тикшерүдә һәм аңлатуда ике хезмәтенә совет чорында аерым соклану белән бәя бирә иделәр. Аның беренчесе – «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» булып, икенчесе «Урал» һәм «уралчы»лар» дип атала.

«Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты һәм Татарстан Башкарма Комитеты бүлекләре һәм комиссияләре карарлары белән Татарстан дәүләт нәшрияты тарафыннан Казанда 1925 елда аерым китап булып басылып чыга[1]. «1926 елда русча басмасы да дөнья күрә. Китап турында 1926 елгы «Правда», «Известия» газеталарында, «Новый

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 7. Тарихи хезмәтләр (1911–1927) / томны төз., текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче *С.Х. Алишев.* – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Б. 502.

Восток» журналы битләрендә һәм башка газета-журналларда уңай рецензияләр була»[1]. «Урал» һәм «уралчы»лар» исә «1927 елда Казанда аерым китап булып басылып чыга. Титул биткә «Урал» гәзитәсенең 20 еллык бәйрәмен үткәрү комиссиясе карамагында басыла» дигән искәрмә бирелгән»[2]. Г. Ибраһимовның бу хезмәтләренә Х.Х. Хәсәнов, К.Ф. Фасеев, Ф.И. Агзамов, Р.И. Нафигов һәм башка галимнәр югары бәя бирделәр[3], М.К. Мөхәррәмов, С.Х. Алишев – әдипнең, тарихчы буларак, «марксист-тарихчыларының беренчеләреннән» булуына аерым игътибар иттеләр[4]. Бу мәсьәлә белән М.Х. Хәсәнов аерым кызыксынды, Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлын җентекле тикшереп фәнни монография язды һәм аны бөек язучы, революционер тарихчы буларак бәяләде[5]. Ул фәнни тикшеренүләрендә галимнәр һәммәсе дә Г. Ибраһимовның марксистик-ленинчыл юлда булуын расладылар. Әмма шул заманга хас социологик принципны файдалануы белән бергә, илдәге сәяси вазгыятькә Г. Ибраһимовның бар тулылыгы белән бирелгәнлеген, коммунистик дәүләт системасының теләкләренә җавап бирүче хезмәтләр язуын, татар халкына һәм аның тарихына советларга кирәкчә мөнәсәбәт тудыруга омтылуларын аңласалар да, карашларының чикләнгәнлеге хакында фикер дә йөрттеләр, аның милли хисләргә иярүләрен тоемлап, шушындый хаталану очракларына да игътибар иттеләр. Әмма бу хезмәтләре Г. Ибраһимовның, миллилеккә бирелүдән бигрәк, татар халкын бөек рус милләтенең сателлиты, иярчене, хезмәтчесе буларак аңлатып һәм сөйләп бирергә омтылышларыннан гыйбарәт иде. Ул тарихи-объективлык юлын сайлавын расларга тырышты, шул ук вакытта марксистик-ленинчыл социологиягә тулысынча буйсынып эш итүен дә күрсәтте.

Г. Ибраһимовның иҗат чоры гаҗәеп катлаулы дәвер иде. Бер яктан солтангалиевчелек каты эзәрлекләнде, икенче яктан илдәге сәяси вазгыять шактый буталчык иде, өченчедән булып узган

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 7. – Б. 502.

[2] Шунда ук. – 509.

[3] Хусаин Ямашев / сост. *Х.Х. Хасанов.* – Казань: Татар. кн. изд-во, 1972. – С. 3–138.

[4] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 7. – Б. 490.

[5] *Хасанов М.Х.* Писатель, ученый, революционер: Страницы жизни и творчества Галимджана Ибраһимова. – М.: Наука, 1987. – С. 224–227.

иҗтимагый-сәяси тетрәнүләр дәверен яхшы хәтерләгән халыкта шул үткәнгә карата ачык бер социологик караш тудыру галимнәрдән таләп ителде. Шушы соңгысын Г. Ибраһимов әдәбиятта да, фәндә башкарып чыга алды. Ясалма тарихлар бары тик югарыдан кушу белән генә һәм аларга ярарга тырышудан туа. Әгәр дә әдип шушы юлга басса, андый хезмәтләре белән хәтта үзенең әдәби әсәрләрен инкяр итәр иде. Социологик тарихлар ул елларда объективлык, партиялелек, марксизм-ленинизм исеменнән, татар милләтен тәмам кечерәйтүдән гыйбарәт хәлдә иҗат ителә башлыйлар. Без хәзер ул хакта ачыктан-ачык, турыдан-туры сөйләшә алырга тиешбез. Темабызның актуальлеге дә шуңардан гыйбарәт.

Г. Ибраһимов, шул чорның тарихчылары кебек, 1905–1907 елгы Халык күтәрелешен татар милли азатлык хәрәкәтенә бәйле, аның үзенчәлекле күрсәткече буларак тикшерә, иҗтимагый үсешнең асылы буларак бәяли алмады. Менә шул сәбәпле татар буржуазиясе динчелектә гаепләнде. Югыйсә татарда дингә сыену милли кысуларга каршы протест рәвешен алган иде инде. Бездәге дини хәрәкәтләр эчтәлекләре белән милли-азатлык хәрәкәтләре дә иделәр. Менә шуның өчен дә, аңлашылып тора, 1905–1907 елгы Халык күтәрелеше моңа кадәр барган милли-азатлык хәрәкәтләреннән бер этабының, әмма беренче этабының түгел, махсус тикшерүгә лаеклы нәтиҗәсе иде, шул ук вакытта ул яңа чорны да башлап җибәрде. Аның либерализм дәвере булуы аңлашылып тора. Икенчедән, 1905–1907 елгы Халык күтәрелеше милли-азатлык һәм революцион хәрәкәтләрнең һичшиксез җиңү белән тәмамланачагына ышаныч тудырды. Өченчедән, 1905–1907 елгы Халык күтәрелеше татар милли революцион көчләренең мәдәни яктан алдынгы һәм халыкларны әйдәп барырлык дәрәҗәдә өстенлекле булуын да күрсәтте. Бу яктан татар халкы белән, мәсәлән, поляклар арасында аермалар юк дәрәҗәсендә иде. Әмма алдагы хәрәкәтләрдә бөтен авырлыклар татар халкына төшәсен, Россия уртасындагы саналган, әмма мәмләкәтнең һәммә өлкәләрендә диярлек үз җирләрендә яшәүче татар халкына милләтне географик җирлек белән бәйләп карау хата икәнлеген, бары тик мәдәни мохтарият кысаларында күзаллауның дөрес һәм табигый булуын төшенүгә юл ачты, шул хакыйкатьләрне ачык күрсәтеп бирде. Моны аңлау алдынгы көчләрнең югары фикерле булулары хакында сөйли

иде. Әмма Г. Ибраһимов башкача уйлый, башка төрле нәтиҗәләр чыгара. Сәбәбе, әлбәттә, бик гади. Ул иҗтимагый үсеш, иҗтимагый аң белән сыйнфый үсеш һәм аңны бер ноктада карый, шуның нәтиҗәсендә тарихи карашлар системасын тудыра. Бу аның марксистик-ленинчыл социологик принципларның нигезләрен төгәл үзләштерүеннән килә. Г. Ибраһимов гомумән дә европа һәм рус акыл ияләренә, авторитетларына иярергә яшьли өйрәнә. Аның бу үзенчәлеге «Татар шагыйрьләре» (1913–1914) хезмәтендә аеруча ачык чагыла. Татар дөньясын «мәдрәсә исе килүче» буларак бәяләп, европоцентристик идеалларны ул үзенә байрак итә һәм халыкны да шул идеалларга иярергә чакыра. Татар милли буржуазиясенең формалашуын һәм югары катламы тарихын, үзенчәлекләрен тикшергәндә Г. Ибраһимов аның Россия империясенә хезмәт итүенә төп басымны ясый, әмма империя ягында торганына караганда, «турыдан-туры татар җәмәгать эшләрен үзенә кәсеп итеп алган»[1] булуына бар игътибарны юнәлтә. Бу үзенчәлеге әдипнең тарихи хәрәкәтләрне милли кысаларда карарга кирәклеген ачык күзалламавыннан килә. Әгәр дә аның аңында марксистик-ленинчыл тенденциоз карашлар бөтен тулылыгы белән урнашып җиткән булса, ул татар буржуазиясенең калган ике катламын да шул ук бәя кысаларында карамый калмас иде. Әмма алар аны кызыксындырмыйлар, чөнки социологик тарих өчен ул катламнарның роле юклыгын әдип инде ачык күрә. Бу ике катламның берсен ул «самодержавиягә багланган»[2] алпавытлар-мирзалар буларак атый, икенчесен «иске тип чиновник булып каткан»[3] төркемгә кертә, «болар бюрократия лагеренда калдыралар»[4] дип белдерә. Татар милли-азатлык хәрәкәте һәм аның тирән тамырлары да Г. Ибраһимов фикерләмәләреннән шулай ук читкә чыгарыла. Патша фәрманнарына буйсынмау, җирдән-байлыктан милли мәнфәгатьләрне өстен куйган татарның югары катламы оештырган аң уяту, дини реформалар уздыру кебек катлаулы фикер үсеше хәрәкәтләре, аларның халык эченә китүләре һәм бу процессларның бездә көчле булуына төпләп игътибар тиешле дәрәҗәдә бирелми. Бөтен мәсьәләләр сыйнфый мәнфәгать

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 7. – Б. 355.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук.

таләбенчә алга куела. Чөнки боларны факт буларак искә алу һәм кузгату гына да социологик теориянең асылын какшатыр иде.

Татар буржуазиясе XX гасыр башына кадәр үк, XIX йөзнең урталарына үз идеологиясен булдырып, җәдитчелек кысаларында аны алга таба үстерде. 1883 елда «Тәрҗеман» газетасы чыгарыла башлый. Милли хәрәкәтнең сүз ирегe алу юнәлешендә бу беренче бөек җиңүләреннән берсе иде. Чөнки татар милли буржуазиясе 1906 елгы Конституцион ирекләргә кадәр үк, төрле китап нәшриятлары һәм типографияләре булдырып, милли җәмәгатьчелеккә хезмәттә шактый мактаулы уңышларга ирешә алды. Шундыйларның тагын да берсе чын мәгънәсендә милли мәктәпне тудыру, аны ныгыту, саклап калу һәм үстерүдән гыйбарәт иде. Г. Ибраһимов та, аңардан соң да социология кысаларында үстерелгән тарих гыйлеме бу милли казанышларга озак еллар бәя бирә алудан мәхрүм калды. «Китап дөньясына сәяхәт» хезмәтендә галим Ә.Г. Кәримуллин 1612 елдан татар милли басма китабының яшәү тарихын ачыклап[1], патша цензурасы заманнарында аның шактый көчле басым һәм каршылыкларга дучар булганлыгын, әмма халыкка аң-белем тарату юлында хезмәт итүен ачык аңлатып бирә алды, ә 1905–1907 еллардагы Халык күтәрелешеннән соң да, конституцион ирекләр бирелүгә карамастан, Россия шартларында шактый авырлыклар белән яшәвен язды[2]. Г. Ибраһимов исә «татар буржуазиясенең Беренче революциягә кергәндә әйтерлек әзерлеге дә, ачык яки яшерен организациясе дә, партиясе дә булмады»[3] дип язды, Габдерәшит Ибраһимовның (1857–1944) «милли кыңгырау» дип аталуының тарихын да ачмады, аны бары тик «татар буржуа-алпавыт дөньясының тарихи кыңгырагы»[4] дип, кимсетеп, Россия Эчке эшләр министрлыгының агенты рәвешендәрәк кенә телгә алды, татар идеологларыннан һәм бөек галимнәреннән берсе Муса Бигиев (1873–1949) аның өчен «Мөселман иттифакы» партиясенең «җанлы протоколы»[5] гына иде. Әгәр дә ул аларның тарихи-мәдәни

---

[1] *Кәримуллин Ә.Г.* Китап дөньясына сәяхәт: Татар басма сүзенең сәхифәләреннән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – Б. 14.
[2] Шунда ук. – Б. 206.
[3] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 7. – Б. 355.
[4] Шунда ук. – Б. 357.
[5] Шунда ук. – Б. 357.

эшчәнлекләрен ача башласа, сайлап алган методына һәм стиленә хилафлык киләчәк иде, әлбәттә. Ничек тә татар милли буржуаз көчләренең дәрәҗәсен төшерү омтылышлары аның тенденциозлыгын көчәйтте генә. Андый урыннарда ул тарихчы булудан пропагандист роленә күчә. Менә шуңа күрә дә татар пролетар оешмаларының нәкъ башка телдә сөйләшүче эшчеләр кебек үк эшләрне оештырып алып бару, «социал-демократия байрагы астында берләшү, тик агитация, пропаганда чараларында гына татар өчен аерым методлар куллану»[1] сыйфатлары аны сокландырды. Дөрес, ул яктан татарның сокландыргыч эшләре бар иде. Большевистик басма китаплар, брошюралар, листовкаларның XX йөз башында масса төсен алуы И. Абдуллинга, «Большевистик көрәшчән сүз» исеме астында аларны махсус туплап, өйрәнеп, бәяләп, аларны 1987 елда аерым китап буларак бастырып чыгарырга мөмкинлек бирде[2], беренче татар пролетар язучысы Г. Коләхмәтов XX йөз башында «Уалган мол» хикәясен язды, «Ике фикер», «Яшь гомер» большевистик драмаларын иҗат итте[3]. Бу фактлар татарларда 1917 елга кадәр сыйнфый аңның шактый югары булганлыгы хакында сөйли, бәхәс юк. Бу исә татар буржуазиясенең милли-азатлык идеалларына хезмәт итәргә чакыруларының сәбәпләрен дә ачык күрсәтә. Әмма изелгән милләттә сыйнфый көрәш башлану өчен, марксистик-ленинчыл тәгълимат аңлатуынча, милли-азатлык хәрәкәтенең уңышка ирешүе шарт[4]. Г. Ибраһимов моны танымый, хәтта искә дә алмый. Бу түгелме аның тенденциозлыгы күрсәткече?

Милләтенең дәрәҗәсен төшерү, аны мескен, тормыш өчен яраксыз итеп тасвир итү өчен, Г. Ибраһимовка аның авангард рус халкыннан башка, үз мөстәкыйльлегендә, беркем дә түгеллеге уйдырмасын уйлап чыгарырга, моның өчен берничә мисал да китерергә кирәк була. Материалны ул «Мөселман иттифакы» документлары арасыннан барлый, төп матбугат чаралары булган «Казан мөхбире»

[1] Шунда ук. – Б. 356.

[2] Большевистик сугышчан сүз / төз. һәм кереш сүз, искәрмәләр авт. *И.А. Абдуллин.* – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 31–32.

[3] *Гыйззәт Б.* Татар пролетариат әдәбиятына нигез салучы // Гафур Коләхметов: революционер-язучының 100 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б. 36–37.

[4] Философский словарь / под ред. *М.М. Розенталя.* – Изд. 3-е. – М: Политиздат, 1972. – С. 270–271.

газетасын актара. Турыдан-туры дәлил ролен үтәрлек мисаллары очрамагач, арадан кайбер вакыйгаларны көлкегә алудан гайре чарасы калмый. Шул рәвешле, «Иттифак»ның Икенче съезды барышы вакыйгалары аерым һәм максатлы мыскыллана[1]. «Конституцион демократия партиясе» белән кушылуны да, шушы кадетларның 1906 елгы съездда докладчыларыннан татарны һәм Чыңгыз ханны искә алып сөйләгәннәрендә Йосыф Акчураның француз телендә керткән кисәтүләрен дә ул «иркәләнү» буларак атый[2]. Съезд рәисе князь Василий Александрович Долгоруков (1868–1918), ягъни 1907 елдан башлап Николай патшаның адъютанты, аннары генерал-майор, сарайдагы үзара исеме – «гофмаршал Валя», үзе махсус, турыдан-туры килеп тә, ахырдан да «Иттифак» вәкилләре һәм шәхсән Йосыф Акчура каршында берничә тапкыр гафу үтенүләре дә Г. Ибраһимов каләме өчен Россиядә татар мәртәбәсе күрсәткечләре түгел[3]. Шунысы гаҗәп: русның алдынгы карашлы акыл ияләреннән, олы алпавытларыннан берсе Федор Измайлович Родичев (1854–1933) «Россиядәге җәмәгать белән җир биләү ысулын тәнкыйть кылып сөйләгәндә, «бу борынгы татар урдалары заманыннан калган начар бер мирас» дигән мәгънәдә»[4] чыгыш ясый. Моны Г. Ибраһимов аерым игътибарга ала, әмма көлке бер ситуация буларак мисалга китерә. Мондый урыннар аның акылының «төрттерү», «чыгымлап кую» үзенчәлегеннән килә. Әмма андый хисләргә бу тарихи хезмәтләрендә ул бик сирәк бирелү җаен карый. Татар милли-буржуаз хәрәкәтенең көчен, аның Россиядә алдынгы урыннарга менүен, яңа заманның яңа эшләре өчен әзер булуын, әйдәп баручы көчкә әверелүен, сәяси яктан җитлеккәнлеген Г. Ибраһимов күрми кала алмый, анысы. Әмма аларга дөрес бәяне ул шушы язмаларыннан читтә куя. Әмма, Дәүләт думасы депутатлары хакында сүз кузгатканда, «монда татар милли буржуазиясенең атаклы юлбашчыларыннан төпле сәясәтче Йосыф Акчуриннар, оренбурглы төпле сәясәтче Фатих Кәримиләр кебек фамилияләр юк»[5] дип белдермичә узмый. Димәк, татарның акыл

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 7. – Б. 365–366.
[2] Шунда ук. – Б. 376–377.
[3] Шунда ук. – 377.
[4] Шунда ук.
[5] Шунда ук. – Б. 382.

ияләреннән, төпле кешеләреннән Россия патша хөкүмәтенең коты алынып торган, андыйлар булса, аларны дәүләт һәм халык бәхете өчен эшләрдән мөмкин кадәр читләштерергә тырышкан. Мондый сәясәтнең ил өчен зыянлы булуын Г. Ибраһимов искәртми кала алмаган. Бу урыннарда аның шәхси хисләре дә уйнап алган. Әмма, шушындый ачышлары булуга да карамастан, аның тарихи хезмәтләре социологик һәм рус большевикларының тенденциозлыгы кысаларына куып кертелгән марксистик-ленинчыл дип аталган карашларга буйсындырылып язылганнар. Бу яктан безнең әдибебез татарда алда баручылардан берсе иде. Аның талантлы, әдип буларак тасвирлы күзаллаулары, оста каләме халык эчендә коммунистик тенденциоз идеологиянең җәелүенә уңышлы хезмәт итте.

## Әдәбиятта әдәби-текстологик анализ алымы нигезләре

Борынгы әдәби ядкярләрне барлаганда, аларга бәяләмә биргәндә әдәби-текстологик анализ алымыннан башка эш итү хаталы фикерләмәләргә, фәнни булмаган нәтиҗәләргә этәрә. Шунлыктан бу төр анализ алымын гыйльми эзләнүләрдә файдалану зарури икәнлеген ассызыкламый мөмкин түгел. Әдәби-текстологик анализ алымын борынгы ядкярләрне анализлауда гына куллану дөрес икән дигән хаталы фикергә дә килергә ярамый. Ул һәртөрле әдәби текстларны анализлау өчен кулай, кирәкле һәм таләп ителүче анализ юлы буларак та кабул ителергә тиешле.

Инде күптәннән, әдәби текстларны төшенү кирәклеге кешелек тарафыннан аңлана башлаганнан бирле диярлек кулланылучы бу анализ алымы фәндә файдаланылса да, аның отышлы һәм каршылыклы яклары барланганы, бәяләнгәне юк диярлек. Моның сәбәбен бары тик әдәби-текстологик анализны кулланып эш итүне заман таләпләреннән ерак, урта гасырчылык дип күзаллауда күрергә мөмкин. Әмма соңгы елларда еш телгә алына торган герменевтика юнәлеше бу фикерне тулысынча диярлек инкяр итә. Шуның белән бергә, күп очракларда, моны практик тәҗрибәләрнең әлегә җитенкерәмәвеннән дип белергә кирәк. Герменевтиканы хаталы аңлау һәм аңлату да күзәтелә.

Әдәби-текстологик анализ алымын текстология гыйлеме белән бердәй итеп карау очраклары гыйльми һәм гамәли текстология гыйлеме өлкәләрен белеп бетермәүдән килә. Һәрхәлдә, әдәби-текстологик анализ методы текстология фәне белән ныклы бәйләнештә тора, әмма аның аерым һәм төп өлкәсе булып санала алмый, бәлки әдәбият белеменә карый. Моның сәбәбе әдәби текстларны өйрәнүгә һәм аларны аңлатырга омтылышка барып тоташа. Әдәби текстологик анализ методлары текстология гыйлеменнән үсеп чыга, шуның аркасында аны гыйльми текстология өлкәсенең фәнни алымнары белән бутап күзалларга да мөмкин. Һәрхәлдә, әдәби-текстологик анализ алымы, тулы килеш булмаса да, татар әдәбият гыйлеме фәнендә туктаусыз кулланыла. Башка төр әдәби анализ методларында да аның кайбер якларын файдаланалар. Бу үз чиратында фикер буталчыклыгына китерә. Шушы сәбәпле әдәби-текстологик анализ алымы нигезләрен билгеләү фән өчен методологик яктан әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе икәнлеген монда ассызыклап үтәргә кирәк.

Әдәби-текстологик анализны, тар мәгънәдә алсак, әдәби текстларны шәрехләү, гомумән, шәрех бирү, аңлату дип тә атап булыр иде. Әмма шәрехләү әдәби текстологик анализның төп максаты һәм нәтиҗәсе түгел. Ә әдәби-текстологик анализдан башка шәрехләүгә килергә ярамый. Димәк, герменевтиканы әдәби-текстологик анализның бер өлкәсе дип карарга мөмкин дип уйларга нигез бар.

Татар әдәбият белеме фәнендә, герменевтиканың иң затлы үрнәге буларак, Т. Ялчыголның (1768–1838) 1796 елда тәмамлаган «Рисаләи-Газизә» хезмәте кала килә. Аның без, хәтта авторы «Шәрхе “Собател-гаҗизин”» дип, ягъни Суфи Аллаһиярның «Гаҗизләргә терәк» әсәренә шәрех буларак атаса да, әдәби-текстологик анализ алымына нигезләнеп башкарылганлыгын белдерә алабыз. Моңа Т.Ялчыгол шәрехләүне киң планда аңлау ярдәмендә ирешкән.

Инде әдәби-текстологик анализ алымының нигезләрен барлап, аларга тукталып үтик.

## I

Әдәби-текстологик анализ алымы әдәби әсәрне аңлатуга корыла. Шәрехтә, мәсәлән, һәр сүзнең мәгънәсе әһәмиятле. Хәзерге текстологик хезмәтләрдә аңлашылмаучы сүзләргә астөшермә

сүзлекчәләр бирелә. Бу юлдан аермалы буларак, әдәби-текстологик анализ алымы әдәби әсәрнең эчтәлеген ачыклый һәм аңлата. Икенче төрле без аны, гадиләштереп әйткәндә, эчтәлек сөйләүдән гыйбарәт дип билгеләр идек. Чәчмә әсәрләрнең эчтәлеге, драма жанрларыныкы кебек үк, сөйләп бирелә ала. Шигъриятнең эпик формаларында язылган әсәрләрнең дә эчтәлеген сөйләү һәм аңлату авырлык тудырмый. Әмма лирик поэзия белән эш башкачарак тора. Аның эчтәлеге гади сөйләмгә буйсынмый. Бу мәсьәләне чишү өчен, әдәби-текстологик анализ алымы шигырьнең образ һәм символлары бергәлегенә игътибар юнәлтә, аларны барлый, ачыклый, аңлата. Асылда, берләштерә. «Яшерен мәгънә» буларак, символ шактый катлаулы эчтәлеккә ия була. Аны дөрес итеп бары тик «культурология тәртибе» («культурологический ряд») нигезендә генә ачыкларга мөмкин. Әмма хәзерге шагыйрьләр күпчелек очракта бу «тәртип»не «белмиләр», яки аны инкяр итеп, үз талантлары кушканча «ирекле мәгънә» салынган символлар кулланалар. Мондый шигырьләр анализланганда, галимнән шактый сак булу таләп ителә. Андый символларның мәгънәсен ачыклауның үз методикасы бар.

Мисалга «таң» сүзе белән бәйле символны алып карыйк. Суфичылык әдәбиятында ул Ахирәт көнен аңлата. Ә инде XX йөз башыннан бу символ «кискен үзгәреш» кичерә. Монда Европа әдәбиятларының тәэсирен игътибарга алмый мөмкин түгел. «Таң» сүзе, символ буларак, революцион яңарыш, күтәрелешне аңлата башлый. Бүгенге көн шигъриятендә ул «асыл», «хакыйкать» мәгънәләрен дә йөртә. Моны суфичылыкка хас мәгънәсенә үзгәртелеп кайтартылуы дияргә мөмкин.

Шулай итеп, текстны аңлату тарихилык принцибын таләп итә, шунлыктан әдәби-текстологик анализ алымы әсәрнең эчтәлеген тарихилык принцибыннан читләштереп аңлата алмый.

Әдәби текстны аңлау һәм аңлату иң җиңел ысулга, ягъни «эчтәлек сөйләүгә» генә кайтып кала кебек тоелса да, әдәби-текстологик анализ алымы бу юлында катлаулы мәсьәләләргә очрый. Аларны гомум методик нигездә хәл итү юнәлешен тота.

Шулай итеп, әдәби әсәрнең эчтәлеген ачыклау гади яки катлаулы эш булырга мөмкин. Бу – әсәрнең үзенә бәйле. Гади әсәрнең эчтәлеген аңлату җиңел булса да, катлаулы әсәрләр аңлау өчен

авыр булалар, аларның текстына төшенү киң белемнәрне таләп итә. Гади әсәрне аңлатканда ялгышлар булган кебек, катлаулы әсәрне аңлатканда алар күбрәк очрыйлар. Андый катлаулы «урыннар» шәрехләүне таләп итәләр.

Әдәби-текстологик анализ алымы белән эш иткәндә туктаусыз куела торган сораулар текст белән бәйле була: сүзләр дөрес аңлашыламы, аларга автор нинди мәгънәләр салырга мөмкин? Хикмәт – әсәрнең мәгънәсен аңлау-аңламауда. Әгәр дә әдәби әсәрнең мәгънәсенә төшенәбез икән, аның эчтәлеген ачыкладык дигән сүз.

II

Текстология фәненең төп нәтиҗәләре әдәби әсәрнең авторын, язылу датасын һәм тарихын ачыклауга бәйле. Әмма әдәби-текстологик анализ алымы өчен әсәрнең, язылу тарихыннан бигрәк, язылу сәбәпләре аерым әһәмияткә ия. Дөрес, әсәрнең язылу тарихы белән язылу сәбәпләре үзара бәйләнештә булалар. Әдәби-текстологик анализ бирелгәндә әсәрнең язылу тарихы исәпкә алына, шулай да төп игътибар язылу сәбәпләренә юнәлтелә, чөнки әсәрнең язылу сәбәбе яки сәбәпләре аның текстын аңлау һәм аңлату өчен әһәмиятле булып тора. Моның өчен әсәр язылган чорны, тарихи вакыйгаларны, авторның аларга бәйләнешен яки мөнәсәбәтен белү таләп ителә. Бу белем башкаларга бары тик сөйләп бирү юлы белән генә тапшырыла ала.

Әдәби әсәргә анализ ул шул әсәр текстының эчтәлеген ачыклау һәм билгеләүдән гыйбарәт дип белсәк, әсәрнең язылу сәбәбе яки сәбәпләре әдәби-текстологик анализ алымы өчен эчтәлекнең масштабын билгеләгәндә кирәк. Ә аны ачыклау исә әсәрнең тарихи әһәмиятен күрсәтә.

Мисалга Г. Тукайның «Китмибез!» (1907) шигырен алырга мөмкин. Язылу сәбәпләре «ачыкланмау» аркасында, бу әсәр 1950–1970 еллар әдәбият фәнендә пан-төркичелеккә каршы, татар халкын Төркиягә китәргә чакырган татар байларына җавап буларак язылган дип аңлатыла иде. Мәктәп дәреслекләрендә дә шундый фикер җәелдерелде. Әмма бу шигырьнең бүтән төрле тарихи вакыйгаларга барып тоташканлыгы ачыкланылгач, әсәр бөтенләй башка эчтәлектә «ачылып» китте. 1906 елның 31 март император фәрманы нигезендә татарча укытуны бетерү белән турыдан-туры

бәйләнеше барлыгы раслангач, әсәрнең урыс карагруһларына каршы язылганлыгы да билгеле булды. Г. Тукайның бу шигыре белән милли телне, милли телдә укытуны яклап чыкканлыгы аңлашылгач, әсәрнең киң масштаблы икәнлеге дә беленде.

Бу мисал әдәби әсәрнең язылу сәбәбе аның асыл эчтәлеген ачыклау өчен аерым әһәмияткә ия булуын төшенергә ярдәм итә. Әдәби-текстологик анализ юлы, шулай итеп, текстология гыйлеме нәтиҗәләрен әдәби әсәрне аңлатуга мобилизацияли һәм шуның белән башка төр әдәби анализ методларыннан аерылып тора.

III

Әдәби-текстологик анализ алымы әдәби әсәрнең эчтәлегеннән, ягъни текст концепциясеннән автор концепциясен, ягъни автор алга сөргән фикерне бер-берсеннән аерым куеп тикшерә, аларның охшаш булуларын яки каршылыкка килүләрен ачыклый. Бу аңа әдәби әсәрнең эчтәлегенә ирешү өчен кирәк.

Билгеле, күп кенә әсәрләрдә автор концепциясе әдәби әсәрнең үз эченә «яшерелгән» була. Әмма кайбер авторлар, бигрәк тә борынгы һәм урта гасырларның әдипләре, әсәрләренең колофонында (ягъни башлам һәм тәмамлау өлешләрендә) үз концепцияләрен белдерүне мәгъкуль күргәннәр. Шул ук вакытта әсәрнең эчендә дә «мөнәҗәтләр» рәвешендә (бигрәк тә эпик, киң планлы әсәрләрдә бу шулай) автор концепциясе бирелергә мөмкинлек булган.

Әдәби-текстологик анализ алымы белән эш иткән вакытта, авторның үз концепциясе чагылган кисәкләр төп тексттан аерып алына һәм берсе икенчесенә чагыштырма планда анализланалар. Әгәр дә андый «үзеннән-үзе» аерымланучы «автор сүзе», «лирик чигенеше», «автор белдерүе» юк икән, ул вакытта әсәр тарафыннан калку итеп алга сөрелгән фикерләр автор концепциясе буларак исәпкә алына, әсәрнең анализыннан чыккан фикер исә әсәрнең үзенең эчтәлеге сыйфатында тикшерелә. Монда әдәби әсәргә тарихилык принцибы белән «якын» килергә кирәк. Тарихилык принцибы автор концепциясен ачарга ярдәм итә, язучының ни әйтергә теләгәнлеген ачыклау көченә ия.

Мисалга Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясен алырга мөмкин. Әсәр Әҗәл фәрештәсе белән Әлмәндәр карт арасындагы «конфликтка» корылган. Әлмәндәр карт эш сөя

(үзе авылда яши, ә бакчасында дача төзеп маташа – бу, мөгаен, көлке өчен шулай уйлап чыгарылгандыр?), Хәмдебануга өйләнмәкче, ачы бал эчә, гарип-горабаны сөйми һәм башкалар. Автор концепциясе буенча, Әлмәндәр шушы сыйфатлары аркасында Әҗәлдән өстен, кеше шундый булырга тиеш. Әмма текст эчтәлегеннән Әлмәндәр хәйләкәр, ялганчы, эчүне һәм зинаны да читкә куймаучы буларак аңлашыла. Бу каршылык көлке тудыру өчен эшләнелгән, әлбәттә. Укучының Әлмәндәрне «ил карты» дип кабул итүе исә идеянең автор концепциясенә салынып бирүе аркасында барлыкка килә.

Монда автор концепциясе укучыга үзенчә тәэсир итә, фикер тудыруда текст концепциясе әсәрнең идеясен бирә. Бер текст, шулай итеп, ике катламнан торырга мөмкин. Бу катламнар берничә дә була алалар, андый күренешне әдәбият белеме фәнендә «полифония күренеше» дип, музыкаль термин белән атыйлар. Әдәби текстологик анализ вакытында шушы катламнар ачыкланылып, аерым-аерым анализлана, шул юл белән әдәби әсәрнең эчтәлеге ачыла.

Әдәби әсәрне анализлаганда автор концепциясенә иярү субъектив фикерләүләргә, субъектив нәтиҗәләргә этәрә. Объектив бәя бирү өчен, әсәр, ягъни текст концепциясен автор концепциясеннән аера белергә, аларны аерым-аерым тикшерергә, чагыштырырга, бер төрле яки аермалы булуларын ачыкларга кирәк.

Автор концепциясен субъектив фикергә генә кайтарып калдырырга, әһәмияте юк дип белдерергә ярамый. Ул, асылда, хәтта текстның язылу сәбәбен аңлау һәм төшенү өчен дә төп дәлил булып тора.

Шулай итеп, әдәби-текстологик анализ ул әдәби әсәрнең язылу сәбәбен ачыклаудан, әдәби әсәргә герменевтик анализ ясаудан, ягъни текстка шәрех бирүдән һәм әдәби текстны берничә катламда, ягъни автор концепциясе һәм текст концепциясе юнәлешләрендә тикшерүдән, аларны чагыштырып бәяләүдән гыйбарәт. Бу анализ юлы әдәби текстны объектив фикер нигезе итеп карый, шуның ярдәмендә хакыйкатьне ачыклауга ирешә. Аның максаты да шушыңа, ягъни әдәби әсәрнең эчтәлеген объектив планда аңлау-аңлатуга юнәлдерелгән.

**Мисал** итеп Һ. Такташның «Нәни разбойник» әсәрен алып тикшерергә мөмкин. Галим һәм язучы М. Мәһдиев бу әсәрнең

1990 елларда ук мәктәптә укытылырга лаеклы түгеллеген, балаларга тәрбия бирү урынына, аларны бозуын берничә кат аңлатып язып та чыкты. Әмма күпләр аның белән килешергә теләмәделәр. Ике якның да дәлилләре ышандырырлык анализга корылмау да моңа сәбәпче булды. Менә шуңа күрә дә Һ. Такташның бу әсәренә объектив фәнни бәяләмә бирү зарурлыгы хәзерге көндә дә актуаль булып кала килә. Әдәби-текстологик анализ алымы бу мәсьәләне чишүдә дөрес юл була ала.

I. *«Нәни разбойник»ның язылу сәбәпләрен ачыклыйбыз.*

1. Һ. Такташ бу шигырен Казанда 1925 елның 18 февралендә иҗат иткән. Шагыйрь бу әсәренең язылу сәбәпләрен үзе болай дип аңлата: «Нәни разбойник» шигыренең бу юллары меңнәрнең башына шул тәрбиясез яшьлеген исенә төшергәндер. Казлар кыйнап үскән меңнәрчә кешеләр хәзер партия сафында – бөек көрәшнең солдатлары, шуларның берсе Такташ – хәзерге көндә «назлы, мактаулы» шагыйрь...»[1].

Димәк, «Нәни разбойник»ның язылу сәбәбе ачык, ул коммунистларга үзләренең электә кем булуларын исләренә төшерер өчен язылган.

2. Авторның субъектив фикере «элек кем идек тә хәзер кем булдык» дигән гыйбарәгә сыеп бетә. Элек «ата казлар кыйнап үскән» нәни разбойниклар инде җитлеккәннәр, «салкын тайгада яз ясаячаклар», «ачулансалар, айга да шлем киертәчәкләр», ягъни менә нинди булдыклы кешеләр, алар дөньяны үзгәртергә алынганнар. Аларга юлны Ленин үзе күрсәткән.

II. *Әсәрнең эчтәлеген ачыклау, аңа шәрех бирү, аны аңлату этабы. Монда һәр символ, образ, әсәр вакыйгасы сөйләнелергә, шәрехләнергә тиешле.*

«Нәни разбойник»ка автор эпиграф итеп үз әнисенә рәхмәт шигырен биргән. Асылда эпиграф ул әсәрнең темасын ачарга ярдәм итәргә тиеш. Димәк, тема белән турыдан-туры бәйләнештә тора.

Эпиграфта шагыйрь әнисенә үзен тудыруы һәм «төннәр буе йокламыйча», «җырлый-җырлый багуы» өчен рәхмәт әйтә. Әмма

---

[1] *Карагыз: Такташ Һади*. Әсәрләр: өч томда. – Т. I. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 474. «Искәрмә һәм аңлатмалар» бүлеге.

«авыр кара тормышында әнкәсенә ярдәмче була алмавын» искәртә. Ул аңа ярдәме тисенгә түгел, бәлки «авыр көрәш һәм бөек еллар өчен» туган икән. Димәк, Һ. Такташ, «Нәни разбойник» дигәндә, бөек эшләр кылырга тиешле көрәшченең балачагын күздә тота булып чыга.

*Әсәрнең эчтәлеге.* Лирик герой үзенең усал булганлыгын искәртә һәм башкаларга күрсәткән яманлыкларын саный башлый. Ул, гөнаһ дип тә белмичә, «зәңгәр төндә күрше карчыгының ак әтәчен урлаган». Караклык, әлбәттә, зур гөнаһ. Монда «зәңгәр төн» һәм «ак әтәч» символик мәгънә төсмерендә килсәләр дә, асылда андый мәгънәгә ия түгелләр. «Күрше карчыгы» исә үзе дә усал икән, ул лирик геройны: «Денеңнән яз, явыз, урыс!» – дип каргый.

«Ден» – борынгы төрки сүз. Ул хәзерге телебездә «тын» формасында кулланыла, борынгыларда «җан», «рух» мәгънәләрендә йөргән. Гарәп сүзе «рух» һәм фарсы сүзе «җан» кулланылышта активлашкач, җанның билгесе булган «тын» мәгънәсендә генә калган. Әмма ислам дине һәм мәдәнияте йогынтысыннан читтә калган төрки телләрдә ул бүген дә «җан» мәгънәсендә йөри. Татар әдәби телендә дә борынгырак гыйбарәләрдә сакланып калган.

«Явыз» һәм «урыс» сүзләре тиңдәш кисәкләр формасында килгәннәр. Гыйбарәдә «явыз» белән «урыс» бергә кулланыла. Алар «разбойник» сүзе белән уртак эчтәлеккә ия. Шул рәвешле «явыз», «урыс», «разбойник» сүзләре шигырь текстында үзара тәңгәлләшәләр.

Алга таба шигъри сурәт бирелә, аны лирик чигенеш дип тә билгеләргә була. Монда Һ. Такташның хис шагыйре икәнлеге ачык сиземләнә: «Кышкы төннең салкын күкрәгеннән Чаналар да шаулап үттеләр...» Шул «чаналарда» лирик геройны «еллар бик еракка алып китәләр». Елларның алып китүе, әтәч пешергән учакларның әллә кайчан сүнүе күп вакытларның үткәнлеген тоярга ярдәм итә.

Лирик герой тагын үз усаллыкларын исенә төшерә. Ул карчык-корчыкларга бик күп бәла-казалар китергән, бакчасына кергән «үрдәкләрен таяк белән кыйнап үтергән». Бөтен усаллыкны аннан күргән авыл халкы аны «разбойник» дип атаган.

Тексттагы хәбәрләр лирик геройның чыннан да «разбойник» булуына ышандыра. Шигырьнең дәвамында тагын гомер узуы

искәртелә. Лирик герой кабат усаллыклары хакында сөйли. Бу юлы аның «разбойник»лыктан баш тартмавы аңлашыла бара, ул туган авылындагы «муллаларны кыйнап үтәргә» нияте барлыгын әйтә, шуны дәгъва кыла. Һәрхәлдә, заманасы өчен муллаларны «кыйнау» «дөрес гамәл» буларак күзалланган. Илдәге социализм төзү дәвере мондый «геройлыклар» белән тулы. «Муллаларны кыйнау» лирик геройның сыйнфый көрәшче булып китүен искәртергә тиеш исә дә, автор аңа башка төсмер дә бирә: «Сагынып сөйләр өчен ядкяр итеп» кыйнамакчы икән ул. Хикмәт бары тик хулиганлыкка гына кайтарылып калдырыла.

Алга таба шагыйрь тагын да еллар үтүен тәкрарлауга кайта, бу юлы гомумиләштерү ясап, үзенә алмашка килүче яшь коммунарларның әле дә ата казларны кыйнап үсүен белдерә. Монда «ата казлар кыйнау» символ мәгънәсендә түгел. Димәк, тексттан шул аңлашыла: коммунар булып үсү өчен, ата казларны кыйнарга кирәк икән. Көлкеле сурәт итеп күзаллаганда, калку куелган бу фикер әсәрнең эчтәлеге белән бергә ачылыр иде. Әмма монда ул авторның очраклы әйтелгән фикере рәвешендә кала.

Усаллыгы аркасында лирик герой «авылга сыймаган», «тилергән хисләр җырчысы булган», «сезгә килгән». Монда шагыйрь «сезгә» дип читкә китүен күздә тота.

«Давыл сүнәр», ди ул, революцион үзгәртелешләрне давыл эпитеты ярдәмендә биреп. Үзе үлсә, алмашка аның улы калачак һәм ул «соңгы көрәштә солдат булыр». Менә шунда әсәргә солдат образы килеп керә, ә ул шлем киеп йөри. Әгәр дә алга китеп, «шлем киертербез Айга да» дигән сүзләренә игътибар итсәк, аны да солдат итәчәкләре хакында сүз барганлыгы аңлашыла башлый. Шлемлы солдат, – һәрхәлдә, кызылармеец инде ул, Советлар иле өчен көрәшүче, аның сагында торучы каһарман, Гражданнар сугышы герое.

> Еллар көрәш чиген үтәрләр,
> Яшьләр тимер булып үсәрләр,
> Ата казлар кыйнап үскән яшьләр
> Буржуйларны тотып кисәрләр...

Димәк, тимер булып үсәр өчен, «ата казлар кыйнап үсәргә» кирәк икән. Шул вакытта алар буржуйларны тотып кисәчәк буын булырлар.

Монда шагыйрь үз фикер концепциясен өстен чыгару өчен махсус кабатлана. Әмма текстның үз фикри концепциясе инде ныгып өлгергән, балансны сакларга кирәк. Шуның өчен автор көтелмәгән чигенеш ясарга мәҗбүр. Моны аның үз фикерен укучыга көчләп тагасы килмәве белән генә аңлатып була.

Көтелмәгән чигенеш маяклы кышкы юлдан чанасын печән белән күмгән юлчы килүен сурәтләү белән бәйле. Ул юлчы Мәккә каласын тупка тоттырган Англиянең чит илләр министры Остин Чемберлинны (1863–1937) сүгенеп ачулана. Маяклы юл ул элекләрне кышкы бураннарда адашмас өчен юл буйлап кадап чыгылган агач ботакларыннан гыйбарәт булган. «Сатыйм анасын» сүзтезмәсе татар халкында сүгенү өчен кулланылган. Монда изгелек, ягъни Мәккә каласына хөрмәтле мөнәсәбәт һәм усаллык, ягъни сүгенү аша бирелгән хулиганлык бергә бәйләнештә килә. Моңа кадәр эчтәлектә үстерелә килгән текст концепциясендәге ике тема – яманлык белән яхшылык мәсьәләсе – монда бер юнәлешкә җыела. Әсәргә дин белән бәйләнешле фикер килеп керә.

Шагыйрь аны тема итеп үстерә башлый. Лирик герой үзенең динсез булганлыгын исенә ала, шуңа күрә аннан «әткәсе кулын ташлый», ягъни аңардан кулын селти, ваз кичә, «бу имгәктән кеше чыкмас, Иблис булыр», ди. Иблис, икенче төрле – Шайтан, кешеләрне аздыручы явызлык иясе, кешелек дошманы. Ул, Аллаһы әмереннән чыкканы өчен, Иблис аталган, башбаштаклык, гыйсъянчылык, мин-минлек символы.

Шигырьнең бу өлешендә юлчы белән лирик герой каршы куелалар. Аның берсе – усаллык иясе, икенчесе – усаллыкны усаллык белән инкяр итәргә теләүче, ачуланучы.

Текстта ике фикер концепциясе туктаусыз үстерелә: аларның беренчесе усаллык иясе хакында, икенчесе аны моның өчен ачуланулар турында. Ә еллар һаман үтә торалар. Шагыйрь әсәренә мөмкин кадәр полифоник яңгыраш бирергә омтыла, фикер сызыкларын саклаган хәлдә, аларны эчтәлектә тирәнәйтә. Әсәрнең төзелеш үзенчәлеге, корылмасының нигезе шуңардан гыйбарәт. Мондый алым татар әдәбиятында Һ. Такташка кадәр очрамый.

Еллар уза, ата казлар кыйнап, шалкан урлап үскән лирик герой шагыйрь булып җитлегә. Ул әтисе алдында мактанырга тели. «Юлдан язарына» Ленин үзе «юл күрсәткән» һәм кулына «үткен

каләм» биргән. Монда «үткен каләм» күчерелмә мәгънәдә килә, ул – шагыйрьнең сүз ирегe алуы турында сөйли торган берәмлек.

Автор тагын вакыт узуын сурәт аша белдерә, кичәге февральне кар ашаучы нечкә билле март җиле алыштыра. Майга да ерак калмаячак, салкын тайгада яз ясаячаклар әле. «Җир безнеке булыр» дигәнендә, әлбәттә, бөтен дөньяда революцияне җәелдерү хыялы хакында сүз барганлыгын аңлавы кыен түгел. Әгәр «ачулансак», ди ул, «шлем киертербез Айга да». Бәлки, шушы рәвешле автор хәтта галәмнең «разбойник»лар кулында булачагын әйтергә телидер? Һәрхәлдә, сүз Айны да кызылармеец «ясау» мөмкинлеге хакында бара, тик моның өчен «ачу килү» генә кирәк, имеш.

Шигырь сагынып сөйләр өчен авыл мулласын кыйнап үтәргә исәбе барлыгы, лирик геройның күрше карчыгын кисәтеп куюы, инде бер тапкыр әйтелгән фикеренең кабат искәртелүе белән тәмамлана.

Мулланың гаебе нидә икән дигән сорау тумый калмый, билгеле. Монда автор, мөгаен, муллаларның дини тәгълиматны алга сөрүләрен түгел, бәлки хәрәм-хәләл, гөнаһ-савап кебек этик кагыйдәләрне билгеләүчеләр һәм саклаучылар булуларын истә тоткандыр? Һәрхәлдә, замана шаукымы да чагылмый калмаган, анысы.

Шигырь эчтәлегеннән шул аңлашыла: Һ. Такташ «разбойник»ны афәрин кеше итеп сурәтли, ул киләчәк тормыш өчен көрәшүче икән.

III. *Автор концепциясеннән текст концепциясен аеру һәм аларны чагыштыру.*

Әсәргә шәрех биргәндә үк, концепцияләргә ачыклык кертелеп барылды, чөнки мәсьәләне тикшергәндә кабат шул ук эчтәлеккә мөрәҗәгать итәргә һәм аны сөйләргә, аннан дәлилләр китерергә мәҗбүр булыр идек. Шунлыктан анализның бу пунктында гомуми фикерләмәләр белән эш итәргә мөмкинлек туа.

Нәрсә соң ул *текст концепциясе* дигәндә, аны күпләр катлаулы итеп аңлата һәм аңлатмаларда буталчыклык тудыралар. *Текст концепциясе* әсәрнең кем турында, нәрсә хакында барганлыгына бәйле, аның эчтәлеге темада чагылыш таба, әмма ул теманы алыштырмый. Шулай итеп, әдәби әсәрнең *текст концепциясен*

тема белән бәйләнештә дип белдерә алабыз һәм аны темадан чыгарырга тиешбез.

*Автор концепциясенә* килгәндә, ул әдәби әсәрнең идеясенә якын тора, аның белән бәйләнештә була. Идея, – шулай итеп, *автор концепциясенең* әдәби әсәрдә чагылышы ул, ягъни *автор концепциясе* әдәби әсәрнең идеясе өчен хезмәт итә һәм аны ачыклауга юнәлдерелә.

«Нәни разбойник»та мондый фикер алга сөрелә: элекке «разбойник»ларга Ленин юл күрсәткән һәм алар «юлга кергәннәр», инде «салкын тайгада яз ясаячаклар», «Айга да шлем киертәчәкләр», әгәр ачулары килсә, әмма «ядкяр өчен» авылларындагы муллаларны кыйнап китәселәре бар. Димәк, «Нәни разбойник» шигыре кичәге «разбойник»ның бүген «коммунар», «партия солдаты» булуы турында. *Текст концепциясе* тема белән бәйле дип карасак, димәк ул «разбойник»ны сурәтләүдән, аның чыннан да разбойник булуын раслаудан гыйбарәт.

*Автор концепциясе* исә әсәрнең идеясенә бәйле, дидек. «Нәни разбойник», димәк, *автор концепциясе* буенча караганда, көрәшче-коммунарның, «партия солдатының» яшьлеге ул, ягъни кечкенәдән «разбойник» булып ныгып, «гөнаһ-фәлән дип уйлап тормыйча» үскәндә генә синдә көрәшче рухы яши.

Ике концепция дә үзара туры килгән төсле, әмма аерма да бар, ул нюанслар дәрәҗәсендә: *текст концепциясе* «разбойник»ны акламый, *автор концепциясе* аны олылый, аны яңа заман кешесе итеп күрсәтә. Әсәрдә сурәтләнелгән детальләр, искә алынган фактлар *текст концепциясенә* карыйлар, алар «нәни разбойник»ның чыннан да гөнаһ иясе булуын раслыйлар. Әмма *автор концепциясе* «разбойник»ны аклауга юнәлдерелгән, моның өчен шагыйрь заманага хас көрәш рухын алга сөрә. Идея темадан өстен чыгарыла, ягъни *текст концепциясе* исә *автор концепциясенә* буйсындырыла: көрәш рухы кичәге «разбойник»лардан үскән бүгенге коммунарда яши икән! Юкса *текст концепциясеннән* бөтенләй башка фикер аңлашылыр иде: дөньяның алга барышы «разбойник»лар кулында мәгънәсендә.

Автор концепциясе белән текст концепциясе арасында нюанслар дәрәҗәсендә булса да туры килмәүчелек иртәме-соңмы әсәр тирәсендә төрле бәхәсләр тудыра башлый. Әмма аларның туры килүе әсәрне талантлы итә, билгеле.

Әдәби-текстологик анализда иң авыры – өченче пункты. Беренче икесендә фикерләүнең таяну нокталары конкрет, ачык күренеп торалар. Өченчесендә мәсьәлә шактый катлаулана, әсәрне тикшерүчедән аналитик фикерләү осталыгы таләп ителә башлый. Әдәби әсәрләрне анализлау эше белән даими шөгыльләнгәндә, әлбәттә, мантыйкый фикерләү дәрәҗәсе дә арта бара.

Монда шуны киңәш итәргә кирәк: текст концепциясен ачыклау өчен, мөмкин кадәр әдәби әсәрдә алга сөрелгән идеядән читкә китәргә, вакыйгаларга, каһарманнарның эш-гамәлләренә гомумкешелек принципларыннан чыгып бәя бирергә, теманы ачыклый белергә өйрәнергә кирәк. Автор фикеренә генә ияреп йөрү ул – аңда томаналык кына тудыруга сәләтле.

Без күпчелек очракта авторны төшенергә тырышабыз, шуның белән әдәби әсәрне, текстны аңларга омтылуыбызны чиклибез. Дөрес, текстны автор тудыра һәм аны үз фикер юнәлешенә мөмкин кадәр буйсындырырга тели, әмма ул сурәтләгән материал автор фикерен куәтләр өчен хезмәт итмәскә тә мөмкин. Бигрәк тә күчерелмә мәгънәдә сөйләргә мәҗбүр булганда, төрле сәяси һәм иҗтимагый кысулар дәверендә авторлар әсәрнең идеясен үз концепцияләренә түгел, текст концепциясендә чагылдыру юлына баралар. Шуның өчен дә автор концепциясе белән текст концепциясе мәсьәләсен читкә кагарга киңәш итмәс идек.

**Алда аңлатылганнарга өстәмә рәвештә тагын да берничә мисалны карап үтәргә мөмкин.**

*1) Г. Тукайның* ***«Шүрәле»*** *әкият-поэмасына әдәби-текстологик анализ нәтиҗәләре:*

Бу әкият-поэмасы шагыйрьнең «3 нче дәфтәр»ендә (1907) беренче тапкыр басылып чыккан. Әсәрнең ахырында автор аны «хикәя» дип атый, А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтовларның үрнәгендә «авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуларына» ияреп иҗат итүен белдерә. Алга таба татарлардан да оста рәссамнар чыгып, Шүрәленең «кәкре борынын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысуларын», урманны сурәтләп бирәчәкләренә өмете барын яза, мондый авыл хикәяләрен халыкның үзенә кабат кайтарып бирүнең бары тик файда гына икәнлеген аңлатып уза. Шушы язмасы ахырына «Г.Т.» имзасын куя.

Әсәр биш бүлекчәгә бүленгән. Эчтәлегеннән чыгып караганда, ул ике өлештән, ягъни лирик һәм эпик кисәкләрдән гыйбарәт. Лирик өлеше беренче, икенче, өченче бүлекчәләрдә бирелгән. Беренче бүлектә Кырлай авылы турында языла, Г. Тукай «Кырлай» сүзенә көй өчен «тавыклары җырлай» тезмәсенең рифмалашып килүен, Кырлай халкына шушы сүзләр белән, ягъни «Кырлай – тавыклары җырлай» дип үртәк ясауларын шаянлык белән искәртеп уза, моның белән әсәргә күңелле төсмерләр бирә, шушы авылда бераз яшәп китүен, кыр эшләрендә катнашуларын исенә ала.

Кырлай авылы лирик геройның хәтерендә урманнар эчендә, яшел хәтфә үләнле болыннары белән уелып калгандай аңлашыла. Әмма ул авыл зур түгел икән, кечкенә инеш буена урнашкан, һава торышы да монда уртача, яңгыр да вакытында ява, җил дә вакытында исә, урманы тулы кызыл җиләк, күзне ачып йомганчы аны бер чиләк җыясың, чыршы-наратлары да гаскәр кебек тезелешеп торалар, аларның төпләрендә хәл җыеп, күккә карап, лирик геройның ятканнары да булган.

Бу тасвирларны Г. Тукай әкият дөньясын күз алдына китертү максатында шушы рәвешле бирә, әсәре белән укучының күзаллавын чынбарлыктан әкият дөньясына алып китә. Монда шагыйрьнең әдәби иҗат осталыгы да соклану тудыра. Сурәтләрне тагын да көчәйтеп, агачлар, гөлләр, чәчәкләр хакында язып узганда, әдип хәтта «яшелдән чәчәкләр» дип тә тасвирлап ала, гүяки яшел төстәге чәчәкләр дә Кырлай урманында бар икән дигән фикер уяна, моның белән әсәрнең әкиятилеге тагын да арта сыман. Күбәләкләр, Ходайның кошлары, ягъни җәннәт кошлары да тасвирга алынып искәртеп узыла, аларның сайравыннан җаннарның киселүе-хозурлануы хакында языла. Бу күренешләр бульварларны, клубны, танцевальняны (бию урыннарын), цирк, оркестр, театр, концертны алыштыруы хакында фикерләрен биреп, Г. Тукай табигать белән мәдәниятне үзара бәйләнештә икәнлеген, берсе икенчесен алыштырырга мөмкинлеген белдереп уза. Урманның чиксезлеге тарихи Чыңгыз хан гаскәрләре белән тиңләштерелеп, эчтәлеккә милли тарихи тойгылар өстәлә. Шагыйрь бу тойгыларны тагын да тирәнәйтеп, бабайларның батырлыклары, дәүләтләре, дәрәҗәле исемнәре «кылт итеп искә төшәдер» дип искәртеп уза да үз чорына укучының уйларын кире кайтарып, нигә без хәзер «болай соң?» дип

аһ та орып, милли аңны уятып ала. Шуның белән беренче бүлек тәмамлана.

Икенче бүлектә көз һәм кыш көннәрен, чибәр кызларны язуга күчүен белдереп, әмма җыен, сабан туйларын уйлары еракка китмәсен өчен язмаска иткәнен әйтеп уза да, сүз башының, ягъни сөйләргә җыенганының Шүрәле хакында булуын искәртә. Шагыйрь шушы рәвешле укучының хис-тойгыларын җиңелчә генә үртәп-көчәйтеп ала һәм шулай өченче бүлеккә күчә.

Бу бүлектә Кырлай урманын ул «кап-кара урман» дип атый, анда аю, бүре, төлке, куян, поши һ.б. төрле киек-җанварлар булуын, аларны аучыларның очратуларын искәрткәч, җен-пәри, албасты, убыр, шүрәлеләрнең төрлесе барлыгын да белдереп, укучысын экият дөньясына шагыйрь тулысынча алып кереп китә, реальлек һәм шагыйранәлек арасында хисләре куерган укучы экияткә ышаныр хәлгә җиткерелә. Мифик-экияти җан ияләренең дә булубарлыгының сәбәпләрен шагыйрь урманнарның калынлыгына, күкләрнең очсыз-кырыйсыз булуына бәйләп әйтеп уза.

Шушылар белән «Шүрәле» әсәренең лирик өлеше тәмамлана. Моннан соң, искәртелгәнчә, дүртенче бүлектән эпик кисәк башланып китә. Анда да шагыйрь вакыйгаларны сөйләүгә тиз генә күчми, ике шигъри юлда укучының дикъкатен сынап ала, «аз гына җырлыйм әле, көйлим әле» дип куя. Бу рәвешле «күчешләр» бирүе экиятчеләрнең экият сөйләү манерасын да кабатлый, шулай укучының күңел күзе каршысына авылдагы экият сөйләүче әбибабайларны китереп бастырган сыман итә.

Эпик вакыйгалар матур айлы кичтә Кырлай авылының бер егете урманга утынга ат җигеп ялгызы китү хәбәре белән башлана. Ул бик тиз барып җитә. Шагыйрь инде укучының күңелен ялыктырмый. Утын кисүне дә тиз-тиз башкару рәвешендә тасвирлый һәм, шиккә салып, җәйге төннең бераз салкынлыгы, урманда тып-тыныч булуы язылa. Утынчының балта тавышыннан гайре авазлар монда юк. Эшеннән егет туктамый. Әмма күңелгә салынган шик алда нәрсәдер буласын искәртә. Автор, курыкмаска өндәгәндәй, шик-шөбһәләрдән гүяки арындырырга теләп, егетнең «балтасы кулда» булуын белдереп ала да, шунда ук бер ямьсез-ят тавыш ишетелеп, нәрсәнеңдер кычкыруыннан егетнең, сискәнеп, аяк үрә катып калуын әйтеп ала.

Шүрәле «кот очарлык, бик килешсез», «бармак кебек бөгелгән кәкре борынлы», аяк-куллары ботак-тармак кебек рәвешле, эчкә баткан ялтыравык күзле, ялангач, нәзек, әмма кеше сыман гәүдәле, бармаклары исә төз һәм ярты аршын озынлыгында итеп Г. Тукай тарафыннан сурәтләнелә. Шуның белән дүртенче бүлек тәмамлана.

Бишенче бүлектә вакыйгаларның төп өлеше бирелә. Шүрәле белән бик озак карашып торгач, егет: «Сиңа миннән ни кирәк?» – дип сорый. Ә Шүрәле аны шикләнмәскә өнди. Карак та, юл кисүче (юлбасар)ише дә булмавын, әмма бик үк тугры да түгел икәнлеген белдерә. Егетне очратуына бик сөенүен, кешеләрне кытыклар өчен бармаклары яратылуын, көлдереп үтерүен яшерми әйтә дә егетне кытыклы уйнарга чакыра.

Ә егет шунда ук аңа ризалыгын бирә, әмма бер шарты бар икән Шүрәлегә. Кисек агачны арбага күтәреп салышырга булышуын сорый. Бүрәнәне, күтәреп салу өчен авыр булганга, егет урталай яра башлап, аның бер башына чөй каккан икән. Шүрәлегә бармагын ул шул ярыкка тыгарга куша. Аны шунда хәтта «урман сарыгы» дип тә атый, ягъни Шүрәленең аңсыз-акылсыз булуын искәрүен сиздереп ала.

Егетнең сүзенә Шүрәле күнә, эре-эре атлап барып, бармагын «авызын ачкан» бүрәнә ярыгына китереп тыга. Шагыйрь шунда егетнең хәйләкәр икәнлеген укучысына искәртә дә, аның агач ярыгына кыстырылган чөйне балта белән бәреп чыгара башлавын яза. Бу урында Г. Тукай әсәрдә вакыйгалар барышын акрынайта. Егет балта белән суга тора, Шүрәле кузгалмыйча көтә. Менә чөй чыгып оча. Шүрәленең бармаклары кысылып кала. Ул әрнеп кычкырып җибәрә. Ычкынмакчы итә, сызлана, башка Шүрәлеләрне ярдәмгә чакыра. Изгегә сабышып, тәүбә итеп, егетнең кызгануын, бу бәладән коткаруын үтенә, нәселенә-улына тимәячәген әйтә. Ул хәтта башкалардан да кимсеттермәячәк икән аларны, урманда ирекле йөрергә дә ирек бирәчәк, имеш. Шулай тартыла, йолкына, акылыннан шаша. Ә егет өенә китәргә маташа. Ул ат башыннан тоткан, Шүрәленең үкерүләрен асылда ишетми дә.

Егетне Шүрәле мәрхәмәтсез дип атый, үз дусларына белдерер өчен, аның исемен сорый. Егет Былтыр исемле икәнлеген әйтә, егетлек иясе кеше булуын «бу егет абзаң булыр бу» дигән сүзләр белән төшендереп бирә.

Шүрәле һаман да ычкыныр өчен тырыша, котылса, егеткә берәр зыян салырга итә һәм: «Кысты, харап итте явыз «Былтыр» мине!..» – дип кычкыра бирә.

Иртәгесен, башка шүрәлеләр җыелып, шушы сүзләренә җавапта бу Шүрәлене хурлап, хаталы аңлауларын яшермичә, былтыр кысканга быел кычкырма, диләр. Әсәр шуның белән тәмамлана. Анда егетнең батырлыгы, Шүрәле кебек җан ияләренең ахмаклыгы, беркатлы булулары тасвирлана.

Г. Тукай «Шүрәле» әкият-поэмасын халык әкиятенә нигезләнеп язганын вакыйгаларны сурәтләү барышында төрле формаларда искәртә. Г. Тукайныкы кебек үк эчтәлектәге халык әкиятенең тәүге әдәби варианты беренче тапкыр Т.Яхинның «Дәфгыль-кәсәл минәс-сабийавә сабийати, ягъни яшь ир балалардан һәм яшь кыз балалардан ялкаулыкны җибәрә торган хикәяләр» (1900) хрестоматиясендә дөнья күрә. Ул анда чәчмә формада бирелгән, шулай да Г. Тукайдагыча «хикәя» исеме астында урнаштырылган.

Г. Тукай үзенең «Шүрәле» әсәрен, истәлекләргә караганда, Уральски шәһәре янындагы Урал елгасының тармагы булган Чаган буенда җәен 1907 елда ял иткән вакытында язган. Әсәр 63 строфабәеттән гыйбарәт. Тезмәләр янәшә рифмалы, рәмәл үлчәмендә төзелгәннәр. Кыйсса калыбында язылган әсәрләренең берсе. Тасвирларының әкияти булуы белән аерылып тора.

Г. Тукайның «Шүрәле»се әкият-поэма жанрына карый. Кайбер галимнәр аңарда баллада жанрының да үзенчәлекләрен табалар. Әмма «Шүрәле»дә балладаларга хас булган метрик алымнар һәм рифма үзенчәлекләре, эчтәлектә ачык чагылган легендарлык мотивы юк, ягъни анда баллада корылырга тиешле поэтик үзенчәлекләр кабатланмый.

*2) Г. Тукайның* ***«Су анасы»*** *әкият-поэмасына әдәби-текстологик анализ нәтиҗәләре:*

Әсәр беренче тапкыр «Җуаныч» исемле балалар өчен чыгарылган җыентыкта («Сабах» көтепханәсе, И.Н. Харитонов матбагасы. Мәктәп мөкяфәтеннән беренче китап. – Казан, 1908) басылган, тексты шуннан алынып, Г. Тукайның җыентыкларына һәм күптомлыкларына кертелгән. Эчтәлеге буенча әсәрдән балладага хас үзенчәлекләр табарга мөмкин булса да, формасы һәм вакыйгаларның бирелеше белән шигъри формада язылган әкият, ягъни әкият-поэма

икәнлеге аңлашыла. Г. Тукайның 1907 елда язылган «Шүрәле» әкият-поэмасы кебек үк балалар өчен татар халык иҗатына нигезләнеп иҗат иткән иң яхшы әсәрләреннән берсе. Вакыйгаларның бирелешендә һәм чишелешендә әкияти формалар өстенлек итә, әдәп һәм әхлак тәрбияләүдә әһәмияте зур, кеше әйберенә сораусыз кагылырга ярамауны өйрәтә.

Су анасы – татар халык иҗатының мифологик образларыннан берсе. Ул, күзаллаулардан билгеле булганча, асылда суда яши, Әстерхан татарлары ышануы буенча, хәтта иске мунчада да һәм су тегермәнендә дә, хәтта борынгы зиратларда да очрарга мөмкин икән, ир затындагылары *Су атасы, Су бабасы* кебек исемнәр белән атала, нәселе ир һәм хатын җенесеннән үрчи. Үзе кеше сыманрак, әмма борын сөяге юк, бер борын тишеге генә бар. Тәне вак канат сыман йомшак йон белән капланган. Аяклары артка таба карап торалар. Күкрәкләре зур һәм җиргә кадәр салынып төшкәннәр. Аларны җилкәсенә ташласа, артыннан ат белән дә куып тоту мөмкин түгел. Кешеләрне суга батырып үтерә.

Чәчләре озын һәм килбәтсез. Аларны алтын тарагы белән тарый. Әгәр дә аның чәч бөртеге сындә булса, зыян итә алмый, курка. Г. Тукай да аны тузгыган чәчле һәм куркыныч хатын дип яза. Су анасын Әстерхан татарлары күпчелек очракта *албаслы* дип атыйлар, ә Оренбург һәм Себер татарлары, Казан татарлары кебек үк, *Су анасы* дип беләләр, һәртөрле су да, хәтта җыелып торганы да Су анасыз булмый, имеш. Аның чәчләре озын, ә күкрәкләре тезләренә кадәр, диләр.

Казан татарларының ышанулары буенча, Су анасы яр кырына еш чыгып утыра һәм озын чәчләрен тарый. Кулында алтын тарагы бар. Чәч толымнары – кара, озын, үзе буе. Тәне – ямьсез, кызгылтрак. Башы – зур һәм озынча. Күзләре – кара, шар кебек кабарынкы. Күкрәкләре – киң һәм зурлар. Су астында пыяла сарайда яши, имеш. Яхшы кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәттә, начар кешеләрне сөйми. Өлкәннәрне, бигрәк тә балаларны су кергәннәрендә, яисә су алырга төшкәч, суга батырып үтерә. Терлек-туарны, кош-кортны, эт һәм песи ишене су эчкән вакытында суга суырып ала. Г. Тукай сурәтләгәнчә, Су анасы алтын тарагын чәч тараган урынында онытып калдыручан икән. Әгәр дә кешеләргә ачуы килсә, корылык һәм зәхмәт юллап, аларны харап итә. Табул

(Тобул, Тубыл) татарларында Су анасы һәммә төрле Су пәриләренең, яман көчләрнең башлыгы, имеш. Күп якларда аны карчыклар кыяфәтендә, агарган озын чәчле дип тә күзаллаганнар. Аның төп атрибутларыннан дип яки алтын тарак, яки алтын чиләкләр санала. Әкият вакыйгалары Су анасының аларны онытып калдыруы, яисә урлатуы белән башланып китә.

Г. Тукай исә үз әкиятен *«Бер авыл малае авызыннан»* дип, аның теленнән сөйләнүче вакыйга итеп язган. Ул малай эссе җәй көнендә сәгать ярымлап бик озак су керә һәм, күңеленә курку төшеп, тиз генә йөгереп чыга да киенә башлый, шунда басмада Су анасын күреп ала. Ул чәчен тарап утыра. Эше беткәч, суга төшеп китә, юк була. Басмада онытып калдырган алтын тарагын бу малай урлап кача, артыннан куып килгән Су анасын этләр, куркытып, кире боралар. Малай таракны әнисенә кайтарып бирә, әмма төнлә Су анасы килә, тәрәзә шакып, таракны кайтаруын сорый. «Бая көндез алып качты углың – карак!» – дип белдерә. Таракны тышка ыргытып кына, аның бәласеннән котылалар. Әмма малайга бу вакыйга гомерлек сабак була. Г. Тукай аның сүзләрен болай дип китерә: «Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым, «Йә иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым». Димәк, бу малай һәммә әйбернең иясе булуына шулай инана, иясез һични юклыгын төшенә. Әсәрдә уздырылган төп фикер дә шушыннан гыйбарәт.

*Октябрь, 2005*

## Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗаты хакында Г. Сәгъди

Г. Исхакыйның әдәбият мәйданына килгән чорында татарда әдәби теле ике юнәлештә үсеш алырга өлгергән була. Бу мәсьәләне аерым өйрәнеп, 1926 елда басылып чыккан «Татар әдәбияты тарихы»нда галим Г. Сәгъди XX йөзгә кергәндә әдәби телебезнең үсешенә бәйле күзәтүләрен бирә, бу ике юнәлешне И. Гаспринский куәтләгән төрекчелек һәм К. Насыйри нигезләгән татарчылык хәрәкәтләре буларак аңлата[1]. Моның хикмәте шунда: XVIII гасыр

[1] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926. – Б. 104.

ахырында, беренче тапкыр мөфтине сайлау мәсьәләләре килеп тугач, татар милли буржуазиясе шактый активлашып ала. Шул чорда аның милли-мәдәни карашлары формалаша. Дини китапларның татарга аңлаешсыз булулары, аларны аңлау өчен озак еллар буена гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнү таләп ителүе, алга таба болай барырга ярамау, татар милли мәгарифен булдыру кирәклеге хакында Казан байлары еш әйтә башлыйлар. Тел мәсьәләсе актуальләшеп китә. XIX йөзнең икенче яртысында гарәп-фарсы телендәге китапларны милли телгә тәрҗемә итеп бастыру эше алга китә. Шәригать гыйлемнәрен халыкка үз телендә җиткерүгә зур игътибар бирелә. Шул чорда иҗат иткән әдипләребезнең, галимнәребезнең хезмәтләренә игътибар итсәк, аларның никадәр бу хәрәкәткәберегеп китүләрен ачык күзалларга була. Бу хәрәкәтнең иң актив эшлеклесе И. Гапринский уку-укыту эшен милли юнәлешкә кору концепциясен эшли. Аның нигезенә «җәдит методы»н (әлбәттә, шартлы рәвештә хәзерге фәнни әдәбиятта ул шулай атала, әмма чынлыкта «ысулы сөбүтия», ягъни «аваз методы» исеме белән мәшһүр укырга-язарга өйрәнү-өйрәтү методикасын) куя. И. Гаспринскийның төрекчелек хәрәкәтен матур әдәбиятта алып баручы әдипләр итеп Г. Сәгъди М. Акъегетне, З. Бигиевне, Р. Фәхретдиновны атый, бу исемлекнең шактый киң булуын да искәртә[1]. Ә К. Насыйри юлын алып баручы әдипләр исемендә Г. Ильяси, Ф. Халиди, Г. Камал, Ф. Кәрими, С. Максуди, Г. Исхакый, Я. Вәли, Ш. Шәһидуллин, Ш. Рәхмәтуллин телгә алыналар[2]. Шушы хәбәрләргә нигезләнеп, Г. Исхакыйның әдип буларак беренче адымнарыннан татарчалыкка өстенлек бирүен ачык билгели алабыз. «XX йөзгә кергәндә, бу юлда шушы төркемнең эше күзгә күренерлек бер хәл иде» дип ассызыклый Г. Сәгъди һәм бу әдәби телнең «гавәм теле» нигезендә үсә башлавын аңлата[3]. Монда, «гавәм теле» дигәнендә, гади сөйләм телеме, әллә гади халыкка аңлаешлы татар милли әдәби телеме күздә тотыла – галим боларга аңлатма бирми. Шулай да аңлашыла: сүз гади сөйләм теле хакында бара алмый, чөнки әдәби әсәрнең төп үзенчәлегенең берсе – аның әдәби телдә язылуы. Гади сөйләм телендә публицистик әсәрләр иҗат ителә, журналистика аның

[1] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Б. 104.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.

нигезендә үсә. Әмма «гади сөйләм теле» теге яки бу диалект теле дип аңларга ярамый. Гади сөйләм теле ул – текстның әдәби сурәтсез, тасвирлар урынына хәбәрлекләр бирүдән гыйбарәт тел. Алар икесе дә язма телгә карыйлар. «Сөйләм теле» дип аталуы гадәти, туры җөмләләрдән булуыннан килә.

1906 елда татар әдәбиятының үсешенә бәйле мәкаләләрендә Й. Акчура «Милләттәшләрем арасында ике чын әдип җитеште: берсе – хәссас, адәшле [артыгы белән хисле, утлы] милләтпәрвәр идеалист вә романтик Гаяз; икенчесе – гасаби [борчулы], тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист Фатих»[1]. Бу сүзләргә таянып, Г. Сәгъди аларга мондый уртак характеристика төзи: «Болар икесе дә мөгаллим, икесе дә җәдитчеләр булып, татар буржуазиясенең сулрак, радикальрәк булган яңа, яшь гыйльмиәдәби терәкләре – чын «яурупеист» юлбашчылары иде. Икесе ике яктан торып, буржуазиянең матди ярдәменә таянган хәлдә эшне кызулата башладылар»[2]. Болардан аңлашылганча, Г. Исхакый милли буржуазиянең революцион канаты вәкиле, европачыл фикер иясе, милли яңарыш вәкиле, мәгърифәтче-мөгаллим һәм юлбашчы буларак бәяләнә. Й. Акчураның фикерләренә килгәндә, Г. Исхакыйның ул иҗат портретын тулы һәм конкрет ача, аның иҗатына хас үзенчәлекләреннән хислелек һәм ялкынлы милләт сөючәнлекне төгәл күрсәтә. Аның бу бәяләмәсе белән килешми мөмкин түгел. Шул ук вакытта Г. Исхакыйның идеалист һәм романтик булуын да билгели. Димәк, Г. Исхакый әдәби геройларын күңел дөньялары үзгәрешләре белән бәйле сурәтли, вакыйгаларны да геройларының эчке дөньялары аша, күңел күзләре күргәнчә тасвирлаучы әдип буларак бәяләнә.

Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗатын Г. Сәгъди 1900 елда басылып чыккан «Теләнче кыз» хикәясенә бәйләп икегә бүлә. Аның беренчесе «зәгыйфь, өйрәнчек һәм телендә мишәр вә госман йогынтысы көчле» әсәрләр тәшкил итүен күрсәтә. Аларга «җәдитчә, яңа мәктәпләрдә укытуга кызыктыру», «ризалар [Р. Фәхретдинов кебек әдипләр] юлынча әдәбиятта рационализм агымының бер тамчысы» буларак бәя бирә[3], Гани бай Хөсәеневнең мактавын искәртә.

[1] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Б. 122.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук. – Б. 123.

Җәдитче, Оренбургта «Хөсәения» җәдит мәдрәсәсен оештыручы һәм аны югары уку йорты дәрәҗәсенә җиткерү өчен байлыгын да кызганмаган Гани Хөсәенев кебек кешенең Г. Исхакыйга беренче әсәреннән башлап фатиха бирүе олы иҗтимагый резонанс тудырган, билгеле.

Беренче әсәрләреннән әдип төп игътибарны шәхес мәсьәләсенә бирә. Аны кешеләрнең бәхете күбрәк кызыксындыра. Әдәби герой омтылышларын ул иҗтимагый яссылыкка әдәби сурәт аша бирми, әлегә турыдан-туры, сүз буларак әйттерү белән чикләнә. Бу аның әлегә әсәрләрне схематик планда коруыннан килә. Беренче әсәренең язылуы һәм бастырылу тарихын соңыннан исенә алып, аны бер-ике көн эчендә язып бетерүен, аннары укып та тормастан китапчы бертуган Кәримовларга илтүен, аны сатып калдыруын, бу гамәле белән ничә көннәр очынып йөрүләрен яза[1].

Г. Исхакый, язучы буларак, укучының мәхәббәтен «Кәләпүшче кыз» хикәясе белән яулый. «Әдәби агым ягыннан әсәр – сентиментализмның татар әдәбиятында беренче ачык үрнәге, – дип билгеләп уза Г. Сәгъди. – Ләкин фикерчелек-рационализмнан аерылып бетмәгән бер рәвештәгесе», – ди ул[2]. Бусы сүзләре дә «Кәләпүшче кыз»ны Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗатына нисбәтле бәяләргә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта Г. Сәгъдинең бу сүзләреннән әдипнең фикерчелектән сентиментализмга таба авышуын публицистикадан матур әдәбиятка күчеш башлавы буларак та бәяләнү дип аңларга кирәк. Димәк, фикер бирү публицистик әсәрләргә хас булса, хисси тасвирлар әдәби әсәрнең тууында төп рольне башкаралар. Әдәбиятта фикер бирү мәгънәле тасвирлар белән ирешелә. Г. Исхакый да нәкъ шуны эшли. «Кәләпүшче кыз» белән ул башлангыч иҗат чорының икенче баскычына күчә. Әмма әлегә фикер бирүдән котылып җитә алмый. Г. Сәгъдинең «Гаязның соңыннан басылган бөтен хикәя-романнары, пьесалары аның киң шашкын котырык хыяллы һәм тасвирының күренешле (картиналы), җиңел алымлы булуын күрсәтәләр»[3] дигәннәре аерым бер

[1] *Сәхәпов Ә.* Г. Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты: монография. – Казан: Мирас, 1997. – Б. 54–55.

[2] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Б. 125.

[3] Шунда ук. – Б. 124.

иҗат дәверенә генә түгел, бәлки «Кәләпүшче кыз»га һәм аннан соң язылган һәммә әсәрләренә карый, тулы, дөрес бәя булып тора.

Бу хикәя Р. Фәхретдиновның «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрен хәтерләтә. Монда татар кибетче-приказчикларының кызлар белән уйнарга яратулары, аларның булышчылары буларак карчыкларның арадашчылык итүләре хис-кичерешләр стихиясе эчендә тасвир ителә. Хикәягә сүз башында Г. Исхакый Камәр кебек юлдан язган кызларның язмышлары нәрсә белән бетәчәген күрсәтергә теләвен аңлатып язып уза[1]. Хикәянең ахыры, Р. Фәхретдиновныкыннан аермалы буларак, герой һәлакәте белән тәмамлана. Шәхси язмыш һәм бәхет турында мәгънәви яктан уйлану бу чорда Г. Исхакый иҗатының төп көченә әверелә. «Өч хатын белән тормыш» драмасы – шундый әсәрләреннән берсе. Ул 1900 елда дөнья күрә, ахырдан да татар театры тарафыннан уйнала, репертуарында төп спектакльләреннән берсе санала. Г. Сәгъди бу драманы толстойчылыкның татар әдәбиятында чагылышы буларак бәяли, надан Кәрим байның энесе Ризаны шул идеяләрне әсәрдә турыдан-туры сөйләүче персонаж буларак бәяли[2].

Г. Исхакыйның башлангыч иҗат чорына Г. Сәгъди «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен һәм «Теләнче кыз» роман-трилогиясен дә кертә[3]. Әдип бу әсәрләре белән шәхси әдәп һәм бөек әхлак мәсьәләләреннән иҗтимагый проблемаларга кадәр үсеш кичерә, гомумкешелеккә һәм милли язмышка бәйле әдәби-мәгънәви эзләнүләрен башлый. Бу аның язучы-мөгаллим булудан әдиплеккә таба кыю адымы буларак бәяләнергә тиешле.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен тикшереп, аның жанры табигатен билгеләү юлында эзләнүләр алып барып, Ә. Сәхапов аны, И. Нуруллин кебек үк, «фантастик-публицистик повесть» дип атый[4]. Галимә Ч.М. Гыйләҗева «Инкыйраз» турында Габдрахман Сәгъди» мәкаләсендә шактый кызыклы һәм фәнни әһәмияткә ия

---

[1] *Исхакый Г.* Әсәрләр: унбиш томда. – Т. I. Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – Б. 51.

[2] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Б. 127.

[3] Шунда ук. – Б. 130–133.

[4] *Сәхәпов М.Җ.* Татарны инкыйраздан саклап калу өчен көрәштә // Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: Әдипнең 120-еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2000. – Б. 50–54.

күзәтүләр уздыра һәм Г. Баттал кебек үк Г. Сәгъдинең дә әсәрне «хитаби тәэлиф» буларак атавына туктала, мондый фикерне алга сөрә: «Структурасы ягыннан караганда, әсәрнең төзелеше чыннан да хөтбә рамкаларына туры килүе күзәтелә»[1].

Хөтбә мәсьләсенә килгәндә, ул публицистик жанр, әлбәттә. Аның эмоциональ характерда булуын, моның өчен әдәби стильгә мөрәҗәгать итүен, әдәбият үсешенә йогынты ясавын У.А. Гафарова 1989 елда кандидатлык диссертациясе буларак яклаган «Арабское ораторское искусство (Хутба) VI – середины VIII в.» хезмәтендә махсус тикшергән, аның киң таралыш алган сөйләм чәчмә жанр буларак формалашуын, матур әдәбиятта да файдалана башлавын ачыклаган[2]. Әмма хөтбәнең аерым, матур әдәбият жанры буларак түгел, бәлки публицистик әдәбият жанры булуын дөрес аңларга тиешбез. Әдәбиятыбыз галимнәренең фикерләренә таянсак, Г. Исхакый аны әдәби жанрга әверелдерүен ассызыклый алабыз. Г. Сәгъдинең «хитабы тәэлиф» дигән, Г. Батталдан алынган терминына килсәк, аны «нотык тупланмасы» буларак тәрҗемә итәргә тиешбез. Ә моңа карап әсәрнең жанр табигате үзгәрми. Димәк, аның публицистик формада язылганлыгы раслана. Киләчәктә булачак вакыйгаларны тасвир итүе белән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» хыялый күзаллауга корылганлыгын, ягъни фантастика булуын белдерә. Автор үзе әсәрен «хыялый роман» дип атый[3], Г. Сәгъди әсәрнең, күләменә карап – романга, формасыннан чыгып хикәягә нисбәт итәргә, стиле белән әдәби хөтбә икәнлеген ачыклый[4]. Бу фактлар исә «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның фантастик-публицистик повесть булуын тагын бер кат раслыйлар. Димәк, аның жанрын билгеләгәндә, И. Нуруллин да, Ә. Сәхәпов та дөрес позициядә торганнар. Әмма әсәр авторының ихтыярын да исәпкә алырга, ягъни «хыялый роман» булуын исәпкә алырга тиешбез.

---

[1] *Гыйләҗева Ч.М.* «Инкыйраз» турында Габдрахман Сәгъди // Гаяз Исхакый иҗаты: Хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2008). – Казан, 2008. – Б. 109.

[2] [Электрон ресурс]. URL: http://cheloveknauka.com/arabckoe-oratorckoe-iskusstvo-hutba-yi-serediny-yiii-vv (мөрәҗәгать итү датасы: 28.03.2018.).

[3] *Гыйләҗева Ч.М.* «Инкыйраз» турында Габдрахман Сәгъди. – Б. 109.

[4] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Б. 128.

Әдәбиятлар үсешен тикшергәндә, ихтыярсыз шундый күзәтүгә килергә мәҗбүр булдык: беренчедән, ничек кенә булмасын, әмма рус-европа мәдәниятен үзләштерүгә таба борылганда, милләтебезнең шул чор зыялылары, асылда, лубок әдәбияты саналган китапларга тартылганнар, әдипләрнең үз әсәрләрен укудан бигрәк, «халык китаплары» буларак басылып чыккан, эчтәлек сөйләп чыгуга корылган вариантларын укыганнар булса кирәк, икенчедән, дөньякүләм танылган рус-европа әдипләренең әсәрләрен шул форматта гына булганнар дип күз алларына китергәннәр төсле, өченчедән, менә шуңа күрә дә аларның романнары сирәк очракта гына йөз сәхифәдән артып киткән. XIX йөз ахырында, алга таба XX гасыр башларында язылган «милли роман»нарыбызның күләм ягыннан кечкенә булуларын башкача аңлап-аңлатып бетереп булмый. Аннары бу фикерне ул чордагы тәрҗемәләр дә раслыйлар. Алар, чыннан да, «халык китабы» форматында эшләнелгәннәр һәм зур-зур чәчмә әсәрләрнең эчтәлекләрен кыскача сөйләп чыгуга корылганнар.

## Мәхтүмколый шигъриятендә афористик фикерләү алымы үзенчәлекләре

1

Афористик фикерләү урта гасырлар төрки әдәбиятларының төп, асыл үзенчәлекләреннән берсе буларак шактый үсеш алып, яңа гасырлар өчен дә әдәбиятта мәгънәне уңышлы тасвирлау тармагы сыйфатында яшәп калды. Кистереп, хәтта өздереп фикерне төгәл, ачык, үтемле итеп белдерү шигырьдә гражданлык пафосын алга чыгарырга мөмкинлек бирә. Мәхтүмколый Фиракый шигърияттә менә шушындый афористик фикерләмәләр белән эш итүче әдип буларак җитеште һәм XVIII йөз төрки әдипләре арасында шушы ягы белән ачык аерылып тора. Аның мәхәббәт лирикасы да афористик фикер бирә алуы белән шагыйрьне гражданин итеп күрсәтте. Мәхәббәт лирикасы аның рухының сафлыгын, хисләренең камиллеген тәсдыйк итте. Сөю-сәгадәт шигырьләре кешедә асыл сыйфатларны үстерү көченә ия. Мәхтүмколый үзенең

афористик фикерләве белән мәхәббәт лирикасын тагын да үстереп, яңа рухта, яңа юнәлештә көчәйтеп җибәрде. Аның тәэсири вә тәрбияви көче тагын да артты. Югыйсә шагыйрь бары тик үз хисләре, үз тойгылары хакында гына сөйлидер сыман иде. Әмма ул кешелекнең рухи сафлыгын, шуның белән өстенлеген тәкрарлый. Шушы ягы белән Мәхтүмколый әсәрләре, һәр заманда, һәр чорда яңача булып, үзенчәлекле сыйфатта кабул ителделәр. XX йөз башы символист шагыйрь Дәрдемәнднең һәм аның юлында барган башка татар модернист шагыйрьләре өчен, ягъни Ф. Ибраһимов, Г. Сөнгати, Н. Исәнбәт, Г. Сәгъди-Таңгатаров һәм башкаларга аның иҗаты рухи яктан якын иде. Шуның өчен дә «Шура» журналы һәм «Әдәбият мәҗмугасы» исеме белән чыккан аның кушымтасы шигъри җыентыкларда «Фиракый»ның мәхәббәт шигырьләре белән очрашабыз[1]. Мәхтүмколый иҗаты барлык тирәнлегендә һәм фикри бөеклегендә татар укучысы тарафыннан сокланып, нәкъ менә Дәрдемәнд каләме тәэсирендә тәрбияләнүенә бәйле кабул ителде дә. Афористик фикерләү шигъри символик мәгънә тирәнлеген бирү өчен иң кулай алым икәнлеген татар шагыйрьләре Фиракый иҗатыннан алдылар дигәнебездә һичбер хата күрмибез. Ул гына да түгел, татар шигырендә мондый формада афористик фикерләүнең соңгы, ягъни безнең гасырдагы яңа әдәпләребездә, хәтта үзара капма-каршы типтагылар булмасыннар, Р. Харис һәм М. Әгъләмов шигъриятендә дә бер сабакның икегә тармакланып китүе кебек үзенчәлектә үстерелеше белән очраша алабыз.

Татар укучысы Тукай-Дәрдемәнд чорында Мәхтүмколыйны Фиракый буларак кына белә иде, алардан соң бире дәвердә ул аны Мәхтүмколый дип таныды, Фиракый белән Мәхтүмколыйны бер үк кеше, бер үк шагыйрь сыйфатында белмәде. Без Фиракыйны Дәрдемәнднең үзе буларак та кабул итәргә әзер идек[2]. Моңа шигъри афористик алымны символик мәгънәгә хезмәт итүче формага әверелдерә алуы этәрми калмады. Әмма әсәрләрендәге ком чүлләре, Хива кызлары, дөя күзләре һәм башка төрле төрекмән даласы стихиясе белән хозурландырылган сурәтләр күңелгә икеләнүләр дә салмады түгел. Бары Фиракый белән Мәхтүмколыйның икесе бер

---

[1] *Яхин Ф.З.* Дәрдемәнднең билгесез тәхәллүсе // Идел. – 1996. – № 11. – Б. 41.
[2] Шунда ук. – Б. 42.

әдип булуын кабул итү авыр, чөнки ул XX йөз башы татар шигъри фикерләмәләрендә ят түгел иде. Әгәр дә Фиракый Дәрдемәнд түгел икән, 1911 елда Гурьев якларына, аннан ары Төрекмән сахраларында яшәргә сөрелгән татар шагыйре Ф. Ибраһимовтыр дигән фикер дә тумый калмады. Ярый әле боларны расларлык дәлилләр табылмады.

Фиракыйның XVIII йөз төрекмән шагыйре Мәхтүмколый булуы бүгенге көндә беребездә дә шик тудырмый. Дөньяга караштa күңелләребезне үзгәртәчәк шагыйрьнең кайда һәм кайсы халыкта, нинди дәвердә туасын белмибез дә. Хәтта гасырлар үтеп кенә моны таныган чакларыбыз була. Мәхтүмколый Фиракый да шундый әдипләрдән иде. Аның иҗатына хас шигъри киңлекләр һәм мәгънә тирәнлекләре бүгенге көнебездә дә тәмам ачыкланып җитмәгән. Бу хәл аның иҗат мирасының кешелек дөньясы өчен аерым әһәмияткә ия булуын ачык сөйли торган күренешләрдән берсе. Моны бәхәс итү мөмкин түгел. Үз милли әдәбиятының бөек шагыйрьләре иҗаты тәрбиясендә үскән рәхмәтле татар укучысының саф рухи дөньясына Мәхтүмколый шигырьләре берничек тә ят, чит була алмаганлыгын бу фактлар ачык дәлилләп торалар.

2

Мәхтүмколый Фиракый афористик фикерләмәләрендә күңеле дөрес кешене үрнәк буларак сурәтли. Моның өчен ул акыл һәм гыйлемне өстен чыгара. Аның фикерләмәләрендә акыл белән ахмаклык даими каршы куелалар, галим белән надан янәшә торалар:

Ахмак өзүн акыл билен дең эйләр,
Бер иш тутар, соңрасындан җең эйләр,
Зехиниң кәйидер, аклың тең эйләр,
Дидигиң эйлемен, нашы яндырыр[1].

Мәхтүмколый ахмак кешенең акыллы кешегә үзен тиң куюын искәртә һәм бер эшне башлап та аны ахырына кадәр җиткерми ташлауны шулай ук ахмаклык бәласе буларак бәяли. Аның ачык-

[1] Мәкаләдә Мәхтүмколый шигырьләре төрекмән телендә басылып чыккан «Магтымгулының парасатлы сөзлери / Чапа тайарлан *Мәти Көсәев, Аман Кекилов* редакциясы билен [Түркменистан ССР Ылымнар Академиясы Магтымгулы адындагы эдебият институты]. – Ашгабат: Түркменистан дөвлет нешрияты, 1959. – 51 б.» китабыннан алып, төрекмән телендә биреләләр.

лавынча, кешенең акылы белән зиһене үзара тиң киләләр. Хәтере яхшының акылы да камил дигән сүзе бу. Акыллы кешегә әйткән сүзең аңа берничек тәэсир итми, чөнки акыл билгеләре сүзләреңне яндырып юк итәләр. Бусы – афористик фикерләмәнең шигъри күзаллау кысасында бирелү күренеше.

Шагыйрьнең шушы рәвешле тирән мәгънәләрдә фикер бирүләре тормышны, аны тудыручы кешеләрне дөрес бәяләвеннән килә. Төрекмән галиме Аман Кекилов моның төп сәбәбен Мәхтүмколыйның халык җаны һәм аңы, ягъни шуларның чагылышы саналган фольклор белән берегүеннән күргән һәм ул, фикерен аңлатып, болай дигән: «Халкың җаны хем аңы хасап эдилйән фольклор бейик шахырың дөредиҗилик чешмелериндеп бири болупдыр»[1].

Шагыйрьнең күңеле саф, ул үзен башкалардан акыллыга да, галимгә дә санамый. Аның күңеле дөньяны-галәмне гизәргә, ягъни һәммә ни бар – барчасын танып белергә, аңларга, төшенергә тели. Әмма канаты юк, оча да белми, нишләсен? Укыйм, барча сүзләрне таныйм, ди ул, әмма ул сүзләрнең тулы мәгънәсен белә алмавына зар итә.

Көңлүм истәр гезсем дүнйә-әлеми,
Ганатым ёк, уча билмен, нейләйин!
Окыр мен, гөрер мен барча келамы,
Манысыны сача билмен, нейләйин!

Аның мондый афористик шигъри фикерләмәләренең башы суфи шагыйрьләр шигъриятенә хас хис-тойгыларга барып тоташа. Бигрәк тә Г. Хәйамның робагыйларындагы шагыйранә фәлсәфәләрне хәтерләтәләр. Мәхтүмколый әсәрендә дә сүз хакыйкатьнең танылып беленүендә чикләре булмау хакында бара. Шуңа күрә дә шагыйрь алга таба болай ди:

Махтымгулы, бу дүнйәниң намысын
Йыгып, дүйрүп, еле бердим хамысын,
Пикир дерясына аклым гәмисин
Батырмышам, чыга билмен, нейләин!

Лирик герое үзен бу дөньяны кулына җыеп алуын, шулай тотуын һәм минминлек дәрьясына акылы сагышын батыруын, шул

[1] *Кекилов А.* Сөзбашы // Магтымгулының парасатлы сөзлери. – Б. 7.

халәтеннән чыга алмавын белдерә. Моны, әлбәттә, суфи шагыйрьләргә хас рәвештә үз-үзеңне «камчылау» дип бүгенге әдәбиятчылар гадәтенчә аңлатуы җиңелрәк. Әмма шигырьнең алдагы строфасын исебезгә алсак, анда сүзләрне күреп-укып та төшенә алмавыннан зарлануына да игътибар итсәк, мәгънәләр башка төрлерәк төс алганлыгын төшенербез. Кулында бу дөньяның барлык мөмкинлекләре булып та алардан файдалана алмавыннан зар итүне сурәтли шагыйрь. Менә шуңа күрә дә кешене Мәхтүмколый, бу очракта лирик герой буларак үзен, кемлек хәсрәтендә, ягъни «пикир дерясында» батып калучы дип аңлата. Әгәр дә аның фикерләмәсен дедуктив юл белән чишсәк, шигырьдәге афористик фикерләмәдән кеше минминлек, кемлек хәсрәтен чикмәсә, дөньяның үз кулында булуын белер иде дигән мәгънә килеп чыга. Бу – Мәхтүмколыйның фикер бирү алымы. Ул шигырендә гомуми бер фикер чыгара һәм аны кабат, зиһендә яңартып, дедуктив юл белән фикерләмәне чишәргә укучының күңеленә этәргеч бирә белә. Шул рәвешле, Мәхтүмколыйча шигъри афористик фикерләмә туа. Мондый юл аның шигырьдә биргән мәгънәләрен тирәнрәк аңлауга мөмкинлек ача.

3

Мәхтүмколыйның фикердә таяну ноктасыннан икенчесе (әлбәттә, акылдан һәм гыйлемнән кала) – мәхәббәт, гыйшык. Без боларны акыл, гыйлем, мәхәббәт культлары димәс идек. Гомумән дә Шәрык әдәбиятларына бәйле фәнни тикшеренүләрдә *культ* сүзен куллану әдәби рухларына хилафлык итә, табигатьләрен бозып аңлауга китерә. Фикердә таяну ноктасы Шәрыкта культ дәрәҗәсенә җиткерелми. Моны яхшы төшенеп эш итәргә тиешбез.

Мәхәббәтне Мәхтүмколый «Кылзум суында йөзү» буларак белдерә. Бу мифологик дәрья – урта гасырлар Шәрык әдәбиятларының төп символик образ-мәгънәләреннән берсе. Мәхәббәт дәрьясы буларак аны аңлау һәм аңлату исә Мәхтүмколый шигъриятендә яңа бер мәгънәви төс ала. Ул аны сөю-мәхәббәт белән яшәү урыны буларак та күзаллый, япан-кыр итеп күзалларга да әзер:

Гулзумы гыр санып кырк ёл гечер мен,
Эгер ки мейил этсе яр бизиң сари;

Гадам ерне ганат баглап учар мен,
Дийсе дилбер: «Ашык, йөр бизиң сары».

Ул монда кырык ел дәвамында мәхәббәт тотуы хакында сүз алып бармый, әлбәттә. Аның «Кырк ёл гечер мен» дигәнен «кырык ел буена да үтәргә әзермен» дип аңларга кирәк. Чөнки шагыйрь: «Әгәр дә сөйгән яр безнең тарафка килергә теләсә», – ди. Димәк, сөйгәне аны сайласа, ул аның янына Кылзум суын япан-кыр (тигез дала) санап, кырык ел буена (ничәмә-ничә еллар, ягъни бик еракта булса да) кичеп чыгарга әзер икән.

Саф хиснең шушы рәвешле бөек итеп сурәтләнүе күңелдә бу шигырьгә карата соклану тойгысы тудыра. Лирик герой хәтта «гадам ерне», ягъни утлы тәмугны да «канат бәйләп очып узарга» әзер, бары тик сөеклесе аңа: «Ашык, безгә таба йөр!» – дисен.

Бу шигырьнең мәгънәләре шактый тирән. Югыйсә бары тик кыйтга формасында, лирик геройның мәхәббәт белән бәйле хистойгыларын суфилар күзаллавынча тасвирлап язылган гадәти әсәр кебек. Әмма аңарда сурәтләнелгән идея кешедә күңел сафлыгын тәрбияләү көченә ия. Шуның өчен андый фикерләмәнең дөньяви әһәмияте дә югары.

Махтымгулы, межалым ёк сөйләйин,
Достларга дердимни беян эйләйин,
Эй яранлар, йыгламаян нейләйин?
Ышк мени яндырып, якып барадыр... –

ди ул, дәрте хакында дусларына сөйләми чамасы калмавын белдереп. Әмма шунда ук: «Еламыйча нишлим», – дип тә белдереп куя. Аны мәхәббәт «яндырып, ягып бара» икән. Бер яктан, лирик геройны шагыйрь мәхәббәтсез яши алмаучы итеп сурәтли, икенче яктан, бу мәхәббәтнең аны яндырып юк итүен яза. Монда укучы күңелендә урынлы сорау туа: лирик герой нинди мәгънәдә юк була бара соң?

Шул рәвешле, дедуктив юл белән фикерләүгә этәрелгән күңел шигырьдән җавабын да таба: әлбәттә, сафлану, үзгәрү мәгънәсендә юк була бару икән ул!

* * *

Кысматын Хак билен ризкын азламаз,
Сөз биленлер билен сөзүн гизлемез,

Көңүл җоша гелмез, дил хем сөзлемез,
Хер йүрекде ышкдан гөз хем болмаса.

Дүнйә сөзи меңзәр дузсуз тагама,
Сөз ичинде гелин-гыз хем болмаса.

Юм гөзүңи, гысып гезгин дишиңни,
Яза етсең, унутмагын гышыңны.

Магтымгулы, хыял дүшүп өзүме,
Көп томаша гелир, гечер гөзүме,
Эшиденлер айп этмесин сөзүме,
Иллер кимин сөзүм уз хем болмаса.

Шагыйрь дөньяда яшәү серләрен аңлы рәвештә төшенеп иҗат итүен бу әсәрендә тагын да ачык белдерә. Сүзе кабул булмаса, сөйләгәннәрен ишеткән кешеләр гаепкә алмасыннар дип тә үтенә.

Мәхтүмколый иҗатының асыл өлеше халкының язмышы өчен кайгыру хисләре белән сугарылган. Төрекмән илен ул «гөл гонҗәсе, кара күзем карасы» дип атый, аның Хазар (Каспий) диңгезе белән Җейхун (Әму-дәрья) елгасы арасындагы чүлдә булуын да төгәл белдереп яза. Халкының тормышы җиңел түгеллеген дә күрә һәм моны «Кара таудан төрекмән елгасы ага» дигән афористик формадагы символик мәгънәле шигъри фикерләмә эчендә бирә. Ә бер кыйтгасында ул болай ди:

Пырагы йүз тутар түркмен илине,
Душман гол урмасын гызыл гүлүне.

Аның иҗат мирасында яшьлек тәэсире белән язылган, дөньяга караштa яшьләрчәлек хисе белән сугарылган әсәрләре дә очрый. Ул аларда егетлек күрсәтә, хәтта күңеле, аңы, йөрәге белән таянган дини тәгълиматка каршы да берничә сүз әйтә. Мәсәлән, шундый кыйтгаларыннан берсе:

Моллалар ахырет сөзүн сөйләрлер,
«Мүңкүр олма, гелҗек ишдир, эйләрлер»,
Ким билер ки ахыретде нейләрлер, –
Ийип, ичип, минип, гучуп өт ягшы.

Әмма Мәхтүмколыйга мондый характерда фикер йөртү, асылда, хас түгел. Ул боларны вакытлы бер тәэсир, тормышы авырлыклары тәэсирендә күңеле таркалып алу аркасында язган булса кирәк.

Аларда дәһрилеккә төшүен түгел, бәлки дөньядан ваз кичү хисен тоярга була. Югыйсә муллалар нәсыйхәтенә каршы егетлекне ул каршы куймас иде. Икенче бер касыйдәсендә моның шулай булуы ачык күренә:

Магтымгулы, гарыпларың гөз яшы
Даглары яндырар, эридер дашы...
Пакыра җебр эден залымың иши
Розы-магшар диванында беллидир.

Мәхтүмколый Фиракый үзен Шәрыкның бөек шагыйрьләре арасында дөрес күрә. Бу хакта ул болай ди:

Әбу Сәгыт, Омар Хайям, Хемеданы,
Фердөвси, Нызамы, Хафыз перваны,
Җелаледдин киби, Җамы элнаны,
Аларның янында менем сан болсам.

Шушы манерада үз таланты дәрәҗәсен ачык күзаллау безнең татар шагыйрьләреннән Г. Тукайда да бар. Димәк, мондый хис-тойгы аңарда Шәрык йогынтысыннан килә икән дия алабыз. Бу афористик фикерләмәләр белән эш итү осталыгына да бәйле.

Мәхтүмколый Фиракый иҗат мирасының тарихи-мәдәни-әдәби әһәмиятен ачык күз алдына китерү өчен аның афористик фикер алымнарын иҗатта уңышлы файдалануына бәйле аңлату – дөрес юл. Бездә әдәби әсәр тормышны чагылдыра дигән фикерне кабатларга яраталар. Әмма аның идеяне, фикерне чагылдыруын, ягъни төрле алымнарда сурәтләп бирүен оныталар. Ул гүяки идеалистик караш кебек күзаллана. Тормыш – әдипнең өйрәнү объекты. Ул аны бәяли, аңлата, аның үсеш-үзгәреш үзенчәлекләрен ача. Әмма чын әдип моның белән генә калмый. Тормышның үсеш-үзгәрешендә дөрес юнәлештә китүендә ул, халыкның рухи дөньясына әдәби фикерләре белән тәэсир итеп, һичшиксез төп эшне башкара. Ничек кенә булмасын, бүгенге мәдәни үсешебезнең бинасын әдипләребезнең әсәрләре хасил итә. Мәхтүмколый Фиракый иҗаты да төрки дөнья өчен һәм гомумән дә гомумкешелеккә шушы ягы белән кадерле. Аның шигырьдә афористик фикер алымнары белән эш итеп әдәбият дөньясын баетуы яңа мәдәни күренешләргә, әдәби агымнарга юл ачты. Моны ачык аңларга татар шигърияте үсеше үзенчәлекләре дә мөмкинлек бирә.

## Г. Кандалый әсәрләрендә дин әһелләре образлары: әдәби-тарихи мәсьәләләр кысасында

**Гомуми караш.** Габделҗәббар Кандалыйның (1797–1860) иҗат мирасына бәйле уртак бер фикри бәяләмә электән яши. Ул да булса, академик М. Госманов сүзләре белән әйтсәк, «аның әдәбиятыбыз үсешенә керткән бәхәссез яңалыгын ихлас күңелдән тәкъдир итә килү»дән гыйбарәт[1]. Бу фикернең чыннан да дөрес, хакыйкать булуын раслау өчен, галим монографик пландагы мәкаләсен Г. Кандалыйның 1988 елгы шигырьләр җыентыгында тәкъдим итте. Шагыйрьнең әсәрләрен туплау кебек гаҗәеп катлаулы эш белән беррәттән, М. Госмановның төп анализлары, әдәби-тарихи мәсьәләләрне дә чишүе аерым мактауга лаеклы. Мәкаләсендә ул әдәбият галимнәренең фикерләренә бәйле әле бәхәсләр кузгата, әле аларның дөреслеген раслый, эзләнә, төшендереп яза. Капиталь хезмәт.

Г. Кандалыйның иҗат мирасы XIX йөздән бирле татар әдәбиятын өйрәнүче галимнәр тарафыннан бәяләнеп киленә. 1869 елда Салихҗан Күкләшев «Татарская хретоматия» китабын Казанда бастырып чыгара һәм анда шагыйрь иҗатына берникадәр урын бирә[2]. Әмма шагыйрьнең иҗатына төп игътибарны юнәлткән галим Каюм Насыйри булды һәм ул «Кырык бакча»[3], «Фәвакиһелҗөләса (фил-әдәбият)»[4] китапларында Г. Кандалыйның әсәрләренә шактый урын бирде. Тормыш юлын өйрәнү һәм иҗатын бәяләү эшен XX йөзнең 20–30 нчы елларында К. Иртуган[5], Бәхтиев Исхак[6], Г. Ибраһимов[7] мәкаләләрендә башкарылдылар, Г. Рәхим

---

[1] *Госманов М.* Габделҗәббар Кандалый: Бер гомердә ике чор // Кандалый Габделҗәббар. Шигырьләр һәм поэмалар / төз., текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, кереше сүз авт. М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б. 5.

[2] *Кукляшев С.* Татарская хрестоматия / Диване хикәяте татар. – Казань, 1859. – Б. 109–110.

[3] *Насыйри К.* Кырык бакча. Казан, 1880. – Б. 47–56.

[4] *Насыйри К.* Фәвакиһел-җөләса (фил-әдәбият). – Казан, 1884. – Б. 556–583.

[5] *Иртуган К.* Шагыйрь Габделҗәббар Кандалыйның кыскача тәрҗемәи хәле һәм шәхси хәяты // Безнең юл. – 1927. – № 8. – Б. 30–32.

[6] *Бәхтиев И.* Шагыйрь Габделҗәббар Кандалый турында // Яңалиф. – 1929. – № 13. – Б. 13–14.

[7] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 256, 338–339, 369–370, 387, 463.

һәм Г. Гобәйдуллин аңа үзләренең «Татар әдәбияты тарихы» китабында төп урыннарның берсен бирделәр[1], 1927 елда шагыйрь хакында Г. Сәгъди «Кандалый хакында» мәкаләсе белән чыгыш ясады[2]. Аларга кадәр әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче Җәмал Вәлиди 1912 елда Оренбургта басылып чыккан «Татар әдәбияты барышы» китабында[3] әдипнең иҗат мирасын бәяләгән, Г. Тукай «Исемдә калганнар» истәлегендә тугыз яшьлек малай чагы икәнлеген искәртеп, Г. Кандалый шигырьләрен укуына бәйле, «бик яратып укыйм һәм аңларга тырышам», аларның тәэсирендә «хатыннардан көлә идем»[4] дип язып узган иделәр. Һәм, гомумән, әдәбият тарихын өйрәнүче галимнәр тарафыннан әтрафлы яктыртылган Г. Кандалый иҗаты хакында нинди дә булса яңа сүз әйтү мөмкин дә түгел сыман. Мәктәп һәм вуз дәреслекләренә кертелгән бу иҗатны күз алдына китермәгән кеше юктыр. Аның «Мулла белән абыстай», «Сәхипҗамал» әсәрләрен кайсы татар белми дә исенә алмый? XIX йөзнең башында шушындый бөек татар шагыйренең яшәгәне һәм иҗаты белән халкыбызны яңача уйлый белергә, урта гасырлардан килгән дини-клерикаль карашлардан аерылырга юл күрсәтүе аерым игътибарга һәм олылауга лаеклы. Г. Кандалыйның әдәбият һәм фикер үсеше – тарихыбызның чыннан да зур мәртәбәсе.

Аны, иң тәүдә, «бунтарь», «гыйсъянчы», диләр. Һәм ул чыннан да шундый. Г. Кандалый, хәтта күп кенә бунтарь шагыйрьләрдән аермалы буларак, хистә, фикердә бөтенләй башка. Аның лирик героенда тынгысыз, буйсынмаучы, горур йөрәк. Әмма ул – саф хисләргә ия йөрәк.

Дөрес, Г. Кандалый «бозык хисләр иясе», эротик шагыйрь буларак та билгеле. Ул интим күренешләрне шигъриятендә каләм очына да, куе сурәткә дә алмый калдырмый. Боларны ул мыскыллау, көлке-сарказм өчен дә куллана. Үтә нечкә хисләргә бай иҗатка андый тупаслык килешеп бетмидер сыман. Әмма укучыны шушылай

[1] *Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы: феодализм дәвере. – Икенче басма. – Казан, 1925. – Б. 296–313.

[2] *Сәгъди Г.* Кандалый турында // Безнең юл. – 1927. – № 9. – Б. 29.

[3] *Вәлиди Җ.* Татар әдәбияты барышы. – Оренбург, 1912. – Б. 93–98.

[4] *Тукай* Г. Әсәрләр: биш томда. – Т. V. Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 25.

хәйран итә алуы, икенче яктан, көчле бер әдәби алым да түгелме? Тик хисләрнең нечкәлеге әдәбилектә нечкәлек түгел әле ул, анысын да аңларга, бәяләргә тиешбез.

Г. Кандалыйны иҗатындагы шушы үзенчәлекләре өчен һаман да акларга тырышабыз. Ә мондый очракта аның башкача да язарга мөмкин булын исәпкә алмыйбыз. Әгәр дә ул үтә конкрет, хисси-җенси тойгы-кичерешләр белән бәйле, мәсәлән: «Чү сәнә, абзый, чү сәнә, / Кысыбрак яхшы сөйсәнә, // Сөйгәчтин – күңлем үсә лә, – / Дәйүб уйнар күшки кызлар» («Мәгъшукнамә»)[1] кебек шигъри юллар урынына, искечә суфийана хис-тойгылар тулы әсәрләр иҗат итсә, шигъриятенең сафлыгы белән без аны һәммә шагыйрьләргә өлге итәр идек.

Дөресе шул: Г. Кандалыйны нечкә әдәбиятның саф өлгесе дип санарга хакыбыз юк. Аның мәртәбәсе башка якта, иҗаты әдәби кысаларны ваткан, аңардан бик күпкә читкә чыгып киткән. Шушы сәбәпле хәтта диндарлыгы да юк кебек аңлашыла. Г. Кандалый шигырьләрендә «мужикчалык», «телле авылчалык», әйтергә кирәк, «дөньяви диваналык» күп. Бу – үртәп-үртәшеп чарланган күңелнең «егетлек» итүе. Шушы үзенчәлеге Г. Кандалыйны нечкә әдәбият вәкиле буларак күзалларга мөмкинлек бирми. Әмма хисләре кайвакытта шулкадәр нечкәрә, икенче урында күңел кыллары авыр аһәңнәр белән, тупас яңгырап куйганда – аһ итәсең. Болай булырга тиеш түгел сыман! Хәер, мондый сыйфат ХХ гасыр татар шигъриятенә дә хас. Һ. Такташ та, Р. Харис та, Р. Гаташ та, Р. Зәйдулла да шундыйрак шагыйрьләр. Бу үзенчәлек – хәзер безнең татар әдәбиятының традицияләреннән берсе. Хәтта, чигенми әйтергә кирәк, Г. Кандалый тудырган шигъри рухның кичә дә, бүгенге көндә дә татар әдәбиятында яшәвен барларга мөмкинлек бирүче әдипләр алар.

Г. Кандалыйдагы темалар, мотив рәвешен алып, Г. Тукайның да мәхәббәткә һәм дин әһелләренә багышланган әсәрләрендә (әлбәттә, бары тик юмор һәм сарказм белән сугарылганнарында) кабатланмый калмаганнар. Димәк, ул «авылчалыклар», «егетлекләр» татар шигъриятенә Г. Кандалый иҗаты белән килеп кергәннәр

---

[1] *Кандалый Г.* Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б. 387.

һәм, тамырланып, аның иҗат мирасы тәэсирендә үсеш алганнар. Бу тарихи һәм мәдәни фактларны, тормышыбыз һәм әдәбиятыбыз хакыйкатьләрен без юкка санарга һәм инкяр итәргә тиеш түгелбез. Г. Тукайның юмор-сатира тамыры кайдан килгәнлеге Г. Кандалый иҗатын белгән-өйрәнгән кешегә аңлашылып тора. Татар милли шигърият җене бер шагыйрьдән икенчесенә күчеп яши, аларны бөек ясый.

Г. Кандалыйның иҗат мирасы зәвык ияләренә ошамый, алар тарафыннан яратылып бетелми. Әмма бу әле «аның талантын кире кагабыз» дигән сүз түгел. Сүз юк, Г. Кандалый бөек талант иясе шагыйрь булган. Әмма аның таланты нечкә әдәбият кысаларын бозуга, какшатуга, яңа, заманча, тормыш күренешләрен сурәтләүгә корылган әдәбият тарихын башлап җибәрү өчен мәйданга чыккан. Ул тормышчан әдәбиятны тудырган. Бу яктан аның бөеклеген һичкем кире кага алмас. Бу бөеклек тормышның үзен, аның ваклыкларына, шәхескә бәйле булуын, шәхси һәм шәхсәни үзенчәлекләрдән торучы яшәеш икәнлеген конкрет кешеләргә мөнәсәбәтле сурәтләүдә кыю әдәби адымнар ясап ачыла барган.

Ә моның хикмәте дә бар.

Татар суфичылык әдәбияты урта гасырларда абстракт хакыйкатьләрне тасвирлауга һәм ачыклауга күчә. Әгәр дә XII гасыр мистик шагыйрьләре Ә. Ясәвидә дә, С. Бакырганида да хакыйкатьләрне ачу һәм ачыклау юлы шигърияттә шәхси һәм конкрет тормыш фактларына нисбәтле булса, инде XIII йөздә, Кол Гали әсәрен мисалга алабыз, хәтта Шәрык бөекләре Җ.Румида һәм Ф. Гаттарда да ул шулай – башкача, тормыштагы шәхси, конкрет фактлар исәпкә дә алынмыйча, абстракт поэтик фикерләүгә тәмам күчеп бетү күзәтелә. Моны – әдәби конкретлыктан әдәби абстрацияләргә күчүне – гомумтөрки әдибе Ә. Югнәки алданрак, Ә. Ясәвигә кадәр үк башлый югыйсә. Хәер, инде Ә. Ясәви үзе дә конкрет тормыш фактларын сурәтләүдән абстракт фикер бирүгә таба кискен борылыш ясаган әдипләрнең берсе булган. Чөнки тормыш хакыйкатьләре, конкрет күзәтүләрдән бигрәк, абстракт фикерләү юлы белән тирәнрәк ачыкланыла һәм ачыла. Аннары абстракт фикерләү юлы мистик аң үсешенә зур мөмкинлекләр бирә. Илаһият гыйлеменең үсеш алуы шәхси, үз тормышың фактларыннан ерагаю, аерылу һәм абстракциягә, абстракт төшенчәләр дөньясына

күчүгә бәйле. Шул сәбәпле суфичылык чорында әдәбиятта аерым, шәхси тормыш фактларын, бигрәк тә тормышның үзен, аның очраклы хәлләрен сөйләүне һәм тасвирлауны фикер бирү алыштыра. Вакыйгалар һәм күренешләр гомуми, хәтта типик вакыйгаларга һәм күренешләргә бәйле тасвир кылына. Абстракт фикер бирү хакыйкатьне ачуга, аны асылына үтеп ачыклауга корыла һәм шуның белән табылган бер-бер фикер, мәкальдәге кебек, тормышның һәр очрагын аңлату өчен яраклы була бара. Моны без әдәбиятның *хакыйкатьне эзләү юлына керүе*, *танып белүгә корылуы* дип тә атый алабыз. Менә шуңа да ул дәвер әдәбияты үгет-нәсыйхәт итүдән, фикер бирүдән, фәлсәфә тудырудан, тормышның һәр очрагына ярашлы мәгънәләр тәкъдим итүдән гыйбарәт. Шуның аркасында ул тарихыбызны «әдәбиятның үгет-нәсыйхәтчелек дәвере» дип атыйбыз.

Татар әдәбияты тарихында абстракт мәхәббәт, абстракт фикер, абстракт вакыйга, абстракт күренеш, абстракт мөнәсәбәтләр челтәреннән күчеп, конкрет тормышны сурәтләүне «Собәтелгаҗизин»дә Суфи Аллаһияр кузгатып ала. Ә. Ясәви заманында әдәбият ничек абстракт төшенчәләргә күчә барса, С. Аллаһияр аны кабат конкретлыкка кайтару адымын ясый. Бу кайтару-кайту адымы, шулай итеп, әдәби абстракцияләрдән әдәби конкретлыкка күчү юнәлешен ала (дөрес, аның иҗатында бүтән төрле әдәби башлангычлар да бар, әмма, алар темадан читтә булганга, монда башкалары хакында сүзне кузгатмавыбыз хәерле). Ул үзенең ничек суфи булып китүен, байлыктан, гаиләдән баш тартуын, ата-бала, шәхес һәм гавәм мөнәсәбәтләрен конкрет сурәтләүдә бирә. Инде аңарда ук абстракциядән конкретлыкка күчеш көчле тәэсир итү һәм тәэсирләнүгә корылган. Бу алым исә әдәби конкретлаштыруның перспектив булуы хакында сөйли. Моның өчен, тормышны яхшы белү белән бергә, сурәтләү осталыгы да аерым әһәмияткә ия. Автор үзенең тормышны өйрәнүдә туган фикерләрен түгел, бәлки конкрет хис-тойгыларын сурәтләүдә тәэсир көченең югары булуын сизми-сиздерми калмый. Конкрет күренешләрне, вакыйгаларны һәм шәхесләрне сурәтләүдә татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни тагын да алга китә. Бу алым, әдипләр һәм укучылар тарафыннан хупланып, гомуми әдәби юнәлешкә әверелә. Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллин аны «элегик дәвер» дип атыйлар.

Г. Утыз Имәни үзенең хатыннарына, балаларына, үлү вакыйгалары белән бәйле, әлбәттә, сагышлы мәрсияләрен багышлый. Әдәби тасвир өчен ул конкрет тормыш детальләрен файдаланырга мәҗбүр була. Бу юнәлештә татар әдәбияты тарихында иң уңышлы иҗат эшен алып барган шагыйрь Г.Чокрый булган. Бездә мәрсия жанры әдәбиятны абстракциядән, фикер бирү юлыннан тасвирга, тормыш күренешләрен конкрет, очраклылык белән бәйле сурәтләүгә алып чыккан. Әмма абстракт әдәбиятны типиклаштыру алымнарына корылган әдәбият белән бутарга ярамый. Абстракция типиклаштырудан аермалы буларак гомумиләштерми, бәлки аерымлый. Аерымлау исә хакыйкатьне аңлауга мөмкинлек ача. Конкретлаштыру да, анысы, гомумиләштерми-типиклаштырмый, бәлки очраклы күренеш, вакыйга, тормыш детальләрен бер-берсенә үзара бәйлелектә карый. Шушы сәбәпле конкретлаштыру әдәби күренешне һәм вакыйгаларны сурәттә бай ясый, шәхесләрне тормышчан детальләрдә ачык күрсәтергә мөмкинлек бирә. Монда «каләм каш», «ай йөз» кебек метафорик эпитетлар файдаланылса да, «бакча алмасыдай бит очы», «кызыл чия иреннәр» отышлырак кебек тоела. Авторлар, детальләштерүдән, тормышчан төсләр һәм эпитетлар файдаланудан тыш, үз хисләрен төгәл һәм үтемле-ачык сурәтләргә корырга мәҗбүр булалар. Чөнки конкретлык детальләрнең үзара бәйле булуын таләп итә, тышкы күренешләрне эчке тойгыларга, ягъни күзаллауларга, хисләргә бәйли. Шунлыктан шагыйрь «алма кебек» дидеме, җитмәсә, ул кызарып пешкән һәм татлы да итеп әдәби сурәттә бирелсә, мантыйк таләбе буенча, әлбәттә, аны яки тешләп алырга, яисә кабып йотарга теләр һәм шушы хисе тууны әсәрендә автор бирми калдыра алмас. Менә шушы әдәби конкретлылыкка омтылыш Г. Кандалыйны бөек шагыйрь ясап кына калдырмый, бәлки эротик хисләр җырчысына да әверелдерә. Бу исә татар әдәбиятының элгәре чорда абстракт юнәлештә югары үсешкә ия булуы сәбәбеннән дә киләә. Ә болар дини күзаллау кысаларына сыямы?

**Дин һәм Г. Кандалый.** Бу мәсьәлә тәмам ачык кебек. Аның «Мулла белән абыйстае» (исемне әсәренә укучылары куйган) мәктәптән үк һәркемгә яхшы таныш. Җиңел истә кала. Көлке дә, шаян да. Татар укучысы андый әсәрләрне сөя. Шул көлкедән, шаянлыктан һәм шаяртудан бездә олы мәгънәләр табалар һәм андый

әсәрләрдән тәрбияви мәгънәләрне бик теләп барлыйлар, аларны кабул итәләр. Милләт бәхете гүяки уен-көлкедә, шуклыкта, шаянлыкта. Безнең андый үзенчәлекләребез үзләреннән-үзләре килеп чыга. Мәгәре мәхәббәт мелодрамасына, игезәкләрнең аерылуына, ахырда ананың балаларын табуына, апа-сеңел, абый-эне табышуга сюжеты корылмаса, һинд киносы бездә сәер хисләр тудыра. Һинд фильмнарының мотивлары һәм вакыйга корылышлары башкача булмаска тиеш сыман. Шуның кебек татарда да бераз көлке, бераз уен, бераз драма, бераз юләрлек, бераз мәгънә һ.б. шундый «беразлар» зур соклану тудыра. Ул «беразлар»ның микъдары-үлчәме дә бар. Килеп җитмәсә, яки артыкка китсә – җаныбыз корый башлый. Г. Кандалыйның «Мулла белән абыстае» нәкъ менә шундый, «беразлар» татар чамасына туры килеп тора. Аны төрек, үзбәк аңламас, әмма башкорт, казакъ, уйгур кабул итәрләр.

Әдәбиятта конкретлаштыру образ-тасвирда әдипләрне ваклыкларга алып кереп китә. Һәммә детальнең әһәмияте арта бара. Алар үзара бәйләнештә тасвир ителәләр. Мондый детальле тасвир укучыны фикерләүгә этәрә. Күңел кабул иткән һәр күренеш, сыйфат, үзенчәлек яңа мәгънә тууга китерә. Әмма мәгънәләр төрлечә туа, төрлечә бәяләнә. Берәүләр өчен алар кызыклы тоелалар, икенчеләрнең гайрәтен чигерәләр. Һәр очракта да тәрбияви-эстетик әһәмиятләре югары дәрәҗәдә кала.

Г. Кандалыйның һәр әсәре дини тәгълиматлар, әдәп-әхлак системалары белән кисешеп тора. «Мулла белән абыстай»дагы дини ашлар, йола буларак көлкегә алынган кебек, дин әһелләренең дә шул ашлар өчен генә яшәүләреннән мәзәк ясала. Автор дини йолаларның башкача булырга, үзгәрергә тиешлеген таләп итми төсле. Монда иҗтимагый тәнкыйть югары, чөнки дин әһелләре татар халкының өске сыйнфый катламына әверелгәннәр. Татар халкы ул чорларда чын мәгънәсендә клерикализм кысаларында яшәгән. Автор бу хакта турыдан-туры яза. «Мужикның сыртын игәүләп» дигәне – шул вакыттагы яшәү рәвешенә аңлы, ачык бәяләмә. Шуңа да әсәр совет чорында әдәбиятыбыз тарихы фәнендә бик сөенеп кабул ителде, идеологик тәрбиядә актив файдаланылды. Бу юнәлештә әдәби-иҗтимагый фикерне Г. Кандалый кебек үк югарылыкта XX гасыр башында Г. Тукай үстерә алды. Икесендә дә клерикализмга карата сарказм катнаш юмор, дин кешеләреннән көлү, яңача

яшәү рәвешен эзләргә чакыру, иң хикмәтлесе – клерикализмның киләчәге юклыгын сиздерү. Г. Тукай белән Г. Кандалый шигырьләре арасында бер гасыр чамасы ераклык бар. Аларның әсәрләрендә сурәтләнелгән вакыйгаларга нигезләнеп, «тормыш һаман да искечә калган, үзгәрә алмаган» дияргә мөмкин. Әмма Г. Кандалыйның авангард фикерле шагыйрь булганлыгын бу факт тагын да ачык белдереп тора. Тарихи яктан Г. Кандалый XIX йөз башында ук җәдиди юнәлештә иҗат итүгә алынган, Г. Курсави ничек иҗтимагый фикер үсешендә җәдитчелекне нигезләсә, Г. Кандалый аңа ишекләрне әдәби фикер бирүдә ачкан. Дөрес, ул, үзенең иҗат дәверендә суфичылык әдәбиятына хас булган абстракт юнәлешнең көчен барлау өчен, «Рисаләи-Иршадийә», «Кыйссаи-Ибраһим Әдһәм» әсәрләрен язуга керешә. Бары тик аларда ул системалы рәвештә суфичыл юнәлешен тота алмый, үз әдәби юлына, конкретлаштыруга кире кайта. «Иршадийә» әсәре дини әдәп кагыйдәләрен һәм төшенчәләрен конкрет алып барлауга, тәрбия, белем-мәгърифәт мәсьәләләрен күтәрүгә, авыр кара хезмәткә һәм аны башкаручыларга, байлыкны белемнән өстен күрүчеләргә карата инкяр, хәтта чиркану хисләрен тудыруга бәйле төзелгән. Конкретлаштырылган һәм үзара бәйләнештә үстерелә барган ул фикер һәм хисләр асыллары белән «автор мине»нә, аның уй-кичерешләренә бәйле, шәхси-шәхсаәни рамкаларда ачыкланганнар. Бу юнәлештә С. Аллаһияр кузгалышны башлап, Г. Утыз Имәни беренче адымнарны ясаса, Г. Кандалый аларны дәвам иттергән. XIX йөзнең соңгы чиреге татар җәдитче романистларында ул фикерләр, хисләр тагын да конкретлаштырылып сурәтләнелгәннәр. Фикер бирүдә аларда яңалык юк та кебек, мәгънәләрдә Г. Кандалыйны кабатлыйлар төсле.

Г. Кандалыйның «Ибраһим Әдһәм»е беренче бүлегеннән үк абстракт сурәтләр белән, суфичыл фикер бирү юнәлешен тотып башланып китә. Әмма автор алга таба дини-суфичыл хакыйкатьләрдән бөтенләй дә аерыла, үз чорына бәйле, үз заманының әхлагын бәяләү белән кызыксынып, конкретлылык юнәлешен ала. Урта гасырлардан килгән абстракт сюжетны конкрет вакыйга-күренешләрнең тасвиры алыштыра. Бу алым Ә. Каргалый иҗатына да хас. Аның «Кыйссаи-әүлия»сендә әле абстракт суфичыл хакыйкатьләр тасвирлана, әле шагыйрьнең шәхси һәм конкрет

иҗтимагый тормыш фактлары бәян ителә. Ике шагыйрьнең дә әсәрләре бу яктан охшаш алымнары белән укучыны мавыктыру көченә ия. Мондый әдәби-эстетик күренешләр татар әдәбиятының XIX йөздә, дөресрәге, XVIII йөзнең соңгы чирегеннән башлап, алга таба тәмам үзгәрә баруын, абстракт хакыйкатьләрне раслауга һәм сурәтләүгә корылган суфичыл дәвернең тәмам үтеп, сыйфатлары югала баруын күрсәтеп торалар.

**Суфичылык һәм Г. Кандалый.** Бу мәсьәлә шулай ук тәмам ачык кебек. Әгәр дә Г.Утыз Имәни фәндә тулысынча суфи шагыйрь буларак бәяләнсә, Г. Кандалый исә бар асылы белән дөньяви. «Иршадийә»сендә ул мистик карашларын тасвирласа да, җәннәт, тәмуг, Ахирәт көне, башкалары хакында үз күзаллауларын бирсә дә, боларны, рәсми юнәлешкә бәйле мөселман кешесе буларак, иман тәгълиматы һәм шәригать чикләреннән чыкмыйча, конкретлыкта һәм бәйләнешле сыйфатларда тасвир итә, маҗараларга бирелми. Бу исә Г. Кандалыйның диндә ныклыгы, ачык фикерле, аңлы караштa булуы, һәммә нәрсәне тәнкыйди бәяләү аша кабул итә белүе хакында сөйли.

Суфичылыкны бездә «Аллаһыга мәхәббәт һәм шул мәхәббәт хисенә бирелү, аның белән генә яшәү» дип аңлыйлар, аңлаталар. Әмма, «Аллаһыга мәхәббәт» дигәндә, асылда ни-нәрсә күз алдында тотылуы бөтенләй дә искә алынмый. Менә шуннан «әфләтүн мәхәббәте» рамкаларына суфичылыктагы «мәхәббәт» төшенчәсе куып кертелә. Әмма «әфләтүн мәхәббәте» белән «суфичыл мәхәббәт» – икесе ике нәрсә. Суфи шагыйрь Аллаһының мәхәббәтенә лаек түгеллеге хакында зар елый икән, бу әле аның «әфләтүн мәхәббәте» фәлсәфәсе белән яшәве дигән сүз түгел. Шуны ачык аңларга кирәк: суфи өчен Аллаһы Тәгалә – хакыйкать ул. Шуңа да аны «Хак», «Хак Тәгалә» дип атый. Бу хакыйкать абсолют һәм аңа бары тик абстракцияләнү юлы белән генә якынаерга мөмкин. Тормышның конкрет күренешләре, вакыйгалары, шәхесләре һәм яшәешнең үзара бәйләнешле сыйфатлардан, детальләр берлегеннән гыйбарәт булуы аңа хакыйкатькә ирешергә, ягъни хакны-асылны танып белүгә комачау итә. Ул алардан котылу юлын эзли. Моның өчен «гаиләдән китү», «тормыштан аерылу», «сөекле яр белән бергә калу», «кавышу» кебек халәт кичерү күңеленә ярдәм иткәнен белә. Иман – аның өчен хакыйкать юлындагы тәүге баскыч, ул

исә хакыйкатьнең барлыгына абсолют-тәмам ышанудан гыйбарәт. Иманлы кеше ялганны сөйләми, ялганга ышанмый, хакыйкатьне ялганнан аера белә. Һәрвакыт Хак белән булуны ул – иманлы яшәү, хаклыкка тугры калу дип белә. Кеше иманын югалтса, яисә имансыз икән – ул хата сөйли, ялган белән яши. Суфи – хакыйкатьне танып белү юлында яшәүче кеше. Коллыкны да бары тик шул кысаларда гына аңлый. Суфи конкрет тормыштан күңел-аң белән абстракцияләнүгә бара. Шуның өчен ул тормышны «каһәрли», аның котнкретлыкта бары тик хатага гына китерүен, хакыйкатьтән ераклаштыруын күз алдына дөрес китерә. Суфилар күп кенә, төрледән-төрле хакыйкатьләрне ачканнар, дини мәсьәләләрне төгәл билгеләгәннәр һәм чишкәннәр. Әмма тарихи үсеш барышында суфичылык үзенең әһәмиятен югалта бара. Чөнки ул җәмгыятьне тормыштан аерган, яшәешнең үзгәреше, кешелек алдында куелган мәсьәләләрнең конкрет чишелеш таләп итүе, сәясәтнең динне читләштерүе, фән-техника дәверенең башланып китүе, кешенең үз иҗат көченә таянырга омтылышы, рәсми диннең үзенең дә суфичылыкка каршы баруы – болар халыкның суфилардан читләшүен китереп чыгарган. Г. Кандалый шушы читләшү, хәтта аерылу, яңа иҗтимагый катламның барлыкка килеп, ныклы адымнар белән үсешен иҗаты белән раслаган, шушы яңа кешеләргә әдип буларак хезмәт итүне үз җилкәсенә алган фикер иясе шагыйрь булды. Моның өчен аңа үтә катлаулы, үзенчәлекле характеры да хезмәт иткән. Абстракт фикер бирүдән конкрет тормыш материалын сурәтләүгә күчү аның чорында диннән китү буларак та аңлашылган. Хәер, ул хәзер дә ортодокслар тарафыннан шулай төшенелә. Дини-суфичыл төшенчәләрнең урта гасырларда тормышның һәр очрагы өчен универсаль белем, хакыйкать рәвешен алуы, шулай кабул ителеп файдаланылуы, инде заманалар үзгәреп, һәр тормыш очрагы кешедән мәсьәләләрне үзләренчә, аерымлы, үзенчәлекле хәл итәргә тиешлекне замана кешесе тоймый калмаган.

Г. Кандалый яшәгән чорда тормыш вакыйгалары шактый кискен җанланып киткән. Монда Е. Пугачев җитәкчелегендә восстание-күтәрелеш, Ватан сугышы һәм аларда милли көчләрнең катнашуы, фикергә, аңга тәэсире, милли хисләрне көчәйтүе генә түгел, җәмгыятьтә иҗтимагый активлык арта барган чор бу (монда табигать үзгәрешләре дә, мөфтият ачылып, дин кешеләренең

мәхәллә тарафыннан сайлануы һәм нәзарәт алдында, имтихан тотып, җаваплылыкны үз өсләренә алулары да, сәүдә һәм җитештерү капиталына үсеш мөмкинлекләре табылу да, төп халык массаларының кискен ярлылануы да төп рольне уйнаган). Бай халыкка мулла белән абыстайны ашлы-сулы итеп асрау берни түгел. Байлыкта юмартлык булмый калмый. Әмма ярлы халыкта эшләр башкача тора. Хис-тойгылар да үзгәрә. Кискен ярлылана баруы, тормыш авырлыклары аңарда күңел кысынкылыгын тудыра. Ә. Каргалый «Кыйссаи-әүлия»ның беренче хикәятендә үзләренә дә ашарга булмаган Мөхәммәд Ансарины искә ала, мосафир һәм бер җимеш вакыйгасын бәян итә. Суфи буларак, аның гаиләсен өлге итеп, халыкны шагыйрь суфийана юмартлыкка чакыра. Г. Кандалый исә, киресенчә, мондый юмартлыкка кискен тәнкыйть белән чыга һәм бу очракта: «Кайсы гуманлырак?» – дигән сорау куярга мәҗбүр булабыз. Г. Кандалыйның «Мулла белән абыстае» кешелеклелек өлгесе түгелме? Мулла белән абыйстайның «мужик җилкәсен игәләве» кешелексезлек буларак бәяләнгән шул. Динме аларны моңа өйрәтә?

«Мулла белән абыстай»да сурәтләнгән күренешләр дини-суфичыл идеаллар белән яшәүнең заманы үткән, инде актуаль түгеллекләрен ачык күрер, аңлар өчен көчле этәргеч бирәләр. Яңа идеяләрнең, фикерләрнең мәйданга куелуы өчен, әлбәттә, яңа карашлар системасын тудырырга кирәк булган. Монда Диния нәзарәтенең суфичылыкны үзенең рәсмилеге белән кире кагуы да аерым игътибарга лаеклы, зур әһәмияткә ия. Рәсмилек белән һәрдаим каршылыкта яшәгән суфичылык яңа иҗтимагый шартларда үзенең актуальлеген тәмам югалта. Суфичылыкта рәсми дин даирәләре бидгатьлек, буйсынмаучанлык, башбаштаклык барлыгын яхшы тойганнар һәм белгәннәр. Суфи кеше үзлегендә танып белүне алга чыгара. Яшәешен абстракцияләргә буйсындыруы, күңеле һәм аңы абстракт төшенчәләр белән коралланып, уйда һәм гамәлдә туктаусыз абстракт идеалларга тартылуы, максатта абстракт хакыйкатьне эзләве аны, әлбәттә, үзфикерле, серләрне төшенүчән, аңлы-зиһенле кеше иткән. Тормышның даимилеге, үзгәрешләрнең азлыгы, яңалыкларның бөтенләй диярлек булмавы, яшәешның бертөрлелеккә корылуы суфичылыкка иң кулай шартлар тудырган.

Татарда сәяси-тарихи үзгәрешләр еш барса да, эчке иҗтимагый яңачалык 1742 еллардан, Оренбургның сәүдә һәм сәүдәгәрлек үзәгенә әверелүеннән башланып китә. Шәрык илләре белән сәүдә эшен татар үз кулына ала. Россиянең эчке сәясәтендәге татарга карата аз гына үзгәрешләр дә милли тормышта активлыкны тудыра алган. Халык клерикализмнан котыла барган. Көчле сәүдә һәм сәнәгать буржуазиясе барлыкка килеп, 1774 елдан ул үзен бердәм сыйнфый көч итеп күрсәтә дә башлый. Бу процесс, 1920 елларда Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов тарафыннан өйрәнелә башлап, әмма хәзерге фәндә берникадәр читтәрәк калдырылып, аңа бәйле гыйльми мәсьәләләрнең чишелмәве сәбәпле, аңлашылып та җитмәскә мөмкин. Шунлыктан, Г. Кандалыйның яңа идеаллар тудырудагы эшчәнлеген тикшергәндә, тарихи материалга артык киң тукталу да мөмкин түгел.

Г. Кандалый иҗатында мәхәббәт – төп мәсьәлә, ул һәм динисуфичыл, һәм дөньяви. Аны төгәл ачыклап аңларга-аңлатырга тиешбез.

Башта ук билгеләп кую дөрес: Г. Кандалый өчен мәхәббәт ул – шәхси, интим хисләр чыганагы. Шигърият өчен тагын нәрсә кирәк?

Әмма хикмәт күңел фантазиясенә бирелүдә түгел, бәлки тормыш фактларын, аның күренешләрен һәм кешеләрен шигъри анализ, ягъни күңел фәлсәфәсе аша уздыруда. Г. Кандалый нинди дә булса фактны, сурәтне, бәяне кабатламый, бәлки күңел фәлсәфәсе аша аларны уздыра, үзенчә бәяли, менә шуннан яңа фикер, дөньяга карашның яңа рәвеше, системасы барлыкка китерелә. Суфи өчен мәхәббәт – хакыйкатькә тугрылык, аны аңлау, танып белү, аңлату, шуның белән хакыйкатькә, ягъни Хак Тәгаләгә, Аллаһыга берегү мөһим булса, шул абстракт хакыйкать бу һәм теге дөньяларның серләрен аңа танытса, аны күңел рәхәтлегенә, Хакны тою шатлыгына ирештерсә, Г. Кандалый өчен дә мәхәббәт шундый ук рольне башкара. Әмма бу мәхәббәт абстракт хакыйкатьләргә ирешү түгел, бәлки конкрет дөреслекне табу, аны аңлаутөшенү һәм аның һәммә яшәеш белән бәйле икәнлеген тоюдан-тойдырудан гыйбарәт.

Суфиның юлы дини тәгълимат кысаларына буйсындырылган. Ул әүвәле шәригатьне, ягъни үзенә кадәрле билгеле булган хакыйкатьләрне үзләштерә, аннары гына үзенең танып белү юлын

эзли, таба, шулай белемгә ирешә. Аның өчен шәригать – абстракт идеяләрне үзләштерү, ягъни аңлау, кабул итү генә түгел, бәлки аларны гамәлгә, яшәү рәвешенә әверелдерү, ә тарикать – абстракт фикерләүгә өйрәнү, ягъни һәр яңа, үзенчәлекле хәл-халәттән абстракт шартларга, абстракциягә күчүгә, абстракцияләнүгә ирешә алу. Аңа ирешкән суфи мәгърифәтле, ягъни аңлы була. Әмма аң дәрәҗәсе – хакыйкатьне танып белүдә өченче баскыч, югары урын, әмма соңгысы түгел. Суфи хакыйкать белән кушылырга тиеш, ягъни аны тоя, аңлата, белдерә алырга. Ул шушы хакыйкатьтә тәмам «эри», анда аның иске «мин»е юкка чыга, үзе дә башка төрлегә, саф, чиста, аңлы – абстракцияләнгән кешегә әверелә. Аңа конкрет дөнья һәм аның үзенчәлекләре берни түгелләр, ул алардан аерымлана ала. Шулай Әл-Газали, Фәраби, Әбугалисина, Ясәви, Нәкъшбәнди һ.б. бөек галимнәр барлыкка килгәннәр. Аларны конкрет белемнәр түгел, абстракт хакыйкатьләр кызыксындырган. Һәм алар бу юлда зур уңышларга ирешкәннәр. Әмма ул абстракт хакыйкатьләр конкрет очраклар өчен никадәр яраклы? Абстракт белемнәр абсолют хакыйкать түгелләр. Абсолют хакыйкатькә алар да ирешә һәм аңарда «эри» алмаганнар. Чөнки бу хәл мөмкин түгел. Менә шуңа күрә дә суфичылыктан кешелек баш тарта һәм абстракциядән конкретлыкка күчешне яклый. Г. Кандалый иҗаты менә шушы күчешнең татар әдәбияты тарихында ничек барганлыгын һәм беренче уңышлары нәрсәдән гыйбарәт булуын тарихи яктан ачык ачыклап күрсәтеп тора. Ул әдәби-тарихи фактлар күңел тарихыбызның сәхифәләрен ачарга да мөмкинлек бирә. Г. Кандалый иҗатын дингә, дини әхлакка, дини әдәпкә каршы корылган әсәрләрдән гыйбарәт дип булмый. Ул дөньяви, әмма суфи шагыйрьләрнең иҗатлары белән чагыштырганда гына дөньяви, идеяләре һәм идеаллары нигезендә караганда – шул ук ислам дине тәгълиматлары кысаларында, аңа хезмәттә чәчәк аткан иҗат. Сүз хәтта «Сәхипҗамал»ы хакында да бара. Әмма гомумкешелек идеалларына тартылган әсәрләре дә юк түгелләр.

Тагын да шунысы әһәмиятле: мәхәббәт хисе суфи шагыйрьләргә ничек абстркацияләнүгә, абстракциягә бирелүгә ярдәм итсә, аңа илтүче юл булса, Г. Кандалыйга да нәкъ шул мәхәббәт хисе тормыш хакыйкатьләрен танып белүгә юл ача. Әмма бу очракта аңарда хисләр конкретлылык белән аерылып торалар.

Чөнки алар Җир кешесенә юнәлдерелгәннәр. Шуңа да шагыйрьнең күңеле чуар буларак күзаллана башлый. Ул әле Фәрхине сөя, әле Сәхипҗамалны, әле башканы. Күп очракта аның шигъри детальләре, метафора-символ-образлары да бертөрле. Аларда аерма юк. Хисләре даими дә түгелләр, вакытлы, хәтта очраклылар. Әмма шагыйрьнең ул хис-тойгылары тормыш чынбарлыгын ачыклауга, танып-белүгә хезмәт итәләр, шушы яклары белән мәдәни-тарихи-иҗтимагый кыйммәтләргә дә ияләр. Монда иң калку сурәтләнелгәне – белемле кеше надан адәмгә, мәгърифәт исә – наданлыкка каршы куелалар.

Г. Кандалыйның иҗат манерасы хакында М. Госманов болай ди: «Ул тормышта нәрсә бар – шуны яза, үзе күргәнчә һәм бәяләгәнчә яза»[1]. Анысы чыннан да шулай. Г. Кандалый, лирик шагыйрь буларак, күңел кичерешләрен тасвир итә һәм алар аша, хисләренә таянып, дөньяны бәяли. Ә иҗатының реалистик иҗат буларак тоелуы аның тормышны конкретлыкта сурәтли белүеннән килә. Бу исә әдәбият өчен ул вакытларда иң зур уңыш иде. Г. Кандалый әсәрләрен үз күңел дөньясына, тойгы-хисләренә таянып яза. Конкретлылык аның әсәрләрен тормышчан итә, хискә ияртү образларны, күренешләрне, шулай ук әдәби детальләрне тәэсирле ясый. Алар исә үз чиратларында укучыда тагын да яңа хисләрне, тойгыларны уяталар. Шушы рәвешле Г. Кандалый хыялый әдипкә әверелә, хәтта дуамал кебек аңлашыла башлый. Бу исә аның әсәрләре романтизм белән сугарылган булу хакында да сөйли. Г. Кандалый – чын мәгънәсендә романтик шагыйрь. Конкрет тормышны, бигрәк тә аның шәхси-шәхсәни якларын хис-тойгылар белән баетып сурәтли белүе татар әдәбиятында яңа, дөньяви романтизмны тудырды. Хезмәт кешесенә карата тискәре бәяләре дә, авыр хезмәттән, кара эштән чиркандырулары да, хезмәт кешесен «мужик» дип мыскыллап атаулары да Г. Кандалыйның романтизм вәкиле булуыннан килә.

Строфика ягыннан ул һаман да шул ук «Мөхәммәдияче» иде, әмма аның уңышы татар халык җырларына хас әдәби образ һәм

---

[1] *Госманов М.* Габделҗәббар Кандалый: Бер гомердә ике чор // Кандалый Габделҗәббар. Шигырьләр һәм поэмалар / төз., текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, кереш сүз авт. М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б. 36.

символларны файдалана белүендә, таба һәм иҗат итә алуында булды. Бусы исә шулай ук әдипнең таланты, тормышны яңача танып белүе, яңача аңлатып язуы хакында сөйли. Дөньяви булсын, романтизм шагыйре булсын, суфичылыктан баш тартсын, әмма Г. Кандалый ислам динен инкяр итүче дә, аны читкә кагучы да түгел иде. Аны ислам мәдәнияте үсеше генә әдәбиятка бирә алган. Ул рәсми ислам тәгълиматлары кысаларыннан читләшми, әмма үзенең дөньявилыгы белән бунтарь-бидгатьче шагыйрь буларак тоела. Бу исә безнең, аның укучыларының, дини дә, дөньяви да гыйлемнәребез, күзаллауларыбыз, Г. Кандалыйныкы белән чагыштырганда, фәлсәфи-мәдәни яктан караганда, шактый аермалы булуы хакында гына сөйли.

*2015*

# V. СҮЗЛӘРМЕ ТЕЛДӘ ЙӨРМИ?

## Муса Җәлилнең «идеологик агым шигърияте»ндә тәэссорат тудыру осталыгы

М. Җәлил шигъриятенең бөеклеге, аерым алганда, шуннан килде: укучы күңеленә тәэсир итеп, ул соклану гына түгел, могҗизаны тою мизгелен бирү дәрәҗәсенә күтәрелә алды. Шушы сыйфат үзенчәлеге күпләрне җәлеп итте һәм шагыйрьнең һәр әсәре өчен диярлек имманент күренешкә әверелде. «Идеологик агым»дагы шигърияттә бу зур биеклек һәм хәтта бөеклек иде. М. Җәлилнең әдәби символлары 1950–1960 еллардан сәнгатьнең барлык өлкәләренә үзеннән-үзе җәелде, уй-фикерләрне генә түгел, күңелләрне яулап алу көченә ирешүе дә нәкъ менә шул могҗизаны хис иттереп тасвирлавы сәбәпле дә иде.

Аның шигырьдә кулланган әдәби образ һәм символлары концепт дәрәҗәсендә һәм үз чоры совет әдәбиятына хас, әсәрләрдә еш кабатланган күзаллаулардан гыйбарәт иде югыйсә. Шул ук Ватан һәм Ана, әмма ул ялгыз ана гына түгел, кулына Бала күтәргән Ана, шул ук Ир, әмма ул – Ватан сагы өчен күтәрелгән, аның иминлеген кайгыртучы, батыр рухлы, горур, акылга төпле кеше. Һәм кара көч – дошман, ул дәһшәтле, явыз, миһербансыз.

Батырлык мизгеленең сыйфаты, сафлыгы, бөеклеге М. Җәлил шигъриятендә әдәби могҗиза, уңай тәэссорат буларак кабул ителә. Караңгылык, бәхетсезлек, һәлакәт һәм аңа каршы куелган күңел сафлыгы, чиста тугры тойгы, аның чуарланмаган, катлауландырылмаган, идеаллардан аерылган булуы, ягъни табигый сафлык шушы әдәби могҗизаның имманент берәмлеге булып тора. М. Җәлил менә шуны тойдырып яза.

Дөрес, бу могҗизаны сурәтли дә белергә кирәк иде. Шагыйрь моңа шактый зур әдәби иҗат тәҗрибәсе белән килде. Әүвәлдә ул

гади, турыдан-туры сөйли барып кына яза, хис белдерү, фикер җиткерү белән чикләнде. «Егерменче еллар башында «Кызыл йолдыз» газетасында басылган шигырьләр циклындагы иҗтимагый-социаль күренешләрне аңлатудагы турысызыклылык, коры агитация аның үзен дә канәгатьләндерми башлый. Ул сурәткә һәм шигырьгә җан кертү юлларын эзли»[1]. «Моабит дәфтәрләре»ндә М. Җәлил боларга тулысынча ирешә.

Шунысын истән чыгарырга тиеш түгелбез: бу – гомумән дә әдәбиятның үзәк мәсьәләсе, аны һәр бөек әдип үзенчә хәл итә. Моны шигырь тудыру технологиясенә бәйле аңларга-аңлатырга тиешле. Ул – аерым фәнни-тикшеренүне таләп итүче өлкә. Монда форма һәм эчтәлек гармониясен тудыручы үзенчәлекләрне барлау сорала. Н.Г. Юзиев хезмәтләрендә ул тирән яктыртылган[2], М. Җәлил иҗаты да аның тарафыннан шушы юнәлештә тирән һәм ачык бәяләнгән[3]. Н.Г. Юзиевның фикерләрен дәвам итеп, без исә М. Җәлил шигъриятендә идеологик нигездә күзаллауның хакыйкый һәм мәңгелек булуын хис итүне тудыру үзенчәлекләрен барларга һәм бәяләргә кирәк таптык.

Тышкы дөнья белән кеше күңеленең бәйләнешен бердәнбер өлкә – шәхси тойгылар тәэмин итә. Алар хисләрне күзаллаталар, хәтта аң белән бәяләү мәҗбүриятен тудыралар. Идеологик берәмлекләрне, ягъни сәяси-иҗтимагый идеяләрне кабул итү һәм тормышта аларга таяну ихтыяҗын шигърият (гомумән дә сәнгать һәм аның бер төре буларак әдәбият) тәэсирле сурәтләре белән тудыра. Бөтен хикмәт тә менә шул тәэсирле сурәтне иҗатчының барлыкка китерә алу көченә бәйле. Моны бөтен кеше дә булдыра алмый, һәм ул һәркемнән таләп тә ителми. Идеологик берәмлек, аның «идея берлеге» дип тә билгеләргә тиешбез, сурәткә авыр бирелә, авыр буйсындырыла. Аның нәкъ менә мәгънәви һәм шул мәгънәне тойдыручы эчтәлеккә ия булганын табуы авыр. Кешелек аны төрле символлар ярдәмендә күрсәтү юлын тапкан. Байрак, герб, гимн

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Т. 5. – Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 67.

[2] *Юзиев Н.Г.* Татар шигыре: тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – Б. 304.

[3] *Юзиев Н.Г.* Муса Җәлил поэмалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – Б. 135.

кебек символлар дәүләтнең идеологиясен, ягъни идеяләр дөньясын материаллаштырган кебек, мәсәлән, каен, чишмә образлары, символ дәрәҗәсенә җиткерелеп, сагыну, эчке сафлык кебек хисләрне тасвирлау өчен дә файдаланыла. Болар – әдәбиятыбыз фәнендә өйрәнелгән мәсьәләләр. Аннары, эчтәлекләре болай да аңлашылып торадыр сыман. Чөнки халык җырларыннан килгән образлар үз эчтәлекләрен фикерләп чишүне таләп итмиләр. Алар – логослар, кешегә гүяки тумыштан «бирелгәннәр». Халык иҗаты образлар системасында кеше бала чагыннан ук тәрбияләнә.

Һәр тойгы өлкәсе (күрү, ишетү, ис сизү, тәмләү һ.б.) – һәркайсы специфик, модаль, икенчесенә охшамаган, ягъни төсләр тавыштан аерылалар. Әмма шигырьдә төс кенә, тавыш кына да түгел, башка тойгылар да катнаштырыла, шигырь аларның һәммәсен дә үз эченә ала. Авазлар системасы ритм-рифма ярдәмендә төзелә, төсләрне сурәтләр бирә, мәгънәләр символлар һәм эчтәлек бәйләнешендә барлыкка килә.

М. Җәлилнең шигырьдә мәгънәләр тудыруы үз чорының идеологиясеннән аерылмый, бәлки аны тулысынча кабатларга омтылыш белән бәйле иҗат ителгәннәр. Әмма шушы иҗат эшчәнлегенең нәтиҗәсе идеяләрне коры кабатлау, хәтта шигырьгә салып сөйләп чыгу гына түгел, бәлки рухи байлыкка әвереләдерүдән гыйбарәт.

Татар совет әдәбияты, формасы белән милли булса да, эчтәлеге ягыннан социалистик иде. Ул чорда әдәбият башкача яши дә алмас иде. М. Җәлилнең шигырьләре дә шушы җирлектә туды, хәтта Моабитта язылсалар да, әдипнең әсәрләре совет идеологиясе кысаларыннан чыкмадылар. Ул чор әдәбиятының формаларда милли булуы хәзерге көндә дә укучыны үзеннән читләштермәүдә аерым әһәмиятле рольне башкара килә. Әмма эчтәлекнең социалистик (коммунистик) булуы демократик тәрбия алган укучыларда аңа мөнәсәбәтне үзгәртә, билгеле. М. Җәлил шигърияте белән дә шул ук хәл булырга тиеш иде сыман югыйсә. Әмма монда эш башкача тора. Беркая да китеп булмый: М. Җәлилнең әсәрләре хәзер дә халык күңелендә изге хисләр, затлы уй-теләкләр тудыру көченә ия! Бу исә әсәрләренең үлемсезлеген тагын да раслый.

М. Җәлил шигырьдә абстракт фикерләмәләр белән эш итмәде. Ул хис-тойгыларны конкретрак, төгәлрәк бирү ысулларын таба белде. Шунлыктан шактый тирәнәйтелеп, гомуми тоелган төшенчәләр

дә аның әсәрләрендә тормышчан мәгънәләр алдылар. Моның өчен шагыйрь әдәби күренешләрне, шигъри вакыйгаларны, драматик ситуацияләрне шигырь форматында сурәтләү алымнарын файдаланды. XIX йөздә рус шигъриятеннән укучылары читләшкәч, аларны әдәбиятка кире кайтару өчен әдип Н.А. Некрасов шушы алымнарга мөрәҗәгать иткән[1] кебек, абстракт төшенчәләрне, шигъри күзаллауларны үтемле ясау юлында М. Җәлил дә шул ук чараларны файдалана белде. Моның белән ул шигырьне гадиләштермәде.

М. Җәлил әсәрләрендә абстракт төшенчәләр шигъри сурәтнең «эчендә» тудырылдылар, ягъни тасвирлар укучыны патриотик хисләрнең сафлыгын һәм кешелек дөньясында өстенлеген хис итәр һәм тояр дәрәҗәдә үтемле итеп тудырылган иделәр. Әдәби фикерләүне бу рәвешле итеп «ясау» осталыгы М. Җәлилнең шагыйрьлек талантына бәйле иде.

## Татар әдәбият белемендә Гали Халит

Гали Халитның (1915–1992) нинди зур галим булуын аңлау-аңлату өчен, татар әдәбият белеме фәненең тарихчасын берникадәр искә төшереп алу хәерле. Ерак китмибез. Аның әдәбият белеме өлкәсенә килүе елларына гына күз салабыз.

XX йөзнең 20–30 нчы елларында әдәбият белеме фәне бөтен асылы белән диярлек социаль-генетик принципларга, гадирәк итеп әйткәндә, социологизмга корылып өлгерде. Социалистик җәмгыять төзү өчен, киләчәктә ирешеләчәк коммунизмга дөрес баруда әдәбият-сәнгать тулысынча сәяси-идеологик таләпләргә җавап бирергә һәм хезмәт итәргә тиеш иделәр. Татар әдәбияты гыйлеме бу яктан алдынгы булды, аның авангардында данлыклы революционер әдип Г. Ибраһимов барды. Ул татар тарихын ничек социологизм һәм революцион большевизм юлында дөрес ачыклап корса, тел һәм әдәбият фәннәрен дә социологизм принципларында өйрәнү ягында иде. Бу фәнни өлкәләрдә Г. Ибраһимов 1917 елга кадәр танылып өлгергән, рус әдәбияты-теле галимнәре А.А. Потебня һәм аның

---

[1] *Проскурин О.* Некрасов – поэт // Некрасов Н.А. Избранные сочинения. – М.: Худож. лит., 1989. – С. 18.

укучылары хезмәтләренә таянып фикер йөртүче алдынгы сафлардагы тәнкыйтьче дә булып җитешкән иде югыйсә. Аның карашларының киңлеге, фикерләренең тирәнлеге һәм стиленең бәхәскә этәрү көченә ия булуы сокландыра, әлбәттә. Рус эстетика һәм поэтика мәктәбе фикерләмәләрен кабул иткән һәм татар тәнкыйте өлкәсендә үстерә алган Г. Ибраһимов, алга таба В.И. Ленинның һәм Г.В. Плехановның өйрәтмәләренә таянып, татар әдәбиятының пролетарий һәм революцион катламын ачып сала, өйрәнү һәм бәяләү эшен башлый. Ул гына да түгел, 1906 елда ук «Матур әдәбият һәм капитализм» хезмәтен бастырган һәм әдәбиятны өйрәнгәндә һәм бәяләгәндә иҗтимагый-генетик методны файдалана башлаган, 1917 елдан соң аның методологиясен эшләгән В.М. Фриче хезмәтләрендәге фикерләрне дә ачык аңлап кабул итеп, татар әдәбият белемен марксизм нигезенә кора. Шул сәбәпләргә бәйле, без Г. Ибраһимовны татар фән дөньясында социологизм принципларын үзлегеннән һәм үзенчә җитештергән галим буларак та беләбез. Әмма Үзәк, ягъни һәртөрле милли-мәдәни хәрәкәтләргә сизгерлек күрсәткән Мәскәү, Г. Ибраһимовның карашларына төзәтү кертергә ашыкты. «Демократик централизм» дип аталган большевистик принцип әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә генә түгел, фәнгә дә баш була барды. Мәдәният өлкәсенә бәйле социологизм теориясе марксизмнан үсеп чыккан иде. Ул, социал-демократ, революционер һәм гомумән дә революцион фикерләр иясе, әмма халыкчан рухлы Г.В. Плеханов тарафыннан нигезләнгән һәм төгәл аңлатылган, алга таба В.М. Фриче хезмәтләрендә конкретлаштырылган, системага салынган, XX йөзнең беренче чирегендә үстерелгән теория буларак, советлар чорында әдәбият һәм сәнгать үсешен билгели һәм бәяли торган, әдәби-мәдәни тормышны аңлатып бирә алучы бердәнбер принципка әйләнеп калды. Яңа совет мәктәпләре укучыларны һәм вузлары исә гыйльми кадрларны өлгер рәвештә шушы социологизм методикасын һәм методологиясен өйрәтү, принципларын аңлату һәм төшендерү эшенә керештеләр. Әдәбият иҗтимагый фикер өлкәсенә әверелде. Әмма социологистлар, болар белән генә канәгатьләнә белмичә, сәясәткә дә үтеп керә башладылар һәм шуның нәтиҗәсендә «вульгар-социологистлар» ярлыгын алдылар. Эшләре каты тәнкыйть уты астында гына түгел, бәлки юк ителү белән тәмамланды.

Социологизм принцибы әдәбиятны һәм мәдәниятне турыдан-туры сыйнфый-революцион үзаң белән тәңгәл куя, шул үзаңны тәрбияләүгә яраклы булу-булмавына карап бәяли иде. Фәнне дә ул феодаль, буржуаз, пролетарий, вак буржуаз (крестьян) карашлар буларак, сыйнфыйлаштырып күзаллау ягында торды. Әгәр әдәби әсәр феодализм чорында язылса, анда феодаль карашлар хөкем сөрә, әгәр капитализм дәверендә тудырылган икән, ул вакытта – буржуаз була. Халыкчан икән – вак буржуаз, революцион икән – пролетарийлашкан һ.б. Бу формулаларны, әлбәттә, гадиләштереп аңлатуыбыз, һәм күпләр аны шулай гадиләштереп аңлый һәм кабул итә, шуңа таянып фикер дә йөртә, социологизмны вульгарлаштыра иделәр. Һәм мондый карашлар хаталануларга китерделәр. Татар әдәбияты фәнендә һәм тәнкыйтендә тиздән яңа буын, милли кадрларның милли хаталарын төзәтү өчен Мәскәү вузлары тарафыннан әзерләнгән алдынгы кадрлары да барлыкка килде, алар, чын галимнәр буларак танылып, алдынгы сафларга чыктылар. Араларында иң танылганы Г. Нигъмәти иде.

1920 елларда әдәбият белемендә барлыкка килгән «иҗат методы» төшенчәсе дә социологизм методологиясе тарафыннан алга чыгарылды. Һәм ул, әүвәле, әдәбият һәм сәнгатьнең үзләренә түгел, бәлки аларны өйрәнүче һәм бәяләүче әдәбият белеме фәненә карый, әдәби күренешләрне анализлауда һәм төркемләүдә төп чараларның берсе иде.

«Әдәби иҗат методы» төшенчәсе марксистик карашлар нигезендә барлыкка килгән һәм социологизм юлы белән әдәби әсәрләрне анализлауда һәм бәяләүдә иң катлаулы чишелешле мәсьәлә буларак күзаллана башлады. Әсәрнең талантлы яки талантсыз язылуы, мәгънәле яки мәгънәсез булуы әдипнең гүяки иҗтимагый аң үсешендә марксист булуына бәйле, имеш. Иҗат методы, ягъни тормышны чагылдырганда язучының күңел эшчәнлегенең очраклы хисләргә корылмавын ачыклау, – әлбәттә, фәнни әһәмияткә ия мәсьәлә. Социологизм вәкилләре исә аны төп, әдәби иҗат принцибы буларак карый, ачыклый, күрсәтә башладылар. Социологизмның әһәмияте «социалистик реализм» төшенчәсе барлыкка килгәч һәм совет әдипләренең бердәнбер иҗат юлы, принцибы дип игълан ителгәч, тагын да актуальләште. Социологизм теориясе белән коралланган галимнәр иҗат методын әсәрдә төп, әдәби әсәрнең асыл эчтәлеген һәм

төгәл формасын, аның уңышын-уңышсызлыгын күрсәтүче фактор рәвешендә дә белдерә һәм аңлата башладылар. Социалистик реализм тәнкыйди реализмнан, ә тәнкыйди реализм үзе мәгърифәтчелек реализмыннан үсеп чыккан дип күзаллау һәм раслау аларның фикерләмәләренең асылына әверелде. Социологизм вәкилләре бу фәнни юнәлешне «иҗтимагый-генетик анализ методы» исеме белән атадылар. Прогрессив, киләчәккә төбәлгән романтизмның яңа совет җәмгыяте рухи күтәрелешендә роле ачык аңлашылып, социалистик реализмның исә, тормышны үсештә тасвирлаучы метод буларак, романтизм чараларын да ят итмәвен алар күрергә тиеш иделәр. Һәм социологистлар кешелек мәдәниятен сыйнфый эчтәлектә генә күзаллап, шуның нигезендә әдәби әсәрләрне бәяләү һәм иҗтимагый үсеш өчен яраклы булганнарын гына сайлап алу ягында тордылар. Мәктәп, вуз программалары, уку-укыту, тәрбия эшләре шушы социологизм вәкилләренең өйрәтмәләренә корылган иде.

Шушы чорда, нәкъ менә 1930 елларда әдәбият дөньясына шагыйрь буларак аяк баскан Г. Халит, әдәби тәнкыйтькә һәм фәнни-тикшеренүләргә дә тартылып, социологизм методологиясен иң яхшы үзләштергән ышанычлы яшь буын вәкиле буларак, тиз арада танылу ала. Аның Г. Ибраһимовны вак буржуаз әдип буларак бәяләве, Дәрдемәндне эре капиталистларның хисләрен җырлаучы буржуаз, декадент шагыйрь дип аңлатулары, социал-революционерлар партиясе вәкиле С. Рәмиевне «революцион позицияләрдә тормады» дип раслап язулары һәм башка шушындый фикерләрдән гыйбарәт, эчке мантыйкка, фикерне төгәл белдерүгә корылган, марксистик-ленинчыл аңлы мәкаләләре матбугатта урын ала башлый. Аның өчен романтизм вак буржуаз хис-тойгылар чыганагы сыман күзаллана. Хәер, алгарак китеп әйтсәк, Г. Халитның социологизмнан читләшә башлавы исә (бу хәл соңрак була) нәкъ менә шушы романтизмның социалистик реализмдагы урынын күреп алуыннан башланып китә дә инде югыйсә.

Г. Халитнең заманча аңлы, фикерле, белемле һәм, иң кирәге, матур аһәңле, сыгылмалы, әмма катгый һәм мантыйклы тел белән мәкаләләрен язуы күпләрне соңландыра. Ни генә дисәк тә, ул үзен бик яшьли талантлы галим сыйфатында күрсәтә, фәннәрне системалы үзләштерүе аның акыл эшчәнлегенә һәвәслегенә һәм характерына бәйле килгәнлеге язмаларыннан сизелеп тора.

30 нчы елларның икенче яртысында социологизм методы һәм методологиясе каты тәнкыйтьләнә башлый, аны фәнне, бигрәк тә марксизмны вульгарлаштыруда гаеплиләр, Г. Ибраһимов та, Г. Нигъмәти дә кулга алыналар һәм хөкемгә тартылалар. Бөтен хикмәт – әдәби әсәрләрне иҗтимагый-идеологик-сәяси яктан гына бәяләүдә, югары әхлак принципларын, сәнгатьлелек дәрәҗәсен социологизмның исәпкә алмавыннан килә югыйсә. Әмма социологизмның вульгарлашуын әдәбиятны сыйнфый позицияләрдән торып кына бәяләүгә кучүеннән дип белделәр. Әгәр дә әдәби әсәр эксплуататор сыйныф вәкиле тарафыннан язылган икән, ул әхлаксыз, ул – бозык хисләргә корылган, ул – череп баручы хис-тойгыларны сурәтли, ул романтизм методында иҗат ителгән. Ә менә, мәсәлән, М. Горькийның «Тормыш төбендә» яки башка әсәрләре югары әхлакны матурлык тойгысында тасвир итә, имеш. Чөнки ул әдип – пролетарий сыйныфының хисләрен җырлаучы, социалистик реализмны нигезләүче язучы, тәнкыйди реализмнан үсеп чыккан даһи.

Социологизм методын ныгыткан һәм үстергән, аның методологиясен һәм принципларын эшләгән, социализм төзүчеләрне сыйнфый үзаң белән тәрбияләүдә төп әһәмияткә ия булуын аңлата-төшендерә алган В.М. Фриче әдәбиятны һәм сәнгатьне сыйнфый-иҗтимагый аңның үзенчәлекле-специфик формасы буларак бәяли һәм шуны төп эстетик закон буларак игълан итә[1]. Язучының тормышын һәм эшчәнлеген аерым сыйныфка бәйле тикшерү дә социологизм методологиясендә төп әһәмияткә ия саналган. Г. Ибраһимов кына түгел, татар әдәбият белеме фәне дә һәрьяктан төгәл принциплар нигезендә, мантыйклы һәм ачык эшләнелгән социологизм теорияләрен 1920 елда ук үзләштерергә өлгереп, аны төп фәнни-тикшеренү юлы буларак алга таба үстерә башлый. Шушы карашларны яхшы үзләштергән Г. Халит исә әхлак һәм әдәбилек мәсьәләләренә бәйле эзләнүләрен дә мәкаләләрендә сиздереп ала. Шунысы әһәмиятле: ул аларны яңа җәмгыять төзүгә бәйле мәсьәләләр белән берләштерә ала. Әмма аның һәр фикере һәм карашы революцион-сыйнфый идеаллар белән тәмам сугарылган була.

Г. Халитның шушы чорда, 20–25 яшьләрендә язылган күләмле монографиясе «Мәҗит Гафури иҗаты» дип атала. Ул хезмәте

[1] *Курилов А.С.* Социально-генетическое литературоведение // Русская наука о литературе в конце XIX – начале XX века. – М.: Наука, 1982. – С. 307.

1941 елда Казанда Татгосиздатның укыту-дидактик әдәбият секторы тарафыннан редакцияләнеп, «Мәктәп сериясе»ндә бастырып чыгарыла. Г. Халит үз хезмәтен «критик очерклар» дип атый. Моңа кадәр, 1939 елда, шул ук нәшрият аның «Халык шагыйре Тукай» дип аталган мәкаләләр җыентыгын бастырып чыгарган була.

Хезмәтләрнең икесе дә социологизм методологиясе нигезендә язылганнар. Аларда Г. Тукай да, М. Гафури да демократ революционерлар (революцион-демократлар) буларак бәяләнәләр, иҗатлары да сыйнфый-демократик карашлар кысаларында анализлана. Әмма яшь галим, социологизм принципларыннан үсеп чыга барып, әдипләргә аерым сыйныфларга бәйләп ярлыклар тагудан котылырга тырышып, әдәбиятны иҗтимагый фикер үсеше юнәлешендә тикшерү юлына баса һәм, социологизм методологиясен файдалануына карамастан, аны, иҗтимагый аңны, катлаулы һәм четерекле мәсьәлә – әдәби-эстетик үзенчәлекләрне өйрәнүгә таба бора. Ачык фикерле, аңлы булуы һәм фәнни-тикшеренү стилендә яза белү осталыгы аны беренче адымнарыннан уңышка китерә. Г. Халит бу хезмәтләрендә мәгърифәтчелекнең һәм халыкны агарту идеалларының татар әдәбиятында ничек барлыкка килүен һәм аларның алга таба, ныгый һәм җәелә барып, азатлык хәрәкәтен тудыруын, аерым алганда, Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатлары мисалында конкрет анализлар белән аңлатып, раслап бирә. Шушы рәвешле бу ике бөек әдипнең иҗат мирасы тәмам социальләштерелә һәм идеологик кысаларга кертелә. Г. Халит, яшь галим булуына карамастан, максатчыл фикерләмәләр корып язу манерасына ирешүен М. Гафури иҗатын тикшерүгә багышлаган монографиясендә ачык күрсәтә. Моның өчен ул мантыйклы, фикерләп, ачык мисаллар белән язу стилен корал итә. Аның язганнарына ышанмый мөмкин түгел, алар укучы фикерен үзләренә ияртеп бару көченә ия. Һәм шушы яклары аны фән дөньясына зур галимнең килүе буларак таныталар да. Аннары, Г. Халит, күренеп тора, хезмәт сөючән, һәр мәсьәләне җентекләп өйрәнүне максаты итеп куя белгән. Шунысы кызык: М. Гафуриның әсәрләренә анализ ясаганда, Г. Халит аның кадимче буларак тәрбияләнүен, җәдитчелекнең бер дә кабул итмәвен, битарафлыгын, уку өчен сайлаганда җәдит мәктәпләрен түгел, кадими мәдрәсәләргә керүен бөтенләй дә искәртми. Чөнки фәнни карашлары хаталы булачагын ул аңлап эш итә. Менә шуңа

күрә дә «Мәҗит Гафури иҗаты» монографиясенең беренче бүлеге беренче параграфы «Мәҗит Гафури – мәгърифәтче» дип атала да. Җәдитчелек, әлбәттә инде, татар буржуазиясенең идеологиясе буларак күрсәтелә.

XX йөз башы әдәбият үсешен Г. Халит Россиянең эчке шартлары белән бәйли һәм иҗтимагый үзаң үзгәреше белән характерлый. Асылы социологизмга корылса да, юнәлешендә революцион-демократик идеалларны барлаудан гыйбарәт булуы сәбәпле, галимнең хезмәтләре җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап кабул ителә. Алга таба Г. Халит XX йөз башы татар әдәбиятының үсешен мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализмга күчеш буларак аңлату юнәлешендә фәнни тикшеренүләрен алып бара башлый. «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре» (1948) хезмәте шул фикерләрен раслау юнәлешендә язылa. «Иҗат методы» төшенчәсе әдәбият фәненә социологизм вәкилләре тарафыннан кертелгән булуын да исәпкә алсак, Г. Халитнең тәнкыйди реализмны революцион-демократик фикер үсеше белән бәйләп аңлатуы социологизм теориясеннән берникадәр азат булуын да күрсәтә, ягъни ул әдәбиятны сыйнфый яссылыкта караудан читләшә. Әмма бу очракта да әдәбият иҗтимагый аңның бер өлкәсе буларак бәяләнә югыйсә. Мантыйклы фикерли белүе, әдәби-тарихи материалны максатлы файдалану осталыгы, иҗтимагый-сәяси яктан аңлылыгы Г. Халитка хезмәтләрендә социологизм карашларын саклап калу һәм үстерү мөмкинлекләрен бирде.

1950–1960 елларга татар әдәбияты тарихы фәне тулысынча Г. Халитның карашларына нигезләнеп үсте һәм үстерелде. Шул елларда фәнгә килгән И.З. Нуруллин да, башка галимнәр дә аның фикерләре тәэсирендә формалаштылар. Шулай итеп, татар әдәбияты белеме фәне XX гасырның 40 нчы елларыннан Г. Халит тоткан юнәлеш белән үсте һәм әдәбиятның әдәби үзенчәлекләрен түгел, бәлки татар иҗтимагый фикере үсешен өйрәнүче өлкәгә әверелде.

1950 елның икенче яртысында әдәби мирасыбызны кайтару юнәлешендә зур эшләр башланып китә. 1920 елларда әдәбият тарихыбызны системалаштыру юнәлешендә хезмәтләр басылса да, алар ничек фәнни фикер үсешеннән өзеп-өзелеп калдырылсалар, инде хәзер бу эшнең яңара баруы, әмма тарихи барышның дәресләре тирән яралар калдыруы сәбәпле, галимнәрне шактый

саклык белән эш итәргә этәрде. Социологистлар тарафыннан буржуаз фикер иясе буларак бәяләнгән һәм декадент дип белдерелгән Дәрдемәнд иҗаты да кайтты, башкаларныкы да. Г. Халит шушы чорда «реализм һәм романтизм синтезы» мәсьәләсен өйрәнүгә керешә һәм XX йөз башы татар әдәбиятына бәйле шул «синтез» теориясен эшләде. Бу исә татар әдәбият белеме фәненең социологизмнан ерагая баруы һәм әдәбиятның үзен өйрәнүгә күчүе хакында да сөйли иде. Менә шул чорда Г. Халит әдәби-эстетик анализның фәлсәфи чикләре киң, эчтәлеге шактый тирән икәнлеген аңлап алды. Менә шуңа күрә дә ул 1959 елда В.М. Фриче методының хаталы икәнлеген атап белдереп язып чыкты[1], Г. Нигъмәтинең романтизм теориясендә гыйльми хаталар булуын, романтизмның прогрессив юнәлешен яклап язды[2], хәтта иҗат методын кире кагу мәсьәләсенә дә якынайды һәм аны талисман итмәскә чакырды[3]. Шушы язмалары белән Г. Халит үзен сүздә һәм фикердә социологизмнан тәмам аерылган, котылган галим сыйфатында белдерде. Әмма безнең татар әдәбияты белеме татар иҗтимагый фикере үсешен өйрәнүче өлкәгә әверелеп беткән, асылы белән социологизм принципларына корылган иде инде. Бу бигрәк тә XX йөз башы татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә бәйле шулай булды. Әдәбият теориясе дә социальгенетик өйрәтмәләргә корылган иде. Бер методны әдәби тарихи үсештә икенчесе алыштырып килүе, язучыларның иҗат методы эчендә төркемләнүе, бер төрле иҗат методы белән язуларын раслаулар – болар барысы да социологизмнан килә иделәр. Әдипләрне вак буржуаз, буржуаз, пролетарий һәм башка шундый сыйнфый классификацияләр ярдәмендә төркемләү һәм бәяләүләр онытылып бетмәгән кебек, иҗат методларына бәйле билгеләүләр дә табигый хәл кебек аңлашыла иде. Г. Халитның реализм һәм романтизм синтезы теориясе татар әдәбиятында модернизм-декадентлык хакында сүз алып бармау өчен дә яраклы иде. Җитмәсә, XX йөз башы татар әдәбиятын шул теория нигезендә аңлату татар әдәбияты фәненең алдынгы өлкәсенә әверелде. М.Х. Хәсәнов шушы теория белән бәйләнештә хезмәтләр язып, тиздән зур галим буларак

[1] *Халит Г.* Портреты и проблемы: Избранные статьи разных лет. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – Б. 260–280.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук. – Б. 281–300.

танылды. Татар әдәбиятының барча модернистик хәрәкәтләре һәм үсеш юнәлешләре реализм һәм романтизм синтезы теориясе белән алыштырылды һәм, һәртөрле әдәби-эстетик мәсьәләләрне чишү һәм аңлату өчен, универсаль формулага әверелде. Бу синтез, әлбәттә, зур ачыш иде. Барча теоретик карашлар шушы синтез нигезендә корыла башладылар.

XX йөз башы татар әдәбияты үсеше тарихы ул чорда җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тартып тора иде. Моның сәбәбе билгеләп үтелә торган юбилейларга бәйле булды. Г. Тукай, Г. Ибраһимов һ.б. XX йөз башы әдипләре иҗат мирасын пропагандалауга багышланган фәнни конференцияләр елдан-елга активрак рәвештә, киңрәк даирәләрдә оештырыла торды. Фикерләр ешрак туды. Фактлар төгәлрәк барлана башладылар. Бу эшкә коммунистларның җитәкче органнары һәм шәхесләре тартылды. Шулай килеп, 1980 елларда XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә бәйле «тизләтелгән үсеш» теориясе тудырылды. Чөнки татар әдәбияты XX йөздә бер дистә ел эчендә мәгърифәтчелектән социалистик реализмга кадәр үсеш юлы узды, арада символизм, тәнкыйди реализм, экспрессионизм һ.б. иҗат методлары чорлары бар иде, әдипләр бер иҗат методыннан икенчесенә күчә бардылар, диделәр, Европада бу әдәби иҗат юлын ике йөз ел буена кичтеләр, диделәр. Димәк, татар әдәбияты тарихына бәйле караганда, XX йөз башы тизләтелгән үсеш чоры булган икән.

Г. Халит шушы юнәлештә фикерли башлап, бу теориягә бәйле мәкаләләрен дә әзерләргә кереште. Бу теория әлеге дә баягы шул ук социологизмнан котылып җитмәүдән килә иде. Бер иҗтимагый формацияне икенчесе алыштырып баруын марксизм-ленинизм аңлаткан кебек, бер иҗат методына икенчесе алмашка килүен, шулай әдәбиятның үсеше күзәтелүен социологистлар үз чорларында раслаган иделәр. Татар әдәбият теориясе исә һаман шул караштa торды. Галимнәр бер чор әдипләренең төрле-төрле методларда иҗат итәргә хаклары барлыгын танымадылар, язучылык эше – күңел эше, ә күңел эшенең талантка бәйле икәнлеген аңлый һәм аңлата алмадылар. Шул сәбәпле икенчел, өченчел законнарны алар беренчел итеп алга чыгардылар. Әдәби әсәрнең әдәбилеген ачканда һәм аңлатканда, метод һәм алым мәсьәләренә тукталулар анализ нәтиҗәсе генә була ала югыйсә.

Мисалга XX йөз башы татар әдәбиятын гына алып карасак та, иҗат алымнары, юллары, методлары ягыннан чыннан да чуар чор ул. Бу төрлелекне Г. Халит бер тәртипкә кертергә теләде. Әдәбиятның «тизләтелгән үсеше» рус һәм европа әдәбиятларына бәйләнешнең, рухи-мәдәни интеграциянең көчәя баруы белән аңлатылды. Ә хикмәт татар халкында мәгариф эшенең үсешенә, халыкта грамоталык артуга, әдәби талантларга мәйдан алу мөмкинлеге барлыкка килүгә бәйле иде югыйсә. Дөрес, ул талантлар мәйданга чыккан һәм тарихи үсештә онытылган да иделәр. Әмма галимнәр аларны өйрәнә башладылар, әсәрләрен бәяләү, тикшерү мөмкинлекләре туды. Шулай да Г. Исхакый, Й. Акчура, И. Гаспринский, С. Максуди, Г. Баруди кебек үз чорларында киң танылган әдипләрнең иҗат мирасын өйрәнүдән читтә калдырырга туры килә иде. Алар хакында сүзләр 1980 еллар ахырында гына куера башладылар.

Г. Халит аларны тарихка кайтару яклы булмады. Әмма кискен каршы да чыкмады. Бу елларда татар әдәбият белемендә аның теорияләре һәммә әдәби күренешне ачыклый һәм аңлата алырлык, системалы иде. Яңа заманны да ул «татар әдәбиятында тизләтелгән үсеш» теориясе белән каршы алды, һәм аңа бәйле фикерләре сәяси хәрәкәтләр белән уртак яңгырашта кебек иделәр.

Г. Халит үзенең теоретик карашларын 1985 елда Казанда рус телендә чыккан «Портреты и проблемы» һәм 1990 елда басылган «Многоликая лирика» китапларында туплап бирде. Алар аның гыйлем дөньясын бар тулылыгы белән диярлек ачып бирәләр.

Г. Халит социологизмнан әдәби-эстетик фикерләүгә таба катлаулы юл үтте. Әмма, әдәби әсәрләрне бәяләгәндә, иҗтимагыйгенетик метод һәм методологиянең фикерләрен һичбер вакытта да читкә куймады. Алар аның күңеленә яшьли салынган орлыклар гына түгел, гыйлем дөньясы да иделәр. Әдәбият барышын һаман да иҗтимагый фикер үсеше кысаларында, аның белән тыгыз бәйләнештә каравы аны какшамас материалист итеп тә күрсәтә иде. Ул гыйльми юнәлешеннән һәм фикерләреннән баш тартмыйча, аларны үстерә дә белде.

Татар әдәбияты тарихын бүгенге көндә дә Г. Халитча аңлату яшәп килә, чөнки фәнни теорияләрнең нигезенә аның карашлары салынган. Әдәбият-сәнгатьнең үз үсеш закончалыклары бар югыйсә. Талант иҗтимагый формациягә, сыйныфка һәм хәтта

биографиясенә бәйсез рәвештә туа. Әмма аның ачылуына, үсешенә, күренә башлавына, фикерләренә җәмгыять, әйләнә-тирәсе, тормышы тәэсир итми калмыйлар, әлбәттә.

*2015*

## Татар тәнкыйтендә

Бүгенге татар әдәбиятында әдәби тәнкыйть өлкәсендә тирән фикерле, карарлы һәм ачык акыл белән иҗат итүчеләр хакында сүз барса, арадан беренче итеп Рифә Рахманны атасак, аның янәшәсендә Фәридә Хәсәнованы һәм Алсу Шәмсутованы күрсәтә алабыз. Бездә, татарда, тәнкыйть юк түгел, бар. Бүлмәдән-бүлмәгә сөйләнелеп йөртелгәне дә, телефоннарны, Интернетны тутырганы да, колакка кермәгәне дә. Кайбер очракта геройдан әдәби геройны аера белмәгән «фикерчеләр» дә дан казана.

Чын әдәби тәнкыйтьче булу өчен, яхшы гыйльми әзерлексез мөмкин түгел. Юкса фараз итүләр, шул фаразларга корылган фикер берәмлекләрен «тәгәрәтүләр» матбугатта үзенә урын яулап интегә.

Сүзебезне өч тәнкыйтьчене атаудан башлап киттек. Әмма ни кызганыч, аларның икесе (Ф. Хәсәнова һәм А. Шәмсутова) Татарстан Язучылар берлегеннән читтә йөри. Идарәнең төп эше талант ияләрен берлеккә туплау югыйсә.

Алсу Шәмсутова – әдәби иҗатта чын мәгънәсендә өлгереп җиткән эдибә-тәнкыйтьче. Аның әдәбиятны нечкә тоемлавы, һәр әдәби әсәрдә эчке тирән мәгънәләрне барларга көче җитүе, аларны кузгатып кына калмыйча, аңлата алуы – болар, шиксез, чын талант икәнлеге хакында сөйли торган факторлардан.

А. Шәмсутованың 2010 елда Татарстан китап нәшриятында 10,92 табаклы «Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш» дип аталган әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме мәсьәләләренә бәйле китабы 2000 тираж белән басылып чыкты. Аның белән шунда ук тирән кызыксыну башланды. Әдәбият сөючеләр арасында китап яратып кабул ителде һәм югары бәя алды. Шушы уңышыннан соң А. Шәмсутова әдәби тәнкыйть өлкәсендә бер-бер артлы кызыклы хезмәтләрен бастырып чыгарыр кебек иде. Белеме бар, зиһене яхшы, бәяләмәләре дөрес. Тагын нәрсә кирәк?

Әмма көнчеләре табылдымы: аяк чалдылар, ахрысы. Моны башкача берничек тә аңлату мөмкин түгел. Таланты, каләме бар кеше халкыбызга хезмәт итәргә тиеш тә тиеш инде ул! Язмыйча да тора алмаячак. Бу талантка юл һичшиксез бирелергә тиеш.

Алсу Атласовна Шәмсутованы Татар дәүләт гумантар институтында укыткан елларымнан ук беләм. 1999 елда мин анда әдәбият белеме кафедрасына мөдир буларак чакыртылдым. Тулы канлы, эшчән, алдынгы карашлы кафедра булдыру эшен йөкләделәр. Әзер һәм монда килергә атлыгып торган галимнәр әлегә юк иде кебек. Коллективны туплау һәм аның эшчәнлеген оештыру шактый авырга килде. А. Шәмсутованы да үзебезгә чакырдык. Аек акыллы, төгәл белемле, яхшы зиһенле яшь ханымны студентлар да якын иттеләр. Иң сокландырганы шул булды: А. Шәмсутова киң фикерле, демократик карашлы, тирән белем иясе икәнлеген фәнни тикшеренүләрендә күрсәтә башлады. Кандидатлык диссертациясен яклатуга юллар ачу, кафедрада гыйльми дәрәҗәсен үстерү дә кирәк табылды. Мондый эшләр шактый зур каршылыкларга, саллы дәлилләрне инкяр итүләргә юлыга. Шунлыктан аларга каршы көрәшне яңадан-яңа аргументлар белән алып барырга туры килә. Кадрның үзеннән дә тырышлыкларын күрсәтү сорала.

А. Шәмсутова максаттан борылмады, зур уңышларга иреште. Ул әдәбият гыйлеме өлкәсендә фән кандидаты булды, институтта укытуда өлкән укытучы, аннары доцент дәрәҗәләрен алды. Әмма гаиләсе яшь иде. Баласы да авырмый гына тормады. Эшләрне дә җилкәсенә күп өйгәнбездер? Лекцияләре калу, укытуга игътибары кимү, кафедра эшләреннән читләшү очраклары да булмады түгел, хәтта җитәкчелекнең күзенә дә мондый хәлләре еш чалына башлады. Боларны без «талант шуклыгы» дип атый идек. Андый вакытта укытучыларыбыз аңа ярдәмгә килә белделәр, дәресләрен алыштырдылар. Кафедра А.А. Шәмсутовага мөмкин кадәр ярдәмчел була алды.

2003 елда, кафедра һәм институтның ярдәме белән, А. Шәмсутова «Гаяз Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идеяэстетик эволюциясе (1897–1954)» исемендәге монографик хезмәтен «Гуманитария» нәшриятында 12 автор табагы күләмендә бастырып чыгарды. Бу хезмәте аркасында ул иң беренче чиратта әдәбият галиме сыйфатында киң җәмәгатьчелек алдында танылу алды.

Г. Исхакый иҗатын тирәнтен өйрәнү белән бергә, А. Шәмсутова татар гавәмендә хатын-кызларның демократик хәрәкәтенең тарихи, фәлсәфи, әхлакый юнәлешләрен тикшерде, бәяләде һәм җитди үзенчәлекләрен ачыклады, аны дөньякүләм феменистик хәрәкәт белән тәңгәл куйды, аның милли эчтәлеген ача алды. Үзәктә, әлбәттә, Г. Исхакый иҗаты һәм әсәрләренең үзенчәлекләрен кокрет билгеләү, төшендерү иде. Бу өлкәдә, тема кысаларына бәйле карагандa, безнең татар әдәбияты фәнендә һәм әдәби тәнкыйтьтә мондый тирән эчтәлекле хезмәт әлегә юк иде, яңалары да язылмады.

Кафедрада эшләгән чорында язылган һәм коллективтан уңай бәя алган икенче бер хезмәте – «Фәүзия Бәйрәмова прозасы» китабы, 2005 елда басылды, 6,5 табак күләмендә.

Кафедрада фәнни һәм әдәби тәнкыйть юнәлешендәге эшләр һәр татар әдибенә багышланган аерым монографик хезмәтләр язуга юнәлдерелгән иде. Төп игътибар бүгенге көн язучыларына бирелде. А. Шәмсутова хезмәте шулар арасыннан берсе иде.

Әмма Татар дәүләт гуманитар институты белән язмыш рәхимсез шаярды. Аны Казан дәүләт педагогия университетына 2005 елның июлендә куштылар һәм икесеннән бер – Татар дәүләт гумантар-педагогик университет ясап куйдылар. Мондагы җитәкчелек уку-укыту эшләренә бәйле хезмәтләрне, био-библиографик очерклар тибында язылган хезмәтләрне генә хуплады. Татар әдәби тәнкыйте шул еллардан бирле биобиблиографик очерклар кысаларында гына яши, көн күрә башлады. Моңа каршы татар язучылары күтәрелеп тә карадылар, үз фикерләрен дә матбугатта яздылар, татар әдәбияты өлкәсендә әдәби тәнкыйтьнең үлемен белдереп чаң да суктылар. Әмма әдәби тәнкыйть сәясәте университет мөнбәрләреннән билгеләнеп куелган иде инде. А. Шәмсутова кебек алдынгы карашлы тәнкыйтьче һәм әдәбият галименең кирәге калмады. Һәм менә шул заманда ул «Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш» дип аталган әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме өлкәсендәге эзләнүләре белән сугарылган тагын бер данлыклы китабын бастырып чыгарды.

«Хәзерге татар прозасы», «Бүгенге прозада миф тудыру», «Фәүзия Бәйрәмова повестьларында яшәү фәлсәфәсе», «Нәбирә Гыйматдинованың «Болан» әсәрендә мифологик образлар», М. Мәһдиев, Т. Миңнуллин, Р. Харис, Д. Салихов, Н. Гамбәр, Х. Әюпов, Зөлфәт, Ф. Яруллин, Г. Гыйльманов иҗатларына ба-

гышланган әдәби анализлы, саллы, мәгънәле, тирән эчтәлекле мәкаләләр бу китабының дәрәҗәсен бермә-бер арттырдылар. Ул елларда университетта һәм аның тирәсендә күкрәкләренә А. Шәмсутованың шушы китабын кысып тоткан, аның фикерләре белән күңелләрен сугарган студент яшьләрне еш очратырга була иде. Хезмәт бүген дә актуальлеген югалтмады. Һәм без әйтәбез: «Бездә дә бар ул үлмәс китапларны язучы авторларыбыз!»

Бүгенге көндә А. Шәмсутова Кремль музеенда фәнни, гыйльми-практик эштә. Әдәби-сәнгати тикшеренүләр алып бара, әдәби очрашулар оештыра, күргәзмәләр ача. Татар әдәбиятына актив хезмәттә. Мәкаләләре дә матбугатта күренеп тора. Алга таба аның иҗаты бермә-бер активлашачак. Моңа А. Шәмсутованың теоретик әзерлеге дә, әдәби күзаллаулары да мөмкинлек бирә.

*2016*

## Каләм сүзенең тәме

*(Әхәт Гаффар иҗаты)*

1

Әхәт Гаффар әдәби әсәрләрендә сурәтләр бирүдә шундый оста эш итә, күңелләрдә каләменә хөрмәт һәм соклану хисләре бөреләнә. Татар әдәбиятында аңа кадәр бу рәвешле оста тасвирлар бирә алучы юк иде әле, дияргә ашыгасың. Чөнки ул бу юлында шактый талымсыз да. Укучыны әдәби вакыйгалар агышына шулай алып кереп китә, аларда гүяки могҗизаның үзе белән очрашкан кебек буласың. Тасвири картиналар тудыру ягыннан бәяләгәндә, аның кебек осталарны татар әдәбияты аз бирмәде, билгеле. Классикларыбыз Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Ибраһимов... Даһиларыбыз шактый. Әмма Ә. Гаффар башкачарак кебек. Ә шулай да аның тасвирлары үзенчәрәк, җетерәк саф, җетерәк чиста сурәт бирү алымнары белән эшләнелгән булулары сәбәпле соклану тудыралар. Әсәрләрен укыганда, гүяки тәти кашыкка хәйран итеп, ботканың суы беткәнне дә онытып җибәргән хәлгә төшәсең.

Тасвири сурәтләр әдәби әсәр вакыйгаларыннан укучыны читкә алып китәргә тиеш түгел. Алар «реклама паузасы» ролен

башкармыйлар. Моның өчен хәтта вак тасвири детальләрнең дә функциональ-асыл роле, сюжет элементы булуы таләп ителә. Картина өчен генә тудырылган картиналар, вакыйгаларда катнашмаган очракта, үзләренең әдәби әһәмиятләрен югалталар, әсәрнең тышкы тукымасын чуарлау гына булып калалар. Укучы аларны андый очракларда атлап үтәргә, укыганда ук онытырга мәҗбүр.

Ә. Гаффар тасвирлары истә калу үзенчәлегенә ия. Бу факт исә аның язучылык таланты көче хакында сөйли. Шушы рәвешле яза алуы аның беренче хикәяләреннән саналган «Зәңгәр яулык» (1970) белән үк югары бәяләнергә мөмкинлек тудыра. Картиналар бирү осталыгы аның әсәрләренең төп элементы булу белән бергә, аерым фикер уены, хәтта әдәби уйдырмасын нигезләү өчен махсус таянычы да икәнлегенә укучы игътибар итеп тормастан, сюжетларына күңелен ияртте түгелме?

Укучылар Ә. Гаффар әсәрләрен яратып кабул итте. Мондый тарту көче М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, К. Кәримов иҗатларына да хас югыйсә. Әдәби әсәр укучы күңелен үзенә ияртмәсә, аның тәэсир көче дә булмас иде. Туры сүз, әдәби талант белән мәйдан яулау һәм әдәби уйдырмага, хәтта аерым очракларда әдәби-психологик уйдырмалар мозаикасына таянып эш итү – болар икесе ике нәрсә, анысы. Бу әдәби-психологик уйдырмалар мозаикасы күңелне сурәтләр белән котыртуга, хисләрне кузгатып һәм уйнатып алуга гына түгел, талантлы каләмнәр иҗатында тәэсирле күренешләр тудыруга, хәтта, тагын да үстерелеп, могҗизалыкка һәм маҗара хикмәтләре стихиясенә ияртеп алып керү көченә ия. Алар бер дә артык булмыйлар, алардан таләп бер генә: әдәби вакыйгалар эчендә үз вазифаларын югалтмасыннар!

Маҗаралыкка һәм могҗизалыкка корылган кызыклы әдәби-психологик уйдырмалар стихиясен тудыручы әдәби-манипулятив формаларда иҗат иткәндә, һәммә авторлар да диярлек риминалистик романнарга хас сюжет ясау юлын сайлыйлар һәм, төп, асыл сурәтләрне читтә калдыра барып, шул юлдаваклыкларга, вак детальләр бирүгә кереп китәләр. Зур әдипләр иҗатында алай була алмый.

«Зәңгәр яулык» хикәясендә вакыйга егетнең автобустан төшеп калуы очрагын белдерү белән башланып китә. Аңа авылларына әлегә барып җитмәгәнлекләрен, ашыга икәнлеген искәртәләр. Егетнең җәяүләп кайтасы килгән икән.

Ә. Гаффар каләменә вакыйганы шулай сәер төс биреп сурәтли башлау гына кирәк. Әсәрдән әсәренә автор бу әдәби формаль алымын ныгыта бара һәм аны төп иҗат манерасына әверелдерә. Табигый булмаган гамәл һәм шуңардан канәгатьлек – Ә. Гаффарның әдәби геройларының төп сыйфатларыннан. Алар аңа әдәбипсихологик уйдырмасын төзү өчен кирәк. Моның максатында автор башта табигать идиллиясен сурәтләүгә алына. Әмма алар һич кенә дә буш картиналар түгел. Алда әле бер-бер вакыйганың булачагын хәбәр итәләр сыман тойгы уяталар, күңелне шиккә салу, шомландырып алу һәм үртәр өчен, Ә. Гаффар каләме боларны яза.

Урман һәм сырт аша узачак икән егетнең барыр юлы. Кайтып җиткәндә, әнисенең сыер сауган вакытына туры киләчәк ул. Чиләкне авыштырып кына, яңа савылган сөтне эчәр, маэмайга да салып бирер. Бу кечкенә эт аның әнисе белән ялгызак картаючы икән.

Үргә килеп чыгып, үзән буйлап тузан эчендә авыл көтүе узып баруын герой карап тора. Димәк, әнисенең сыеры әле кайтмаган һәм ул аны саумаган. Шулай булгач, мантыйкка хилаф килеп чыга, моңа кадәр авторның вакыйгаларга бәйле сөт эчү хакында сөйләп алулары урынлы буларак кабул ителә алмыйлар. Әдәби әсәрдәге формаль каршылыклар эчтәлекнең таркалуына китерүчән.

Шунда көтү алдыннан кайткан кәҗәнең җитди төстә баруын күреп, герой иртәгәсе көннең нинди булачагын юрап ала. Балачактан калган гадәте икән ул аның. Онытылып бетмәгәннәреннән, автор тасвирлаганча, «күңелнең иң тузган кесәләрендә», төшеп югалмыйча, торып калганы.

Герой шунда тургайның сайравында да үз күңел халәте белән аваздашлык таба. Һәм менә уйнап очып йөрүче өч күбәләкне күреп кала, ике егет арасында аптырап, кайсын сайларга белми, әле берсен, әле икенчесен сынаган кыз сыман бәяли уртадагысын. Шунда ук акыл да сатып өлгерә автор: башка берәүнең йөрәк эшенә читтән торып бәя бирү мөмкин түгел дигән фикер дә уздыра. Аңлы, хисле, мәгънәле әдәби герой укучыга үз булып тоела. Шуңа да Ә. Гаффар һәркемнең ышанычын яуларлык итеп тасвирлап бирергә омтыла әдәби каһарманнарын. Әсәрдәге сурәтләр, картиналар берсе икенчесен героеның күңел халәте белән бәрабәр рәвештә алыштырып киләләр. Кабатланмыйлар. Әсәрдә дөньяның матурлыгы төрле яклап ачыла бара. Күбәләкнең мәхәббәт хисләренә бәйле

фикерләмә корып кына калмый, әдәби каһарман үзенә пар сайлавы, ахырда бөтенләй башкача бәхетле тормыш коруы хакында уйлап ала. Сурәттә мондый импрессионистик алым – татар әдәбияты өчен Ш. Камал иҗаты тәэсиреннән башлап, XX гасыр башыннан ук хас күренеш. Ә. Гаффар да аны уңышлы файдалану үрнәкләрен биргән әдип буларак бәяләнергә тиеш.

Язгы вакыт икән бу. Менә ак чәчәкле шомырт куагы (Ә. Гаффар әсәрләрен укыганда, мондыйрак сорауларны үзеңә биргәлисең: «Ә шомырт куакмы?»), кәрлә, юл читендә үсә. Аңа машиналар ышкылып китеп, гүяки күлмәген ертып узганнар. Янәшәдә пар каен үсә, берсе корыган. Ә төпләрендә ике капчык ашлама ята. Агу инде алар, әгәр дә чамасыз, капчыгы белән берьюлы томырылган булсалар.

Моны автор экологик теманы кузгатып алу өчен шулай телгә ала. Мисалларны киңәйтеп, шунда ук әнисенең маэмаена күчә. Ә аңа агу биргән булганнар. Этнең көтүче Робертныкы булган вакыттагы вакыйгасы икән бу. «Түбәтәй» дип атап йөрткәннәр. Капка төбендә тәмәке тартып утырган чагында, Роберт шул Түбәтәйнең койрык артын, шырпы сызып, ут белән өтеп ала. Өрмәгәне өчен җәзалавы икән. Менә шул хәлдән соң хикәянең каһарманы Түбәтәйне үзләренә сорап ала. Автор аның эт җанлы кешеләрдән ул өстен булуын шулай ача. Кешелекле итеп тасвирлый, димәк.

Герой, юлында тагын да тукталып, кузгалак табып ашый, хәтта үзәнлеккә төшеп, карт миләш тамырлары арасындагы чишмә күзеннән учына алып су эчә. Шунда аңа эндәшәләр. Кара чәч көлтәсен иңбашына һәм күкрәкләренә каплаган хатынмы, кызмы черек агач төбендә басып тора. Аңа эндәшә икән.

Кояш күмелгән вакыт бу. Теге хатын шунда иңкүлеккә йөгереп төшә, ир-егет каршына килеп баса. Муенындагы зәңгәр яулыгы белән ул кемнедер хәтерләтә. Электән танышлар, хәтта кайтканда бер үк автобуста булганнар югыйсә. Әмма Ә. Гаффар каләме уйнаклап ала. Ул мантыйкка әллә ник сак түгел. Сизелә, анысы, вакыйгаларга автор яңа төсмерләр һәм куерту кертергә кайчан да соң түгел дигән принцип белән эш итә. Укып үтелгән сәхифәләргә, вакыйгаларны кабат кайтарып сүтеп, алга таба яңартылган төзәтмәләрне ясаштырып баргандай яза. Автобуста бергә кайткан булулары искәртелү дә – шушы сәбәптән килеп туган хәбәре. Әмма

менә шушында укучы үзен әдәби-психологик уйдырма колына әверелүен тоеп ала, бераз аптырап кала. Моңа кадәр хисләрең белән автор юри генә шаярткалаган икән дигән уй күңелең аша уза. Сыйфатлы әдәби әсәрләрдә андый күренешләргә урын бирелми, анысы. Чөнки әдәби мантыйк әдәби сурәтнең тигез булуын таләп итә. Иң көчле үзенчәлек ялтырап алдан күренүчән, анысы. Ул әдәби иҗат хаталарын яшерергә мөмкинлек калдырмый. Көчле сыйфат шулай йомшак якка да әверелергә мөмкин. Ә. Гаффар иҗатыннан бу әсәре дә моңа мисал була ала.

Әдәби вакыйгалардан аңлашылганча, хикәядәге ул хатын шушы ир-егет белән очрашу өметендә монда килгән. Нәкъ шушы урында буласын белеп, әлбәттә.

Алар үзәнлектән күтәреләләр. Хатын аңа ябышып үрмәли. Итәге дә кыска икән. Героебыз шунда тәмам оялчанлык һәм тәүфыйк билгеләре күрсәтә. Аларның әле утыз яшьләрдән узган икәнлекләре дә аңлашыла. Гомерләренең утыз өченче җәйләре икән бу.

Сөйләшеп алалар. Шунда әсәр каһарманының: «Килдең бит, барыбер килдең, шайтан кызы!» – дип эчтән сөйләнеп, хатынны күтәреп алырга теләве сурәтләнелүеннән соң, укучы: «Ничек инде? Алар бит алдан бу хакта килешмәгәннәр иде. Димәк, автобустан егетнең алдарак төшеп калуы да баштан ук килешүләре сәбәпле булган», – дип уйлап, мантыйкка бирелергә, ахырда әдипнең уйдырмасына хәйран итәргә мәҗбүр. Димәк, автор монда әдәби-психологик уйдырманың чикләрен уза, аны укучы күңеле белән шаяртуга, тугры хисләрен манипулятив уйнатуга мөмкинлек бирүче психологик чараларга алыштыра. Ул әсәргә маҗаралык өсти, билгеле. Чөнки маҗара тудыру алымы буларак әдәби-психологик манипуляция хәтта халык әкиятләрендә дә, ышандыру көчен тудыру һәм арттыру өчен, әлбәттә, әдәби алым ролен башкара. Иҗатына бәя биреп, Ә. Гаффар аны аңлап һәм тоеп кулланган дияргә кала. Әмма әсәрләрендә андый урыннар, артык күп очрап, вакыйгаларның эзлекле барышын үзгәртеп, сюжет корылмасын бозып-уйнатып алалар. Маҗара алымнары кирәк, әлбәттә. Аларны үтә нечкә куллана белү әдипнең таланты югарылыгына бәйле. Әдәби әсәр укучы күңелен әсәрләндерергә тиеш. Әгәр юк икән, ул аны аңлап укымаган. Хисләрең белән әсәргә кереп бикләнеп укыганда, маҗаралык күңелдә соклану, күзаллауда могҗиза тудыру көченә

ия була. Әгәр дә әдәби уйдырма яхшы һәм нәзек эшләнелгән икән, ул сурәтләрнең дә көчен арттыра. Өстәп куелган җөмлә яки деталь кебек кенә булса, әдәби-психологик манипуляция рәвешендә кала. Аларны укучы сизеп ала, күңеле белән айнып, әдәби сихерләнүгә бирелүен аңлап өлгерә.

Ә. Гаффарның каләме сурәтләп барышы тасвирларында әдәби чигенешләрне еш ясый, шулай сүз сурәте чигешләрен тудыра, моның өчен әсәр каһарманын әледән-әле хатирәләре дәрьясында йөртеп ала. Матур гыйбарә – «язмыш музее». Чыннан да, хатирәләр белән калуны «язмыш музеенда булу» рәвешендә метафоралар тудыру Ә. Гаффар иҗатының зур уңышы икәнлеген ассызыкларга тиешбез.

Әлеге хикәядә дә көтелмәгәндә пәйда булган хатынны каһарман язмыш музеennан килеп чыкмадымы дип күзаллый. Кама суы буенда егет аны кайчандыр озатып калган икән. Кызлар, әле генә җыйган букетларын ташлап, яңадан чәчәкләр сайлый башлыйлар. Хатын менә шул хакта искәрә. Хисләрен алыштыруны, башка бирәүне очратуын ассызыклый. Мондый метафорик фикерләмәләр әдәби әсәрнең көчен арттыручан булалар. Әсәр геройлары телләрендә алар очраса, күңелләрен укучыга ача да сала. Ә. Гаффар бу яктан олы талант аталырга тиеш. Ул метафоралар остасы булуы белән бергә, метафорик фикерләү иясе дә. Шуңа күрә тасвирлары искиткеч матур, хәтта гүзәл килеп чыгалар. Шушы ягы белән Ә. Гаффар – әдип, моны бәхәс итеп булмый. Әмма алар үлчәнгән һәм вакыйгалар бирелеше кысаларында үсештә гәүдәләнергә тиешләр. Ахырда детальләре генә түгел, әсәр үзе үк тулысынча метафорага әверелеп киткәндә – бу инде чын мәгънәсендә әдәби уңыш дигән сүз. Без бары тик шундый әсәрләрне генә чын әдәбият дияргә тиешбез.

Ә. Гаффар әсәрендә егет кызның беренче умырзаяны да башта өзеп, аннары ташлап калдыруын белешә. Алар хат та алышканнар. Ядәчләшеп, егет кыздан хәтта зәңгәр яулыгын откан. Ә кызга истәлеккә талир тәңкә биргән. Бу билгеләр язмыш кебек, ике яклы икән, әле бу ягы белән, әле икенче төрле булып төшәргә мөмкиннәр.

Бу хакта мең тапкырлар ишетелгән, сөйләнгән, язылган булсын, әмма Ә. Гаффарның хикәясендә ул матур саф яңгыраш ала,

шуның белән укучыга авторын акыл иясе язучы буларак күзаллата. Әдиптә тормышны дөрес аңлау һәм аңлата белү көче юк икән, әсәрләренең тәэсире дә югала. Матур төзек тел берни түгел, әгәр дә шушы хакыйкатькә хилафлык китерелсә. Ә. Гаффар әсәренә метафорик яңгыраш бирергә омтылмый калмый, моның өчен ул әдәби-психологик уен-манипуляциягә тартыла, ягъни метафорик яңгырашны китереп чыгарырга омтылуы сәбәпле, гүяки тылсымчы кеше, фокусчы, кебек эш итә. Шуның өчен дә әсәрләре матур булып түгәрәкләнеп төгәлләнеп бетә алмыйча кала. Әмма алар метафоралары һәм метафорик сурәтләре белән матурлар һәм укучыны үзләренә җәлеп итеп, күңелен соклandырып торалар. Ә. Гаффар әсәрләрен өзекләргә калдырып укуы күңелле. Алар, бер өлеше төзелеп бетеп, икенчесе башланган хәлендә, агач-куаклар үсеп чыгып, өченче өлеше проект рәвешендәге совет төзелеше күренешен хәтерләтә. Бу аның иҗат манерасына бәйле үзенчәлеге. Проект хәлендә дигәннәрен әсәр эчендә, фикер уйнатып алып, вакыйгаларны катлауландыру рәвешенә кертеп, шул уңайда җай гына сиздереп тә куя. Бу хикәядә, мәсәлән, сауган сөтне чиләктән каһарманның күтәреп эчәчәген искәрткән кебек.

Вакытның соң булуын белдереп, хатын иргә үз юлларына китүләре хәерле икәнлегенә ишарәли. Шунда әдәби каһарман хатынның каршына барып баса һәм битеннән сыпырып куя. Хатын аны читкә этәрмәкче, үзеннән куа. Әмма шунда муенына сарыла, күкрәгеннән, иңбашыннан үбеп елый.

Аннары гына аерылышалар. Ир ялгызы кала. Бераздан караңгыда еракта янган авыл утларына карап атлый. Аңарда сөенү дә, газап хисләре дә кайный. Егет шунда муенына зәңгәр яулык бәйләнгән булуын сизенеп ала. Укучыны әсәрдәге бу хәбәр бөтенләй шаккатыра. Нәрсә уйларга белмисең. Аның зәңгәр төстә булуын караңгыда ничек белде икән каһарман? Әсәрдә моны аңлатып тору юк, әдәби чигенеш тә ясалмый, автор укучы алдында акланып торырга теләми кебек. Мондый урыннарга юлыкканда, язучы әсәрен үзе өчен генә, үз күңелен барлап кына язган икән, дияргә мәҗбүрсең. Укучыдан ул кадәр үк ераклашмаса да ярар иде.

Йолдызлар калка. Алдан атлап барган хатынны шәйли ир. Муеныннан зәңгәр яулыкны чишә дә җилгә очырып җибәрә. «Пары булмаган күбәләк кебек, бөек җилфердәгән зәңгәр яулыкны

очырып җибәрде, – дип яза автор, каһарман исеменнән вакыйганы сөйләп барып. – Мин үз күбәләгемне күптән таптым инде». Һаман да шушы хәл Ә. Гаффарда: әдәби-психологик уйдырманы биргәндә, урынны һәм вакытны исәпкә алмау үзен сиздерә, хронотопның бозуы күзәтелә, аларны укыганда, караңгыда зәңгәр яулык очканы күренерме, дигән кебек, ничек инде, дисең, җанны төрле сораулар били. Алар мантыйксызлыктан югыйсә.

Хикәя матур тәмамланган, картина тулы килеш күзалланырлык язылган. Ә. Гаффарның каләменең төп сыйфаты булган әдәби картиналар тудыру осталыгы, шушы юлда талымсызлыгы сәбәпле, бу хикәяне дә сәеррәк ясаган. Яулык белән бәйле сораулар белән бергә, мантыйкларда абынып, укучы үз күңеленең алдануын тоеп кала. Ә авторны ул сораулар бөтенләй кызыксындырмаган, димәк. Чөнки ул үз чорына хас рәвештә, замандашлары журналист-очеркистлар кебек эш иткән, матурлатылган, бизәкле тормыш картиналары тудыра, шушы юлда көнкүреш детальләренең хакыйкый бирелешен хыялый сурәт тантанасы алыштырган.

Ә. Гаффарның беренче әсәрләрендә үк какшатылмас итеп утыртылып куелган менә шушы «баганалары», бөтен, тулы иҗат биографиясендә аударылмыйча, үз урыннарында тотрыклы сакла给налар. Хикәя язудагы алымнарын ул повестьларына, романнарына күчерә. Шулай да хикәя – аның төп жанры, Ә. Гаффар аңа гомере буена тугры кала.

1970 елда «Зәңгәр яулык» хикәясеннән соң ул «Соңгы сүз»ен язган. Ике совет гаскәри разведчигы – Рахман белән Вася – чокыр казыйлар. Дөресрәге, кабер. Аларны немецлар шунда атып үтерергә тиешләр. Казый торгач, Вася минага туры килә һәм дошманнары белән бергә шартлап һәлак була.

Рахман сугыштан исән кайткан икән. Ул бәрәңге бакчасы башында чикләвек агачларыннан читән үрә. Малайларга шул сугыш вакыйгасын сөйли. Аның бер кулы юк. Анысын немецлар күмгән кайсыдыр минага эләгеп өздергән...

Әсәр ахырына таба автор читәннең дә тузуын искә ала. Менә шулай читән үрә-үрә, Рахман абыйлары хушлашадыр, соңгы сүзне әйтә кебек тоелган аны тыңлап утырган вакытта малайларга. Әдәби борылышы табигый ук түгел, әмма урынлы. Бу әдәби алымны автор уңышлырак та кулланырга мөмкин иде. Моның өчен вакыйга-

ларның бирелеш тәртибен генә түгел, әдәби-тасвир юнәлешен дә үзгәртергә мөмкин иде югыйсә.

Ә. Гаффар монда Рахман сөйләгән сүзләрне укучыга бәхилләшү буларак тәкъдим итә. «Безнең кабердән исән чыкканны саный башласаң, минем генә бармаклар җитми», – ди ул. Соңгы сүз булгач, аңа әдәби әсәр багышлангач, хикмәтле дә, мәгънәле дә, тәкъдири дә ясалырга тиеш инде ул. Сугышны узган Рахманның сүзләре дә шундый булып ишетеләләр. Ә аларны читән үргәндә генә шушылай итеп әйтеп була микәнни? Бусы – авторның әдәби-психологик уйдырма алымын манипулятив рәвештә файдаланырга омтылышы мисалларыннан тагын да берсе. Шуның өчен дә Ә. Гаффар өстәмә рәвештә белдерергә кирәк таба, хәзер инде читән үрмиләр, ә искеләре тузган, диярәк. Монда соңгы сүзнең, бәхилләшүнең, әйтеп калдыру гадәтенең онытылуы сәбәпле, кешеләрнең аңа мохтаҗлыклары калмауга ишарә бар, дип гөман итәргә генә кала. Шушы фаразый фикерләмәнең туа алуы сәбәпсез түгел, хикәянең исеме дә моңа этәрә.

Ә. Гаффар, әдәби картиналарны сурәтле итеп ясау осталыгына ия булу белән бергә, әсәрләренең ахырында фикер бирүләргә дә игътибарын юнәлтә. Аның хикәяләре бу ике үзенчәлекне бер генә тапкыр да читкә этәреп калдырмыйлар. Фашистлар Рахманның да, Васяның да куркуларына өметләнәләр. Аларга шул тойгылары рәхәтлек бирә. Ә болар, киресенчә, үлемнең тизрәк килүен телиләр. Менә нинди батырлар, имеш. Әдәби-психологик уйдырма әсәрдә менә шушы фикерләмә эченә яшерелә. Әмма ул совет әдәбиятында күп тапкырлар кабатланган вакыйгаларның берсеннән генә гыйбарәт.

Әдәби-психологик уйдырмага таянганда, язучы, беренчедән, укучының ваклап, җентекләп уйлап тормыйча әсәрне укуына өметләнсә, икенчедән, бусы инде аның максатына да бәйле, укучының хис-тойгыларына тәэсир итү чарасы буларак аны файдалана. Бу ике очракта да автор югары зәвыкка өметләнми. Әмма Ә. Гаффар, үз чоры әдипләреннән аермалы буларак, әдәби картиналарны чын мәгънәсендә югары, әдәби сурәтләү кимәлендә төзи алган һәм әсәрләре ахырларында фикер йомгагын төгәл һәм мәгънәле ясавы белән иҗатын көчле итүгә ирешкән. Бу алымнарны Ә. Гаффар үзе генә уйлап чыгармаган, билгеле. Алар аңа кадәр үк дөнья классикасында

яхшы эшләнелгәннәр, бигрәк тә XIX йөз европа язучылары иҗатта алардан башка эш итмәгән, аның яңадан-яңа төрләрен барлаганнар, кулланганнар. Аларның табышлары XX йөздә татар әдәбиятында да яңа сүз, яңа мәгънә тудыруда көчле терәк булганнар.

2

Әдәби әсәрне самимилеккә коруга хезмәт иткән әдәби-психологик уйдырма әйтеп бетермәү, башлаган сүзне борып җибәрү өчен уңай, уңышлы иҗади мөмкинлекләр бирә. Ә. Гаффарның «Кояшның салкын чагы» (1971), «Ләкләк» (1973) хикәяләре шул юнәлештә язылганнар. Рус әдәбиятында дан алган В. Шукшин хикәяләре дә шундый иделәр. Ә. Гаффарның беренче әсәрләреннән шукшинчалык үзен күрсәтә башлады. Охшаш һәм аваздаш әдәби картиналарга һәм тасвирларга киң игътибар бирү, төсләрнең җетеләрен сайлап алып эш итү Ә. Гаффарның да иҗат стихиясенә әверелде. Ул хәтта сюжетларын да В. Шукшинча, аның әсәрләренә аваздаш манерада корды. Әмма бер генә хикәясен дә, иҗади булсын, кабатламады. Алардагы аваздашлык тоелырлык дәрәҗәдә генә иде. Бу аның талантына бәйле шулай.

«Пәрәвезле көзнең бер чиге» (1975) хикәясендә дә шукшинчалык сиземләнер дәрәҗәдә генә. Әсәр төп герое Зөлкарнәйнең тегермән бүкәненә бәйле уй-истәлекләренә кысаланган язмыш хакындагы фәлсәфәсен Фәйзулланың уңганлыгына мөнәсәбәтен сурәтләүдән гыйбарәт. Ә. Гаффар һаман да башкача, үзенчәлекле яза белде. В. Шукшинда һәр әдәби деталь әсәр вакыйгаларына береккән, чөнки вакыйгалары сурәтле детальләр белән озатылып барыла. Шуңа тасвирлары вакыйганың үзенә, әсәрләренең каһарманнары төсенә әверелә. Ә. Гаффар да матур, уңышлы, тәэсирле күренешләр бирә. Әмма алар әсәрдә аерым-аерым да яшиләр. Югыйсә ул да каһарманнарын үз әйләнә-тирәләрендәге күренешләргә игътибарлы буларак тасвирлап яза. Шул сәбәпле якты һәм ачык сурәт бирү аның үзмаксатына әверелә, әсәрләренең әдәбилеген тагын да арттыруга хезмәт итә. Әгәр дә шушы сурәтләре булмаса, алар коры вакыйга схемалары хәлләрендә калыр иделәр. Әгәр туры сөйләмнәргә, вакыйгалар бирелешенә килсәк, алар әле генә башланалар да кырт, кисәк өзеләләр. Сюжет җебен хасил итәргә, яңа әдәби мәгънә алып килергә тиеш иделәр югыйсә. Ә алар үз

эчтәлекләрендәге мәгънәләре белән йомылып калалар. Мондый манерада язу әдәби матурлык тудыруда үз функциясен башкара, әсәр тәэсирле һәм матур агымда үстерелеп барыла. Инде әллә кайчан утынга ярылып, мичтә янып бетәргә тиешле кул тегермәне бүкәне истәлекләр кысасында кабат эшләтелә, хикәянең төп герое Зөлкарнәйнең күзенә чалынып, инде бу юлы ватылыр да кебек. Ирне хатыны Ләмига чәйгә керергә чакыра. Кул тегермәне бүкәне бу юлы да исән калдырыла. Пәрәвезле көз сурәте гомер чите түгел икән әле дип, бу укыганнардан бер-бер фикер чыгарырга гына кала укучыга. Югыйсә фикер дә чыгармаса, нәрсә өчен генә укырга тиеш булган соң ул бу хикәяне?

Әдәби әсәр укучыга дөньяны яңача, моңа кадәр күрмәгәненчә ачарга тиеш. Юк икән, аның әдәби иҗат нәтиҗәсе түгеллеген танырга тиеш булабыз. Чын иҗади әсәрләрне укыганда, укучы көтелмәгән яңа әдәби мәгънәләр белән очраша. Дөньяда берничә тапкыр әйтелеп тә, яңадан икенче яисә өченче тапкыр кабатланылучы хәбәрләр журналистика өчен генә кулай. Айлык журналлар да шундый әсәрләр белән тутырылалар. Һәр әдәби әсәрләрен җитди әдипләр яңа иҗат нәтиҗәсе буларак мәйданга куя. Мондый фидакяр рәвештә иҗат итү талантлар өчен хас.

«Ак каен дегете»ндә (1975) Шәймәрдәннең, комбайнда эшләгәннән соң, аны киләсе елга әзерләп юып, майлап, саклау урынына куйгач, әле тегермәнне эшләтә башларга күчүе алдыннан үз ихатасын да тәртипкә кертүе, аннары патефон белән бәйле вакыйгалар, өйдәге гамәлләре, Казанга барып, Луи Армстронг кебек берәр җырчыны тыңлау теләге белән йөрүе, Мәүлет Нәбиенең Фәйзелхак исемле егетләр яшендәге улы белән ресторанга кереп коньяк эчүләре, ахырда милициягә эләгеп тә, үзе кебек үк сугышны кичкән майор Касыймханов автомобилендә концертка озатылуы хакында ярым уйдырма, әкияти вакыйгалар сурәтләнелә. Ә. Гаффар бу фантастик әсәрендә иҗатына хас манераларыннан бары тик картиналарны оста сурәтләп бирү көчен генә файдаланган. Җитмәсә алары да мондый сәер гыйбарәләр белән чуарларга кирәк тапкан: «Комбайнын, төзәтеп бетергәч, әзерлек сызыгына куйды» (монда «әзерлек сызыгы» төшенчәсе әдәби түгел, русчадан калька), «бер малай, ике кыз тән күнекмәләре алып маташа» (ә монысында сүз гимнастика күнегүләре хакында бара), «тузанлы бите буенча юл-юл

булып тир ага» (бите буйлаптыр инде?), «суда йөзгән казлар шикелле чагылган болытлар көтүе», «бу киек бездә чылбырсыз тотыла» – болар барысы да сәер яңгырыйлар, татарча түгелләр. Андый табигый булмаган җөмләләр Ә. Гаффар әсәрләрендә еш очраганга, хаклы рәвештә аларны «гаффаризмнар» дип атарга гына кала.

«Гальери» (1976) хикәясендә Гали-Гальери, Гариф, Нәкый исемле өч көтүченең колхоз сыер көтүләрен савымчыларга алып кайтып, ял вакытларында вагон эчендә вермут эчеп утырулары, арадан Галинең чыбыркы шартлатып шырпы кабызачагын бәхәс итүе, аның чыннан сүзендә торуы, ә бу вакыйганы шофер белән хисапчы хатынның тамаша итүләре тасвир ителә. Шофер шунда Галинең ни өчен Гальери булуын, Сальеридан бозып әйтелүен, хатыны Нәркиснең исә, иренә белдерми, сөйгән кешесе белән хатлар алышуын, соңыннан чын йөзе ачылып, «авиа хатлары» артыннан үзенең дә очуын сөйләп ала. Моны белмәгән икән хисапчы. Чөнки башка авылныкы. Ул шушы шоферның, Саматның, хатыны.

Шунда торак-вагоннан көтүчеләр шаулашып кабат чыгалар. Галинең ялганы ачыла. Ул, чыбыркы шартлатса да, шырпыны, йөгереп барып, үз кулы белән кабызган икән. Ут чыбыркы очыннан чыкмаган. Цирктагы клоуннар да халыкны шулай шамакайланып көлдерәләр, ди.

Вагонда Гали Нәкыйның мунча салдырту өчен дип алдан юнәтеп сатып алып куйган кызыл аракыларын, бәхәстә отып, чөмереп эчеп бетергән. Инде хәзер аның ялганын Нәкый да ача. Тартмадагы шырпылар саныннан чыгып фикер итә ул һәм алданган булуын төшенә.

Алар вагонга Гариф белән кереп китәләр. Гали гармунын сорап ала да язгы ташу ярга чыгарып калдырган субай агачына утырып уйный, җырлый. Аның күңеленә сагыш тулган. Бу җырын Нәркис ишетсен өчен җырлый кебек: «Инде дә кабыздым дип уфтанып куя, ә йөрәк... йөрәк...»

Аңлашыла, Нәркиснең йөрәгендә мәхәббәт уты кабыза алмаган Гали. Аның мәхәббәте дә шаярту-ялган булып чыккан. Әмма, шаяртуы бер хәл, уеннан уймак чыккан, Галинең үз йөрәгендә шул шаяртудан чын хисләр ут булып дөрләп кабынып калганнар. Бусы инде олы хисләр белән тулы. Нәркисне сагынуыннан ул шулай килеп чыккан. Автор бу хакта ачык белдереп бетерми, әмма аның сүз

сөреше шушы эзгә укучыны кертә. Шаярту белән хакыйкать бергә укмашып, сурәтләнгән вакыйгалар Гали-Гальериның язмышын төшенергә ярдәм итә. Ул – шамакай кеше, әмма аның да чын мәхәббәткә хакы бар.

Шушы рәвешле Ә. Гаффар иҗатының үсешендә әдәби-психологик уйдырма геройларының шамакайлыгын сурәтләү белән алышына бара. Бу аның юмористик планга күчәргә омтылышына бәйле шулай. Дөресрәге, манипуляциягә хас шамакайлык үз тулылыгы белән, әдәби сурәт белән баетылмаган хәлдә, схематик формада калып, үзен күрсәтә башлый. Мондый әдәби күренеш Ә. Гаффарда алга таба да күзәтелә, хәтта үзенчәлеге булып әверелә. Нәтиҗәдә иҗатында схематизм көч ала. Аларга тәнкыйтьчеләрнең дә, галимнәрнең дә игътибары җитмәгән. Ул күренешләрне ничек аңлатырга да белми аптырау әдәбият фәнендә бүген дә саклана. Зур әдипне тәнкыйть итүе җиңел түгел.

Ә. Гаффар алга таба язган әсәрләрендә әдәби-психологик уйдырманың схематик, коры хәлдә калдырылуын, әдәбилеген киметүнең уңышсыз иҗади юл икәнлеген аңлап, кабат сурәтлелек эзенә кайтырга омтылышлар ясап карый һәм шушы юлда уңышлы барганда, әдәби фикер бирүдә киңәя барырга мөмкин икәнлеген төшенми калмаган. Мәсәлән, «Ир» (1880) хикәясе моңа иң уңышлы мисал. Оста сурәтче буларак яза аны Ә. Гаффар. Аерым игътибарга алганда, шушы җөмләсе искә төшә: «Җете яшел ашъяулыкка ак гөмбә бастырып куйдылармыни!». Бу – урман эченнән, агачлар арасыннан килеп чыккан хатын-кыз кыяфәте. Аның башында – киң кырлы көрән эшләпә, ә өстендә – ак кофта-чалбар. Ханымның киенүенә игътибар иттереп, тормышыннан тәм табып яши белүен дә тойдырып тасвирлый автор, укучы күңелендә шундый фикерне уздыра белеп яза. Бу ханым күз алдына гүяки тере хәлендә килеп баса. Җылы-йомшак уйлар алга таба күңелнең хис-тойгылар йөгәненә әверелдерелә. Аларның көчен арттыру өчен, әсәрендә автор шул фикерне бирү элементларын төрләндерә бара. Шукшинчалык, ягъни әдәби-психологик уйдырмалык Ә. Гаффарда үз манерасы, язу стиле дәрәҗәсенә җиткерелә. Ул аны әсәрләрендә берничә юнәлештә куллана башлый. «Ир» хикәясендә, мәсәлән, ханымга бәйле бирелә. Имеш, гөмбә җыеп йөри кебек ул. Һәм әдип: «Нечкә зәвыклы икәнлеге сизелеп тора. Гөмбә җыю аңа театрга яки мәҗлескә

баргандагы шикелле бер тамаша, күңел ачу гына, ахрысы?» – дип белдереп ала. Әмма бу хатын чынында гөмбә җыю уе белән йөрергә тиеш түгел – укучыда шундый шик туа. Ә автор бу хакта сүз кузгатмый, бәлки мондый уй туугa этәрүче ишарәләрне генә бирә («гөмбә җыю аңа театрга яки мәҗлескә баргандагы кебек бер тамаша»), әмма вакыты да, көне дә гөмбә чорына хас түгел дип, ялгыш кына да искәртми. В. Шукшин исә ул хакта искәртер иде. Әмма Ә. Гаффар – Шукшинның үзе түгел, ул аның манерасында язуны иҗат кредосы итеп сайлап алган, шукшинчалыкка ирешә алган әдип. Хикәясендә автор бу ханымның, асылда, нинди максат белән йөргәнен белмәгәндәй итеп үзен күрсәтә. Монысы Ә. Гаффарның әдәби-психологик уйдырманы файдалануын укучыдан мөмкин кадәр яшерергә омтылышыннан шулай. Хәтта ахырында да әдип асылны ачмый калдыра. Укучы үзе дә, акылына һәм зиһененә, зирәклегенә бәйле, авторның бу серен әсәре белән бәйле уйланып йөргәндә генә сиземли ала, анализ юлы белән генә төшенә.

Ханымның муенында – алтын кулонлы чылбыр. Һәм ул умарталыкка кәттә генә карап тора. Мондый күренеш, әсәрне укыганда гаҗәеп бер картина рәвешенә китереп, күз алдына килеп баса. Ә. Гаффар әдәби тасвирларны төсле дә, тоемлы да ясап иҗат итә. «Умартачы хатын аңа кызыгып, көнләшеп, сокланып карап торды», – дип белдерә ул. Яланаяклы, ак халаттан, челтәр маскалы хәлендә аның каршында булуы игътибарга алына. Әмма Ә. Гаффар әсәрдәге бер бирелгән картиналарны кабат телгә дә алмый, хәер, күренешләрнең үзгәрешен бирми. Картиналар үстерелми, шуның нәтиҗәсендә югала бара. Шуңа да умартачы хатынның маскасын кайчан, нинди очракта салганын укучы белми дә кала. Бәлки, ул шул маскада хәлендә чәй эчкәндер? Автор мондый детальләргә игътибарлы булырга тиеш иде. Әгәр аның әсәрләрендәге тасвирлар, кайсы да булса бер язучыдан өлге итеп алынып, иярүдән генә туганнар икән, ул картиналар ясалма чыгар иделәр. Сурәтсез әдәби әсәр – яфраксыз агач сыман.

Ике хатын үзара карашып торалар. Умартачы «Йөрәкле Сөембикә» кушаматлы икән. Танышалар. Эшләпәле хатынның ире, машинасында хатынын көтеп утырасы урынга, каядыр китеп югалган.

Һәм ул монда бер-бер ирнең буталып йөрмәгәнме икәнлеген сорый. Иртәнге якта гына колхоздан завхоз, килеп, умартачылыктагы

эшләрне исәп-хисапка алып китkән. Ә бу затлы хатынның ире күн итек кигән, күн курткалы, шакмаклы күлмәктән, ди. Машинасы – зәңгәр төстә. Шуны юып кына куясы булган.

Алга таба сөйләшүләреннән Сөембикәнең иренең элекләрне эчкәләгәне беленә, алары да олы эш башкаргач кына булган, анысы. Сәбәпсез түгел. Ә хәзер?.. Хәзер алар аерылышканнар.

Гөмбәче хатынны Сөембикә чәйгә чакыра. Ире Сәлимҗан исемле булган икән. Сагына, ярата ул аны. Әмма артыннан, эзләп, шәһәргә бармаячак. «Ирне үзең белән калдырырга ниятләп ялынуны ул яратуга иң зур хыянәт кылу дип белә иде», – дип яза автор, үзенең чын мәгънәдә асыл акыл иясе икәнлеген дә бу сүзләре белән раслап.

Ә. Гаффар, шулай итеп, әдәби-психологик уйдырманы, әдәбипсихологик манипуляция дәрәҗәсенә җиткереп, сюжет кору өчен дә, эчтәлекне серле итеп бирүдә дә уңышлы файдалана. Моңа ирешүдә тәэсирле сурәтләр, мәгънәле фикерләр белән укучы күңелен мавыктыра. Әдәбиятның бөтен хикмәте матурлык тудыру һәм кешелек дөньясын хисләр белән баетуда да түгелме соң? Бүгенге көндә әдиплек хикмәтен күпләр шунда күрергә мөмкиннәр.

Әсәрләрендә урыны белән Ә. Гаффар реалистик планга күчә, күпчелек очракларда романтизм вәкиле сыман яза. Бу аның шәхси үзенчәлеге генә түгел, гомумән дә социалистик реализм өчен дә, аның нигезеннән үсеп чыккан безнең татар постмодернистларына да хас. Шулай берничә планда язу әдәбиятта озак еллар тәртип ителде. Стильләр аерылмас хәлгә килеп буталдылар. Ә. Гаффар да әдәби геройларын вакыйгаларны әле читтән күзәтеп, күреп торучылар манерасында, әле күңелләрендәгене сөйләүне, уйларын бирүне алга чыгаруы белән реалистлардан берникадәр читләште.

Иҗатына хас булган реализм һәм романтизм синтезы әсәрләре вакыйгаларына һәм каһарманнарына авторның үз бәяләмәләре буларак та берләштерелеп алга чыгарылды. Шуның белән ул каһарманнарының күңелендәге уйларын ачып бирү агымына да тулысынча кереп китте. Моны инде шул ук стильләр синтезы буларак та бәяләргә була. Сөембикәнең уйларын да хикәядә ул шушы манерада тасвирлый. Хәер, ул үзенчәлеге алга таба башка әсәрләрендә дә еш кабатлана барып, Ә. Гаффарның реализмнан ераклаша баруын да күрсәтәләр. Әмма тагын да ассызыклыйбыз, асылда, каһарманнарының күңел монологлары объектив чынбарлыкның дәвамы һәм

фәлсәфәсе төсен ала. Әдип шушы рәвешендә формалашып җитә, зур романнар тудыру алынуы да шул чорына карый.

Умарталыкта очрашкан бу ике хатын тәмләп чәй эчәләр. Берберсен якын күреп, хәтта ошата, дус итә үк башлыйлар. Сөембикәнең ике бала үстерүе дә беленә. Бу гөмбәче хатын кибетче булып эшли икән.

Бу әсәр язылган ул чорда кибетчеләр халык арасында шактый өстен куелып, дөньяның кендегә дәрәҗәсендә хөрмәттә иделәр. Тормыш, сәясәт, иҗтимагый мөнәсәбәтләр тәмам алар кулына һәм идарәсенә күчеп бетеп бара иде инде. Сәүдәгәрчелек алар белән бәйле кабат борынлап, тормышта алар урнаштырган мөнәсәбәтләр һәм тәртипләр иҗтимагый-сәяси үзгәрешләргә этәрде, яңа иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләрнең төс алуына китерде. Кибетче тормыш-көнкүрештә төп таянычка әверелде. Алар илне 1990 елгы базарларга китерделәр.

Хикәядәге кибетче хатынның ахырда Ниса исемле икәнлеге укучыга да мәгълүм була, ул Ниса Хаковна икән. Кибет мөдире. Беренче ире дә булган, инде икенчесе белән тора. Беренчесе белән аерылышуга, бер машина алып куйган. Шул автомобиленә ирләр кызыгып, аңа ияләшә башлаганнар. Ә бервакыт кибетенә хезмәткә яңа йөкче эшкә урнаша. Хәзер менә шул ир белән яшиләр икән.

Алга таба вакыйгалар барышы шушы Ниса белән Сөембикәнең танышуларын сурәтләүгә корыла. Нисага Сөембикә ачыбал эчеп сыйланырга тәкъдим ясый. Советлар дәверендә мондый сыйланышу гамәле мактала иде, билгеле. Шунда Ниса: «Ярык тәлинкә шикелле әйләнүеннән туйганымны сизмәгәнме?» – дип уйлап куя. Аннары, бераздан: «Шушындый хатынны ташлаган ир аның кулына эләксәме, – дигән эчке уйларын, моңа өстәп: – Эһ бу тәкъдирен әйтер идем!.. Үзен ташлап китәрлек бер ир һәм шул ирнең аякларын кочаклап елый-елый, кал инде, кал, дип ялварырлык язмыш белән очраштыра алмады, хәерсез!» – дип, каршылыклы уйларын авторның искәртүләре – болар әдәби-психологик уйдырма-манипуляция алымы белән Ә. Гаффарның кирәгенчә оста эш итүендә бераз шик тудыра, сюжетка хилафлык ясый, уңышлы уйлап табылган форманың бозылып алуына китерә. Югыйсә бу Ниса, акыллы булгач, дөнья кендегә, монда Сөембикәне махсус рәвештә эзләп килгән, аның ирен, Сәлимҗанны, үзенә караткан-

нан соң, нинди кеше икәнлеген, аңардан алга таба нәрсәләр көтәргә мөмкинлекне чамалар өчен хәйләләп йөрергә тиеш иде. Ул бер дә гөмбә җыя торган кеше түгеллеген автор ничә кат әйтте түгелме? Димәк, болай йөрүенең башка сәбәбе булырга тиеш! Аннары, гөмбә чорымы инде?

Шушындый урыннар, башка әсәрләрендәге кебек үк, авторның иҗат манерасына әверелгән әдәби-психологик уйдырмаларда акцентларның дөрес куелмавы хакында ачык сөйлиләр, әсәрләренең җитәрлек кадәр уңышлы эшләнелгән булуларында шик тудыралар. Алар, аңлашыла, артык, хәтта сюжет-вакыйганы да, форманы да, эчтәлек бөтенлеген дә бозалар. Әгәр боларны автор аңлы рәвештә, алай кирәк түгеллеген белеп эшләсә һәм шулар артында аерым әдәби максатларны күздә тотса, аның язу манерасын аклап булыр да иде. Әдәби-психологик уйдырма-манипуляция Ә. Гаффарның үз табигый таланты җимеше түгел, бәлки башка әдипләр иҗаты өлгеләреннән тулысынча аңлап бетерми алынган сыйфаты икәнлеген мондый фактлар ачык күрсәтеп торалар түгелме? Фикерләмәне бу рәвешле корганда, Ә. Гаффар табигате белән ясалмалыкны бергә кушкан, моны иҗат эше буларак күзаллаган әдипләребезнең берсе кебек күзаллана башлый. Һәр әдипнең башкалардан өйрәнергә, хәтта аларның әдәби алымнарын файдалана белергә хакы бар. Әмма чын әдип үз талантының табигый үзенчәлекләрен барлауга һәм аларның табигый үсешләренә һәммә көчен диярлек сарыф итәргә бурычлы. Башкалардан өйрәнү үз хаталарыңны тану һәм алардан арыну өчен кирәк ул.

Хатыннар ачы бал эчеп алалар. Бу һәммә яктан килешле кибет мөдиренең ире ни өчен мескен булуын уйлый Сөембикә. Аны өенә килеп кергән сары мәче белән дә чагыштыра. Мәчегә консервы савытына салып сөт бирә. Шунда ул хәтта, ни хикмәт, ташлап киткән ире Сәлимҗанның кайнаган сөт яратканын да исенә төшерә.

Инде хәзер әсәр вакыйгалары барышы бераз үзгәрә. Нисаны ире эзли. Машинасыннан төшеп, аны чакырып дәшә.

Нисаны озата чыкканда, Сөембикә аңа ярты литрлы банкада күчтәнәчкә бал бирә. Ханым шунда аның маңгаеннан үбеп ала. Ниса артыннан Сөембикә көнләшеп карап кала.

Аңлашылып та өлгерә: Нисаның ире шушы авылныкы булган икән. Танышларын да очраткан. Кибетләре ачылмыйча торган.

Ниса артыннан бусагада озата калган Сөембикә машина янындагы кешенең ташлап чыгып киткән үз ире Сәлимҗан булуын танып кала. «Авылда ул балаларын очратмаган, ә кешеләр Сөембикәнең умарталыкта эшләгәнен әйтмәгәннәр иде», – дип яза автор һәм шушы рәвешле әсәрнең формасын һәм сюжетын тәмам гадиләштереп, беркатлылык белән нокталап куя. Әдәби затлылык бозылырга өлгерә. Ахырда Сөембикәнең төне буе мендәрен чылатып елаганын да искәртә, аңардан мескен кеше ясый. Болары ук – артык, әлбәттә.

Бу хикәясен, сизелеп тора, Ә. Гаффар ике төрле сулышта язган. Аның беренчесе ханымнарның чәй эчүләренә бәйле урында киселеп кала, икенче өлеше ачы бал эчү күренешләре тәэсирендә язылган. Хикәяне гүяки ике төрле әдип иҗат иткән. Беренчесендәге ачышлар, сокландырулар, әдәби-психологик уйдырма-манипуляция, икенчесендәге уй-хискә бирелү, әдәби-психологик номенклатура ахырда үзара укмашып китә һәм бергә әвәләнә.

Ә. Гаффарның таланты үсешендә шушы ук 1980 елда язылган «Ир» хикәясе икенче чорга күчешен һәм аның нинди юнәлеш алуын ачык күрсәтеп торучы әсәре дә булып чыккан.

3

Әдәбиятта «пьеса» дигән жанр юк. Ул – сәнгати төшенчә. Әдәбиятта драма жанрлары бар. Сәхнә алардан үз таләпләре нигезендә пьесалар ясый. Әдәбият белеме пьесалар аша драмаларга бәя бирми, аның белән сәнгать белеме шөгыльләнә. Әдәбият белемен драма әсәре (әдәби әсәр буларак, билгеле) кызыксындыра. Драма әсәрен пьеса дип белдерү сәхнәләштерелгән әдәби әсәр күздә тотылганын кайбер очракларда онытып җибәрәләр, хәтта теоретик фикерләмәләргә дә китереп кертәләр. Әдәбият фәне өчен драма әсәренең сәхнәдә уйналуы яки уйналмавы игътибар үзәгендә тора алмый һәм ул драма әсәрен сәхнәдә уйналуына карап бәя бирми. Пьеса, драма әсәреннән аермалы буларак, бөтенләй башка эффектлар тудыру көченә ия була. «Зәңгәр шәл», «Галиябану» әсәрләре, пьесалар буларак сәхнәләрдә уйналып, бөтенләй дә башкачарак эчтәлекләр алдылар түгелме? Хәлилнең аягына чабата кидереп, аңардан ярлы крестьян ясап та уйнадылар. Әмма әсәрнең үзендә, сәхнә вариантларыннан аермалы буларак, хәтта вакыйга-күренешләр дә аермалар бар, алар текстның пьесада кыскартылып

алынуларына бәйле дә килеп туалар. Әдәби әсәрләр нигезендә киносценарийлар язылган кебек, пьесалар да эшләнелә.

«Язлар моңы» әсәренең пьеса дип аталуы да драманың сәхнә өчен яраклаштырылуына ишарә итә. Күренешләр яңа ел алды, буранлы, кышкы салкын көннәр хронотобында төзелгән. Туй килә. Әмма көтелмәгән хәл: Сәгыйдулла карт үлгән. Туй белән җеназа – бер үк көнне. Урамның бер очында – бәйрәм, икенчесендә – җеназа. Бу вакыйгалар куелыгында сүзләрне шактый төрләндереп кузгатырга була, әдәп-әхлак мәсьәләләрен дә җентекләп тикшерергә мөмкин. Яхшы сайлап алынган каршылык, әмма фикерләрнең авыр хәбәрләргә корылачагы тоемлана. Автор вакыйгаларны шушы каршылыкта чишелешкә кадәр алып бара алырмы? Әгәр дә уңышлы үстерә алмаса, каршылыклар ясалма кебек тоелачаклар. Килеп туган мәсьәлә куертылып, персонажлар имеш-мимештән дә артык күпне сөйлиләр, аларның ул сүзләре тамашачыга халык йоласы һәм күзаллавы буларак тәкъдим ителә. Әмма алар ни шәригатьтән, ни гореф-гадәттән түгелләр, һәр абыстайның үз шәригате формасын алалар. Әсәр белән танышканда, әгәр дә йола һәм шәригать мәсьәләләреннән хәбәрдар түгел икәнсең, аларны хакыйкатькә саныйсың. Билгеле булганча, туй җеназага, җеназа туйга комачау итми, әгәр бер үк йортта булмасалар. Татар әдәбиятында шәригатькә бәйле хакыйкатьләргә әлегә шактый зыян китерелә, язучылар диндә һәм гореф-гадәттә булмаганны бар итеп күрсәтүдә шактый маһирлар.

Ә. Гаффарның «Язлар моңы» дип аталган повесте да бар. Анысын 1973 елда ук язган. Ә пьеса 1977–1978 елларда иҗат ителгән. Икесе дә язучының 2016 елда Татарстан китап нәшриятында бастырылып чыгарылган «Сайланма әсәрләр»енең дүрттомлыгына кертелгән. Монда аның «пьеса» дип куюы үзен аклый. Димәк, повесть нигезендә сәхнә әсәре язылган.

«Язлар моңы» повестеның күләме бер табактан артмый, хикәя жанры кысаларында иҗат ителгән, әмма авторның хикәяләреннән тасвири үзенчәлекләре белән берникадәр аерылып тора, стиле белән повесть манерасындагы хикәяләргә тарткан әсәрләреннән берсе.

Әсәрдә төп вакыйга Җидегән авылында бара. Фәрданә карчык элекләрне, Бөек Ватан сугышы вакытында, ире Сәгыйдулланың һәлак булу хәбәреннән соң авылдашы Ярмигә кияүгә чыккан

булган. Дөрес, әсәрне укыганда моның шулай булганлыгы башта аңлашылып та җитми.

Автор монда әдәби-психологик уйдырманы үзенчәлекле юл белән, күренешләргә тартым вакыйгалар алмашында үстереп алып бара. Күбрәк хискә, холык үзенчәлекләренә басым ясый. Хәер, әдәби-психологик уйдырма вакыйгаларын башкача төзеп тә булмыйдыр кебек, әсәрдән шундый хис кала. Укучы, аңлаудан бигрәк, әдәби әсәрнең тәэсир көче йогынтысын кичерә, аңлаудан бигрәк, хисләнүгә таяна, тойгылар моңын үзләштерә. Моның өчен Ә. Гаффар үзенчәлекле әдәби тел сурәтләү чарларын да уңышлы таба. Аны укучы шук, бераз буталчык тасвирлар теле белән иҗат итүче язучы буларак кабул итә. Аңарда неологизмнар да, җирле сөйләм элементлары да, индивидуаль ясалма сүзләр дә, әдип Р. Батулла әсәрләрендәге кебек, үзенчә, үзенә генә билгеле һәм укучы өчен дөрестер сыман тоелган ясалма сүзләр дә кулланылышта йөри. Әмма алар белән артык мавыкмасын гына! Андый ясалма тел укучы күңелендә көлке хисе тудырмый калмый.

Әдәби теле белән Ә. Гаффар кайвакыт шук, үртәлчек малайларны хәтерләтә. Катлаулы драматик вакыйгамы, гайре табигый хәлме, көлкеле очракмы – һаман да шундый әдәби-психологик уйдырмага корылган тел белән эш итүе язучыны үзенчәлекле ясаган. Шуңа да аның әсәрләре берәүләргә ошый, икенчеләргә кызыксыздыр тоела. Язучы укучыны сайламый, укучы үз язучысын таба. Ә. Гаффарның ул сүзләре (мәсәлән, «тоба казанлыгы», «чүлмәк түбәле», «тормышның кияре», «кабык җеназа» һ.б.) чын татарча кебекләр (хәер, хәзер татар язучылары «колакка кереп калды» дип түгел, «колакка чалынды» дип язалар, «күзгә чалынды»ны «күзгә керде» дигән кебек), татар сүзләре калыбында ясалганнар. Гүяки адәм баласы яңа гына үз телендә сөйләшә башлаган да татар җөмләсенең, яңгырашы-аһәңенең матурлыгын ачкан. Бүгенге көн Казан яшьләрендә дә, ничек күңелсез, шундыйрак тел белән язу гадәттә түгелме соң? Аларның кайберләре «Ялкын» һәм «Сабантуй»да эшләделәр, ул матбугат органнарын укып та, аңлап та булмаслык иттеләр. Хәзер шул ясалма телне тагын да чуарлап, күп нокталы шигырьләр язучылар да телгә керә башладылар.

Ә. Гаффарның «Язлар моңы» повесте Сәгыйдулланың Фәрданәне гомере буена яратуы, аңа багышлап җыр чыгаруы һәм шуны

язгы ташуда бозлар кузгалган вакытта җырлап йөрүләре хакында шактый тәэсирле язылган. Сәгыйдулла сугыштан гармун күтәреп кайта. Хатыны Фәрданәне күрергә тау ягындагы басуга, урак уручылар янына менә. Гармунны аңа Фәрданә алып биргән. Сугышны ул шушы гармун белән бергә узган. Әмма Фәрданә, инде башка кешенең, Ярминең хатыны буларак, аны сөенеп каршы алмый. Авыр вакыйга. Сәгыйдулланың ел да бер тапкыр, яз аенда, моңга бирелүе Фәрданәне дә, ире Ярмине дә газаплый, аның йөрәк серләрен гармун уйнап ачып, авыл әйләнүенә хатыны Сара да риза түгел. Сәгыйдулла бу гамәленнән ваз кичәргә тиеш. Ул инде бу хисләреннән һәм гадәтеннән үзе дә туйган. Әмма берни дә эшли алмый. Язда, ташу кузгалган кичтә, аның хисләре күңел түреннән ташып чыгалар һәм гармун уйнатып, җырлатып урам әйләндерәләр.

Сәгыйдулланың ул вакыйгалары повестьта җеназасын озатуга бәйле сөйләнелә башлый. Фәрданә инде карчык кеше, аның ире Ярми дә вафат. Фәрданәдә фатирда яшь укытучы Люция яши.

Җеназадан соң Сара Сәгыйдулланың гармунын (җиз бакалы, сөяк телле, сыерчык оясы хәтле генә зурлыктагы яшел гармун), яулыкка төреп, Фәрданәгә китерә. Иренең васыяте шушылай икән. Аны сугышка кадәрле үк, көзен, Йөзем базарыннан ире Сәгыйдуллага Фәрданә сатып алып кайтып биргәнлеге дә искә төшерелә. Иске гармунын идәндә мүкәләп уйнап йөргән уллары Габделхариска бирәләр. Шул кичтә Сәгыйдулла яңа гармунында уйнап, авыл урамын әйләнә.

Фәрданә Басыйрова данлыклы тракторчы булган. Колхоз рәисе иптәш Габидуллин, трактор алып кайткач, анда эшләүне Сәгыйдуллага тәкъдим итә. Әмма авылның бердәнбер гармунчысы ул эшкә барырмы соң? Хатыны батыррак булып чыга. Беренче ызанны да басуда ул елны тракторда Фәрданә сала.

Сара чыгып киткәч, гармунда Фәрданә үзе дә уйнап карый. Фатирда торучы Люциянең егете, Шәүлегән Насыйрының уртанчы улы Хөрмәт, шунда килеп керә. Ул тракторчы икән. Ә пьесада Хөрмәт башка, ул – авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган белгеч. Люция анда да укытучы.

Бу ике әсәрне чагыштыргач, вакыйгаларның автор тарафыннан уйлап чыгарылган әдәби уйдырма булуын танырга мәҗбүрсең.

Андый чагыштырулары аркасында укучы авторга ышанмый башлый, аны хәтта ялганчылыкта да гаепләргә мөмкин. Укучыда Ә. Гаффарга, язучыга буларак, җиңел карау, мөгаен, шушы әсәрләре аркасында тугандыр?

Печәндә вакытта Сәгыйдулла абзый бер көй уйнаган, җырлаган. Анда Хөрмәт тә булган. Сәгыйдулла абзыйның җырын-көен шунда ук отып та калган. Гармунны алып, ул аны уйнап-җырлап бирә. Аннары Люцияне Яңа ел бәйрәменә кияүгә аласын әйтә, Фәрданә әбидән фатирда торып калырга ризалыгын сорый. Килешәләр. Хөрмәт чыгып китә.

Хикәядә вакыйгалар шулай бара. Ә пьесада Хөрмәт белән Люциянең туй вакыйгалары башлануы, шунда Сәгыйдулла абзыйның вафат булу хәбәре килеп ирешү картинасы күренешләрне ача. Ике әсәрнең тәңгәл килмәгән башка очраклары да шактый. Бу фактлар исә иҗат мәсьәләсенә кабат кайтырга, аны конкретлаштырырга мәҗбүр итә, пьесаның повесть нигезендә түгел, бәлки мотивларында төзелүе хакында белдерергә мөмкинлек бирә.

Сәгыйдулланың гармунын салып куярга Фәрданә сандыгын ача. Яшь чагында сабантуйда Сәгыйдулланың көрәшеп алган сөлгесе дә шушында икән. Әмма аңа көя төшкән булып чыга. Фәрданәнең хәтта кәфенлеген дә көя кискән икән. Монысын ул озын гомерле булуына юрый. Повесть шулай дәвам итә.

Яшьләр өйләнешәләр. Туй Фәрданә йортында була. Хөрмәтнең гармунда уйнавына бирелеп, Фәрданә оеп ала. Шунда Сәгыйдулла белән Ярминең арыш кырын чабуын, ә аларның кайсысы артыннан көлтәләп барырга белми аптырап калуын, югарыда тургайлар сайравын төш буларак күреп өлгерә. Арыш урган вакытта тургайлар сайрамый инде, анысы. Әмма төшендә кеше ни-нәрсә күрмәс, дисең.

Фәрданә әби черемennән айный. Әллә елап, әллә көлеп ала. Күз яше тәгәри. Шунда ул соңарып килгән бәхетен уйлый башлый.

Мондый финал аңлашылып җитми, укучыны саташтыра.

Ә. Гаффар аңлатып, ачыклап торуларны яратып бетерми. Ул серлелекне сөя. Моның өчен мистик күренешләрне, ярым шәүләләр белән сурәтләп алуларны гадәте итә. Хәер, башкача була да алмый. Әдәби-психологик уйдырмаларны бүтәнчә ничек төзергә мөмкин? Авторның осталыгы да шушында түгелме?

4

Повесть белән хикәянең аермасы күләмнәрендә генә. Повесть – шул ук хикәя ул, әмма вакыйгаларга баерак булганы, сюжеты озынгарак сузылганы өчен аны «повесть» дип атаганнар. Шуңа да бу жанрны «озын хикәя» дип күрсәтү очраклары да бар.

Ә. Гаффарның «Язлар моңы» повесте хикәя форматында булуын белдергән идек. Әмма, хикәяләре белән чагыштырганда, ул күләмлерәк күренә. Шушы күзәтүгә таянып, автор бары вакыйгаларның озынга киткәне өчен генә андый әсәрләрен повесть буларак атаганын белдерә алабыз.

«Яра» повестен Ә. Гаффар 1968–1973 елларда иҗат иткән. Аңа ул вакытта инде 20–23 кенә яшьләр булган. Әсәренең язылган урыны дип Ә. Гаффар туган авылы Әшнәкне һәм студент еллары узган һәм эшләгән җире Казанны күрсәтә.

«Яра» повестеның төп герое – Рахман, язучы. Әсәр вакыйгалары аның исеменнән сөйләнелә. Ул үзен «прәннек ашарга яратучы саран малай» буларак белдерә. Аның сөйгән кызы да булган. Зәңгәр күзле, Миләүшә исемле икән.

Автобустан төшеп калып, чемодан күтәреп кайтканда, Рахманга юлы уңаенда җигүле ат арбасында Галимҗан ага туры килә. Киртә тотарга яшь юкәләрне кисеп төягән. Тукталып, Рахманны да үз янына утырта. Сөйләшеп кайталар. Рахман үзенең язучы булуын әйтә. Ә Галимҗан ага аны газетада эшли дип белгән. Редакцияләренә колхоз председателеннән зарланып хат язган булган, менә шуңа бәйле уйлаган: фактларның дөреслеген тикшерергә кайтмыймы, имеш. Юк икән шул. Рахман ул эш белән йөрми.

Галимҗан ага элекләрне үзе дә колхоз председателе булган. Аның фамилиясе – Сираев.

Бервакыт Рахманның әтисе авырып киткән. Ә аннары вафат булган. Тормыш йөге Рахман җилкәсенә төшкән. Ул тау араларыннан печән чабып, аны киптереп, чүмәләгә куйган. Ә председатель Галимҗан Сираев аны ут төртеп яндырган. Чөнки колхозда эшләргә тиеш булган Рахман, шәхси хуҗалыгын кайгыртмаска.

Бу тормыш хакыйкате чынбарлыкка туры килә, чөнки советлар дәверендә колхоз председательләре шулай артыгын кылана торган иделәр.

Арбада кайтканда Галимҗан аганы Рахман кала күчтәнәче белән сыйлый. Эчеп үк алалар. Рахман шунда Галимҗан агага үзе язган китабын бүләк итә. Билгеле, мактау һәм хуплау көтә. Шуңа да бераздан соң Бакый, Вәсимә, Гарифҗан турында хикәяләрен укып бирә. Галимҗан ага андагы вакыйгаларның тормыштан алынган булуларын таный, чөнки аларда үзе дә катнашкан. Аңлый: шактый гаделсез кыланган. Хәтта әсәр каһарманнарының прототипларын да танып, исемләп әйтеп бирә. Хикәядәге Вәсимә чынлыкта Вәзирә икән. Аның үз хатыны. Ә Бакый, аңлашылганча, Рахманның әтисе булып чыга. Әмма укучы күңеле сагаеп кала. Алга таба хикәя әтисенең көндәшеннән улының үч алуы буларак яңгырый. Шул сәбәпле Рахманның күңеле чиста булып ачылмый, укучыны ул ятсындыра, хәтта чиркандыра башлый.

Бу вакыйгага кысаланган икенче әсәр дә бар. Рахман китаптан башка бер хикәясен укый башлый. Анда сүз Булат турында бара. Ул, сугышны узып, аннан соң да Сталин тоткынлыгын һәм лагерьларын күреп, авылына кайта. Әтисе – вафат, хатыны Вәзирә – кияүдә. Иртәнге кояшлы матур вакыт. Булат рәшәткә итеп тотылган койма аша Хисами Вәлиханы кызы Рәхимә белән күрешеп сөйләшә. Аны Вәзирә дип тоя. Монда автор, тойгылы сурәт алымына биреләп: «Аның күзе әлеге хатынның рәшәткә арасына туры килеп, юка ситсы күлмәк аша сизелеп торган калку күкрәкләренә төште», – дип, сәер тасвир да биреп ала. Ә. Гаффар – андый алымнарга оста әдип. «Чыбыркы бөгәлҗәсе», «чыңкый чын китап», «йөрәк сулка», «калай кружкасын мулкытып спирт салып эчте», «аңа аркан борылды», «әйтергә яскана» кебек, үзенә генә мәгълүм мәгънәләргә ия сүзләр белән монда да эш итә. Алар әсәрне түгел, бу юлы да авторның үзен көлке итәләр, әдәби теленең зәгыйфь булуын күрсәтәләр. Вакыйгаларны һәм геройларны әдәби сурәт һәм тасвирда бирү урынына тел уйнатып, ясалма чукландыру-чуарландыру белән авторның мәшгуль булуы аркасында, алар шулай килеп чыгалар. Зәвыксызларга матур, хәтта искиткеч сыман тоелачаклар. Андыйлар беркатлы шаккатыруларны яратарак төшәләр шул.

Әсәрне укыганда, тагын да сәерсенеп куясың: Булат белән Вәзирә бер генә тапкыр да үзара хат алышмаганнар. Ире сугышка киткәч, хатыны аны сагынмаганмы? Табигый күренешләрнең мантыйгы автор күзеннән төшеп калган, шуңа да мондый урын-

нар укучыны аптыраштa тота, вакыйгаларга бәйле сораулар да туа. Әдәби әсәрнең көче тиз юкка чыга. Андый эпизодлар бу повестьта гына очрамый, кабат-кабат үзләрен күрсәтеп, Ә. Гаффарның иҗат йөзен хасил итүләрен сиздерәләр.

Булатның яшьлек мәхәббәте Вәзирәне Галимҗан кияүгә алган икән. Ул хәтта үз куллары белән Булатның үле гәүдәсен сугыш кырында җирләп калдыруы турында ялган хәбәр тарата. Шулай раслап сөйләгәч, аңа ышанмый мөмкин булмый. Ә ялганы ахырда, Булат авылга кайткач кына ачыла.

Галимҗан хакында автор баштарак «бер челләдә теләгенә иреште» дип язса, аннары, икенче бер урында, «кичке бөркү һавада» дип искәртә, Вәзирә исә аны: «Туймас тәнеңдәге сөлегеңне минем йөрәккә каптырдың», – дип әрли. Бу соңгысы бигрәк буталчык төзелгән җөмлә, аны аңлавы да кыен. Әгәр ул шунда: «Минем йөрәгемне тәнеңдәге туймас сөлегеңә каптырдың», – дип язса, башкачарак булыр иде. Яки инде: «Тәнеңдәге туймас сөлегеңә минем йөрәгемне каптырдың», – дисә? Юк, алай ярамаган, ахрысы? Чөнки ул очракта сүзләр тезмәсе Ә. Гаффарча килеп чыкмаячак.

Әсәрдәге печән вакыты сурәтләнгән вакыйгаларда аҗаган уйнавы күренешләре искәртелү исә арыш җитлеккән, уракка төшкән чакта печән чапканнармы соң болар дигән фикергә укучыны этәрә. Полковник Григорьев Павел Юрьевич, сәер фантазияләр иясе буларак тоелса да, Булатның әсирлектә бәла-казаларга тармавында төп таянычы итеп искәртелә. Сугышка кадәр Булатны гаепсезгә төрмәгә яптыруда да төп сәбәпче – Галимҗан, аның кушканнарын үтәгән Мәүләви күп төрле этлекләр кылып өлгергән икән. МТС директоры Рәүф тә, әсирлектә чагындагы удмурт егет Табейкин да әсәрдә гадел, дөрес кешеләр буларак бәяләнәләр. Болар барысы да Галимҗанның чын йөзен ачу өчен вакыйгалар барышында автор тарафыннан әсәрдә махсус телгә алынуларын укучы җиңел төшенә. Дөрес, Рахман үзе укып таныштырган әсәрнең мантыйклары, сурәтләре шактый йомшак, беркатлылар, хәтта мәгънәсез дә кебекләр. Шулай да әдип вакыйгаларны очын-очка ялгап барырга омтылуы белән шактый тырышлык күрсәткән. Бу әсәр татар әдәбиятының уңышы була алмаган, аерым әдәби чорга хас мотивлардан төзелгән повестьларыннан берсе буларак, тарихи әдәби күренеш сыйфатында гына телгә алынырлык дип билгеләнелергә

мөмкин. Галимҗан Сираев мәкерле, кара йөрәкле, начар гамәлләр иясе буларак әсәрдә ачыла. Автор төсләрне йомшартырга тырыша, шул сәбәпле бераз буталып та алгалый. Галимҗан ага, өенә кайтып, шушы очрашу тәэсирендә мылтыктан атылып үлә. Аны, димәк, Рахманның китабы үтергән. Китапның катилче ролен алуы, инквизиторлык рухында язылуы әдәби миссиясенә шактый олы зыян сала.

Ә. Гаффар бу әсәре белән әдәбиятны хөкемче роленә куюы белән әхлакый хата ясый.

Шулай да авторның кысаланган кыйссалар форматын, урта гасырларга хас әдәби форманы яңартуы кызыклы. Әмма аны камил әдәби тәртиптә үстереп җиткерү осталыгына ирешмәвен дә билгеләп үтәргә кирәк. Сюжетны җыясы урынга, бу форма әсәрне таркаулыкка китергәнлеге сизелеп тора.

5

Әдәби әсәрдәге тасвир һәм сурәтләр әгәр дә дөрес, вакыйгакүренешләргә ятышлы түгелләр икән, аларга детальләштерүгә хилафлык китерүче төсмерләр дә кушылса, әдипнең фикерләренә дә, нинди генә гадел булмасыннар, ышанычны юкка чыгаралар. Ә. Гаффар «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» романы башлам өлешендә болай дип яза: «Кәүсәриянең кәфендә биләүдәге бала төсле ятканы күз алдыма килде. Кара чәче толымлап үрелгән, шуңа күрә ап-ак маңгае өчпочмаклы хатка охшап калган». Шунда ук, кәфендә хатын-кызның яулыклы булуын, хәтта чәче дә, маңгаеның чәч өлеше дә яулыклы (пәрәнҗәле) булуын белмичә яза дип, күңел киселеп һәм сыкрап куя. Кәфен ул табут түгел шул. Гомумән дә, шәригатьне белмичә, гореф-гадәтләрне санга сукмыйча язылган хезмәтләрнең кадере була алмый. Әле холык-психологиядә, вакыйгалар бирелешендә, каһарманнарның төс-кыяфәтләрен тасвирлауда укучы күңелен ияртергә була, әмма фактик материал сурәтләүдә анық белән шаярырга ярамый. Ә. Гаффарның каләме уйнакларга ярата һәм бу аның әсәреннән-әсәренә шулай, иҗат манерасы булып киткән.

Бу роман сугымга куылучы үгезләрнең көтүләре белән күпергә куылып кертелүләре вакыйгасы тасвирыннан башланып китә. Кара «Волга» (мондый автомобиль совет заманнарында олы түрәләр-

не генә йөртә иде) шоферы Исмәгыйль һәм аның хуҗасы Иман Иманович Зәйнушин аларның үтүен күзәтеп, иткә озатылулары хакында сөйләшеп алып, юллары ачылуны көтеп утыралар. Бу да тегермәндә он ителәчәк бодай бөртеге белән аваздаш күренешләрдән берсе инде дияргә кала укучыга.

Урман аша узгач, юлларында бер авыл буласы икән. Иман аганың яшьлеге шунда калган. Моннан кырык биш ел элгәре, Каманың уң ягындагы шул авылда бер турбиналы электр станциясе салуда җитәкчелек иткән ул. Беренче мәхәббәте Кәүсәрия авылның иске зиратында җирләнгән.

Иман Иманович шунда юнәлә. Әмма, әүвәлдә, ул су буена төшә. Аяк киемнәре көрән түфлиләрен салып калдырган. Көрән костюмнан, пинжәген, элгеченнән тотып, аркасына салган.

Ә. Гаффар матур сурәтләр биреп, мәгънәле фәлсәфәләр коруга күчеп-күчеп алгалаганда, аларны күңелгә ятышлы итеп оста тасвирлый. Әсәре укучыга шушы урыннары белән үз булып өлгерә.

Су буенда электр станциясенең буасыннан калган соңгы субайны электр пычкысы белән кисеп маташкан Каһирга туры килә Иман Иманович. Алар бер-берсен танып та өлгерәләр. Иман Иманович Таш чишмәгә төшә. Аякларына киенеп алган булуын ул «кар түгел, чын күннән тегелгән түфлием шулай шыгырдый икән» дигән җөмлә белән генә искәртә. Аның кайчан яланаяк, кайчан аяк киемле икәнлеген инде шәйләми башлыйсың. Авторның матур сурәтләрне фактик мәгълүматларга нигезләргә тиешлеген исәпкә алып бетермәвеннән бу шулай.

Каһирның Кәүсәрия һәлакәтендә гаепле булуы хакында да, аның моңа кан белән түләве дә ике арада булган сөйләшүләрендә беленә. Электр станциясе инде җимерелгән, сүтелгән икән. Хәзер Каһирның улы Таһир трактор белән киләчәк, егерме субайны алып китеп, баз ясаячаклар.

Иман Иманович шушы таныш сукмаклардан йөрүләрендә Кәүсәрия белән очрашкан кебек олы тойгылар кичерә. Автор бу хыялый күзаллау вакыйгасын намус кузгалуы белән бәйле сурәтләп бирсә, әсәре сәхифәләре тагын да тәэсирлерәк булырлар иде. Моның өчен Кәүсәрия һәм Иман арасындагы әңгәмә бирелеше киң мөмкинлекләр ача. Әдип аның табигый килеп тууын намус көче аша аңлатканда, шактый мәгънәле эшләр иде. Ә болай – ни саташу,

ни күзаллау түгел. Әдәби әсәрдә эчке мантыйк вакыйгалар барышы белән идарә итәргә тиеш түгелмени?

Бу роман төп герой авызыннан сөйләнелгән рәвештә, романтизм калыбында язылган. Асыл вакыйгалары өченче бүлектән башланып китәләр. Иман Иманович Казанда рабфакны тәмамлаган да Мәскәү югары уку йортында энергетика инженеры һөнәренә өйрәнә, ягъни, диплом алгач, электр станцияләре төзүче-инженеры булачак икән. Имтиханнарын яхшы билгеләргә биреп, Казанга ялга кайта, Такташ кичәсендә була, театрга бара. Тормышлар җиңел чор түгел. 1929 ел бу. Тарихтан яхшы мәгълүм, бу елда, нәкъ җәй айларында, татарга латин язуы кертелә, «Солтан-Галиев эше» яңартыла, «атласичылар» атыла, кулакларны Себергә сөрү баш ала. Кулаклар белән көрәш хакында искәртүләрдән тыш, калганнары хакында әсәрдә ярты сүз дә юк, ишарә дә ителми. Ә Иман, студент, бераз акча эшләп алырга дип, тире-күн фабрикасына (югыйсә завод булырга тиеш инде ул) эшче буларак ялланырга килә. Әмма наркоматтан Әбҗәлиловны очраткан булган, аңа да барып күренергә вәгъдә иткән. Шунда юнәлә.

Нарком аның язмышын башкача хәл итә, Иман Имановичны авылга бер турбиналы электр станциясе төзергә билгели. Монда аңа кадәр Рамазанов эшләгән. Әмма аны кулаклар үтергәннәр. Иман Иманович аның урынына эшкә алынырга тиеш.

Балык Бистәсе районында мөһерле пакетны Иман Иманович кырыс кеше итеп үзен күрсәткән секретарь Мирсәяф Янышевка тапшыра. Ә. Гаффар, вакыйгаларны очерк стилендә һәм очерк характерында тасвирлаганда, ышанычлырак һәм үтемлерәк яза. Әсәр нәкъ шул рухта бара да. Романның агышы матур, вакыйгалар мантыйгы да андый урыннарда төзек. Очерк тибында язу манерасы татар әдәбиятында бигрәк тә В. Нуруллин повестьларында 1970 еллар ахырында, 1980 еллар башында көч алган иде, М. Мәһдиев дә ул стильдә иҗат итүне яратып өлгерде. Андый формалар 1920–1930 еллардан татар әдәбиятында көч алганнарын да искәртергә тиешбез. Ул манерада язу бүгенге татар әдәбиятында да яши. Мәсәлән, К. Кәримов, Р. Кәрами әсәрләре шул рухта төзелә, Г. Гыйльмановның хәтта уйдырма хикәяләре дә күп вакыт очерк формасын алалар.

Очеркларга матбугат теле хас. Газета-журналларга бастыруга тәкъдим иткәндә, язучылар, хәтта әдәби журналларга да, әсәрләрен

матбугат теленә якынайтып эшләп китерергә мәҗбүрләр. Бу тенденция күптән безнең милли басмачылык үсешендә аерым, кызыклы бер күренеш алды.

Матбугат теле – әдәби телнең бер юнәлеше ул. Сурәтләп язуның, тасвири көчнең сөйләп бару юлына кереп китүе әсәрләрне җиңел аңлаешлы, йөгерек телле итә. Сурәтле язмаларның күңелне алҗыту үзенчәлеге бар. Әмма бу хәл әдипнең талант дәрәҗәсенә бәйле һәм аның мәртәбәсен ачык күрсәтеп тора. Талантлы әдәби әсәр, публицистикадан аермалы буларак, күңелне үстерү көченә ия була. Матбугат теле белән иҗат иткән әдипнең әдәби таланты дәрәҗәсен билгеләү мөмкин түгел. Талантлы әдип матбугат теленә мәҗбүрият аркасында гына күчә. Чөнки аның каләме белән эчке куәте идарә итә. Шунлыктан ул матбугат теленә авырлык белән генә күчеп ала.

Бу яктан Ә. Гаффар бөтенләй башкача бәяләнергә тиешле. Татар әдәбиятында әгәр дә Г. Бәширов, Ә. Еники стиле бар, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Т. Галиуллинча язучыларыбыз да җитәрлек дип, киштәләрдәге китапларны төркемләп тезгән кебек, аларның да иҗатларын үзара янәшә куя барсак, икенчесенең шактый күбәя барган тау рәвешен алуын күрербез. 1970 еллардан гына түгел, электән, 1920 еллардан татар прозасында сурәт стиле түгел, сөйләм юлы өстенлек алуын кат-кат искәрербез. Хәер, борынгы һәм урта гасырларыбызга бәйле әдәби ядкярләрдән Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыфы» да, Габделхәлим Төркестаниның «Мәликә китабы» да, Шәмсетдин Таразиның «Кисекбаш китабы» да шундыйлардан иделәр. Бездә сурәт сирәк күренеш булды. Сурәтле язылган булулары аркасында, Дәрдемәнд шигъриятен Г. Ибраһимов мактап югарыга чөйде. С. Рәмиев әсәрләреннән ул хисне сөйләү осталыгын яңалык буларак күрсәтеп атады. Бу юнәлештә язылган Һ. Такташ әсәрләренең яңгырашы сүрелмәс дәрткә әверелде. М. Җәлил шигъриятендә сурәтле язу соңарып өстен чыга барды, Н. Исәнбәт иҗатында да шул ук юнәлештә үзгәреп алулар күзәтелде. Әсәрләрендә Ә. Гаффар сурәт бирү белән публицистик бәяләү алымнарын бер эзгә кертү юлларын табарга тырышты. Әмма ул да, М. Әмир кебек, һәр әсәрендә диярлек әле сурәтләүгә, әле сөйләп баруга гына күчә алды. Әмма чынлыкта алтын белән көмеш үзара карышкан кебек килеп чыкты.

Район җитәкчесе секретарь Янышев белән Иман Иманович авылга барырга тарантаста юлга чыгалар. Җитәкче үзен шактый җаваплы һәм җитди тота. Ул флотта хезмәт иткән. Диңгездә үзен кеше итеп тойганлыгын, ә җирдә тормышның күпкә катлаулырак булуын юлда барышлый сөйли. «Ә халыкка торырлык диңгез юк әле ул. Давыл кузгаткан дулкыннарга каршы торып була, ә халыкка каршы торып кара син!» – дип тә сөйләп, яшәеш хакындагы үз фәлсәфәсен аңлата бара.

Авыллар да иң шаулы диңгез кебек икән. «Көрәш хәзер фронтлардан ерак шәһәрләргә, аулак авылларга күчте», – ди ул. Шушы сүзләре белән чын большевик булуын ача. Чын диңгез белән халык диңгезе үзара тәңгәл куелу авторның образлы фикерләвен аңлауда кайбер урыннарда комачаулык тудыра. Шунда ук сораулар куясы килә. Чын диңгездә үзен ышанычлы тоткан кеше халык диңгезендә ничек башкача булыр икән? Хәер, Янышевныкы кебек фәлсәфәләрне советлар чоры укучылары ярата иделәр.

Янышев, тельняшкасын салып, Иман Ивановичка бүләк итә, эссе тәнендә тузуын тели. Аннары гына барасы авыллары, андагы крестьян халкы, бай һәм урта хәллеләрнең бүре, ярлыларның төлке кебек булуларын аңлата, иртәгәге көннең ничек туасын көтеп яшәүләрен әйтә.

Романда алга таба вакыйгалар электр станциясе салыр өчен урынны барлау, Рамазановның үлеменә китергән сәбәпләрне ачыкларга тырышу, эш барышы белән бәйле мәсьәләләр хакында тасвирлар белән бергә үрелә. Әмма хезмәт батырлыгын сурәтләү бөтенләй дә юк. Автор авыл халкын барлауга, сыйнфый мәсьәләләр белән бәйле күренешләрдән милли күзаллауларга, уй-хис каршылыкларына күчә барып яза, алар арасында М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романындагы күренешләрне хәтерләткән фәлсәфи фикерләмәләрне дә бәянлап ала, шуларга ияреп, асыл вакыйгалардан, нәкъ менә станция төзелеше күренешләреннән шактый ерагая. Хезмәттә кешеләрнең чыныгу алулары, фикерләре ачылу, яңа тормыш төзү мәгънәләренә төшенү тасвирлары бирелергә тиеш иде. Алар урынына автор көндәлек тормышның башка якларына игътибар итә, дошманнарны барлау һәм эзләү белән мәш килә. Югыйсә барысы да хезмәт процессында һәм шул хезмәткә мөнәсәбәттә мәгънәле булып ачылырлар иде.

Әдәби геройлар фрагментлар рәвешендә бирелү дә әсәрнең йомшак ягы икәнлеген ассызыкларга кирәк. Иман үзе дә, төп әдәби каһарман буларак, шул бәяннар эчендә төссезләнеп кала. Роман аның теленнән сөйләнгән вакыйгалардан төзелсә дә, эчке уйхисләре, кичереш-тойгылары дөньяны аңлау һәм аңлатуы, иҗтимагый көчне танытуы, бәяләве үзенчәлекләрен күрсәтү ягыннан да әсәр канәгатьләнерлек түгел. Укучыдан Иман ул яктан бөтенләй дә бикле калдырылган. Шулар сәбәпле каһарманны һәм әсәр вакыйгаларын аңлауда һәм кабул итүдә икеләнүләр туа. Акыллы гына кеше булып тоелган Иман Иманович, әсәрдәге кайбер тасвирларда бөтенләй дә эшсез каңгырып йөргән сәер кешене хәтерләтә. Ул кирәкмәгәнчә пассив һәм хистән артыгы белән коры калган кеше. Әсәрнең таркау, сюжетсыз төзелүенең сәбәпләре дә Иман Ивановичның вакыйгаларны, хәтереннән алып, истәлек итеп сөйләве тәртибендә корылуыннан килә. Шунлыктан автор үзенә объектив булырга урын калдыра алмаган. Кайсы гына героен сурәтләмәсен, алар бары тик Иман Иманович күзлегеннән генә бәяләнә һәм ачыла баралар. Аннары, аның кешеләргә мөнәсәбәте дә тигез түгел. Бу исә вакыйгаларның башыннан ахырынача шулай бара.

Әсәрнең жанры «роман» дип куелса да, формасы ягыннан ул повесть форматында язылган. Аны шуңа да озын хикәя буларак аңлату дөрес булыр иде. Ул – Иман Имановичның тормышы хикәясе. Истәлекләре күп вакыт һаман да бер үк урыннан башланалар, әле Каһир Сафинга бәйле сөйли ул аларны, әле Кәүсәрия белән булган хәлләрен искә ала, әле башкасын. Бу формада, истәлекләр кысасында, аерым шәхесләрнең тормышына һәм холыкларына, яңа кеше буларак үсешләренә бәйле яхшы хикәяләр тудырырга мөмкин булыр иде. Югыйсә әсәр материалы үзе үк шушыңа этәрә. Әмма Ә. Гаффар ул юлны да сайламый. Роман геройлары берсе дә шәхес буларак ачылмыйлар, бәлки журналистик бәяннар хәлендә калалар. Дөрес, аларның кайсылары, бирелгән тормыш вакыйгасына бәйле бәяләнгәндә, төп геройдан өстен дә булып чыгалар. Автор моны күрми калмаган, шуңа да аларны тулы канлы итеп сурәтләүдән читләшкән. Иман Имановичның күзлегеннән карап авторның аларны мөмкин кадәр бәянлап бирүен башкача аңлатып та булмый.

Әсәрдә хезмәт вакыйгаларының бөтенләй булмавы сәер, дидек. Укучыны бу хәл аптыраашта калдыра. Электр станциясен төзиләр

түгелме? Менә шул күмәк хезмәт батырлыкларын сурәтләү урыннары әсәргә, соралса да, җитми. Бу исә «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» әсәрен бәйрәмчәлек төсендә язылган әсәр буларак бәяләүгә китерә. Куелган исеме дә сәер, романнарга хас түгел кебек тоела.

«Язлар моңы» әсәрләрендәге кебек, монда да автор мистик образларга мөрәҗәгать итеп, совет әдәбиятында ул чорда урнаша барган сәер күзаллаулардан берсе – рухлар белән сөйләшү, аларга мөрәҗәгать итү белән мавыга. Мифик затларны уйлап чыгару ягыннан өлгерлек күрсәтүе, аларга идея, фикер йөкләргә омтылыш Ә. Гаффарның да әдәби эзләнүләреннән берсе икәнлеге күренеп тора. Әмма алар укучыны кызыксындырырлык дәрәҗәдә, әсәрнең эчтәлеген хасил итүче элемент сыйфатында эшләнелмичә, әсәренә өстәмә мәгънә тыгызлыгы бирергә омтылу белән бәйле генә тудырылганнар һәм Ч. Айтматов иҗаты тәэсирендә барлыкка килгәннәр. Шунлыктан алар органик, табигый түгелләр, бәлки артык әдәби элемент буларак бәяләнә алалар. Дөрес, «Язлар моңы» әсәренең пьеса вариантында мистик образлар әсәрнең төп элементы төсен алалар, эчтәлекне хасил итүдә турыдан-туры катнашалар. Югыйсә ул 1979–1984 елларда язылган «Тегермән ташы һәм бодай бөртеге» романыннан берничә ел иртәрәк, 1977–1978 елларда иҗат ителгән. Автор андагы уңышын монысында кабатлый алмаган.

Ә. Гаффар иҗатына тулы бәя биреп шуны әйтергә кирәк: ул үзенең табигый талантыннан елдан-ел читләшә барган әдипләребезнең берсенә әверелгән. Аңарда әдиплектән китү, публицист була бару көч алган. Әсәрләре теленә гади сөйләү манерасы җәелә барып, ул ахырга таба тасвирлау осталыгын да югалткан. Соңгы елларда бөтенләй үк язмавы шулар белән бәйле, билгеле.

## 6

Әсәрләрендә матур әдәби сурәтләр бирү ягыннан язучы Әхәт Гаффар беренче хикәяләреннән үк үзенең укучыларын тапты. Әдәби күренешләрендә төсләрне тойдыра белүе беренче иҗат үрнәкләреннән соңгыларына кадәр җетелеген саклады һәм уңмады. Алар никадәр чуар булсалар, шулкадәр уңышлылар буларак кабул ителделәр. Әдәби вакыйгаларны төзүдә, каһарманнарының сурәт-портретларын бирүдә ул кадәр үк каләменә таләпчән карама-

са да, күренешләрдә һәм мохитне тасвирлауда Ә. Гаффар каләме үз көчен җуймады. Хәтта очеркларында һәм очерк тибындагы әдәби әсәрләрендә дә әдип тасвирлауларга бирелеп-бирелеп ала белде. Аның каләменә хас шушы үзенчәлеге елдан-елга үсәргә, ныгырга, иҗатында киңәергә тиеш иде, әдәби вакыйгалары үзләренә күрә бер ямьле тасвирга әверелеп китеп, каһарманнары шушы зур һәм киң мәйданлы картиналарда затлы сурәтләр буларак бирелүен укучы олы өмет белән көтте. Аның «Әҗәт», «Ир» хикәяләре, «Гозер» повесте, «Олы юлның тузаны» романы шушы юлда үсеше күрсәткечләре иделәр. Ә. Гаффар бар өметләрне дә аклады кебек. Әмма иҗатта үсеш тә сикәлтәләрсез була алмый. Әдип һаман да эзләнергә, каләме көчен төрле юнәлешләрдә сынап карарга мәҗбүр шул.

Прозаик, публицист һәм драматург буларак әдәбият мәйданында 1970–1980 еллардан танылу алган Әхәт Гаффаров – Габделәхәт Габдерахман улы Гаффаров, 1949 елның 1 гыйнварында (ә чынлыкта исә 1948 елның 23 декабрендә) дөньяга килә[1]. Бу гаиләдә бары тик язучы ир балалар гына туган, диярсең. Ике энекәше дә әдәби иҗат эшен үз итәләр.

Туган авылы – Татарстанның Балык Бистәсе районы Олы Әшнәк. Көньяктан, Кама елгасы буйларыннан киң иркен тигезлек, шаулы кырлар, болыннар булып Олы Әшнәккә килеп җитәләр дә биек яр булып калкулыклар хасил итәләр. «Яшиселәр алда иде» повестенда (1985) әдип туган авылын болай тасвирлый: «Арьякта авыл көтүе йөрер өчен сукаланмый калдырылган озынча болын. Кара-каршы торган үрләр арасындагы тар иңкүлеккә кереп киткәнче, ул болында иртәләрен авыл көтүе таралып, чемченеп ала, көне буе колхозның ат көтүе утлап йөри. Болынның теге ягындагы үр кашы буенча таш юл сузылган. Ерак офыкны күгелҗем урман чикли. Уң кул якта – авыл. Ә елга буенча түбән төшеп китсәң, кичү юлын һәм ерак ерганакны үткәч, тагын бер болынга килеп чыгасың. Аның түрендә – сигезле санын хәтерләткән буынтыклы сай күл. Ул болынга барып чыксаң, таулар белән инеш арасындагы

---

[1] Язучының тормыш һәм иҗат юлына бәйле төп материаллар мәкаләгә «Әдипләребез» китабыннан алынды. *Карагыз:* Әхәт Гаффар // Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда. – 1 т. / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – Б. 383–385.

киңлектә каласың. Тауларның итәге җәенке, түбәләре тоташ тигез. Анда – югарыда – иген басулары, иңкүлекләр, үрләр, авыллар»[1].

Ә. Гаффар үскән елларда Олы Әшнәкнең табигате искиткеч ярлы булып, авыл тирәләре хәтта бөтенләй шәрәләнеп калган чаклар икән. Шушы ярлы табигать кочагында әдипнең дөньяны күзаллавы тернәкләнә. Инешкә төшеп балык каптырырга омтылу, урманлыкка җиләк һәм гөмбә эзләп барулар, колхозда балачак вакытлардан башлап җиң сызганып эшләүләр – болар һәммәсе аның күңелен үстерүдә, хыялларын киңәйтүдә үз рольләрен башкарганнар. Язучының тормышны аңлавы кече яшеннән гаделсезлекләрне тануы һәм алардан өстен чыгарга омтылышы белән бәйле үсә һәм ныгый. Кулында каләмен ышанычлы тибрәтә башлагач иҗат иткән әсәрләрен укыганда ук, укучы аның ул тойгы-хисләре белән кат-кат очраша. Әдипнең гаилә эшләрен кайгыртып чиккән хәсрәтләре гаделлек тойгысын тагын да ныгыта. Язучыларның күңелен биләгән балачак хатирәләре – гомерләре буе сөйли торган каләм кебек алар. Шуңа күрә дә Ә. Гаффарның да рухы иртә өлгерә, аңа тормыш хакыйкатьләрен таныта башлый.

Олы Әшнәктә сигезьеллык мәктәптә укып, Олы Солтан авылына тугызынчы, унынчы сыйныфларга укырга йөреп, 1966 елда Ә. Гаффар урта белем алып чыга һәм Казанга килә, Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетындагы журналистика бүлегенә укырга керә. Моңа кадәр берничә язмасы белән иҗат көчен сынап караган яшь егет университетта уку елларында әдәби иҗатка ныграк тартыла. Әмма әсәрләрендә публицистик алымнар, хәбәр бирү, хәбәр сөйләргә омтылыш көч ала бара. Студент еллары Ә. Гаффарның үз каләме юнәлешен, иҗат алымнарын эзләү һәм барлау еллары булалар. Аның язмаларында характерларга штрихлар, вакыйга-күренешләргә бәя бирү һәм аларны иҗтимагый әһәмиятләре ягыннан танып, күрсәтеп яза белү хас икәнлеге күренә. Алар аңарда язучылык сәләте көчле булуы хакында сөйлиләр. Ә. Гаффар журналистикадан язучылыкка күчә бара. Моңа ул әдәби тасвирлар бирүдә эзләнүләре сәбәпле ирешә. Алар, хәбәрләр бирү белән бергә, әдәби чигенешләр ясап алу формасында күзәтеләләр.

---

[1] *Гаффаров Г.Г.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – 2 т. Повестьлар, романнар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 9.

1971 елда Ә. Гаффар университетны тәмамлый һәм «Яшь ленинчы» газетасында хәбәрче булып эшли башлый. Ул чорда яшь язучылар төрле матбугат органнары тирәсендә туплана. «Яшь ленинчы» газетасы, «Ялкын» журналы, «Татарстан яшьләре» яшь каләмнәрнең чарлану үзәкләре булалар. Кичке якларда әдәби бәхәс белән озатылган утырышуларга читтән дә иҗатчылар тартылалар, студентлар да килә. Әдәби әсәрләргә яшьләрчә үтә катгый бәяләр бирүләр белән бергә, каләм ияләренең үзләренең дә аң-белем, кешелек сыйфатлары исәпкә алына. Ә күп очракларда әдәби әсәрләрне түгел, язучыларын бәяләү өстен чыгарыла барып, аларга төрле ярлыклар тагу, шул ярлыкларына карап фикер йөртү дәвере шулай башланып китә. Әдәби тәнкыйть тә шул юлга баса, әдәби анализны иҗат портретлары төзү алыштыра. 1970 елларны шуңа да «шәхесләр дәвере» дип атау хәерле. Ул шаулашуларның дулкыны 80 нче елларга да күчеп, дулкыннарының көченнән бигрәк, шаулары хәтта XX йөз ахырына, XXI гасыр башларына кадәр ишетелә торды. «Торгынлык чоры» дип тарихта үз исемен тапкан ул елларны шәхесләр дәвере буларак характерлау сәбәпсез генә түгел. Бу елларда эш-гамәлгә түгел, кешегә табыну өстенлек алды. Шуңа да вакыйгаларны күрү түгел, шәхси мөнәсәбәтләрне бәянлау матбугатны күмеп китте, шәхеснең кемлеге аңа мөнәсәбәттә билгеләнә башлады. Ә андый бәяләү тиз генә үзгәрә алмый. Язучы Ә. Гаффарның иҗат манерасы шул дәвер кысаларында формалашты һәм һәр әсәре, вакыйгаларны ачу, килеп туган мәсьәләләрне күрсәтү һәм чишү юлларын барлаудан бигрәк, шәхесләрне тасвири сурәттә бирергә омтылу белән язылдылар. Әмма бу шәхесләрнең прототиплары гади һәм вак кешеләр иделәр. Шушы елларда «кечкенә кеше фәлсәфәсе» темасы кабат тернәкләнгән иде. А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис бу юнәлештә төп локомотив көчләргә әверелделәр. Гади кешегә дан җырлау тарихи шәхесләрне барлау һәм аларны «кечкенә кеше фәлсәфәсе» нигезендә бәяләүдән башка мөмкин түгел иде. Шуңа да татарның легендар тарихы вәкилләре алар иҗатында мөмкин кадәр гадиләштерелделәр. Мондый фәлсәфә күзлегеннән бөеклекне бәяләү тормыш барышын гадирәк итеп аңларга юл ачты. Бу исә әдәбиятта һәм җәмәгатьчелек алдында чыннан да яңа сүз иде. Бөек Әлмәндәр карт шушы фәлсәфә эчендә тудырылды. «Кечкенә

кеше фәлсәфәсе»н яңартучы әсәр татар әдәбиятында Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыяте» иде. Иске фәлсәфә аңардан башлап бөтенләй яңача ачыла башлады.

«Кечкенә кеше фәлсәфәсе» илдә ул елларда көчле иҗтимагый яклау тапты, хәтта аның эчке сәясәтенә һәм тәрбия эшенә әверелде. Шул нигездә шәхес концепциясе кабат эшләнелеп, тарихны халык иҗат итә дигән теория гадиләштерелеп аңлатылды, шәхеснең ихтыяри роле бөтенләй диярлек арткы планга калдырылды. Ә. Гаффарның әсәрләренә хас төп үзенчәлекләр, хезмәт процессы һәм аның нәтиҗәсен бәяләүнең аларда бөтенләй булмавының сәбәбен менә шушылардан күрергә була. Иҗатында вакыйга бирүгә, сюжет коруга Ә. Гаффар бервакытта да игътибар итмәде, аларга мохтаҗ да булмады. Ул беренче әсәреннән үк шулай башлап китте, бу яктан М. Галиев белән бер адымда иде. «Казан утлары» журналының 1972 елгы 10 нчы санында Ә. Гаффарның беренче хикәясе басылып чыкты. Ул «Әҗәт» дип атала иде.

Ә. Гаффар бу хикәясен 1980 елда берникадәр тасвирлауларга баетып кабат эшләгән һәм 2016 елда Казанда басылып чыккан дүрттомлык «Сайланма әсәрләре»нә керткән[1]. Шул хикәягә бәйле фикерләрен белдереп, язучы В. Нуруллин: «Әхәт Гаффарның бу хикәясе мәктәп дәреслекләренә, хикәяләр антологияләренә кертелде һәм ул инде иң зур сынауларны үтте: берничә тапкыр рус телендә Мәскәү нәшриятларында һәм дөнья халыклары телләрендә басылды. Һәм һәркайда югары бәя алды»[2], – дип яза. Бу фактлар язучының татар әдәбиятына керткән уңышы буларак та бәяләнергә хаклы. Әдәби тәнкыйть тарафыннан үз вакытында ук бу хикәя кат-кат шулай югары бәяләнә[3]. Язучының тасвирларны әдәби югарылыкта бирү таланты чагылганын аның мисалында төгәл күрсәткәннәр.

[1] *Гаффаров Г.Г.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – 1 т. Хикәяләр, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 136–146.

[2] *Нуруллин В.* Талантлы әдип // Гаффаров Г.Г. Сайланма әсәрләр: 4 томда. – 4 т.: Публицистика, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, очерклар һәм панфлетлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 559.

[3] *Карагыз: Мостафин Р.* Төптәнрәк уйлаганда // Казан утлары. – 1977. – № 1. – Б. 157–158; *Сверигин Р.* Төсләр һәм кешеләр // Казан утлары. – 1982. – №7. – Б. 165–167.

Хикәянең төш мотивына корылуы кызыклы. Мәрьям әби адәм йөзле козгынны күрә. Аны ничек һәм нәрсәгә юрарга да белми. Сөйләргә ахирәт дусты Галимә әбигә керә. Шунда әҗәте барлыгы хакында ишетә, әмма бу юрауга ышанасы килми.

Бөек Ватан сугышы чорында булган хәл икән. Мәрьям әбинең Нәкыйп исемле улы, сугышта яраланып кайтып, йорт арасында эшләрне карап, шулай эш арасында савыккач, фронтка кабат китеп барган. Шунда аңа, аннан-моннан юл ризыгы хәстәрләп, күршеләреннән бер ипи алып торган булганнар. Нәкыйп ул икмәкнең яртысын биштәренә салган, әҗәтне үз өстенә калдырырга кушып, кайткач түләячәген белдергән. Әмма ул кире әйләнеп кайтмаган, сугыш кырында ятып калган. Козгынның кычкыруы менә шул әҗәтне таләп итүе икән.

Мәрьям әби икмәкне күршеләренә түләргә тиеш. Шул нияте белән ипи пешерә. Аны, куенына алып, күршеләренә кертмәкче. Әмма гамәлен ахырынача башкарып чыга алмый. Капка төпләрендәге сөян агачына барып утыра. Кертә китергән икмәкне күкрәгенә кыскан хәлдә үлеп китә. Аны иртәнге савымга баручы кызлар күрәләр.

Бу әсәр кечкенә кешенең әхлакый бөеклеге турында, олы фәлсәфи мәгънәгә ия. Мотивлары белән ул рус язучысы В. Шукшинның «Письмо»[1] хикәясенә тартым. В. Шукшин хикәясендә Кандаурова әби төш күрә, аны төшләр юрауга маһир Ильичиха әбидән юрата. Юраганы белән башта килешми. Аннары башыннан узган вакыйгалар аның хаклы булуын таныргa мәҗбүр итә. Бу хикәянең ахыры әбинең үлеме белән тәмамлана. В. Шукшин әсәре дә, Ә. Гаффарныкы кебек, кечкенә кешенең әхлакый бөеклеге хакында.

Ә. Гаффарның бу хикәясендә үк каләме вакыйганың үзенә түгел, бәлки каһарманының тормыш-көнкүрешенә, әйләнә-тирәсе күренешләренә игътибарлы булуын күрсәтә. Язучы тасвирлау остасы югарылыгында ачыла. Автор моның өчен әле Мәрьям әбинең күңел дөньясына туры китереп, аның уй-хисләрен белдереп яза, каһарманы күзләре аша тормыш ваклыкларына һәм очраткан кешеләренә бәя биреп бара, әле, киресенчә, читтән торып, әдәби героеның үзен бәянлый, аның кәҗәсен, бәтиләрен, казларын, песиен

[1] *Шукшин В.* Охота жить: рассказы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – С. 46–51.

каләм очына ала. Тасвирлары матур һәм әдәби яктан килешле, мантыйклы килеп чыгалар. Әмма алар тасвирлар гына, әсәрнең эчтәлеген хасил итмиләр. Ә менә Мәрьям әбигә тыкрык башында очраган яшь кыз Зөбәрҗәт, әсәрдә башта тасвири деталь булып кулланылса да, ахырда эчтәлеккә берегә. Ул Мәрьям әбинең үле булуын беренче булып танып ала. Төшләр мотивы исә хикәядә шулай ук үзен аклый.

Әдәби әсәрдә тасвирлар да мотив рәвешен алганда, аның әдәбилеге югары дәрәҗәдә булуы хакында сөйлиләр. Импрессионистлар моңа зур игътибар биргәннәр. Алар да вакыйга-сюжетсыз язганнар. Мотивларның югары дәрәҗәдә әдәби эшләнеше әсәрләрен көчле иткән. Ә. Гаффардагы бер тасвири деталь икенчесен алыштырып, яңалары искеләрен оныттырып бара. «Әҗәт»нең яңа редакциясендә дә автор моңа игътибар итмәгән. Тәнкыйть тә бу яктан фикерен әйтми калдырган. Шушы сәбәпле тасвир әдипнең иҗатында бәянлап бару үзенчәлеген алган. Иҗатының буеннан-буена бу сыйфаты дәвам итеп, язучының төп иҗат манерасы булып калган.

Талантлы яшь каләм иясе буларак үзен «Әҗәт» хикәясе белән күрсәтеп кенә калмыйча, алга таба Ә. Гаффар журналист буларак та танылу ала. «Яшь ленинчы»дан «Социалистик Татарстан» газетасына хәбәрче булып күчә, ә аннары «Казан утлары» журналына бүлек мөхәррире эшенә алына. Шул рәвешле, ун эл эчендә, 1970 еллар буена, ул талантлы каләм буларак танылып өлгерә, укучыларның яраткан язучысына әверелә. Шушы елларда аның «Яра» (1973), «Язлар моңы» (1973), «Гозер» (1975), «Кашан җыры» (1977), «Су астындагы чишмә» (1980), «Бишек» (1981) әсәрләре басылып чыга. 1975 елда «Әҗәт»[1], 1978 елда «Гозер»[2], 1980 елда «Бер йотым су»[3] китаплары дөнья күрә. Әдәби тәнкыйть аның китапларына игътибарлы кала һәм әсәрләрен югары бәяли.

«Яра» повестен әдип 1968–1973 елларда иҗат иткән, университетта укыган елларында яза башлап, соңыннан, журналист булып эшләгән чагында тәмамлаган.

---

[1] *Гаффаров Ә.* Әҗәт: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 127 б.

[2] *Гаффаров Ә.* Гозер: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 168 б.

[3] *Гаффаров Ә.* Бер йотым су. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 208 б.

Повесть сулар һәм вакыт агышын сөйләгән фәлсәфә белән башланып китә. Әдәби герой үзен давылга каршы очкан нәни карлыгач итеп тоя. Бу уе аңа скрипка моңы тәэсиреннән икән. Ул – Рәхимов Рахман, аның сөйгән кызы – Миләүшә. Рахманның әтисе яшьлегендә Миләүшәнең әнисе Вәзирәне яраткан булган да, әмма аны Галимҗан, мөмкинлектән файдаланып, үзенеке иткән.

Бу повестьта автор күңелгә ятышлы тасвирларны гадәтенчә еш бирә, табигать күренешләрен идиллик сурәтләр белән баетып матурлауда барлык осталыгын күрсәтә. Әмма әсәрнең корылмасы булган вакыйгаларда Рахман үчле, тискәре холыклы кеше буларак ачыла. Повестьта бер генә уңай герой да юк. Алар арасында хәтта Вәзирә дә күңелсез төсләр эчендә кала. Матур тормыш күренешләрен, ихлас тантаналарны караңгы тәэсирләр, ризасызлык, әрнү алыштыра бара. Рахманның ярасы шуңа да төзәлми, ачык кала. Әсәр шушы прәннек яратучы малайның үсеп җитеп, язучы буларак, үткәндәге үпкәләүләре-үпкәләтүләре өчен үч алуы хакында, шуларны сөйләп, күңелне сагайтуга корылган.

Шул ук 1973 елда язылган «Язлар моңы» повестенда да бу мотивлар чагылыш таба. Әсәр сугыштан ирен көтеп алмаган хатыннарга хөкем сүзе буларак яңгырый. Фәрданә карчык, аңарда фатирда яшәүче яшь укытучы Люция, шушы кызга гашыйк Хөрмәт тормышка ышаныч белән карыйлар. Сәгыйдулла вафат була. Аның белән Фәрданә карчык бәхилләшергә өлгермәгән булган. Сәгыйдулланың хатыны Сара иренең гармунын Фәрданәгә кертә. Васыяте шулай икән. Сәгыйдулла гомере буе Фәрданәне яраткан. Ташулар кузгалган кичне гармунда уйнап урам әйләнү гадәте булган. Әмма бу гамәле белән хатыны Сараның күңелен ватуын башына да кертә алмаган.

Люция белән Хөрмәт, мәхәббәтләренә тугры буларак, яратышып кавышалар. Бу әсәрендә Ә. Гаффар тормышчан, гадел хөкем ягында тора. Тормыш сынауларын һәммә кеше дә күтәрә алмый, сынатканнарны таптарга, җиңүчеләрне мактарга да урын юк икәнлеген аңлый башлыйсың. Ә. Гаффарда үч алу фәлсәфәсе шулай чишелә. Бу – кечкенә кешеләрнең тормышы, анда югары идеалларга урын юк, димәк. Моны әсәр вакыйгалары барышында төшенергә туры килә.

«Гозер» повестенда автор бу рәвешле фикер йөртүләрдән читләшә дә кебек. Әсәрдә төп вакыйга Әҗмәх авылыннан Җиһангир

картның сыеры үлү, яңасын сатып алырга теләп эзләве белән бәйле тасвири күренешләр каһарманның эчке монологларына төрелеп үстерелә. Җиһангирны юлы Җәмәлҗән авылына илтә. Кыш уртасы вакыт. Бу рус авылында элекләрне Җиһангир бер булган да инде. Ат йөге белән печән алып кайтышлый, буранлы төндә Гафиатулла белән, аерым фатирлар табып, кереп кунганнар. Җиһангир Наталья исемле тол хатынга фатир төшә. Аңа дүрт пот печән калдыра. Ире Константин Леушин белән бергә сугышта йөргәннәр. Җиһангир аның алдында гозерле булып калган. Коля үзен аның исәнлегенә корбан иткән. Үтенече буенча, ике гаиләнең дә терәге, ышаныч йөге Җиһангир җилкәсенә калдырылган. Әмма ул бу гозерне үтәми калдыра.

Һәм менә аңа сыерны Натальядан сатып алырга туры килә. Ул шунда Коляның гозерен үтәмәве өчен гафу да үтенергә җай эзли. Барысын да сөйләп бирә. Аннары, үз авылына кайтышлый, төнгә калып, Натальядан сатып алган сыерын бүреләр талап, куып алып китәләр. Җиһангирның бүре белән сугышуы да мыскыллану гына булып чыга. Ә. Гаффар әсәр вакыйгаларын бер тезмәдә, берсен икенчесенә йөкләп, тыгыз итеп төзи. Тасвирларны әдәби яктан камил дәрәҗәдә матур итеп алып бара. Бу әсәре авторның әдип буларак җитлеккән булуын күрсәтә, повесте уңышлы чыккан. Ямьсез төртелеп торган чагыштырулар да анда сирәк очрый («Ертык балактан чыгып торган тез башы шикелле, болыт сәләмәләреннән ай кырые күренгәли» ишеләр хакында искәртүебез)[1].

Тасвирлауларга бай бу әсәрендә Ә. Гаффар геройларының портретларын тулы чагылдыруны кирәк тапмаган. Шулай да вакыйгалар барышында берничә урында укучының бу яктан кызыксынуларын канәгатьләндерерлек сурәтләрне очратырга була. Башка әсәрләрендә андый урыннар бөтенләй юк. Җиһангир картның олы гәүдәле, олы куллы булуы телгә алына. Алары да бик ипле, очраклы рәвештә генә, тасвирларны биргәнендә чагылып китәләр. Аның кабак башлы, чәче кыркылган икәнлеген дә улы Александрга Натальяның әйткәннәреннән генә белеп каласың. Болар бу юлы да әдипнең тасвирда осталыгын күрсәтәләр югыйсә. Тик ул каһарманнарының портретларын бирү белән бәйле мондый осталыгын баш-

[1] *Гаффаров Г.Г.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – 1 т. – Б. 513.

ка әсәрләрендә сирәк кулланучан. Каһарманнарның характерлары ачылуда портрет аерым роль уйный. Автор моны сәбәпсез игътибардан читтә калдырып язу манерасын сайлаган.

Әманәткә тугры булмау темасын «Гозер»дә әдип шактый мәгънәле итеп тасвирлый. Тормышның авырлыгына мәсьәләне аударып калдыру хакында ул уйламый да. Каһарманын хәтта хөкем дә итми. Повестьның әдәби өстенлекләре шул үзенчәлегенә дә бәйле. Әмма бүреләр белән сугышу вакыйгалары һәм аннан соң булган хәлләр ышандырырлык итеп сурәтләнмәгән. Аннары, бер дә бүреләр вакыты дип әйтерлек еллар хакында сүз бармый. Җитмәсә, күптән түгел генә үлгән сыерын үләт базына илтеп калдырганнар. Бүреләр шул үләт базы яныннан үтеп китәләр. Ә бу хәл мөмкинме соң? Бүре иң тәүдә үләткә ташланучан ул. Аның табигатьтәге роле-миссиясе шул түгелмени? Бүреләр вакыйгасын автор повестька кертмәскә дә мөмкин иде югыйсә. Әдәби-эстетик, идея-фикер ягыннан да ул артык гыйбрәтле түгел. Җиһангирның батырлыгын расларга тырышумы бу, әллә шәхесен мескенәйтүме – аңлашылмый. Төп мотивлар белән бәйләнеп баруы ягыннан ул үзен аклый да кебек, әгәр дә аңларга-аңлатырга бик тырышсаң. Ә көтмәгәндә колхоз рәисенең Җиһангирга буаз сыер бирдерү карары – бусы инде әсәрдәге ясалмалык элементын тагын да көчәйтә. Шулай да, боларга да карамастан, «Гозер» повесте Ә. Гаффарның иң уңышлы иҗат өлгесе буларак бәяләнергә тиеш.

1977 елда әдип «Кашан җыры» повестен яза. Ә. Гаффар анда очерк стилен файдалана, каләменең көчен шул юнәлештә дә сынап карый. Студентларның авылларга фольклор җыярга чыгулары вакыйгалары үзәккә алынып, Бәхтияр исемле егетнең маҗаралары тирәсендә повестьның сюжет сызыгы сузылган. Мәгънәле фикерләр тарихка, халык күңеленең тирәнлегенә бәяләмәләр белән сугарылган бу әсәрендә язучы тормыш чынбарлыгын төрле яклап сурәтләп баруга ирешә. Повесть авторның башка әсәрләреннән стиле белән генә түгел, фикер бирү ягыннан да аерылып тора, аның әдәби үзенчәлекләре алга таба язган романнарында урыны-урыны белән кабатлана. Бу повесте белән башка төрле әдип, башка бер Ә. Гаффар кебек тә күзаллана.

Вакыйгаларны кызыклы итеп сөйләүгә күчеше аның «Бишек» повестенда да ачык чагылыш тапкан икән дип, әсәрнең беренче

бүлеген зур кызыксыну белән укыйсың. Бу юлы ул тасвири вакыйгалар бирүгә ирешкән, дисең. Җор тел, бизәкле һәм бормалы тасвирлар белән бергә үстерелә барган вакыйга-күренешләр әсәрнең башыннан ахырынача үзара үрелеп килерләр сыман. Бу әсәре язучының чираттагы уңышы булып чыккан кебек тоела. Грек мифологиясенә бәйле фәлсәфәләре повестьның ахырынача матур гына сузылырга тиеш иде югыйсә. Аит исемле каһарманның туган йортына хатыныннан аерылып кайтуы, тормышка Троя сугышы вакыйгалары аша каравы сәер дә, кызыклы да, хәтта берникадәр көлкеле дә. Әмма кызганыч, болар барысы да беренче бүлектә генә оешкан, табигый итеп эшләнелгән тасвирлар икән. Алга таба, повестьның башка бүлекләрендә бу әдәби матурлыклар онытыла, сүнә, Аит белән Сөмбел мөнәсәбәтләре генә калдырыла. Ә алар ялангач тойгылар белән сурәтләнелгәннәр, тасвири мәгънәләрне тәмам күмеп китәләр. Беренче бүлектән соң, алга таба бары тик коры вакыйгалар тезмәсе генә кала, маҗаралыкны төртмәле әйтешү-әйткәләшүләр алыштыра. Сөмбелне Аит янында үртәлүе тота. Ир, моны аңлагандай, коры, үчле һәм үртәләк халәтен саклый.

«Бишек» повестеның эчтәлегенә бәйле фикерләрен белдереп, Т. Галиуллин әсәрнең баналь вакыйгаларга корылуын, ышандырмавын белдерә һәм «Ә. Гаффар тулаем бик динамик язучы булса да, урыны-урыны белән озын, буш һәм тасвирлы сөйләм юлына төшә»[1] дип аңлата. Аитның авылдагы күршесе Мөкатдис белән бәйле вакыйгаларында да автор урыны-урыны белән тасвири күренешләр һәм әдәби чигенешләр ясап ала. Аларда аның язучылык осталыгы кабат тернәкләнә. Үсеп китүенә өметләнәсең. Аитның әтисенең фронттан язган хатлары табыла, аларның җылылыгы әсәрне үз эзенә кертер сыман. Әсәр ахырында Аит үзен туган йортына килеп кергән һәм аны туздырган Троя аты буларак танырга мәҗбүр була. Ә Мөкатдис – хатыны Солтаниянең әтисе икән, анысы да ахырда гына укучыга белдерелә. Бу повесте язучының нәрсә язарга белми иҗат итү манерасына корылган. Кызы Солтаниядән Мөкатдис хат китерә. Аны ул Аитка атап язган. Алмагачларны яңартып утыртырга кушкан. Шунда гына Мөкатдис кияве Аитка Солтаниянең шушы

[1] *Галиуллин Т.Н.* Әхәт Гаффаровның «Тәңре юлында» исемле кулъязмасы турында // Галиуллин Т.Н. Сайланма әсәрләр: биш томда. – 4 т. – Казан: Эш, 2013. – Б. 512.

иртә генә йөрәге тибүдән туктаудан үлүен хәбәр иткән телеграмма алуын белдерә.

Бишек ул – Җир шары икән. Аит, Солтаниянең әти-әнисе белән бергә, хәзер самолетка ашыгырга тиеш. Повесть шулай тәмамлана. Аны әдәби яктан өстен куеп булмый. Әсәрен Ә. Гаффар язучылык осталыгыннан баш тарткан кебек язган.

Шушы иҗат чорында мәйданга куйган хикәяләрендә Ә. Гаффар тасвирлау үзенчәлекләрен бозмый саклый. «Зәңгәр яулык» (1970), «Соңгы сүз» (1970), «Кояшның салкын чагы» (1971), «Ләкләк» (1973), «Пәрәвезле көзнең бер чите» (1975), «Ак каен дегете» (1975), «Гальери» (1976), «Акчураның җир үбүе» (1976) хикәяләре әдәби тасвир үзенчәлекләре белән төрлечәрәк язылганнар. «Әҗәт» повесте кебек югарылыкка «Ир» (1980) хикәясе ия. Бу чорда әдип әдәби вакыйгага бирү, сюжет төзү авырлыкларын кичерә. Әсәрләре күпчелек очракта хәбәр бирүгә, тасвири хәбәрлекләргә корыла яки очерк рухына кереп китә. Боларын күңел дөньясының журналистик эшчәнлек җирлегендә формалашып җитүе белән бәйле генә аңлатып була.

1982 елдан Ә. Гаффар журналистикадан китеп тора. 1982–1987 елларда Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасына, 1987–1990 елларда СССР (Россия) Культура фондының Татарстан Мәдәният фондына (Казан) җитәкчелек итә. Һәм менә шул ук 1987 елдан матбугат хезмәтенә кабат әйләнеп кайта, «Шәһри Казан», аннары «Ватаным Татарстан», аннан соң «Мәгариф» газеталарында эшли, «Казан» журналына күчә. Бераздан «Мирас» журналында әдәби хезмәткәр, бүлек мөхәррире була, С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында әдәби мөхәррир эшен башкара. Шул вакыт эчендә «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» (1983), «Яшиселәр алда әле» (1987), «Олы юлның тузаны» (1989), «Дәрья башы» (1995), «Богау» (1998) повесть һәм романнарын иҗат итә. Мулланур Вахитов шәхесенә бәйле «Сызылып таңнар атканда» (1984), Муса Җәлил турында «Хөкем» (1986), Г. Тукай тормышыннан итеп күзаллап «Соңгы сәгать» (1986) драмаларын иҗат итә. Бу әсәрләре вакыйгалары ясалма һәм схематик килеп чыгалар, сәхнәгә күтәрелсәләр дә, озак яшәмиләр. Ә. Гаффар Әфганстанда Совет Армиясенең канлы сугышларына бәйле «771 аршын җир» (1991) очерклар китабын да яза. Андагы язмалары бу гаделсез сугышка һәм аны оештыручыларга хөкем буларак та яңгыраш алалар.

1983 елда тәмамлаган «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» романы вакыйгалары әсәрнең төп каһарманы Иман Имановичның истәлекләре формасында бәян итеп алып барыла. Бары тик романның башында һәм ахырында гына вакыйгалар автор күзлегеннән бирелә.

Бу роман татар авылы тормышының иң катлаулы чорын, колхозлашуның беренче елын, 1929 елны чагылдыра. Ул елда Татарстан тарихында кискен үзгәрешләр була. Латин әлифбасына күчү, солтангалиевчелекне һәм туранчыларны хөкем итү, кулаклар белән көрәш башлану вакыты бу. Бәлаләр халык өстенә бер-бер артлы яудырыла. Гүяки аны тураклап һәм өзгәләп аталар. Әсәрдә боларның күбесе хакында бөртек тә сүз юк. Анда җирле электр станциясе салуга бәйле вакыйгалар сыйнфый көрәш ноктасыннан чыгып бәянлана. Хәтта хезмәт стихиясен һәм удар төзелеш өстенлекләрен сурәтләү дә максат ителми. Каһарманнарның үзара мөнәсәбәтләре иске тормыш калдыклары һәм кулаклар белән көрәшнең ясалма төсмерләре, милли каршылыклар мәсьәләсен кузгаткалап алулар белән сугарыла, татар һәм рус халыклары «безләр» һәм «сезләр» ярлыкларын ала. Әсәр вакыйгалары, күпчелек очракларда схематик, очерк корылмасы тибында бирелүгә карамастан, темага авторның яңачарак якын килергә омтылышы сәбәпле, укучыда кызыксыну тудыру көченә ия. Әсәр ахырында аңлашылганча, әсәр язылу чорындагы партия һәм удар төзелешләр җитәкчелеге бу романнан күпне өмет иткән, авторга, әсәрнең үзендә белдерелгәнчә, «һәр Чапаевның үз Фурмановы» мөнәсәбәтен күрсәткән. Очерклар стилен түгел, тасвири юнәлеш юлын сайласа, Ә. Гаффарга әсәре киң танылу китергән булыр иде. «Сайланма әсәрләре»ндә автор бу романын 1979–1984 елларда иҗат итүен күрсәтә[1].

1985 елның мае-июнендә, Әлмәттә яшәп иҗат иткән чорында, Ә. Гаффар үз авылдашы Кәримулла Гатиятуллинга багышланган «Яшиселәр алда иде» повестен яза. Аңарда ул очерк стиленнән тулысынча диярлек котыла алган, әдәби тасвир стихиясенә әйләнеп кайткан әдип сыйфатында ачыла. Әсәрнең төп каһарманы Сөнгатулла Тимершин исемле, Бөек Ватан сугышында танкист буларак катнашкан, аннары тормышны күтәргән, намус

[1] *Гаффаров Г.Г.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – 2 т. – Б. 309.

иясе кеше. Гомере авылда эш белән, ялны иртәгәгә калдырып узган. Шушындый фәлсәфәләр белән мәгънәле дәвам иткән әсәргә вакыйгаларның җитешмәве кайбер урыннарда үзен сиздерә, анысы. Әмма матур әдәби тел укучыны барыбер дә мавыктыра. Гадәттәгечә, Ә. Гаффар тасвирларга бирелсә, сюжет төземи, вакыйгалар тезмәсеннән читләшә, вакыйгалар бәянына күчсә, тасвирлаудан китә. Монда да ул шул ук эздән иҗат итеп бара.

Сөнгатуллага операция булган. Күптән авылына кайтмаган. Аны кызы Мәрзия Казаннан озата килә. Авылларына җитәрәк, ачылып китеп, алда ниләр көтәсен сөйли. Янгын чыгып, Сөнгатулланың ихатасы янып беткән икән. Өлкән улы Муса йортныбашкасы өр-яңадан башка йорт төзеткән, хәтта коймаларынабаганаларына кадәр. Кече улы Фәрхаднең, армия сафларында һәлак булып, кайтарылып җирләнүен дә этисе авылда гына белә. Ул герой икән, аңа алтын йолдыз бирәселәр, аны Сөнгатуллага тапшырасылар, ди.

Повесть натурализм һәм романтизм синтезында язылган. Шуның аркасында ышандыра да, очы-очка ялгана алмыйча аптырата да. Ә. Гаффарның әдәби уйдырмалары табигый булмаганча арттыруларга корылсалар да, тасвирларына могҗизалык өстәүләре белән шул ук вакытта акланалар да. Автор сюжетсыз әсәрен дә укылырлык итү осталыгына шушылай ирешкән. Мәгънәле, зирәк фикерләр белән сугарылган урыннар да кызыклы. Бу повестьның төрле стильләр синтезына корылуы да автор каләменең аерым уңышы буларак бәяләнергә тиеш.

«Олы юлның тузаны» романын Ә. Гаффар туган авылы Олы Әшнәктә һәм Казанда 1986–1988 елларда иҗат итүен әсәре ахырында күрсәтә. Катлаулы, күптөрле юнәлештәге, ярым хыялый, ярым реалистик рәвештә язылган. Вакыйгалар Бөек Октябрь революциясе елларыннан алып советлар иле таркалып төшкән чоргача китерелеп, олы бер дәвернең төрле вакыйгаларын, колхозлашу, Бөек Ватан сугышы, Хрущев заманы, Әфган сугышы елларын, берсеннән-берсенә күчә-күчә йөреп, үзара бер мәгънәви җепкә тезеп яктырта. Үзәктә бернинди вөҗдан, намус, оят тойгылары җаннарында калмаган Нәймүшин Солтан һәм әфганчы Масленников Степанның рус зираты каберлекләре өстендәге агач тәреләрне ватып учак ягулары, вандализмы сурәтләнелә. Мондый коточыргыч

вакыйгаларны язучының җитди рәвештә тасвирлап, матур һәм мәгънәле фикерләр белән үреп барулары тәмам хәйран итә. Аңарда шул чорга хас дөнья әдәбиятлары үсеше тенденцияләре чагыла. Бу романны татар әдәбиятында постмодернизмның иң югары үрнәкләреннән берсе буларак бәяләргә тиешбез. Совет җәмгыятенең череп таркала баруы аңарда бар тулылыгы белән чагылган. Солтан белән Степан полковник Кулунчаков склебына диварын лом белән тишеп керәләр. Аннан аның табутын сөйрәп чыгарып, ачып, мыскыллап түбәнсетеп, елга буйлап агызып җибәрәләр. Аларның бу гамәлләренә параллель рәвештә Солтанның бабаларыннан Нәймүш, Чаныш, Кадрәк тормышлары сөйләнелә. Вакыйгалар шулкадәр тыгыз үрелә, тасвирлар камил һәм җитди рәвештә бирелеп, мондый эчтәлектәге әсәрләрне кабул итәргә әзер булмаган укучыны тәмам бутап бетерә. Әсәрдә менә шул саташуны булдырмый йөртүче якты хис көче сүрәнрәк сыман. Ә аның көчле булуы постмодернистик әсәрләр өчен үтә дә шарт.

Каберлекне калдырып кайтып киткәч тә, бу ике мордар кабат киләләр. Лом һәм бау онытылып калган икән. Әмма көймәләре туктый, ягулыгы бетә. Күрәләр, полковникның табуты кире йөзеп килгән. Бу Кадриянең эшеме? Табутны кабат склепка сөйрәп кертәләр. Шунда таш ишелеп төшеп, нарат авып, аларны склепта бикләп калдыра.

Әсәрдә параллель вакыйгаларның берсе – сандугач язмышы, тагын да аерым кертелгән, әмма вакыйгаларга кушылып киткән җир асты елгасы белән югарыдан аккан елга язмышы бар. Солтанның бабалары Чаныш белән Кадрәк олы балык тотканнар. Әмма ул судагы подвалда икән. Аны тартып чыгарырга трактор сорап китертәләр. Халык җыела. Балык – кырпы-белуга икән. Бу вакыйгалар белән бергә Солтанның бабалары Кадрәк, шулай ук Чаныш, полковник Кулунчаков һәм Нәймүш, Мария, Кадрия мәхәббәтләре дә тезмә-тезмә ачык тасвирланып, ничәмә үлемнәр бергә кушылып китеп, Шәмгун картның мүкләк сыеры белән бәйле сюжетлар, авылга күселәр һөҗүме, атлар белән бергә егетләрнең кайтмаска китеп барулары, аларның еракта удар төзелештә булып, артларыннан кызларның юлга чыгулары хакында да шашынып, буталып, саташып укыйсың. Караңгы романтик тойгылар да калмый, һәммәсе кузгатыла.

Бу романы белән Ә. Гаффар үз юлын, үз стилен тапкан һәм ныгыткан әдип буларак күренә. Ул «Әҗәт», «Ир», «Гозер» әсәрләре белән бер дулкында туып, чын постмодернистизм юлына баскан әдипнең иҗат җимеше дип бәяләнә ала. Бу романында Ә. Гаффар үзен зур язучы, көчле тасвирчы һәм тапкыр сүз иясе буларак тулысынча күрсәтә алган. Аңа шушы юлында калырга, аннан чыкмаска, аны дәвам итеп, иҗатында тагын да камилләшергә мөмкин иде югыйсә. Ярым уйдырма вакыйгалар белән реалистик күзаллауларның үзара катнашып китүләре, гаскәриләрнең сугыш уеннары, шартлатулары, өстән аккан суның түбәнгә убылуы, артыгы белән арттырулар, боларны чын хакыйкать буларак җөпләп-тәмләп тасвир итүләр – һәммәсе романны мәгънәви яктан шактый катлауландыра һәм мавыктыргыч итә. Әмма күңелне тәмам ялыктыра да.

Романны автор вакыйгалар алмашы калейдоскобына корган. Бу алым аңа данлыклы советлар хөкүмәтенең халык хисабына яшәвен һәм моның гаделсезлектән гыйбарәт икәнлеген сурәтләргә мөмкинлек биргән. Әсәр Көнбатышның коточыргыч романнары рухында язылган. Ә. Гаффарның күңел дөньясы да, фикерләү алымнары да, тойгы-хисләр чуарлыгыннан тәм табулары да нәкъ шулар рухындагы әдип булып формалашуына китергән. Ни сәбәпледер ул аңардан һаман да тайпылган, әмма барыбер дә шул юлга кайтып төшә алган. «Олы юлның тузаны» Ә. Гаффарның әдәбиятта триумфы буларак бәяләнергә тиеш. Тик шунысы бар: бу юнәлештәге әсәрләрне гомуми әдәби процессның уңышы дияргә ярамый. Гомуми үсешнең әйдәүчесе – реализм, әлбәттә. Әдип моны яхшы аңлаган, шуңа да постмодернизм юнәлешендәге уңышларын дәвам итә алмаган, алардан ваз кичкәндәй, традицион реалистик һәм романтик юнәлешләрдә иҗади эзләнүләре нәтиҗәсе булган «Дәрья башы» повестен язган. Ә рухы барыбер дә үз ягына тарткан. 1990 елларда язган «Богау» романы шул хакта сөйли.

«Дәрья башы» повестен Ә. Гаффар 1995 елда иҗат итә. Аның сюжеты Габдулла Тукайның Казаннан Җаек шәһәренә 9 яшендә китерелү вакыйгаларына багышланган, каршы алулары турында. Әсәр тулысынча диярлек хыял белән тудырылган, шунлыктан анда хаталы күзаллаулар белән бергә табигый булмаган вакыйгалар да урын алган, хәтта күпчелек шәхесләр дә тарихта бөтенләй башкалар. Фактларны җентекле өйрәнмәү тарихи шәхесләрне ача алмый,

билгеле. Шул сәбәпле булыр, повесть кинәт өзелеп кала, вакыйгаларның бирелешеннән авторның киң масштаблы әсәр ясарга алынуы тоемланып кына кала. Әсәрне Габдулла Тукайга бәйле дип исәпләргә ярыйдырмы икән?

Ә. Гаффарның 1996 елда иҗат иткән «Богау» романы исереп саташкан «бераз адәми затлар, бераз шүрәлеләр»[1] турында. Әсәрдә әле шүрәлеләрнең тормышы, аларның үзара әйткәләшүләре, юктан да котырынулары тәфсилле сурәтләнелә, әле кешеләр тормышы языла, әле алар үзара кушылып китәләр. Мондый манерада иҗат итүе Ә. Гаффарның постмодернистик алымнарны кыю сынап каравыннан килә. Автор романын югары әдәби зәвыкта язарга омтылышы белән зур, кыю адым ясаган. Әмма әсәргә киңлек, фикер-мәгънә көче җитми. Роман уңышлы барып чыкмаган дигән ашыгыч нәтиҗә ясау да урынсыз булыр иде.

Ә. Гаффар драматургия өлкәсендә дә шактый уңышлы эшли. 1982 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Язлар моңы» дип аталган пьесалар җыентыгы дөнья күрә. Аларда ул әдәби күренешләрне символ-кинаяләр синтезында кора. «Иртәгә улың булам» (1977). «Язлар моңы» (1978), «Җиләк вакыты бер генә» (1979), «Соңгы ләкләк»» (1980), «Өч сорауга бер җавап» (1980), «Бер картлыкта, бер яшьлектә» (1981), «Мунча көне» (1982) пьесалары алданрак язган хикәяләре мотивларына нигезләнгәннәр. Тарихи шәхесләр тормышына багышланган драмалары схематик рухта язылсалар да, бу пьесаларының чагыштырмача уңышлы булуларын белдерми узу мөмкин түгел. Театр тәнкыйтьчесе Д. Гыймранова «Язлар моңы»нда, мәсәлән, олы мәгънәләр күргән, мәкаләсендә авторның уңышын югары бәяләгән[2].

«Язлар моңы», ике бүлекле («пәрдә» төшенчәсе әсәрдә кулланылмаган) драма әсәре буларак, авторның томлыкларында тәкъдим ителә. Беренче бүлек «Сугыш җыры» дип аталган. Мистик башлангыч белән сугарылган вакыйгалар белән әсәр башлана. Сәгыйдулла да, Ярми дә үткән тормышларына үз мөнәсәбәтләрен белдереп алалар да югалалар. Әсәр барышында бу аларның кешеләр күңелендә калган сурәтләре генә икәнлеген аңларга була. Әмма өрәкләре

---

[1] *Гаффаров Г.Г.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. – 2 т. – Б. 670.

[2] *Гыймранова Д.* Язлар моңы // Социалистик Татарстан. – 1978. – 29 авг.

вакыйгалар барышында үз фикерләре белән катнашып китәләр. Аларның әйткән сүзләреннән тормышны дөрес аңлый башлаган кебек буласың. Ә. Гаффарның сәхнә әсәрләренә хас булганча, һәр персонажы акыллы һәм дөрес сүзләр генә сөйли, әмма алар арасында һаман да аңлашылмаучылык, бер-берсен кабул итә алмау, аңламау калкып чыгып тора. Шушылар аркасында мәгънәләр бутала һәм эчтәлек катлаулана бара, инде генә чишелергә тиешле мәсьәлә дә авырлаша. Ә мондый язу манерасы драма әсәрләрен күңелсезли, сәхнәдә барганы очракта, тамашачыны ялыктыра. «Язлар моңы» Сәгыйдулланың мәхәббәте көче, Фәрдانәнең гүяки битарафлыгы, Сараның сабырлыгы, Ярминең бу хәлләрне аңлавы белән озатылып барыла, Хөрмәт белән Люциянең бәхетле мәхәббәт язмышы тыныч тормышның өстенлеге буларак аңлашыла. Бөек Ватан сугышы кешеләрне гариплэп кенә калмаган, аларның хис-тойгыларын да бозган, шулай аларны бәхетсез ясаган дигән фикергә килми мөмкин түгел. Сугыш белән тугры мәхәббәт ярәшә алмыйлар икән, бары тик тыныч тормыш кына кешеләрне бәхетләре белән кавыштыра, дисең. Автор әсәренең икенче бүлеген «Сагыш җыры» исеме белән атаган. Сәгыйдулланың җырын Хөрмәт отып алганыннан чыгып, бу җыр әле тормышта онытылмаячак дигән фикергә киләсең һәм «Язлар моңы» нәрсә хакында икән соң дигән уйда каласың. Әсәрнең эчке мантыйгы булырга тиеш түгелмени? Хәер, Ә. Гаффарның башка драмалары һәм прозасы белән танышканда да, шушылай төрле фикер юнәлешләрендә язуына карап, иҗат манерасының төп үзенчәлекләреннән берсе – әсәрләрендә үзара каршылыклы, хәтта әдәби мантыйкка сыеп бетә алмаган тармаклы фикерләр уздыруы икәнлеген төшенәсең.

Шул ук 1977–1978 елларда ул «Җиләк вакыты бер генә» дип аталган пьесасын яза. Аның жанрын «ике пәрдәле драма» дип билгеләгән. Эчке һәм тышкы мәгънәләр, зирәк, акыллы сүзләр, әйткәләшүләр, кычкырышулар белән дыңгычлап тутырылган бу әсәре дә төрлечә юнәлешләрдә кабул ителә. Төп персонаж Раушанның күренешләрдә кырыкка төрләнүе кызыклы да, гаҗәп тә. Вакыйгалар да гайре табигый, ышандыралар да, ышандырмыйлар да. Әмма кызыклы һәм көлкеле килеп чыкканнар. Беренче күренеш ишегалдына кайтарып куелган шәрә хатын-кыз сыны белән бәйле катлаулы тойгы һәм хисләр эчендә озатылып барыла, аны патефон

тәлинкәсе белән бәйле вакыйгалар үзгәртеп җибәрә, дәвамы мунча ягу һәм Раушанның улы булганлыгы хакында сөйләшүләр белән озатыла барыла. Автор драманың ул пәрдәсен «Зөфаф кичәсе» дип атаган, икенчесенә «Дөнья җылысы» дигән исем куйган. Җиләк вакытының бер генә булуы ачыкланганы кебек, утын вакыты алга таба чишелә. Кинаяләрне автор персонажларның бәхәсле сөйләшүләре-тарткалашулары эчендә матур бирә. Шәрифел янына Раушан председатель булып эшләгән дәверендә йөргән булган. Әмма бергә яшәп китмәгәннәр. Уллары Рашат үскән, инде студент егет. Менә ул да кайтып килергә тиеш. Раушанның Җәваһирәсе бар, гаиләсе. Әсәрнең башыннан ахырынача персонажларның бик тә мәгънәле, төртмәле, акыллы сүзләр белән әйткәләшкәндәй авылчарак сөйләшүләре, гаҗәеп эрудит булулары көлке тудырмый калмый.

Яшьләрнең умарталыкта ял итүләре белән бәйле «Соңгы ләкләк» әсәре «Ике кисәкле драма» дип аталган. Ул да шул ук елларда язылган. Аны замана тормышына сатира буларак кабул итәргә була. Умартачы Мөкатдәс картның карт биясе колынлау һәм үлү дә, ана ләкләкнең үзен үзе һәлак итүе дә – болары төп символлар. Аларны ачарга тиешле башка төрле кинаяләр дә драмада җитәрлек. Ә. Гаффар барча персонажларын да каршылыклы хис-тойгылар эчендә яшәүчеләр буларак тасвирлый. Арада Шәмсия батыр кыз кебек. Беренче пәрдәдәге ау мылтыгы әсәрдә берничә тапкыр ата. Бер атуында Шәмсия кыр казын бәреп төшерә, икенче тапкырында Аллаһияр үзен үзе үтермәкче. Былтыр батып үлгән Рафаэльнең үлеме сәбәпләрен ачыкларга омтылышлар да, мәхәббәт һәм нәфрәт тойгылары белән яшәүләре дә әсәр персонажларын катлаулы һәм авыр холыклы шәхесләр буларак тасвирланулары да күңелгә төрлечә тәэсир итә.

Ә. Гаффар һәр каләм очына килгәнне төзәтеп тормыйча язган кебек итеп үзен күрсәтергә тырышмый да кебек. «Чатта» дип аталган «бер пәрдәлек пьеса»сы да кызыклы гына. Әмма шул ук әйткәләшү, төртмә сөйләшү белән бергә белем, аң, тапкыр сүз үрнәкләрен күрсәтүләре белән персонажлары аптыраашта калдыручан. Кешеләр болай ук булмыйлардыр сыман. Әмма бар икәннәр, әдипнең күңелендә генә булса да яшиләр.

2004–2005 елларда Ә. Гаффар «Күзләремне тутырып» дип аталган ике пәрдәле, сигез күренешле драма яза, «Кояш тотыл-

ганда» дигән «әкият-драма»сы да, «Ышанырга кирәк, капитан!» «драматик хикәясе» дә кызыклы гына. Автор боларда да кинаяле-символик эчтәлек белән эш итә, әкият-драмасында Мәкер, Хыянәт аерым персонажлар кыяфәтен ала. Ә. Гаффар тирән эчтәлекле һәм мәгънәле фикерләр белән эш итәргә яратуын аларда да сиздереп тора. Табигый булмаган персонажларның гайре-табигый шартларда һәм табигый күренешләрдә яшәүләре аңа символик мәгънәләрне бирергә мөмкинлек ача. Хыялый сурәттә күзалланырга мөмкин очракларны да тормышта бара, булып тора рәвешендә тасвирлый белүе Ә. Гаффарны заманча кызыклы әдипләрдән берсе итә.

Татар әдәбияты тарихының 1970–1980 еллары проза үсешендә Ә. Гаффар аерым бер тармакны, сюжетсыз бирү юлын үз алымнары белән ныгытып, аны куәтле агымда алга алып киткән әдипләребезнең берсе булды. Шул юл белән янәшә ул романтизм һәм реализмга да хезмәт итәргә тырышты. Аңа ярым хыялый, ярым хакыйкый вакыйгаларны һәм күренешләрне киңкырлы тасвирларда бирә алуда һичбер язучы тиңләшә алмады. Шушы ягы белән үз укучыларын тапты. Зирәк фикерле, бәхәстә җиңелмәс тапкыр каһарманнары тормыш дәрте белән сугарылган булулары белән укучыны мавыктыра алырлык эшләнелгән булып чыктылар. Ә. Гаффар татар әдәбиятында постмодернистик алымнарны тудыруда катнашкан һәм үстергән әдип сыйфатында хаклы рәвештә күзалланырга тиеш.

*2019–2020*

## ЭЧТӘЛЕК


Аңлашырбыз дип беләм *(Башлам сүз урынына)* . . . . . . . . . . . . . 3

I. Шәхес сүзе

Ренат Харисның мәхәббәт шигъриятендә лирик герой *(Аналитик мәкалә)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

Равил Фәйзуллин шигъриятендә күзәтү һәм шигъри бәян берәмлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17

Роберт Миңнуллинның лирикасы һәм аның «эстетик дөнья сурәте» . 27

Дәрья дәрте *(Рөстәм Мингалим иҗаты хакында)* . . . . . . . . . 42

Зөлфәт шигъриятенең үзенчәлекләре *(Әдәби-эстетик анализ тәҗрибәсеннән)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51

Урал тулпары *(Шагыйрь Р. Ягъфәров иҗаты үзенчәлекләре)* . . . . 59

Флера Тархanованың шигъри гаме *(Шагыйрәнең иҗат мирасын барлаганда)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .63

II. Кичәге сүздән бүгенгегә

Ә. Еники иҗатында әдәби герой концепциясе . . . . . . . . . . . . . . 70

Татар әдәбиятында ироник реализм *(Камил Кәримовның «Ком сәгате» романы уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82

Безнең Фәнзаман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

«Оча торган кешеләр», яки Ак төс тантанасы *(Г. Гыйльманов иҗатына бәйле)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100

III. Кабатланган сүз түгел

Риза Фәхретдиновның ваһһабилар хакында тәнкыйди фикерләре . 105

XIX йөз татар китабы үзенчәлекләре: эчтәлек һәм тәртипләштерү . 109

«Тотса мәскәүләр якаң» *(Алтын Урда шагыйре Ходадат)* . . . . . 116

Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы нигезләре . . . . . . 124

М. Акмулла иҗатының тарихи әһәмияте, әсәрләренә текстологик анализ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170

Акмулланың әдәби мәктәбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187

Г. Тукай иҗатының беренче чоры: асыл хикмәтләре . . . . . . . . . . 192
Г. Тукай «Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты»нда . . . . . . . . . . 205
«Г. Тукай журнализмы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Мәҗит Гафури шигърияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
IV. Аңлап та сөйләргә була
Г. Ибраһимов – экспрессионист әдип . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
Г. Ибраһимов «Мөселман иттифакы» партиясе хакында . . . . . . . 277
Әдәбиятта әдәби-текстологик анализ алымы нигезләре . . . . . . . 284
Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗаты хакында Г. Сәгъди . . . . . 302
Мәхтүмколый шигъриятендә афористик фикерләү алымы үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
Г. Кандалый әсәрләрендә дин әһелләре образлары: әдәби-тарихи мәсьәләләр кысасында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 316
V. Сүзләрме телдә йөрми?
Муса Җәлилнең «идеологик агым шигърияте»ндә тәэссорат тудыру осталыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Татар әдәбият белемендә Гали Халит . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 334
Татар тәнкыйтендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Каләм сүзенең тәме *(Әхәт Гаффар иҗаты)* . . . . . . . . . . . . . . . 347

Научное издание

**Яхин Фарид Закизянович**

**ЦЕНА ЛИТЕРАТУРНОГО СЛОВА**
Сборник научных и литературно-критических
статей о литературе

(на татарском языке)

Редактор *А.А. Давлетова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать 14.12.2020.
Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 21,2. Уч.-изд. л. 21. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12